# Казан утлары

10. 1993



## МӨХТӘРӘМ КАЛӘМДӘШЛӘР,
## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Без Сезне журналыбызның якын дуслары, киңәшчеләре, басмабызның нигезен тәшкилләүче затлар дип саныйбыз. Соңгы 2—3 ел эчендә Сез иҗат иткән әсәрләрнең, язмаларның, хат сөземтәләренең журналда әледән-әле басылып килүе шуңа ачык бер дәлил. Беләсез ки, моңарчы, «Казан утлары» татар халкының төп журналы, аның рухи көзгесе булып килде. Вакытында басылып чыгуы, төрле регионнарда таралуы һәм тиражы күплеге ягыннан да хәлебез чагыштырмача начар түгел иде. Әйтик, кайбер журналлар, газеталарның тиражы 10—12, хәтта 2—3 мең данә булганда, без әле бүгенге көндә 26 мең данә белән чыгып киләбез. Әмма лидерлык дәрәҗәсен саклау елдан-ел кыенлашып бара. Хикмәт — башка басмалар белән конкурентлыктан бигрәк, татарлар яши торган бүтән төбәкләр белән икътисади, мәдәни бәйләнешләрнең өзелебрәк китү сәбәпле (Урта Азия, Себер, Балтыйк буе һ. б.), яздырып алучыларның саны катастрофик кимүдә. Төп әбүнәчеләребез (подписчиклар), нигездә, Татарстанда гына калып бара. Өстәвенә, кыйммәтчелек тә тез астына суга. Безнең журналны төп алдыручылар — пенсионерлар, укытучылар, укучы яшьләр өчен бу бәяләр аеруча нык сиздерә. Кыскасы, журнал язмышы, анык киләчәге хәзер һәммәбезнең, бигрәк тә журнал активистларының эшчәнлегенә бәйләнгән. Шуңа күрә редакция коллективы исеменнән Сезгә мөрәҗәгать итәбез һәм сорыйбыз: Сез, иң әүвәл, үзегез вакытында журналга язылып куйсагыз икән! Ул гына да түгел, якыннарыгыз, дусларыгыз, ерактагы яки Татарстандагы танышларыгызны күндереп-үгетләп, ким дигәндә берәр дистә данә журнал алдыруны оештыруыгызны сорыйбыз. Сез безнең редакция хезмәткәрләренең эчке халәтен, гомумән, милли басмаларның асыл хәлен анык күз алдына китерәсез булыр. Журналны саклау — халык рухын саклау, җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген ныгыту икәнен дә яхшы аңлыйсыздыр дип ышанабыз.

«Казан утлары»
журналы коллективы.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(852)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ПУБЛИЦИСТИКА

Татулык — иң зур байлыгыбыз *(Казан шәһәр хакимияте башлыгы К. Ш. Исхаков белән әңгәмә)* . . . 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ПОЭЗИЯ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Йөгез, бер дога! *Роман-хатирә* . . . 7

Р. ХИСМӘТУЛЛА. Су ялваруы. *Шигырьләр* 100

С. МУЛЛА ГАЛИ. Биздерсәләр туган җиреннән. *Шигырьләр* . . . 106

Н. ГАМБӘР. Ма-ту-у-у!!! *Эссэ* . . . 110

М. ГАЛИ. Сабый Тукай. *Шигырьләр* . . . 116

Х. МӨДӘРРИСОВА. Былтыргы көз. *Шигырьләр* . . . 120

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. ХӘКИМ. Империя кояшы батканда . . . 123

М. МӘҺДИЕВ. Татар зыялысы... Ул — кем? . 143

Ә. БОРҺАНОВ. Сез кем белән, зыялылар? . . 147

ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ

М. ЮНЫС. Юлыбыздагы сикәлтәләр, упкыннар . . . 151

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

А. Г. РҮРЛИХ. Татарлар: бер милләтме, әллә берничәме? . . . 157

Ә. ГАЛЛӘМЕВА. Җәмгыятьнең бер чире . . 167

Д. ИСХАКОВ. Бер сорауга — бер җавап . . . 172

КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР ХӘЗИНӘСЕ

Ф. ТӨРЕКМӘН. Юныс Әмрәнең кешегә мәхәббәте . . . 174

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫ

Р. ГАНИЕВА. Нәҗип Думави: Шәрекъме, Гарепме? . . . 179

Латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . 183
Тарих сәхифәләрендә — татар шәхесләре . . 184

Төркия илчесе — «Заман» . . . . . . . . . 186
Котлыйбыз . . . . . . . . . . . . . . 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 188

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Публицистика»: Интервью Р. НИЗАМИЕВА с мэром города Казани К. Ш. ИСХАКОВЫМ.
«Проза и поэзия»: роман-воспоминание А. ГИЛЯЗОВА, эссэ Н. ГАМБАРОВА; стихи Р. ХИСМАТУЛЛИНА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА, М. ГАЛИ, Х. МУДАРРИСОВОЙ.
«Публицистика»: статьи Р. ХАКИМА «Крах империи», М. МАГДЕЕВА «Татарский интеллигент... Кто он?» А. БУРГАНОВА «С кем вы, интеллигенты?»
«Дискуссия»: статья М. ЮНЫСА «Барьеры на нашем пути».
К истории народа»: статьи А. Г. РОРЛИХА «Татары: одна нация или несколько?», А. ГАЛЛЯМОВОЙ «Болезнь общества», Д. ИСХАКОВА «История демографии татар».
«Дружба литератур — дружба народов»: статья Ф. ТУРКМЕНА. «Любовь к человеку в творчестве Ю. Амры».
«К истории культуры»: статья Р. ГАНЕЕВОЙ «Наджип Думави: Восток или Запад?»
На наших обложках: «Колыбель» — картина алматинского художника К. Муллашева, известный поэт Роберт Ахметзянов.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.09.93 ел. Басарга кул куелды 4.10.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 000. Заказ Я-552. Бәясе 30 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
© «Казан утлары», 1993 ел.

# ПУБЛИЦИСТИКА



## ТАТУЛЫК — ИҢ ЗУР БАЙЛЫГЫБЫЗ

**Шәһәр!.. Аның үз тормышы, үз сулышы, үз мәшәкатьләре бар. Төзелеш, юл-транспорт, урам-бакчаларның чисталыгы, яшелләндерү зоналары, архитектура байлыкларының саклануы һ. б. Шәһәр үзе генә аерым яши алмый, аны эш сөючән кешеләр, хезмәт осталары яшәтә, яңарта, киләчәк буыннарга бүләк итеп калдыра. Шәһәр кешеләренең тормышы, ялы, көнкүреше, аларны социаль яклау турында да даими кайгыртырга кирәк. СССРның элекке республикалары, өлкәләре белән икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр шартлап өзелгән заманда бу бигрәк тә шулай.**

**Кыскасы, шәһәр хуҗалыгы — катлаулы тармакларның берсе ул. Әйтик, Татарстанның башкаласы Казанда 1 миллионнан артык кеше яши. Транспорт дигәндә, автобусларның — 80, трамвайларның — 17, троллейбусларның 12 маршрут сызыгы бар. Дистәләгән завод-фабрикаларны, югары уку йортларын һ. б. санап китсәңме... Барысын-барысын исәпкә алырга, шәһәр пульсын кулдан ычкындырмаска, аның һәр тибешен игътибар үзәгендә тотарга кирәк. Мондый эшләр белән, хәзергечә итеп әйтсәк, турыдан-туры шәһәр мэры шөгыльләнә. Кем ул? Нинди уй-ниятләр белән яши? «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиев үткәргән әңгәмә аша сез, хөрмәтле укучылар, әнә шушы сорауларга да азмы-күпме җавап табарсыз.**

(КАЗАН ШӘҺӘР ХАКИМИЯТЕ БАШЛЫГЫ
**КАМИЛ ШАМИЛ УЛЫ ИСХАКОВ** БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ)

— *Дөньяда әллә ничаклы һөнәр һәм шуның санынча һөнәр ияләре бар. Әйтергә кирәк, теләсә кайсы эшнең уңай һәм кыен яклары була. Мәсәлән, Сезнең бу җаваплы эшегездә иң кыены нәрсә?*

— Кызыклы сорау бу. Мөгаен, иң кыены — вакыт дигән нәрсәнең җитмәвеләр. Вакытын кая куярга, нинди шөгыльгә юнәлтергә дип аптыраучылар да бардыр бу тормышта. Без исә — җитәкчелек халкы — чыннан да, зур һәм җаваплы эшкә җигелгәнбез. Мөгълүм булганча, атнада нибары 7 көн бар. Менә шуның 7 көнендә дә ихтыярсыз эшләргә туры килә безгә. Бу — һич тә зарланып әйтүдән түгел. Кайсыдыр язучыбыз әйтмешли, үзебез сайлап алган язмыш... Ял көннәрендә дә эш-

ләү — вакытны дөрес итеп оештыра белмәүдән түгел, ә бәлки шәһәребез өчен, аның яшәү мөмкинлекләрен яхшырак тәэмин итүдән килеп чыга. Тәүлектә нибары 24 сәгать бар, менә шуңарга сыеп бетеп булмый. Әгәр бер тәүлектә утыз сәгать булса икән, уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, без, мөгаен, күбрәк нәрсәләргә ирешә алыр идек.

*— Игътибар иткәнегез бардыр, гадәттә, әдәбият сөючеләрдә язучының биографиясе белән кызыксыну көчле була. Бу, әлбәттә, әдипнең кем икәнен белергә, аның шәхесен аңларга тырышудан килә. Соңгы елларда, ягъни хәбәрдарлык канат җәйгәннән соң, җитәкчеләрнең биографиясе белән кызыксыну да көчәйде. Шуңа күрә, Камил Шамилевич, укучыларыбызга үзегез турында үзегез азмы-күпме сөйләп китсәгез иде.*

— Гомумән, минем биографиям меңләгән казанлылардан әллә ни аерылмыйдыр. Бер аермасы шунда булырга мөмкин: миңа үзем өчен генә түгел, күпвакыт хезмәттәшләрем өчен дә җавап бирергә туры килде. Җитәкчелек эшендә табигый хәлләр бу, күрәсең.

Казанда, эшче гаиләсендә тудым. Сигезенче класстан соң хезмәт биографиямне электромонтер буларак башлап җибәргән идем. Эштән аерылмый гына Казан элемтә электротехникумын тәмамладым. Казан дәүләт университетының физика факультетына кичке бүлеккә укырга кердем. Аннары 1969 елда шушы факультетның көндезге бүлегенә күчтем.

Университетны тәмамлап, бераз вакыт комсомолда кайнаганнан соң, студентларның «Алгоритм» дип аталган Казан фәнни-укыту үзәгендә директор булып эшләдем. Теге елларга хас булганча, партиянең Совет райкомында беренче секретарь вазифаларын да башкарырга туры килде. 1989 елның февралендә халык депутатларының Казан шәһәр башкарма комитеты рәисе итеп сайладылар. Инде менә 1992 елдан бирле — Казан шәһәр хакимияте башлыгы вазифасындамын.

Гаилә хәленә килсәк, хатыным һәм ике кызым бар. Күптән түгел «бабай» булдым. Халыкның: «Балдан татлы ни татлы, балдан да оныкм татлы», — дигән сүзләрен хәзер мин шәхси тәҗрибәмдә бик яхшы аңлыйм.

*— Күпләр хәтерлидер әле, Сез заманында спорт мастеры булган кеше. Ә менә хәзер, дәүләт эшләренә күмелгәч, спорт белән шөгыльләнергә вакытыгыз кала микән?*

— Сезнең бу мәгълүматегез бераз гына ачыклауны сорый. Мин, чыннан да, кайчандыр спорт мастерлыгына кандидат идем. Ләкин, зыян-җәрәхәт алу сәбәпле, спорт мастеры программасын үти алмадым. Бик кызганыч, әлбәттә. Әмма хәзер спорт белән шөгыльләнү өчен вакыт калмый диярлек. Шулай да яшь вакытта спорт белән дус булу миңа бик күп файда китерде дип саныйм. Нәкъ менә шуңарга булса кирәк, авырып-чирләп ятканымны хәтерләмим диярлек. Шәһәр башлыгы буларак, беләсезме, миңа көн саен бик күп сорауларны хәл итәргә, бихисап мәсьәләләрне чишәргә туры килә. Әгәр яшьрәк чакта спортта физик чыныгу алмасам, мөгаен, бу кадәр җаваплы мәшәкатьләрне күтәрү җинелдән булмас иде.

Сезнең журналны яшьләр дә укыйлар дип беләм. Шуңа күрә мин аларга, спорт белән дус булудан курыкмагыз, дигән гап-гади киңәшемне бирер идем.

*— Казан — Татарстан Республикасының башкаласы, горурлыгы. Аны җөмһүриятебезнең визит карточкасы дип тә әйтергә мөмкин. Чит илдән килгән кунаклар, гадәттә, иң элек шәһәрнең йөзенә, урамнарының чисталыгына, архитектура үрнәкләренең саклануышына игътибар итәләр. Дөресен әйткәндә, шәһәрнең шушы проблемаларына элек-электән игътибар җитеп бетми шикелле. Әйтик, Болакны тәртипкә китерү турындагы карарга заманында Калинин бабай кул куйган документлар барлыгы да билгеле. Нәрсә, һаман да вакыт үзар, без һаман да акчасыз һәм мескен булып яшәрбез микәнни? Кыскасы, Сез шәһәребез алга таба ничегрәк үсәргә тиеш дип күзаллыйсыз?*

— Әлбәттә, Татарстанның башкаласы бар яктан да гүзәл, матур, күркәм булырга тиеш. «Мин Казанда яшим!» — дип горурланып әйтерлек булсын. Минемчә, горурланырга җитди нигез бар. Чөнки Татарстан үзенең суверенитетын — мөстәкыйльлеген игълан итте. Дәүләтчелегебезне ныгыту юнәлешендә уңышлы гына адымнар ясала тора. Чит илләр белән элемтәләребез арта. Татарстанның да, аның башкаласы Казанның да статусы хәзер нык үзгәрде. Чит илдән килүчеләр — гади бер кунакмы ул, әллә югары дәрәҗәдәге рәсми кешеме — элекке СССРның, бүгенге Россиянең бер шәһәренә дип түгел, нәкъ менә яшь Татарстанның баш-

каласына дип киләләр. Шуңа күрә дә Казаныбызны төзек, күркәм шәһәр итеп тоту хәзер аеруча мөһим. Мәскәүлеләр яки ленинградлылар безгә карап сокланырлык, көнләшерлек булсын. Бу юнәлештә, әлбәттә, эшлисе эшләребез күп әле.

Әйтик, шәһәр Советының соңгы сессиясендә җимерек өйләр, иске-тузык кварталларны бетерү мәсьәләсендә программа расланды. Һәм мин яңа төзелгән йортларга беренче чиратта шундый кварталлардан килүчеләрнең килеп урнашуы өчен кулымнан килгәнчә тырышачакмын. Казанның үзәк өлешенә килсәк исә, иске-тарихи байлыкларны саклаган хәлдә, аның йөзен тагын да яхшыртасы бар. Шәһәребезнең тарихи үзенчәлекләре яңа микрорайоннарда түгел, нәкъ менә үзәк өлештә саклана. Шуңа күрә төзәтү, яңарту, ягъни реставрация һәм реконструкция эшләрен онытып җибәрергә ярамый безгә. Шәһәребезнең киләчәге матур булыр, мин моңа ышанам.

— *Сез — шәһәр кешесе, миллионлы шәһәр башлыгы. Ә менә авылны, аның кешеләрен һәм проблемаларын яхшы беләсезме? Гомумән, Сезне авыл белән нәрсә дә булса бәйләп торамы?*

— Күп нәрсәләр бәйли дип саныйм. Әти-әниләрем — Әтнә һәм Арча районнарыннан. Мин үзем поселокта үстем. Якташларым, авыл хезмәтчәннәре белән элемтәдә булырга тырышам. Урынбасарларымның берсе турыдан-туры авыл хуҗалыгы мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Үзегез әйтмешли, миллионлы шәһәрне туйдырырга да кирәк ич әле, ә бу эш авылдан, аның ярдәменнән башка мөмкин түгел. Шәһәр хакимияте башлыгы буларак, минем күз карашым авылга, аның хезмәтчәннәренә дә төбәлгән.

— *Бөтендөнья татарлары конгрессы көннәрендә Сез урамда халык белән сөйләшергә вакыт таптыгыз. Ничек уйлыйсыз, менә шул чакта: «Сез татарның Дудаевы булырга әзерме?» — дигән сорауны яшьләр ни өчен нәкъ менә Сезгә бирделәр икән?*

— Әйе, андый хәл булды. Андый сорауга мин үзем дә гаҗәпләндем. Дудаевның бик популяр чагы иде бит ул чакта. Хәзер Дудаев та икенчерәк, андагы хәлләр дә бүтәнчәрәк. Мине белгән кешеләр миңа карата «диктатор» дип әйтмәсләр. Әгәр мин бик таләпчән икәнмен, монысы — башка мәсьәлә. Мин үзебезнең шәһәрне яратам, аның кешеләре яхшырак яшәсен дип телим. Шушы юнәлештә миңа ярдәм итүчеләр — минем дусларым, фикердәшләрем, хезмәттәшләрем. Шушындый ярдәм, аңлашу юк икән, алар миңа юлдаш түгел. Бу тормышта һәркемнең үз урыны бар дип саныйм. Кеше шунда гына җәмгыятькә файда китерә ала. Үзе өчен дә күңел шатлыгы таба.

— *Ялгышмасам, Татарстан Югары Советының бүгенге депутатлары арасында Сез — иң стажлы депутатларның берсе. Хәтерлик, тырышып-тырышып социализм төзеп ятканда бүтәнчәрәк яшәү заманнары да бар иде. Заманалар үзгәрде. Вакыт әнә бик күпләрне «җиз иләк» аша үткәрде. Кемнәрдер яңача яшәргә һәм эшләргә бик тиз генә өйрәнеп китте. Кемнәрдер, ике каен арасында адашкан кебек, ике заман арасында буталып, югалып калды... Сез бүгенге хакимиятнең шактый югары баскычында басып торасыз. Менә шушы биеклектән үткәннәрне һәм бүгенге көнне ничек бәялҙр идегез?*

— Кайсы гына тармакта булсам да, мин намус белән эшләргә тырыштым һәм тырышам. Миңа үзгәрергә, ярашырга тырышу кирәкмәде. Дөньяда күп нәрсәләр үзгәрергә мөмкин, ләкин җаваплылык, дөреслек дигән нәрсәләр һәрвакыт үзгәрешсез кала бит. Мин, бик күп кешеләр шикелле, халыкка, дәүләтебезгә хезмәт итәм. Республикабызның Югары Советында эшләү бик күп вакыт сорый, ләкин мин анда, ягъни югары власть органнары каршында шәһәр һәм аның кешеләре мәнфәгатьләрен кайгырта алам. Яклый алам. Казаныбыз тормышын, сулышын, аның пульсын эшем буенча мин, һәрхәлдә, күпләргә карый яхшырак беләмдер. Кыенлыклар күп. Мәсәлән, кайбер тармакларда производство аксый, халык арасында бай белән ярлыга бүленү процесслары бара, җинаятьчелек үсә. Мин — табигатем белән оптимист кеше. Боларны вакытлы кыенлык дип саныйм. Яхшы заман килеренә ышанам.

— *Татарстан Югары Советына халык депутатлары сайлауның кайнар, мәшәкатьле көннәре истә әле. Көндәлек матбугат битләрендә Сезнең дә сайлау алды*

*платформагыз басылып чыккан иде. Ничек уйлыйсыз, әнә шул сайлау алды платформасындагы вәгъдәләрне үтәүгә ни дәрәҗәдә ирешә алдыгыз икән?*

— Мин 61-нче номерлы Имәнлек (Дубравнин) округыннан Татарстан Югары Советына депутат булып сайландым. Сүз эштән аерылмаска тиеш, дип саныйм. Үземне сайлаучылар төбәгендә еш булам, аларның күбесен биткә-йөзгә дигәндәй, яхшы беләм. Алар, әлбәттә, үзләрен борчыган мәсьәләләр буенча миңа еш мөрәҗәгать итәләр. Бу сорауларның күбесенә җавап табылды. Ләкин күп мәсьәләләрне хәл итәсе бар әле. Мин үз сайлаучыларымның — миңа үз тавышын бирүчеләрнең ышанычын акларга, әйткән вәгъдәләремне конкрет эш белән ныгытырга тырышачакмын.

*— Татар телен дәүләт теле итү турында күптәннән сүз бара. Бу инде законлаштырылды да. Бу юнәлештә, азмы-күпме эшләр дә эшләнә кила. Моны бүген-иртәгә генә тормышка ашыру мөмкин түгел дип уйлыйм. Сорауны кабыргасы белән куясы килә: чынга ашарлык ниятебезме бу, буш хыялга бирелеп, көчне-вакытны әрәм итмибезме?*

— Бик зур һәм әһәмиятле сорау. Өзеп кенә җавап бирү дә кыен. Мин Сезнең, язучы буларак, туган тел өчен борчылуыгызны аңлыйм. Хәлбуки, төрле халык, милләт һәм фаҗигаләребез буталып беткән шәһәрдә татар телен көчле дәрәҗәдә гамәлгә кертү җиңел эш түгел. Миңа калса, моның иң дөрес юлы — эшне акрын-акрын гына тормышка ашыру дөрес булыр. Күреп-ишетеп торасыздыр ич, вокзалларда белдерүләр татарча әйтелә башлады, трамвай-троллейбусларда тукталышларны татарча һәм рус телендә игълан итү дә гадәткә керә. Ике телдә язылып, урам исемнәрен дә яңарту бара. Игътибар иткән булсагыз, быелның май аенда Казан шәһәр администрация башлыгы исеменнән татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертү турында махсус карар кабул ителде. Татар теле акрынлап үз көченә кайтыр һәм теләсә кайда дәүләт теле буларак яңгырар дип саныйм мин.

*— Әдәбиятны яратасызмы, ниләр укыйсыз?*

— Нинди физик «лирик» та булмасын икән! Укырга яратам, ләкин соңгы елларда вакыт җитми дә җитми инде. Татар, рус һәм чит ил классикасын яратам. Көндәлек матбугатны укымый-күзәтми мөмкин түгел — ил-көн тормышын белеп торырга кирәк ич. Газета-журналлар шәһәребез һәм республикабыз турында бик күп проблемаларны, өлгергән мәсьәләләрне күтәреп чыга. Кулны тормыш пульсында тотмый мөмкин түгел.

*— Бу дөньяда күп нәрсәләр ике полюска корылган. Менә, ниһаять, соңгы сорау. Сезне иң нык борчыган һәм иң нык шатландырганы нәрсәләр ул?*

— Мине борчыган сораулар күп. Җинаятьчелек белән көрәш, җәмгыятьтә әхлак югалу, сәүдә торышы, халыкны социаль яклау, төзелеш-ремонт эшләре һәм башкалар, һәм башкалар. Барысын да санап чыгу мөмкин түгел. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен, җимешләрен күрсәң, шуңардан да зуррак бәхет юк. Андый чакта икеләтә, өчләтә энергия белән эшлисең. Ә шулай да иң зур шатлык — мөгаен, казанлыларның дус һәм тату яшәведер. Татулык — иң зур байлыгыбыз. Кайсы милләттән булуга карамастан, казанлылар менә шушы күркәм казанышны югалтмасыннар иде. Кешеләр бер-берсенә елмайса, мәрхәмәтле булса, тормышыбыз да матуррак булачак ич. Башкалабыз Казандагы, гомумән, Татарстан халыклары арасындагы дуслык һәм аңлашып яшәү — ачылмаган хәзинә шикелләрәк. Әйдәгез, без аны бергәләп ачыйк һәм конкрет эш, уй, гамәлләребез белән тулыландырыйк.

*— Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Тормышыгызда һәм җаваплы эшегездә уңышлар юлдаш булсын Сезгә!*

Әңгәмәне **Рашат НИЗАМИЕВ** үткәрде.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Аяз Гыйләҗев



# ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА!

РОМАН-ХАТИРӘ

**Күргәнем-кичергәннәрем һәммәсе ошбу китапка теркәлгән. Бер ел мин кара белән яздым — карам бетте. Икенче ел күз яшьләрем белән яздым — алар да кипте. Өченче ел каным белән яздым — каным да җитмәде.**

**Гаяз ИСХАКЫЙ.** «Локман Хәким».

## Беренче бүлек

### 1

**Какую власть все-таки имеют над нами воспоминания!**

Юрий КАЗАКОВ

«И-и, төрмәнең сөенечле мизгелләре!» — дип башлап китсәм, хөрмәтле укучым: «Бу бәндә әллә әзрәк ычкынганмы?» — дип, рәнҗеп-сүгенеп китапны ябып куярга ашыкма, зинһар! Әгәр бик күпләр күзеннән яшерелгән төрмә тормышы бары тик кайгы-хәсрәттән генә торса, аннан берәү дә исән-аман чыга алмас иде!

Төрмә эчендә — тоткыннарны бергә җыйнап яткырган караңгы дөньяда да нәни генә, чәнти бармак очы хәтле генә юанычлар, хәтта ки

---

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ (1928) — *прозаик, драматург, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, күп санлы китаплар авторы. Казанда яши.*

сөенечләр дә була. Һәр мәхбүскә ияреп, беренче нәүбәттә тынчу, кысан камераларга Өмет керә. Язмышыңны урталай бүлеп тамырыңа балта чапсалар да, адәм балаларының соңгы Өметенә иң явыз җәлладлар да хөкем чыгара алмый. Башың калса — Өмет яши. Һәр төрмәнең үз канун-нары, гадәтләре, төсе, исе, ашатуы үзгә, үзенчә була. Ләкин һәр төрмәдә дә тоткыннар күмәк юаналар, берәүләр капкынга яңарак төшә, икен-челәр читлекләрдә күптәннән саргая, ирек көтеп дөнья белән хушлашып куючылар да очраштыра. Төрмәгә һәркем ияртеп керүгән тормыш өзек-өзек кебек тоелса да, андагы Хәтер чылбыры берчакта да өзелми, һичбер вакыт буш тормаган төрмә тоткыннары юаныч-өметләрен елдан-елга, буыннан-буынга, түкми-чәчми тапшыралар. Төрмәгә килеп кергән сәга-тьтә, синең үтә нык борчылган, тәмам рухың сынган чакта сине ошбу төрмәнең караңгы тарихы белән таныштыра башлыйлар. Иң азакта: «Бу төрмәне төзеткән архитекторның үзен дә утыртып куйганнар!» — дип кыстырып җибәрәләр. «Әһә! — дип юанасың, — шул кирәк ул мөртәткә!» Әйе, — диләр иптәшләрең, — җәһәннәм базын уйлап тапкан адәм актыгы җәзадан коры калырга тиеш түгел! Төрмә тарихын чишәргә алынган тоткыннар бүтән җәзачыларның, төрле елларда монда башлык булып торганнарның, тикшерүчеләрнең булып китүләре хакында сансыз мисал-лар китереп, күңелләрен юаталар.

Ни гаҗәп! Черек күл «кунакханәсе»нең 24 камерасына китереп тык-канның икенче иртәсендә үк коридордан тык-тык атлап берәү килә! Агач аяк! Надзирательгә яман җикеренә бу! Камерадашларым — казанлы Нигъмәт Габит улы Халитов белән Подберезье егете Кәбир Мөхәммәт-шин авызларын ердылар. «Бәй, прокурорны йомдырганнар түгелме?! Әле үткән атнада гына камераларны тикшереп йөргән иде».

Соңыннан мәгълүм булды: прокурор урынбасарын кулга алганнар икән. Мондый сөенечле хәбәрләр төрмәнең калын диварларын гына түгел, Җир шарын үтәли тишеп йөри алалар!

Без утырган, кара даны бик күп ак күңелләргә кара дегет яккан яманаты киң таралган төрмәдән тиз генә котылып чыгу юк икән, тарих аны хәтерләми, буыннар чылбырының хәрәкәтенә андый хәл теркәл-мәгән. Качып чыгу, сакчыларны алдау хакында уйларга да ярамый! Көлке! Әлерәк кенә килеп эләккән, тәҗрибәсез тоткыннар: «Хаталык бу! Мине чыгарачаклар!» — дип хыялланалар икән — бушка! Бер-ике камера аша үтеп, чиркәнчек алып, Рәсәйдәге җәза кануннарының чынбарлыгы белән танышуга, тоткыннар буш хыялларыннан тиз-тиз котылалар. Ияр-теп кергән уйлар бер-бер артлы сүнә, иң ахырга «Амнистия!» дигәне генә кала. Амнистия — төрмәнең какшамас ныклы өмете. Октябрь бәйрәме җитә — өметләнәләр. Яз җилләре исә, Май җитә, күзен сүнгән өметләр тагын терелгәндәй була. Тора-тора тоткын хыялларын үзеннән дә яшерә, тына, басыла. Ярты ел Черек күлдә батар-батмас йөзгән тоткын — ул юридик фәннәр докторы, бер ел тоташ төрмә баландасы чүмергәннәр — профессорлар, арада өчәр ел күлдә быкырдаган бичаралар очрый икән, бел, ул — академик! Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк. Сый-ныф арты сыйныфка күчә барып, барлык «фәннәрнең» кая илткәнен аңлаган тоткын амнистиягә дә өмет итми, төшләрен дә юрамый, вак-төяк җимгә ташланган камерадашларына өстән генә карый. Ул үз-үзенә кереп бикләнә, тимер ишеккә артын куеп баса да тыгыз такталар белән томаланган, пыяласы зәңгәрсу-карага әйләнгән сукыр тәрәзәгә карап тора. Тоткын — уе белән генә бикләрне җимереп, ишек-тәрәзәләрне үтеп чыга, үзе белгән, күңелендә яшереп саклаган ирекле дөньяга барып кайта. Ишеккә әйләнеп тә карамый ул, андый бөек мизгелләрдә, төрмә ишеге тоткынны кертер өчен генә киерелеп ачыла, аның әлегә чыгарыр өчен ачылганы юк.

«Сөенечләр», дидем. Бар алар. Килгән передачаны алу сөенечтер дип әйтерсез инде сез? Әйе, әз-мәз ризык килсә — сөенәсең. Ләкин кытлык совет заманында туганнарыңның, якыннарыңның үз авызларыннан өзеп

туймас төрмә тамагын тыгындырып йөрүләрен уйласаң... передача алуның шатлыгы, җил күзендә утырган шәмдәй дөртләп сүнә. Төрмәдә уйларга вакыт мул!.. Алай да... Берәү дә сине юксынып килеп йөрми икән — беттең. Суык таш диварлар арасына кертеп кыстырылган бөҗәк кенә түгел, син — нул, юк син, кылдый-былдый чүплеккә барган арба күчәреннән төшеп калган сынык чәкүшкә син. Син — дегетле әрем-куралар арасында ятып онытылган файдасыз чөй.

Нигъмәт ага Халитов, уртачарак буйлы, базык татар — передачаларны өзмәс ала. Яшәгән йорты да төрмәдән ерак түгел, Чернышевский урамында, университетның без укып йөргән химия корпусына күрше генә. Бу — бер. Икенчедән, иң мөһиме — Нигъмәт ага сәяси тоткын түгел. Ул Ташаяк урамындагы «Динамо» фабрикасының баш бухгалтеры. Фабрика хуҗалары, аларның ярдәмчеләре, ярдәмчеләренең булышчылары тегеп чыгарган спорт товарларының сортлылыгын бозып, чимал тирәсендә күз буяп менләгән акчаларны җыеп ятканнар да берзаман яман шеш тишелгән! Фабрика директоры Бибишева ханым да, баш инженер Клейнерман да, нәни генә киоскада сәүдә хәйләләренең актыккы буынын тормышка ашырып яткан юаш, итагатьле, күрә карау Исаак Горлицкий да монда. (Без Горлицкий белән алдарак очрашырбыз әле!) Миллионлаган акчалар кул аша шуып торганда Халитовның тормышы муллан булганга охшый. Хатыны иркәли, төрмә хадимнәре дә аның саулыгы, кәефе өчен туктаусыз борчылалар, казна исәбеннән аңа ак калач та эләгә, майда йөзгән карабодай боткасы, пар атып торган коймаклар сәгатеминуты белән өеннән безнең камерага килеп җитәләр. Еш кына ботканың майлы күл уртасында, ботын безнең ач күзләргә чөеп, тавык ята! Чәйне безнең төшкә дә кермәгән алтын кәгазьле шоколад конфит белән генә эчә баш бухгалтер!

Миңа да күчтәнәч килә. Аны миңа университеттагы шәригем, яшәү тарафында бүлмәдәшем Нил Юзиев алып килә. «Күчтәнәчне алдым», — дип имза салганда исем китә, анда: «Тоткынга нинди мөнәсәбәттә торасыз?» — дигән сорауга Нил: «Иптәше», — дип язып куя. Ах, аллам! «Таныш» — дип кенә куясы да бит, Нил төрмә серләрен белми шул. «Иптәше», — дип язган кешеләрнең берзаман кара сукмакка төшәсен белми шул әле! Язса-яза инде, Нил эчкерсез, саф күңелле, ихлас егетләрнең берсе. Ул алып килгән бер-ике бөтен кара икмәк би-ик ярап куя. Ул чагында тәмәкене бик нык пуфылдата башлаган идем, «Норд» папиросы тартам, бер суырсаң, колактан төтене чыга, күздән ярты сәгать яшь ага. Шул агу-тәмәке дә юаныч! Явыз полковник Катерли, 1950 елның 22 мартында, аңгыра пүнәтәйләрен ияртеп, мине алырга килгәч, тентү актына Нилдән дә имза салдырган иде. Шуннан ары минем эшкә аның бер катнашы да юк. Рәхмәт Нилгә, хәтер якты чакта аңа тирән рәхмәтемне җиткереп куйыйм әле! Кемдер явызланып, Нилгә нахак бәлаләр тагып, кара гайбәт тарата икән, ышанмагыз! Каршылыклы, аңлавы үтә кыен заманда безнең ныгып өлгермәгән язмышлар хәл ителгәндә, мәсьәләнең бөтен чарпалышларын, тирән серләрен аңламаган чакта да Нил хак, туры сүзле һәм ихлас булып кала алды. Ә ул заманда, илдәге өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә Черек күл белән бәйләнештә булганда дөрес сүзне әйтү дә, аны кәгазьдә беркетеп калдыру да ифрат авыр адым иде. Бүген: «Без болай идек!.. Без тегеләй була алдык!» — дип тар күкрәкләрен тәүргә маташкан калай әтәчләрне шул чорларның тотрыксыз, караңгы мизгелләрендә күрергә теләр идем мин. Ходай сакласын!

Кәбир Мөхәммәтшин — озын, какча булса да, җилкәсе шактый киң, көрәк куллары эре сөякле тезләренә төшеп җитә язган авыл егете. Маңгаен да тарайткан ходай, иреннәре бер-берсенә ябышып тора. Мин аның елмайганын да, көләп җибәргәнен дә хәтерләмим. Легионер. Татар легионерларының язмышы бер калыпка сугылган: дөбердәтеп ызаннар арасыннан алып киткәннәр дә өч солдатка бер мылтык, ун патрон тоттырып сугыш кырына илтеп ыргытканнар. «Мылтыклы иптәшегез

үлгәч, коралны шуннан алырсыз»,— дип коммунистик киңәш тә биргәннәр. Күпме татар җаны кырылган да, күпмесе балчык белән аралашып, кан белән юылып, Ак диңгездән Кара диңгезгәчә күмелеп калган — беркем белми. Аулак чаукалыкларда, дымы мәңге китмәс сазлык-баткаклыкларда ак сөякләре таралып ята әле татарларның. Дога тәтемәгән, бәхилләшү ишетмәгән газиз җаннары әлегәчә җир белән күк арасында тинтерәп, ыңгырашып йөри. «Исән калганнар үлгәннәрдән көнләшер»,— диелгән китапларның берсендә. Исән калган әсирләрнең каһәрләнгән язмышы хакында без озак вакытларгача ләм-мим дәшмәдек, курыктык. Хәзер һәммәсе тәгаенләнде, саннар, язмышлар чагыштырмача мәгълүм булды. Рәсәй ягыннан немецларга әсир булып биш миллион җиде йөз мең кеше төшкән икән. Бу — 1941 нче елның июненә, сугыш башланган көнгә тупланган Совет армиясе санынннан артыграк! Әсирлектә өч миллион өч йөз мең кеше үлә яки үтерелә. («Известия», 4 апрель, 1991). Бу коточкыч саннарны немец хәрби тарихчылары бөртекләп исәпләп чыгарган. Бу җәһәттән әле безнең төпле эзләнүләр юк, бар булган мәгълүматлар бик астында. Без һаман нидер көтәбез, кемнәндер шүрлибез. Һәр әсир — җан иясе. Һәр әсирнең кабатланмас язмышының башы-азагы бар.

Кәбир — шул миллионнарның берсе. Исән калганы. Аның гаебе бер генә — исән калуында. Сугышка кадәр туган авылыннан читкә чыкмаган, эш арасында мәктәпнең дүрт классында ыштан төбе туздырган авыл малае, татар, әсир эләккән. Ачыккан, җәфаланган, кыйналган, тукмалган. Үләм дигәндә кемнәрдер җәһәннәм базына — лагерьга килеп чыккан, татарларны җыйган, үз телләрендә кешеләрчә сүзләр табып эндәшкән. Подберезье егете үз тиңдәшләре белән легионга язылган, Берлинга эләккән, анда ат караган. Ул шуннан артыгын белми дә диярлек, кусалар барган, кушсалар туктаган. «Чәк-чәк кенә немец аракысы шнапсны кәгеп, немец пилоткасын каешка кыстырып, Берлин урамнарын яңгыратып «Галиябану»ны җырлап кайткан чаклар бар иде»,— дия иде Кәбир, әллә сагынып, әллә офтанып. Хәзер тикшерүче бу егетнең бугазын буа, шнапсын костыра. Аның белергә теләгәне шул гына: Кәбир ничек вә нигә исән калган да, кайсы илгә шпион булып сатылган һәм Татарстанга нинди заданиеләр белән кайткан?

Йомыры бүксәле, сүз саен үзенең ашказаны чире белән интегүен искәрткәләп торган Нигъмәт ага төрмә баландасын ашамый да диярлек, җирәнеп кенә, мыскыллап кына бер-ике тапкыр гына кабып куя. Ботка мул, тавык симез булганда да кәстрүл төбен Кәбир кыра, гәүдә алыпныкы, тамак таза егетнең. Немец-урыс лагерьларын байтак үткән, Черек күлдә утыра-утыра башы томалана башлаган егетнең сөйләр сүзе дә калмаган иде шикелле. Берзаман ул мине таң калдырды... Авылда аның ата-анасы, хатыны калган. Бала-чагасы бар идеме, хәтерләмим. Туган йорты да әллә кайда түгел, шунда, аяк астында, Тау ягында. Поездлар өзлексез килеп-китеп тора. Кызганычка күрә, Кәбир Мөхәммәтшин янына килгән-киткән кеше юк. Иртән бал калагы очына эләктереп шикәр комы, күз алдар өчен генә чәй бөртекләре йөгерткән кайнар су һәм биш йөз грамм ипи бирәләр Черек күлдә. Көндез лакан исе аңкып торган баланда, кичкә бармак башы хәтле генә балык кисәге. Ите күбрәкме балыкның, тозымы, әйтүе кыен. Көннәрдән бер көнне Кәбир ачылып китте, кул аркасы белән күзен сөртә-сөртә озаклап җылады. Җылавы да үзенчә, әллә каргый Кәбир, әллә улый, тыңлаган кешенең чыдар әмәле юк! Коридор буйлап әрле-бирле йөреп торган надзиратель дә сәерсенде бу тавышка, «волчок» дигән тишекнең калаен ачып-ябып безнең камера турында хәтсез вакыт басып торды. Инде тәмам өмете өзелгәч, Кәбир беренче хатынын сагына, тәкатьсез калып сагына иде. Шуңа җылый. Беренче хатыны кышкы зәмһәрир салкында, ян-яклары шома боз тавына әйләнгән коега суга чыга, чиләкләрен тутырып таеп китә дә егыла, арт чүмече белән калын бозга чәчрәп барып төшә. Тын да тартмый бичара, шунда ук җан бирә. Хәзер Кәбирнең иң соңгы, иң газиз теләге шул:

«Оныттылар мине, ташладылар, дөньяда берәүгә дә кирәгем калмады... Ходай насыйп итеп, кайчан исә бер котылып чыга алсам, кайтам, зиратка барып мәрхүмәнең каберенә егылам да тормыйм, шунда үләм!»

Төнтек сымаграк йөргән тар маңгайлы легионер Кәбир Мөхәммәтшинның өмете һәлак булуын күзәтү, кеше бәхетсез чакта чарасыз калу миңа бик авыр тәэсир итте. Кайсыдыр дәүләтнең шпионы тамгасын тагып, егерме биш ел срок алып, Кәбир Черек күл белән хушлашты да эзсез югалды...

Март — апрель аенда яшәгән читлегем — егерме дүртенче камера хакында күбрәк сөйләп ташладым, кичерерсез, чөнки Нигъмәт ага белән Кәбир төрмәдә мине кабул итеп алган, тәүге сабакны бирергә тырышкан, икесе ике дөньядан шактый тәҗрибә туплап килеп кергән затлар иде. Кәбир миңа татар легионы хакында беренче гыйбрәтләрне ачып бирде.

Тоткын һәрчак хәрәкәттә ул, аны камерадан камерага туктаусыз күчереп йөртәләр. Кәбирне күчерделәр, Нигъмәт ага белән без икәү калдык. Аның җиткән ике кызы бар икән, берсе Химия-технология институтында укый, икәү калган мәлләрдә минем аңа тагын да якынаясым килә, гомере буе МВД системасында эшләгән бу кешенең әз-мәз өметемне җылытуын көтәм. Ни әйтсен инде ул бичара тоткын, сүзе һаман бер тирәдә йөри: «Менә, көне килеп, берзаман ирекка чыксаң, олы кызымны, дөньяның бер чибәрен тотам да сиңа бирәм!» Ә мин тилебаш, язмышымның тар ишеген ачып ике адым да алга карый алмаслык исәр, колагымны шәнкәйтеп аңа ышанып утырган булам!.. Нигъмәт ага мине читкә какмый, ни өчен утыруымны белергә теләп иптәшләрем хакында да, арабызда йөргән сүзләр хакында да җай чыккан саен төпченә. Тавык ашап кикереп куйгач, аны тикшерүчеләр янына алып менеп китәләр.

Төннәрнең берсендә җәфалы һәм газаплы допростан соң таң атканда гына кайтып кердем. Диварларга нык беркетелгән ике тимер карават арасына ике урындык бастырганнар да топчан җәйгәннәр. Как тактада кырык ямаулы иске бишмәтен ябынып, алама бер гәүдә ята. Камера ишеге шалтырап ачыла, гөр килеп ябыла, теге бәндә кымшанмады да, күтәрелеп тә карамады. Урын-җир бирмәгәннәр, ягъни бүген генә тотып япканнар иске бишмәтне. Төрмәгә килеп кергән төндә ничекләр йоклап ята диген гамьсезне! Көн килде, йоклый алмыйча угаланып иртәне каршыладык. «Подъем!» — дип, волчок тимерен кактылар. Иртәнге чәйне сүзсез генә эчтек тә, Нигъмәт аганы югарыга алып менеп киттеләр. Катнаш оешмаларның экономикасын учында йомарлап тоткан кеше буларак аны еш чакыралар, баш инженер Клейнерман һәм бүтәннәр белән күзгә-күз очраштыралар. Допрослар хәвеф-хәтәрсез үтә иде шикелле, Халитовның «җәһәннәмнән тәмугка төшкәч» зарланганын, кемгәдер рәнҗегәнен хәтерләмим. Баткан аяк чыланган! Бу йортта тел яшерүдән файда юк. Ачыл, сөйлә һәммәсен! — дип еш үгетли иде мин сантыйны...

Ул чыгып китүгә үк алама татар миңа таба иелде дә ярым пышылдап: «Син, малай, бу тук күркәдән сак бул! Бу кошны сине чишендерергә утыртканнар. Бә-әк шикле күренә!» «Каян белдең?» — дип сорадым мин ачык авыз, тотлыгып. «Без сәяси тоткыннар, политическийлар. Ә ул чека кешесе... Ун ел утырып чыккан абзаң булырмын. Утызынчы елларда төрмәгә ябылып, исән калганнарны кырык сигездә яңадан җыя башладылар. Эх, чыгып ычкынырга кирәк иде дә, кара якка, кыргыз-казакъ арасына кереп чумасың да эт тә таба торган түгел иде дә... саулык бетте. Магадан-Колымаларда калды саулык. Җанны суырдылар, күкрәк капкачын ачып, йөрәкне таладылар.»

«Колхозлашуга каршы коткы таратты» диган гаеп белән төрмәгә эләгеп, ун ел урман кисеп, шахта базларында чиләнеп, кусәүгә әйләнгән бу татарның кайсы як кешесе булуын да, кем икәнен дә сораша алмадым. Шушы сүзләрен әйткәндә дә ул буылып-буылып ютәлләде, ютәле тыелгач, ике кулы белән күкрәгең кысып утырды. Ишек сакчысыннан ялынып-ялварып бер тустаган кайнар су сорады — бирмәделәр.

## 2

Память моя, память, что ты делаешь со мной?!

Виктор АСТАФЬЕВ

Алама бишмәтле татар, авыр тормыш сыналышларында кыйналып акыл җыйган рәхимле җан мин аңгыра сарыкны кат-кат кисәтсә дә, аның сүзләрен колагыма да элмәдем. Аның зирәклеген, минем пырдымсыз акылыма булышырга теләвен бүгеннән торып, бүгенге акылым белән генә бәялим. Нигъмәт аганың өметсез бер студентка сылу кызын кодалап йөрүенең серен шул чакта ук шәйләдем, мәгәр, телемнең тотанагы юк иде, кичергәннәрем, яшьли күргәннәрем шактый җыйналып, бер акылга килә язып йөргән мәлләрем иде, уйларымны бикләп куюя түгел, бераз кыланып, бераз кабарынып Сталинны яратмавымны, совет властеның гаделсезлеген Халитовка ярып салдым бугай. Җүләр чаклар диген, булды, ялгышлар ычкынды, хаталар ясалды. Хәер, мин боларны бер чакта да яшермәдем. Исәрлегемә караганда акылым өстенлек иткәнгә, ялгышларымны, кемнәргәдер артык дәрәҗә ышанып хаталануларымны уйлап үкенсәм дә, төпле уйларымның дөньяны дөрес аңлавын чамалап, төрле яктан үлчәп, яшьлегемне дә исәпкә алган мәлләрдә, үз-үземне акларга да көчем җитә!

Димәк, утызынчы-кырыгынчы елларда бер тапкыр утырып чыккан тоткыннарны өр-яңадан җыя башлаганнар. Алама бишмәтле агай иректә чакта ук бу хакта ишетеп, белеп яшәгән. Димәк, алар — элеккеге сәяси тоткыннар гел-гел посып утырмаганнар, бу, чираттагы мәрхәмәтсезлекне ишетеп, үзара хәбәр алышып торганнар. Камерадан камерага күчеп йөри башлауга төрмә тормышын аңлый алдым, адәмнәрне аера, төркемнәргә бүләргә тотындым. Черек күлдәге тоткыннарның иң зур күпчелеге легионерлар иде. Әһә, дип уйлады минем ачыла башлаган зиһенем, легионерлар да сугыш еллары гаепләре өчен утыралар. Димәк, сугыш беткәч тә аларны өерләп төрмәләргә тыкмаганнар әле, аларны да кырык сигездә, илленче елларда гына җыеп алганнар. Кырык өчтә илгә кайтканнарны да илленче елда гына камаганнар! Ни өчен алай булган? Нигә легион солдатларын кырык сигездә ябарга тотынганнар? Ил сәясәтендә кырык сигездә ни үзгәргән?

Икенче тапкыр төрмәгә алынганнар арасында миңа аерата нык тәэсир ясаган кеше инженер Кулешов булды. Исеме-фәләне исемдә калмаган. Ул көннәргә кырык елдан артык вакыт үткән ләбаса, аңларсыз! Нәни генә капчык тотып бер нәрсәгә дә исе китмичә, ерак әбисенә кунакка килгәндәй килеп керде камерага Кулешов. Ишек шартлап ябылганны сабыр гына көтеп торды, шуннан соң гына башын иеп сәлам бирде. Шактый утырып, беренче давылларны кичергән адәм дип уйласам, Кулешовны әлерәк кенә тотып китергәннәр икән. Дөрес, элек тә утырып чыккан! Бер тапкыр җәһәннәмне кичеп, икенче кат төрмәгә эләккән кешенең шундый сабырлыгы, үз-үзен иркен тотышы, горурлыгы, олысымаклагы мине сокландырды. Сугыш елларында тоткынлыкта булган Кулешовны үз һөнәре буенча бик мөһим хәрби заводка эшкә кайтарганнар. «Заводта мине махсус сак, бер солдат озатып йөрде». Була бит урысның бик борынгыдан затлы токымнан килгәнен раслаучы олпат ирләре! Биек, төп-төз буй, затлы дәү танау, киң, мәгърур маңгай, алгарак чыгып торган, металлдан коелгандай калын, нык ияк. Саллы, салмак хәрәкәтләр, чиста, капса өзә торган көчле тешләр... Кулешов инженер-химик булу өстенә, әдәбият-сәнгатьне үлеп ярата торган нәзәкатьле, тәрбияле вә укымышлы кеше дә икән! «Бер заманда Колымага, Магаданга килеп эләккән тоткыннар арасыннан бик әзләр генә җан саклап кала алды. Мин кулга алынган көннән башлап исән калырга тырыша идем.

Әгәр бурлар, караклар арасына эләгәсен икән, алар белән тапма да, бүлешмә дә... Кулыннан бер эш тә килми дисеңме? Һөнәрең дә юк икән. Бусы начаррак. Мәгәр башны җуярга ярамый! «Һөнәрем бар, ташчы мин!» — дип чәчрәп чык. Син бит студент! Елгырлыгыңны эшкә җик». «Исән калуның ни әмәлен таптыгыз сез?» — дип сорагач, Кулешов көлеп җибәрде. «Гюго белән Бальзак саклап калды,— диде ул.— Яшьтән үк үзешчән актер идем мин. Башта суфлер булдым. Кырык өч пьесаны яттан беләм! Бурлар алар гаҗәп халык, алар китап сөйләгәнне ярата. Тотынам тегеләргә кичтән романнар сөйләргә! Шәхрезада кебек ин кызык җирендә генә таңда туктатам да кич тагын башлап китәм. Берәүләрне этапка куалар, икенчеләре килә. Ә мин һаман тел тегермәнен әйләндерәм. Белгәннәрем саекса, үз күтемнән уйлап чыгарам!» Кулешов алда нинди газап-җәфалар көткәнен һич яшермичә сөйләде дә икмәк каты-котыларын җыештырып, мине ташчы һөнәренә өйрәтергә тотынды. Кирпечләрне ничек ялгарга да, җекләрне ничек сыларга, почмакларны ничегрәк күтәрергә кирәклеген дә һич иренмичә, вәзенләп сөйләп бирде, укытты.

Бу гаҗәеп акыллы, киң күңелле кешедән мин: «Элек утырып чыккан тоткыннарны нигә кабат җыялар?» — дип сорадым. Инженерның беренче мәртәбә каушавын күреп гаҗәпләндем. Алай, турыдан-туры сорарга да ярамагандыр, хәзер шулай уйлыйм, мәгәр кызыксынуым соң дәрәҗәдә көчле иде шул. «Нигә бер үк эш өчен икенче кат хөкем итәләр?» — дип тә сорадым, төрмә сабакларын үзләштерә башлаган мин исәр... Җавап бирмәде инженер, асрылып сәгать сукканны чамалап, нык итеп кулымны кысты һәм: «Монда нидер бар, студент! Моның тирән бер сере булырга тиеш!» — дип кабатлады. Мин белгәндә аны югары катка бер тапкыр да чакырмадылар. Ул да, мин дә, өскә чакырсалар ни дә булса ачыкланмый калмас, дип өметләнгән идек.

Ярый, күңелебезне таратмыйк, Кулешовны тагын төрмәгә ябу Совет хөкүмәтенә зарурый булсын да ди... Хәрби серләр белә, таза, яшь диярлек, әзме-күпме киләчәге бар. Бөршәеп беткән, ун ел Архангельск якларында танавы белән җир казыган казанлы Анатолий Рязановны нигә тәбегә бөтереп тыгарга иде?.. Мең кешедән берәү исән булып кайткан, тол ир. Ике кызы калган. Үлчәсәң ир санап гер таба алмый интегерсең! Бөтен барлыгы ике учка сыеп бетә. Күз нуры калмаган, юынырга кергәч, адәм скелетын өйрәнәсең килсә... Теле сакау, көҗә сакаллы, яман сәфәрдән кайткач, бик озак интектереп йөргәч кенә элекке урынына «Спартак» комбинатына эшкә алганнар. Юашның юашы, бахырның бахыры! Әүлия тек әүлия!.. Тагын төнлә барып кереп дуылдатып Черек күлгә алып килеп батырганнар урысны! Җылый да алмый, ул да вакытсыз китеп барган карчыгын сагына. Әйтә алмый калган сүзләре бар икән... Торам-торам да шаккатам, берни аңламыйм, ул чагында әле мин бик күп нәрсәләргә төшенмәгән идем!.. Аны да тикшерүчегә чакырып йөдәтмиләр, димәк, төрмәгә кергәнче үк аның хөкеме расланган инде... Җөмләдән шул булсын, Анатолий агай җәһәннәмнең түреннән бу юлы да исән кайтты. Урам-тыкрыкларда ирек белән куанып йөргән мәлләрдә еш-еш очраша идек. Ике тапкыр иблисләр тозагында булып кайткан әүлия карт ике аяктан таякка калды, озак кына югалып торды. Очрашканда танымадым Рязановны... Бер күзен алдырган, сынары белән текәлеп миңа карап тора. Таныды тануын, гыжылдап: «Исемең ничек иде әле синең?» — дип сорады. Кырынмаган, чалбар төбе салынып тезенә төшкән, муены кәкерәйгән... И тәңрем, зинданнарның адәм баласын гарипләткәнен күрмисеңмени син, илаһым?.. Рязановны янадан күрмәдем...

«Хаҗ сәфәреннән» әйләнеп кайткан казанлыларның тагын берсен яхшы сүз белән искә алып үтим әле. Фамилиясе Авдеев иде аның. Илледән узган адәм ул чагында миңа бик карт булып күренә иде. Авдеевка илле дә тулмаган булгандыр, бәлки, төрмә камерасындагы кешенең яшен тәгаен генә әйтү мөмкин түгел. Харбинда хастаханә лабо-

раториясендә хәтәр гауталардан читтә яшәгән Авдеев илгә шактый мул корсак үстереп кайткан. Төрмәгә кергәч, шул корсагы аркасында бик күп җәбер сүзләрен тыңлаган репатриант[1] мин очратканда өшәнеп-куырылып калган иде. Корсак шиңгән, төймәләре киселгән чалбар гел аска шуып тора. Авдеевның сул кулы чалбар биленә береккән кебек. Бу адәм үзенең ихлас диндарлыгы белән миңа ошап калды. Төрмә дип тә шаккатмый, дөнья күргән баш, ашау-эчүенең хөртилегенә дә зарланмый, алласына гыйбадәт кыла алмавына үртәлә иде бичара җан! Җитмәсә гомере буе муеныннан төшмәгән көмеш хачны да тартып алганнар. Авдеев төрмә диварының чистарак урыныннан бер өлешне билгеләп ала да иблис күзе күрмәслек итеп кенә хач сыза. Ә түшендәге хачны теләгән бер кеше күрә ала! Шырпы очы белән сызган түшендәге кызыл тәресен ул һәр таңда яңартып тора. «Төрмә стенасыннан чиста урын эзләп гөнаһка батасың. Анда йә кан, йә күз яше чәчрәгән!» — дип әйтеп карыйлар, Авдеев колагына да элми. Өстәгеләр белә, аның күкрәк итендәге тәрене карап тамаша итәр өчен генә дә чакырып алалар. Унарлап җыелалар икән яшь айгырлар, тәресенә төртә-төртә шаркылдыйлар икән. Сүз белән әйтмәсә дә ходасыннан шәфкать вә мәрхәмәт көтеп торучы Авдеевның иманын үзгәртә торган көч юк иде. Ул да исән-аман Казанга кайтып төште, аның белән дә урамнарда рәхәт чигеп йөргәндә очраша, сөйләшә торган идек. Тора-бара ул да күздән югалды. Иманын мыскыл итүләргә, хакарәтләүләргә әле дә ничек түзгәндер ул кеше!

Черек күлдәге тагын бер ишле төркем барлыгы ачыкланды. Революциянең канлы тырнагыннан чыгып ычкына алып, чит җирләргә барып урнашкан, гаилә корып, бала-чага үстереп яшәп яткан Рәсәй кешеләрен — мөһаҗирләрне нәкъ кырык сигездә төрмәләргә тутырырга тотынганнар. Хәзерге акылым югарылыгыннан кабатлыйм: нинди дәһшәтле кырык сигезенче ел булган бу? Нигә бүгеннән торып без ул елның усал серенә бәя биреп үтмибез?!

Легионерлар, легионерлар, татар легионерлары... Мин баштарак легионнарда булган әсирләрне генә чүпләгәннәр дип уйлаган идем. Күз алдымнан байтак бәхетсезләр үтеп, аларның гади булмаган тарихларын тыңлап яши торгач, гап-гади кешеләрне, бары тик дошманга әсир төшкән кызылармеецларны да төрмәгә ташый башлауларын сизендем. Хәзер аларны һәр камерада очратасың. Шушы Черек күл төрмәсендә судсыз-нисез икешәр ел, аннан да артык утырганнары бар. Әйе, пленда булган, иленә хыянәт итмәгән, хыянәт итмәвен төрле-төрле фильтрация пунктларында, эрелеваклы иләкләрдә кат-кат ачыклаганнар. Әсир солдатның ачыкланмаган бер атнасы гына калса да, сугыш бетүгә үк аны читкә сөргәннәр, комендатураларга беркеткәннәр! Төп гаепләре — исән калуда! Хәзер, әсирлектә булганнарны, легионерларны бергә җыйгач, каян да булса бер-бер шикле оч төртеп чыкмасмы дип яткыралар. Аксыл чәчле, киң майгайлы, зыялы кыяфәтле бер татарны очраттым. Минзәлә ягыннан түгел идеме икән. Ике тапкыр фашистлар лагереннан ычкынган, өченчесендә качып котыла ук алган, француз партизаннары арасына барып кергән! Фашистларга каршы сугышкан. Икенче фронт ачылгач, инглизләр аны үз илләренә үк алып киткәннәр. Калырга мең мөмкинлек булса да, тугры татар илен сагынып Татарстанга кайткан... Барыбер тотып япканнар теге батырны! Гаебе юк, ләкин Черек күлдә: «Пленда булганнар арасында гаепсезләр юк, аны ачарга гына кирәк!» — дип исәплиләр. Югарыдан шундый боерык килгән... Ике ел утыра кеше, өченче ел, ахырда: «Ни язсагыз, шуңа кулымны куям!» — дип, әллә нинди ялган-ялаларны күтәреп, егерме биш еллык йөк төяп, Черек күлдән чыгып китә. Бүтәнчә аңа юл юк!..

Алты кешелек камералар да бар Черек күлдә. Өченче катта. Мин барында легионерлар анда өчәү иде. Константинов фамилияле озын, юка керәшен мине өр-яңа уйларга китереп тәрәде...

---

[1] Репатриант — чит илгә китеп, соңыннан янә үз иленә әйләнеп кайтучы кеше.

## 3

> Бу дөньяның эшләре, шык-шык итә тешләре!
>
> Татар сүзе.

Ни белгән дә, ни күргән инде бу легионер! Чебен очып чыгалмас төрмәдә бикләп тоталар. Күрештермиләр, очраштырмыйлар! Камерадан тыш беркемне күрә дә, белә дә алмый бичара!.. Җиде кат бик астында, бер минутын төрмә күзеннән ычкындырмыйча сакларлык куркынычлы, гайрәтле шәхесме ул?.. Белеме аз, мәктәптә укымаган да шикелле, хәзер тикшерүче ни уйлап чыгарса, шуңа кул куеп төшә. Эре-эре бармаклы агач көрәк хәтле кул каләм тотарга да, язу эшенә дә күнекмәгән, ә фамилия озын... Ат башы-ат башы хәрефләрне тезеп «Константинов» дип язып очлап куя алмый икән керәшен. Ә һәр битнең астына имзаңны беркетергә кирәк. Тикшерүче сүзгә юмарт, анын легионерга мең төрле гаеп өясе, аны зур җинаятьче, үзен дөньяда бер тикшерүче итеп күрсәтәсе килә! Тигез генә барган допрос иң актыкта ызгыш белән тәмамлана. Константинов кулына каләм эләккәч, тикшерүче ярсый, түземе бетә!.. Ашыктыра, кабаландыра, яңакка да менеп төшә!.. Ә фамилия кәгазь битенә сыймый... Камерага кайткач та, йокларга яткач та бичара солдат һавада үз фамилиясен сырлап интегә иде. Камера түшәменә дә сыя фамилиясе, ишеккә дә, әмма ләкин уч төбе хәтле кәгазьгә сыймый...

Легионерлар, легионерлар, татар легионерлары... Икенче бөтендөнья сугышында татар солдатларының язмышын бергә китереп төйнәгән оешма хакында әле төпле хөкем чыгарылганы юк. Без белгәннәр бүгенге чынбарлыкта сафсата, адәм көлкесе булып кына калдылар. Без татар язмышының аерым тармакларын, дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи сәхифәләрне бары тик большевикларның таләпләренә яраклаштырып кына аңлатып килдек. Италиядә фашистларга каршы көрәшкән, Атлантик вал алдында башларын салган, Франциядә макиларга кушылып немецлардан үч алган, соңыннан төрлесе төрле илләргә чәчелгән татар солдатларының язмышы «хыянәт» дип бер сүз белән аңлату — намуссызлык. Вөҗдансызлык! Үзем күргән легионерларның күпчелеге авыл агайлары иде, аларның да әз белемле, дөнья күрмәгән куркак катлавы. Әйе, беренче җай чыгуга ук алар алны-артны, уңны-сулны карамыйча, сөрлегеп, туган җирләренә кайтканнар. Совет властеның мәрхәмәтенә өметләнгәннәр. Булгандыр, лагерьларда совет властеның асылын, аның утызынчы, утыз җиденче елларда халыкларда күпме бәла-каза китергәнен аңлата белүчеләр дә очрагандыр. Кемнәрдер хакыйкатьне үз акыллары белән ачкандыр. Кыскасы, большевизмның канлы-дәһшәтле нигезен чамалаган әсирләр, легионерлар үз туган төбәкләренә кайтмаганнар, илдә ни көткәнен алар төгәл чамалаганнар. Черек күл камераларына шыплап тутырылган сугыш әсирләре, легионерлар — шуның ачык мисалы! Сугыш тарихында тирән эз калдырган Шәфи Алмазны безнең кайбер әдипләр нинди дегетләргә генә манчымадылар! Ә тоткынлыкта гүр газаплары татыган, сүздә, гамәлдә намус сагында торган Әнәс Галиев бер җөмлә белән кистереп куйды: «Күпме татар егетләренең гомерен саклап алып калды ул Шәфи Алмаз», — диде. Легион хәрәкәтен шушы ноктаи назардан карарга безнең көч-куәтебез җитми, без большевиклар каккан авыр дагалардан, муеннардагы камыттан һич арына алмыйбыз...

Аны безнең камерага җәен, урак өстендә китереп тыктылар. Черек күл кануннарынча, төн уртасында. Минем тикшерүче белән пәрмә-пәр уйнаган йокысыз төннәр! Бу Казан арты, Арча ягы татарын көлтә керткән җиреннән, басудан тотып алганнар. Килгән көннәрдә дә терсәкләре тишек, тезбашлары ямаулы киемнәреннән үткер очлы кылчыкларны

чүпләп азапланды. Яп-якты, озынча кавын башлы бу татар үтә елгыр, тере-кара күзле иде. Хәрәкәтләре тоташып китә дә кулга ияләшеп бетмәгән киек-җанварга охшап кала. Якты пеләшенә, елтыр күз карашына карап мин аны белемле, башлы адәм дип уйлаган идем. Баксаң, ул хәреф танымаучы, надан бер бәндә булып чыкты. Кыска гына төрмәчә аралашкан арада мин аның күңеле кителгәнен, моңсуланганын хәтерләмим. Барса бара, туктаса — ял итә! Көлеп үк җибәрмәсә дә, ирен читләренә шуклык әләгеп тора иде бу татарның! Кулга алыныр алдыннан гына ул көлтә төягән чытыр арбасына күршесендәге тол хатынны утыртып кайткан. Хатын үтә әгълә, нәкъ пешеп җиткән кура җиләге икән!.. Юлда ике төймәгә чак эләгеп торган чалбарының күселегеннән мылт итеп ирлеге бүлтәеп чыккан. Тол абыстай: «Йә, йә, яшермә инде!» — дип хәзинәне кулына алган һәм куяр урынын да эзләп тапкан. «Әллә шуны күреп тотып яптылармы»,— дип шигәйгән икән татар. Легионда йөргәне өчен ябылганын ишеткәч: «Һәй, һаман шуны тугылыйлар икән әле! Бер-ике атна тотарлар да типкәләп чыгарырлар әле!» — диде бу, фильтрацияне үткән чакларын исенә алып. Бу Рәсәйне, ярты Европаны түше белән шуып гизсә дә нә тарихтан, нә җәгърәфиядән берни белми торган томана татар бу юлы нык ялгышты! Әйткәнемчә, урысча ипилек-тозлык та белми иде ул. «Конвоир» дип әйттерергә тырыштык, «комбайн» дип йөрде. Сугышка, сугыш атамаларына әзме-күпме күнеккән авызыннан «следователь» сүзе дә «истребитель» булып чыкты, телен чүкеп азаплансак та барыбер шул рәвешендә калды. Өстендә бер күлмәк белән юка ыштан, трусигы, майкасы да юк иде бахырның. Безнең, камераның мунча чираты җитте, Черек күлдә чисталыкны җете күзләр күзәтә, мыштым гына юынырга бардык. Чирек шырпы кабы хәтле сабын тоттырдылар, тол хатыннарны буш җибәрми торган адәмнең арык, кырда, җилдә-яңгырда какланган кап-кара тәненә бетле бәздән күлмәк-ыштан кунды. Төрмә ашханәсендә бәрәңгедер, яшелчәдер беткән чак, өзеклек, ашка алар урынына ярма салалар, көндезен шактый куе баланда эләгә. Допросларда бер карышусыз, ни әйтсәләр шуңа пичәт сугып утырган тоткыннарга «премия» эләгә, пеләш башка ашны ике пурция бирә башладылар. Табак тутырып умыра крестьян баласы! Гомерендә бер тапкыр да тамагы туймаган, сугыш, әсирлек елларында арты көйгән, көне-төне колхоз эшендә чиләнеп җене өзелгән бу табигать баласы, бу мокыт крестьян ак күлмәк-ыштан киеп җибәргәч, корсагы кап булганчы баланда чүмергәч: «Кумасалар, мин монда ун ел рәхәтләнеп ятам» — дип ычкындырды әле.

Кәбир Мөхәммәтшин «кучтәнәч китермиләр» дип юккарак рәнҗегән түгелме? Илленче ел уртасында иген иккән, уңыш җыйган татар крестьяныының хәлен пеләш татар тәмам ачып бирде түгелме?! Үз теләге белән төрмәдә калырга әзер торган кешенең кемлеге, хәл-әхвәлләренә тагын ни өстәп була?!

Соңыннан хәбәр килеп ирешге: шушы риясыз табигать баласын, җирнең хыянәтсез улы — татар крестьянының эшен трибуналга җиткергәннәр һәм Совет властеның ныклыгы сагында торган алтын погоннарына эре-эре большевистик йолдызлар таккан олысымак офицерлар: «Совет властен тамырдан җимерергә Англия, Франция, Бельгия дәүләтләреннән задание алып кайткан шпион»,— дип аяусыз хөкем чыгарганнар. 25 ел каты режимлы төрмә, 5 ел сөрген, тагын 5 ел хокуклардан мәхрүм итү турында приговор әвәләгәннәр.

Нигә тартмасыннар хөкемгә? Тикшерүчегә акчалата бүләк эләгә, паегы арта, абруе һаман югарыга үрли...

Ул еллардагы Черек күл тарихы тоташ кара пәрдә белән капланган. Мөхтәрәм Ибраһим ага Салаховның хатирәләре белән без таныш инде. Җәзаларның нинди төрләрен генә кулланмаганнар утызынчы елларда!

Миңа егерме ике яшь! Яңалыкларны, хәбәрләрне иң тирәннән дә сосып ала торган зиһенле чагым! Һәр кеше — табышмак!.. Шулай да адәм улларын төркемнәргә аерып куеп өйрәнү кызыгырак. Нигә алай?

Ни гаебе бар бу төркемнең? Легионерлар, кабат эләгүчеләр, репатриантлар, студент яшьләр. Төркемнәргә сыймаган ялгызаклар да бар биредә! Менә Санько. Украин егете. Солдат киеменнән. Юешрәк иренле, кус, калын кашлы. Кыланыбрак сөйләшә, сүзләр белән уйнарга ярата. Аны-моны уйламаган егет кызыл почмакка кергән дә өстәлдә яткан журналның беренче битендә Ким Ир Сенның рәсемен күреп: «Нәкъ маймыл икән бу Корея юлбашчысы!» — дип кычкырган. Трибунал ана үтә мәрхәмәтле булган, бүтәннәргә рәттән егерме биш ел бүләк итеп килгәндә, Санькога ун елны гына биргәннәр...

Гадәттә, алты-жиде тоткын утыра торган 36-нчы камерада мин шактый озак утырдым шикелле. Берзаман камера ишегеннән кышлау умарта сыман юантык, алагаем дәү-дәү йодрыклы, чуен муенлы, аяк асларын, яңакларын кус төк баскан берәүне китереп керттеләр. Бүтәннәр ишектән каушап-югалып, кыюсыз гына килеп керәләр иде. Чөнки тоткын өчен ишек куркыныч нәмәрсә: аның артында ни көтеп торганын кем белгән?! Ә бу... парадка чыкканмыни! Күкрәк бүлтәеп алга чыккан, баш чөенке, йодрыклары йомарланган. Сәер кеше иде Шамраев!.. Паекка тигән ипине урталай сындырып ике генә каба. Ашау такы-токы булса да шатыр-шотыр кашына, төчкерә, төкерекләрен чәчеп пошкыра. Тәмәкене уба, ике суырuда бер папируз юк була. Шамраев безнең як кешесе түгел, Татарстандагы урыслар да татарлардан күреп әз-мәз әдәпкә өйрәнгән булалар, моңа бармы кеше, юкмы — дөньяга ул хужа! Оятсыз анекдотларны, хатын-кыз белән булган шәхси мажараларын иң оятсыз ваклыклар белән бизәп алып китә, ят та үл! Ул бер чакта да үзенең кем булуын, кайсы яктан килеп чыгуын телгә алып сөйләмәде. Кемдер сөйләми икән, аның хакында тагын да ныграк беләсе килә. Ә кеше синең артыграк кызыксынуыңны чамаласа, тагын да ныграк йомыла бара. Бу — төрмәнең язылмаган законы. Шамраев белән очрашканда мин шактый сабак алган тоткын идем инде! Шамраевның кем икәнен белми кала идек, бер көнне яныбызга яңа тоткынны кертеп яптылар. Шуның алдыннан гына Шамраев мәзәк уйлап чыгарган иде. «Хәзер кемне дә булса кертәчәкләр. Ишек тавышы ишетелүгә, без барыбыз да жүләргә сабышыйк. Керсә — дәшмибез, түшәмгә карап күз акайтып тик кенә утырабыз!» Ишек шылтырады, бикләр шалтырады, камерага юаш кына, ак чырайлы, мескен генә кыяфәтле бер яһүдне китереп керттеләр. Без — Шамраевка ияргән ахмак ишәкләр — кыланып, телләребезне чыгарып түшәмгә карап акаеп калдык. Шамраев исә үз тәкъдимен онытып, яшен тизлеге белән яһүд каршысына килеп басты. «Әһә! Жид! Бусы ярый! Кулымнан килсә бөтен жидларны төрмәгә тыгар идем мин!» Керүче, аксыл керфекләрен леп-леп йөртеп, әле Шамраевка, әле безгә, жүләр булып кыланучы ишәкләргә карап катты. Кемдәр тиз-тиз акылына килеп, яһүдкә игътибарын юнәлтте, сөйләшә башлады... Хатабызны тиз-тиз төзәтеп, керүче Исаак Горлицкийны үз арабызга алсак та Шамраев, кышкы йокысыннан вакытсыз уятылган аю кебек, шыпырт кына барыбер үкерде. Хәзер без аның кемлеген чамалый идек: шул бер-ике ямьсез сүзе аркасында без аның йә полицай, йә жандарм булуын абайладык. Татарстанга качып килеп, берәр мич башында посып яткан явыз бәндә иде Шамраев.

Исаак Горлицкий да Казанга исән-аман әйләнеп кайтты. Үз эшен дәвам иттерде, киоскада вак-төяк товарлар, гәжитләр сатты. Еш очрашмасак та күрешкәли торган идек. Исаак, гадел һәм итагатьле, һәркемгә яхшылык итәргә әзер торган адәм, һәр очрашуда Шамраевны телгә ала, беренче көндәге рәнжешен һич оныта алмый иде.

Ниндидер бер сыйфаты белән үзеңне баеткан кешеләрне бер чакта да оныта алмыйсың. «Мин бу адәмнән шул якларын әле генә алыйм әле!» — дип тотынмыйсың, киресенчә, аны-моны сизми дә каласың, акыл, рух үз янындагы юлдашларыннан нидер ала. Һәрбер яңа кеше белән очрашу, аралашу тагын бер хәзинә табу белән бер ул.

Ир-атларны «матур кеше!» дип тасвирлаганда нинди сыйфатларына басым ясала?.. Кырык елдан артык вакыт узса да аның төсе-бите күз алдымда! Рухың камил, акылың сәламәт, күңел пакь булса, Черек күл төрмәсендә дә матур килеш калып була икән! Кайгы-хәсрәт кешене изә, ваклый, кеше ихтыярын җуеп һаман бәләкәйләнә бара, иплэп кенә җир кортына әверелә. Төрмәнең төп бурычы әнә шул булса кирәк! Мин моның кайбер мисалларын алдарак әйтеп үтәрмен әле. Инде Черек күлдә үк өметсезлеккә бирелеп төс җуйган, дөнья гамәлләренә һәм үзенең киләчәгенә кул селкегән адәмнәр очраштыра иде. Өс-баш таланган, ничәмә ничә көннәр саф һава, кояш нуры күрмичә тирән чокыр-баз хәшәрәтләре төсенә кергән тоткыннар арасында ул үзенең горур кыяфәте, чиста-пөхтәлеге, кием-салымының пакьлеге белән аерылып тора иде. Кичә-бүген генә читлеккә ябылган кеше түгел, белгәнемчә, бу төрмәдә ул өч-дүрт ай утырган тоткын иде! Үзен ничек саклый, саклана алгандыр, хәзер аңлата алмыйм, күңел тәрәзәләре һәрчак бикле иде аның, әмма үз-үзенә ышанычы, ныклыгы һәр күзәнәгеннән бөркелеп тора. Ул ашыкмый, һәр хәрәкәте алдан ук үлчәнгән, көйләнгән, чамалы тәртипкә салынган була иде. Аның кайнар сулы кружканы тотуы да, кашыгы белән баландага үрелүе дә, ашаганнан соң кирсез диярлек кульъяулыгы белән иреннәрен пөхтәләп сөртеп куюы да үзенә бер төсле, нәзакатьле һәм купшы иде. Ничек саклый алды икән кульъяулыгын ак килеш? Белмим. Әйтә алмыйм. Шамраев та серле иде, тик аның серлелеге тупаслык белән ерткычлыкка, кансызлык белән вәхшилеккә төренгән иде. Бу кешенең сүзсез серлелеге исә дәһшәтле вә куркыныч иде, шул хәлдә дә ул ягымлы булып кала иде. Күз карашы дәһшәтле идеме, таш кыя сыман басып торуы шикләндерә идеме, Шамраев палач белән камерада икәүдән икәү булырга ризалашсам да, бу адәм белән икәү генә калырга куркыр идем. Әле дә ярый камерада без алтау идек! Бу кеше берәү белән дә сүзгә керми, уртак әңгәмәләргә катнашмый иде. Күз карашлары кисешкәндә эндәшсәң дә, ул күз чите белән салкын гына елмая да колагына төртеп күрсәтә, янәсе, «ишетми!» Мин аерым билгеләр аша аның бик яхшы ишеткәнен, бары тик сөйләргә вә сөйләшергә теләмәвен аңлап алдым. Бу сәер кешенең фамилиясе Аюкин иде. Фамилияңне яшерә алмыйсың, үзгәртүе дә кыен, чөнки конвой төшә дә йодырыгын күкрәгенә тери: «Фамилия?» — дип сорый. Сорап чыга, шуннан соң гына үз кирәген чакырып алып менеп китә. Аюкин тек Аюкин. Татар түгел иде үзе. Серле, шомлы, әмма үтә чибәр бу бәндәне дә 36 нчы камерада озак тотмадылар. Бераздан без Аюкинның Пятигорск шәһәрендә немецлар хөкем сөргәндә жандарм идарәсе начальнигы булуы хакында ишеттек. Төрмә төрмә ул, ни тырышсаң да сереңне алалар анда! Жандарм диген... Каннар суынып китә. Уйладым, бер Шамраевлар гына явызлыкны тормышка ашырмый икән, әнә шундый Аюкиндай ыспайлар, тел яшергән мыштыбыйлар да кан эчәргә ярата торган була. Тышкы кыяфәт еш кына алдый, бутый... Күз ачып йомганчы тәбе капкачы шапылдап төшә дә... син явызларның ризыгы буласың!

Төрмә — җанлы хәбәрләр оясы ул. Тоткыннарны бер камерадан икенчесенә өзлексез куалап йөртәләр. Биш-алты көн саен кабатланып торган тоташ тентүдән соң бик сирәк чакларда гына элек утырган читлегеңә әйләнеп кайтасың. Тентүчеләр шулкадәр остарган ки, дивардагы черки боты хәтле сызык та, ясмык бөртеге хәтле тап та алар күзеннән китми. Алар камераның астын-өстен ялап чыгаралар. Мин укыган китапларда төрмә стенасында тулы бер архив саклана иде, шигырьләр язылган була анда, васыятьләр һ. б. Черек күл төрмәсендә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Шәхси тенту шулкадәр мыскыллау белән үтә ки, чәч төпләреңне аралыйлар, чүгәләргә боералар, артыңны туңкайтып, ярымшарларыңны аерып ыштан төбеңнән бүтән берни күрмәгән тирәнлекләрдә казыналар. Муса Җәлил Моабит төрмәсендә җәфа-газап чиккән, Шпандауда интеккән. Әгәр Муса Черек күлдә утырган булса, без

аның сыңар шигырен дә эзләп таба алмас идек. Немец төрмәчеләре безнекеләр янәшәсендә сабый, өйрәнчек булып кына калалар түгелме соң? Әйбер юклыгын беләләр тентүчеләр, тапмыйлар да, болар һәммәсе дә тоткынны кимсетү, рухын сындыру өчен кирәк. Кемдер, мактанырга теләп, Черек күл төрмә диварлары аша шакылдатып, борынгы алфавит белән хәбәрләр алыштык, дисә, ышанмагыз! Ялган! Черек күл — өч катлы, шактый зур төрмә. Ул кара төндә йөзеп барган караңгы кораб сыман, анда шылт иткән тавыш ишетелми, шакып кара бар! Төрмәнең юеш, салкын, кыргаяклы подвалларына очып төшүеңне сизми дә калырсың!..

Нинди максатлардан чыгып, нинди мәкерле планнар корып тоткыннарны өзлексез күчереп йөртәләр икән? Хәзерге акылымнан чыгып мин тикшерүчеләрне болайрак күз алдыма китерәм: менә өч-дүрт тикшерүче атна азагында җыйналалар да тоткыннар исемлеген карта уйнагандагы кебек таратып-чәчеп ташлыйлар. Фараз кылалар. Кемне кем янына утыртканда аларга кыенрак булачак? «Психологическая совместимость» дигән нәмәкәйне төрмәчеләр әллә кайчан үзләштергәннәр. Тикшерүчеләр еш кына төрмә коридорына төшеп, волчок аша үз кулларына тапшырылган кол-тоткыннарның яшәү рәвешләрен күзәтеп, ни сөйләгәннәренә колак салып, аерым нәтиҗә ясап йөриләр, дип ишеткән идем, рас булган. Тоткын — читлеккә ябылган җәнлек сыман ул. Тоткынлыкны һәркем үзенчә кичерә. Берәүләрнең авызы йомыла, икенче берәүләр сүзе булмаса да сөйләшеп вакытны кыскарта. Онытылган, иректә чакта кирәк саналмаган догаларын хәтергә төшерергә тырыша. Элегрәк вафат булган әткә-әнкәсеннән, туганнарыннан, якыннарыннан бәхиллек сорый. Зинданда һәркемнең күңеле йомшара, элеккеге гөнаһ-языкларын исенә алып үкенә тоткын... Дөрес, зинданда тәмам җебеп төшкән тоткыннарны яратмыйлар, андыйлардан тиз читләшәләр. Камерада төрле холыклы, төрле характерлы адәм балалары үзара сыешып, янәшә яшәргә мәҗбүр. Тикшерүчеләр бер-берсенә һич ярашмый торган каршылыклы холык ияләрен бергә утыртырга тырышалар. Тикшерүче каршысында гына түгел, камерада да аңа тынычлык булмасын! Шулай иткәндә тоткын тизрәк сына, буйсына башлый. Галәмгә очучыларның янәшә сыеша алуларын зур-зур институтлар, йөзләрчә галимнәр өйрәнә. Сыеша алмыйлар икән — һәлакәт! Газап!

Адәм баласын кырыкка төрләндерү ысуллары бар Черек күл хөкемдарлары кулында! Карышып кара син аңа!.. Передача-күчтәнәч бирдерми. Янына быткыч, явыз, тешләк, ачәрвах, тилемсә, вак, ахмак, өчләтә юньсез тоткыннарны китереп тыга. Берәвесенең исе үк синең күңелеңне кайтара. Берәү дөнья бетереп гырлый, буыла, сикереп торып сине тәпәли башлый, күзен акайтып тешләргә итенә. Берәүнең арт шәрифе туктаусыз тегермән тарта... исенә чыдар әмәл юк, тешкә сылана. Берәү тәмәкене убыр урынына ашый.

Тәмәке димәктән... Утыз алтынчы камерада даими биш-алты кеше утырабыз. Күпчелек легионерлер, авыл кабартмалары. Аларның берсе дә передача-күчтәнәч алмый. Тәмәке — дефицит! Берзаман ул күзгә кырып салырлык кына кала! Дөньяда Колумблар юк, Америкадан кайтарта алмыйсың тәмәкене! Ә тәмәке... солдат белән рисtанның аерылмас юлдашы! Тәмәке түгел, аның төпчеге генерал дәрәҗәсендә йөри. Урыс аны олылап: «чинарик» дип атый. Төпчек кулдан кулга йөри, бармак пешмәсен өчен уртак бер мөштек ясала. Мөштекне шырпы кабын ватып, йомычкасын кәгазь белән урыйлар, яки йомшагын изеп ябыштыралар. Шобага салына, кем беренче булып тәмәкене суыра? Ул мул итеп суыра да янәшәсенә чиратка баскан тоткынның авызына өрә. Авыздан авызга күчә барган төтен чират азагына җиткәнче сыеклана, аның инде исе генә кала. Нәни төпчек шулай авыздан-авызга бәхет өләшеп әрле-бирле йөри. Чират саклана, хәрәмләшергә уйлап арага керсәң — беттең, тәмәке төтене өчен буып ыргытырлар. Ходай сакласын. Ниһаять, тәмәкенең соңгы

бөртеге да яна, камерага шомлы тынлык китмәскә кайта. Тәмәкесез калган җиде ир — тозакка төшкән җиде ач арыслан, өчәр башлы җиде дию пәрие! Берзаман тәмәкенең бөртеге дә калмый, кесә төпләре кагылган, тумбочка почмаклары кат-кат себерелгән! Мәскәүнең Кызыл мәйданын да шулкадәр тырышып себермиләрдер! «Берәүдә дә юкмы?!» Хөкем авазы яңгырый: «Берәүдә дә!» Чират кулдан ясалган, җиде авыз арасында хәрәкәт иткән мөштеккә җитә. Никотин сеңгән сары йомычканы, кәгазь кисәкләрен бик вак итеп турыйлар, һәм үзен тәмәке итеп төрәләр. Бу гаять әче тәтенле, зәһәр исле «йомычка-сигараны» бер генә суыра аласың, шундук күздән яшь коела башлый, бөтен камера төчкерә, йөткерә. Зәһәре коридорга ук чыга, надзиратель дә йөткерә-төчкерә, ул тимер ишекне дәү ачкыч белән төеп: «Мин сезне!.. Сусыз, бәдрәфсез калдырырмын!» — дип яный.

Черек күл зинданындагы читлекләр бер чакта да буш тормый, иллә мәгәр бер-береңне күрү, очрашу — мөмкин булмаган хәл! Әгәр сине җавап алуга каулаганда каршыңа үз ишләреңнән берәүне алып киләләр икән, һәр почмакта Мисыр мумияләре салынган саркофаг дәүмәлеге агач сандыклар куелган, күз ачып йомганчы сине шунда төрткәләп кертәләр. Тоткыннарның аяк тавышларын ун-унбиш минутка һава суларга алып чыкканда гына ишетеп каласың. Дүрт яктан биек-биек таш диварлар белән томаланган мәйданга чыгып керү зур куаныч. Ул да булмаса, зәңгәр күкне, болытларны күрмичә адәм баласы саргаеп үләр иде. Төрмәдә хатын-кызлар да бар, алар мәйданга чыгып, туфля үкчәләре белән асфальтны такылдатып йөри башласалар, эчтәге ир-ат тынып кала, алар мөмкин булганча мәйдан як диварга елышалар...

## 4

> Не надо стремиться на встречу с прошлым, потому что неизбежны разочарования.
>
> Василь БЫКОВ

Хәбәрләр, хәбәрләр...

Мин хәзер шактый нәрсәләр беләм! Читлекләрнең берсендә университет студенты Адлер Тимергалин утыра. Якташ егет. Иректә чакта без бик сирәк кенә күрешкәләп куя идек. Подлужная урамында өч-дүрт студент фатирда торалар иде шикелле. Адашып бер барып керсәм, егетләр майкачан гына калып, тар, эссе бүлмәчекне ярып нидер бәхәсләшәләр, берөзлексез тәмәке пыскыталар, бүлмә зәһәр төтен белән туп-тулы иде. Сүзгә мине дә катыштырдылар. Адлер мине йомыкыйлыкта, пассивлыкта гаепләде бугай. Мин бу фикерне өзеп раслый алмыйм, әмма көнелем түрендә Адлер шактый үҗәт, максатчан, үз юлын анык билгеләгән кеше буларак сакланып калган. Адлер рух ягыннан миннән көчлерәк, төгәлрәк булып күренде. Рухи житлеккәнлек житенкерәми иде миңа, җилъяк егет идем шикелле, юк-бар кешеләргә өстенлек биреп, аларга ияреп китеп байтак хаталар ясаганымны хәзер аңлыйм да... Хәзерендә дә аерым кешеләр турында хаталанулар булгаламыймыни?! «Алтыдагы алтмышта», — ди татар.

Төрмәдә Адлер утырганын белмәгән кеше юк иде шикелле. Ул җәйдә камера саен студент ябылган иде дисәм дә хак, мәгәр студентларның данлысы һәм мактаулысы Адлер булып, аның хакында авыздан-авызга легендалар йөри иде. Совет властеның явызлыгы, Сталинның кансызлыгы турындагы фикерләрен тикшерүчеләрнең чырайларына бәреп әйтә икән! Һич тайчынмыйча туп-туры бәрә, ди! Тегеләр куркып та калалар, имеш. Зиһененә кимлек килгән санап, Адлерны Арча кырын-

дагы җүләрләр йортына тикшерергә йөртә башлаганнар. Югыйсә Черек күлдә мондый тоткынның булганы юк икән! Онытмагыз: бу әле илленче еллар! Әйткәндерме Адлер андый сүзләрне, юктырмы, әмма егетне Арча кырына, Рәсәйнең иң караңгы төрмә шифаханәсенә йөртүләре хак. Легендалар буш урында тумый. Черек күлдә ятып сыныл-җимерелеп беткән тоткыннарга да үз араларыннан чыккан әкияти батыр кирәк, алар батырның данын таратып үзләре дә зураялар... Әһә, дип юана аларның күңелләре, сез, чекистлар, безне буйсындыра алсагыз да сезнең куллар кыска, әнә, Адлер Тимергалин белән сөйләшеп карагыз! Тешегез үтмиме ана, тү-тү!..

Мин «Мәҗит Рафиков та төрмәдә» дигәч, ышанмадым. Совет власте дигәндә тезләнә торган, мин белгәндә Ленин-Сталинны, совет властен мактап йөзләрчә шигырь язган кеше ничек монда килеп эләксен? Кырык тугызның җәендә туган ягы Күгәрчен районында ял итеп килгәч, Мәҗит Рафиков очына-очына колхозларның шәплеген, крестьяннарның мул тормышта, Сталин биргән бәхеткә чумып яшәүләрен тәкерекләрен чәчә-чәчә сөйләгән иде. Мин үз ягымнан нәкъ киресен сөйләп, Мәҗит белән бәхәскә кергән идем. «Безгә Америкадагы фермерлар системасына күчәргә вакыт! Шунсыз Рәсәй авылларының тамагын туйдыра алмабыз»,— дип, аны ышандырырга тырышкан идем. Бу сүзләрем КГБ өстәленә кереп ятыр дип кем уйлаган?

Мәшһүр тоткыннарның икенчесе университетның юридик факультеты студенты Фролов иде. Кылган гамәлләренә караганда, ул сакалы белән мәшһүр иде Черек күлдә. Төрмә бусагасын атлап керүгә сине парикмахер дигән бәндә үз коллыгына ала! Бер җирдә дә йон бөртеге тотмый менә, үсә башлауга кыркып ташлый. Зур, пеләш башлы, тонык күзле адәм иде безнең чәчтараш. Фролов шул җен-пәридәй көчле чәчтарашка бирешмәгән, сакалын кырдырмаган. Көчли башлагач, сакалын учлап идәндә тәгәрәпме тәгәри икән! Сакчылар тәмам шашынганнар, буйсынмас егетне көчләп — әле арт юлыннан, әле борын тишекләре аша туйдырырга тотынганнар. Килбәтсез, бөкере, тәбәнәк, юаш кына, туберкулез авырулы бу бичара мәхбүснең безне ай буенча киеренкелектә тоткан мәшһүр сакалын күрү миңа да насыйп булды. Инде срок алып, этапка әзерләгәндә тоткыннарны зуррак, күчеш камерасына җыялар икән. Шунда Фроловны очратып йөзенә карадым да егылып китә яздым. Менә сиңа Бәдыйг мәзин күркәсе! Дөньяга фаш булган сакалында нибарысы өч-дүрт бөртек төк бар иде!

Шул күчеш камерасында тагын бер гаҗәеп кеше белән кыска гына танышып өлгердек. Молотовның тәрҗемәчесе сыйфатында байтак илләрне гизгән бу зыялы урыс мин белмәгән, җавап таба алмаган сорауларга төпле җаваплар да таба алган булып иде. Тиз аерылыштык! Җәл! Черек күлдә елга якын утырып күп нәрсәләрне аңлый башласам да, үземнең баш кына җитмәслек шактый сораулар бәялеп калды:

— сугыш әсирләрен, легионерларны нәкъ менә кырык сигездә ник җыя башлаганнар?

— бер тапкыр җәзаланып, төрле-төрле срокларда төрмә-лагерьларда биктә тотылганнар котылып чыккач, нигә кырык сигездә кабат аларны тотып япканнар?

— репатриантларны да шул чамада нигә төрмәләргә утыртканнар?

— югары мәктәпләрдә укучы, зиһеннәре, алдынгы фикерләре белән бүтәннәрдән әзме-күпме өстенрәк торган яшьләрне нигә җәмгыятьтән аерганнар? Гурий Тавлинны да, Мәҗит Рафиковны да кулга алдылар. Алармы соң инде «халык дошманнары»?

Студентлар димәктән, утыз алтынчы камерада мин университетның биофак студенты Михаил Хошәбәне очраттым. Тәбәнәк, симез, күкрәгенә куе йон каплаган ассирияле хәйләкәр Михаил Хошәбә шыпырт кына әле инглизчә, әле татарча җырлап минем һушымны алды. «Ай кэн си, зе сан вин ит из райнинг»,— дип инглизчә җыр башлый да, һич көтмәгәндә, уйламаганда:

Сунының кадерен чүлдән килгән
Юлчылардан сорап бел.
Дусларыңның кем икәнен
Авырлыкта сынап бел!

— дип җырлап, минем күзләремнең дымын чакыра...

Михаил да исән-аман йөреп кайтты. Илленче еллар азагында, инде мин «Чаян» журналында эшләгәндә яшен ташы кебек очып, арба тәгәрмәчедәй тәгәрәп килеп керде бу түгәрәк! Казан аша үтеп барышы икән. Ассирияле бит, шома егет, «Юлга әзрәк акча бирә алмассыңмы?» — дип сорады. Кая баруы булгандыр, онытылган. Акча бирүем генә исемдә! Үземнең дә яңа өйләнеп, Искәндәр дигән егетне алып кайтып, Яңа Бистәдә кеше почмагында яшәп яткан чаклар иде. Шәп, зиһенле, тере кеше иде Михаил Хошәбә, ассирияле егет!

* * *

Төрмәчә җанлы, төрмә таләп иткәнчә сабыр, төрмә кушканча түзем тормыш алып барган утыз алтынчы камерадан чыгарып беренче катка алып төштеләр. Тар, нәни читлеккә кертеп япкач, кинәт моңсуландым. Буш камера тоткынны һәрчак өркетеп җанына кырау төшерә. Нигә күчерделәр мине? Тагын нинди этлек эзлиләр. Тикшерүчем белән ике арада артык зур каршылыклар юк, алай да бер нәрсә: Шәрәф Мөдәррискә кара яктырырга теләп, ул мине атна буе кысып карады, сүз ала алмады. Нигә каныгалар алар Шәрәфкә, аңламыйм.

Нигә монда мин? Уйның тезгене минем кулда түгел, ул мине бәрепегып әллә кайларга чаба. Моңсуландым, әти-әниемне уйладым. Университет егетләре минем хакта ни сөйләшәләр икән? Сизенәм, хәзер берәмберәм аларны Черек күлгә чакырып алалардыр. Ниләр әйтәләр икән?

Өч-дүрт көн, яңалыкларга зарыгып ята торгач, кичкырын отбой алдыннан гына кемне китереп керттеләр дисең? Нигъмәт Халитовны! Бер-беребезгә яхшы мөнәсәбәттә идек, кочаклашып күрештек. «Чыгарып җибәрмәделәрме?» — диде Нигъмәт ага көлемсерәп. «Ә сине?» — дип сорадым үз чиратымда. «Без бит күбәү... Кешеләр һаман өстәлә тора. Эш яңадан сүтелә башлый, кирегә китә». Сүзгә мавыгып, кычкырып ук сөйләшә башлаганбыз, волчок калаен кактылар. Бүген надзиратель — «китаянка». Бу хас кытайларга охшаган сары чырайлы, кысыграк зәһәр күзле татар хатыны, явызларның явызы. Диварга ялгыш кына арканны терәсәң дә, терсәгеңә таянганны күрсә дә, «китаянка» давыл булып куба: «ни прислоняйся!», «не облокотись!» «Я тебе...» Урысчасы ватык-сынык бичараның, күптәннән кешечә сөйләшүне оныткан...

Тоткыннарның иртән обход ясый торган кизү офицерларга, көн саен алышынып торган надзирательләргә үз мөнәсәбәте. Бу мөнәсәбәт бер чакта да үзгәрми, буыннан-буынга тапшырылып килә. Еллар һәм тоткыннар ялгышмый: надзирательләр бер кигән кабыкларын һәм битлекләрен салмыйлар. Арада тагын бер татар бар. Озын буйлы гап-гади авыл баласы. Ничек килеп капкандыр бу этләр өеренә. Юаштыр үзе, йомшактыр холкы, бер чакта да җикеренмәс, ашыктырмас. Коридорның аулак җиренә җиткәч бер-ике сорау биреп тә куя, кызыксына, бик интеккәнеңне сизгән мәлләрдә бер-ике папирос биреп тә калдыра. Яше, карты аны «Абый» дип атап йөртә.

Тәбәнәк, явыз эттәй ырлап торган урысның кушаматы «кусачки». Безгә тырнак кисәргә «кусачки» дигән тимер теш бирәләр. Нәкъ үзе инде бу тәбәнәк! Бер башы үткер, икенче башы тумпак, тупас. Кизүләрдән Пронин фамилиялесе аерата истә калган. Төн уртасында ул мине кабул итеп алды, канәгатьлек белән мырлый-мырлый мине анадан тума чишендерде, чалбар төймәләрен кырды, ботинка бауларын суырып чыгарды...

Коридордан алып йөргәндә ике кулны да яман авырттырып боргычлап тота торган иде! Селкенә дә алмыйсың! Кул богавы да кирәк түгел, умырып кына ала! Бу кеше төрмәдә туып, шуннан чыкмыйча яшәп, шунда үләргә хөкем ителгәндер, дип уйлыйсың. Ул монда төп хуҗа, иртән керә, кырыс күзләре белән камераның һәр почмагын, борылышын җентекләп капшап үтә, кермәгән ярык, күрмәгән нокта калмый аңардан. Әүвәл старшина иде, без утырганда аңа кече лейтенант дәрәҗәсе бирделәр. Моңа кадәр Пронин эт иде, югары дәрәҗә алгач котырган эткә әйләнде. Алтын погоннар тагып керсә дә туймас тамак, төрмә күсесе булып калды. Кеше җанын ашап, бәгырендә казынып туйдыра иде ул тамагын! «Ул монда утыз җиденче елда ук хезмәт иткән, бик күп җаннар аның кулы аша үткән»,— дигән хәбәрләр аңа җуелмаслык коерык булып тагылган иде... Җөгенә керә алмыйм, ишеткәннәремне генә сөйлим. Пронин әле дә исән, ап-ак чәчле, бөкерәя төшкән тыныч кына бер адәм...

Иң гаҗәбе шунда ки, илле яшем тулган көннәрдә котлау телеграммалары миңа атна буе килә торды һәм телеграммаларны җен дә түгел, шайтан да имәс — шул Пронин ташыды! Ышанасыңмы-юкмы, ишектә кыңгырау тавышы, ничә чыксам да кәгазь кисәкләре тотып Пронин басып тора! Таныдымы ул мине, төсмерләдеме, сорашырга кыймадым, уңайсыз хәлдә калдырасым килмәде. Шулай да почта хезмәткәрләре аша белештем: Седов икән аның фамилиясе, анкеталары раслаганча «гомере буе урта мәктәптә физкультура укыткан». Черек күлнең чын тарихы шулкадәр тирәнгә яшерелгән ки, һәммәсе алдан ук исәпләп нокта куелган, надзирательләр кебек вак-төякләр дә исемнәрен яшереп кушамат белән генә йөргәннәр.

«Сүз башым шүрәле» иде бит, читлектә ялгыз калгач, зиһенем буталып югалып калганмын! Нигъмәт ага кергәч тынычрак йоклаганмын, «Подъем!» дигән усал кисәтүгә сискәнеп, сикереп тордым. Бәдрәфкә барып, бит-күзне югандай иттек, «параша»ны түктек. Чәй-суны көтәбез. Куркытып ишек шалтырады, без икәүләшеп кулларыбызны артка куеп сагайдык. Пронин килеп керде, як-ягын тикшереп чыккач кына коридорга карап кул изәде. Тәбәнәк кенә, җирән сакал-мыегының төрле якка тырпайган шырпы бөртекләре ямьсез йөзен тагын да шыксызрак иткән берәүне китереп керттеләр. Иректән тотып китерсәләр һәркемнең кулында бәләкәй генә юл төенчеге булмый калмый, бүтән камерадан күчкәннәр култык асларына мендәр-фәләннәрен кыстырып киләләр, бу тәбәнәкнең куллары буп-буш иде. Пронинның кансыз иреннәре: «Эй вы! Примите царский подарок!» дип мыскыллы пышылдагандай булды. Әле ул ишекне элеп коридорга чыккач та бүре күзе «волчоктан» озак кына карап, тыңланып торды. Керүче итәге җиргә тигән сукно шинель кигән, башына язгы карга оясы дәүмәләге — бүрек чәпәгән. Ул кыюсыз гына күзләрен арлы-бирле тәгәрәтеп йөртте дә, ашыкмыйча гына шинельбүреген салды. Сөякләре шыраеп торган арык гәүдә, балак очлары тузган оекка тыгылган нәзек аяклар һәм тубалбаш килеп чыкты. «Сузык!» — диде ул күгәрчен тәпие төсле күм-күгәргән арык бармакларына зәгыйфь тынын өрә-өрә. Беренче сүзләре шул булды һәм безне тагын бер кат гаҗәпләндерде: эссе үк булмаса да, бүлмәбездә шактый җылы иде. Кеше өстәп куюны кирәк тапты һәм аяк очын селкетеп аска, аяк башына ишарә ясады: «Мине астан, подвалдан меңгерделәр»,— диде. Аның аякларында калын табанлы, каты күннән тегелгән тимер үкчәле чит ил ботинкалары иде. Без бер-беребезне исәнләшеп, сынашып торган арада чәй китерделәр. Теге ташбаш шикәрен чәенә салмады, башын артка чөеп учыннан тамагына сипте дә голт-голт итеп бер кружка чәйне ике генә йотты. Без аны күзәтәбез, ул безне.

Бу кыяфәтсез кеше легионер, аның да гадие генә түгел, «Идел-Урал» гәҗитенең җаваплы хезмәткәре, сугышка кадәр үк Казанда әдәбият тирәсендә ышкылып йөргән, сугыш елларында Берлинда «Кави Таң» псевдонимы белән ике шигырь китабы чыгарган Кави Ишмурый булып

чыкты. Сугыш бетүгә, совет гаскәрләреннән Чехословакиягә шылган, Антонин Полачек исеме белән моңарчы шунда яшәгән. Кырык тугызның декабрендә Ишмурыйны эзләп тапканнар һәм конвой белән Черек күлгә кайтарып япканнар. Моңарчы әле аны беркем белән дә очраштырмаганнар, ул подвалда карцерда тотылган, тикшерүчесе Узмашов, кулына эре чуртан кабуына чиксез сөенеп, моны көне-төне каезлый икән. Ишмурыйның яшерер сере юк, «Идел-Урал» гәҗитенең төпләмәсе Узмашовның кул астында ята. «Синең бер мәкаләң асып куярга җитә, шакшы җан!» — дип сүгә Ишмурыйны Узмашов. «Бәс, шулай икән, нигә мине интектерә!» — дип, Кави күз яше коеп та алды. Ялгызлыктан, подвал суыгыннан, күселәрдән һәм куркыныч ыржаеп торган киләчәктән гаҗиз бичара шагыйрь минем университет студенты икәнлегемне, әз-мәз кәгазь кыштырдатуымны да белгәч, чиксез куанды. Сораулар белән күмде. «Төгәллектә күнеккән» Нигъмәт Халитов сизгер колакларын җилгә куеп, күрер-күзгә шикләнмәслек сораулар кыстыргалап, әңгәмәгә катнашып киткәләде. Мин Кави Ишмурыйга, зыян салмаслык дәрәҗәдә генә, җавап бирергә тырыштым. Кавины күп нәрсәләр кызыксындыра иде: гәзит-журналлар ни хәлдә, театрлар, әдәби түгәрәкләр, студентлар, базар бәяләре, кибетләр, тагын ниләр хакында гына сөйләшмәгәнбездер ул чакта!

Инде байтак легионерлар белән очрашып сөйләшкән, язмыш серләрен бүлешкән кеше идем ул чакта. Радом, Вустрау, Едлин лагерьлары хакында, Атлантик вал, Төньяк Италиядәге сугышлар турында байтак мәгълүмат алсам да, Кави Ишмурыйга мин исем китеп карадым. Совет властена каршы оешкан төстә көрәшкә чыккан, большевиклар режимын каһәрләп шигырьләр язган беренче кешене күрә идем. Яратыргамы аны, яратмаскамы? Күпне белә идем, дип шапырынсам да, Кави Ишмурыйны һәм татар легионерларын тарихтагы хак урыннарына куярлык белем, тәҗрибәм юк иде, әлбәттә!

Ишмурый бик озакка кадәр җылына алмады, подволда ятыпмы, әллә совет судыннан чиксез куркыпмы аның эчендәге җылысы качкан иде. Китергән чәйнең салкынлыгыннан бик зарлана иде. «Э-әх! Шаулап-гөжләп утырган самавырны екканчы эчсәң иде чәйне!» — дигән сүзләрен хәтерлим.

Шушы өтек шагыйрь Европа үзәгендә кайнаган тарихи вакыйгаларга катнашкан, «Идел-Урал» Президенты Шәфи Алмаз белән еш аралашкан, Муса Җәлил белән дә якын мөнәсәбәттә булган икән.

Әле мин татар легионының төп максаты, кылган гамәлләре хакында чынлыкны белми идем, Кавины теге дөньядан кайтып кергән кеше хәлендәрәк диеп кабул иттем. Кави Муса Җәлил хакында да артыгын ычкындырмады, ничектер ваемсыз гына сөйләде...

Ишмурый үз замандашлары, кайчандыр бергә укыган, бер тирәдә шигырь тырмый башлаган Шәйхи Маннур, Хатип Госманнар хакында кат-кат сорашты. Мин, утын авыз, халык арасында киң танылган олы шәхесләрнең өй тормышлары хакында ни сөйли алам? Кавины исә интәшләренең шул ягы ныграк кызыксындыра иде шикелле. «Нинди фатирларда торалар, ни ашыйлар, кемнәр белән йөрешәләр?» «Идел-Урал»да Шәйхи абыйның мәшһүр «Тартай арбасы» дигән шигырен бастырганнар һәм шагыйрьгә багышлап куш бит биргәннәр. «Шәйхи кыю шагыйрь!» — диде Ишмурый, рәвеше бозылган авызын бөрештереп.

Легионерларның — дөнья күргән, нужа камыты кигән, илләр гизгән татарларның наданлыгы, чикләнгәнлеге, аларның үз тарихлары, әдәбияты белән бөтенләй кызыксынмаулары мине бик нык рәнҗетә иде. Илленче елда мин шундый-шундый зирәк, акыллы, фикер иясе идем дип әйтергә җыенмыйм, мәгәр Кави Ишмурыйны, татар легионы җитәкчеләреннән берсен күргәч... шушы ярым надан йолкыш бөек татар милләтенең язмышын хәл итәргә маташканмы? — дигәнрәк уй күңелемә килде. Килде дә китмәде. Кулешовны, Молотов җәнапләрендә тәрҗемә-

че булып хезмәт иткән урысны, Пятигорск каласының жандарм идарәсе башлыгы Аюкиннарны... күреп, шундый асыл затлар белән аралашкач... нишлисең, мин Кавины бөтенләй яратмый башладым. Шөкер, безне тиз аердылар, тикшерүчем бер чакта да, бер сорау белән дә аның хакында сүз кузгатмады.

Котылып Казанга кайткач, Шәйхи абыйга үткәндәге очрашуларым хакында нәкъ монда язганча сөйләп бирдем. Төнтек Ишмурыйның үземә ошамавын да яшереп калдырмадым.

«Аталар мине!» — дип инрәде Ишмурый чардуган козгыны Узмашов янынннан төшкән кызулыгы белән.— Атарлар, мөгаен!»

Чирләшкә, көчсез, зәгыйфь рухлы, кыяфәте өтек шагыйрь кисәге Кави Ишмурыйны трибунал җәлләгән, атмаганнар, егерме биш елга гомерен озайткач, Кави унга-бишкә бөгелеп хөкемдарларына рәхмәт укып, оҗмахлы киләчәк теләп чыгып киткән. Илле алтынчы елда, тоткыннарны толыкманы-толыкманы белән иреккә куа башлагач, Ишмурый да чыккан, Казанга кайткан. Шәйхи абый белән дә очрашканнар. «Муса хакында мин белгәннәргә өстәп сыңар сүз дә әйтә алмады, офыгы үтә тар иде егетнең»,— дип көлемсерәде Шәйхи абый.

Тарихыбызда «татар хәрәкәте, татар күтәрелеше, татар милли гамәлләре» дип бәяләнерлек эш-гамәлләр әллә ни күп түгел. Икенче бөтендөнья сугышы дөрләп янганда, әүвәлдән телдә йөргән «Идел-Урал» атамасы яңа эчтәлек, яңа төсмер ала. «Идел-Урал»ның рәсми житәкчеләре, Муса тирәсенә тупланган зыялылар хакында әлегәчә соңгы сүзне әйтә алган, гадел хөкем чыгарган гайрәтле замандашыбыз әлегә күзгә чалынмады. Бигрәк тә, соңгы елларда Әнвәр Галим дигән эшлекленең хатирәләр төене Казанга кайтып чишелгәч, агай-эне арасында, нәкъ татарча, каршылыклы, әмма дәлилсез фикерләр давылы купты. Ул кульязма әзгә генә мин фәкыйрегез кулына да кереп чыкты. Тәүбә әстәгъфирулла, мин ул истәлекләргә терсәгем белән таянып, корсагымны бүлтәйтеп нинди дә булса яңа уйлар кузгатырга, Мусабыз тирәсенә сыенып яшәгән, рух алган, үз вакытында — ходай кушканча үлемне кабул итүләрен бәян итеп үзгә сүз әйтергә алынмыйм. Моңарчы кабул ителгән мәгънәләргә яңарак, ачыграк төсләр зарурый икән, аны зур белгечләр, еллар дәвамында, инде күмелә башлаган тарих төпкелендә казынган, Мусалар төркеменең һәр адымын, һәр ымын-ишарәсен яңадан барлап, өлгеләргә, үлчәүләргә кат-кат салып, тикшереп егетлек күрсәткәч кенә әйтә алырлар. Дөнья яңармады, дөньяның күләгәдә калып килгән ярымшарлары ачылды, архив рәшәткәләре җимерелеп төште диярлек, авызлардагы йозак-бикләр йомшады. Димәк, татар тарихи фәненә дә яңа күзәтүләр, әр-яңа дәлилләр, какмашас фактлар килеп кереп түргә узар... Бу яңа сүзнең, Мусалар хакындагы иң гадел хөкемнең кирәклеген яки кирәкмәслеген киләчәк үзе күрсәтер. Тарихны төзәтәм дип, аны бозып куюлар да еш очрый!

Әнвәр Галим дигән исем — безнең өчен яңа исем. Бу татар 1988 елның 3 мартында йөрәк өянәгеннән Нью-Йоркта вафат була. Авырып ятканда, әҗәленең якынлашканын сизенеп, фатирының ачкычын үзе белән бергә «Азатлык» радиостанциясенең Нью-Йорк бюросында эшләгән Сабирҗан Бәдретдингә тапшыра. Бәдретдин һәм аның якыннары Әнвәр Галимне мөселман зиратына җирлиләр. Урыны җәннәттә булсын татарның! Кылган гонаһларын кичер, илаһым! Бәдретдин белән җеназада Рокыя вә Абдулла Вафалы дигән татарлар да була. Соңра бергәләшеп алар мәрхүм яшәгән йортка керәләр, әйбер-караларын барлыйлар һәм арада күләмле генә кульязма табып алалар. Киңәш-табыш итеп, кульязма белән өстән-өстән генә танышкач, аның югалырга тиеш түгеллеген чамалап, мәрхүм үзе «Хатирәләр» дип атаган төргәкне Мюнхенга, «Азатлык» радиосында татар-башкорт редакциясенең баш мөхәррире Гариф Солтан әфәндегә юллыйлар. Солтан әфәнде дә кульязмага игътибарлы була, кульязманың берничә ксерокопиясен эшләтә һәм

1990—1991 елларда Мюнхендә булып киткән берничә татар сәяхына һәдия итеп биреп җибәрә.

Кулъязма хакында да, югарыда исемнәре саналган әфәнделәр турында да моңарчы белгәнем юк иде. «Кемдер шул материалларга нигезләнеп роман тәмамлап килә инде!» — дигән сүзне ишеткәч, соң дәрәҗәдә сөендем: татарларда да өлгерлек булыр икән!

Югарыда искәрткәнемчә, кулъямага хуҗа булырга да, алдагы көннәрдә файдаланырга да җыенмыйм. Нибарысы шул, хатирәләрнең кыска бер өлешен, аның да мәрхүм Кави Ишмурыйга багышланган сәхифәләрен китабыма кертеп җибәрергә уйладым. Минем моңа хакым бар дип саныйм: Черек күлдә аны беренче күргән кеше — мин. Сәхифәләрне һич үзгәртмичә, кайбер тел кытыршылыкларын ипләштереп кенә теркәп узам.

Әнвәр Галим кулъязмасының 195 нче бите, ул «Кави белән бер кич» дип атала.

**«Берлин. 1943 ел, 12 август. Кичке сәгать 11.**

**Мин Әхмәт Симай тарафыннан язылган, Муса Җәлил тарафыннан татар легионерлары арасында таратылган өндәмәне укып чыгар-чыкмас, «Идел-Урал» газетасы редакциясендә эшләүче Кави килеп керде. Кави зур башлы, кечкенә гәүдәле, тулы бер егет иде. Ул үзе илдә техникум бетергән һәм бер-ике ел укытучы булып хезмәт иткән, үзе туган районда район газетасында да эшләгән. Үзе эшләгән район газетасында шигырьләрен бастырган. Ләкин Казанда чыга торган зуррак газета-журналлар шигырьләрен кабул итмәгәннәр, бастырмаганнар. Фәкать «Яшь ленинчы» газетасында гына балалар өчен язылган уникешәр юллык ике шигырен бастырып чыгарган. Шул ике шигыре басылганнан соң сугыш башланганга чаклы шагыйрь булу, Казанга барып берәр редакциягә кереп урнашу хакында хыялланып йөрсә дә, теләгенә ирешә алмаган. Казанга баруын барган, ләкин бер генә редакциядә дә җылы, ягымлы мөнәсәбәт тапмаган, кая гына барса да: «Сезгә әле өйрәнергә кирәк, эшләгән җирегездән шигырьләрегезне җибәреп торыгыз, карарбыз»,— дигән җавабтан башканы ишетмәгән. Берлинда, «Идел-Урал» газетасында эшли башлау белән: «Киң юл ачылды, язган шигырьләремне һич каршылыксыз бастыра алырмын»,— дип уйласа да, алай ук булып чыкмаган. Алиш, үзе язучы буларак, аның шигырьләрен төзәткән яки үзгәртергә киңәш биргән. Шул сәбәпле, Кави Алишны бик үк яратып бетерми иде, аны комачаулаучы итеп исәпли иде.**

**Кави бүлмәгә керү белән хәрби киемен салып ташлады да «Уф», дип урындыкка утырды. «Аудан кайттым»,— диде. Аның авы — урыс, украин кызлары «Остербетерлар» яши торган лагерь булып, Кави эштән чыгу белән көн саен диярлек шунда чаба иде. Бераз хәл алгач, Кави сүзгә керешеп: «Бүген кызыма бераз бәрәңге һәм ипи алып бардым, ашау карточкасын да калдырдым». Кавиның шул эшеннән зур канәгать булганлыгын йөзеннән сизәргә була иде. Мин эндәшмәдем, аның сөйләвен, күбрәк сөйләвен көттем. Минем бик сөйләшергә теләмәгәнлекне сизеп ул: «Нәрсә бар, син гадәттәгечә түгел бүген, әллә берәр нәрсә булдымы?» — дип урыныннан торды. Мин аңа Алишны алып китүләрен, кичә Мусаны кулга алуларын сөйләп бирдем.**

**— Алайса, чират сиңа калган икән,— диде ул. Мин аптырап калдым.**

**— Ничек инде, Кави, чират миңа булсын, минем ни катнашым бар? Әллә миннән шикләнәсеңме? — дип сорадым.**

**— Сез барыгыз да бер шайка, барыгыз да бер җирдән, бер-берегезнең эшен белә торгансыздыр,— дип мыгырданды ул. Мин аңа эшнең нәрсәдә икәнлеген, ни өчен тегеләрне кулга алуларын аңлатып бирдем. Кави тынычланды. «Хәзер, Кави дус»,— дидем мин аңа,— редакциядә әдәбият белән Симай җитәкчелек итәчәк. Аның белән дуслыгың начар түгел булса кирәк, шигырьләреңне җиңелрәк бастыра башларсың»,— дигәч, Кави ачылып китте. «Сиңа бер үпкәм бар,— диде ул.— Моңа чаклы әдәби журнал**

өчен бер шигыремне дә кабул итмәдең, ни өчен икәнен беләсем килә, әллә минем шигырьләр Нигъмәти шигырьләреннән түбәнме?» «Кави! — дидем мин аңа.— Күрәсең, түбәнрәк булса кирәк, мин дә яхшы нәрсәне начардан аера алам, ничек кенә булмасын, уйлабрак, тырышыбрак язсаң, яза аласың, моңа шигем юк». Мин Кавиның газетада әдәби бүлекнең башлыгы булырга теләвен күптән сизә идем. Бүген ул теләгенә ирешә алмаганын сизде, бераз эндәшми торгач, сүзне башкага борды: «Беләсезме, Галим, дөресен әйтмичә булмый, мине дә эләктерүләре мөмкин, дим, чөнки моннан бер ай элек Алиш мине Идриси ханымның квартирасына алып барган иде. Анда Әхмәт Симайдан башка Муса Җәлил, Гариф Ш., Фуат Булатовлар бар иде. Бер шешә аракылары да бар иде. Бераз эчкән булдык, алар үзара нидер сөйләшеп утыргандай булдылар, мин араларына кереп сүзгә катнашырга бик үк теләмәдем. Әхмәт Симай гына минем янга килеп: «Кави иптәш, бик яхшы иткәнсез, килүегез өчен рәхмәт, сезгә Алиш сөйләр, аңлатыр»,— диде дә Муса белән чыгып китте. Без озакка калмадык. Кайтканда Алиш миңа: «Бу инде яшерен түгәрәк була, беркемгә дә әйтмә, соңгарак сөйләрмен»,— диюдән башка сүз әйтмәде. Шуннан соң байтак вакыт үтте, әмма Алиш ул хакта бүтән сүз сөйләмәде, мин әлегә: «Соңрак, башка вакытта!» — диюдән башка нәрсә ишетмәдем. Хәзер аңлыйм инде, ни өчен кулга алынган булуларын аңлыйм! Димәк, мине дә әйтәчәкләр. Мине дә исемлекләренә керткәннәрдер!» Мин Кавины тынычландырырга теләп: «Бөтен күргән-белгән нәрсәң шул гына булса, бер нәрсә дә булмас, бәлки чакырып сораулары мөмкин, белгәнеңне, күргәнеңне әйтерсең»,— дип киңәш бирдем. Кави тагын сүзгә башлады: «Остербетерлар лагеренда советларның Берлинга килеп житүләрен көтеп яталар, немецларның сугышны оттырулары хакында сөйлиләр, һәр жирдә бу хакта пыш-пышларны күп ишетергә туры килә. Ничек уйлыйсың, шулай булыр микәнни?»

Сугышның ничек тәмам булачагы хакында фикер йөртергә бик теләмәсәм дә, Кавига шуларны әйттем: «Белмим, мин ялгыша торганмындыр, бәлкем! Бәлкем, хата фикердәмендер. Һәрхәлдә, бу сугышта русларның жиңүләренә, Берлинга килеп житүләренә һич тә ышанасы килми. Руслар Берлинга килеп житсәләр дә, Американнар белән Руслар арасында берәр низагның башлануы мөмкин дип өмет итәм. Әгәр дә чыннан да руслар килә икән, безгә монда качып калудан башка чара юк... Ипилек-тозлык немецчә беләбез, бәлкем монда калып булыр, бәлкем американнар безгә ярдәм итәр?»

«Юк! — диде Кави,— мине кулга алсалар, төрмәгә япсалар, руслар килгәнче төрмәдә утырсам, минем өчен иң яхшысы шул булачак. Сезнең эш башка: төсегез, буегыз бар. Ә мин: «Төрмәдән чыктым: немецларга каршы көрәшкән өчен төрмәдә черттеләр»,— дисәм, миңа бернәрсә дә булмас. Төрмәдә утырмаган очракта, руслар килү белән чәчләрне туздырып, ертык киемнәр киеп, кырынмаган-питмәгән көе пычрак килеш урамга чыгачакмын, алар мине илгә озатырлар, минем өчен дөрес юл — шул». Кавиның планы әнә шулай иде.

Мин Кавига, илдә бер төрле дә уңай үзгәреш юклыгын, булмаячаклыгын, бер төрле дә жинеллек тумавын һәм тумаячагын, нәрсәләр генә кыланып карасак та безгә мәрхәмәт булмаячагын аңлатып бирдем. Ике арада булып үткән сөйләшүләрдән соң, Кавиның туктаусыз муеның кашуын яки һәркем ишетерлек итеп борынын тартуын, бик еш юка башын сыйпап алуын күзәтеп утырдым. Кавиның бу гадәтләре аның борчылуын, аның тынычсызлыгын күрсәтүче билгеләр иде. Эндәшми-питми генә урыннан торды да ишеккә юнәлде, ләкин кабат борылды: «Дөресен әйт әле, Алишны алырга килгән немецлар аны кыйнамадылармы?» — дип сорады. «Кави,— дидем мин аңа,— син әсирләр лагеренда булган кеше, легионда да булдың, редакциядә дә немецлар белән очрашасың, сине кыйнаганнары, мәсхәрәләгәннәре яки рәнжеткәннәре бармы?»

— Юк,— диде Кави,— моңа чаклы андый хәл булмады. Мин кыйналудан куркам, руслар кулына эләгә калсам да кыйналудан куркам, юкса ул чаклы борчылмас идем...

**— Алишның кулына яки аягына богау кебек нәрсә дә салмадылар, авыр сүз әйтмәделәр, күптән бирле таныш иптәшләр кебек чыгып киттеләр,— дидем. Кавиның йөзе ачылып китте. «Иртәгә тагын сөйләшеп утырсак яхшы булыр иде, вакытың бармы, мин инде лагерьдан кайткач һәрвакыт ишләргә белми йөрим»,— диде дә чыгып китте.**

**Иртәгесен без күрешә алмадык, мин яңа квартира артыннан йөреп, бик соң кайттым. А. Алишны кулга алгач, берничә көн үтте, Кавины да кулга алдылар. Ләкин берничә көннән азат иттеләр. Ш. Нигъмәти, Кави исәнаман әйләнеп кайткач: «Беләсезме, Кавины ни өчен төрмәдән азат иткәннәр? Чөнки Кавиның башы төрмә ишегенә сыймаган, шул сәбәпле аны чыгарарга мәҗбүр булганнар!» — дип көлдерә иде.**

**Кави төрмәдән чыккач та «Идел-Урал» газетасы чыгудан туктаганчы шунда эшләде. Рус гаскәрләре Берлингә кергәндә аның анда булуына шик юк. Бәлкем, үзе уйлаганча, чәчен-башын туздырып, атналар буена кырынмыйча, иске киемнәр киеп, Совет гаскәрләре каршына баргандыр, үзен: «Сәяси тоткын идем!» — дип күрсәтә, ышандыра алгандыр? Мәрхәмәтлерәк урыс офицерын очраткан булуы да ихтимал. Һәрхәлдә, Кавиның туган илгә кайтуы хакында хәбәрләр ишетелде».**

Рас, кайтты Кави, дөресрәге — кайтардылар. Кырык тугызның азагына кадәр чех-словаклар арасында яшеренеп ятканда тагынниләр кичерде, ниләр күрде икән? Качып ятуның мең төрле ысуллары бар, әмма ләкин Кави Ишмурыйны күз алдымнан үткәрәм дә... Юк, ходай егетлекне кызганган иде байгыштан! Бүтәнчәрәк хөкем йөртергә дә җай кала икән: гади тормышта куркак, жебегән адәмнәр дә, сәгате суккач, каһарманлык кылып куйгалыйлар түгелме?! Әйдә, теге чакта сенеп калган тәэсирләр онытылсын, бүген мәрхүмне яхшы сүз белән яд итәсем килә: жаны бераүгә дә рәнҗемәсен, дөбердәп дөнья читләре җимерелгәндә, таулар ишелеп, диңгезләр упкыннарга чигенгәндә, көнне-төнне бутап онытып, вакыт берәмлеге югалганда, коралсыз килеш немец ташкынына каршы чыккан татар крестьяннары, кичәге гадел крестьяннар, нинди әмәлләр табып җаннарын саклап кала алсалар да, бу гамәлләрне бер сүз белән батырлык дип кенә атарга кирәк. Кави Ишмурыйның берәр кемгә явызлык кылганы булдымы икән, ай-һай, мәгәр этап белән куылып, кимсетелеп, сүгелеп булса да Туган иленә кайтуына сөенгәне аермачык хәтеремдә. Аның белән очрашуымның иң олы, иң мөһим нәтиҗәсе әнә шул. Без татарлар туган илне җиңел ташлап китәбез, тиз онытабыз, кая барсак, шул илнең чапанына бөркәнеп: «Татар икәнем күренмиме? Казаннан булуым беленмиме?» — дип куркып-шүрләп, җирле халыкларга ярарга тырышып, битлек киеп яшәп ятабыз. Илаһым, соңгы сүзем шул: әгәр Кави Ишмурый исеме кайда да булса ялтырап китә икән, икеләнмәгез: Кави Ишмурый туган илен ярата иде!

## 5

«Кави төрмә ишекләренә сыймас»,— дип юкка гына шаярткannar. Сыйды Ишмурый, керде дә чыкты да, шуып кына йөрде! Төрмә ишекләре киңәя дә ала! «Тукмарлар, кыйнарлар!» — дип тә юкка курыккан солдат. Илленче елларда, без Черек күл түрендә «кунакта» чакта, тоткыннарга кул ягулар юк иде. Әлбәттә, зур төрмәнең бөтен тәртипләре өчен җавап бирә алмыйм, карцерга төшәргә туры килмәде, ходай саклады, ә болай аяк терәп, авыз тутырып «кыйнадылар, бирделәр кирәкне!» дип зарланганны ишеткәнем булмады. Әйткәнемчә, төрмә — аерым кануннары белән яшәүче, көн-төн бәхетсезлек-газап диңгезендә, билгесез утрауларга йөзүче кораб ул. Никадәрле калын ишекләр белән томалап, мәкерле йозаклар белән кат-кат бикләп тотсалар да, төрмәнең бик күп яшертен гамәлләре тоткыннарга таныш. Утыра-утыра кеше төрмәнең кадерле улына әйләнә, өч катлы сөйкемсез бинаның һәр

хәрәкәте, нәни генә тавышы да сер булудан туктый. Ишек тишеге ачылып аш булә башлауга, син күрше камерада ничә кеше утыруын ялгышусыз беләсең. Мәйдандагы аяк тавышларыннан йөрергә ничә кеше алып чыгулары да сиңа мәгълүм. Ялгыз кош сайрыймы — ул сиңа нидер сөйли. Күкне урталай ярып самолет үтсә, гел-гел җилдә утырып карлыккан завод морҗалары гүелдәп аваз салса — сиңа сәгатьнең кирәге дә юк, син вакытны төп-төгәл әйтеп бирәсең. Кыйнамыйлар иде. Нигә кыйнап, көч түгеп азапланырга? Төрмәнең, тикшерүчеләрнең сине изәрлек, кешелегенә төкәнерлек, рухыңны гомерлеккә җимерергә җитәрлек мең кат сыналган, бик тирән үзләштерелгән мең ысулы, әмәле бар. Ирегеннән мәхрүм ителгән җан ияләрен каезлау, тиресен тунау фәне мең еллык тәҗрибә туплаган иң нык эшкәртелгән фән ул. Илләр үзгә, дәүләт рәвешләре охшамаган, конституцияләр төрле-төрле, әмма җәзалау системасы бөтен гасырларда, бөтен илләрдә бер диярлек. Әйтик, йокысызлык. Көндез яту түгел, таянып торырга да рөхсәт юк. Тыгыз, сасы исле читлек. Теләсәңтеләмәсәң, ишек катына таба почмакта агулы гөмбә булып тимер «параша» утыра. Бәдрәфкә иртә-кич кенә алып баралар. Кеше организмы төрмә режимына буйсынып бетми шул, төрле кеше бар, һәркемнең үз бушаныр вакыты!

Биш-алты камерага бер сакчы, ул да утырып тормый, күзәтеп, тикшереп әрле-бирле йөреп кенә тора. Отбой сәгате сукканда син ярым үлек: күз кабакларын йокы баскан, иңбашлары авырайган, тезләр хәлсезләнгән. Урынга сузылып кына ятасың — йокыны ерак качырып, күңелгә уй килә! Төрмәдә иң куркыныч нәрсә — уй. Инде сәгать унбер җитә, төн уртасы, кинәт күк күкри — ишек ачыла. Гади ишек түгел — төрмә ишеге! Бу ишекне уйлап тапкан конструкторны да ябып куйган булсалар ярар иде дә... Ике кулыңны каерып тотып, җилкәңә суган, сарымсак исе бөркеп, ашыктырып сине өченче катка — тикшерүчеләр бүлмәгегенә алып менеп китәләр. Тикшерүче тук, сәламәт, көне буе ял иткән, спорт белән шөгыльләнгән, хатыны белән кети-мети уйнаган, шат, аннан кыйммәтле хушбуй исе аңкый. Аяклары тимерләнгән авыр урындыкка сеңәсең дә кулларыңны тезең өстенә куясың. Менә күр, кара: кулларым буп-буш. Тикшерүче сиңа әйләнеп тә карамый, нүл внимания, ул бәхетле, пиндидер Галяга шалтырата, аңа мактау сүзләре, төче мәдхияләр яудыра... Трубканы куя да тагын номер җыя... Бусында Таняга тап була. Танյаның йомшак, тегермән ташы хәтле артын һич тайчынмыйча мактый, тез асларына шуып төшә... Көлә, шаркылдый! Бармы син дөньяда, юкмы, кешеме син, бөҗәкме — аңа барыбер. Ялтыравык күнычлы итекләрен шыгырдатып көяз, бөдрәч капитан килеп керә. Алар кочаклашып диярлек сагынышып күрешәләр, сүзләр борчак урынына тәгәри, алар кемнеңдер бәхетле туган көне, затлы коньяклар, сыралар, кыслалар турында фикер алышалар. Бер-берсен бүлдерә-бүлдерә бәйрәм ясыйлар. Тагын телефонның карусыз колагын боралар. Николайга шалтыратып, Марусяның туган көне кайчан икәнне белешәләр. Вакыт бара, йомыры артын, кендек турысын нәни генә ак алъяпкыч белән авызлыклап куйган көяз кызчык кәз-кәз атлап, май ягылган, сыр куелган ак күмәч һәм хуш исле, тоткын башын тилертерлек исле чәй кертә. Офицерлар көяз, купшы кулларын бер-берсенә ышкып, озаклап, тәмләп, көлә-көлә чәй белән сыйланалар. Капитан рәхмәт әйтеп чыгып китә. Тикшерүче кәкре хәрефләр белән бизәлгән көмеш портсигарыннан озын, хуш исле папирос чыгарып тарта башлый. Тәрәзә каршысына басып еракка, ераккә карап тора. Тагын утыра. Телефон трубкасына үрелә, кире куя. Тагын кемдер кереп чыга. Хәрәкәтсез утырудан синең гәүдәң бөкерәеп ката, күз чокырлары тоташтан сызлый, билне бөгәр, тезне кыймшатыр хәл калмый. Бер нәрсә сорамый тикшерүче, бер сүз әйтми, синең шактый буаз «Дело»ның шапылдатып яба да конвой чакыра.

Таң атар алдыннан читлегеңә кайтып башыңны уй тутырган мендәргә куюга, «волчок» тимерен шакылдаталар: «Подъем!» Уянмый кара,

тормый кара! Бер төн шулай үтә, икенчесе өченчесенә ялгана. Адәм балаларының иң ныклары да өч төнгә генә түзә, берзаман ач тамагына аш үтми башлый, чәй наждак сыман бугазны кыра, чыда гына! Адәм баласы үз-үзен югалта, шәүләләр дөньясына күчә, күзенә теләсә ни күренә, ныклык көтеп кара син аңардан!.. Дүртенче, бишенче тәүлеккә киткәч, кулын гына селки: «Яз, ни теләсәң шуңа кул куям!» Шушы мәктәпне үткән, хөкем карарын көтеп яткан камерадашлар да үгетлиләр: «Моннан котылып чыкмак юк, исән-аман лагерь киңлекләренә барып җиткәч прокурорга язарбыз, Сталинга! Черек күлдән исән-аман ычкынырга кирәк!» — дип акыл бирәләр. Ныклыкка, каршы торырга өндәгән тоткыннарны очратмадым мин. Төрмәдә кеше сүзе дә ярап куя, анда кемгәдер ышанасы, янәшәңдә акыл бирерлек кешеләр барлыгын тоясы килә... Беләм, унтугыз ел каторгада яшәгән, аягыннан богаувы төшмәгән, унтугыз ел дәвамында тоташтай кыйналган, таш базарларда җәфа чиксә дә, рухы бөтен калган, тәне бирешмәгән алтын багана — Жан Вальжаннар бар. Әмма тоталитар режимның өметсезлегендә андый каһарманнар калдымы икән? Әле мин Черек күл җәзасының бик гади, бик күпләр татыган ысулын гына китердем.

1992 елның 29 февралендә «Дворян оясының бетүе. Билгесез террор» исемле документаль фильм күрсәтелде. Телевидениедә. Алып баручы Томск төрмәсендә һәлак ителгән затлы кешеләр — князь Голицыннарның, Волконскийларның төрмә «Дело»ларына карый-карый бик күп гыйбрәтле мисаллар, дәһшәтле фактлар китерде.

«Ун меңләп «Дело» актардым,— диде ул, ачынып.— Арадан ике тоткын гына үзен гаепле санамаган, ялаларны кире каккан. «Дело»ларда «виновным себя не признал» дигән йомгак ясалган. Ун меңнән нибарысы ике кеше ныклык күрсәткән! Шуларның берсе княгиня Елизавета Волконская булган. Затлылык, ныклык кануннарын сабый чактан ук үзләштергән, горур, мәгърур токымнан килгән ханымны төрмә сындыра алмаган. Алар нәселенә сеңдерелгән затлылык төрмәләрдә дә көч биргән, гайрәт өстәгән. Елизавета Волконская большевизм палачларына өстән карый алган, йөзләренә төкергән. Хәтерлисездер, декабрист Волконский хатыны, иренә ияреп, Себергә сөргенгә барган. Сталин заманында да шул хәл кабатлана. Княгиня Волконская да ире артыннан Томскийга кадәр бара. Ире сөргендә, бүтән фамилия белән театрда рәссам булып эшли. Анда да каптырып алалар Волконскийларны!.. Төрмәдә юк итәләр, ә намуслы исемнәре һәм горур «Дело»лары кала.

Ун меңгә якын тоткын бер Томск төрмәсендә үзләренә үзләре гаеп ташлаганнар, палач балтасы астына барып кергәннәр. Тикшерүчеләр, төрмә хадимнәре нинди җәза ысуллары гына кулланмаганнардыр, уйлау да куркыныч!

Ә нәрсә ул «гаебеңне тану»? Бу хакта ачыклык кертеп китү ифрат урынлы һәм вакытлы булыр. Син — СССР гражданы, туган илеңне өзелеп ярат, гомереӊ буе колхозда яки завод-фабрикаларда хезмәт кыл, ударник бул, стахановчы, шушы ил язмышы өчен кан-тир түк, «кашыклы каныңны да жәлләмә», үрнәк бул, сәяси түгәрәкләр утырышын калдырмыйча Маркс вә Ленин тәгълиматларын өйрән, ятла, киярең ыштаның булмаса да, киштәләреңдә шул даһиларның томнары тезелеп торсын, социализм ныгыткан кануннарны, тәртипне бер чакта да бозма, сайлауларга беренче булып йөгер, Май-Октябрь демонстрацияләрендә, «мине күрәләр микән?» дип, сыек муеныңны суза-суза «ур-ра!» кычкыр — барыбер «мин чын совет кешесе!» дип ышандыра алмыйсың. Юк, ышанмыйлар сиңа! Совет кешесе булуыңны чынлап торып раслау өчен кемнедер сатарга, кемнедер төрмәгә тыгуда тиешле органнарга булышырга кирәк. Аның бүтән юлы, мөмкинлеге юк. Партҗыелышта күршеңне тар-мар китереп чыгыш ясыйсыңмы, Черек күлдә йөреп сатасыңмы — анысы синең эш, бары шул очракта гына партия, совет, җәза органнары сиңа

ышана башлыйлар. Әгәр Томск төрмәсендә ун мең кеше: «Мин гаеплемен!» — дип беркетмәләргә кул куйган икән, һәркем үз артыннан кемнедер иярткән дигән сүз...

Беләм, бармак буыннарыннан ишек ярыгына кыссалар, тырнак асларына инә кадасалар, утлы тәмәке төпчеге белән колак бөдеркәләренне көйдерсәләр, бот арана — нәзек җиреңә шапылдатып типсәләр, сынмас җирдән сынарсың. Төрмә үзенең барлыгы, сулышы, тәртибе белән адәм җанын имгәтүгә көйләнгән. Шуны да хәтердә нык тотарга кирәк — Ленин, Сталин, аларның канэчкеч яраннары төзегән дәүләт үзе дә төрмәдән әз аерыла иде. Тоткыннарны төрмә генә сындырмады, алар камераларга инде әзер килеш, рухлары төшеп, көч-хәлләре бетеп килеп керде. Төрмәләр Ленин-Сталин сәясәтенең дәвамы гына иде. Рәсәй халыкларын ирек дип аталган төрмәләрдә сытып-сындырып, калыпка салып ярым мәет хәлендә яшәттеләр. Шуңа да унар мең зоологик төркем арасыннан горурлык саклап калырлык көчләләр бармак белән генә санарлык табылды.Утыз җиденче елларны бәян иткәндә күпчелек авторлар тән җәзаларына басым ясыйлар. Ибраһим Салахов та шул юлдан бара. Илленче еллардагы җан җәзасы авырлык ягыннан тән җәзасыннан бер дә ким түгел иде. Гомумән, тоткыннарның психологиясе һәр җәза чорында үзгә була дип кабул итәргә кирәк. «Известия» гәҗите 1991 елның 15 ноябрендә бик күп төрмәләрдән тупланган гамәл дәфтәрен бастырып чыгарды. «Нужна новая тюрьма!» дип аталган ул мәкалә. Димәк, һәр яңа чорга, яңа тәртипләргә корылган яңа төрмә дә кирәк икән! Бу бер. Шактый гыйбрәтле фикерләр арасында минс тетрәндереп җибәргәне шул булды:

«Тоталитар дәүләт оештырган җәзалау системасы барыннан да бигрәк тән җәзасына йөз тота, акылга утыртуның бердәнбер чарасы итеп шуны саный. Адәмнәрне изәргә кирәк аңа, шуның ярдәмендә кешенең рухын сындыру кирәк! Кыйнап-тукмап тотсаң андый төрмәләрдән сәяси системага каршылык күрсәтә алмаслык, ни кушсалар шуңа риза адәм тәгәнәсе чыгачак. Фашистик Германия һәм Сталин төрмәчеләре гаҗәеп тирән психологлар булган! Алар эшне шундый шартларга куйганнар ки, вак-төяк җәзаларны туктаусыз бирә-бирә, адәмне зур кайгыларга да битараф калырга күндергәннәр. Н. Кристи сүзләренә таянсак, ул фашист концлагерьлары надзирательләре белән күп очрашкан кеше, тоткыннар каты җәзаларга караганда, вак-төяк кимсетүләрне авыррак кичергәннәр. Яңакларына суккач алар сабыйлар кебек җылаганнар. Үзләрен кыйнаганда яки иптәшләрен үтергәндә һич исләре китмәгән аларның!»

Монда уйланырлык гамәлләр бар.

Бүгенгә Рәсәй төрмәләреннән утыз миллионнан артык кеше үткән.

Кем булып чыкканнар алар, алдагы буыннарга, нәсел-нәсәпләренә нинди хис-тойгылар тапшырганнар?..

Француз Жерар д'Абовиля 1991 нче елның 11 июлендә Теси исемле япон портыннан Тын океан аша сәяхәткә чыгып китә. Бер ялгызы. Көймәсенең буе 8 метр, иңе ике метрга якын. Кыю сәяхәтче кулындагы ишкәк тә сыңар гына! Ун мең чакрым юл үтеп, җәһәннәмнең бөтен бизәкләрен гарык булганчы татыган сәях 134 көн эчендә давыллы-шаулы Тын океанны сыңар ишкәге белән кичә. «Иң читене, ахыр чиктә, давыллар түгел, тәнгә чыккан кутырлар да түгел, җан газаплары да түгел, ә бертөрлелек. Океан — дөнья йөзендәге иң зур төрмә ул, ялгызак төрмәсе, мин ирекле баштан шуның тоткыны идем һәм тәүлегенә унбишәр сәгать ишәргә мәҗбүр ителдем», — дип язды ул соңыннан, ялгызлыгыннан әрнеп.

Нидер үзгәреп торгандай тоелса да төрмәнең аяусыз бертөрлелеге, ныклы закон кысаларының бары тик чикләүгә корылган булуы кешене изә.

* * *

«Жәдәч!» диярга ашыкмагыз, «исемдә, исемдә!». Сүз башым төрмәдәге сөенечләр хакында иде. Бу сәер «мәсьәләнс» дә чишәр вакыт житте. Әйтимме? Төрмәдә иң зур сөенеч — камера идәнен юу, эш белән мавыгып онытылу бәхете... «Балаларча фикер йөртү» диярсез! Әйдә, булсын, адәм балачагыннан тәмам арынып бетсә, нишли?.. Дөньяның ямен югалта ул, башта гарипкә, аннан мәеткә әйләнә.

Ишек ачылу, иртәме-соңмы, өркетә, баш миенә кан йөгерә, буыннардан хәл китә. Ә бүген коридорда үзгә тавышлар ишетелә, чиләк бавы күңелле шылтырый, кайдадыр чырылдап су ага. Йа ходай, чыраең яктыра, җәя угыдай киерелгән мускуллар язылалар, бүген ишек тавышын түземсезлек белән көтәсең. Ниһаять, мәңге кырыс, мәңге сөйкемсез надзирательгә дә бүген кеше төсе кергән: кулында сулы чиләк, сулы чиләктә иске чүпрәк! Гаҗәп, бик әзгә генә ул да, син дә гади кешегә әйләнәсең! Син файдалы эш үтәргә җыенасың, ул сиңа ярдәмләшә. Ишек ягымлы гына шылтырый, син сулы чиләк, юеш чүпрәк белән камерада япаялгызың каласың. Чиләк! Ничек матур бөгелгән аның бавы, бау тоткалары. Ишек өстендәге мәңге сүрән, чепи күзле уттан төшкән нурлар су өстен алга-кызылга манган. Иелеп карап ал — көзгегә!.. Фу, сакал житкән икән!.. Менә эшкә тотынасың... Чүпрәкне сыгып тузанлы идәнгә беренче юеш эзне сызасың... сызык боргалана, тора-бара чәчәккә әйләнә. Чәчәк ясыйсың син, кар бөртекләре... Иеләсең, бөгеләсең, тезләнәсең — һәр хәрәкәт синең ихтыярыңа ярап эшләнә. Беркем сине кумый, җикеренми. Чүпрәкне тыккач, чиләктәге су чопырдый, чәчрәп синең танавыңа куна, анысына да исең китми, син — эштә. Рәхәтләнеп маңгай тирен сыпырып учыңа җыясың... Бөтен гәүдә рәхәтлектән изри. Ашыкма, ашыкма! Озаграк юан, эш тәмен кешечә татып кал! Син ашыкмыйсың, кая ул, камераның һәр ярыгын, почмаклардагы һәр уентыкны ялап узасың. Юеш чүпрәк идән ярыкларын мең кат үбеп чыга, ярыклар да риза, карышмыйлар, тоныклыкка да ялтырап җавап бирәләр! Ни бу? Нинди тавыш?

Надзиратель кормушкага керә язып сиңа кычкыра икән ич!.. Ә синең исең китми! Син — эш кешесе. Син бүген файдалы эш башкарасың. Эш бирмәү, еллар буе эш-хәрәкәтсез интектерү төрмә әһелләренең өстәмә, каты җәзасы. Дөрес, һәммәсен бик шәп беләсең, Черек күлдән киткәч... сине каторга хезмәтләре көтеп тора. Магадан, Колымаларда булып кайткан, Красноярскида урман кискән булмыш тоткыннар «эш!» дигәндә агарынып калалар. Эш белән дә, эшсезлек белән дә адәмнәрне юкка чыгара ала тираннар...

## 6

*Гитлер җәһәтенә килгәндә, эш шунда, аның котырынуын түгел, котырынырга ирек бирүчеләрне хөкем итәргә кирәк! Серне аның җүләрлегеннән түгел, шыр тилегә власть тапшырган замандашларыннан эзләгез.*

Андре ГЛУКСМАН, француз философы.

Коммунистларның тарихи XX съездында канлы тиран Сталинның кылган җинаятьләре берән-сәрән фаш була башлагач, ил сискәнеп куйды. Адәмнәр, партия кушканча гел-гел алга караудан тыелып, капылт кына артларына, сукыр килеш үзләре үткән сукмакларга борылып карый башладылар. Хәтеремдә, «Известия» гәжитендә шул заманның мәшһүр журналистлары Заславский белән Рыклин арасында нәни генә, әмма бик зур мәгънә яшерелгән тарткалаш булып алды.

«Юк,— диде берсе аларның,— илдә канлы террорның шул тиклем киң җәелгәнен, миллионнарча корбаннарны кабып йотканын белмәдем дә, ишетмәдем дә!» Икенчесе чәчрәп аңа каршы төшкән булып кыланды: «Ялган! Юри-марый гына белмәмешкә салышасың. Ил башына төшкән җәзаларның тау ташкыныдай ябырылганын белеп үк бетермәсәк тә, барыбер нидер белә идек, нидәрдер ишетеп яшәдек».

Большевиклар хакимияте канлы Октябрьдән башлап санга-исәпкә сыймаслык явызлыклар эшләгән. Америка Президенты иманлы һәм денле Рональд Рейган Рәсәйне «Явызлык империясе» дип тамгалагач, кемнәрдер койрык чәнчеп, чырай сытып йөреп маташтылар. Хак сүз әйтте Рейган, тарихи иң гадел бәяне бирде, бер сүзе белән коммунистларны хурлык баганасына сендерде. Большевиклар партиясе — аңылда караклар, ришвәтчеләр, талаучылар, үтерүчеләр, шымчылар һәм җәзалаучылар фиркасы ул. «Ленин алай иде, Ленин тыйнак иде, революциядән соң Ленин ярым ач яшәде»,— дип, күзгә төтен җибәреп, Ленин мисалына туры китереп, Рәсәй халкын ач-ялангач яшәттеләр. Янәсе: «Аның тәртибе яхшы, аннан үрнәк алыгыз!» Илдәге бөтен явызлыклар, усаллыклар аның исеме белән бәйләнгән, халыкларның бәхетсез язмышын Лениннан аерып булмый, шуңа күрә, әгәр мин байтагыбызга таныш булган мәгълүматларны хатирәләр дәфтәремә тагын бер кат теркәп китәм икән, бер дә артык булмас. Фикер юнәлешем, эчке максатым шуны таләп итә. Ленин һәм террор гел янәшә яшәгәннәр! Берничә мисал. «Без Россияне яулап алдык һәм аның белән идарә итәргә өйрәнергә тиеш!» — дип игълан итә халыкларга бәхет китерәчәк юлбашчы. 1918 ел башында адәмнәрнең котын очырырлык террор әзерли һәм шуны фәнни нигезләргә керешә. Фән кирәк Ильичка, үтерү-куркыту фәне! Илнең бөтен почмакларына Ленин фәрманы ява: «Дәһшәтле һәм кансыз булыгыз», «террорның көчәюенә һәм киң таралуына ирешергә кирәк», «әгәр канлы һәм дәһшәтле үч кулыгыздан килми икән, хәбәр итегез», «кәгазь боткасы пешереп ятмагыз, беркемнән сорамыйча атыгыз!» Ильич — сүзендә нык торучы большевик. 1918 елның 26 июнендә Питергә канлы бурычлар йөкләп җибәргән Зиновьевны йомшаклыгы өчен пешекли, эт итә: «Володарскийның үлеме өчен Питер эшчеләре террор игълан итәргә җыенганнар, ә сез — мәми авыз, каршы төшкәнсез дип ишетелде. Катгый каршы чыгам! Без совдеп резолюцияләрендә дә гомумтеррорга ачыктан-ачык өндибез! Ә сез эшкә тотынганда гына массаларның ихтыярын чиклисез! Болай яра-а-мый!»

Большевикларның планлы рәвештә террор кулланууларының нигезен Ленинның бик күп хезмәтләрендә табарга була. «1920 ел» дип тамгаланган документларының берсе: «Ашыгыч чаралар күрү өчен комиссия төзергә... (Исемнәр санала А. Г.) Яшерен генә террор әзерләргә кирәк! Үтә зарур һәм бик кирәк!»

Асылда чикләнмәгән террор әллә кайчан киң күләмдә башланган инде. Менә Ленинның 1918 елның 11 августында язган хаты. Әле илдә ачлык башланмаган, ә яраланган Ленин һәм үтерелгән Урицкий өчен Рәсәй кешеләрен тоташ кыру кызып киткән. Пенза коммунистларына адресланган хаттан өзек:

**«Биш волостагы крестьяннар күтәрелешеннән файдаланып, кулакларны кырып бетерергә кирәк. Моны революция зарурлыгы таләп итә. Хәзер кулакларны кырып-себерүне төп бурыч итеп куябыз. Бүтәннәргә сабак булсын!**

**1. Кулаклардан, байгуралардан һәм кан эчүчеләрдән иң кимендә 100 кешене асарга. Халык алдында асарга: күрсеннәр!**

**2. Асылганнарның исемнәрен газетләрдә басарга!**

**3. Асылганнарның бер-бөртек икмәкләрен калдырмыйча алырга!**

**4. Кичәге телеграммага нигезләнеп заложниклар алырга.**

**5. Шулай эшләргә кирәк ки, йөз чакрымдагы тирә-юньдә халык дәһшәттән куркып дер калтырасын, коты чыксын, белсен һәм бугазын киереп акырсын: канэчкеч кулакларны буалар һәм буачаклар.**

**Ошбуның үтәлешен телеграф аша белдерегез.**

**Нык, каты куллы кешеләр табыгыз!»**

**Әле моннан соң да Пензага телеграммалар ява: «латышлардан файдаланыгыз!», «җебеп ятасыз!» «йомшаклык — җинаять!», «берәүгә дә рәхим-шәфкать күрсәтмәгез!»**

Ленинның кансызлыгы чик-чаманы белми: ул 1918 елның 3 июнендә, әгәр шәһәрне Британия һәм Төркия гаскәрләре басып алу куркынычы туса, Баку шәһәрен яндырырга боера!

Киштәләрегездә Ленин томнары элеккечә «гаскәр кеби» тезелеп торамы әле? Озак ачып карамагач, китаплар бер-берсенә ябышып беткән булса да, 51 томны алыгыз әле. 1919 елның 22 октябрендә Троцкийга язган хатны эзләп табыгыз. Хатның иң әһәмиятле канлы юлларын төзүчеләр төшереп калдырган, әлбәттә. «Юденичны изеп ташлау (нәкъ шулай: изәргә кирәк!) — кирәкнең кирәге! Һөҗүм башлануга өстәмә көчләр тагын 20 мең питер эшчеләрен һәм 10 мең буржуйны чакыртып булмыймы? Артларына пулеметлар тераn куясың да бер-ике менен атып егасың... Юденичка котын очырырлык басым ясыйсың».

«Әсир итеп алмаска!» дигән боерыкны Ленин ярата, чәчеп кенә тора. Яки менә Ленинның үз кулы белән 1920 елның августында Реввоенсовет рәисе урынбасары Э. Склянскийга язган хатына күз төшерик. Хатта күрше дәүләтләр — Латвия, Эстония чикләрен яшерен үтеп чыгу турында сүз бара. Чикне үтеп эчкәрәк керергә, чиновниклардан, әйтик, бер мең кешене асуны оештырырга, асучыларга һәр баш өчен 100000 сум түләргә һәм шушы канлы җинаятьне Польшада тупланган акгвардиячеләргә сыларга боерык бирә мәрхәмәтле Ленин бабабыз! Кемнәр асылганын, мәрхүмнәрнең тәгаен байлар, кулак-поплар булганын тикшереп торганнар дисезме? Ас та — йөз мең тәңкәне чумырып ал!

Ленин алдын-артын үлчәп эш йөртүче үтә хәйләкәр һәм явыз политик булган. Иреклe фикер йөртерлек зыялыларны, укымышлыларны илдән куарга карар иткәннән соң... ул бу явыз ниятен якын дусты, сердәше Максим Горькийдан яшереп тә тормаган: «Үзләрен милләтнең акылы, зиһене дип санаган капитал лакейларына килгәндә, миләре юк аларның, башларында бук!» — дигән. Шулай, тарсынмаган, читенсенмәгән шәфкатьле Ленин бабабыз, Рәсәй зыялыларның чыраена «бук» чәпәгән һәм шаһитлыкка «бөек пырлитар язучысы» Максим Горькийны чакырган.

1922 елның 19 маенда хәлләрне төрле яктан исәпләп язган хатында Ленин болай ди: «һәммәсен төрле яктан үлчәп, профессорларның, язучы-әдипләрнең эш стажларына кагылышлы белешмәләр җитәрлек туплаганның соңында гына илдән куу хакында карар кабул итәргә». Күрегезче, нинди шәфкатьле җан безнең Ленин бабабыз! Чыннан да, аның бу хаты китаптан-китапка, гәзиттән-гәзитләргә күчә-күчә Рәсәйдә калучыларның башын томалады. Ике миллион ярым зыялының илне мәҗбүри ташлап китүендә Ленинның катнашы булмаган, янәсе. Ленинга тел тидерәләрме соң! Ә бүтән боерык хатларны укысаң, чәчең үрә торыр. Шул елның унҗиденче июлендә Сталинга ул болай дип яза: «һич кызганып тормастан чит илләргә сөрергә! Берсен калдырмыйча Россиядән куарга! Йөзәрләп-йөзәрләп кулга алырга да, нигә икәнен аңлатып тормыйча: «Таегыз, әфәнделәр, таегыз! Үкчәгезне ялтыратыгыз! Без Россияне бик озакка сездән арындырабыз!» — диярга!»

Арындыралар, чистарталар! Акыллылар, тәрбия күргәннәр, эшлеклерәкләр китә. Хөкүмәт башына, урыннардагы хакимият идарәләренә аз белемле, надан, дөнья күрмәгән ярым ахмаклар, ялкау-аңкаулар кереп тула. Рәсәйнең акыл ияләрен пычрак пумала белән куалар, сөрәләр,

чистарталар. Аннан соң да ничә еллар дәвамында акылга-зиһенгә ия булганнарны аталар, асалар, су төбенә җибәрәләр...

Сталин бөтен яктан караганда да Ленинның тугры шәкерте була алган, канлы, җимергеч байлык Ленин кулыннан тар маңгайлы Сосога күчкән. Утыз җиденче еллардагы дәүләт күләмендәге җинаятьләр өчен бер Сталинны гына гаепләү гадел түгел, дип язып чыккан грузин әдипләре, әлбәттә, хаклы. Тарихның безнең замандагы канлы сәхифәләренең беренче җөмләләрен һичшиксез Ленин язган һәм үз юлыннан тайпылмыйча барырга чакырган.

Канлы сәхифәләр!.. Хәзер аларны әкренләп ача баралар.Тик укырга куркыныч, кан катарлык хәлләр!

Соңгы вакытларда ачылган берничә вакыйгага тукталам...

1940 елның җәендә Катынь урманында һәм якын-тирәләрдә НКВД әһелләре 21857 поляк офицерын атып үтерәләр. Поляк милләтенең каймагын кыралар һәм сатлык академик Бурденко белән аның яраннары «Поляк офицерларын немецлар атып үтерде», дигән ялган нәтиҗә ясыйлар. Бу ялган елдан-елга расланып киленде һәм тарихта сеңеп кала дигәндә генә ленинчыл палачларның эшчәнлеге ачыкланды. «Полякларны юк итәргә!» дигән боерыкка (Политбюро карарына!) Сталин артыннан ук Калинин кул куйган. Менә сиңа кәҗә сакаллы гадел карт! «Кәли бабай!» Бөтенсоюз старостасы, халыкларның сөекле юлбашчысы!

Без гомер буе, Рәсәйнең даны саналган Днепрогэс буасын немецвәхшиләр шартлатты, дип, аларны карган-тиргәп киләбез. Асылда, 1941 елның 18 августында, дошманны сул як ярга үткәрмәс өчен, тимер-бетон плотинаны иртәнге сәгать дүрттә коммунистлар шартлата. Ясалма сусаклагычтан күтәрелгән 10 метр биеклектәге дулкын юлында очраган һәр нәрсәне ялмап, 200 километрга кадәр түбәнгә ыргыла, меңләгән совет сугышчылары һәм җирле халык су астында кала... «Җиңүләрдән җиңүләргә алып бара партия!»

1968 елның 8 санында «Новый мир» журналында инженер Побожийның «Мертвая дорога» дип исемләнгән язмасы дөнья күрде. 1969 елның көзендә мин, шул «Үле юлны» эзләп барып, аның хәрәбәләре белән җылый-җылый танышып йөрдем. Побожий язмалары мине тетрәндергән иде. Илленче еллар башында монда тиңдәше булмаган төзелеш — Салехард — Игарка юлын сала башлыйлар. Бу эш Побожий хезмәт иткән 503 төзелеш идарәсе карамагына тапшырыла. Сталинның иң яраткан төзелешләренең иң яратканына илнең барлык матди байлыгы багышлана. Йөз меңнәрчә сәяси тоткыннарны шунда куып китерәләр. Бу авантюра әз дә түгел, күп тә түгел — 45—50 миллиард сум акчаны йота. Каторга хезмәтендә ачлы-туклы интеккәннәрдән күпмесе вафат булгандыр, аның чутына чыга алган кеше юк. Илленче еллар... Сугыштан соңгы авыр бөлгенлек еллары. Колхозчы-крестьяннар һаман бушка бил бөгәләр... Дошманнан азат ителгән өлкәләрдә хәерчелек, җитмәүчелек. Ә караңгы тайгаларда йөз яшәр агачлар ава, йөзләрчә елгалар өстенә күперләр менеп ята, мәңге эремәс бозлы тундраларда боланнарны һәм төньяк халыкларын өркетеп, чуен юллар сузыла. Милләтләрнең матди байлыгы, буш хыялларны тормышка ашырырга омтылып, бер дә юкка исраф ителә... Салехард тирәсендәге күгәреп яткан рельсларны, күгәреп-череп ауган баракларны карап йөргәндә йөрәгемә кан сауды... Әз булдымы Рәсәй киңлегендә мең вә миллионнарны йоткан гел кирәксез төзелешләр! Үзе булмаса да, илдәге һәммә эшләр Ленин исеме белән башланды, аның явыз, канлы рухына багышланды. Политбюро әгъзаларының, генсекларның генералиссимустан да көтебрәк алган титуллары бар иде: «руководитель ленинского типа» дисәләр, чирләшкә, бөкшәйгән, акылы зәгыйфьләнә башлаган Черненко да бүксәсен киерергә маташа иде!.. Брежнев, Андроповларны әйткән дә юк! Алар шушы титулга лаек булган Ленин шәкертләре. Әле хәзерге заман кәрләләре, сәяси аренага үрмәләп чыккан ертлачлар да шушы бөек титулга ия булу турында хыялланалар. Ком-

мунист-түрәләр әкрен-әкрен баш калкыта... Әйе, Берлин стенасы, Венгрия, Чехословакиядәге кан коешлар, Ангола, Эфиопия, Никарагуа, Вьетнам, Компучия илләренә йоктырган большевизм чумасы гына әз әле коммунистларга, алар тагын бер кат дөньяның биш кыйтгасын большевизмга әйләндерергә, канлы, шәфкатьсез диктат урнаштырырга омтылалар... Коммунистлар кул тыккан бер илнең дә әле ипкә килә алганы юк, чөнки Җир шарын чолгаган бу чиргә әле дәва табылмаган. Ленин тибындагы җитәкчеләр Әфганстан авантюрасы өчен һәр айда өч йөз миллион доллар акча тоттылар. Эх, шушы кадәр байлыкны риясыз татар крестьяннарына биргән булсалар!.. Оҗмах ясарлар иде алар бәрәкәтле татар җирендә, оҗмах!

## 7

*Октябрьдә туганнарның*
*Ленин була бабасы.*

Мәгълүм җырдан.

Без утырган «особый лагерьларда» дөньядагы барлык милләт вәкилләре бар иде дисәм дә, ялгыш булмас. Сакалбай Маркс-ның өндәве, ниһаять, сәяси лагерьларда тормышка ашты, «барлык илләрнең тоткыннары берләштеләр!» Канлы террордан, катлаулы җәза системасыннан башка коммунистик җәмгыять төзүнең мөмкин булмавын алдан ук сизенгәндер Маркс. Киләчәкне ул шулай, совет чынбарлыгы хәлендә күз алдына китердеме икән? Моңарчы совет системасына, төрмә-лагерьларга багышланган әсәр язучылар бер юнәлешкә — тоткыннарның бер гаепсезгә утыруларына басым ясыйлар һәм большевизмның явызлыгының төп чагылышы шул дип исәплиләр иде. Хәлбуки, бу гаепләү актына дөреслекнең яртысы гына сыйган. Безнең «особый лагерьларны» берләштергән «Луглаг» системасында Совет властеның асылын, большевизмның эчке вә тышкы рычагларын тулысынча аңлаган, аның Җир шарына, барлык илләргә, кешелек дөньясына деспотизм, җәбер-җәфалар, кыенлыклар, рухи инкыйраз алып килгәнен ачыклаган кешеләр утыра иде. Берәүләр шул явызлыкны лагерьга кадәр үк үз җилкәләрендә татыса, икенчеләр шушы канлы режимга каршы корал тотып көрәшкән кешеләр иде. Арада фикри каршылык күрсәтә алган зыялылар да байтак иде. Безнең арада: «Мин гаепсез!» — дип әйтергә тырышучылар да, совет властен яклап чыгучылар да юк иде.

Илленче елның декабрь азагында мин Свердловскиның атаклы күчеш төрмәсендә утырдым. Камера зур, җитмешкә якын кеше сыя, тоташтан фикердәшләр утыра, сәясиләр, Сталинның һәм совет деспотизмының кан дошманнары, арадан тик берәү, мадьяр, совет хәрби майоры, фамилиясе Ходяш: «Боларны, бу хәлләрне Сталин белсәме?.. Хыянәтчеләр партияне дә, юлбашчыны да алдый!» — дип чыгыш ясаган иде, аны гадәттән тыш тын калып, усалланып тыңладылар. Яклаучы табылмады. Ишетелде: лагерьга барып кергән төндә үк майор Ходяшның Сталинны мактаган иреннәрен кисеп алганнар. Безнең арада әлерәк кенә кан елгалары ярыннан — Украинадан, Литва урманнарыннан тотып китерелгән яшьләр күп иде шул...

Ни өчен утырганын кычкырып йөрүче мактанчыклар булмаса да, без юлдашларыбызның, янәшәдәгеләрнең совет режимының дошманнары икәнен белә идек, моңа шикләнми идек.

Бу хакта дәлилле сүзләр алдарак булыр, әлегә мин яшьлегемә, Совет власте гаделсезлеген бик яшьли аңлый алган якташларым янына кайтасым килә.

Әтием — Сарман тумасы, иң фәкыйрь «Ак ыштанлылар мәхәлләсе»нең имамы, утызынчы еллар башында Алабуга төрмәсендә үтерелгән Сәхәбетдин хәзрәт улы Мирсәет — Югары Баграж дигән керәшен авылына укытырга бара да шунда төпләнеп кала. Нигә туган төягеннән еraктарак, чит-ят керәшеннәр арасында калырга булганын мин соңгы елларда гына аңладым. Мулла малае булуыннан курыккандыр, ахрысы! Намуслы, эчкерсез, сабыйлык матурлыгы бер чакта да уңып бетми торган керәшеннәр яшь укытучыны зурлап каршылаганнар. Күрә әти: монда гадел, тырыш халык яши. Кулакларны куганда да Югары авыллар үз араларыннан таза тормышлы крестьяннарны читкә сөрергә ирек бирмәгәннәр. Иң эшлекле таза тормышлы кешеләрнең йорт-җирләрен алып мәктәп салганнар, авыл советы, колхоз идарәсе төзегәннәр. Ансыз да котыла алмаганнар булса кирәк, кулак хуҗаларны үз ихаталарында калдырганнар, йә таш амбарга, йә мунчага күчергәннәр. Югары Баграж тирә-якта атаклы, төзек һәм нык авыл булган. Чиркәүле авыл гына түгел, чиркәү янындагы мәктәбе белән дә дан тоткан. Утызынчы елларда ШКМ ачканнар, аннан тулы булмаган урта мәктәп — ТБУМ. Тора-бара мәктәп урта мәктәп дәрәҗәсен алды. Баграж мәктәбенә бик ерaклардан — Сарман, Зәй районнарыннан килеп укыйлар һәм бу — авылга үзенчәлекле төс бирә торган иде. Баграж — сугыш алды елларының бер мәдәни үзәге иде. Күз җиттеме, авыл гөрләп, гөжләп тора! Әллә кайлардан — Сәвәләй, Якты күл, Чыбыклы, Борды, Иштирәк, Кәрәкәс, Сармашбаш кебек ерак авыллардан да егет-кызлар килеп тула. Мәктәптә алты — сигезенче, биш — тугызынчы, дүртәр унынчы класс була торган иде. Укытучылар саны да кырык-илле җан. Нинди затлы, килбәтле, кызыклы шәхесләр юк иде алар арасында! Әдәбият түгәрәгенә утыз-кырык кеше даими йөри, күпләр шигырь яза. Җитәкчебез Василий Федорович Тарасов — «В. Багряшевский» псевдонимы белән бер-бер артлы ике китап чыгарган атаклы шәхес! Ул безнең өчен буй җитмәслек биеккә менгән пәйгамбәр! Җае чыкканда бу рыясыз, баламишкинлыгы ярылып яткан, әдәбиятны ихлас яраткан якты кешегә рәхмәтемне әйтәсем килә. Әз-мәз каләм тибрәткән берәүнең дә өметен кисмәде, өметләндерде, канат куйды, бар булган күңел байлыгын яшьләргә юмарт өләште.

Укытучылардан берәү — Осипов фамилияле Ләке авылы керәшене Пушкинның шигырь-поэмаларын тәрҗемә итеп түгәрәккә алып килә, уртага сала, кычкырып укый. Түгәрәк гөж килә, китапларда инде басылган тәрҗемәләр белән янәшә куеп, укучылар Осиповның тетмәсен тетәләр, бәхәс кыза... Якага яка килгән чаклар да, мөгаен, булгандыр! Чиркәүнең ике манарасын да авылны җылатып кисеп төшерделәр. Шуннан бирле анда клуб, ишегенең ябылып торганы юк. Спектакльнең берсе сәхнәгә менүгә, икенчесен әзерли башлыйбыз. Менә дигән режиссерларыбыз, актерларыбыз бар. Олимпиадалар кичтән таңгача дәвам итә. Түбән авылдан скрипкәчеләр менә, Сарсаз Баграждан гөсләчеләр төшә. Тирәякны җылаткан җырчыларыбыз бар: Чукмарлы ягыннан Александра Михайловна Ямашева, Олыжы тирәсеннән Бәгъдәнур Кәбиров... Багражның үз җырчысы ятим бала Николай Муханов. Ул «Мирсәет бәете»н җырласа, бөтен зал үкереп җылый. Сөйкемле Кашшаф ага Хәмитов. Директор, актер, режиссер, скрипкачы. Иң атаклы мәзәкчебез Мәхүб абый Садыйков. Кышын чаңгы ярышлары, бөтен шартлары китереп үткәрелгән кросслар, җәен бертуктаусыз футбол, волейбол уеннары... Ел дәвамында шахмат чемпионатлары. Көзлектә колхоз басуларында башак җыю, шалкан, кишер йолкулар, борчак сугарга барулар. Тәтен исе килеп торган борчак штиен корсаклар кап булганчы ашаулар. Урманда һәр агачка бөгелеп сәлам биреп, кәүсәләреннән ак күбәләк корты җыюлар. Карга боткалары, дәмәкләр, сыер ябагасыннан укмаштырган сага чөюләр. Олы көн, Тройсын, Покрау бәйрәмнәре, май чабулар. Мәйданнар. Бездә Сабан туен шулай атап йөртәләр иде. Кыскасы, өч яктан калын-калын урманнар белән уратып алынган Югары авыл үзе бер дәүләт булып яши иде.

Һәр өйдә җиде-сигез кыз яки егет фатирда тора. Беләләр, Чытыр Питрухаларының бары тик кызларны гына кертәннәрен дә беләләр, чөнки үзләрендә бер оя сөйкемле кыз бар. Бәләкәй генә ике-өч тәрәзәле өйләрдә яшәсәләр дә, Баграж керәшеннәре киң күңелле, тарыкмыйлар. Шушы кадәр ишле яу төшсә дә, авыл арасында тавыш-гауга юк, эчү-сугышу дигәннең тарихта да күренгәне булмагандыр. Аллам сакласын! Аулак өйләр, йөзек салышлар, кырау куулар, май чабулар, кәшәкәле уеннар, бәйрәмнәр, мең төрле җырлар, биюләр, һәммәсе татулыкка, үзара дуслыкка нигез булып килələр иде. Укучылар яшь ягыннан шактый чуар иде ул чакларда! Классташым Тычкый Иван бездән өч яшькә олы булса, Үткен Җәкәвенә мыек куерып чыккан иде инде. Бишенчедә, безнең белән бергә, кияүгә тупырдатып бирерлек җиткән кызлар да йөри иде.

Татарлар, керәшеннәр! Утыздан артык авылдан җыелган яшьләр. Сугыш алды малай-кызлары! Арада акыл, кыяфәт, йөреш-тотыш ягыннан бүтәннәрдән нык аерылып торган бер төркем бар иде. Ничек, ни сәбәпле мин аларны үз иткәнмендер, нинди җай белән араларына тартылганмындыр, җитеп килгән егетләр нигә дип мине читкә какмаганнардыр, мин шушы өлкән класс укучыларының сәяси әңгәмәләренә катнашып киттем. Дүртенче класстан шигырь-поэмалар яза башлап, бишенчедә «Ул үскәндә» повестен әмәлләргә тотынуым, күп санлы нәни пьесалар язып, сәхнәдән бер дә төшмичә спектакльләрдә, шахмат ярышларында чуалып йөрүем, чаңгы кроссында дүртенче-бишенче урыннарга чыгуым аркасында мин кыюланып, алар арасына барып кысылдыммы? Әтиемнең шушы ук мәктәптә абруйлы гына укытучы булуы булыштымы, егетләр миннән тарсынмадылар, читкә тибәрмәделәр. Мин алар төркеменә барып та кердем, үз кеше булып та киттем. Әллә минем яшьлегемне, бала чагалыгымны исәпләп: «Йөрсен, зыян итмәс, ишетә торсын!» — диделәрме, аңлата алмыйм. Хәзер озын тәнәфесләрдә кордашларга ияреп чая кызларның толымын тартып читкә йөгерүләр юк, мәктәп ишегалдына кысылып калган мунча мүген тәмәке итеп тартып йөрүче шамакайлар да мине ияртеп китә алмый, звонок булуга атылып чыгам да, олыларны көтәм. Хәтеремдә, әңгәмәләр озын тәнәфестә коридор башындагы аулакта, көзләрен исә мәктәп бакчасында уза торган иде. Бакча зур, уртада масаеп борынгы, агач чиркәү кукыраеп утыра. Шунда ук бер читтәрәк дәү-дәү авыр имән хачлар, кабер өсләренә шомырт агачлары утыртканнар, егетләр шул тирәне — аулакны яраталар. Спорт мәйданчыгына, ишегалды киңлегенә сибелгән кым-кырыч бала-чага хачлар тирәсендә чуалырга шүрли, зурраклар да шигәеп кырын-кырын карап юргалыйлар. Әңгәмәләрдә әлегә минем вазифам гел бер төрле: мин мыштым гына, танау тартырга да кыймыйча тыңлап утырам. Сөйләнгән сүзләрне йотлыгып тыңлыйм, тынсыз, кыю егетләр авызыннан чыккан һәр сүз минем саф, пычранмаган аңыма сеңеп бара. Баграж — олы юллардан бөтенләй читтәге, Сарман белән Зәй районнары чигендә утырган бер авыл. Әмма дөнья тамырларының хәрәкәте әнә шул тере егетләре аша Баграж урамнарына да килеп җитә. Егетләр сүзне эредән йөртәләр. Белеп, аңлап сөйләшәләр. Шушы, әзме-күпме оешкан төркем яшьләрнең илдәге хәлләр хакында усал-усал сүзләр ычкындыруы миңа көннән-көн ныграк ошый бара! Беләм, бүгеннән торып бу сүзләрне уенга алырлар, «Мактана, Аязча бу!» — дип хөкем чыгарырлар, әмма бу сүзләрдә бер нинди купайту, арттыру, бизәү юк, Тәңрем шаһит, яшьлегемдә миңа акыл өләшеп калдырган асыл егетләрнең исемнәренә һич нинди кара күләгә төшерәсем килми! Бары тик исемдә калганнарны, белгәнемне, үзем катнашкан вакыйгаларны гына язам. Әйтәм, мин яшьлегемдә бөтен җәһәттән дә акыллы, олыларча фикер йөртә алырлык камил бала түгел идем, бар иде, шыттырган, арттырган чакларым да була торган иде. Чөнки мин, Гаяз Исхакый әйткәнчә, туганда ук язучы булганмын, күрәсең. Күңелем әллә кайларга чәчелеп серләр, вакыйгалар эзли, чок-

чына, казына торган иде. Ходай миңа хәтерне вә зиһенне чумырып биргән иде. Рәхмәт Тәңремә, мең-мең рәхмәт.

Әңгәмә-очрашуларда, ул кайда гына узса да, мәҗлеснең түрендә Бигеш авылы егете, үтә сөйкемле, ирләрчә кырыс-чибәр, яшьтән үк җитди сүзнең кадерен югалтмаска ияләнгән, һәр нәтиҗәсен сыгып кына ясый торган Хәбир Зәйнуллин була торган иде. Егет бүтәннәргә караганда күбрәк укыган, урысчаны су кебек эчә, Ходайның фәрманы белән яшьтән үк узаман, олпат булып тәрбияләнгән сирәк очрый торган зат иде. Сүздә бу егеткә каршы төшүләрен, аның белән бәхәскә кергәннәрен хәтерләмим. Бүтәннәр кызып киткәндә ул дәшми, түзә, иң азактан гына саллы итеп фикерен уртаклап куя торган иде.

Мин Хәбир Зәйнуллинны тәү тапкыр телгә алып, аның тормышы белән кызыксына башлагач, киленебез Энҗе, энем Алмазның хатыны, төп Бигеш кызы: «Мин Хәбир абый хакында кайчан сорашырсың икән, дип көтеп йөри идем»,— диде. Димәк, Энҗе дә аны башкалардан аерып куеп, күңелендә хөрмәт белән искә алып йөри икән. Эшкә керешер алдыннан мин Энҗегә хат язып салдым һәм: «Хәбир түгәрәгенә йөргән егетләрнең берәрсе исән түгел микән?» — дип сорадым. Белүемчә, ул түгәрәккә катнашып йөргән егетләр сугышка китеп, эзсез-өнсез югалганнар иде. Эзләре бар аларның, бар, ул кыю бөркет-шонкарлар хакында якты сүз әйтүне Ходай миңа йөкләгән булып чыкты. Хәбир түгәрәгенә актив йөргән, уртак фикерләрне кыю яклаган ул заманның чая егете Гәрәй Гәрәев кенә исән икән...

Энҗе киленем Хәбир белән бер чордарак Багражда укыган, исән калган хатын-кызларга дәшеп караган һәм миңа түбәндәге хатны салды:

**«Бигештән Багражга унлап егет укырга барган: Хәсәнов Камал, Исмәгыйлов Ибраһим, Муллин Әхмәт, Шәмгунов Фәйзи, Кәлимуллин Әбрар. Түләп уку кертелгәч, күбесе мәктәпне ташлап кайткан. Хәбир Зәйнуллин, Гәрәй Гәрәевләр белән аралашып йөрүчеләрне хәтерләүче юк. Мәгәр шундыйрак фикер бар: Хәбирнең якын дуслары Дүрт Мунча егете Кәшипов Рәүф, Ашыт авылыннан Нигъмәтуллин Галимҗан булмадымы икән? Алар бик шәп укыганнар, чая булганнар, мәктәптә иң уңганнардан саналганнар. Ул вакытта Багражда укыган Гәрәева Оркыяападан төпченеп сораштырдым, мәгәр ул да күп нәрсәне оныткан. Бик күптәнге хәлләр бит! Гәрәй Гәрәев авылга кайтмасмы дип йөрдем (хәзер ул Чаллыда яши), кайтмады. Шуңа өстәп ни языйм?»**

Хәзерге акыл белән үлчәп-үлчәп карыйм: түләүле уку кертү болай да такы-токы яшәп яткан татар крестьяннары арасында зур ризасызлык тудырган! Әнә шул тоташ дулкында туып-яралдымы уйчан Хәбир Зәйнуллиннар? Кызып укып, зур-зур планнар корып йөргән җирдән иптәшләренең, дусларының мәктәпләрне ташлап кайтып китүе Хәбир төркеме әгъзаларының телендә түгел идеме?

Әйе, батырып әйтә алам: сүз, бәхәсләр асылда илдәге гаделсезлекләр турында бара иде: Авыл кешеләре ач, фәкыйрьләр һаман бөлә бара, өй саен дүрт-биш бала, күбесе мәктәпкә йөри алмый — өс-баш койты, инде чамаңны туры китерергә тырышып, зиһенлерәген сайлап, мәктәпкә урнаштырсаң, авызыңнан өзеп, ипиен-бәрәңгесен җибәреп торасың... Мә сиңа! Инде укыган өчен дә салым түләргә кирәк! Яшьләр дәртле, гаярь, үз шәхесләрен табып алырга омтылган чаклары. Сүздән сүз чыгып, Хәбир егетләре кайбер адәмнәрнең авыллардан кинәт кенә югалуына да хәйран калалар иде. «Фәлән авылда фәлән кешене төн уртасында алып киткәннәр дә хәзер кайдалыгын белмиләр икән!» Мисаллар җитәрлек, әңгәмә саен кемдер тагын бер мисал китерә. Бүген бер мисал, иртәгә икенчесе, өченче көнне нәтиҗә ясарга тырыша егетләр!

Иң гаҗәбе шул: егетләр бөтенесе дә бер нәрсәгә ышаналар — юлбашчыбыз Сталин бу хәлләрне белми икән, илдәге чын хәлне, аны урап

алган хыянәтчеләр яшерә икән. Әгәр белсәме?! Иптәш Сталин арт сабакларын укытыр иде!.. Имеш, фәлән авылдан фәлән укучы Надежда Константиновна Крупскаяга хат язып, үзләрендәге яман эшләрне фаш иткән дә... теге егетне орден белән бүләкләгәннәр! Безнең якларда да яман хәлләр юкмыни, нигә без генә тик ятабыз?!

Очрашкан саен сүз шул тирәдә йөри, очрашкан саен фикер яңа мисаллар белән баетыла, арага имеш-мимешләр дә кысылгач, безнең егетләр кызып ук китәләр! Йодрыклар яшен булып түгәрәк эчендә уйный.

Болар һәммәсе дә минем яшьтән алган сәяси сабакларым иде. Рыклин-Заславскийлар: «Белмәдем, ишетмәдем!» — дип тәлкеләнсәләр дә, чырайларына гамьсезлек битлеге япсалар да, Югары Баграж мәктәбе укучылары әнә шул дәрәҗәдә сөйләшеп, илдәге сәяси хәлләрне шул югарылыкта аңлап, мине үзләренә ияртеп йөрттеләр. Егетләр мәктәптән тыш очрашалар идеме, белмим, алары хәтердә калмаган. Аларның шул дәрәҗәдәге җитди сүзләрен мин яшерен уен диебрәк кабул иткәнмендер, җәйге каникулларда Гәрәй Гәрәевкә, Бигешкә, хат язуларым, өчпочмаклы хатларның чит-читен җөй машинасында тегеп җибәрүләрем исемдә. «Теге хакта язмыйм», — дип искәрткән чакларым да бар иде. Ни хакында язганмындыр, әйтә алмыйм.

Көннәрнең берендә ишеткән хәбәрем Хәбир Зәйнуллинны гына түгел, мине дә тетерәндерде. Авыл егетләрен һөнәр мәктәпләренә, шәһәрләргә, ФЗӨләргә алып китә башлыйлар икән! Бу хәбәрне егетләр авыр кабул иттеләр. Әле теге яман сүзләр читкәрәк барып төшсә, бусы нәкъ аларга төбәлгән, аларга килеп кадала иде. «Татарстан егетләрен Донбасс шахталарына җыялар икән, әгәр унынчыны тәмамлаганчы безне алып китсәләр — баргач та шахталарын шартлатабыз!»

Бу инде буш сүз генә түгел иде! Бу — яшьләрнең алдагы тормышларына корган планнары иде. Мин бу сүзнең кайчанрак тууын ачыкларга теләп, тарихка мөрәҗәгать иттем.

«СССРның хезмәт резервлары турында Указ» 1940 елда чыккан икән. Анда болай диелгән: «Колхоз рәисләре мобилизация тәртибендә (ундүрттән илле бишкәчә) 100 кеше исәбеннән ел саен һөнәр һәм тимер юл училищеларына 14—15 яшьлек ике үсмерне, ФЗӨ мәктәпләренә 16—17 яшьлек икене җибәреп торырга мәҗбүр итәргә!» Бу Указ «Правда» газетасының 1940 ел, 3 октябрь санында басылган. Димәк, Хәбир Зәйнуллиннар кырыгынчы елның көзендә унынчыда укыган булып чыга. Утыз җиде, утыз сигезләрдә илдә барган кулга алуларны егетләр әзме-күпме чамалаганнар булса кирәк. «Татар егетләрен Донбасска, күмер базларына көчләп җыялар икән», — дигән хәбәр авылдан-авылга чабып кына йөри торган чаклар.

Крупскаяга хат язып, сукыр Сталинның, күрәкарау Политбюро члennарының күзен ачарга тырышучы безнең арада юк иде дип кем әйтә ала?! Егетләрнең фикерен йомгаклап, Гәрәй Гәрәев Сталинга озын хат яза һәм почтага төшереп сала. Хат озын, барыр юлы гына кыска була: коты чыккан почта хадиме аны ашыгыч рәвештә директорыбыз Кашшаф ага Хәмитовка китереп тоттыра. Хатны ачып... укый башлагач... танышкач (!!!!!) Кашшаф аганың күзе шакмак була. Ул җитәкләгән мәктәптә ЧП! Бунт! Фикер бунты! Аңа кадәр директор булып эшләгән Хәернас Вәлиев эзсез югалган!.. Чират бүген аңа җиткәнме?.. Хат органнар кулына барып керсә... Фу, каян чыга диген шушы кадәр салкын тир!.. Акыллы, зирәк кеше Кашшаф ага, тормыш тәҗрибәсе җитәрлек... Бу юлы ул тәмам аңгыраеп кала. Үзен-үзе кайсы ярдан ыргытырга белмичә мәктәп бакчасына чыга, кулын артка куеп, авызын бер ачып, бер ябып йөргәндә яшь, бунтарь ваемсыз Гәрәй Гәрәевкә тап була! Үзе! Нәкъ каршысына килә. Ул Гәрәйгә карый, Гәрәй аңа карамый... «Ух, башсыз кирәкә!» — дип уйлагандыр Кашшаф ага. Тик сүз катарга ашыкмаган, сагайган. Илдә ниләр барлыгын белүче зирәк кеше иде мәрхүм. (Кашшаф аганың

вафатыннан соң кызы Ләйлә әткәсенең байтак еллардан туплап килгән архивын миңа тапшырды. Калын-калын дәфтәрләр... Шигырьләр... Истәлекләр. Авыр елларның шаһиты Кашшаф ага сак булган, салкын суны да өреп капкан. Арадан бер җөмләсе мине сискәндерде! «Бүген иртәнчәк, яктырыр-яктырмаста, кулакларны авылдан сөрделәр. Атларга төялешеп киттеләр. Ни гаҗәп: аерылганда берәү дә жыламады, күз яше күрсәтмәде». Кашшаф ага, Кашшаф ага!.. Шушы бер җөмләгез дә дөнья бәясе тора, рәхмәт сезгә! Иллә мәгәр шушы тарихи вакыйганы киңрәк итеп теркәп калдырсагыз, сана!)

Төсе киткән директорга карап, шук Гәрәй ни уйлагандыр, белмим. Сталинга адресланган хат аның кулындадыр дип уйламаган, әлбәттә. Аптыраган Кашшаф ага батып барган саламга ябышкан, түтәлләр арасында аунап яткан такта башын күрсәткән дә: «Гәрәев, шул нәмәстәкәйне укытучылар бүлмәсенә кадәр илт әле!» — дигән. Үзе дә арттан ияреп кергән. Шунда икәүдән-икәү калгач, кара-каршы утырып, Кашшаф Хәмитов ялвара башлаган. Сүгенмәгән, бакырмаган, каушавын да яшерерлек көч тапмаган, кат-кат үтенгән. Йомшак тавыш белән ялынган! «Моннан болай андый хатлар яза күрмә, язсаң — миңа укыт. Башыңны бетерерләр. Әйдә, бусын ертып ташлыйк та онытыйк», — дигән. Хатны шунда ук мич авызына тыгалар, директор ишекне ачып та тормастан кәгазьгә ут кабыза, бүлмә төтен белән тулганчы мич авызыннан күзен алмый директор. Соңра, почмакка сөялгән такта башына абынып егылгач, Кашшаф ага үкереп җибәрә: «Кайсы ахмагы керткән монда бу имгәкне!» — дип кычкыра...

Бу гыйбрәтне байтак еллар үткәч, 1947 дә, мин комсомолда, Гәрәй Гәрәев Район мәдәният бүлегендә хезмәт иткәндә, без икәү Ксения Федоровна Роксманда фатирда торганда яшьлекнең кызык бер истәлеге итеп үзе сөйләгән иде. Гәрәй дус, хәтерлисеңме?!

## 8

Халык язмышын бер бөтен итеп күрә алу сәләте — табигать тарафыннан бик сирәк кешеләргә эләккән бүләк. Үсә төшкәч, күз сыйдыра алган офыклар киңәйгәч, халыкның уртак язмышыннан чыгып аерым шәхесләрнең яшәешен аңлыйсың да, аңлата да аласың. Үсмер чакта, синең рухың әле дөньяның дүрт ягына да тартылганда, аерым кешеләр язмышыннан башканы күрә алмаганда, шул, аерым кешеләр тормышына карап, дөнья кануннарын аңларга, үзләштерергә тырышасың. Ерак-еракта, мәдәни мәркәзләрдән, дөнья язмышы хәл ителә торган үзәкләрдән бөтенләй читтә, тәмам онытылып яшәп яткан керәшен авылы тормышы никадәр бай, эчтәлекле һәм минем өчен гыйбрәтле булмасын, яшьтән үк тирәнтен дөньяви белем ала алмадым. Аның сәбәпләре күп һәм төрле. Алай да табигать бүләге — сизгер күңелем бик яшьтән дөньяда гаделсезлек барын, адәм улларының тигез яшәмәвен үзенә кабул итеп, аңлап алды. Әле без дәүләт оешмаларының сатлык икәнен дә, крестьянны кычкыртып талавын да күреп-аңлап бетерә алмый идек, әлбәттә. Әмма көндәлек гаделсезлекләрнең берсе — ачлык белән һәрдаим күзгә-күз очраша торган идек.

Ачлык, ачыгу, ачлар... Әгәр яшәештә иң олы сүз булмаса да, ачлык бик зур, куркыныч сүз. Бу хакта язу кыен. Укуы да сөенеч булмас, мәгәр тормыш юлымның бик күп тармакларына ачлыкның турыдан-туры мөнәсәбәте булганга сызган буразнамнан читкә тайпыла алмыйм. Әле соңгы очрашуларның берсендә: «Сез татар халкының язмышын бик иртә аңлый башлагансыз. Моңа ни сәбәп иде?» — дип сорадылар. Уйландым һәм: «Мөгаен, мин шаһит булган ачлыктыр!» — дип җавап бирдем.

Ачлык турында аз язылмаган. Татар әдәбиятында аның иң көчле мисалы Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» әсәре. Балачакта мин Ибраһимовның шул әсәрен генә укып калдым, әдипне юк иттеләр. Алай

да исемдә, якташым, бер мәктәптә укучы Гурий Тавлин белән йорттан йортка кереп: «Сездә Галимҗан Ибраһимов китаплары калмадымы?» — дип сораштырып йөргән идек. Колхоз активистларына кермибез, партиялеләрне урап үтәбез, йортларыннан куылып таш амбарларга, кысан мунчаларга күчкән кешеләргә керәбез бит, әй! Алар безнең хакта ни уйлагандыр, белмим.

«Ачлык» дигән мәгънәне мин әүвәл башлап әнием авызыннан ишетеп, зиһенемә сеңдереп калганмындыр. «Егерме беренче елда кешеләр кызыл балчык ашадылар», — дип, кемнәрнедер кызганып, җылый-җылый сөйләгәне хәтердә. Китаптан укып, кеше сөйләгәннәрне тыңлап кына ачлыкның ни икәнен аңлап бетереп булмый. Озакламый мин а ч л ы к н ы ң чыны белән күзгә-күз очраша башладым һәм ачлар аша, ачлар белән бергә янәшә яшәп кенә ачлыкның олы хәсрәт, зур бәхетсезлек икәнен аңладым. Ачлык, ачлар мине язучы ясады дисәм дә, ялган булмас...

Югары Багражда без чиркәү мәйданында, балта остасы Әндриян дәдәйләр йортында яшәдек. Әндриян дәдәйләр киткән җирләреннән — Федот детдомыннан кайткач, Урта урамга күчеп килергә мәҗбүр булдык. Чиркәү каршындагы йортларда таза хәлле кешеләр — Үртәми дәдәйләр, Боярлар яши иде, без барган урам хуҗалары хәлсез, өшәнгән кешеләр иде. Безнең йортка каршы таланган бер ихатада, ярым җимерек сынар тәрәзәле йомык өйдә Үткен Романнары тора икән. Аларның миннән өч яшькә олы Җәкәүләре белән бер класста укыйбыз. Роман дәдәй җинел сөякле, какча, юка кеше. Ул итекче, авылның күн итекләрен, каталарын (керәшеннәр ботинканы шулай диләр) төзәтә, ямый, ипкә-сипкә китерә. Авылның күпчелеге чабатадан йөргәнгә, итекчегә эш тә әллә ни булмагандыр, бүтән бер сәбәп бар идеме, Роман дәдәйнең биш-алты баласы булса да, мин алар ихатасыннан балалар шау-шуын, куанышып көлгәннәрен, йөгерешеп йөргәннәрен күргән-ишеткәнем булмады. Мин Җәкәү белән аралашып йөри башлагач та әни катгый тавыш белән кисәтте: «Кара аны, малай актыгы, Роман дәдәңнәргә кереп йөрисе булма, яме!» Бу сүзгә колак салмаган да булыр идем, Җәкәү уйнап арып капка төпләренә кайткач, мине шунда калдырды. «Көт шушында, хәзер чыгам!» Җәкәү — олырак, аның сүзе закон. Мин танавымны тартып, аяк очыма баса-баса сынар тәрәзәгә үрелеп, җилкапка төбендә көтеп калдым... Ә минем Роман дәдәйләргә керәсем, аның итек-читек ямый торган безләрен, инәләрен, бүтән кораллары күрәсем килә. Шулай да бер мәртәбә әни күрмәгәндә, Җәкәү өйдә юкта мин Роман дәдәйләргә барып кердем. Язын иде бу, ужымнар күтәрелеп, бәрәңге сабаклары калкынып килгән чак... Кердем һәм ишек катында сеңдем дә. Җәкәү каядыр киткән иде, бүтәннәр, өй эчләре белән җыелып, өстәл тирәсендә тамак туйдыралар. Уртада чите кителгән кара чуен, чуенда яшькелт-көрән боламык... Шул боламыктан килә икән бу әче ис!.. Бәрәңге яфрагыннан пешергәннәр ич болар ризыкларын! Роман дәдәй хатынының иелә-бөгелә бәрәңге яфраклары җыеп йөргәне күземә чалынган иде. Өстәлдә бүтән берни дә юк, ипи заты да, сөт-мазар да күренми, алай да дәү-дәү өрәңге кашыклар чуен белән авыз арасында тиз-тиз йөреп торалар. Мине күрүче дә, күз салучы да булмады... Чуен бушап, идән белән түшәм арасында әче ис кенә калгач, Роман дәдәй хатыны сапсыз тустаганга, кат-кат ямалган кружкаларга казаннан чәй дип аталган кайнар су сосып өләште. Самавырлары да юк икән!.. Шикәрсез, иписез тегеләр пешенә-пешенә чәй эчәргә тотындылар, кулларына тиклем пешә!.. Маңгайларына тир бөртекләре чәчрәп чыкканчы күп итеп эчтеләр чәйне. Мин ул арада өй эчен карап, тикшереп чыктым. Бер почмакта бәләкәй генә өстәлгә тезеп куелган вак-төяк кораллардан башка Роман дәдәйнең ис китәрлек бер хәзинәсе дә юк икән. Алай гынамы, мендәр-ястыклары да юк икән бичараларның. Алар сәкегә иске, йоны иегән тиреләр җәеп, өсләренә киеп йөргән иске чикмәннәрен, алача тышлы ямаулы бишмәтләрен ябынып йоклыйлар икән. Үтә ярлы, фәкыйрь булган икән Үткеннәр!..

Аларның нәселдән килгән кушаматлары Үткен иде, фамилияләре дә Байковлар. Колхозга кермәгән «ярлы тәккәббер» Роман дәдәй. (Әни сүзе!) Налог арты налог салып, юк-бар өчен дә акча түләтеп желегн суырганнар аерым хуҗалыкның. Заемнар белән каезлаганнар. Боларын хәзер генә аңлыйм! Ул чакта да аңлаганым житәрлек булган. Җәкәү кайтмагач, мин аска карап, юаш кына атлап урамга чыктым һәм Үткен Романның хуҗалыгына башка бер күз белән карадым. Йортның ояддысы да юк икән ләбаса! Озын-озын усак корыкларны өйнең арт ягына сөягәннәр дә шуны салам белән томалагандай иткәннәр. Шунда аларның кәҗәсе һәм бер сарыгы кышлый. Сарык-кәҗәләре булса да мин аларның сөтле чәй эчкәнен яки итле шулпа ашаганын искәрмәдем! Бар булганны салымга чыгара барганнар икән лә алар!

Роман дәдәйларнең ничек яшәүләрен олылар ачык белгәндер белүен, әмма бала-чагаларыннан серләре бер кая саркып чыкмады. Җәкәүнең: «Ашарыбызга юк, утын бетте, малга курмы житми»,— дип зарланганын ишеткәнем булмады. Ул безгә сирәк булса да кергәләп йөри, аш өстенә туры килгән чаклары да була, ләкин үтереп кыстасаң да, табынга утырмый, тартып китерергә тырышканда, аякларын идәнгә терәп, каршы килә, «Мин тук, әле яңа гына тамак туйдырган идем»,— дип кабатлый.

Бу юлы мин жилкапка төбеннән тиз генә аерыла алмадым. Җәкәүне күрәсем, нидер әйтәсем, юатасым килде бугай... Өйгә керәм дигән мәлдә Сарсаз тыкырыгыннан Җәкәү килеп чыкты. Ул биленә нәни генә киндер капчык таккан иде. Мине күргәч тә ялт борылып китте һәм әллә кайлардан урап, ындыр артларыннан әйләнеп күзгә күренмәскә тырышып, өйләренә йомылып кереп югалды. Шигемне әнигә әйттем, ул авыр итеп бер көрсенде дә: «Хәер сорашып кайтып килә бичара. Ашарларына юк. Ачыгалар»,— диде.

Мин мөгаллим баласы, әти хезмәт хакы — акча ала, ара-тирә — паек, ондыр, ярмадыр. Әни җөйче, кыз-кыркынга күлмәк тегә әз-мәз анын да кереме бар, безнең тамак тук. Өс тә бөтен. Тик безнең күршедә, каршыбызда гына Үткен Романнары яшәп ята. Кайчандыр, борынгы заманнарда, мөселман чакта кушаматлары Үткен булган аларның. Юкка тагалармы авылда кушаматны? Үткен булгандыр Роман дәдәйнең ата-бабалары... Безнең яшьлеккә нибарысы кушаматлары гына калган. Роман дәдәй чүккән, беткән... Тәрәзәдән караган саен жылысыйм килә иде минем. Дөньяның тигезсезлеген беренче тапкыр таныткан, күңелемә «ачлык» дигән комсыз сүзне сеңдергән Үткен Романын хәзер дә бик яхшы хәтерлим. Ике якка бөтерелеп менгән, балавыз белән катырылган мыеклары да исемдә. Җәкәү сугыш башлануга армиягә алынды һәм Суслонгер лагеренда эч зәхмәтеннән сырхаулап, дөнья куйды...

Хәзер Маркс тәгълиматының «XX гасырның иң куркыныч ерткычы» икәнен (урыс рәссамы Илья Глазунов сүзләре!), Ленин эшчәнлегенең канлы эзтәлегән, большевиклар хакимиятенең чикләнмәгән явызлыгын аңлагач: «Мин әллә-ә-ә кайсы вакытларда ук боларны аңлый идем!» — дип, бер оя тере саескан очыручылар күпләп очрый башлады... Белдек дисәк тә, утызынчы еллар хакында без әле тулаем белмибез. Украинада ачлык. Большевиклар тарафыннан махсус оештырылган ачлык. Казакъстанда тоташ ачлык. Ил мәйданнарында миллионлаган крестьяннар шешенеп үлә, бала-чага кырыла. Җир хуҗасыз кала, таза тормышлы крестьяннар, авылның каймагы читкә сөрелеп, эш башында «комбедлар» — кияргә ыштаны булмаган ачбетләр менеп утыра. Үчне ала болар таза хәллеләрдән! Утызынчы еллар фаҗигасен тәмам өйрәнеп, тарихның якасына ябышып хаклык таләп итеп ул чорны әдәбиятта беркетерлек әсәр бармы татар әдәбиятында? Юк андый әсәрләр. Мин шулай саный идем. Ул хакта әрнеп язып чыкканнарым да булды. Татар язучылары кулга-кул тотынышып, гөрләп-җырлап колхозга кергәннәр һәм шунда калганнар да. Урыс әдәбияты исә чорның бөек үрнәкләрен калдырган. Шагыйрь Клюев: «Социализм урыс крестьяннарына бәлгенлек һәм һәла-

кәт китерәчәк»,— дип раслаган. Андрей Платонов социализмның илгә җимереклек, халыкка чиксез бәла-казалар китерәчәген алдан күргән. Большевизм аякланып килгәндә үк аның барыр юлының өметсез, нәтиҗәсез буласын ап-ачык аңлаган.

1991 елның 1 маенда язучыларның Переделкино иҗат йортыннан китәсе көнемдә, иртәнге чәйдән соң, мөхтәрәм Әмирхан ага Еники белән йөрергә чыктык. Ул да анда иҗат итеп ята иде. Урман-кыр сукмакларында ике сәгатьтән артык дәвам иткән сәяхәтебез дәвамында мин күпне татыган өлкән агама байтак сораулар бирдем. Җөмләдән, шундый сөалем да булды: «Сезне дә теге елларда Черек күлгә чакырып йөрттеләрме? Хәвефле заман икәнен тоеп яшәдегезме?» — дидем. Әмирхан ага гомергә җитди булды, һәр сүзен җаваплылыкны сизеп әйтә килде. «Тоймыйлармы соң, бик сизә идек! Әгәр икәү әңгәмә сугып торганда янга өченче берәү якыная башласа, шунда ук, «җилкәннәрне күтәрә» торган идек... Черек күл димәктән, бер тапкыр чакырып алдылар. 1934 ел иде. Артыгын талкымадылар, нибарысы бер сорау бирделәр. «Сез шагыйрь Сириннең иҗатына ничек карыйсыз?» — диделәр дә, җавап әзерләргә кушып, мисалга бер шигырен китерделәр. Шигырь болайрак иде: авылдан куылгач эзсез югалган крестьяннарның хатыннары итәк тулы балалары белән Казанга киләләр дә Болак күпере өстендә хәер сорашып, җылашып утыралар. «Сез шушы шигырьдә Совет властена каршы мотивлар күрәсезме?» — диделәр. Фикеремне, алар таләп иткәнчә, язмача итеп бирдем. «Күрмим,— дидем,— шагыйрь бу юлларда әнә шул хатыннарга, бала-чагаларына шәхси теләктәшлеген генә белдерә». Бүтәнчә Черек күлгә чакырып йөдәтмәделәр. Аннан мин тиз арада Ташкентка китеп бардым, эзем югалды, мөгаен, төрле-төрле хәлләрдән, җәзалардан мине шул ерак сәфәр коткаргандыр...»

Димәк, татар әдипләре арасында да утызынчы еллар фаҗигасен аңлаган, аңа протест йөзеннән үз сүзен әйтә алган шәхесләр дә булган икән! Берән-сәрән очраштырган. Ә язучыларның күпчелеге, галим-әдип Мөхәммәт Мәһдиев мисаллар белән раслаганча, утыз җиденче елны тырышып-тырышып әзерләшкәннәр, нарком Ежовларга мәдхия укыганнар һәм үз-үзләренә баз казышканнар. Ленин-Сталинны, кәҗә сакал Калининнарны күккә чөюләрен әйтеп тә тормыйм...

Әмирхан аганың хәтере ачык, сүзен үткәзеп әйтә, Переделкинода очрашканнан соң күңелемне бер горурлык биләде. Горурлык биләү дә эчке халәтнең бер мисалы!..

Чор фаҗигасен шагыйрь Сирин аңлаган. Әдәбиятта шул фаҗигане ул беркетеп калдырган. Тик, кем ул Сирин? Кайда, ничек яшәгән? Ничек дөнья куйган? Безнең көннәрдә вафат булган бу олы затны без тоташтан белмәмешкә салыштык. Аның чордашлары бахырны тырышып-тырышып оныттырдылар. Без онытырга әзер халык, кушсыннар гына. Тагын әрнеп кабатларга туры килә: татар акылы төштән соң! Черек күл әһелләрен сагайткан ул шигыре исәнме Сириннең?

Һәр көне, һәр минуты татар халкына кайгы-хәсрәт ташыган сугыш еллары... Өметсезлек соңгы чигенә җитеп бәгырьләргә төшкән, җанны суырган сугыштан соңгы еллар!.. Бу дәвер турында әдәбиятыбызда байтак әсәрләр язылган. Аларның күпчелеге ялганга, күз буяуга манчылган булса да, арада дөрес фикерләр, үткен күзәтүләр, әрнүле нәтиҗәләр дә ялтырап китә. И, эчертте инде колхозлар татар крестьянына лаеш шулпасының кайнарын!

Безнең эрага кадәр 116 — 27 елларда яшәгән Рим язучысы һәм галиме Марк Теренций Варрон «Авыл хуҗалыгы турында трактат» дигән мәшһүр әсәрендә зирәк бүленеш бирә: «Эш кораллары өч төркемгә бүленә: теле барлар, мөгери алучылар һәм телсезләр. Теле барларга коллар керә, мөгери алучылар — үгезләр, телсезләр — арбалар булып чыга». Без белгән, без чиләнгән колхозларда бу мәгънәләр урыннарын

алыштырып бетергән иде инде. Арбалар — телгә килгән, алар май сорап туктаусыз шыгырдый, мыгырдана. «Телсезләр» исә утызынчы елларда авызлары йомылган крестьяннар үзләре иде. Үгезләр генә үз урыннарын бирмәгәннәр, юк, дөрес әйтмим икән, үгезләр сыерларга мәхәббәтләрен онытып тәртә арасына кергәннәр, алаша дәрәҗәсен алганнар иде.

Илдә совет хакимияте урнашканнан бирле ачлык крестьян белән гел кочаклашып йөрде, үз тырнагыннан ычкындырмады ачлык авыл халкын.

Замандашым Мөнирә Гатауллина сөйли. Мөслим районының Мәллә-Тамак авылы кызы. Акыллы, зиһенле, ихлас хатын!

**«1944 елның ямьле май ае... Ир-атлар, тракторлар юк. Арба-чана кырылып беткән. Көзен күпчелек иген кырда утырып калды. Беркемгә бер башак өзәргә, бер көлтә кыстырып алып кайтырга рөхсәт итмәделәр. Көз. Яңгыр ява, кар төшә, карт-корылар басу башында тәгәрәп җылыйлар. Басу юлларында тарантаска киерелеп утырган рәис белән вәкил генә йөри. Әби-сәби, бала-чага янчык тотып башак уарга чыкса, аны ат белән таптаталар. Урылган, чүмәлә-кибәннәргә куелган иген-таруның да яртысыннан күбрәге кар-яңгыр астында утырып калды. Әле без, бала-чагалар, һәммәсен аңлап бетерә дә алмыйбыз, әти-әниләр ятим басуларга карыйлар да күз яшьләрен тыя алмыйлар... Буш буралар, буш өсәкләр белән кышка кердек. И озын, и авыр иде Сталин заманының кышлары! Без ифрат зур гаилә. Әтием Мөхәммәтханга илле яшь, ул фин сугышында яраланып кайткан, матур гына аксап йөри. Сөйкемлеләрнең сөйкемлесе! Әни вафат булгач, әти безгә яшь әни алып кайтты. Яшь әни егерме тугызынчы елгы кызын ияртеп килде. Без биш бала! Уртак ике бала туды. Кышны ничек чыкканбыздыр, ни ашап җан саклаганбыздыр, алары истә калмаган. Ул чакның авыр хатирәләрен алдагы, язга чыккач күргәннәр күмеп китте. Ниһаять, сагындырып кына кояш әйләнеп кайтты. Басу-кырлар кардан ачылды. Яктыра башлауга яшь әни альяпкычын биленә бәйләп басуга чыгып китә, капчык-янчык алырга да курка бичара! Хәтерле иде безнең әни, кайда нәрсә ятканын белә, монда кибән төбе калган, тегендә эскертне ташып бетермәгәннәр. Юлларга басарга да куркып саз ерып, бата-чума эскерт төбенә баралар болар. Башакларны чи саламнан теш белән өзеп, кара тиргә батып, алларына тутыралар. Чабаталарга ябышкан батман-батман кара балчыкны сөйрәп, ыңгыр артлатып аһылдап кайтып авалар. Без, бала-чагалар, башакларны тиз-тиз уарга тотынабыз. Кучтаннар килеп кермәсен, активист-коммунистлар күрмәсен. Калган салам-солымнарны тиз-тиз яндырабыз, мич төбенә калай куеп, бөртекне киптерәбез. Һәр өйдә диярлек ярма ташы бар. Аны базда яшереп тоталар, тавышы чыкмасын дип, бөртекне базда ярабыз. Аннан инде бәйрәм: әчегән исле буын атып, ямаулы казанда бутка пешә. Сигез бала, уналты ач күз белән буткалы казаннан күзебезне алмыйбыз...**

**Күрше хатыннар белән барган әни бер көнне тары кибәне төбенә юлыккан. И куаныштык, куе итеп тары буткасы пешердек. Ярмаларның быгырдап казанда сикерешкәннәре әле дә күз алдымда. Гаҗәп хәл: урамда бала-чага тавышы ишетелә башлады! Вәкил дә күрә бу хәлне, рәис тә сукыр түгел — тәки басу капкасын ачтылар! Безнең өйдән бер көтү кеше чыгып, үрә башлаган бодайны сөенә-сөенә алып кайтып, өй түбәсенә меңгереп тараттык. Әти тегермәнгә барып кайтты. Куанычтан нишләргә белмибез! Тәмле исләр таратып өйдә күмәч пеште! Авыз тутырып кәлчә ашадык. Өстәл тирәли тыгызланып утырдык. Әти сөенә, и сөенә, әле беребезнең, әле икенчебезнең аркасын кага. «Ашагыз, балалар, ачтан гына кеше үлә, ашаган кеше яши ул!»— ди. Шул чагында нинди сүзләр әйткәнен шәйләгән булса... Хәер, белсә дә, якынаеп килгән Үләт чиреннән, Кан чиреннән коткарып кала алыр идеме?..**

**Апрель азаклары, ямьле майга кердек. Корсаклар тулы диярлек, ә безнең өйдә күңелсезлек, балалар хәлсез, барыбыз да боектык, күз төпләребез шәмәхә-зәңгәр. Кем өзлексез корык-корык ютәлли, кем: «Хәлем**

бетте»,— дип сәкегә менеп ята. Һәр бала үзенчә авырый башлады. Күпчелек тамак авыртуыннан зарлана, әни орыша: «Салкын су эчкәнсездер, күмәч-көлчә шулай кибектерә ул!»— ди.

Өйдән-өйгә аякланып хәбәрләр таралды: элек бер дә ашарына булмаганнар гына чиргә сабышкан икән! Теш арасына таза икмәк, сирәкмирәк ит, сөт катыштырганнар сау-сәламәт йөриләр икән! Утыз алтынчы елгы энекәшем Мөхәммәтҗан беренче булып ауды. Искиткеч чибәр, зирәк бала иде! Иртән «Тамагым авырта, сызлый!»— дип җылап уянды, әндри әбәтендә урын өстенә бөгәрләнеп ятты, кичкә йөткергән саен тамагыннан кара кан китте. Төнлә кан тоташтан ага башлады. Ике көн канга тузып ятты да үлде бичара. Күмеп кайтабыз сабыйны, мин әти янында арбада, шунда әти кытыршы кулы белән муенымны кытыклады да: «Әле жиргә хәер биреп кенә кайтабыз, кызым, шушы көннәрдә үзем дә сабыем янына киләм»,— диде. Кайтып керсәк, кырык беренче елгы энем Әнәс егылган. Күзләрен зур ачып томырылып карап ята нарасый, ирен читләреннән сызылып кына кан килә...

Авылыбызга ишелеп кайгы килде, сабыйлар гына түгел рәттән олылар да чирләп тәгәрәде, өй борынча мәет озаталар. Ганләләре белән тоташтан үлеп ятучылар булды. Чирлеләрнең чуты-кырые юк. Мәетләрне куярга кеше җитми! Авыл советы, колхоз идарәсе кичтән нәрәт бирә: «Фәлән-фәлән кешеләр иртәгә кабер казырга чыгалар». Кемнәргә икәнен тәгаенләп тормыйлар, казыйлар һәм ләхетләрнең берсе дә буш калмый! Казаннан врачлар төяп, ике самолет килеп төште. Чокчыналар, тикшерәләр, кан алалар!.. Мәктәптә госпиталь ачтылар, чирләгәннәрне шунда ташыйлар. Нигәдер безнең өй эченнән берәүне дә госпитальгә салмадылар. «Аталы өй, чарасын табарлар!»— дигәннәр, имеш. Өч көннән Әнәс үлде... Ниһаять, өй тоткасы әни егылды. Яп-яшь, энҗе тешләре тезелеп киткән чибәр иде яшь әни!.. Алты айлык имчәк баласы бар. Имә сабый, әни үзеннән бигрәк бала өчен яна-көя, «чирем йогар», ди. Ходайның шәфкате киң, сабый чирләмәде, әле дә исән...

Әни үләсе көнне әти егылды... «Ирең егылды, кереп кара»,— диләр әнигә, ул ояддында ята иде, тора алмады, хәле җитмәде. Әтидән кан күп акты, өч бала канлы чүпрәкне кулдан кулга биреп торабыз. Борыныннан, авызыннан туктаусыз кан саркый. Ике көннән соң балаларны әти янына кертми башладылар... Үз гәүдәсен үзе атып бәрә икән, көчле, гайрәтле кеше иде мәрхүм. Күрше-тирәдән олылар кереп, аны бастырып тотып торалар икән... Дүртенче көнне, сәгать икедә әти үлде... «Чыптага төреп күммәгез, балалар!»— дип ялварды... Шул чактагы аның күзләре... Исемә төшкәч, хәзер дә имәнеп китәм!.. Хәлендә чакта әти байтак мәетләрне озатышып, куеп йөргән иде... Кәфенлек юк, адәм балаларын җир куенына чыптага төреп тапшыралар иде... Туган-тумачалар ашъяулык, бит яулыгы китерделәр, әтине шуларга киендереп озаттык. Ятим-ялпы, карт-коры чыпта киемнәрдән мәңгелеккә күчте... Әтидән соң әни дә озак тормады... Ул танда Түбән очта бер әби вафат булган иде, кабер казыдылар, ике яктан да ләхет алдылар. Бер ягына әнине — чибәр, сылу Саниянe куйдылар, икенче якка әби кереп ятты... Егерме тугызынчы елда туган, Сания әнинең иярә килгән кызы Җәүһәрия апаны да аямады әлеге чир... «Әнием үлде, мин сезгә чит-ят бала, сез мине карамассыз инде»,— дип бәргәләнәбәргәләнә җылады матуркаем. Бер дә генә кара җиргә кереп ятасы килмәде. Әҗәлдән курыкты... Кичтән йокларга ята башласак: «Мин Мөнирә белән генә йоклыйм алам»,— ди... Миңа ул чакта унбер яшь... Кочаклашып ятабыз... Көне буе бәбәй күтәреп, аннан-моннан юнәткән әче катык, әйрән белән сабый җанын саклап йөреп арганмын, ятам да эрим. Хәлем юк... Бервакыт минем кулларымны Җәүһәрия ападан аералар... Мин инде әллә кайчан суынган апамны кочып ятам икән... Мин курыкмасын өчен күрше апа төрле йомшак сүзләр әйтә, иркәли, үзләренә алып чыгып, кан каткан чәчләремне учма-учма аралап юындырды...

Унбиш көндә өебездән биш мәет чыкты. Мөхәммәтжан, Әнәс, әти, әни, Җәүһәрия апа...

Мәллә-Тамакта илледән артык йорт ябылды...

Безнең йортта баш булып егерме сигезенче елгы Назыйма апа калды. Назыйма апа язмышы — үзе бер олы тарих. Апамны ФЗӨгә алганнар иде. Зеленодол фанер фабрикасында чиләнгәннән соң ул өч тапкыр аннан качып кайтты. Өченче качуында әти болай диде: «Теге вакытта качканнарың өчен дә әҗәтләремне түләп бетермәгән идем, кызым, тагын кайттыңмыни?» Ачуланып әйтмәде әти, салымнар белән жаны корыган кеше ни дисен тагын? Өченче кайтуы кырык дүртнең каһәрле май аенда иде. Кайтып күпме торгандыр, апаны тотып алып китеп, милициягә яптылар. Назыйма апа төрмәдә, ә безнең өй эчендәге хәлләрне беләсез! «Өйләрендә хәл мөшкел»,— дип авыл советыннан кәгазь алып баргач, апаны чыгарганнар. «Кайтыр микән ул бала, әллә бөтенләйгә ябып куярлармы?»— дип әти ике көн юлдан күзен алмады. Тик Назыйма апа әти җан биргәч кенә кайтып керде. Әтине җирләмәгән идек әле...

Назыйма апа хакында, бер оя ятим калган балалар хакында тагын бер сөйләрмен әле... Бүген анысына да көчем җитми...»

И дөнья, дөнья! Мөнирә — зирәк җан — моннан ярты гасыр элек булган кайгы-хәсрәтләрнең дәһшәтле бөеклеген аңлаган. Җан бик күнелсез, бик авыр хатирәләрне дә сыйдыра, әгәр без җан бары тик сөенечләрне генә үзенә бикләп асрый ала дип уйласак, адәм баласының офыкларын тарайтыр идек. Саклаган икән — ул шул хатирәләргә кайта-кайта уйланган диган сүз. Хатирәләргә һәр яшьнең үз мөнәсәбәте. Хатирәләрнең дә һәр яшькә үз мөнәсәбәте була һәм алар безнең ихтыярдан башка безнең язмышка тәэсир итеп, үзгәрешләр, төзәтмәләр кертеп торалар. Кеше үз гомерендәге бәхетсезлекләрдән арынырга теләсә дә, алар күңел хәзинәсен бер чакта да ташлап китә алмыйлар. Хатирәләр киемгә кунган тузан түгел, аларны кагып, җилләтеп кенә төшерә алмыйсың. Хатирәләр аякка ябышкан балчык түгел — аларны үкчәңне селкеп кенә читкә очырта алмыйсың. Үзеңне-үзең аңларга теләп хатирәләр сандыгың ачасың икән, күрәсең, төптә син казанган асылташлар белән аралашып, мүк сарган кара ташлар да ята.

Мин Анна Франкның көндәлеген хәтерлим. Ул яһүд кызы да безнең чордаш, егерме тугызынчы елда туган. Германиядә 1933 елда фашистлар хакимиятне яулап алгач, аларның гаиләсе Голландиягә кача. Немецлар кырыгынчы елда Голландияне дә басып алалар... Анна үз күзе белән күргәннәрне, әти-әнисенең, якыннарының язмышын фаҗигале көндәлек дәфтәренә теркәп калдырган. Бу язмалар дөнья күләмендә мәгълүм. «Анна Франк көндәлеге» үнжиде телгә тәрҗемә ителгән. Бу җәһәттән Илья Эренбург болай дип әйткән: «Гитлерчылар алты миллион яһүдне харап иттеләр. Астылар, аттылар, газ камераларында тончыктырдылар. Аларның ни кичергәннәрен, ни уйлауларын берәү дә анык кына белә алмый. Алты миллион җан өчен бер кыз җавап бирә — акыл иясе дә түгел, шагыйрь дә, гап-гади кыз сөйләп бирә... Аның сабыйларча саф тавышы һаман яшь: ул әҗәлдән көчлерәк булып чыкты»,— ди...

И, татарның зирәк акыллы әдипләре! Милли җанга тереклек сулышы өстәп торырга алынган зыялылар!.. Без Анна Франкның батырлыгы белән хаклы рәвештә горурланабыз, мәктәпләрдә балаларга Анна апа горурлык хисләре тәрбиялибез... Нигә без татар халкының кискен мизгелләрендә ни кичергәнен әдәбиятыбызда беркетеп үтмибез икән? Нигә без көндәлек дәфтәрләребезгә чынлыкны беркетеп калдырырга кирәклеген балаларга яшьтән үк өйрәтмибез? Көндәлекләр, хатирәләр милләтнең яшәеш күперенең мәңге какшамас баганалары түгелмени?.. Әгәр мәктәп, зурлар Мөнирәгә һәм безнең барлык чордашларга нинди гыйбрәтле язмышлар кичергән буынга: «Онытмагыз, барын да кадерләп саклагыз, ара-тирә куен дәфтәрләренә язып беркетегез, хәтергә генә

ышанмагыз»,— дип акыл өйрәтсәләр, мөгаен безнең тарихның андамонда чәчелгән асылташлары буыннан-буынга күчә-күчә тагын да яктырак ялтырар иде!

Без — хәтерсез милләт. Мин бу сүзне еш кабатлыйм. Мөнирәнең хәтер хәзинәсе Анна Франкныкыннан киммени? Без кешеләрнең төрлелек тирәнлегенә сирәк төшәбез. Безнең адымнар вак, колачыбыз тар... Мөнирә белән без янәшә эшләдек, «Чаян» журналында. Бу — сабыр холыклы, эшчән, гаҗәеп гадел, сүз үтәүчән, мәңге вәгъдәчел тыйнак хатынның күкрәгенә шулкадәр фаҗигалар сыйгандыр дип кем уйлаган?.. Фикердәшем икән ләбаса ул, чордашым, акыл иясе!.. Тик моңарчы аның мәңге яшәргә тиешле канлы хатирәләренә без игътибар итмәгәнбез шул. Әле күп тармаклы милли хәтеребездә ничаклы кыйммәтле фикерләр дөньяга чыгарга чират көтеп ятадыр?! Алдагы буыннар безнең хаталарны да истә тотсыннар иде!

Мөнирә ханым белән аның башыннан кичкәннәре, күргәннәре хакында матәм хатирәләрен искә төшереп утыргач, болай дип көрсенеп куйды: «Кайчан да булса бу хәлләрне язып чыгарлармы? диеп көтеп йөри идем... Язмыйлар гына бит, язмыйлар...»

Эх, Мөнирә ханым! Мин фәкыйрегез ул коточкыч хәлләргә багышлап әллә кайчан хикәяләр язып карады да... язганнар үз вакытында дөнья күрә алмады... Бүген шуларның берсен — «Гитарачының һәлакәте» дип исемләнгәнен тулысынча теркәп китәм...

«Билгесез үлем чире үзенең кара канатларын ачлыктан тилмергән авыллар өстенә җәйде. Бу кара канатның усал күләгәсе акрын гына кыймылдап ямьле Зәй буйларына да төште. Кешеләрнең коточарлык хәсрәтләреннән кояш ыржаеп көлде. Май ае җиле чәчәкләр һәм гыйшык исе алып килү урынына сөрсегән үлем исе ташыды. Бу ис артыннан ук куркыныч хәбәрләр ташбака төсле үрмәләделәр. Хәбәрләргә ябышып ук үлем — билгесез һәм ямьсез үлем үзе дә килде, көттермәде.

Зәй буйлары кардан ачылдылар. Җирнең канга буялган күкрәге өстендә җылы җилләр белән бөтерелеп бөре исенә тулыккан ак пар уйнаклады. Басу-кырлар өстенә күз текәп торган ач кешеләрнең күзләре көздән кырда калган башакларга төште. Алар, ярым тилереп, кырлар өстендәге дымлы башакларга ташландылар. Бу күксеп юанайган бөртекләрдән алар котылу чарасын, тереклек чаткысын эзлиләр иде. Әмма кырлар өстендәге җылы пар да, саллы башаклар да берни кыла алмадылар, үлемнең кара күләгәсе һаман якынайды. Аның тимер куллары болай да тереклек әсәре чак эләгеп торган адәмнәрнең кипшергән бугазыннан чытырдатып тотып ала иде. Бугазлардан бары тик бер аваз гына ысылдап чыга алды: «ИК-МӘК».. Халык куркынып ары-бире ташланды. Ләкин аяусыз үлем бөтен җиргә үтеп керде.

Дәһшәтле хәбәрләр Н. авылына май башында ук килеп җитте. Имеш, тәмуггтан яэҗүҗ-мәэҗүҗ чыккан икән дә Мәһди күтәрелгән икән! Үләт, имеш, төннәрен авылдан-авылга йә кош булып очып, йә колын булып чабып килә икән. Иң ышанмаучыларның да күңеленә шик салып хәбәрләрнең чыннары да ишетелә иде. Бүген фәлән авылда сиксән кеше үлгән, үлгәннәрнең бармак очларыннан, маңгайларыннан, үкчәләреннән тишелеп сасы кан ага, ди. Төгән авылда унбиш кешене бер каберга куйганнар, ди. Күмәргә кабер җитешми, ди, табут-фәлән дә ясап тормаганнар, ди... Боларда ялган никадәр булса, хакыйкать тә шулкадәр иде.

Н. авылы тегеләй дә юк-барга бик тиз ышанучан булганга, хәбәрләр якын-тирә авыллардан үрмәли башлагач, халык бөтенләй тилереп китте. Кыр эшләре бөтенләй онытылды, халык кулыннан эш төште. «Барыбер юкка кала бит!»— дип, һәркем сыерын, сарыгын егып суя иде. Ә киемсалымнарны юк кына бәяләргә базарга озата башладылар. Кешеләр төркем-төркем булып җыелалар да язгы кояшның ничек итеп авыр, күз яше кебек саллы булып офыкка тәгәрәвен, офыкның канлы ефәк белән

өретелгәндәй кызарып-янып торуын күзәтәләр дә бер-берсеннән шомланып-куркып өйләренә таралалар.

Бер-берсеннән шомлана-шомлана өйләренә таралалар, кем дә булса берәү үлем чирен инде эләктергән кебек. Һәм хәбәрләр курку киртәләрен җимереп көннән-көн якынаялар.

Авырып шәһәрдән кайткан музыка мәктәбе студенты Данил кулларын артка куеп йөрде дә йөрде. Аның сары көтек сакаллы, карсак гәүдәле, очлы борынлы атасы, ерактан күрми торган күзләрен бүрәнә диварга терәп, яньчелгән алюминий мискедән чупырдатып итле шулпа ашый. Данилның аның ирен чупырдатуына ачуы килсә дә дәшми. Ул өстәл-урындыкларга абынмаска тырышып әле бер почмакка, әле икенчесенә эре-эре атлап йөренә. Тегеләй дә биш адым, болай да биш адым. Ә уйлар чиксез, аларның очы-кырые юк...

Атасы, ашап туйгач, бик озаклап почмакка карап дога укыды, кулын киң-киң йөртеп чукынды да майлы иреннәрен ямьшәйгән картузы белән сөртеп, вак-вак атлап, кыбырсып өйдән чыгып китте. Данил тәрәзә каршысына килде. Биек, шәрә тупылларның зур, иләмсез ботаклары арасыннан мыскыллап, көлеп торган айга бик озаклап текәлеп карап торды ул. Аннан стенада, зур кадакка эленгән гитарасын алып, акрын гына кылларын чиртә-чиртә сәкегә килеп утырды. Гавай гитарасы кеше төсле үксеп җылап җибәрде. Көй генә барып чыкмады, йөрәкне нидер тырный иде. Данил уфылдап урамга чыкты. Аларның өй турындагы бүрәнәгә байтак кеше җыелган. Барысы да шыпырт кына сөйләшәләр. Тавышын җил ашаган бер хатын:

— Бөгелмә ягы авылларында үләт төннәрен яшь, чем кара колын булып авыллардан-авылга күчә, ди. Шуннан бу авыл кешеләре мондый хәйләгә керешкәннәр! Үләтне алдап та була икән! Кырык хатын җыелып бөтен өйләрдәге утларны сүндереп бетергәннәр. Чөнки үләт иң элек утка кереп оялый икән. Кырык хатын бер сабанга җигелеп, келәү итеп, догалар укып авылның бөтен ягыннан уратып, сабан белән сөреп чыкканнар. Үләт ул сөргән ызан аша үтә алмый икән! Аннан авылга кайтып, ике агачны бер-берсенә ышкып Таза ут чыгарып бөтен авыллары белән Таза ут ташыганнар. Үләт алар ягындагы бөтен авылларны кырып салган, ә боларның ник берсенә җил-яңгыр тисен икән!— дип сөйли. Кешеләр тып-тын гына тыңлыйлар да бер-берсенә карашалар. Бераздан:

— Безгә дә шулай эшләргә кирәк, хатыннар,— дип пышылдый Данилның әтисе. Хатыннарның күләгәләре әкерен генә кыймылдап өйләренә тарала. Йөрергә булгач йөрергә! Тик үләт кенә килә күрмәсен! Борчылып басып торган егеткә бәреләә язып үтсәләр дә хатыннар аны күрмиләр. Авыл утлары берьюлы сүнеп беттеләр диярлек. Айның тонык яктысы, өстен булып калганын сизгәндәй, тәрәзәгә чиртми-нитми генә үтә дә тәрәзә төбендәге сулган гөлләрнең шиңгән яфракларын яктырта. Данил әкрен атлап, уңда-сулда сурәйгән йортларга карый-карый елга ягына китеп бара. Ярга житәрәк туктап, үзенең кыска күләгәсенә карап тора. Авылда беркем дә йокламый, шулай да тып-тын. Бераздан сабан тәгәрмәчләре шыгырдаганы ишетелә. Билләренә зинарлар таккан, баулар бәйләгән хатыннар, борын эченнән белгәннәрен укый-укый, сабанны бер кул очына күтәреп, бер чиная жирдән сөйрәп, авыл очына атлыйлар. Иң алдан карачкы булып, түшенә элгән көмеш кәгазьле тәресен ялтыратып Паулый карчык бара. «Кайда эш — Паулый әби аннан чыга! Кайда аш — Паулый анда баш!» дип мактый аны авыл халкы. Ул иң ялкау, иң диндар, биләмгә-кунакка йөрүне генә ярата торган карчык. Бүген алда! Иң арттан ямьшәйгән картузын колакларына ук батырып кигән Данилның әтисе уза. Ай яктысында бу арык кешеләр өрәкләрдәй кыймылдыйлар. Бераздан төнге караңгыда эреп югалалар. Данил бик озаклап алар артыннан текәлеп карап кала. Тора да күзен күккә күтәрә: үтәли күренеп торган сибелмә, юка ак болыт нурга манчылып эрер-эремәс йөзә. Тып-тын. «Эх, шушы бәхетле ак болыт булсаң

икән лә!— дип уйлады Данил.— Ерак-еракларга кит тә бар иден! Ә болай үләт килгәнен көтеп, борын төбенә килеп җиткәнче бер эш-ихтыярсыз утыр инде!» Уйлады да кипшергән сукмак буйлап елгага якынрак, буа алдына төшеп китте. Сәрви куаклары куерып үскән таучыкка килеп утырды да уйга талды.

Ай нурына мул коенган дөньяның шундый сихри матурлыкка ия булуын егет беренче тапкыр күрде шикелле. Су буендагы тал агачының чуклары суга иелгәннәр, алтын Ай су өстенә ука белән чигү чиккән. Ерак офыктагы карасу пәрдәләр әкрен генә җилфердиләр төсле, шундый ук пәрдә белән төренгән кырлар сүзсез. Җидегән йолдыз. Елга аръягындагы әрәмәләр кара булып сузылганнар. Аның күзләре ихтыярсыз бер матурлыктан икенчесенә күчә. Чыннан да, дөньяда күпме матурлык, гүзәллек бар икән!

Кинәт аның чигәләре сыкрап алды, сабан тәрәннәре җирне ертып чыелдадылар. Тилмергән хатыннар авазы белән төнге тын дөнья тулды.

— Алиллуя аллилуй, господи помилуй!

Мышкылдаган төркем аңа якынлашты. Алдан Паулый карчык бара, ул бүтән тавышларны басып кычкырып дога укый. Аның артыннан эреле-ваклы хатыннар тезелгән. Сабан тоткасына ябышкан карт, чирле әткәсе Данилга искиткеч кызганыч һәм мескен булып тоелды. Төркем сузылып, ава-түнә атлап, сабанның үткер тәрәннәрен адәмчә җылатып, Данил янынннан узып китте.

Кая китте сихерле табигать матурлыгы? Егетне ниндидер ябышкак, усал шом чорнап алды. Ботакларын иеп сәҗдәгә чүккән тал ябалдашлары аның күзләренә үләт, усал һәм котылгысыз үләт булып күренделәр. Ул урыныннан сикереп торды. Сабан һәм дога тавышлары инде ерагайды. Бу кызганыч бәндәләрнең тавышы чирле гитарачыны тетрәтте. Ул елга ярына ук килде, суда сизелер-сизелмәс кенә тирбәлгән күләгәсенә озаклап карап торды. Аннары буа алдындагы дәү ак ташка барып утырды. Өзек-өзек тавышлар колакка шом салып, баш миен ертып-ертып керәләр иде.

Таң җиле исеп куйды. Коры үлән чожтырдады. Тал куагының очы суга тиеп-тиеп китте, су чопырдады. Данил кулындагы ялтыравык металл гитара кыллары өстеннән йөгереп үтте. Гитара табигатьнең тулыккан, җыларга әзерләнгән сагышлы моңына татлы кайгы өстәде. Аяз күк кашын җыерды, арыктагы су кызурак ага башлады, талларның үткер очлы яфракларыннан күз яше тамды. Әй, кызганыч бәндәләр. Үләттән шулай гына котылып калып булса икән! Данил шашынып уйнады. Уеннан тукталса, сабанның күгәрек чыелдавын ишетермен, ул ямьсез тавыш тагын мине ертып-ертып үтеп керер, дип курка иде. Кыллар шашып җыладылар да җыладылар. Тик йөрәк басымына чыдый алмаган кыллар шартлап өзелде. Уен тукталды. Данилның шашкан карашы алтынсу нурлар уйнаган гамьсез буага карап тукталды. Еракта алҗыган хатыннарның ыңгырашулары ишетелде. Егетнең күз алдыннан аларның шәүләләре шуышып узды. Данил ватык гитарасын җиргә китереп сылады. Аның кылларыннан чәчрәп монсу, үксез тавыш тынганчы су буе тынлыгында икенче бер тавыш яңгырады...

Су өстендә таралган алкалар, нидер пышылдаган төсле яр балчыгына һаман, һаман бәрелеп тордылар. Таң җиле көчәйде. Яр өстендә аунап яткан ватык, ятим гитараның исән кыллары арасына кысылып гарип җил уйнады. Нәзек кенә чыңлаган кыллар таңның яңа туган ал нурларына яшь гитарачы Данилның истәлеген сөйлиләр иде».

1947 елның декабрендә Зәйдә комсомолда эшләгәндә язганмын мин аны. Дөрес, әле дөньяны аңлавым чикләнгән булган, әдәби яктан да чатлы-ботлы ботаклары бардыр, мәгәр язганмын!!! Язып куйганмын!.. Мин шаһит идем бу ят вакыйгаларга!.. Әнә, түшенә таккан тәресен ялтыратып Паулый карчык бара. Аның артыннан кырык хатын бер

төрәнле сабанны сөйри. Алда өчесе — баш балалар, аннан соңгы өчесе урта балалар, аларга тагылган өчлек-төпчекләр. Сабан төрәне мәгълүм бер киңлектә, бер тирәнлектә җирне ертып барса гына үләт-мөртәтне тыя алачак! Хәйләгә урын юк, әгәр бер бәләкәй генә өзек калдырсаң да Үләт үзенә юл сабачак!.. Моны сабан тоткасына ябышкан ир күзәтә!.. Хәтеремдә, йортларда утлар сүнде, таң алдыннан кара тиргә, тузанга баткан хатыннар каравыл өе янына җыелып, ике агачны бер-беренә ышкып Таза ут чыгардылар. Шуннан китте, калай савытларга, балчык чүлмәкләргә тутырып өй борынча Таза ут өләшеп йөрделәр... Черек күл беркетмәләрендә: «Аяз миңа советка каршы язылган хикәяләрен укыды, фәлән-фәлән әсәрләрен»,— дип раслап киткән җавап сүзләре бар. Минем шушы өйрәнчек әсәрләремдә дә ни әйтергә теләгәнемне чамалаган егетләр! Чынбарлыкны дөрес чагылдырырга омтылган һәр әсәр ул мөшкел заманда «советка каршы язылган» дигән югары бәя алган.

## 9

*Тыныч яшисең килсә — иманга кил,*
*Хаклык эзләсәң — укы.*

НИЦШЕ. Сеңлесенә язган хаттан.

Әгәр дә «ачлык — мине язучы ясады» дисәм, гаҗәпләнмәгез. Бу сүзләрдә авыр дөреслек бар. Югары Баграж мәктәбен, укытучыларын яман сүз белән телгә аласым килми. Гүзәл адәмнәр бар иде арада! Сугыш башланды, ир-атларны берәм-берәм сугыш чүпләп бетерде. Тылда калганнарның язмышына да сугыш хуҗа булып алды һәм кешеләрне арлы-бирле, арлы-бирле йөртә башлады. Җир йөзендә ничаклы кеше булса — сугышның да шулкадәр кулы бар, һәркемгә җитә ул кул, берәү дә өлешсез кала алмый. Югары Баграж мәктәбе саекты, тынды. Класслар кимеде. Укытыр кеше эзләп тинтерәгәч, мәгариф оешмалары тугызынчы, унынчы класслардан алдынгырак, зиһенлерәк укучыларны сайлап алып, түбәнрәкләрне укытырга җибәрделәр. Тугызынчы класс укучысы безгә — сигезенчеләргә анатомия укыта, унынчы класс егете Миронов немец теленнән керә. (Сугышка китеп үлде егетебез, һәйбәт, күркәм, уңган бала иде!) Кырык дүрттә Югары Баграж урта мәктәбен яптылар, унынчыга мин Сарман мәктәбенә бардым. Кырык бишнең язында беренче тапкыр кулланышка «Өлгергәнлек аттестат»лары керде. Законда әйтелгәнчә, яңа төр аттестатка имтиханнарны бары тик югары белемле укытучылар гына алырга хокуклы иде. Өч районнан: Сарман, Зәй, Ворошилов районнарыннан көч-хәл белән җыеп, эзләп имтиханнар алырлык югары белемле педагогларны Теләнче Тамак мәктәбенә тупладылар. Сарман мәктәбеннән бер укытучы да комиссиягә кермәде, югары белемле укытучылар булмаган дигән сүз. Урыс теленнән безне Владимир Вуль дигән майор укыта иде. Бернинди педагогик белеме һәм әзерлеге булмаган Вуль кыш буена юньле бер дәрес дә уздырмады дисәм, һич ялгышмам. Кызлар сагыз чәйни, челтәр бәйли, гайбәт сата, ә без — өч бөртек егет. Вульны урап алабыз да... ул безгә солдат анекдотларын сиптерә, еврейча сүгенергә өйрәтә... Арадан берәү: «Имтиханнар бирәсе бар ич безнең!» — дип уфтанып куйса, Владимир Владимирович сикереп калкына да: «Әһә! Шәп! Әйдәгез, Маяковскийга игътибар итәбез!» — дип майор тавышы белән безгә «Во весь голос»ны кычкырып укый башлый... Теләнче Тамакта ике айга якын ятып ни нужарганыбызны язып тормыйм, шәкерт ачлыгы мәгълүм нәрсә, гомер булса, ул көннәргә бер әйләнеп кайтырмын әле!... Кырык дүрттә Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Кысыр болытлардан шифалы яңгыр көтеп йөргән ач күңлемә бәйрәм килде: барам! Мул уңыш алырлык

бәрәкәтле кыр шунда! Алдагы бәхетле көннәргә — дан-шөһрәт китерәчәк дәвергә юл бары тик университет аша үтә! Барам! Укыйм! Дөньяны өр-яңадан ачам!

Теләнче Тамакта имтихан биреп йөргән вакытлар, август башында пароход коерыгына төялгән мичкәләр арасына кысылып, Казанга барулар, шәһәр урамнарындагы беренче кыюсыз адымнар төш кебек кенә истә калды. Сугыш беткән елның көзе! Юллар мажаралы булды, көннәр ыгы-зыгылы, төннәр шик-шөбһәле. Студент елларым хакында аерым бер әсәр язармын әле, ни дисәң дә мин университетка өч тапкыр укырга кердем, өзә-төтә биш ел укып, нибарысы өч курс бетердем. Алда гомер булып, юмарт тәңрем зиһен акылы насыйп итсә, язармын, гомеремнең ул кишәрлегендә дә шактый гыйбрәтле хәлләр булып үтте...

Университет мөгаллимнәренә, сабакташларыма һичбер рәнжешем, үпкәм юк, ходай сакласын! Алай да рух, фикер ягыннан мин үз җаныма якыннарны татар театр училищесы студентлары арасыннан таптым дисәм, бу чын дөреслек булыр. Бигрәк тә шагыйрь Мәүлә Солтан белән якынайдык. Бу кадерле исем, бу олы зат алда әле үзенә лаек урынны алыр, иншалла.

Бер нәрсә ап-ачык: университет мин ашкынып-газапланып көткәннәрне бирмәде, үземне яшь чагымнан борчыган сорауларга җавап табу түгел, сорауларым тирәнәйделәр, ишәйделәр, авырая бардылар. Без укыганнар, без ишеткәннәр белән чын тормыш арасы артык ерак, фән дип безгә сеңдерергә тырышкан фикерләр тормышыбызның катлаулы мәйданнарына һич яраша алмыйлар иде. Гәзит-журналлар бер нәрсә яза, кино-театрлар шашып-шашынып Ленин-Сталинга мәдхия укый... Коммунистларны күккә чөя. Университет мөнбәрләренә менеп баскан бал авызлы мөгаллимнәр ач-ялангач көн күрүче, салымнардан үләр хәлгә җиткән хәерче Рәсәй тормышын безгә иң гадел, иң гүзәл тормыш үрнәге дип ышандырырга тырышалар һәм, иң гаҗәбе: максатларына ирешәләр дә иде! Студентларның зур күпчелеге ленинизмның какшау, ялган идеяләренә табынып, үз ихтыярлары белән күзләрен күрмәс итәләр иде...

Язга чыккач, мин университетны ташлап киттем. Язгы имтиханнарны бирмәдем. Җәй авылда үтте. Урман кистем, печән чаптым... Авылның иң авыр яшәгән еллары... Колхозлар крестьянны талап кына чирле җаннарын саклыйлар. Тукайның:

> — Иң сөекле эшче әүладым бу ел ач калды,— дип,
> Изге, шәфкатьле анабыз — мәрхәмәтле җир җылый,

— дигән бөек сүзләре күңелдән китми. «Быел» гынамы?! Үткәндә дә шулай булган, крестьянны алда да шул көтә! Бу фикер минем иманыма әверелеп, ныгый бара. Авылда әлерәк кенә сугыш кырларыннан кайтып кергән Гурий Тавлин, Алексей Красновлар белән аралашам. Күпне күргән, күпне кичергән егетләр. Күңелләр күңелгә бөтенләй ярашып бетмәсә дә, егетләрдән аерым-аерым сүзләр ычкына. Алар күргән мине сагайта, ләкин мин үземне борчыган уйлар тозагыннан барыбер ычкына алмыйм. Кая барыйм? Нишлим? Туймас җанны кайсы казаннарга салып кайнатыйм?.. Яшьлек эзләнүләрдән туймый, яшьлектә аң тамырлары бик тирәнгә төшеп тә эзләнәләр, баш очыннан үтеп киткән болыт ертыгы сиңа әллә ниләр йөкләп үтеп китә.

«Аптыраган-йөдәгән, артын мичкә терәгән»,— ди татар агайне. Мин тагын Казанга барып егылдым. Университеттан куганнар, кабат укырга керергә үзем дә атлыгып тормадым, кай тарафта башны салырлык мөмкинлек бар, шунда уралып-чуралып көннәрне үткәрдем. Мәүлә Солтан, Рифгать Әминнәр белән бер кыерчык икмәкне бүлешеп яшәдем. Мәүлә белән аерылмас дусларга әйләндек!.. Ул мине ярты сүздән аңлый, мин — аны. Без тормышны аңлагандай булабыз, ачык күз белән тәнкыйтьли дә алабыз. Ләкин барыр юлны беребез дә белми.

Кырык алтынчы елның көзе!.. Миңа унсигез яшь. Адәм баласының маңгаеннан күзгә күренми торган сихри нурлар чәчелеп аның барыр юлын яктырта торган була. Минем исә маңгаемнан кара коелган гына чак булгандыр, көннәрдән бер көнне, һични уйламыйча, бер максатсыз, башын-азагын исәпләмичә Казан — Әстерхан пароходына утырып, Идел буйлап төшеп киттем. Ул чагында минем җәсәдемне уй-фикер түгел, шашкан буталчык хисләр дулкыны йөрткәндер. Барыр юлым, тоткан максатым юклыктан чыгып киткәнмендер дип уйлыйм хәзер.

Кырык бердә дөнья купкан иде, әле шул каһәрле чорның дулкыннары ярларына кайтмаган сәер бер мәл иде. Сугыш тараткан адәм балалары әле җыелып бетмәгән, минем сыңарлар — кая барып бәрелергә белмәгән байгышлар — Рәсәйнең бөтен тарафында кайный иде. Ачлык, хәерчелек, фәкыйрьлек... Бер уйсыз-нисез Әстерханга барып төштем. Ары сугылдым, бире килдем, иске көймә асларында ертык җилкәннәргә төренеп йокладым. Милициянең күзе үткен: «университет студентын» кич саен тотып алалар, аңлатма яздыралар. Кулга ручка эләккәч, яктылыктан файдаланып көндәлек язып та алам... Ул дәфтәрем югалды, кайда, кем кулында саклана икән минем бәхетсез сәфәремнең хатирәләре?! Минем алгысыган күңел монда да урынына утырмады, таяныр таллар юк, күз ял иттерерлек нәни генә нокта да очрамады миңа! Мин шәһәрдән чыгып киттем, Идел тармакларын көймәләрдә кичә-кичә тагын да куерак билгесезлеккә — көньяккарак төшә барам. Анда, диңгезгә таба Киров исемендәге балык совхозы бар, Комузәк дигән урын бар, «туганнарымны эзләп барам», дип кызыксынучыларны алдыйм, ышаналар, дөньяның асты-өскә килгән чор! Ә үземне үзем алдый алмыйм, үз рәвешемне, гамәлләремне аңлата да алмыйм. Сукбайлар әз сүзле, һәркемне нужа бабай йөртә, язмышлар охшаш булса да рәвешләре, тирәнлеге бер түгел. Укырга, белем алырга мөмкинлек булган хәлдә диңгез җиле белән генә тукланып яшәп ятам дисәм, кем мине җүләргә чыгармас?! Хәзер ап-ачык итеп әйтә алам: минем максатсыз тоелган юнәлешсез сәфәрем сак күңелемнең, саф йөрәгемнең үзенә күрә бер протесты булган ләбаса! Шушы сәфәргә тәвәккәлләп минем күңелем ил тормышын киңрәк күрергә, ныграк аңларга омтылмаганмыни?! Халык ничек яши, ят шәһәрләр ни хәлдә, безнең татар ягында кара канатын җәйгән хаксызлык, ялган, талау, мыскыллау офык артындагы офыклар ягасында да бармы?.. Яшь чагында офык артларында оҗмахның җиде каты сыйгандыр кебек тоела иң! Яшьлектә күңел омтылышларының күпчелеге яшертен була, адәм баласы эчке ымнар кушкан гамәлләрен үти-үти дә, берзаман, шаккатып баш чайкап, үткәннәренә карап тора: ничек булды әле бу? Ни сәбәп? Нигә мин моны эшләдем?, — дип, соңга калып булса да үз-үзен аңларга тырыша.

Илдәге тәртипләргә, ялган кануннарга буйсынып, ялганның итәгенә тагылып яши алмаган җанымның ярыкка кысылган урман сарыгы Шүрәледәй йолкынуы булган минем мәгънәсез күренгән сәфәрләрем!..

Комузәккә барып житә алмадым, көзгә кердек, салкын җилләр, суык яңгырлар мине кире Әстерханга алып кайтты. Мин пароходта кысылып, билетсыз гына Кама тамагына килеп җиттем. Аннан Чистайга. Чистайдан Чаллыга кайтучы соңгы пароходның палубаларында калын ак кар ята иде. Ә минем өс-баш юка, кесәләрдә сукыр бер тиен акча юк, ботинканы да сатып ашаган идем, йон оегымны да... Чалбар балакларын аска ук төшереп, юан җеп белән аннан-моннан бәрештердем дә кар өстеннән йөгерәм генә!.. Чаллыдан Зәйгә үк чыгып киттем. Җәяүлим!.. Борды авылына кайтып җиткәч, ары бара алмаслыгым аңлашылды. Берәүләргә, мәрхәмәтле керәшен туганнарыма фатир төшеп, Багражга хәбәр салдым: мине килеп алсыннар!.. Ике-өч көн үткәч, тәрәзәдә тавыш, энем Алмаз кычкыра: «Әй, сездә бер малай бармы?»...

Эзләп, эзләп та сөенерлек җирлек тапмаган адәм ахыр чиктә туган йортына кайтып егыла...

## 10

*Адәм уйларының чиге юк. Ул курка-курка булса да, йөрәксенеп үз адашуларын да тикшерә.*

Виктор ГЮГО

Шулай итеп, һич уйламаганда-көтмәгәндә мин комсомолның район оешмасында эшли башладым. Мондый эш болайрак булды...

Әстерхан «сәфәреннән» кайтып әти-әни канаты астына сыендым. Җылы, әмма оят!.. Кышка кердек. Без мәктәп янындагы кысан, тар, тәбәнәк, почмакларыннан эче дым китмәгән кыйшык өйдә яшәп ятабыз. Әти-әнигә рәхмәт, чәчрәп чыкмадылар, университетны ташлап китеп, әллә кай җәһәннәмнәрдә эт куып йөргән өчен әр, зар сүзләрен яудырмадылар, үз алдымда ың-шың ишеттермәделәр. Мин аларга булган бар дөреслекне сөйләп тә бирмәдем. Дөреслекне һәр тарафтан аңламаган хәлдә ата-анаңа ни сөйлисең? Хәзер, өч ул үстергән ата буларак үткәннәремне хәтер җебенә тезгәндә, «сәфәрем» хакында еш уйланам. Әгәр улларымның берәрсе мин кылганнарны кылып йөрсә? Мин — ярсу җан — нишләр идем икән?! Холыксызрак мин, җир шарын күчәреннән куптарырлык итеп дау күтәрер идем. Зир-зәбәр ясар идем, билләһи!... Димәк, буыннар алышынганда балаларның бунтына шаһит мизгелләрдә үтә нәзек күңелле булырга кирәк икән! Әти-әниләрем чиксез шәфкатьле, киң күңелле, гафучан җан булганнар икән! Алар минем бик яшьли, өченче-дүртенче класслардан шигырь-әдәбият белән саташып яшәвемне чамалап, шашканга чыгарып, ни теләсәм шуны кылып йөрүләремне дә кичергәннәр булса кирәк. Кырык алтының көз-кышында, кырык җиденең яз-җәй айларында мин бер өзлексез шигырь язып тилергәнмен икән. Шигырьне аны җан җылысына тилелек кереп оялаган яшьләр генә яза. Шөкер, ул дәфтәрләрем исән. Аларда минем сәфәремнең эчтәлеге, төгәл сәбәбе ачылмаса да, Әстерханга баруым, анда мине көтеп торган нужалар, Каспий тирәсендә ашкынып-исәрләнеп йөрүем шактый тулы чагылыш тапкан. Дөнья кануннары белән килешмәвеңне, Сталин режимының тоташ гаделсезлеген аңлавымны, тик Мокамай кебек яктыга чыгу юлларын тапмыйча ярым саташып, ярым акылга килеп эзләнүләремне газиз ата-анаңа ничек анлатасың?!

Әни — Кәшердә кызлар мәдрәсәсендә укыганда иң зиһенле, иң тырыш укучы булып танылган зат, минем шигырь язуымны хуплый иде шикелле. Әтием, куркак һәм үтә сак кеше: «Улым, ташла син бу кәгазь кыштырдатуыңны! Язучылык бик куркыныч кәсеп, кемнәрнең генә башына җитмәгән ул!» — дип еш-еш кабатлады...

Өй тирәсендә кыштыр-мыштыр эш тоткан булам, абзар-кураны чистартам, кар көрим. Елгыр бураннар басу турыннан карны авылга ташып сырындылар өйсә, миңа бәйрәм: эш күрсәтергә була! Бәхетле минутларым күп — бертуктаусыз укыйм. Тәмен белеп, аңлап, җан түрләремә кабул итеп укыйм. Абыем Азат Алабугада институтта укый, китапларны ул алып кайта. Ташый, ә миңа һаман җитми. Ниһаять, минем кулга Ф. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» романы килеп керде. Бу китапны мин йотлыгып, шашып, онытылып-уянып укыдым. Ничә тапкыр укыганмындыр, санамадым, әле китапны ыргытып бәрәм, әле барып авам да авторына сәҗдә кылып, күз яшьләрем белән битемне юа-юа тагын укыйм. Бәхетсез эчкече Мармеладовның «Понимаете ли, понимаете ли вы, милостивый государь, что значит, когда уже больше некуда идти? Нет! Этого вы еще не понимаете!..» — дип, җан авазы белән кычкырган сүзләре зиһенемне кисеп үтеп кереп, мине тетрәттеләр... Моңарчы мин татар халкы изелеп дөнья көтә, рәхәтлеккә, якты көнгә

берчакта да ирешә алмаган дип исәпләп, халыкны да яктылыкка, яхшылыкка өндәргә әзер идем. Югары Багражның кимсетелгән бәндәләре — Үткен Романнары, телсез Җәмәйләр, бүтәннәр чын кеше булудан ерак торалар дип уйлый идем. Романның азагында, минем хисләрем ташкын булып ага-ага җанымны төрле якка өстерәгәндә Достоевскийның «Муки и слезы — ведь это тоже жизнь!» дип раславы миңа алдагы көннәремә иман булды. Мин — хаклыкны зарыгып төрле якларга ташланган бичара егет — халкымның бәхетсезлеге өчен зар җылаган яшь әдәбиятчы «В несчастье яснеет истина» дигән тирән мәгънәле сүзләрне җанымның корыч сүрүе итеп кабул кылдым. Моңарчы яшәгәнемне мин яшәү түгел дип санап галәтләнсәм, Достоевскийча халык бәхетсезлегенә шаһит булып яшәү минем аңымны туктаусыз хакыйкатькә өндәгән чын тормыш булган лабаса!

Достоевский әсәрләре адәм улларын хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә, алга этәрә. Радион Раскольников, Соня Мармеладовалар, тегермән арыгыннан туктаусыз төшеп торган су шикелле, мине өзлексез уй хәрәкәтендә тоттылар. Тыкрык янына сыенган, кышын калын кар ястыгы астында калган, түшәм башлары күгәреп тынчыган өй-тартмада яшәү мөмкин түгел иде, җаныма азык эзләп мин туганнарым буйлап сәфәр чыгып киттем. Әле Чукмарлыга, яки Игәнә башына барып чыгам. Анда да шигырьләр язам. Әти-әни әлегә түзәләр, зарланмыйлар. Киләчәгемә карарга да, ул хакта әтиләр белән сөйләшергә дә куркам. Чөнки баш инкегән, дөнья дөм караңгы. Март башларында без, Урта Баграждан алтмыш-җитмеш кеше, Сарман районының Кәшердәге элеватор-глубинкасына солы симәнәсе алып кайтырга чыгып киттек. Мин бу сәяхәтемне «Язгы кәрваннар» повестенда түкми-чәчми бәян иткән идем. Зирәк укучылар хәтерлидер, мөгаен! Шунда, кара буранлы озын юлда, Урта Баграж керәшеннәреннән берәү, кем икәнен хәзер һич хәтерли алмыйм, мондый гыйбрәтле кыйсса сөйләп мине таң калдырды. Имеш, Америкада «Железный занавес» дигән фильм күрсәтәләр икән. Иртә таңда, сәяси тоткыннар ябылган лагерьда, дар баганасына асылган тимер кисәгенә дан-доң кага башлыйлар. Һич гаепсезгә илләреннән аерылган граждannарны әнә шулай эшкә уяталар... Уяталар да көне буе ач тотып, камчы астында эшләтәләр икән... Без дә ач идек, без дә чәнәшкәләр сөйрәп кара буранга күкрәкләребезне терәп бата-чума алга бара идек... Кинәт күз алларым яктырып китте, камчы чарлаган тоткыннарны, кара таңны сискәндереп-куркытып чыңлаган чаң тавышын ишеткәндәй булдым. Әйе, әйе, хак, тимер пәрдә артында без! дип кайнады яшь күңелем. О, каһәрле Баграж — Кәшер юлы! Аның авырлыгы, анда күргән җәфалар... Ләкин бу юлда җаным буш түгел, янәшәмдә Родион-Соняләр бара... Һәммәбез ач, яз борын төбендә, өй борынча йөреп чык, күз алдарлык та ризык таба алмассың. Без бәрәңге галиҗәнапләры көченә ышанып юлга чыкканбыз.

Татар җор сүзләрен бәрәңге янына куша: «Алып баруын барырмын, ди икән бәрәңге, — әмма алып кайтырыма ышанма!» И бәрәңге, бәрәңге! Син татарның үзе белән янәшә тәгәрәдең, иң ышанычлы юлдашы, коткаручысы булдың! Син бердәнбер тормыш чыганагы, юанычы идең! Безне бәрәңге алып барды, җәфалап-тинтерәтеп булса да алып кайтып житкерде. Инде авыл ерак калмаганда, Югары Баграж урманы уртасында үзебезгә каршы килгән озын кәрванны күреп туктап-тынып калдык. Алар да, кырык-илле кеше, эреле-ваклы мөгезләрен тырпайткан чәнәшкәләргә солы симәнәсе төягәннәр. Сарман районына кайтып баралар. Орлыкны безгә терәлеп торган Сарсаз Баграж авылыннан алганнар. Кара-каршы килгән ике кәрван бергә укмашып, тетрәнеп-катып калды. Заманында обкомның идеология бүлегендә эшләүче Мөдәррис Мусин дигән берәү әсәренең шушы өзеге өчен җыелышларда булсын, утырышларда, мине эт итеп сүкте. Большевиклар ике эшне оста башкара: урлый һәм дөнья бетереп сүгенә ала! Ни гаҗәп... «Язгы кәрваннар»ны укыган Ибраһим Нуруллин да Мусин фикерен куәтләде. Аһ, күрсәтәсе иде бер үк

жырны жырлаучы шушы ике коммунистка караңгы төшеп килгән урман юлын... кайсыдыр коммунист-түрәнең ахмаклыгы аркасында Сарманнарның Зәй районына, зәйлеләрнең Сарманга солы симәнәсенә барып йөрүләрен...

Әче жилләр белән шаярган кыш юашлана төште, зират тавыннан искән жилләр безгә жылы дым, әче бөре исләре китерә башлады. Язны РОНО инспекторлары да сизә, әти укыткан дүртьеллык мәктәпне дә чит итмиләр алар. Дәрестән соң, табигый рәвештә, әти аларны ашка-чәйгә өйгә алып керә. Гаилә әгъзаларының авызыннан өзеп, табынга төрле нигъмәтләр куела. Шунда бер бәләкәй акбаш та кукыраеп утыра. Бер килүләрендә, алар икәү булалар, мин кайдадыр өйдә юк, кунаклар ашый-эчә һәм бер жете күзлесе мич арасында аунап яткан комсомол билетымны күреп ала. Ничек, комсомол билеты мич арасына бәйләп куелган йомшак тояклы бозау аяк астында ауныймы?! (Каян төшкәндер ул анда, чәчрәп киткере!) Кемнеке? Ачып карыйлар: «Гилязов!.. Аяз? Улыгызмы?!» Әти шыр җибәрә, каушый, икенче акбашны ача алмый... Әнинең аш бүләргә тотынган арык кулы дер-дер килә. Инспекторлар: «Райкомга алып кайтып тапшырабыз без моны!» — дип, әтинең котын алалар. Чүти артыннан ярты чыккач, икешәр коштабак пилмән соскаңнан соң тегермән ташы дәүмәлге шулпалы бәлешне ике корсакка бөкләп тутырып куйгач кына инспекторлар әзрәк тынычланалар. Юк, бөтенләй онытып бетермиләр, Ленин-Сталиннан акыллы сүзләр сибә-сибә әтине пешекләп, тәрбияләп китәләр. Әти: «Улым Аяз университетта укыган жиреннән чирләп кайтты, хәзерендә ял итә»,— дип кенә котыла.

«Бәхет өеп» калдырган инспекторлардан соң әти ярылды! Кайтып, бусаганы атлап керүем булды... китте чәчәләп-чәчрәп әти!.. «Әрәмтамак, коры куык, ыштансыз күткә каеш бау!» — Әле болары әти теленнән ычкынган сүзләренең иң йомшаклары!

Мин эш турында уйларга, киләчәккә аек карап яшәргә вакыт житкәнен аңладым. Хәзер борылып карап баш ватам: нигә мин язган шигырь-хикәяләремне газит-журналларга юлламадым икән? Хәзер кайтып укып карыйм: язмаларым ул замандагы рухка — ялганга, ялагайлыкка корылмаганнар шул! Беренче шигырьләремне Пушкин, Лермонтовларга ияреп язганмын, дисәм, хәзер көлке тоеламы? Җәһәннәмне оҗмах дип, кара язмышыбызны гөл бакчасы дип ярыша-ярыша язган кайбер татар әдипләренең кемлеген аңлый төшкән идем инде мин. Алай гына да түгел, чит илләрдән килгән кызыл авызларны — Лион Фейхтвангер, Ромен Ролланнарны мин яшьтән үк күралмый идем...

Димәк, эш кирәк. Әти-әни җилкәсен кимереп күпме ятарга мөмкин? 1947 нче елның апреленә кердек. Шул айда Зәйдә район комсомол оешмасының отчет-сайлау конференциясе булып уза да, Урта Баграж кешесен, укытучы Георгий Федорович Панфиловны райкомның икенче секретаре итеп сайлыйлар. Каян табып алганнар, кем күрсәткән, Җәбрәй кушаматлы, ипле, тыйнак кеше бер дә партия ялчысы булырга охшамаган иде! Сөйләү куәте дә әлләкем түгел, сәяси белеме дә әйле-шәйлерәк: «туп-турыдан тут пошел» гына иде. Сайлаганнар, пичәт басылган, ә оештыру бүлегендә кеше юк! Кичке эңгер куерып төшкәндә безгә Панфилов килеп керде һәм мине райкомга эшкә чакырды. «Кил, бергәләп эшләрбез, өйрәнербез»,— диде.

Әти шатланды, әни сөенде, мин — аптырауда! Нинди комсомол ди әле монда! Әнә ич, билетын мич арасыннан табып алганнар. Кергәннән бирле комсомолның эшен дә, ашын да күргәнем юк минем. Ә Георгий Федорович үтереп кыстый, дулкынланудан әтинең ирен читләре калтырый...

Ничарадан-бичара, истә-оста югында мин Зәйгә барып урнаштым. Авыш ындыр арты шаулап-гөрләп, гайрәтләнеп агып яткан мул сулы Зәй елгасына диярлек төшә торган Ксения Федоровна Роксман янына квартирага кердем. Ленинград блокадасын башыннан үткәргән бу Мәлем

кызы картлыгын ялгыз башына үткәреп ята иде. Бер кәҗәсе бар, бер тавыгы, нә утарында, нә өй эчендә шулардан гайре күз төшәрдәй нәрсә юк иде. Райкомолның беренче секретаре Иван Николаевич Никитин ошаткандырмы мине, юкмы, белмим, сүзгә үтә саран иде, сөйләшкәндә дә безнең ише ыбыр-чыбырга телен әрәм итми торган һавалы адәм иде. Учет-хисап эшләрен алып баручы курнос борынлы, бетчә маңгайлы, якты күңелле Зәй кызы Елена Мачтакова белән тиз арада килешенеп киттек, ул мине үз итеп, якын итеп каршылады.

Ул елларда үзе кереп эшләмәгән кеше кырыгынчы еллар азагы комсомолының ни хәлдә булуын күз алдына да китерә алмый. Миңа оештыру эшләрен тапшырдылар. Кыскача гына теркәп китәм. Район зур, 113 комсомол оешмасы бар. Мин эшкә кергәндә шуларның яртысында җитәкче-секретарьлар юк иде. Булганнары да берниндн эш алып бармый, взнослар җыелмый, җыелышлар үткәрелми. Комсомолны белүче дә, аңа керүче дә юк. Анда-санда мәктәп укучыларын чөшкенләп куып кертәләр дә — вәссәләм.

Кыршылган бригадир букчасын иңемә салып, кирза итегем белән яңа сукмаклар салып, Зәй комсомолларын тирән йокыдан уятырга, җан өрергә, коммунизмның иң алгы сызыгына алып чыгарга дигән бурыч-заданиеләр төяп чыгып киттем. Ямьле яз! Күзеңне чынлыкка йомсаң, ул язда да матурлыклар табып була! Минә сызылып кына юллар төште, сирәк-мирәк ярым ватык арбалар таккан арык алашалар очраштыргалый... Авыл араларында җылы җил, ярсып-ярсып сайраган тургайлар белән юанып әз-мәз онытыласың. Авыл урамына барып керү белән җан өшеп, куырылып ала. Һәр йорттан, күгәннәре каерылган капкалардан, өлгеләре кырылып такта-токта белән томаланган сукыр-букыр тәрәзәләрдән, өй түбәләреннән ишелеп аккан черек саламнардан, җимерек күперләрдән, ауган кое чыгырларыннан бөлгенлек, фәкыйрьлек, ятимлек күзне кисә, зиһенне томалый. Былтыргы бәрәңге басуларында тездән балчык ерып, карт-коры, бала-чага кәлҗемә җыеп йөри. Йөзләр сүрән, чырайлар сытылган, күз чокырларына өметсезлек кереп тулган. Укра тишеп бетергән, янбаш сөякләре тырпайган, ябагаларын коя алмаган сыерлар, кояш бәрәкәтеннән көч алырга өметләнеп, нигез тирәсенә чыгып басканнар да, менә авам, менә түнәм дип як-якка чайкалып өй ишегеннән хуҗалары чыкканны көтәләр. Югары очтан Түбән очка, аргы яктан бирге якка арык биштәрләрен аскан хәерчеләр йөри. Ятимә әбиләр, ятимә әниләр, кашык сабы юанлыгы беләкләрен ачып-сузып йөрүче ятим-ялпы балалар. Бер колхозда бер бөртек ашлык юк, була калса, аны күз карасыдай саклап торалар. Бер авылда да колхозның фатиры калмаган. Тәсләр бозылган, кашлар җыерылган, күзләр бу дөньяның мәхшәрен күрмәс өчен әллә кая тирәнгә кереп чумганнар. Кысылыпмы кысылган күгелҗем-кара иреннәрдән зар, иңрәү авазлары гына чыга. Идәннәре касмакланып каткан авыл советларына, идарәләргә барып керсәң, анда зәңгәрсу гәләфи чалбар балакларын гармун-кунычларга тыгызлап тутырган тук, кызыл чырайлы вәкилләр утыра. Райком, райбашкарма, салым җыючылар, милиционерлар, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр — талаучылар. Алар түшләрендәге киң-киң текә кесә капламычларына кыстырылган алтын каурый каләмнәрен чыгарып ниндидер куркынычлы, явыз кәгазьләргә әллә нинди дәһшәтле сүзләр язалар, саныйлар, теркиләр. Эш бетте саналгач, аларны колхоз рәисләре, бригадирлар, коммунист куштаннар ияртеп китә... Телефонның тынып торганы юк, телефон чыбыкларына кунарга кошлар курка, чыбык буйлап янау, куркыту сүзләре шуышып йөри. Райземотделдан шалтыраталар, уполминзаггтан яныйлар, райфодан куркыталар, райкомнан өркетәләр... МГБ-МВДдан бармак белән төртеп кенә күрсәтәләр: бәндә шунда ук күздән югала. «Давай, давай!» «Бир!» «Тапшыр». «Соңлама!» «Анаңны!» «Арт сабагыңны...» «Сөт!» «Ит!» «Йон!» «Бал!» «Күксагыз!» «Октябрь, Май бәйрәмнәрен тантана белән үткәр!» «Бөек Ста...ның туган көнендә ни, ни, ни...!»

Язгы чәчүдә, урак өстендә районнардан авылларга аждаһалар явы тарала. Күпме симез-симез чиновник ил өстендә ята! Кая ул синең тарихи абжур командаларың?!. Алар болар янында лилипутлар гына! Икмәк тапшырганда Зәйдә бер милиционер калмый, алар арба шыгырдаган юлларга чыга, аһ-зар өзелмәгән сукмакларга аркылы төшә. Биш башак усаң — биш ел төрмә, ун башакка үрелсәң, ун елга җәһәннәм базына дөмегәсең! Төнге сменага чык, көндезләрен басу түреннән кайтып кермә, атың арып егылгач тәртә арасына үзең җигел. Яңгыр астында чүп баскан бәрәңге ызаннарына ятып тәгәрәп җыла. Сиңа шәфкать тә, мәрхәмәт тә, гаделлек тә юк. Бәйрәмнәрдә сине салкын клубларга куып китерәләр, әүвәлге заманнарда тәңренең хак сүзе яңгыраган чиркәү-мәчетләрдә тоташ ялган, тоташ коткы сүзе яңгырый. Авыл куштаннары — коммунистлар, кыптыр туннарын җилбәгәй җибәреп, сәхнәләргә сикерешеп менәләр, рәхәт тормыш биргәне өчен бөек юлбашчыга рәхмәт арты рәхмәт укыйлар, бүләк-санак алалар һәм шыпан-шыпан гына ындыр артларыннан таралалар, тол хатыннарны җылатып-чикылдатып бот араларында казыналар. Районнан килгән олысымак вәкилләр дә буш китмиләр: һәр авылда рәисләр әзерләп куйган мыймылдык хатыннар вәкилләрнең хушбуй сибелгән гәүдәләрен ябынып йоклыйлар...

Мин кыршалган буш букчамны селки-селки вак, ач башаклы арыш арасы сукмакларын үтеп, авылдан-авылга йөрим. Бер җирдә дә мине көтмиләр! Авыл тезләнгән, хәлсез. Кая сугыласың, кемне эзләп табасың монда?! «Комсомолдан» дисәң, сиңа тиле кешегә баккандай карап торалар. Нинди комсомол, кемгә хәҗәт ул! Нәүмиз булып тыелып, туктап каласың. Ә кушып җибәрелгән эшләр бихисап! Бу авылда өч ел инде оешмасы да, комсомолы да, секретаре да юк комсомолның. Ә төптәге кәгазьләрдә бар исәпләнә... Димәк, һаман бер үк суык сүз: взнос җыелмаган, әгъзалар кабул ителмәгән, эш планы төзелмәгән, түгәрәкләр эшләми. Барыннан да бигрәк: марксизм-ленинизм теориясе өйрәнелми... Яшьләр Бөек Сталинның героик сәхифәләрдән генә торган тормыш юлын белми үсәләр! Бу — сәяси сукырлык, сәяси җинаять... Моның өченме?.. Моның өчен... Шундый бөек заманда ил ашыгып-ашыгып коммунизмга менеп барганда, Европа дәүләтләре социалистик системага өерелеп атлаганда, ничек инде даһиларның даһие, зирәкләрнең зирәге бөек Сталинның һәркемгә үрнәк тормыш юлын өйрәнү түгәрәкләре таралган да... әллә тараткаңнармы? Ничек алай таң калырлык тормыш юлын өйрәнмичә яши ала татар-урыс авыллары?! Мин идарәгә юаш кына атлап керәм, мич кырына куелган богаулы кружкадан күгәреп беткән җылы суны эчәм, рәиснең бүтән вәжни вәкилләр белән әңгәмә коруын, кемне алдап, кемне юлдап, кем күзенә төтен җибәреп көйләгәнен-чөйләгәнен тыңлап утырам, рәиснең чак кына бушаганын көтеп торам. Аягымда лайга манчылган кирза итек, өстемдә әни әйләндереп теккән солдат бушлаты. Күн букчамда бер кыерчык ипи дә вак-төяк кәгазьләр. Беләм, ышанам, бу авылда да мине фатирга кертмәячәкләр, түргә утыртып бер-ике чынаяк кишер чәе белән дә сыйламаячаклар. Мин «кемгә кирәк ул бүген комсомол!» дигәнне колагым белән ишетмәсәм дә күзем белән күреп, аңлап торам, шуңамы мин рәисләр белән аяк терәп сөйләшә алмыйм, авылның, колхозның, ахыр чиктә рәиснең мәшәкатьләрен аңлап торганга сүзләремнең дәрәҗәсе, көче, абруе юклыгын бик нык беләм. Инде өстәлне сарган саранчалар әкренләп кими, тамагы сүзгә тыгылган телефон да алҗып тына, мин кыяр-кыймас кына, тавышсыз адымнар белән рәискә якынлашам, аягүрә басып кына аның күз карашын тотып алырга тырышам. «Мин... Зәйдән, комсомолдан...» диюгә рәиснең сытык чырае тәмам караңгылана. Шуннан арысын ул тыңлап та тормый, мич арасында шым утырган ямаулы тешсез корткага: «Миңҗамал түти!» дип кычкыра. Аннан сыңар күзен миңа карап ача: «Фамилияң ничек әле синең?» Мин әйтәм: «Гыйләҗев мин, райкомолдан!» Карчык, ямаулы яулыгын бушатып, җилдә киселгән колагын ачып тыңлый. «Менә... иптәш Гыйләҗевне Миңнурый янына илт!»

Мин адымнарымның тагын да ныграк авырайганын сизеп лыштыр-лыштыр Миңҗамал түти артыннан теркелдим. Миңнурый авылның Зәй очында, әллә кайда яшәргә тиеш икән. Ярты сәгать баргач, күләгәләр озаеп, урам уртасына ук төшә башлагач, моңарчы авызын йомып барган кортка ыңгырашып, үзе белән үзе киңәшә башлый: «Өйдә микән әле ул биләмче Миңнурый?! Бу арада бер дә күзгә-башка чалынганы юк».

«Бу арада» дигәне тора-бара миңа да аңлашылды, Миңҗамал кортка Миңнурыйны сугышка ирләрне озатканда күргән дә... шуннан биргесен белми икән. Миңнурый кайчандыр комсомол секретаре булган, имеш. Барабыз, барабыз да нигезләре бүселеп таралган, өчтән ике тәрәзәсе салам эчле такта белән томаланган өйгә барып җитәбез. Ихата юк диярлек, киртәнең казыклары утырып кына калган. Казык башы саен кара карга, без килә башлагач җилпуч-җилпуч канатлары белән җиргә кара күләгә коеп, каргалар төркеме кузгалды. Миңҗамал карчык кара таяк — бармаклары белән зәңгәрсу томан кунган пыялаларга кагылып-кагылып алды. «Миңнурый, Миңнурый, ятып бәхетең арткыры!» Киртәсе булмаса да ишегалдыннан капка ачып йөз яшәр өшәнгән бер карт килеп чыкты. «Миңнурый өйдәме, Гыйльметдин бабай?»

Миңҗамал кортканың тавышы үзгәрде, җылынды. Бабайның чырае бозылды. «Тагын кәнсәгә дәшәсеңме, кортка? Тагын заемга язылыргамы? Түт-тү! Миңнурый котылды инде, бар, тот, басудагы җилне! Яраслауга турыф эшенә китте Миңнурый. Ике ел эшли инде».

Бу юлы мин Миңҗамал карчыкның алдына чыгам, без шулай, адашкан бәбкәләр төсле, аллы-артлы колхоз идарәсенә кайтып керәбез. Күз алларым караңгыландымы, кич җиттеме, рәис каядыр чыгып сызган, мин Миңҗамал корткадан озаклап сораша торгач, парторгның «адресын» алып, аны эзләп китәм. Кырык җирдә эзләп, «майлы» урыннарга кагылгач, партоешма секретарен тегермәндә эзләп табам. Тегермәннең исеме генә, күптәннән тартмый икән, шунда, он тузаннары арасында парторг тегермәнче-мичкә, аркылысы-буе бер, кәкере аяклы, кәҗә сакаллы куштан-коммунист Мисбах белән тозлы суда җебегән куыш кыяр каба-каба сасы самогон чөмереп утыра икән. Кирәргә ярамаганны белсәм дә кердем, бүтән чарам калмады. Парторг ачык чырай күрсәткән булып, төче-ясалма елмаеп, сүзләр тезде. «Әйе, әйе, моңарчы кул тимәде: комсомолны, даңлы комсомолыбызны ныгытырга күптән вакыт!» Парторг мине иртәгә, клубка кайтты, баксаң, Миңнурый Яраслауга шылганда комсомол «Дело»ларын аңа тапшырып киткән икән. Биш-алты ел элек төзелгән планнар, бер кирәкмәскә өч ел элек язылып, чит-читләрен идән асты «стахановчылары» сычканнар кимереп бетергән җыелыш беркетмәләре. Парторг куе төкләргә төрелгән юан бармакларын теленә тигереп юешли дә саргайган кәгазь битләре арасында йөзә. «Әһә, Ленинның фәлән еллыгына зур тантана уздырганбыз икән... Әһә! Мәһә!» Парторгны борып җибәргәннәрмени, теле тегермән тарта, корсагы тук, кикереп тә куя, эче богырдый... Ә минем моннан тизрәк таясым, нык караңгыга кадәр Урта Багражга — әтиләр йортына кайтып җитәсем килә! Юньле кунар урын юк Ленин комсомолына, аның тамагын комсомол фәрештәләр туйдыра дип тәгаенләнгән, шул акыл иңгәннән бирле мин районны икегә бүлдем. Бу тирә-як авылларында йөргәндә мин әтиләргә кайтып кунам. Икенче якка тап булганда ризыкны үзем белән йөртәм. Ходаваңдәм кичерерсең мин гөнаһкярны! Керәшеннәр арасында яшәвемә рәхмәт укыйм, ерак юл, ач сукмаклар өчен тозлаган дуңгыз маеннан да кулай ризык юк. Чиметеп кенә капсаң да комсомолның ялкынлы көрәшләренә катышып китәргә була! Райкомолда күпме батырлык кылып, күпме урыс-татар авылларын секретарьле итеп, активларның санын арттырып ике тапкыр чынлап торып кунак иттеләр диярга була. Урак өстендә Ялантау дигән урыс авылында мине комбайнчылар ризыклана торган фатирга керттеләр. Хуҗа хатын, йөзе күгелҗем җыерчыклар белән мул бизәлгән орчык башы хәтле генә сөйкемле маржа, ах-ух килеп, ухватка

утыртып киң авызлы юмарт мичтән бер батман су сыешлы чуенны тартып чыгарды. Исем китеп карап утырам, авыздан селәгәй ага, ул миңа өреле, татлы исле, куе кәбестә шулпасы сосып бирде. Чите китек агач кашык шактый бәндәләрнең авызына кереп чыккандыр, мәгәр аның шушы кадәр җитез очканы булдымы икән? Шулпаны чупырып алганда тәлинкәдә нәни генә дулкыннар хасил була, шул дулкыннар сүнеп тә бетми, агач кашыгым тагын тәлинкә өстенә килеп куна. Өч тәлинкәне ашап бетергәч, марҗа апаның сирәк кашлары бер илле өскә күтәрелгәч, ул, Рәсәйнең миллионлаган адәмнәре арасында мине аңлаган бердәнбер җан иясе, дәшмичә авыр сулады да, чуеннан кушйодрык хәтле ит калҗасын бакрач белән сөзеп алды да тәлинкәмә китереп тә салды! Калҗадан күтәрелгән хуш истән башым әйләнеп китте. Әгәр гәүдәм өч тәлинкә кайнар аш белән ныгымаган булса, валлаһи, идәнгә тәкмәрли идем... Мондый да тәмле шулпаны, йомшак симез итне, гел кәрәзләрдән генә торып күпергән бодай калачын ашаганым булдымы икән? Минем юк эш артыннан комсомол көтүчесе булып йөрүемне марҗа апа белмәгәндер, үзем әйтмәдем, ашагач, яңгыратып бер кикереп җибәрдем дә эре генә: «Зәйдән... Хөкүмәт эшләре белән йөрү!» — дигән булдым.

Икенчесендә тамагымны пух итеп Югары Пәнәче авылында туйдырдым. Анда авылдашым, Югары Баграж кешесе Иван Николаевич Урамов укыта икән. Көләч, ягымлы, сөйкемле кеше иде Иван Николаевич! Аның мине зурлап каршылавын, якты чырай белән түренә дәшүен, кыстый-кыстый кунак итүен гомергә онытканым юк. Исемдә, бәрәңге дурычмагы пешергәннәр иде, аны чүмәләкәй итеп өеп китерделәр... Шәп ашаганым хәтеремдә, чүмәлә төбенә төшеп үк җиттем микән, әллә иягем учына терәп, терсәгенә таянып миңа шаккатып карап утырган хуҗаны күргәч тыелдыммы? Онытканмын...

Мин ярлы авылдан ярлырагына барып керәм, юллардагы хәерчеләр дә мине белеп бетерде инде, очраганда берәр телем ипи тәкъдим итәләр, ачны ач тиз күрә, тукларның гына миндә мазалары юк. Эшлибез, кәгазь кимерәбез, ә райкомолның эше үрчеми. Исәп-хисап бүлеге хезмәткәре Елена Мачтакова көне-төне райкомолда ятса да, тартма-тартма шыплап тутырган учет карточкаларының рәтен таба алмый. Сугышка озатканда егетләрне ур-ра кычкыртып комсомолга кабул иткәннәр. Митинглар булган, учет карточкаларын әштер-өштер тутырганнар да караңгы киштәләргә ыргытканнар. Элек комсомол сафларында торганмы ул, юкмы — вакчылланып тикшерергә вакыт җитмәгән. Йөзәрләгән егетләрнең икешәр учет карточкасы калган. Берсе дә артларыннан ияреп китмәгән. Егетләр таралган, берәүләр вафат, икенчеләре эзсез югалган, ә безнең комсомол учеты каберлегендә алар сау-сәламәт сакланып башыбызны катыралар. Авыллардан кайтып кердемме, мине Еленага булышырга куялар. Чытыр арта тутырырлык иясез катыргыларга карыйм да Мачтаковага пышылдыйм: «Әйдә, тотабыз да яндырабыз боларны!» Елена сак, сизгер кыз, почык борыны белән беренче секретарь утырган, фанер белән генә бездән аерылган куентыкка ишарәли: «Тс-с... Ярамый!»

Ул чагында минем балачак дустым Гурий Тавлин армиядән кайтып авылда яшәп ята, без еш-еш очрашабыз, икебезнең дә әдәбият белән саташып йөргән чаклар. Икебез дә Василий Багряшевский түгәрәгенең иң актив әгъзалары. Гурий, шигырьләрен урысча гына язып җиффәреп, безне шаккатыра. Нигә татарча язмый икән, дип гаҗәпләнеп йөрсәм, Гурий Надсон, Байрон шигырьләре белән мавыга икән. Мин ул вакытта үзем дә китапларны «ашап» кына бара идем. Тамак туймаса да, җан азыгы табыла, урысчам яхшырды, классикларны укыйм, урыс язучыларына ябырылам. Йотам гына! Безнең райкомол бинасы Кавказ халыкларының саклясы кебек ярты ягы белән таучыкка кергән иде. Өске катта большевиклар штабы — партия райкомы. Үзебезгә дә гәзитләр килә, комсомол һәрчак белемгә омтыла! — гәзитләрнең элеккеләрен дә төпләптуплап теккәннәр. Эш сәгате беткәч тә райкомолдан китмим, гәзит-

журналларны актарам, фатирыма кочак-кочак алып кайтып та укыйм. Коммунистлар көтепханәсе, буфетлары шикелле үк бай. Җай чыкса, анда да менеп төшкәлим.

Яшь чагындагы уку — эзләнү ул. Күңел юату, ял итү өчен китаплар белән мавыгу соңрак килә. Яшьлектә ризык белән тәнеңне ныгытасың, китап укып зиһенеңә көч җыясың. Укыйм мин, уйланам, хәтерем нык, уем йөгерек: мин уралып яшәгән тормыш хакында бер генә газит тә, бер генә журнал да язмый, язылганнар белән күргәннәрем арасы җир белән күк арасы! Газит-журналларның яртысы Сталинны мактаудан, икенче бер яртысы безнең илдәге иркенлекне, киңлекне күккә чөюдән тора иде. Ә анда, буржуа дәүләтләрендә... Бичара Жан ач-ялангач, яңгыр астында калтырап утыра... Өрлектәй негрлар аяк киеме чистартып, чүп савытларында казынып җан саклый... Шуларны җәлләп җылый татар балалары. И бәхетсезләр!.. Яшь чагында күңелгә иңгән уй әзме-күпме ныклы урын алуга үзенә юл таләп итә. Яшьлек сере ялгыз була алмый. Күзәтүләремне, күңелгә уелган уйларны кем беләндер уртак итәсе, үз акылыңа куәт, яклау ишетәсе килә. Тора-бара андый иптәшләр дә табылды. Авылга кайткач зар-моңнарымны Гурий Тавлинга түгәм. Баграждагы тагын бер иптәшкә сөйлим. Сарсаз Баграж урта мәктәбенең директоры мине аерата якын итте. Чакырып кына тора, кайттым исә мунча яктыра, өстәлгә гөҗләп, күп серләрнең шаһиты җиз самовыр менә. Сүзем өзелми, берәүдән дә шикләнмим, уема ни килсә, яшен яшьнәтеп чыгарып салам. Нигә шулай мескен безнең авыллар? Җирең юк, мал-туарың юк, гаиләдә нужаны сөйрәп барырлык ир-ат калмаган... Шулай да кемнәрдер синең тамагыңа ач бет булып кадала, талый. Сине як-ягыңда йөз буанак корылган, тәбе сагалый. Җәза отрядлары бары тик сине буарга әзер. Инде шулай да булсын, ди. Ил бөлгенлегенә сәбәпләр дә таптык, ди. Нигә без шушы тоташ хәерчелекне туктаусыз мактыйбыз? Нигә без балачактан гүргәчә бер-беребезне алдарга һәм алданырга өйрәтәбез? Нигә безнең канаган авызлардан, хакимият җимергән иреннәрдән бер генә дә хак сүз чыкмый?.. Районда мин булмаган хуҗалык юк, мин кагылмаган авыллар калмады, һәркайда чамасыз бөлгенлек, ачлык. Нигә алай?!

Нигәлеген инде ап-ачык чамаласам да, мин еш кына беренче остазым, барыбызга акыл бирерлек дәрәҗәдә аңы үскән зирәк Хәбир Зәйнуллинны сагына идем. О, бәхет, шулай килеп чыкты: минем бульшылык белән Гәрәй Гәрәев районның мәдәният бүлегенә эшкә керде, һәм без — иске дуслар бер фатирда яши башладык. Авыллардан алган тәэсирләремне, күргән-белгән фаҗигаларны һич яшермичә Гәрәйгә сөйли идем. Ул, яшь чагындагы кебек теләндә утлар уйнатмаса да, фикер йөрешендә миңа иярә, үзе белгән мисаллар ярдәмендә минем шик-шөбһәләремне ныгыта торган иде. Гәрәйнең егет чак шуклыгы өстенлек алганда, аның кайбер йогышсыз мавыгуларының чик сызыгыннан чыгып киткән мәлләрен белгәнгә без тәмам аңлашып, җан дуслар булып китә алмадык шикелле.

Көннәрдән бер көнне, аһ-уһ итеп, Елена Мачтакова райкомолга кайтып керде һәм без аулакта икәүдән-икәү генә калгач: «Аяз, бел, мине МГБга чакырдылар, синең хакта бик җентекләп сораштылар. Аларны бигрәк тә Тавлин дигән кеше белән булган мөнәсәбәтегез кызыксындыра»,— диде.

Кисәтү иде бу, искәртү иде. Хәзерге акылым белән мин ул хәбәрнең асылын болай дип чиштем: шул көннәрдә Тавлин белән ике арага тагын бер кеше килеп кергән! Чыннан да, алдагы тормыш шигемне раслады. Иң хикмәтлесе: бу кеше төрмәгә кергәнче безне күз уңында тотты һәм бер чакта да бездән калмады.

Җитмәсә мин укытучыларның август киңәшмәсендә комсомол исеменнән чыгыш ясадым. «Мәктәпләрнең хәле мөшкел,— дип әтәчләнгәнмен икән,— укытучылар сөрсеп беткән, күбесе күгәрек белән капланган,

наданнар...» Бүтәннәр Сталин исеме белән башлап сүзләрен аның саулыгына ур-ра кычкырып тәмамлыйлар иде. Ә минем чыгыш тоташ каралту булып яңгыраган. «Якты мисалларым юк, минем андыйларны очратканым да юк!» дигәч, хуҗам сытык чырай белән миңа текәлде дә: «Юк икән, тап! Табалмыйсың икән — уйлап чыгар! Сине нигә комсомол вожагы итеп йөртәләр соң?» — дип, озак кына әрләде.

## 11

*Безнең буын сталинизмга чирканып карый. Тапталганнар, изелгәннәр — без идек бит! Гомерем буе гарип уйлар тозагында тырпылдадым мин. Мәктәп елларыннан бирле миңа өзлексез тукыдылар: әгәр син безнең гүзәл илдә түгел, ә ерак Америкада туган булсаң... бер телем икмәк өчен пычрак савыт-саба юудан уза алмаган булыр идең. Ә болай, институтта укыттылар, эш бирделәр, яшәр урының бар. Төрмәгә утыртмадылар! Рәхмәт кенә укы!.. Шулай яшәдек: куркып калтырадык, рәхмәт тә укыдык!*

Валерий ПРИЕМЫХОВ, драматург һәм актер. «Илле өченче елның салкын җәендә» исемле мәшһүр фильмда Басарган ролен башкарган артист.

Мәктәп елларым — сугыш еллары. Җәйгә чыккач ял иткәнем, ялкау симерткән көннәрем булмады да шикелле. Өй арасында, үз ындырында эш бетеп тормый. Әмма төп эш колхозда. Бугазыңа ябышып куалар! Ике ел мал көттем мин Югары Багражда, бер ел сарыкларны, икенче җәйдә мырыйк-мырыйк, чүк-чүк чучкаларны. Колхозчы — кол, көтүче — аннан да түбәндәрәк, аңа татар телендә исем дә калмаган. Көтүче — дуңгыз күтен сөртүче! Шул иде аның исеме. Эш арасына әнә шул дәрәҗәне тагып килеп кергәнгәме мин җитәкчеләрнең һәр каюсыннан — югарысыннан да, түбәненнән дә куркып күнеккән идем. Звено җитәкчесе миңа чүкеч, бригадир пычак, рәис чалгы булып күренә иде. Ә инде район түрәләре — вәкилләр минем күзгә җәллад, сатрап, яэҗүҗ-мәэҗүҗ, тәмуг сакчылары булып кадалалар. Аларның бер рәвешле аякларын ерып атлаулары, тук тамак төбе белән генә сөйләшүләре, һәрчак кемнедер аты-юлы белән сүгеп, орышып китүләре минем шигъри җанымны мең кат рәнҗеткән, суыткан иде. Рәис-бригадирларның, терәлеп торган күрше-авылдашыңның да тәмле тел белән эндәшкәннәрен, хәлеңә кереп сөйләшкәннәрен хәтерләмим мин. Шул гыйлемлеккә үзбашларыннан өйрәнделәрме, көн аралаш районга чакырып кешелексезлек сабагын биреп кайтардыларме, кичәге крестьян бүген урынга утырса, тәмам бозылып бетә иде. Яшьли сеңгән авыр гадәт хәзер дә китми, мин әле дә хакимияттә урын билəгән адәм балалары белән кыяр-кыймас, теләр-теләмәс кенә очрашам. Бер-бер йомыш юллап, начальство катына бару — минем өчен үлем. «Атказанган» исемнәре бирделәр, «лауреат!» дип түшкә калай тактылар, ә көтүчелек, коллык җанның зур өлешен биләп яшәп ята! Большевизм үзенең кара көчен нык сеңдергән безнең буын вәкилләренә. Минем дә вәкил булып караганым бар! Бу мәзәк хәлне дә түкми-чәчми сөйләп бирәсем килә.

Бигеш авылында даими вәкил булып райбашкарма рәисенең урынбасарын тоталар иде. Аны ике атналык семинарга Казанга дәшеп алганнар да, о ужас, колхоз вәкилсез калган. Ярамый, вәкилсез ярамый! Вәкил — алла, ул юк икән — колхозның бар эше өзелә, сыерлар сөт бирүдән туктый, җир сөрелми, силос салынмый. Җил дә исми, яфрак та селкенми вәкил-алла кодрәтеннән башка! Эзлиләр, эзлиләр, Бигешкә ике атналык вәкилгә кеше табалмыйлар. Арысландай үкерә белүче, өч кеше-

лек хәмер әчеп, дүрт кешелек ризык ашаучы киң күкрәкле, кап корсаклы кешеләр беткән Зәйдә. Беренче секретарьның указлы бармагы активлар исемлеген чүпләп өстән — аска, астан — өскә өч мәртәбә йөреп чыга, юк кына, юньле адәм калмаган район үзәгендә! Гөнаһ шомлыгына каршы, кемдер минем исемне атаган, мине чаптырып алып менделәр дә «Барасың!» диделәр. Баткан аяк чыланган, чыгып киттем вәкил булып тарантаска утырып. Тарантаска киерелеп утырып бүксәмне киерә төшеп юлга чыккан идем, үзгәрдем дә куйдым. Чап-чап атлаган җәяүлеләргә кырын күз дә салмыйм, чибәр генә кызлар янымнан үтә, әйләнеп тә бакмыйм, атымны юрттырган да булам әле җитмәсә. Бераз баргач та акылым әйләнеп кайтты: адәм баласы тиз үзгәрә, диләр, үзгәрми ул — бозыла. Киңәшсез чыгып киттем, Никитин да, Панфилов та күптән авылда, тавык бүтәкәсе ашап, кам-мәмер килеп яталар... Ярты юлга җитәрәк, күз белән колак ачылып китте. Чүп басып киткән кырларга карап күңелем сүрелгәннән сүрелә бара, тарантас тәгәрмәчләре шыгыр-шыгыр мине үртәп баралар, өзә-төтә тургайлар сайраган була. Бигеш авылына барып җиттек. Заманында мул тормышта яшәгән авыл. Карбызга кадәр үстергәннәр алар. Шәриф Камал шушы авылга сыйланырга килә торган булган.

Колхозның исеме «Алга», рәисе Ярулла исемле, өлкәнәеп килгән крестьян иде. Авыл арасында Мыек Ярулла дип йөртәләр.

Вәкил дәрәҗәсе алып, авыл арасына чыкканчы фатирга урнашасы бар ич әле. Элек түгел, хәзер шукланып тантана итәм: әһә, бу юлы фатирсыз тинтерәтә алмыйсыз инде! Йончыган, таушалган, өшәнгән Ярулла агай миңа монсу гына карап алды да авыр сулады, почмакта су багы сагында утырган җиңгигә нидер әйтергә омтылды да кулын селкеп, мине ияртеп алып чыгып китте. Фатирга үзе урнаштырды. Дәрәҗә! Абруй!

Фатир хуҗалары белән кыска гына таныштырып үтим. Авылдашым, Югары Баграж күршеләреннән берәү Леонид Макарович Герасимов Бигештә фельдшер булып эшли икән. Хатыны Александра Михайловна Ямашева — укытучы. Леонид — Макар дәдәйнең өченче малае, бөгелмәс гәүдәсен туганнан бирле туп-туры тотып, заманга яраклаштырып калыпланган, берчакта да әңгәмәдәшенең күзенә бакмыйча, әллә кая ноктага, Леонид үзе күрер өчен сайлап алган ноктага гына карап, кабаланмыйча, кулларын як-ягына ябыштырып-элеп куйган серләрнең серлесе иде. Әйтик, клуб-чиркәүдә уен бара, «вичер» уйныйлар. Мәктәпнең кайнап торган еллары, егетләр мыж, кызлар чутсыз. Леонидның егет булып килгән чагы. Ярлы, ишле гаиләдән, өс-баш та әлләкем булмагандыр, ә егет һавалы, өскә чыгасы, әлләкем буласы килә! Түбән авыл укытучысы Уарның Катя исемле, йомырыдыр үзе, чибәрдер, сеңлесе дә шунда, кызлар арасында. Тар юбка итәкләрен ертып ыргытып шәрәтән көнгә чыгардай булып өздереп бии кыз! Уен күрке Катя артыннан берничә егет кыдырып йөри, кызга иркенләп тын алырга да ирек бирмиләр, алмаштилмәш биюгә чакыралар. Леонид биеми, ыбыр-чыбырлар арасына керә, уз гәүдәсен бөгәме соң, аллам сакласын! Бер үткәндә минем каршыма килеп туктады да: «Карандашың бармы синең?» дип сорады. Гөнаһ шомлыгына каршы, мин Леонид шикелле һавалы җан, уен арасында кесәдән эре генә карандаш чыгарып, шыршы кабы хәтле генә үзем теккән кусн дәфтәренә бер-ике шигырь юлы төртеп куючы шагыйрь, карандашымны чыгарып бирдем. Леонид кусн кесәсеннән дәфтәрчек чыгарып, эре-эре хәрефләр белән ике генә сүз: «Дошманнар арасында», дип язып куйды. Шушы ике бөек сүз, Леонидның олысымаклыгы сеңгән төз гәүдәсе, горур кыяфәте, беркемгә бирми белдерми торган серле карашы мине әсир итте. Ярлы крестьян баласы Леонид миңа әкияттәге герой, легендаларга керерлек батыр булып тоелды... Мин кайнарланып адашып йөргән дәвердә егет белем, һөнәр алган һәм өйләнеп җибәргән икән. Һәм аның хәләл җефете — Александра Михайловна Ямашева мине

язучы иткән якты шәхесләрнең берсе иде! Искиткеч моңлы тавышы, яңадан-яңа җырлары белән минем яшьлегемне бизәгән, ашкынулы кайнар хисләр сеңдергән, дөньяга һәм үзенә гашыйк иткән былбыл баласы! Укытучым, үземнән берничә яшькә олы булган Александра Михайловна йомылып яшәргә мәҗбүр булган авылда миңа опера театрларын, концерт залларын, симфоник оркестрларны алыштырган бөек зат, ул минем гыйшык көтеп тилмергән җанымны, шигърият шашынып аккан кан тамырларымны, янарга әзер җанымны үз учында йомарлап, татар моңына алып керә алды. Ләлә, Шәмсекамәр, Галиябану... Ул уйнаган спектакльләр, аның сайрар күңеленнән мул түгелгән борынгы җырлар. Керәшен җырлары! Аның тиңдәшсез моңы әле дә колак төбемдә чыңлый, онытылып тыңлаган сихри мизгелләрем хатирәсе җанымны белеп кенә җылыта. Хәзерендә Нәфисә Василова җырлаганда: «Бу аның тавышы ич! Аның моңы!» — дип сагынып күңелем иңри... Минем аңа язган егетчәк хатларым кайда?.. Син үткән юлларга койган күз яшьләрем ал гөлләр булып тишелә алдымы икән?

Кырык җиденең җәй башы. Бигеш, Бигеш... Борынгы татар авылы. Борынгылыгың шаһитлары булып зиратыңда исемсез-эзсез югалган калкулык-үркәчләр. Синең шушы кадәр таланган, бетәшкән, бичара чагың булдымы икән?! Язмыш мине тагын тоташ ачлык, кытлык белән күзгә-күз очраштырды. Ачлык исе, ачлык төсе йорт-кураларга сыймаган, урамнарга ук ташып чыккан. Өй борынча йөреп, эзләнеп чык, беркемдә ризык заты юк. Колхоз мал курмысы әзерләргә, силос салырга тиеш. Ә эшкә чыгучы юк. Ярулла агайга ияреп, иртәнчәк өйдән-өйгә авылны урап кайтабыз. Кемгә барып кермә, шешенгән, күзләреннән нур качкан, сәләмәләргә төренгән балаларны очратасың. Алар уйнамыйлар, гөрләмиләр дә, йомык чәчкәләр сыман кайсы-кайда каңгырып утыралар. Казанда яшь бәрәңге яфрагына алабута катыштырган боламык пешә. Казаннан быкыр-быкыр чыккан әче ис тә аларны куркытмый, пешсен генә, җәтрәк пешсен, корсакны алдарга бер-бер кайнар нәмәстә булсын. Боламык, ниһаять, өстәлгә менә, күзләрне әчеттереп өйгә бу тарала... Урамнар буп-буш, этләр дә юк, кыр-кыр иткән тавык-кош та күренми. Бөтен өмет әнә шул бөдрәләнгән яшь бәрәңге сабагында. Әле бу ананың фермага, җан биреп яткан хәлсез маллар баш очына төшәсе бар. Аның күзгаласы, ач балаларын ташлап китәсе килми. Ана барда өмет суынмый ул! Ярулла агай тавышсыз атларга тырышып өйгә керә, үгетли, нидер сөйләгәндәй итә, минем колагыма, ачлыктан саңгыраулanган җаныма аның сүзләре үтеп керә алмый. Мин дә мескен апаны юатмакчымын, нидер әйтәсем килә, ә сүзләрем чыкмый, ян сәкегә чүгеп утырам да Ярулла агайның дога укыгандай тавышын хуплап иягемне селкетәм. Нинди көчкә, нинди ышанычка таянды икән Ярулла агай?! Хатынның эшкә чыгарга ризалыгын алып, күрше йортка кереп китәбез. Аларда да шул ук хәл. Алай гынамы сиңа, өй тирәсендә шайтан таягыдай арык, ачлыктан төс җуйган бер-ике карт-коры да күренеп кала. Алар, аламсалам белән арык тәннәрен төреп, безгә күренергә читенсенәләр. Берәү дә телдән зарланып, ялварып тормый, ачлык үзе хөкемдар, йортларда аның өстенлеге генә калган. Мыек Ярулланың бердәнбер юату сүзе дә бар: «Менә, туганнар, кашлакта арыш тугаеп килә. Урта Пәнәче юлына чыгып караганыгыз бармы? Аллаһ боерса, буаны шушы араларда рәтләп бетерербез. Сугу машинасын көйләп куйдык. Беренче башактан ук һәммәбезгә әз-мәз өлеш чыгарырбыз, иншалла». Мин аның күзләренә күренмәскә тырышам, бу юлы ул алдый, хәйләгә сабыша, өметләндерә, ялган аша авылдашларына көч, өмет бирергә тырыша. Ялган дөньясында яшәргә калгач, бичара карт ни кылсын? Ул да, мин дә бик яхшы беләбез, бер бөртекне дә читкә таратмаска дигән райкомның катлы-катлы боерыгы рәиснең өстәл тартмасында бик ләнеп ята. Игеннең беренче вә соңгы потлары да дәүләт амбарларына барып керергә тиеш! Әле элеваторларга барыр юлларга милиционерлар чыгачак, депутатлар, вәкилләр, куштан

коммунистлар сунарчы явыз этләргә әйләнәчәк, төн убырлары шикелле көн-төн ындыр табакларында алар уралачак. Аларның берсе дә ач тамаклы крестьяннар бардыр дип уйламаячак.

Ярулла агайның да авылдан ераклашасы киләме, тау башына менеп китәбез, әлерәк кенә без шаһит булган хәлләр авызларны йозаклаган, аякларга гер таккан. Сөйләшмибез. Тау битендәге аннан-моннан ермачланган басуны өч-дүрт үсмер тырмаларга тиеш икән. Күзге чәчүгә әзерлек бара. Барабыз, барабыз, күрше авыл түбәләре күренде, атлар бар, ә тырмачы малайлар юк. Ни хәл итәсең, язга чыкканнан бирле туя ял итмәгән балалар җылы җиргә бөгәрләнеп ятып йоклаганнар. Ярулла агай кызды: «Син, вәкил иптәш,— диде ул,— читкәрәк китеп тор, мин бу ялкауларның яңагына менеп төшим әле». Кул салмады, әйтте генә, малайлар гүр йокысына талганнар икән, Мыек Ярулла аларны озак уята алмагач җылап җибәрде.

Рәиснең, уракка төшәр алдыннан саклап тоткан бер центнер гәрчис ярмасы бар икән. Идарә карары белән эшкә чыккан һәркемгә шул горчицаны икешәр йөз грамм бирә башладылар. Фельдшер Леонид Макарович дау күтәрде: «Сез халыкны үтертеп бетерәчәксез! Ачтан киселгән ашказанын момент турап бетерәчәк ул гәрчис орлыгы! Аны ашарга ярамый!» И кешеләрнең сөенгәне! Кичтән шул ике йөз граммны алып кайталар икән дә салкын суга салып чылаталар икән. Төн дәвамында суны бер-ике тапкыр алыштыралар, иртәнчәк, чак кына йомшаган сары бөртекләрне агач тукмак белән төяләр дә яшь бәрәңге яфрагына кушып пешерәләр. «Кунак сые!» дип ашыйлар шул нәмәрсәне балалар. Ә аналар ашамый, ничек ашасын, күпме кешегә җитә ул ике йөз грамм?!

Корбан бәйрәме килеп җитте. Бигештә, мәчетнең манарасын кисеп, «мәктәп салганнар». Шул мәчет-мәктәптән ерак та түгел Ленин һәйкәле. Татарстанда салынган беренче һәйкәл дип сөйлиләр. Колхоз уңышлары өчен авылны һәйкәл белән бүләкләгәннәр, бигешлеләр генә аптырашта калган: кая, ничек урнаштырырга бу таш бабайны? Ике елмы, өчме, әллә дүртенчегә үк киткәнме, һәйкәл абзарда, улак башында аунап яткан. Районнан килгән вәкилнең күзе төшмәсә, бөтен дөнья пролетариатының юлбашчысы гомер буе алашаларның башак кимергәнен карап ятасы икән. Вәкил күргәч... Ленинның сынын күгәрчен тизәгеннән арулап, авыл уртасына чыгарып утырткannар. Иртә-кич мин юлбашчы янынnан үтеп йөрим. Бүген дә шуннан үтеп киттем. Төнлә ишеп-ишеп яңгыр явып үткән иде, урам пычрак, чокырларда болганчык су җыелып тора. Зират очыннан кайтып килгүче биш-алты бабайны очраттым. Бәйрәм көн, ә аларның чырае качкан, сөмсерләре коелган. Мыек Ярулла алгарак чыгып, мине бер читкәрәк алып китте. «Буа киткән бит безнең... Буасыз да калганбыз!» Бу чамадан тыш кайгы иде. Ярулла-Мыекның да, авылның да бар өмете буада иде. Буа суына көйләнгән суктыргыч хәзер эшсез калды. Өлгереп, агарып килгән арышны хәзер ни әмәлен табып сугарга? Бабайлардан калган чабагачларга кайтыргамы?

Атна үттеме икән, бер чытыр арба арыш көлтәсен буа ягасындагы ригага кайтарып аудардылар. Ярулла җан тирләрен коеп ялварды: «Туганнар! Әгәр берәрегез ялгышып кына кырдан бер башак алып кайта икән, аны момент өтермәнгә тыгачаклар. Быел катылык. Менә бу кайткан көлтәләрне монда уасыз, монда кыздырып өмә ясап ашап та бетерәсез. Сыңар уч журнаны кесәләргә тыгарга рөхсәт юк. Үзегез дә бетәсез, мине дә бетерәсез». Эш худка китте, уалар чи башакларны, каяндыр калай табып китерделәр, аларның чит-читләрен бөкләп дәү табалар ясадылар. Чатыр-чытыр учаклар яна башлады, күмер төште. Бөтен авыл кызган арыш ашарга җыелды. Уртлар канаганчы, телләр күперең шешкәнче куырган арыш ашады Бигеш халкы...

Адәмнәрнең төрле кыяфәтен күрә алган, аларның бәхетсезлеген, ерткычлыгын, исәрлеген дәһшәтле буяулар белән сурәтләргә куәтләре, талантлары җиткән бөек рәссамнар бар. Иероним Босх, Гойя иҗат-

ларына игътибар итик. Такырланган ындыр табагына җыелып, дүрт почмаклы калайларда кызып, ут атып торган эссе арыш бөртекләрен пешенә-пешенә ач авызларына тутырган җеп сыйраклы, карандаш бармаклы балаларны... Хәер, кирәкме икән аларның өрәктәй сурәтләрен тарихта калдырырга? Кемгә кирәк алар? Без кичергән ачлык газапларын сөйләп тә, сурәтләр аша аңлатып та була торган түгел.

Ихлас ышанып әйтәм, райком җибәрмәде мине Бигешкә. Ходам минем юлымны шунда борды, адәмнәрнең авыл белән ачыгуына мине шаһит итте. Табигать сердәше итеп Тәңрем мине сайлаган дип бүгеннән торып әйтә алам.

Яшьтән үк йомык булмаган үткен күзем белән мин татар кыйналган дөньяны карап үстем. Ләкин кешеләрне кызгану, дөньяга шәфкатьле күз белән карау, юксылларга һәрчак теләктәшлек белән эндәшү минем төп һәм бердәнбер иманым булып бетә алмады. Актер Приемыхов нәкъ мин уйлаганнарны әйтеп биргән! Әйе, бөтен яктан сиңа баллы яңгыр булып татлы сүз ява, татар әдипләре сүз куешкандай илдәге бәхетле тормышка дан җырлый. Җыелышларда — тирес чыгаруга багышланганмы ул, Париж коммунарлары истәлегенә җыйналганмы, сүз гел бер якка борылып тәмамлана: безнең ил, безнең ил! Безнең ил — бәхет чишмәсе, шатлык чыганагы!.. Әле ботарланмаган саф күңелем белән, яшьлекнең зирәк акылы белән бу төче ялганны күреп әрнегәнем дә, икеләнгән чакларым да еш булган. Көне-төне баш очында барабан кагып торган большевиклар минем кебек тиз ышанучан авыл малаен изгән, сыткан. Соңыннан, күп еллар үткәч, яраткан язучыларымның берсе — Стейнбекның: «Все в Советском Союзе происходит под пристальным взглядом гипсового, бронзового, нарисованного или вышитого сталинского ока», — дигән гадел сүзләрен укыдым. Әйе, мондый ук кискен фикерләрне яшьлегемдә авыз тутырып әйтә алмасам да, мин икеләнүләр, шикләр тозагында яши идем. Хәзер ул еллардагы әдәби әсәрләрне укып карыйм да... шаккатам! Язучылар берәм-берәм дә, тыгыз төркемләшеп тә бер үк төссез төче җырны сузганнар икән. Сталинның үзен күрмәгәннәр, күрә дә алмаганнар, аның яшәеше, эшчәнлеге илдә берәүгә дә мәгълүм булмаган. Димәк, татар әдипләре әнә шул гипс, бронза курчакка баш орып, шуннан куркып, шуңа ярашып яшәгәннәр. Нинди кысан, чикләнгән, бозылган язмыш! Алай гынамы сиңа! Сталин киң дөньяны шуның кадәр тарайткан ки, чит илләрдән килеп, СССР тормышы белән берникадәр танышкан, берәр, икешәр ай безнең илнең канлы туфрагына басып йөреп, мәет исе китергән җилләрендә коенып йөргән акыллы гына бәндәләр дә, Сталин нурланышына эләгүгә, үзгәрәләр дә куялар!.. Лион Фейхетвангерга кыюлык җитмәгәнме? Ромен Роллан талантсыз бәндәме? Юк шул, киләләр, кайтып китәләр, ник берәвесе безнең илне сарган саранча-большевиклар хакында дөреслекне сөйләсен! Әгәр әнә шул чит ил каргалары килеп-китеп безнең ил тормышына мәдхия укымасалар, дөньяның акыл ияләре хаклыкны фаш итсәләр, дилбегәдән тәмам ычкынган сталинчылар утызынчы елларда алай ук кылана алмаслар иде!

Ромен Ролланның Сталинга язган мәгълүм хатына гына игътибар итик. Кашыклап кара уылдык умырып, маржалар кочып, Горький һәм Ягодалар (!) белән кочаклашып яшәп иленә кайткач, Роллан сандугач булып Россияне мактаган һәм Европа халыклары Роллан тибындагы кызыл авызлы шарлатаннарга ышанганнар. Әйе, Ромен Роллан «Жан Кристоф», «Кола Брюньон» кебек мәшһүр әсәрләр язган, ләкин аның маңгаендагы һәм түшендәге кып-кызыл канлы йолдызларны күреп торганга, яшь чагымнан ук мин аларга ышанмадым. Яшь чагымда татар матбугатының бер әсәрен дә укымыйча калдырмый идем, һәммәсен тиешле дәрәҗәдә аңлаганмындыр дип расларга җыенмыйм, мәгәр, шикшөбһәләрем дөрес булган! Ролланның Рәсәйдән китү көнендә Сталинга язып тапшырган хушлашу хатын сезнең игътибарга тәкъдим итмичә уза алмыйм. Монда Ролланның эче-тышы ярылып ята.

**«Кадерле иптәш Сталин! Мәскәүдән китәр алдыннан мин Сезгә ялкынлы сәлам озатып калам. Саулыгым бераз какшаган булганга, сездә озак юана алмадым, алай да, шушы кыска арада да мин мең каршылыкны җиңә-җиңә, коммунистлар партиясе житәкчелегендә батырларча һәм нигезле омтылыш ясап яңа дөнья тудыручы бөек халык белән очраштым. Мин аның гайрәтен, тормыш шатлыгын тоюын, дәртен күреп сокландым! Кимлекләрне һәм авырлыкларны әз-әзләп жинә барасыз, һәм бу чынбарлык сезнең бөек гамәлләрнең бәясен бермә-бер арттыра. Килер алдыннан туган фикерләрем тулысынча расланды: дөньяның алга барышы бары тик СССР язмышына аерылгысыз бәйләнгән. СССР — пролетар интернационализмның дөрләп торган учагы, шуларны күздә тотып, барлык илләр аны тышкы тыкшынулардан яклап калырга тиеш! Аның күтәрелешенә комачауламасыннар! Бу уртак бурычтан, үзегез дә моны беләсез, мин бер чакта да тайпылганым юк, тайпылмадым, тәнемдә җаным бар чакта тайпылмам да! Сезнең кулыгызны кысып, мин бөек халыкларның кулын да дусларча кысам! Ул халыкка мин туганнардай береккәнмен.**

**РОМЕН РОЛЛАН.»**

Тарихи бу хат 1937 елның 21 июлендә «Правда» гәжитендә басылган. Бу сүзләргә өстәп тагын ни әйтергә ярый?! Муеннан канга манчылган Сталинга ярарга тырышу гынамы бу, әллә бүтәнчә бер-бер яшерен мәгънәсе дә бармы?

Әйе, Рәсәй киңлекләренә Европа илләреннән зыялылар йөреп торган. Әгәр алар бердәм, бер сүздә булып Сталин террорчыларына нәни генә хөкем сүзе әйтә алсалар, кабатлыйм, большевик-опричниклар шушы кадәр йөгәнсезләнмәсләр иде. Бу минем фикер генә түгел. Егерменче, утызынчы елларда Рәсәйдән йөзләгән, меңләгән зыялылар читкә ычкынып калган. Кемдер качкан, кемнәрдер сәбәбен законлаштырып китә торган, арада кыюлар да табылган: алар чит илләрдәге матбугат чаралары аша дөнья халыкларына мөрәҗәгать итеп, чаң сукканнар: большевиклар Рәсәйне канга батыралар! Ромен Ролландай сатлыкларны тыңлап өйрәнгән халыклар бу соңгыларның сүзенә колак салмаганнар. 1988 елда, Парижда чыга торган «Синтаксис» журналында эмиграциядәге язучы-галим Мария Розанованың тирән мәгънәгә ия мәкаләсе басылып чыкты. Ул болай ди: «Советлар Союзыннан эмиграция инде 70 ел дәвам итә. Өч дулкын булып узды. Тәүгесе, революциядән соңгысы, куәтле эмиграция иде, анда безгә караганда гаҗәеп көчле рухлы шәхесләр, узаманнар бар иде. Бунинны аласыңмы, Бердяев, Ремизов, Лев Шестов, Цветаева, Ходасевич кебекләр, урысның иң күренекле мәдәният әһелләре бар иде ул агымда. Алар безнең илдәге коточкыч хәлләрне сөйләп дөньяны ышандырырга тырышып карадылар, ләкин дөнья аларны бар дип тә белмәде, хаклык салынган әрнүле сүзләренә колак салмады. Дөнья аларга төкерде...

Сугыштан соңгы эмиграция — икенче дулкын, Европага сталинчыл канлы террор хакында, лагерьлар, җәзалаулар турында бүгенге газеталар илгә ни хәбәрләр җиткерсәләр, шуны алып килделәр. Алар меңләгән фактларны фаш итте. Дөнья аларны тыңлады дисезме? Тыңлады, бар! 1947 елда Парижда Кравченко процессы булып үтте, анда Кравченко 37 елгы концлагерьлар хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, француз коммунистлары исә ул сөйләгәннәрне яла ягу дип исбатларга тырышып чәчрәп чыктылар».

Ах, ул чит илләрдәге коммунистлар! Сатлык йолкышлар, караклар, жуликлар! Мин гомерем буе аларны сөймәдем, анда-монда чит илләрдәге коммунистик коерыкларның күтәрелеше булса: «Эх, сталинчыл илдә яшәтеп карыйсы иде аларны!» — дип уйлый идем.

Даплы-шаплы большевистик державадагы хәлләргә килгәндә, минем вәкиллек чорым бетеп килә. Бигеш миңа яңа уйлар өстәмәде, бары тик иманымны яңа дәлилләр белән баетты. Ярулла-Мыек белән ул хакта

авыз ачарга да куркам, рәис — рәис инде ул! Киткән буа алдына көлтәләр ташып, уып, арышын кыздырып ашарга рөхсәт иткән өчен жилкәдән сыйпамаслар! Вәкилләрне төрмәгә тыкканнарын ишеткәнем юк, мәгәр, халыкка чак кына йомшаклык күрсәткәннәре өчен кемнәргәдер нык ук эләккәнен беләм. Район хуҗалары үзләре дә ипекәйгә хуҗа түгел. Казан телефоны аларны пычакның үткер йөзеннән йөртә, таң белән боргычларга тотына. Ә Казанны Мәскәү буа... Мәскәү бар, Мәскәү! Кайбер шагыйрьләр юкка гына Мәскәүгә табына дисеңме?..

## 12

*Диңгездән дә бөегрәк күренеш бар —*
*күк болыр ул; күккә караганда да бөегрәк*
*күренеш бар, ул — кеше җаны тирәнлеге.*

Виктор ГЮГО.

Ярты гомерем Зәйдә узса, яртысын әтиләрдә Урта Багражда үткәрәм. Авылда кызыклы шәхес Гурий бар, өченче иптәш тә бездән калмый. Гурий белән алар яшьтәшләр, икесе дә төп шушы авыл керәшеннәре. Хәзерге акылым белән уйлыйм: ниндирәк мөнәсәбәтләрдә булды икән ике яшьтәш ул заманнарда? Өчәү калган чакларда ни сөйләшкәннәребез әз-мәз хәтердә, ә алар икәү генә калган мәлләрдә нинди фикерләргә килделәр икән? Дошман идеме алар, дус идеме? Әллә алар арасында бик тирәннән, ерак бабалардан килгән дошманлык яшәп килә идеме? Керәшеннәр рыясыз, ачык күңелле, берберсенә ихлас халык. Әмма керәшенне рәнҗетмә, ул чыгымчы юртак ат кебек, аны алай-болай гына эзгә кертә алмассың!

Белмим, бу ике яшьтәш көндәшләр идеме, бүләр маллары бар идеме, соңыннан, байтак айлар үткәч, алар арасында шуып йөргән кара җылан барлыгын абайладым. Соңрак абайладым шул, ни үкенеч! Яшь чагым (акылым белән яшь!), язучы булырга омтылган, тормышның иң биегенә менеп җитәргә хыялланган егет үз-үзе белән мавыгып яши ул, анда «минбеләмлек» чире дә, үзе белән үзе соклану галәмәтләре дә җитәрлек. Кеше сүзе аңа әллә ни керми... Комсомолның район пленумы бара. Чыгыш ясарга кушалар, ыңгырашып кына «комсомолларча ялкынлы речь» сөйлим. Бигештә күргәннәремне дә кыстырам. «Кайчанга кадәр колхозчы крестьяннар ачлыктан газап чигәргә тиеш?» — дип тә ычкындырам. Чын уйларымны ачарга ярамаслыгын сизенсәм дә, солы кибәгедәй буш сүзләрне сибеп торасым килмәгәндер, нидер тагын ычкындырдым шикелле. Бу юлы да чыгышым ошамады, тәнәфестә яныма кырыс кына бер ир кеше килде дә күрешеп тә тормастан: «Син Урта Баграж укытучысы Гыйләҗев улымы?» — дип сорады. Карыйм, искә төшерергә тырышам: кайда күрдем соң бу кылчык бәндәне? Исемә төште... Комсомол билетымны мич арасыннан табып алган бәндә ич бу! «Улы», дип баш кактым. Ул бүтәнен сорашып тормады. Алай да күңелне кырып узды. Алда тагын бер җитди очрашасы барын мин күз алдыма да китермәгән идем...

Сугыштан соңгы еллар! Хәзер мин авылларга сәяхәтнең ни икәнен беләм. Авылга чыгасың икән — алдаша бел, һичкемнән оялып, читенсенеп торма, шыттыр әйдә! Сип ялган сүзләрне! Өметләндер! Георгий Федорович, сугыш күргән кеше, дөньяны миңа караганда күп элегрәк таныган, яраланган, маңгай читендә җәрәхәте зәңгәрләнеп тора. Хәзер без авылларга икәү чыгабыз. Комсомолның сүнгән учакларын җылыткан булып азапланабыз. Комсомоллар калмаган икән, тырыша торгач сукыр күздән дә яшь чыга! Партоешма секретарьлары ярдәмгә килә, ул тотынса яшьләрне дә җибәтә, җинә. Георгий Федорович белән икәүләшеп

рекомендация бирәбез, икәүләшеп «Күчмә бюро» үткәрәбез, шунда ук билетын да тапшырабыз. Георгий Федорович сүз алып сөйли башласа, мин шыпырт кына сәхнәдән чыгып китеп, аны ишетмәмешкә салышам. Менә дигән акыллы кеше, ялагайлана белми, ә сәхнәгә чыгып басса... танымыйсың! Шушы кадәр дөрес коммунист булыр икән!.. Зәйгә кайтып төшәбез, отчет язабыз, безнен ялган отчетлар Казанга оча. Зәй комсомол оешмасы макталып телгә керә. Көтмәгәндә мине Казанга чакыралар. Һәм эшне җайга сала алганымны истә тотып, мина өлкә комитетында эш тәкъдим итәләр... Көләсем килә, көчкә тыелып, тын тартмый утырам, чакырып алган иптәшкә кирле-мырлы җаваплар биреп, гел кирәкмәгән төшкә чабата кайтарып тегенең ачуын чыгарам. Теге иптәш тә җүләр түгел, партия-комсомол аппаратында чарланган туң күчәннәр дә кемнең кем икәнен бер карауда белергә өйрәнгәннәр, өйрәтелгәннәр. Мине озак сынап, үгетләп тормадылар, кайтарып җибәрделәр.

Комсомол эшендәге ялган, тере саескан очыртулар мине тәмам туйдырды. Бер мисал. Зәйдәге прокурор ярдәмчесе, яшь кенә сылу марҗа, большевиклар партиясенә керергә ашкына. Керер өчен комсомолдан рекомендация кирәк. Марҗабыз, чибәр-сылу булса да, бер җирдә дә комсомол учетында тормый!.. (Билеты кайсы мич арасында яки мал абзарында аунап ятты икән?!) Ялынып килде бу! Елена Мачтакованы райкомга эшкә күчергәннәр иде, аның урынына Шепкә авылы кызы, ягымлы, тыныч холыклы, эшсөяр Сара Сәләхетдинова килгән иде. Хәзер ул «үлеләрнең» хисап карточкаларын барлап, эзләп кара бөдрә чәчләрен агарта! Без дуслар, беренче көннән уртак сүз таптык, мин аңа бик теләп булышам. Ялварып килде прокурор ярдәмчесе, Сара миңа караганда үткенрәк, кыю. Күзен дә йоммады, теге марҗадан түләнмәгән өч еллык взносын түләтте. Прокурор ярдәмчесенең эш хакы шә-әп, шактый акча керде. Сара тегенең таушалган тышлы билетына мөһер чәпелдәтте һәм без бюро исеменнән рекомендация биреп тә чыгардык. Марҗа куана, ә без уйда... Утырабыз бер-беребезгә карашып. Сара әйтмәсенме: «Аяз, бу хатын аркасында без болай да гөнаһка баттык, уставны боздык, шуның әҗере итеп әллә бу языкка манчылган акчаларны йомдырабызмы?» Шулай иттек, марҗаның акчасын төп-төгәл икегә бүлдек. Ходам, кичер! Тоташ ялганга ябышып яткан комсомолда үз файдабызга нәни генә җай чыккан икән, гаеп булдымени?!

«Юл — тормыш ул» дигәннәр борынгылар. Мин бу хакта гомерем буе уйланам. Бу асыл тәгъбирне бүтәнчәрәк тә борып була икән! «Тормыш — юл ул!» Чыгасың, барасың, барасың, күзенә ни күренсә шуны төйисең. Яхшысы да бар, яманы да иярә.

Авылларда йөрим, йөзләрчә адәм балалары белән очрашам, алар төрле-төрле булса да, мин бер ич әле!.. Авылда — Гурий. Авылда Хисапчы бар. Күрше авылда мәктәп директоры бар. Йөргән аякка ияргән йөремнәремне очрашкач аларга тапшырам. Күргән-белгәннәренне, күргән-белгәннәр тудырган гыйбрәтләрне кем беләндер уртаклашып, үзеңне зирәк акыллы итеп күрсәтәсе килә! Яшьлекнең хатасымы бу, юл эзләгәндә ярдәм өмет итүеме, моны аяк терәп раслау кыен. Аларга сөйләүдән миңа ни файда? Алдагы сәхифәләрдә мин ялгызак Үткен Романы турында әрнеп язып үттем. Әрнүемне сиздегезме икән?.. Сабый чагым тәмамланып, үсмерчаккa менеп барган елларым шул булган. Мин үзем сайлаган тормыш йөгенә Үткен Романның, аның гаиләсенең ачы язмышын салып, алга киткәнмен. Кан чиренә шаһит булган көннәрдә мин әзерлекле булганмын инде, авыл, төбәк күләмендә фикер йөртә башлаганмын... Комсомолга мин Идел сәяхәтеннән соң, тирә-яктагы байтак авылларда «утырмаларда» йөреп чыкканнан соң килеп кергәнмен. Дөнья киң, дөнья тар да, вакыйгаларның, кеше язмышларының бертөрлелеге белән тар. Хуш, мин шушы мәгълүм вакыйгалар аша бар мәктәп сыйныфларын үткәнмен. Ләкин аннан кемгә ни файда? Мин белде, аңлады, җаны сызлады дип Үткен Романның хәле яхшырдымы? Телсез Җәмәйнең

тамагы туйдымы?.. Паулый карчык командасының язмышы әз булса да үзгәрдеме? Бигеш ачларының күңеле көрәйдеме?.. Әгәр яшь чагында каядыр яктыга омтылып теләкләрең кабул булмый икән, тукта, уйла, кабаланма: адашуың бик мөмкин! Боларын мин уйламаганмын. Хисапчының инде әллә кайчан чекистлар белән бәйләнеш тотканын да, аның гади агент кына түгел, биш авылга куелган резидент «Лесков» булуын да башыма китермәгәнмен. Мәктәп директорының да мине гел җөпләп: «Әйе, әйе, илдәге гаделсезлеккә каршы көрәшкә чыгарга кирәк!» — дигән кискен хөкеменә кушылып, баш кагып утыруларының сәбәбе... Әллә ул да МГБга хезмәт итә идеме?.. Ялгышсам, кичер мине, директор, мин сиңа кинә сакламыйм! Үпкәләмим, рәнҗемим... Бәлки, синең шул авыр чакта минем янда, фикердәш вә көрәштәш булуың ярагандыр да әле!... Мунча чабынган мәлләрдә, икәүдән-икәү генә табын янында һич шикләнмичә, арага җил кертмичә большевизмның явызлыгы турында син сөйләгән дәлилләр, син китергән тере мисаллар барыр юлымда маяк та булганнардыр әле. Мин дә кемгәдер таянып, кемнәрнеңдер ачы тәҗрибәсеннән чыгып, унтугыз-егерме яшьләремдә актан караны аера башлаганмын бит!.. Хәзер шикләнсәм дә, рәхмәтлемен мин сиңа, Директор!..

Хисапчы да исән-сау. Казан каласында яшәп ята. Татар әдәбиятын укыйсыңдыр дип уйлыйм, мәгәр бу язмаларның шаукымы сиңа да барып җитәр. Ишеттерерләр. Сиңа да рәнҗешем юк, гәрчә Тавлин белән мине «җитәкләп, кайгыртып» Черек күлгә китереп җиткергән кеше син булсаң да... гаеп синдәмени?..

Кырык җиденең көзенә кердек. Кыш җитте. Мәдәният бүлеге хезмәткәре Гәрәй Гәрәев белән бергә яшәп ятабыз, агитбригада оештырып, спектакльләр куеп, байтак авылларда йөрдек. Гәрәй атаклы гармунчы, «Кыңгыраулы яшел гармун»ны уйнап-җырлап бирсә, залда җыламаган кеше калмый. Сәяси әңгәмәләрдә Гәрәй бик күп яктан миңа теләктәш, гәрчә аны: «Советка каршы көрәшкә чыгыйк!» — дип өндәгәнем булмады шикелле. Нидер тыйды, тыйлыктырды...

Урамнарда букча асып йөрүче үсмерләр, чәчләренә күбәләк-бантик таккан кызлар ишелеп йөри башлагач күңелем үзгәрде. Мин үзем ташлап киткән иптәшләрнең кайберләрен сагына башладым. Гомерем буе комсомол коткысына ияреп ялган чәчеп йөри алмаслыгымны, кемгәдер тәлинкә тотып йөрүләремнең берәнбер көнне каз куыгы сыман шартлаячагын белә идем. Күңелемә: «Әллә яңадан университетта укый башларгамы?» — дигән кайнар уй иңде. Әти-әни белән киңәштем.

Алар, яхшы күңелле изге кешеләр, миңа каршы төшәргә базмадылар. Уллары алар күнеккән үлчәүгә сыймаса да, әтиләр нидер көтә, нәрсәгәдер өметләнә иде бугай. Икесе беравыздан: «Үзеңә кара инде», — диделәр. Бәлки алар миннән бүтән сүз көткәннәрдер? Партиягә кереп урнашып, җылы урын эләктереп, алдарга вә таларга гадәтләнеп, яхшы аргамак җигелгән канатлы тарантасларда киерелеп утырып, аска капчыгы белән крупчатка яки симез сарык салып кайтуларымны көткәннәрдер — сиздермәделәр, ак-кара димәделәр, бер-берсенә караштылар да тындылар. Рәхимле әти-әнинең хөкем сүзенә караганда җылы карашы үтемлерәк икәнне алар каян белгәннәрдер!

Мин уку, Казан хакында Гурий белән дә, Хисапчы белән дә сөйләшкәнмендер инде, нинди сүзләр сайлаганмындыр, үгетләдем дә микәнни, икесе дә алдагы елда, ягъни 1948 дә Казанга бару турында хыяллана башладылар. Бер нәрсә: икесенең дә урта белеме юк. Белеме юк икән — документлары да юк дигән сүз! Бу җәһәттән мин аларга булышырга булдым. Комсомолда әз-мәз чарланган, танышлар булдырган, оятсызланган... Шулайдыр дип беләм! Хәтеремдә юк, кем миңа булышкандыр, җиденченеме, сигезенченеме тәмамлаган Гурий Тавлинга урта мәктәп аттестатын юнәттем, большевиклар партиясенә шома гына үтсен өчен комсомол стажы да оештырдым. Ә Хисапчы исә «урта мәктәпне гел

отличнога гына тәмамлады» дигән ялган аттестатны үзе әтмәлләде. Фронтовик, отличник, коммунист! Сызгырып кына үтеп китәчәк егетең!

Университетта бергә укыган иптәшләрне күздән кичереп чыктым һәм Ибраһим Нуруллинга барып җиткәч тукталдым. Ул да фронтовик, бер аягын сугыш кырында алып калганнар. Өчме, дүртме хикәясе «Совет әдәбияты» журналында басылган яшь язучы. Исеме телгә керә башлаган дәвер. Үзсүзлерәк булса да, гадел, кыскасы, һәр тарафтан абруйлы ышанычлы иптәш. Көчле ихтыярлы, бәхәскә ыргылып торган моназарачы, кыскасы, миндә булмаган, бик нык урнашкан яшәү сыйфатлары бар иде Ибраһимда. Татар бүлеге ачылган мәлләрдә студентлар арасында иң төпле кеше, мөгаен, Ибраһим Нуруллин булгандыр. 1947 елның декабрь башларында мин аңа хат язып салганмын... «Шулай, шулай, көймәм комга terәлгән чак, җилкәннәрне жил сындырган... Нишләргә?» Хатны алгач ук, 18 ендә Ибраһим җавап язып салган. Өлкән иптәшнең теләктәшлеген белдергән, корырак булса да шактый җылы хаты менә, күз алдымда. Турысын әйтим, Ибраһимның миңа тәкъдим иткән коммунистларча туп-туры юлы... йомшак итеп әйткәндә, миндә актив ризасызлык тудырган иде. Мин монда, ачык ярама учы-учы белән тоз салып, коммунистик режимның колхоз авылларын тәмам кара нужага калдыруын күреп-әрнеп яшәп ятканда, совет хакимияте белән көрәшергә юллар эзләргә вакыт дигән (әйдә, балаларчарак фикер йөртүем булсын!) уйга барып җитә алганда, ул миңа менә нинди киңәшләрен юллады. Хуш. «Сиңа яхшылык итәсем килә, ярдәм итәсем килә,— дигән ул.— Как тебе быть? Минемчә, сиңа коллективка керергә кирәк. Бөтен йөрәге, җанытәне белән коллектив интересларын үз шәхси интересларыннан өстен куя ала торган кеше генә иң бәхетле кеше... Идеал утын шушы халыкларның бәхете — коммунизм булырга тиеш. Минемчә, сиңа укырга кирәк. Гомумән, укырга һәм мәктәпкә кереп укырга. Марксизм-ленинизм тәгълиматын йөрәгең белән аңламый торып, югарыда мин санаган сыйфатлар сиңа килмәс»...

Бу — 1947 елгы Ибраһим Нуруллин.

1991 елның 5 январенда Ибраһим Нуруллин ни яза?

«Юк инде, Октябрьнең теге ягына түгел, бәлки Ленин чорына чигенеп һәм шуннан этелеп китеп, чын социализм төзергә керешү — намуслы хезмәт кешеләре өчен иң дөрес юл».

Үзгәргәнме Ибраһим Нуруллин? Юк, тамчы да үзгәрмәгән. Үз сүзеннән баш тартмавы белән дә, иманын бүтәннәр сыман ашыгыпашыгып алыштырмавы җәһәтеннән дә Ибраһим ага зур хөрмәткә лаек. Ләкин синең иманың XX гасырда дөньяны бутаган, илләрнең үсеш тамырына балта чабып, дәүләтләрне бер-берсенә каршы куйган, милләтләрне үзара сугыштырган Ленин тәгълиматына ябышып яту... Моны ничек дип әйтергә?.. Берара читкә тибәрелгән коммунист-түрәләр өере хәзерендә җанланып маташкандай була. Унсигез миллион коммунистның бер тамчы тир түкмичә илне имеп яткан югары катлавы да әз санлы түгел ләбаса!.. Шуларның бүгенге башлыгы Сажи Умалатова халык каршысына чыгып, ачыктан-ачык: «Без утыз җиденче елны янадан кайтарачакбыз! Алай гына да булмас әле! Без бераүнең дә кыланышларын онытырга җыенмыйбыз!» — дип белдерү ясады. Дөрес, бүгенге җанлану ул фиркаләләрнең тәмам «протестка чыккан» соңгы тыпрылдавы. Акыллы, фикер иясе Ибраһим Нуруллинның илне янадан канга батырырга җиңен сызганып торган иблисләр тегермененә су коюы... аңлашыла да, аңлашылмый да! «Чын социализм» төзергә тотынган — Югославия, Эфиопия, Ангола, Куба, Мозамбик кебек илләрдә Ленин салып калдырган миналар әле бик ерак елларга кадәр шартлап-шартлап, адәм улларына бихисап бәхетсезлек китерәчәк.

Ә Ибраһим Нуруллинга килгәндә, Әмирхан Еникине «яраткан язучым» дип атап та, аның тирән фикерле әсәрләрен тиешенчә яклап, дәлилләп һәм тар маңгайлы большевикларга аңлатып бирә алмавы да

аның дөнья фәлсәфәсен бары тик ленинизмга — җимергеч көчкә ия тәгълиматка гына кайтарып калдыруыннан килә. Соңгы елларда ул Гаяз Исхакый иҗатын татар дөньясына житкерүдә бик күп көч куйды. Мактау һәм дан аңа! Мәгәр, ышанып әйтә алам: Маркс-Ленинга таянган тар иман белән генә Гаяз Исхакыйның иҗат тирәнлеген, рухи бөеклеген беркем дә ачып бетерә алмый. Гаяз Исхакый иҗатының тирәнге катламнары яңа заман кешеләрен, яңа татарларның милли фикерләвен, олпат ирләрнең җитди йомгакларын көтә.

Яшерен өмет бер кешедә калды... Хатларны сирәк-сирәк алышсак та мин аның барлыгын, исәнлеген тоеп яшим. Беләм, бер телем икмәк өчен көчен, вакытын сарыф итәргә мәҗбүр булган Мәүлә хат язарга яратмый. Күрешмәгәнгә шактый булса да... (Ул мине Әстерхан сәфәренә озатып калган, минем кая юл тотканымны белүче бердәнбер җан иде!) Мин гел аны сагынып яшим...

1944 елның маенда Кырым татарларын төрле тарафларга чәчеп ташлаганнан соң, Казан татарларын да Урал аръягына куу коммунистларның көн тәртибенә куела. Өлгергән мәсьәлә! Казан татарларын Ленин үлеп яратмаган кебек, Сталинның да иң күрәлмәс дошманнары без — татарлар булганбыз. Ул бер селтәнүдә билне сындырырга, башны кыеп ташларга омтыла. Сталин омтылышларының үтәлми калганы юк! Татарларны юк итеп ул урыс шовинистларына, урысның кара милләтчеләренә ярарга тырыша. Урысның кара көчләре алдында бөек юлбашчының да калтыраган мизгелләре булгандыр! Аның урыска тәлинкә тотуы шул дәрәҗәгә барып җитә ки, сугыш беткәч бөтен җиңүләрне ул урыска тапшыра. Аның урыс халкын күккә күтәреп әйткән тостын кара милләтче, ата шовинист Валентин Пикуль 1989 елда да күкрәк кагып телгә алды. Пикуль ишеләргә үз кара эшләрен тормышка ашырганда палач та абруйлы, карак та фәрештә.

Ләкин, ни сәбәптәндер, Сталинның кырык дүрттәге планнары әкренәкрен үзгәрә. Маршаллар, атаклы генераллар беравыздан татар солдатларының батырлыгы турында бөек-бөек сүзләр әйтәләр. Тылдагы татарлар хакында да гел мактау сүзләре генә яңгырый. Карышусыз, рыясыз, әзгә дә риза була белгән бөек татар халкы эш җәһәтенә килгәндә илдә беренче була! Кыскасы, татарларны Урал аръягына күчереп бетерәбез дигәндә, кемнәрдер бу авантюрага каршы төшәләр. Һәм бу акыллы каршылыкны, татар язмышын билгеләгән үзгәрешне бәрәкәтле гамәлләр белән дә беркетәләр. Университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла, консерватория, театр училищесы гөрләтеп эшли башлый, нефтьчеләр мәркәзендә театр дөнья күтә. Җыеп әйткәндә, татар мәдәни тормышында берникадәр җанланыш — «ренессанс чоры» шәйләнә. Кем кодрәте белән эшләнә бу борылыш, нинди әмәлләр, дәлилләр табып фикерләре бер дә какшамас таш маңгайлы коммунистларның җимергеч галәмәтләренә аркылы төшә — бу хакта әле без берни дә белмибез диярлек. Борылышны башлаган кодрәт ияләрен юкса без белергә тиеш!

Университет кадәр университетта татар бүлеге! Училищеда татар студентлары! Бу ике уку йорты оешкан көннәреннән алып үзара тату, фикер-уй алмашып яшәделәр. Бердәнбер татар гаиләсе идек без! Университет студентлары булачак артистларга лекцияләр укыйбыз, алар Тукай клубына әдәби җомгаларга, университетның әдәбият түгәрәге утырышларына ябырылып йөриләр. Ул чактагы абруйлы әдәбият түгәрәгендә студентлар, укытучылар гына түгел, күренекле әдипләр дә күренгәләп китә. Татар халкына, әдәбиятына, теленә үлеп гашыйк булган Латыйф ага Җәләйнең утырышларыбызга даими йөрүләре, киңәшләре эзсез үтмәгәндер дип исәплим. Гомәр Бәшировның «Намус» романы тирәсендәге бәхәсләр бер көнгә сыймагач, икенче көнне дә кызып дәвам итте.

Мин Мәүлә белән ничек танышып киткәнемне хәтерләмим, нинди нигездә бер-беребезгә җәһәт тартыла башлаганбыздыр, анысы да истә калмаган. Күп еллар үтте ич ул тарихи көннәргә! Ләкин шунысын анык

беләм, Мәүлә Солтан баштан ук студентлар арасында узаман иде. Шагыйрь иде Мәүлә, шагыйрь күңелле иде, үзенә бик килешле Мәүлә Солтан псевдонимы сайлап алган Хәсәнов иде ул! Куе, тыгыз кара бөдрә чәч. Каралҗым яңаклар. Бер-берсеннән оялып читкәрәк тартылган үткер, коңгырт күзләр. Уртадан әзрәк калкурак буй, нык, хезмәт күргән куллар. Йодырыклары авыр, тамагы тук мәлләрдә, үзара шаярганда бокс күнегүләре ясап, кайбер студентларны тәгәрәтә торган гадәте дә бар. Университет бакчасында тәгәрәп китеп, корыган агач төбенә барып сылангач, касыгым авыртып йөргәнемне әле дә онытмадым. Нык тамызгандыр Мәүлә! Ул карап торышка да, рухы белән дә тәмамланган Көнчыгыш кешесе, Шәрекъ шагыйре иде. Иң мөһиме — Мәүлә Солтан баш-аягы, укымышы, әзерлеге, мәсләге белән большевизмның аңлы дошманы иде. Ни хакында сүз башласак та, безнең уй-фикерләр уртак, ачылып бетмәгән, әмма яралган максатлар да бер, рухи әзерлегебез дә тәңгәл килә иде. Хәзерге биеклектән торып ни сөйләшкәннәребезне аерып-аерып хәтерләмим, иң кирәге, без татар милләтенең кысада, чикләнгән аралыкта яшәвен төрле мисалларда бер-беребезгә аңлата идек. Бүгенге белүебез дәрәҗәсенә карап уйлыйм, без ул чакта да уй-гамәлләребез белән шактый югары күтәрелә алганбыз икән! Әдәбиятның ялган төчелеге, тормыш каршылыкларының берсен дә чишә алмавы, өлкән әдипләрнең җирне, халык язмышын өстән-өстән генә ермачлавы безне әрнетә, газаплый, кыйный иде.

Авыр тормыш алып бара иде училище студентлары! Гомуми торак юк, кайсысы кая иң арзан, иң фәкыйрь фатирларга чәчелгәннәр, соңыннан шактый мәшһүр язучы булып киткән Шамил Бикчурин Мәүләләр белән бер курста укый һәм фатирда Жуковский урамында тора иде. Фатир хуҗасы, унҗиде яшьлек үсмер улы булса да, күрер-күзгә яшь, таза, көлтә җыландай елгыр хатын иде. Әле Германиядән маллар кайтып бетмәгән, шул хатын вагон-вагон малларны кабул итү, урнаштыру бүлегендә эшли иде. Студентлар — шул җөмләдән Мәүлә белән Шамил дә вагоннардан трофей малларны бушатырга йөриләр, бүтәннәр күрмәгәнне күрә беләләр, коммунист җитәкчеләр ул елларда череп баеп калды, алар белеп алган мисалларны бер эзгә салып тыңлагач, без фәкыйрьләрнең чәчләре үрә тора иде. Мал — мал инде, ат аунаган җиргә төк калмыйча булмый, студентлар кыҗыр-быҗыр ясап тамак үткәрәләр, әмма торыр урын булмавы күпләрне изә иде. Ашарга житсә, фатирга түләргә җитми, фатирга түләргә калмый... Аңлаган кешегә трофей маллар да әллә никадәр хакыйкатьне сөйли ала!.. Сугыштан соң шундыйрак бер гыйбрәт йөри иде: сугышта Сталин ике хата ясады — берсе, ул Рәсәй солдатларына чит илне күрсәтте, икенче зур хатасы — юлбашчыбыз чит ил кешеләренә Рәсәй солдатларын күрсәтте... Күрделәр, истә калдырдылар... Хәзерге фактлар заманы Сталинның хаталары икәү генә түгеллеген ачып бирде. Әмма безгә, авызларыннан авыл бәрәңгесе күренеп торган кызу канлы үсмерләргә, шушы ике хата да җитеп ашкан иде.

Мәүлә дә җанына җылы урын табалмаган, уңга-сулга бәргәләнгән, тормыштан шактый туеп, өметсезлек дулкыннарында чайкалучы сизгер җан иде. Казанның Карл Маркс урамында аның бертуган абыйсы яши. Абыйларына әнисе сыенган. Бай тормышлы абыйсы әнисен бергә яшәтүне яхшылыкның чиге дип белә идеме, ул Мәүләгә килеп йөрергә, әнисе белән күрешергә дә рөхсәт итми иде. Югары урында «важный» кеше иде Мәүләнең абыйсы! Черек күл тирәсендә хезмәт итмәдеме икән?

Төрле-төрле рәвешкә кереп яшәгән адәмнәр арасында Мәүлә минем иң якын кешем, киңәшчем, рухи ярдәмчем дә иде. Театр училищесының беренче дәрәҗәдәге йолдызлары — Разия Халитова, Айрат Арслановлар янәшәсендә Мәүлә Солтан бик югарыдагылардан саналып та йөрмәгәнләр, мәгәр талантлы кеше иде!.. Мин Казанны ташлап чыкканда әле ул гомуми агымга ияреп, сыкрый-сыкрый, сызлана-сызлана агып бара иде...

Юллар чатына барып җиткән мәлдә, үткәннәрдән һәм киләчәктән үземә туры сукмак эзләгәндә мин дустым хакында еш-еш уйлый башладым. Чуалган йомгагымның очы аның кулындадыр кебек тоелды, без икәүләп эзли башласак, туры юлны табарбыз, җаныбызны талкыган сорауларга дөрес җавап та еракта йөрмәс дип уйладым.

Көннәрнең берсендә, кызып-кызып, чалбар төбе туздырып бюро әзерләп маташканда, нигәдер җанымны әркетеп телефон шалтырады, мине МГБга чакырдылар. Ләкин бик тиз тынычландым. Бер дә исем китмәде, каушамадым, борчылмадым, җүләр чагым, үзем белән артыгын мавыгып, тирә-юньгә тукталып карап торырга вакыт табалмаган мәлем... Бу ярым яшерен оешманың гайрәтен дә, миңа таба сузылган астыртын капшавычларын да белми идем әле. Киттем, эзләп таптым, үз ихтыярым белән барып кердем. Юан аяклы, сукно белән тарттырып тышланган киң өстәл артында әлеге дә баягы танышым утыра. Сәлам бирдем. Сәламемне алмады, утырырга кушып, күз очы белән урындык күрсәтте. Бераз карашып утырдык, күңел әзрәк шигәя башлады. Бераздан ул сул ягындагы, клеенка белән тышланган тар ишекне ачты һәм кулын изәп кемнедер чакырды. Карасам... егылып китә яздым, тынсызөнсез калдым. Каршымда Мәүлә Солтан бөкшәеп басып тора. Юк, юк, Мәүлә түгел лә, бу — мин үзем, Каспий буйларыннан, Идел тамакларыннан кайтып киләм... Нәкъ үзем! Аерма шунда гына, мин җиргә кар яткач, кыш башында яланаяк кайтып кергән идем. Хәзер җәй азагы... Мәүлә яланаяк, изүе ачык. Тәнендә күлмәк тә, майка да юк. Талкынып, чачакланып беткән чалбар балаклары, хәерче, алама бишмәте итәгенә ябышкандай асылынып торалар. Бишмәтенең бер төймәсе дә юк, Мәүлә аны череп каралган чабата киндерәсе белән тарттырып, буып куйган. Иягенә, тишекләре тирәнәеп каралган танавы астына бөдрә төк кунган. Кояшта янган, яну гынамы сиңа, кибеп-корышып-какланып беткән! Җитү тырнаклары астына корыммы, күмер тузанымы кереп шыпланган. Егет сак кына елмаеп, ымсынып, нидер көтеп, миңа текәлеп карап тора. Маңгае уйлар басымына чыдый алмыйча бер киңәя, бер тарая. Теге бәндә керфек какмыйча безне күзәтә. «Таныйсыңмы бу бәндәне?» МГБ авызыннан шушы сүз чыккач, Мәүлә миңа таба иелә төшкәндәй булды, куллары хәрәкәтләнеп, миңа нидер әйтергә теләделәр.

«Таныйм, таныйм!» — дидем мин, әйтеп калырга ашыгып. «Кем бу?» Чыннан да кем? Ни диергә? Мәүлә үзен кем дип танытты икән?.. «Мәүлә Солтан бу. Шагыйрь. Минем дустым. Театр мәктәбе студенты!» Тагын ни диергә? Дустымның язмышын җиңеләйтер өчен нинди дәлилләр табарга?.. Теге бәндә мыскыллы гына елмайды: «Сәер икән синең дусларың! — диде. — Ә артист дип ялганлыйсың.. Йә, берәр нәрсә уйнап күрсәт. Кәмит күрсәтәсеңме? Җырлап бирәсеңме?» Бирелгән сорау кайчагында хөкем карары, дәһшәтле гаепләү булып яңгырый. Теге бәндә сорагандай итсә дә, аның горгылдык тамак төбеннән: «Җырлый алмыйсың икән, моннан чыгып котылмагың юк!» — дигәндәй янаулы яңгырады. Мин Мәүләгә карап каттым, бичара, минем сымак ук, җырлый белми иде.

Кинәт аның бөтен йөзен, күз-кашларын, маңгаен, җәядәй киерелгән яңакларын ачып-яктыртып ниндидер нур сызылып үтте, ул чебиләп, яргаланып беткән яланаякларының очына басты, сәләмә бишмәт күкрәгенең киңлеген яшерә алмады, кара тырнаклы йодрыклар үлчәү герләре кебек авырайды, күзеннән ике эре бөртек яшь атылып чыкты. «Воин Красной Армии! Спаси!» — дип пышылдады Мәүләнең корычтан коелган иреннәре. Сугыш заманында шундый чакыру-плакат бар иде. Мәүлә шундый бөек этюд уйнап күрсәтте ки, талантлы татар баласы иде, каһәр! МГБ кешесе телсез калды, җиңелгәнен сизеп, кулын селкеде. Мин Мәүләне ияртеп, квартирама алып кайттым...

Юлда кыска-кыска гына сөйләшеп алдык. Аның Томскидамы, Омскидамы туганнан-туган абыйсы бар икән, тәмам ябагасы коелып, кө-

есында су беткәч, Мәүлә бәхет өмет итеп, абзасы янына чыгып китқән. Барса, абзасы юк, алар яшәгән барак җимерелеп җиргә сеңгән, адресын бирәү дә белми, кая киткәннәр, кайда йөриләр. Мәүлә каңгырып, сукбайланып атнага якын яшәгән дә... кием-салымын сатып ашаган, аруракларын иске-москыга алмаштырган... Мәүлә урлаша да, анда-монда эшләп акча юнәтә дә белми иде, ул бөтен барлыгы белән бөек актер, талантлы шагыйрь, дөньяның тар кысаларына сыеша алмаган Югары рух та, сукбай да иде.

Бишмәтен өйалдында кәҗә янында калдырып, үзен өйгә алып кердем. Дүрт тәрәзәнең икесе такта-чыпта белән томаланган кыеш өйнең фәкыйрь, төссез түрен күргәч, Мәүлә көлеп җибәрде: «Монда яшәп була!» Бәхеткә хуҗам Ксения Федоровна каядыр киткән булып чыкты. Ниләр сөйләштек икән? Бер-беребезне ихлас күңелдән сагынышып, нинди хәбәрләр алмаштык икән? Болары истә калмаган. Югары сүзләр, бөек фикерләр, шаулы омтылышлар шунда, Ксения Федоровнаның әҗәлгә йөз тоткан өе диварына сеңеп калды. Без гел хыялый дөньяга омтылган канатсыз кошлар идек шул! Истә: «Дөньяга сыймыйм мин!» — диде Мәүлә. «Дөнья да миңа сыймый!» — дип аркасын кашыды. Истә, бәрәңге пешердем. Истә, бәрәңге пешкән суны түгәргә җыенганда Мәүлә карчыгадай ташланып, кәстрүлне тартып алды, чәчрәтеп кулымны пешерде, алды да күтәреп голт-голт эчә дә башлады. Ач тамак салкын ризыкка да чыдый, кайнарда да пешми икән! «Менә дигән бульон ич бу, тиле!» — диде калынча иреннәрен сөенә-сөенә учы белән сөртеп. Тагын ни истим?

Үзем дә ярлының ярлысы, алай да егетнең өс-башын әз-мәз төзәттем: чалбар бирдем, кирза итекләр, ару гына кыек якалы күлмәк һәм буй-буй көрән пиджагымны кигерттем. Көзгегә карагач, Мәүлә озак кына телсез калды. Өч-дүрт көн хәл кадәренчә кунак иткәч, мин аны Имән авылындагы балалар йортына пионервожатый итеп җибәрдем, кулына документ — бюро карарын тоттырдым. «Түз! — дип ялвардым бер урында утырып тора алмаган җитез дустымның гадәтен белгәнгә.— Бүтән барыр җиреӊ калмаган! Кышны шунда чыгарсың. Зәйгә килгәләп йөрерсең, үзем дә баргалармын! Тамагың детдом казаныннан үтәр, акчаңны җыеп бар».

Атна-атна ярым үттеме, егетем әйләнеп кайтты. Иртән үк кайткан, мин эштә идем, өйгә кермәгән, шунда, Ксения Федоровнаның балчык нигезенә утырып, мин кайтканны көткән. Мин аңа әрнү белән карадым, ул: «Юк, булмый,— диде,— бармыйм. Урман арасы, чолан бирделәр, тамакка да түзәргә була. Бәрәңгене туйганчы аша, үзләре утырткан. Миңа иркенлек кирәк!.. Сизәм, син үзең дә моннан кыйракларга җыенасың, шулаймы? Тел төбеңнән бер көн шул аңлашылды. Миңа иркенлек кирәк... Ирек кирәк!»

Юллык акча биреп, мин аны озатып калдым. Озаттым да Островскийның бөек актерлары Счастливцев белән Несчастливцевларны уйладым. Әйе, Мәүләнең сыйныфташлары матур, мул, бай яшәделәр, югары дәрәҗәләргә ирештеләр. Тик Мәүлә ул чорга, ул замандагы изүләргә буйсынмады. Соңыннан ишеттем: Горький шәһәре төрмәсендә татарның чәчәк ата алмый калган бөек улы Мәүлә Солтан асылынып үлгән...

Хәзер уйлыйм: бер гаиләдә күпме фаҗига! Курка-курка бер улына сыенып, икенче улын читкә тибәргән ана... Үз туганын ярлы булганы өчен, горурлыгы, буйсынмас җаны өчен бусагасына якын җибәрмәгән абый... Томскидан Омскига, Омскидан Томскига күчеп йөргән илгәзәкбиләмче, бәхетен дә, урынын да табалмаган бәхетсез татар кешесе. Һәм шул бәхетсезлекләрне үз күкрәгенә җыеп шул кайгы хәсрәтләр аша ил фаҗигасен күрә алган шигъри җанлы яшь егет Мәүлә... Ул байтак вакытларга кадәр минем һаман киңәя барган офыгымда янган якты йолдыз иде. Бөтен кеше дә Сталин таккан муенчакка риза булып, ленинизм таккан тышауга сүзсез буйсынып, аксак саескан шикелле цитаталар

такылдап кына яшәмәгән икән! Бөек Достоевскийның гаҗәеп акыллы меңнәрчә фикере арасыннан берсен сайлап алдым. «Общество,— ди ул,— бесстрастно взирающее на любое тиранство,— общество больное, разлагающиеся». Хәбир Зәйнуллиннар, яшь Гәрәй Гәрәевләр, һавалы шагыйрь Гурий Тавлиннар сытылып беткән муенсыз адәмнәрдән торган җәмгыятьтә якты йолдызлар булмаганмыни? Мәүлә Солтан Кояш иде, ләкин ул үзен каплаган болытларны каерып-каерып тарата алмады.

Соңгы очрашуларыбызның берсендә мин якын дустым һәм яшьтәшем, искиткеч ярдәмчел, якты күңелле, рухи юмарт Шамил Бикчуринга: «Яшәдек, катлаулы чорны кичтек, тел теләмәгәнне, җан яратмаганны язган очраклар да булды. Ялган таш аллаларга ышанып, шуларның җирдәге чуен маңгайлы сатрапларына ярашып китаплар чыгардык. Соңарып булса да аңга килик! Нигә син театр училищесының оешкан еллары хакында ләм-мим язмыйсың! Мәүлә Солтан кебек бөек шәхес турында кемдер язып калдырырга тиеш ләбаса. Яз! Тотын!» — дип каткат әйттем. Малеевка иҗат йортында, ямьле урман арасында, уйга-хатирәләргә өнди торган сукмаклар чәбәләнешендә яши-очраша идек. Шамил дустым озак кына дәшмичә торды да башын чайкады: «Юк инде...» Айрат Арслановтан — мәшһүр яшьтәшемнән Мәүлә хакында сорашканым булды, алар артык якын булмасалар да Айрат сизгер җан, үз янында кем булып узганын чамалыйдыр дип өметләндем. Айрат та өзеп кенә бер сүз дә әйтмәде.

Мин асылынмадым, үлем турында уй башыма кереп тә карамады. Ул елларда мин байтак хикәяләр яздым, аларның кайберләре әле дә исән, шигырьләр сызгаладым, алары да бар. Язганнарымны гәзит-журналларга тәкъдим итмәдем. Мин ачылып та җитмәдем, йомылырга да уйламадым. Кырык сигезнең көзендә мин яңадан университетка керергә тәвәккәлләдем. Райкомның идеология секретаре, юантык, йонлач маңгайлы Гыймазетдинов-капкорсак эштән китү хакында ишетергә дә теләмәде. Мин бик «кадерле кадр» булганга түгел, ул җәһәттән эт ашаган Гыймазетдинов кирелегемне дә, баш бирмәслегемне дә чамалагандыр, ул чорда комсомолга эшкә килергә атлыгып торучылар бик булмагандыр шул! Бигрәк тә кадерсез, пүчтәк эш иде комсомол! Райком бозган Гыймазетдинов аяк тибеп бакырды: «Мин сиңа шундый характеристика тоттырырмын... сине укырга түгел, бук чукырга да алмаслар!» Сөендем, мин Гыймазетдиновны татарча белми дип йөри идем, ул чак большевиклары бөек туганыбыз телендә генә сөйләшәләр иде бит! Һәм мин: «Төкерәм мин синең характеристикаңа!» — дип урысчалатып әйттем дә ишекне шап ябып чыгып киттем. Бөек урыс теленнән дә кулайрак тел юк үткәзеп сүгенергә теләгәндә!

Бакчы, кыюланган чакларым да булган икән!

## 12

*И маленьким людям большие сны снятся...*

Федор ДОСТОЕВСКИЙ

Тәҗрибә бар, университет ишекләренең кайсы кая ачылганын яхшы беләм, мин шома гына бусагаларны, су асты риф-ташларын үтеп киттем. Минем белән кырык биштә бергә укып йөргәннәр инде дүртенче курста. Озыннар озайган, тәбәнәкләр киңлеккә юнәлгәннәр, кызлар заманчалап чәч бөдрәләткәннәр, авызларыннан бәрәңге күренми, шәһәр туташлары булганнар. Минем ише чабата белән ән-ә-ә каян торып кына сөйләшәләр. Тормыш үзгәргән, курслар саны арткач, татар студентлары күбәйгән. «Әдәби газета» чаршау хәтле булып

даими чыга, студентларның талантлылары шунда җорланалар. Арада сәер кешеләр дә бар, инде байтак китаплар чыгарып халыкка эндәшә алган, гаиләле, бала-чагалы, олыгаеп баручы Әхмәт Юныс та беренче курс студенты, сабакташ. Бу юлы мин гомуми торакка урнашмадым, үткәндә яшәп ятканнарым да истә, салкын тиеп чыккан чуаннарның тирән-тирән эзләре тәннән китми... Островский урамындагы бер марҗага фатирга кердем. Хисапчы да миннән калмады, отличник-фронтовик дигән документ белән университетның тарих бүлегенә укырга керде. Гурий пединститутка урнашты. Очрашабыз, күрешкәләп торабыз. Укыйм, язам, онытылганда бер театр училищесына барып чыгам. Аксубайдан килгән Зәйнәп Алимбекова дигән кыз белән әз-мәз гыйшык уены уйнагандай итәбез. Островский урамында без озак тормадык бугай, курсташым Нил Юзиев, сөйкемле һәм юньле егет, мине үз янына Бехтерев урамындагы Гильмия апа Таһирова квартирасына бүлмәдәш итеп чакырды. Хисапчы да миннән калмады. Квартир хуҗабыз үзе дә шагыйрь. Гильмия апа акчага мохтаҗ булгандыр инде, тол хатын, беркайда да эшләми, ни хисабына яшәгәндер ул ярлы тәккәбер, шул бездән тамган әз-мәз акча хисабына җан саклады микән?.. Без тар гына ләхет-бүлмәгә өчәү сыйдык. Гильмия апа безнең аша үтеп йөри. Көйләндек: Нил азык-төлек юнәтә, мин яшьтән үк аш-су остасы, ә Хисапчы табак-савыт юа, идән себерә. Нил көн-төн укуда, аңа фән җене кагылган, лекцияләрен бер дә калдырмый, һәммәсен кызлар кебек түкми-чәчми язып бара, бөтен җәһәттән ыхтымат, чиста-пөхтә кеше. Минем, һәрвакыттагыча, баламишкинлык көчле, үтә җитди була алмыйм, кием-салым алак-шалак, куе, калын чәчләр майланып иңбашыма төшкән. Арыслан ялыдай сачларен җилбердәтеп Тавлин килеп чыга. Икәү төшкән фотобыз бар, кадерләп саклыйм. Ифрат чибәр иде Гурий, грек аксөякләренекедәй туры борын, затлылыкны өстәгән сак борын бөтеркәчләре, матур, туры гәүдә. Ак маңгай, кашлар, ул сачлар!.. Гурий Бауман урамыннан бер якка бара башласа, урам тутырук хатын-кызлар кая барганнарын онытып, көтүләре белән аның артыннан иярәләр иде. Ә хисле, әдәбият белән җенләнгән сылукайлар аның белән очрашуны ялварып төн йокыларын йокламыйлар иде. Ә Гурий горур, мактанчык, чибәр ирләргә хас булганча, хатынкызга һич исе китми! Курсташ кызларын тилмертеп-кимсетеп «Кәҗә тояклары!» — дип кенә атап йөртә. Гомумән, күз карашы да, үз-үзен тотышы да Гурийның һавалы, текә иде. Күпме вакыт бергә диярлек яшәп мин аны гади кеше, эш эшләгән яки ашап утырган чагын һич күз алдына китерә алмыйм! Ул ниндидер затлы нәселнең дәвамчысы, серле вә бу дөньяга очраклы гына килеп чыккан кешене хәтерләтә иде. Әнкәсе, Борды авылы кызы, Машук апа затлы хатын иде. Ап-ак маңгай, акыллы күзләр, сөйләшүендә дә ниндидер бөеклек, асылзатлык бар иде мәрхүмә Машук апада. Мин Гурийның мактануын, борчак чәчеп җибәрүләрен гел-гел гафу иттем, чөнки мин аны үземнән күп акыллы, күп өстен дип саный идем. Ул еш кына совет власте, илдәге чынбарлык, гаделсезлекләр хакында йомыры-йомыры фикерләр ычкындыра иде... Яныбызда Хисапчы барын ул да, мин дә искәрмәгәнбез икән. Киресенчә, соңгы елларда мин аны Хисапчы белән очраштырырга эзләп бардым. Хисапчы өйдә туры килмәде. Гурий бик гаҗәпләнеп: «Аяз, минем төрмә эшендә Хисапчының бер генә гаепләү сүзе дә юк лабаса!» — диде. Гурий, Гурий, төрмә эшләрен карарга алынган бүтән иптәшләр!.. КГБның чын, түләүле агентларының гаепләү хәбәрләре берчакта да төрмә документларына барып җитми. КГБ үзенең чын ялчыларын кадерләп саклый. Аларның чын йөзләре бүтән, КГБның тирән базларына, җиде кат йозак астында саклана торган сейфларга кереп чумалар. Бүген Гурий белән Хисапчыны сугыштырасым, бер-беренә өстерәсем килми. Хисапчы да замана җимеше, аны да аңларга кирәк. Бер нәрсә генә сер: нигә шулкадәр яратмады икән Хисапчы Гурий Тавлинны?.. Моны без берчакта да белә алмабыз ахры...

Укыйм, йөрим, язам. Үзем белән элек укыган студентлардагы үзгәрешләрне көннән-көн ачыграк күрәм. Ә алар миндәге үзгәрешләрне абайлый аламы?.. Юк, алар шушы «каникул айларында» минемниләр кичергәнемне күз алларына да китерә алмыйлар. Мин югарыда үзем белгәннәр арасыннан Совет режимының явызлыгын мәгълүм бер дәрәҗәдә аңлаган иптәшләремнең исемнәрен теркәп киттем. Ә мин белмәгән, белә дә алмаган йөзләр-меңнәр Совет хакимиятенә гел-гел буйсынып, сүз әйтергә шүрләп, баш сузып карарга куркып яшәделәрмени?.. Әгәр без ул чактагы фольклор әсәрләренә игътибар итсәк, төрле төбәкләрдә талантларның, акыллы адәмнәрнең чәчелеп яшәп ятканына ышанырбыз. Шул заманның шук җырларына игътибар итик:

Бригадир кыз Тәския, ирләр киеме кия,
Ирләр киеме кисә дә үзе чүгәләп сия.

Чагыламы заман сулышы?! Ленин-Сталин намына ясалма, ялган шигырьләр чыгарып чиләнгән, шул чиле-пешле әсәрләрен халыкныкы дип ялганлап орден-медальләр, дан алган шул заман фольклорчыларының такмаклары бер якта торсын!

Биек таудан күренеп тора Кукмара вокзаллары.
Ике яр сөяргә дигән Пленум карарлары.

Егетләр кытлыгыннан ничек котылу турында да уйланган ул заманның җор кызлары, еш кабатланган буш сүзле Пленумнарга да төрттереп уза белгәннәр. Усаллыкка да өндәгәннәр:

Чакрым саен багана, баганалары авыш.
Кеше яры диеп торма, сразы барып ябыш!..

Шигырьләрнең моннан да чаярагын, сәяси үткеннәрен чыгарган татар халкы. Ленин-Сталин турындагы такмаклары белән халык аңын агулаган фольклорчылар, ишетегез!

Кызыл ыштан, киң балак. Колхоз хатыны карак.
Председатель чабып йөри, ыштан төпләрен карап.

Гаҗәп бит, әй! Ике-өч юл белән авылның фаҗигасен ачкан да салган! Яки менә:

Җилпуч инде күптән үлгән,
Күәс тә хәл эчендә!

Менә кайда ул күпереп, әчеп беткән реализм! Чынлык, кыюлык чәчрәп тора бу шигъри юллардан!

Егет җилле, нечкә билле. Күлмәк кыска, корсак зур.
Җилгә каршы төкереп йөри, үзе актив, үзе бур.

Бу җыр комсомол турындадыр, мөгаен. А-а, ошбу юлларга таянып әллә никадәр фәлсәфи фикерләр чыгарып була. Уйлансаң, аңласаң, күрер-күзгә гап-гади шук шигырьләргә дә искиткеч киная, нәфрәт яшерелгән. Менә бу юлларның серен чишәргә тырышып карыйкчы!

Милиция кызыл ыштан, чаптырып сия баскычтан!

Милициягә юнәлдерелгән бу шигырь МГБга да төп-төз аткан, алар, җәза осталары, һәр ымы, һәр зәһәр сулышы белән гади халыктан теш ыржайтып көлгәннәр, сүзләре, кыланмышлары белән аны мыскыл иткәннәр. Ул шуңа өйрәтелгән! Йомышын үтәргә абзар артына җилгә чыгып

мәшәкатьләнмәгән ул, шулпалы бәлешне бөгеп, кысталып чыга да, шунда болдыр баскычына басып кына айга карап чәптерә! Аста туры киләсен икән, унайсызланып-нитеп тормас, күзенә үк сияр ул мәлгунь!

Халык иҗаты җәүһәрләренең асыллары әле җыйналмаган, дәреслек китапларында урын ала алмаган. Күңелгә шушы җырларны төяп, сез югарыда танышкан сәхифәләрдә гыйбрәтләр алган егерме яшьлек тере егет кырык сигездә тагын Маркс-Ленин тәгълиматын — мөһмәлят[1] чәйнәргә мәҗбүр ителде. Кая барасың, Рәсәйдә бүтәнчә мәктәпләр юк, һәммәсе бер иш, ишәк тә, ябалак та бер үк тәгамны ашарга мәҗбүр. Йа бәхет, күп санлы студентлар арасында тормышның, язмышның асылын, усаллыгын, мәрхәмәтсезлеген тулаем аңлаучы, икеләнмичә үз тәҗрибәсе фикерләрен әйтә алырлык иптәшләр дә очрады. Арадан берсе — Әбрар Кәримуллин үзенең уй төгәллеге, фикри югарылыгы белән бүтәннәрдән аерылып тора, ул җаны-тәне белән хакыйкатькә омтыла, халык язмышы өчен яна-көя торган егет иде. Бүтәннәр белән шулай кыю мөнәсәбәттә идеме туры сүзле Әбрар Кәримуллин, Черек күлдә марттан декабрьгә кадәр утырдым, аның хакында бер сүз кузгатмадылар. Кузгатмаулары хәерле, Черек күлдә боргычларның осталары утыра, «ә» дигәнне «җә!» дип язып куярлар да, кәкере-бөкере имза салганыңны сизми дә калырсың!

Театр училищесы студентлары белән үз булып беткән идем инде, диплом спектакльләрен ярсып көтеп алдым. Островскийның «Төшемле урын»ын күрсәттеләр. Булса да булыр икән Рәсәйнең һәр заманына төзәп атылган һәм аткан саен күз чыгарган әсәр! Рифгат Әмин ул чакта Белогубовны уйнады. Героена шулкадәр кус, тыгыз төсмерләр тапкан иде егет, уеннары бүген дә күз алдымда. Рифгат Әмин дә югалды. Әчке уйларга бай, хисчән татар иде мәрхүм. Айрат Арсланов, Жадов ролен башкарып, тамашачыларның һушын алган иде. Буй дисеңме, чибәр, аһәңле тавыш... Иманының какшамаслыгы миңа аерым бер тәэсир ясады... Спектакльдән моңсуланып кайттым: Мәүлә юк, Мәүлә... Татарның талантлы уллары кайсы елларда, кайларда чәчелеп әрәм булмагандыр дисең? Без, татарлар, чәчелергә дигәндә оста, ә җыярга дигәндә... Ай-һай, берәр заман милләт буларак җыелырбызмы-юкмы? Мәүлә белән без, бу хакта еш-еш хафаланып, әңгәмәләр кора идек...

Спектакльне режиссер-педагог Кәшифә ханым Тумашева сәхнәләштергән иде. Ул куна-төнә диярлек студентлары арасында яшәп, сәнгатькә бирелгәнлекнең үрнәкләрен шәкертләренә дә бирә иде. Ни үкенеч, заман ул күрсәткән игелекләрне санламады, «Төшемле урын»да күренеп киткән кызлар күздән югалды, бүтәннәр дә кайсы-кая таралдылар. Кәшифә ханым ул чакта Некрасов урамында яши иде; мин аның кызы «ультра красная» Зөмәррә туташ белән дә таныш, еш кына аларга барып чыгам. Кәшифә апа юмарт әчкерсез хуҗа, хуш исле чәй белән сыйлый, ә Зөмәррә күптин-күп сораулары белән тинтерәтеп тә бетерә торган иде.

Бар иде без яшәгән авыр заманаларда читләр фикерен тартып-йолкып алырга тырышкан җаннар! Хәер, хәзер андыйлар юкмы?

## 12

*Бу җанда ниләр алмашынды?*

Виктор ГЮГО

Адәм баласы — яшьме ул, картмы — үзенең әчке дөньясы белән гомер кичерә, билгеле. Үз күңелендә үзенең яшертен шәүләсен тудыра да айлар-еллар үткән саен аны үзе теләгән төсләр белән тутыра. Һәркем үзе хакында яхшы уйлый, үзенә-үзе ябыштырган тамга-

[1] Мөһмәлят — буш, мәгънәсез сүзләр.

лардан канәгать булып алдана. Була, вак-төяк рәнҗешләре дә була адәм улларының, кечтик кенә үкенечләр дә килеп китә, ә зур чынлыкта кеше дигән зоологик берәмлек үз-үзен бик ярата, уйларында иркәли, сыйпый...

Ә бүтәннәр?.. Син яшәгән мохит, син очрашырга мәҗбүр ителгән адәм балалары синең хакта нинди уйда?.. Без андый уйлар белән газапланмыйбыз, болай, үтеп барышлый гына искә кереп чыккан сораулар «мин-минлек», «үз-үземлек» нурлары астында тиз-тиз уңалар, онытылалар...

Ниһаять, хикәям дөнья күрде! 1948 нче ел иде. «Ян, учагым, ян!» исемле иде ул хикәя. Сөенгәнмендер, истә калмаган. Бер көнне: «Сине өченче курс студенты эзләп кергән иде!» — диделәр. Бер түгел, биш кергән теге егет. Икенче көнне иртәнчәк аудиториядә арык кына, көләч йөзле, бераз артка тайчынган гәүдәле берәү мине кочаклап алды. Кайнарланып, миңа сүз әйтергә дә ирек бирмичә күтәренке сүзләр белән хикәямне мактады. Андый мактарлык ук хикәя түгел ләбаса!.. Мин ышандым, иптәшнең нигә шулкадәр мактавының серен аңламадым... Без еш-еш очраша башладык, кичке караңгыда Казансу буйларында, мәркәзебезнең кәкере-бөкере урамнарында, бер менеп, бер төшеп, табан аслары кабарганчы йөрибез. Мин шигърияттә надан диярлек, ә ул... Шигырьләрнең иң кәттәләрен яттан белә, Некрасовны, Һейнены күңеленә бикләгән, урысчаны су кебек эчә. Үзе дә шигырь яза. Мәҗит Рафиков Башкортстан тумасы икән. Уфа пединститутында укыган да, ни сәбәптәндер, Казанга күчкән. Шагыйрь кеше алдашамыни, әле минем ышана торган чак, күчүенең сәбәбен тикшермәдем, үзе дә ачылып китмәде. Шигырьләре Ленин-Сталинны коры мактауга манчылып, уй-фикерләренең күпчелеге Совет властен, Рәсәй илен данлауга кайтып калса да, Мәҗит минем өчен үзе белән дөнья поэзиясен алып керде...

Тикшерү «Дело»ларында үзең хакында моңарчы ишетмәгән бәяләрне аласың. Алай да мин замандашларыма, курсташларыма, бүлмәдәшләремә рәхмәтлемен. Яман сүз әйтмәгәннәр, карага, ялганга буямаганнар. «Аяз советка каршы язылган хикәяләрен укыды», — дигәннәр. Хак бәя! Димәк, мин ул чакта ук чынбарлыкка ачык күз белән карый алганмын! Хикәяләремне әдәбият түгәрәкләрендә дә укыйм, киңәш бирәләр, курка-курка гына дөрес фикерләр дә әйтелә. Кайберәүләр түгәрәк утырышларыннан соң миннән ерагаялар, кайберәүләр «тел яшерә» башлыйлар. Озакламый университетның «Ленинец» газетасының 8 апрель санында (1949 ел, №12/314) «На неправильных позициях» дип исемләнгән мәкалә басылып чыкты. Менә ул.

**«Татарский литературно-творческий кружок в университете объединяет наших начинающих писателей и поэтов. Упорная работа над собой — вот что определяет творческие успехи кружковцев. Идейная направленность, художественные достоинства отличают произведения нашего молодого поэта М. Хусаинова, кружковцев Р. Гайнанова, Р. Тимергалина, Н. Фаттахова и др. Этого, к сожалению, нельзя сказать об отдельных кружковцах-прозаиках, в творчестве которых имеются элементы формализма и эстетства. Это прежде всего относится к студенту II курса историко-филологического факультета А. Гилязову. Этот начинающий писатель написал рассказ «Мать», в котором нарисовал образ женщины, убитой горем по погибшим сыновьям. Напрасно читатель будет искать в этом рассказе описание героического труда советских людей в годы Отечественной войны. Здесь этого нет, как нет и образов цельных, мужественных тружеников нашего села, тыла, отдававших все для победы над врагом. Автор описывает переживания матери — пассивные страдания.**

**Язык А. Гилязова не отличается простотой и естественностью. Он рассчитан на внешний эффект, и потому изобилует формалистическими выкрутасами. Это не случайность! Формалистические эффекты, анализиро-**

**вание душевных страданий нужны автору, чтобы как-нибудь прикрыть идейную ограниченность своего рассказа».**

Бу мәкаләне янау, донос түгел дип кайсыгыз әйтә ала?.. Автор чыраена кара битлек кия, исемен яшерә һәм, тагын бер кат мине гарьләндерергә теләп, имзасын «В. Сарманов» дип куя!

Атаклы 1948—49 нчы еллар бу! Илдә кешеләр аңын чираттагы «чистарту» бара. Иҗат оешмаларының «алдынгы вәкилләре» космополитизмга һәм буржуаз уйдырмалар тәэсиренә каршы соңгы көрәшкә чыктылар!.. Шушы бер мәкалә үзе генә дә мине Черек күлгә илтеп ябарга азык була ала иде!..

«Без еш кына сүзне һичнинди үлчәүсез сөйләп ташлыйбыз. Хатлар алышканда да аны-моны уйлап, «азагы ничек булыр икән моның?» — дип баш ватып тормыйбыз», дип язган иде дусларымның берсе байтак еллар элек. Сагаерга өйрәтелгән шул без, сакланырга! Үлчәп сөйләрсең — ә үлчәвең ватык булса? Һәр адымыңны Гринвичта саклана торган метрэталон белән үлчәп йөрерсеңме?.. Мин үзем кыюларны яратам, адымнарның үлчәүгә сыймаганын... Минем файдагадырмы, түгелме, хөрмәтле укучым, синең игътибарга тагын бер «документ-хат» үрнәге китереп китәм. Уфа драматургларыннан берәү Әлмәт театрының баш режиссеры Гали Кәримович Хөсәеновка юллаган хат. Анда мондый юллар бар:

**«Мин әллә Кызыл Армия көне белән сездән җылы сүзле хат килдеме дип торам... Ә сез адәм ышанмастай бер гайбәт язгансыз. Уфадан килгән ул юньсез гайбәтченең авызына сугарга иде. Эш асылда болай тора. Мин «Югалган көн» спектакле премьерасының икенче көнендә бардым. Анда А. Гыйләҗев тә килгән иде. Пьеса да, спектакль дә бер язучыга да, сәнгатьне аңлаучыга да ошамады. Тамашачы спектакль беткәнче бер көлми, бер кул чапмый, ә инде азакта күтәрелеп, кул чабып та тормыйча, чыгып китә. Хәтта авторны сәхнәгә чыгаручы зав. лит. Аралбаева гына булды. Тамашачы: «Бик пычрак спектакль, бик әшәке кешеләр, мондый кешеләр арасында яшәү коточкыч»,— диделәр. Обкомда сүз зур булды! Идеология секретаре көндез караган икән. Шуннан спектакльне ике бүлектән бергә калдырып, «Сезон беткәнче барсын инде, әйдә!» дип калдырдылар. Халык бик чамалы йөри. Сез: «Фәлән-фәлән фикерне шәһәрдә таратасыз икән!» — дип язасыз. Ә мин исә беркайда, беркемгә (рәсми урында) бер сүз әйтмәдем. Ә минем әйтергә хакым бар! Беренчедән, мин РСФСР комиссиясенең әгъзасы (сезнеңчә — члены), икенчедән, драматургиядә 40 ел эшләп киләм, ләкин кысылышым булмады, иманым камил. Дөрес, бүтән бер кара эчле кеше булса, андый адым (акт) эшләр иде. Чөнки заманында (моннан 2—3 ел элек) Аяз Гыйләҗев рәсми урында минем бер пьесам турында хулиганнарча чыгыш ясады. Ә ул пьеса гөжләп бара, рус теленә дә тәрҗемә ителде. Гыйләҗев талантлы язучы, уйлана торган язучы, ләкин ул (үзенең биографиясе нигезендәме, характеры шулаймы...) һәрбер әсәрендә Совет хөкүмәтен, безнең системаны чеметергә, энә белән чәнчергә ярата, ә принципиаль тәнкыйтьне белми. Бу әсәрендә дә персонажлар берсеннән-берсе каралы-ущербный, хәтта өшеп-туңган кызыкайга пьесаның азагына хәтле бер йотым җылы су да бирмиләр. Бу бит кошмар... Ә көтүче? Ә саламга баручылар? (Казагыстанга саламга баруны бу чаклы пропагандалау үзе бездән көлү). Ә Мәскәүгә жалоба белән баручы? Ә теге карт? Имеш, юлларны кеше өчен түгел, нефть өчен салалар! Хөкүмәт рәхәтләнеп салыр иде, мөмкинлеге юк, акчасы җитешми... Имеш, вышканы күчергәндә фәлән гектар бодайны таптатканнар. Ә ул вышканы сүтеп күчереп, яңасын монтировать итсәң, унар мең сумга төшә. Сүтми күчерү прогрессивный метод, ә тапталган берничә гектар бодай капля в море...»**

Уфадагы мөхтәрәм каләмдәшемнең гаепләү актын «комментировать» итеп, шәрехләп тормыйм, мин аның төп өлешен түкми-чәчми

күчереп чыктым. Бу хатта безнең чор балаларының бөтен фаҗигасе ярылып-чәчрәп ята. Бер уңайдан әйтеп китим, мин замандашыма искиткеч рәхмәтлемен! Ул минем холкымны, мәсләгемне, иҗатымда нинди фикерләрне алга сөрүемне ялгышусыз аңлаган. Сүз Уфада куелып, уңышка ирешә алмаган «Югалган көн» пьесасы турында бара. Пьеса Казанда Качалов исемендәге Зур театрда күрсәтелүгә мине, театр директорын, мәдәният министрын һәм театр парторгын обкомга чакырып алып, югарыдагы иптәшнеке кебек үк үтергеч бәя биреп, шул бәһага кат-кат мат өстәп, өч сәгать дәвамында эт иткәннәр иде! Әле ярый, урысның сүгенү сүзлеге гаҗәеп бай, тел ардырып кесәгә керәсе юк! Анда да: «Әйдә, игълан ителгән алты спектакльне уйнасыннар да туктатыгыз!» — дип йомгак ясадылар. Соңра, пьеса татар театрының түренә күтәрелү бәхетенә ирешкәч, чорыбызның иң мәшһүр актеры, милләтебезнең каһарманы, ил агасы Шәүкәт Биктимеров: «Ничек шул заманнарда ук син шундый гадел, хак сүзләр әйтә алдың икән?» — дип гаҗәпләнеп торган иде. Шәүкәт, исеңдәме?

Кырыгынчы еллар, кырыгынчы еллар... Кемнәрнедер, мең вә миллионнарны һәлакәткә китергән, күзләрен мәңгегә вакытсыз йомдырган, бик күпләргә йомык күзләр бүләк иткән кырыгынчы еллар! Илдә кулга алуларның өр-яңадан чәчәк атуы кырыгынчы еллар азагына туры килүе юкка гына булмагандыр лабаса!.. Димәк, илдә каршылыклар ишәйгән, халык коммунистлар да ишетелерлек итеп ыңгыраша башлаган дигән сүз.

Ә кемнәрдер шул ук елларда балда-майда йөзгән, каймак ялаган, баеп, үзләренә, оныкларына, аларның балаларына җитәрлек кадәрле мал-мая туплап калган. Инде күп еллар узгач, Займищеда ширкәт оештырып, дачалар салып куйгач, күршемдә диярлек яшәп ятучы, күрер-күзгә юаш кына, итагатьле генә коммунист белән ачылып киттек. Баксаң, министр урынбасары булган икән теге юаш... Каяндыр хатирәләрне уртага алдык... «Хәзер балык балыкмыни ул?! Менә кырыгынчы еллар азагында, илленче еллар башында умыра идек без балыкны! Лаеш тирәләрендә метрлы кырпыларны чумырып кына ала идек! Корбан балыгын ашамадык, «чүп-чар!» — дип кире Иделгә җибәрә идек. Чөгә ухасы дигән булалар, наданнар! Чөгә ухасының өресе күбәйсен дип, ертлач балыгын тутыралар... Кырпы ухасы янында бер тиенгә тормый алар! Ит дигәндә кыр тавыгы гына ашый идек. Ауга чыксам, уникешәр-унбишәр бүдәнә ата торган идем. Эх, кырпы ухасының өресе ике бармак калынлыгы була иде. «КВ» коньягын бер тустаган җибәрәсең дә ике җамаяк уха ашыйсың. Атна буе туксырып, кикереп йөрисең аннары! Дөньяның якасыннан тотып артына типкән чаклар бар иде...»

Аның тәмләп мактануыннан безгә бөтенләй ят дөньялар булганлыгын искәрдем. Үземнең, тирә-ягымдагы бик күпләрнең тоташ ачыгуын, карточкага алган икмәкләрне, кан-яшь түгеп яшәвебезне уйлап куйдым. Кемнәрдер кырпы ухасы ашап, икенче ашка бүдәнә куырдыгы белән кинәнеп, һичкемнән тайчынмыйча Идел-Чулман буйларында яшәп ятканнар бит. Безнең төшкә дә кермәгәнчә рәхәтне чиккән алар! Ә мин... Мунча кереп, салкын каз боты кимереп яшәгән прокурорлардан, райком әһелләреннән көлеп маташам, әсәрләремдә аларның тетмәләрен тетәм. Әнә кемнәре булган Татарстанның! Әнә кемнәр аның җелеген суырган, байлыгын талаган. Илебезне Мәскәүгә сатып, җиребезне таларга булышкан олы кешеләр, дәүләт түрәләре турында әле әсәрләр язылмаган. Җаннан курку китә башлагач, берәребез йөрәксенерме, юкмы — белмим.

Черек күлдә, тимер ишекләр артында саклана торган «Тикшерү дело»сында шактый кызыклы фикерләрем, беркетмәләргә сыланган сүзләрем калган минем.

«Бүгенге колхозчылар крепостной крестьяннарга караганда биш тапкыр начаррак яшиләр, хокуксыз алар!» — дигәнмен. Дөрес әйтмәгәнмен, хаталанганмын мин, кем каршы төшә ала? Бүген без фикеремнең дөреслеген меңнәрчә әсәрләр, миллион фактлар белән раслап барабыз.

Иптәшләрдән берәү: «Аяз крестьяннарны колхоз коллыгыннан коткарып, Америкадагыча фермер системасына күчерергә кирәк дип коткы таратты»,— дип әйтеп калдырган һәм мөбарәк имзасын куйган. Ягез, бу фикер үзенең кыйммәтен югалттымы бүген?

Хәтерле дус-иш белән аралашканмын, әй! «Аяз, Ватан сугышында хәлиткеч көч булган шәхесләрне санаганда Сталинның ролен артык купайтып күрсәттеләр, диде. Арттыралар, шартлаталар! диде. Сугышның авыр арбасын Жуков, Конев кебек маршаллар тартып барды. Алар илтте безне җиңүләрдән җиңүләргә!.. Аяз бөек юлбашчыбызга бу җәһәттән дә яла якты!» — дип раслаган арадан берсе.

Күрегезче, газиз туганнарым! Кырпы ашап, бөҗыр кимереп яткан бәндәләр шул сүзне әйтә алганмы?

Мин: «Советлар союзында иҗат итү мөмкинлекләре юк. Әнә, «Звезда», «Ленинград» журналлары әз-мәз дөреслеккә йөз тота башлаганнар иде, Үзәк комитет махсус карары белән «шап!» тегеләрнең башына. Илдә иҗат иреге юк. Коры мактаудан гына торган әсәрләргә көн күрсәтәләр»,— дип раслаганмын. Бүген йөзем ачык: кыю вә хак фикерләр әйтә алганмын ич! МГБда йоклап ятмаган, агент арты агент җибәреп, уй сукмакларына җәтмә арты җәтмә салган. Арадан берәү, соңыннан бик тәкъва булып йөргән иптәшем: «Аязны аракы эчертеп эч серләрен алыр өчен МГБ хезмәткәре Михеевтан йөз сум акча алдым, аракыны эчерттем, Михеев кушкан бер кыйссаны сөйләдем. Аяз кыйссаны салган баштан тыңлады һәм шундый мәгънә чыгарды: «Кулыңда форсат һәм көч барында Совет власте белән көрәшергә кирәк»,— диде.

Мин 1950 елның азагына хәтле Черек күлдә утырдым, аннары мине Кремль астындагы күчеш төрмәсенә илтеп яптылар. Этапка куар алдыннан мунчага алып бардылар һәм шунда без Гурий Тавлин белән мунча кердек. Гурий истәлеккә ике «сувенир» бирде: берсе балык кылчыгыннан ясалган шоп-шома нык инә иде, икенчесе ипи йомшагыннан ясалган ялтырап торган, корычтан да каты төймә иде. Гурий дустымның ул кыйммәтле аманәтләре минем белән шактый вакыт сәяхәт итте.

Күчеш төрмәсеннән безне шактый зур төркем итеп өерләп, кара билле тәрәзәсез машинага шыплап тутырып, вокзалга алып төшсәләр дә, арада Гурий юк иде. Мине ерак сәфәргә олактырдылар, Гурий шушы тирәдә, Казан төрмәләрендә калган булып чыкты.

Лагерьдан кайткач, укый вә эшли башлагач мин өйләндем һәм, әлбәттә, туйның иң хөрмәтле урынында Гурий Тавлин утырды.

## Икенче бүлек

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!*

ДӘРДЕМӘНД

### 1

*И где лучше узнать людей, чем здесь?*
*И самого себя?*

Александр СОЛЖЕНИЦЫН

Этаплардагы юл газаплары хакында том-том китаплар, меңнәрчә кайгылы хатирәләр инде язылган. Минем беренче төрмә-вагоным да бәхетле булды, юлдашларымнан да уңдым. Вагондагы камерамда кеше әз иде. Мәскәүле врач яһүд Яков Борисович Цудечкис

белән без лагерьда да бергә тап килдек. Икенчебез дә мәскәүле профессор Хинчин, өченчесе дә шулай ук яһүд, гомере буе Тышкы сәүдә министрлыгында хезмәт күрсәткән, картайганчы чит илләрдән кайтып кермәгән, совет режимының четерекле якларын белмәгән, әкиятләр дөньясы сабые Ольгерт дигән карт иде. Алар Мәскәүдән килә, Казанда мине китереп тыктылар, кузгалып китеп бераз баруга, өстән берәү килеп төште. Яланаяк, чалбар балаклары кып-кыска, арык, әз-мәз сипкелле, ике метрлы урыс Митя Афанасьев булып чыкты бу. Яңак сөякләре калкып-очлаеп торган бу Рязань урысы ачык чырае, йомшак дустанә карашы белән бер минутта минем илтифатымны яулап алды. Мәскәүлеләр төрмә сукмагына әлерәк эләккән тәҗрибәсез мәхлуклар булса, мин бөтенләй бозау, ә Митя — власовчы, бу читлеккә төшкәнче тәмугның астын-өстен актарган, Европаны гизгән, әсир калып дөнья җәфасының иң авырын татыган җан иде.

Яһүдләрне дә бакча балалары дип атап булмый. Мәскәүнең дөньяга атаклы Бутыр, Красная Пресня, Лефорт төрмәләрен үткән, йөзләгән торкыннар белән аралашкан, аларның фикер сөземтәләрен, әче тәҗрибәсен үзләренә кабул итеп алган акыллы кешеләр, һич яшермичә, икеләнмичә совет властеның асылын, большевикларның кешелексез, явыз сәясәтен үзләре татыган яки ишеткән мисаллары белән ачып, раслап бардылар. Мине аларның күп белүе, кыюлыгы, иманнарының бөтенлеге таң калдырды. Мин бер мәлгә исәңгерәп, югалып та калдым. Болар мин белгәнне әллә кайчан ашап косканнар! Хаклык эзләп ачыккан миемә минут саен яңалык өстәлә, яһүдләр, шәкерт көтеп зарыккан остазлар кебек, мине һәр җәһәттән тәрбияләргә, мин утын түмәрен юнырга тотындылар. Мин дә авызга су кабып утырмаганмындыр, алар да мине очратуларына сөенделәр, Казан университеты Казан университеты ул! Анда юк-бар кеше укымый... Черек күл камераларында утыручы яшьләр, студентлар юлдашларымны аерата кызыксындырды, мин сөйләгән хәбәрләр ишәйгән саен аларның йөзләре ачыла барды. Үземнең дә төшеп калган бәндә түгеллегемне белдерә алгач, кәефем күтәрелеп китте. Без бер булып, совет властеның дошманнары рәвешендә, бер һава сулап, берләшеп туганлаштык. Митя да күпне күргән, меңне ишеткән, авылына кайтып андагы хәерчелектән башын югалта язган, бәхетсезлеккә, кеше хәсрәтенә битараф кала алмаучы тере урыс егете иде. Яков Борисович арабызда яшь кеше, миннән чак кына өлкәнрәк, институт бетереп бер-ике ел гына эшләп калган моңсу адәм иде. Уйларыбыз Столыпин вагонына сыймаса да, үзебез сыйдык, барабыз! Иртә-кич бәдрәфкә йөгертәләр, ике башта ике усал солдат торып каулыйлар, әз генә мыштырдасаң, авыр йозак белән җилкәңә кундыралар. Монда солдатлар явыз, берәүгә дә көн күрсәтмиләр... Ашау «европейско-континентальный»: юлга чыкканда кулга бирелгән шыр тоз селедка да иртә-кич берәр кружка су. Сусызлыкка, тынчыган тыгыз һавага, тамак ачыгуга да исем китмәде, Казан-Свердловск арасын мин бәхет диңгезендә йөзеп үттем.

Юмарт акыллы сәфәрдәшләремә гашыйк булып, алар авызыннан чыккан һәр сүзне көтеп алып, һәр фикерне йотып барганмындыр шул! Орджоникидзеның Сталин белән килешә алмыйча үз-үзен үтерүе дә... Сугыш башлангач Сталинның эче китеп, куркып өч көн караңгыда бикләнеп утыруын да... Киров үтерелгәннән соң ун меңнәрчә бәхетсезнең бер тәүлек эчендә төрмәгә ябылуын да... Илленче елларда шушы хәбәрләрне бер эзлеклелек белән тыңлап бару бәхет түгел идемени?!

Профессор Хинчин сөйләгән анекдотка якын бер вакыйгага кадәр исемдә! Ленинградта бер карт яһүд типографиядә хәреф җыючы булып эшли икән. 1934 елның 1 декабрендә кызын кияүгә бирә бу. Кичкә туй билгеләнгән! Инде эшен бетереп, киндер алъяпкычын чишеп маташканда атылып редактор килеп керә һәм ашыгыч рәвештә наборны сүтәргә, яңа коточкыч хәбәрне җыярга куша. Кировның үлеме хакында информация алынган икән! Мескен яһүд ачу белән алъяпкычын атып бәрә дә: «Так и знал!» — дип кычкыра... Бичара ата туйны ике тапкыр кичектергән була

инде, шуның өчен редакторның сүзе аның анына да барып җитми, бу юлы да ул:«Бер-бер хәл генә була күрмәсен инде, и ходаем!» — дип смена буе тәшвишләнеп йөргән икән... «Так и знал!» Шул минутта КГБга барып җитә һәм яһүдне шундук кулга алалар, таң ялгалганда чыгарып аталар да...

Безнең вагонны шалтыр-шолтыр озак кына сөйрәп йөрткәч, куелык-ка, вагоннар арасына кертеп туктаттылар. Чыгарга боерык булды, бер конвой тапшыра, икенчесе кабул итеп ала. Усаллыкта бер-берсе белән ярышалар. Як-ягыбызда гөрс-мәрс егетләр, туклар, тазалар, зәһәр усал-лар. Коммунистик режимның ышанычлы ялчылары. Этләр, үткер-үткер тешле усал маэмайлар. Шул көннән мин этләрдән курка башладым, ай-һай, явызлана белә алар! Алар, зөбанилар, минем курыкканны сизә-ләр, кайчан һәм нигә курка башлавымны гына сорашмыйлар. Эттән курыккан кешенең баш түбәсеннән сөрем күтәрелә, диләр. Белмим, бүре-гемне басып киеп карыйм, барыбер куркуымны сизә тегеләр...

Безне тиз-тиз тезделәр, бер-ике тапкыр мылтык түтәсе төшкәч, һәркем үз урынын ялт! — тапты. Кузгалдык. Вагоннар арасыннан лапор-лопыр, абына-сөртенә барабыз. Исемә төште, юлга биргән балыкны да ашамаганмын, ипинең дә чите тешләнгән килеш, өч тәүлеккә якын килсәк тә карыным ачмаган икән! Сүзгә мавыкканмын! Мин башны борырга да куркып, астан гына юлдашларыма карыйм. Совет иленең закон тарафын-нан танылган дошманнары — үз ишләрем белән барам ич! Миңа егерме ике яшь! Шайтан алгыры, күңелдә бер горурлык та бар әле! Ниһаять, мин туганнарым, фикри дусларым арасына килеп кердем. Бехтеров урамын-нан Черек күлгә мине җәяү генә алып килделәр. Шунда мин полковник Катерлигә: «Кулга алуларын үзем дә тели идем!» — дигәч, ул, борылып карады да: «Дурак!» — диде. Дуракмы, түгелме, анысын дөнья күрсәтер, әмма Свердловски күчеш төрмәсе юлында мин үз-үземнән канәгать, горур идем.

Шулвакыт, искәрмәстән, вагон күләгәләре арасыннан бер шәүлә килеп чыкты да: «Воры есть?» — дип сорады. Безнең сафлардан кемдер аңа: «Есть! Мишка фиксатый!» — дип җавап бирде. Шәүлә эреп югалды да. Кеше йөрми торган карлы мәйданга чыгып, машиналарга төялдек. Озак та бармадык шикелле, биек таш коймага поскан тимер капка ачылып китте, без төрмә ишегалдына барып кердек. Һи-и, монда икән ул Рәсәй халкы!.. Аннан да моннан да туктаусыз агып торган этапларны кабул итеп кенә өлгер. Бөтен якта команда тавышлары, тоткын исеннән котырынган этләр абалап өрә, аерата усаллары безнең өскә ыргыла. Анда саныйлар, монда фамилияләр атап кычкыралар, үзара сүгешәләр, һәр конвойның тизрәк тапшырып, ычкынасы килә, ахрысы... Фамилияңне кычкыралар, атылып чыгып исемеңне, әтиең исемен, статьяңны, срогың-ны әйтеп, коридорның икенче ягына бәялгән үз ишләрең янына барып кысыласың. Аксак-туксак та яшен тизлеге белән хәрәкәтләнә, сукырлар-ның күзе ачыла, урысча бер сүз белмәгән эстоннар да команданы һич ялгышусыз аңлыйлар. Сикертә МВД солдатлары Рәсәй халкын! Ниһаять, Свердловск төрмә вокзалының бер камерасына савылып барып кердек. Тәмуг җиде катлы, диләр, без ничәнче катында булганбыздыр, бераз күз ияләшкәч, юлда бергә килгән иптәшләрне табып, алар тирәсенә елыш-тым. Бер җирдә эскәмия-мазар юк, басып торабыз. Мондагы төрмә вокзалы идән белән түшәмне ялгап ябыштырган калын-калын тимерләр белән кырыйланган дүрт читлек-камера ул. Безне, илле сигезенче статья-ларны, аерым читлеккә япканнар икән. Бездән соң тагын бер-ике этапны куып керткәч, басып торыр урын да калмады, карт-коры, чирле-чинкеләр идәнгә чүгәләделәр, соңра авып ук киттеләр. Безнекеләр әлегә сөйләш-миләр, карлы-бозлы яңгырга эләккән сарыклар сыман башларын иеп, аумаска тырышып бер-берсенә терәлеп торалар. Күрше камераларны карарлык булып өлгердек. Анда... күбесе яшь-җилкенчәк, балалыктан чыгып кына килгән үсмерләр дә бар. Карагач, колак та салдык, бу

читлектәгеләр тоташ сүгенү сүзләреннән генә торган без аңламаган ят телдә сөйләшә иде. Усаллыкларымы, чаялыкларымы төсләренә чыккан, алар туктаусыз хәрәкәттә, төрле якка тәгәриләр, тиз-тиз генә йодырыклар да уйнап ала, кемнедер дөмбәслиләр, акыралар. Безнең юашлар арасында сүз китте: «Караклар икән тегеләр, уголовниклар!» Әләй! Болар янына лагерьга элəксəң... Кулешов өйрәткәнчә әкият сөйләп кенә котыла алмассың. Чит илләрдә йөреп рәхәткә күнеккән мәскәүле Ольгерт төймәләре кыркып алынган, корсагы шиңгәч биленә чак эләгеп торган тузанлы чалбарын бер кулы белән кысып тотып, икенче кулы белән борынында кунып ял итәргә теләмәгән күзлеген төзәткәли-төзәткәли: «И это... наши, советские люди?!» — дип шаккатып, сорашып торганы исемдә. Теге читлектәге совет җанварлары — сак колаклар, пычак күзләр — бу тилемсә сорауга игътибар иткәннәр икән! Затлы кубанка, билле көрән тун кигән, алап иренле дәү авызына ярты пот алтын сыйдырган берәү читлек рәшәткәсе аша тәмәкесенең хуш исен өреп: «Не горюй, папаша! Смерть Сталина всем нам принесет свободу!» — дип кычкырды... Күз алдына китерегез, безнең читлектәгеләр сискәнеп куйды, күз ачып йомганчы сәер тынлык урнашты... Йа аллам, таңда авызыбызны «Мәңге яшә, Сталин!» — дип ачып, кичен: «Син яшәсең, безгә рәхәт!» — дип авызны ябып, йөзәрләгән телләрдә аңа саулык-иминлек теләп ялварган бер чорда бүтән теләкләр дә бар икән! Егет-карак, үз сүзеннән генә түгел, үзе ясаган эффекттан канәгать булып, авызын ачып-ачып безгә алтын нурларын койды.

Читлектә озак тотмадылар, шөкер, чыгарга куштылар, каулап икенче катка алып менеп киттеләр, таныш йозак шаулап сәлам бирде, без кысыла-кысыла тынчу, эссе, парлы камерага барып тулдык. Анда халык шактый иде, яңалар ничек сыйганбыздыр, тәмәке төтене тыгызлаган камерада алтмыш-җитмеш кеше бардыр дип уйладым. Ике катлы такта сәкедә энә төртер урын калмаган иде, безнекеләр өйрәнелгән гадәт буенча сәке астына идәнгә үрмәләделәр. Карт-коры калтыранган куллары белән чалбарларны тотып торган чияләнгән бауларын чишәргә азапланып, ишек катында кукыраеп утырган парашаны чолгап алдылар, чаж-чож чәптерә башладылар, камерадагы «татлы» исләргә җылы бәвел исе аралашты. Сүз купты. Каян киләсез, кемнәр бар, нинди ят хәбәрләр ишеттегез?

Мин майор Столяров дигән исемне беренче тапкыр шунда ишеттем. Үзе бик еракта Минск төрмәсендә утырып калса да, легендасы Свердловскига килеп ирешә! Аның белмәгәне һич юк, имеш. Мәскәүдә әлләкем-әлләкемнәр белән аралашып тора, хәрби журналист, искиткеч «укыган кеше!», имеш. Шул болай дигән: «Якын араларда яңа кодекс игълан ителәчәк, анда сәяси тоткыннарга зур җиңеллекләр каралган, егерме биш елга хөкем ителгәннәрнең срогын кисеп, алты елга калдырачаклар, имеш!»

Минем бер урындарак озак таптануым күзгә чалындымы, яшьлегемә игътибар иттеме, сынык тешләре арасына чыланып изелгән тәмәке төпчеген кыстырган берәү сәкедәге урынын калдырып, яныма килде. Култыклап алды һәм сәкегә китереп утыртты. Янындагылар каш астыннан аңа карадылар. «Сыярбыз!» — диде ул җылы тавыш белән. «Син каян киләсең!» — диде сынык теш. Кемлегемне әйткәч, ул мине кочаклап ук алды. «Ә мин Иваново өлкә газетасының редакторы идем, ун еллык йөк тагып, монда озаттылар!» Ул бу сүзләрен мактанып, хәтта горурланып әйткәндәй булды. Ул миңа аны-моны әйтергә ирек бирмәде: «Эх, Мәҗит Рафиков та монда иде! Иртән этапка алдылар», — дип кат-кат кабатлады. Төрмә хәлләре, мондагы тоткыннар белән өстән-өстән таныштыра башлады. Кемнәрдер безнең әңгәмәгә кушылып китте, сүз уртакка әйләнде, мине иң гаҗәпләндергәне шул — монда зарлану, монаю, сыктау юк дәрәҗәсендә иде. Бөтенесе дә тәүге газаплы мизгелләрне кичергәннәр, төрмә камераларында әле ялгыз, әле ике-өч кемсә утырып, дөнья яңалы-

кларына зарыкканнар, ялгызлыктан шундый ишле гаиләгә килеп кушылгач, кинәт үзгәреш, көч сизгәннәр иде. Төрмәнең сасы камерасында да иркен сулыш алып була икән, билләһи! Минем студент булуым, яшь башымнан коммунистик режимның төп нигезен аңлый башлавым аларда — өлкәннәрдә, Власов солдатларында, бандеровчыларда, литвалы-яшелләрдә, зиндан баландасын икенче, өченче кат чөмерергә мәҗбүр ителгән мәхбүсләрдә — ниндидер яшерен өметләр дә уятты булса кирәк. Алар мине үз эшләренең дәвамчысы дип кабул итteләрме, һәркем жылы бер сүз әйтергә, кулымны кысарга тырышты. Ниһаять, йомык авызлар ачылды, хәзер һәр җөмләбез хөкем карары. Хәзер судьялар без үзебез, без үзебезне тәбегә китереп тутырган бөтен җәлладларны — власть иялә-рен хөкем итәбез, хөкем итүнең тулы хокукы безнең кулларга күчкән: һәркем үз уен, үз нәтиҗәсен әйтеп бушанырга омтыла, теге почмакта да, бу почмакта да тавышлар һаман көчәя, ныгый, тоткыннар мичкәдәге тозлы балыклар кебек кысылышып ятсалар да, дәррәү кычкырып көлеп җибәрәләр, кемдер кыска гына, әмма үткер такмак әйтеп ала. Параша капкачы самавыр өстендәге чәйнек кебек бии, бер ачыла, бер ябыла, ләкин ирекка чыккан кош кебек тантана иткән күнелләрне ул да боза алмый! Инде йокымсырыйбыз, онытылабыз дигәндә, өстән, сәке диварга барып орынган почмактан берәүнең тавышы пыскып ишетелде. «Сталин белми бу хәлләрне, әгәр белсәме?.. КГБның бөтен тамырын актарып чыгар иде, актарып! Лагерьга барып кына житик, һәммәсен бәйнә-бәйнә язачакбыз юлбашчыга! Минме? Күрсәтәм әле мин аларга! Танытам!» Пыскыган ят тавышны кинәттән берәү дә бүлдермәде, безне яклаган сыман булса да шөкәтсез аваз иде бу, ят тавыш. «Кем ул анда?» — дип сорады редактор калкынып. «Ходяш ул, майор», дип ачыклады берәү теләр-теләмәс кенә. Камера йокыга китеп бетмәгән икән, шау килеп күпләр күтәрелде. «Егерме бишне селтәгәннәр дуракка, ә ул һаман Сталинның артын ялый!» «Муенын борып буш башын парашага тыгарга кирәк!» — дигән өндәүләр яңгырады. Редактор бәхәсләргә нокта куйды: «Юк! — дип кычкырды ул. — Палачлардан зарланганда үзебез үк палач булмыйк инде!»

Шулчак ишек ачылды, вак-төяк төеннәр, ертык букчалар тоткан ун-унбиш кешелек төркем килеп керде. Арада Мәҗит Рафиков та бар иде. Хатирәләремнең иң читен, иң авыр ноктасына килеп життек. Булган, мине дошман итеп күрсәткән адәм уллары булган. Рәхмәтлемен, күп-челек, мине нидә гаепләүләрен белмәгән хәлдә, яклап чыккан. Нишлисең, барыбыз да заман корбаннары идек бит без! Кирәкмәгән сүзләр минем авыздан да ычкынган. Еллар үткән, хәзергедән торып үткәндәгеләргә яңа хөкем чыгарып, замандашларым алдында үтә сизгер, акыллы булып кыланасым килми. Төрмә юл-сукмакларында меңнәрчә кеше белән аралаштым, ләкин берәүгә дә рәнҗемим! Яхшылык та алдым алардан, яманлыгы да очрагандыр, һәммәсенә рәхмәтлемен: дөньяның дүрт ягын юлдашларым аша таныдым!..

1988 елның октябрь урталарында Пицундада гаҗәеп рәхәт, тымызык көнне Равил Фәйзуллин белән Кара диңгез яры ташларына баса-баса йөрибез. Равил көтмәгәндә мондый сорау бирде: «Мәҗит Рафиков сиңа рәнҗеп китте бугай?» Мин кыска гына: «Бик мөмкин. Рәнҗегәндер дә», — дип җавап бирдем. Сүзне озайтмадык, озайтырлык дәвам да юк иде.

Мин Мәҗитнең «ни өчен?» рәнҗеп китүенең сәбәбен белми идем, Равил да беләдер дип уйламадым, кызыксынмадым. Сорау алуларның берсендә Черек күлләге тикшерүчем: «Сез икәү шундый-шундый кыйсса сөйләшкәнсез. Кыйссаны Рафиков сөйләдеме?» — дип сорагач, «сөйләде», дидем дә имзамны салдым. Мәҗит хакында сынар кыек сүз әйтмәдем, әйтерлеге дә юк иде, чөнки Мәҗит Рафиков шикелле ялган патриотлар тормыш юлымда сирәк очрады. Ике сүзенең берендә Сталинга баш орды, Ленинны күккә чөйде. Боларын Черек күлдә чатнатып әйтеп

бирдем һәм кәгазьгә беркетеп куюларын да үтендем шикелле. Тикшерү тәмамланганнан соң да миңа «Дело»мны күрсәтмәделәр. Миңа кемнәр нинди гаеп ташлаганын да, ни өчен утырткаnнарын да 90 нчы елларга кадәр белмичәрәк йөрдем...

Ходаем шаһит, мин бүгенге көнгә кадәр Мәҗит Рафиковның ни өчен ябылуын белмим. Ул — 1943 елдан бирле КГБның түләүле агенты, минем үземне совет властеның зур дошманы итеп күрсәткән, шул сүзен күп санлы дәлилләр белән раслаган! Мин исә шул кешене ике сүземнең берендә: «Совет властеның чын патриоты!» — дип раслап барганмын. Мине кочаклап алулары, тагылып йөрүләре һәммәсе КГБ кешеләренең кушуы буенча булган икән. Теге, каһәр суккан кыйссаны да КГБ кешесе Михеев котыртуы буенча сөйләгән! Бу гамәлләрен телгә алмас та идем, еллар катлаулы, чуалчык, өметсез еллар иде, миллионлаган бәхетсезләрне кулга алганнар, КГБ юк гаепләрне үзе оештырган, һәйбәт кешеләрнең дә иманын бозган...

Котылып кайткач, икебез дә Казанда яши башладык, еш-еш очраштык, килгән шәптә Мәҗитнең өс-башы өтек иде, мин аңа авызымнан өзеп күлмәк-чалбар бирдем. Өйләнешкәч, хатыннарыбызны таныштырып, кунакка йөрештек. Мәҗит университетның китапханәсендә эшләүче ифрат уңган саф күңелле Наилә исемле кызга йортка керде. Соңра Наилә ханым университетның китапханә директорының урынбасары булды, эшлекле, уңган урынбасар иде! Улы туды Мәҗитнең, аңа Әнвәр исеме куштык, кечтинәгә[1] бардык... Берзаман ишетәм, Мәҗит астыртын гына икенче гаиләсенә дә «нигез салган» икән! Иң авыр чакларда үз янына сыендырган, өстен бөтәйткән, ач тамагын туйдырган Наилә ханымны шулкадәр мыскыл итүен безнең гаилә авыр кичерде. Икенче хатынга өйләнгәч, мин Мәҗит белән якыннан очрашуларымны кырт өздем. Сирәк очраштык, шулай да «Өч тәгәрмәчле арба» исемле, югары йорт шакаллары тарафыннан нык сүгелгән хикәя басылып чыккач, Мәҗит үз ихтыяры белән аны урысчага тәрҗемә итте һәм «Пычакның үткер йөзеннән йөрергә яратасың, Аяз!» — дип мине кайнар котлады.

Әле боларда искитәрлек гыйбрәтләр юк шикелле. Яшәп ятабыз, мин язам, китапларым чыга, пьесаларым сәхнәгә менә, арада бар яхшылары, бардыр уртачалары, Фатих ага Хөсни әйтмешли: «тавык кытаклаган саен алтын йомырка салмый!» Ә Мәҗитнең эчен көнчелек корты кимереп яткан икән... Тукай бүләгенә тәкъдим иткәч, Язучылар союзына миңа төрле яла яккан хат юллый бу! Инде Горький исемендәге бүләккә чират җиткәч, мине шакшы чиләккә манчый-манчый: «Бирмәгез аңа премияне!» — дип Мәскәүгә хат яза... Ул гынамы сиңа... Үләр алдыннан көндәлек дәфтәренә: «Безнең арага провокатор килеп керде... хикәяләр язып йөрүче кемсә... шул сатты мине!» — дип язып калдырган. Көндәлеген күргәнем, тотып караганым юк, әмма бу провокацион язмалар, гайбәтне үтә дә ярата торган берәү кулына килеп керәләр һәм ул сөенә-сөенә дөнья сасыта!.. Мәҗитнең туганы, якыннары миңа ябырыла. Ходам аларның хаталарын кичерсен!

Мин бик озакка кадәр бу Мәҗит аякландырган гайбәттән читтәрәк булырга тырыштым. Инде чик-чамам калмагач, КГБга барып: «Зинһар Мәҗит Рафиковның «Дело»сын Язучылар союзы билгеләгән вәкилләргә күрсәтегез, гайбәтләрдән аралагыз мине», — дип үтендем. Ркаил Зәйдулла белән Гариф Ахунов барып, табып, Мәҗитнең «Дело»сын башыннан-азагына хәтле бөртекләп укып чыкканнар...

Минем вафат кеше хакында авыр сүз әйтәсем килмәгән иде, үлгән белән тарткалашу егетлек түгел. Ләкин, илаһым!.. Үлгән кешенең сүзләрен тереләр күтәреп алып, аны мең тапкыр арттырып, көчәйтеп йөрүчеләр әле җирдә чакта үзем хаклык дип санаган сүземне бу романыма беркетеп китәсем килде. Мәҗиткә дә, аның шомлы гайбәтен байрак итеп

[1] Кечтинә — бәби туе.

күтәргән замандашларыма да бары тик яхшылык кына телим! Яман сүздән ходай сакласын...

* * *

Тагын этап, тагын конвой, тыгызланып тезелгән вагоннар арасындагы тыкрыктан безне куалар. Кар шыгырдый, этләр өрә, солдатлар явызлана... Ул арада вагоннар әнгерендә тагын бер шәүлә пәйда була: «Воры есть?» — дип кычкырып сорый. Конвой кемсәне күреп тора, ачуланмый, кумый, ул аны күрми дә шикелле. Чөнки күз карашлары безгә йотылган. Бу юлы безнең төркемдә «законлы бур»лар булмады шикелле...

Ул чакта надан идем, хәзер беләм, «законлы карак»лар дип аталган җинаятьчеләрнең өстен буын вәкилләре ил күләмендә берләшкәннәр икән, аларның штабы Колымада. Алар Рәсәйдәге караклар челтәренең бөтен җепләрен үзләренең мәрхәмәтсез кулларында тоталар. «Законлы карак»лар ныклы исәптә, аларның кайсы төрмәдә, нинди шартларда утыруын штабта дөп-дөресен беләләр, этапка куылган чакта аларга «күз-колак» тагылып китә. «Закондагы бур» чираттагы төрмәгә килеп керүгә, «җирле караклар» аны кайгырта башлыйлар. «Шәүлә-күләгә» аны вокзалда каршылый, артыннан ук «передача» китереп җиткерәләр. Азык-төлек кенә булмый анда, хәмер-коньяклар, наркотиклар да була. Төрмә хуҗалары мәшһүр каракларны сылу кызлар белән дә тәэмин итәләр. «Закондагы караклар»дан әҗерс мул төшә, эшләп тапкан акчамыни, алар сәдаканы мул яудыралар! «Закондагы бурлар» хакында этапта барганда күп сүзләр ишеттем, безгә яңалык арты яңалык яудырып тордылар. «Закондагы бур» бер чакта да эшләргә һәм чекистлар, милиция хадимнәре белән якын мөнәсәбәткә керергә тиеш түгел. Алар — «югары каста», алланың кашка тәкәләре, төрмә «аларның төп йортлары», иреккә чыгып алар әз-мәз һава үзгәртеп кенә яшиләр дә тиз үк төп йортларына әйләнеп кайталар. Төрмә алар өчен курорт, төрмәләрдә утырган меңнәрчә вак-төяк кесә караклары, өй басучылар, бер сүз белән әйткәндә «шушера» әнә шул бурлык аристократиясенә һич карышусыз хезмәт күрсәтә, юындыра, киендерә, ашата, кирәк икән битен, кирәк икән... күтен бирә. Йөзләгән, меңләгән сукыр черкиләр каста әһелләренең керфек селкенүенә кадәр күзәтеп торалар, алар ни кушса — шуны үтәргә әзер! Үтерергә боералар икән — бетте! Асарга дигәндә дә алар әзер. Кастаның кәефен бозып кара... Беттен! Илдә качар тишек сина калмас! Җиде кат җир астыннан сине табачаклар, җаныңны кыячаклар һәм шул сәгатьтә үк бу хәбәр штабка — Колымага барып ирешәчәк. Караклар дөньясы аяусыз, мәрхәмәтсез, явыз дөнья! Анда демократия була алмый, анда канлы диктаторлар, диктаторларның эресе-вагы хөкем итә...

Сөйләделәр, төньякта, лесоповалда, зур лагерь берләшмәсенә Мәскәүдән яңа начальник килеп төшә. Чокчына, тикшерә, яңа себерке үз көчен күрсәтергә карар кыла. Һәр лагерьда эшкә чыкмаучылар саны китерелгән, эшкә чыкмыйлар икән — план үтәлми дигән сүз. Ә яңа хуҗаны үзәктән боргычлап җибәргәннәр... ни, ни, үзең кара! Һәм бу лагерь бүлекчәләреннән «закондагы бурлар»ны бергә җыя һәм «эшкә чыкмасалар, планны үтәмәсәләр, фәлән-фәлән тәүлеккә карцерга ябарга», дип боерык язып элә. «Закондагы бур» карцердан куркамы? Лагерь кануннары аны анда да эзләп табачак, иркәләп, кадерләп кенә саклаячак! «Закондагы бурлар» Төньякта да алма-хөрмә ашап яшәргә күнеккән!.. Берзаман яңа начальникны вахтага, капка янына дәшәләр... Барса, ни күрә?.. Эшкә чыгарга тиешле караклар һәммәсе шунда җыелган, тез турларында ике куллап утын түмәре күтәреп торалар һәм шул түмәрләргә... күз алдыгызга китерә аласызмы? — «ирлек шәһвәтләре» эре-эре кадаклар белән кадакланган...

Яңа хуҗа үзенең кемнәр белән эш иткәнен шунда ук аңлаган!

Караклар кануннары каты, аяусыз, әгәр чын карак ул кагыйдәләрнең бер маддәсен бозса да, табигый рәвештә, «отошедший вор»га, ягъни «сука»га әйләнә. «Сученый вор» лагерьлардагы иң куркыныч кемсә, аның өчен дөньяда бер генә нәрсә калган: явызлык, явызлык, явызлык. «Караклар» белән «сукалар» арасында өзмәс сугыш дәвам итә, чын карак, «сука» кайда гына очрамасын, күз ачып йомганчы аны үтерергә тиеш. «Карак» «сука» белән бер һаваны сулый алмый!.. Әгәр «чын карак» ялгыш кына, искәрмәстән бергә утырып, табыннан ризык җыйса ул турыдан-туры «сука»га әйләнә. Шуның өчен чын караклар, «закондагы бурлар» үз әйләнә-тирәдәгеләргә якынаерга ашыкмыйлар, башта кемнең кемлеген җентекләп, явызланып тикшерәләр...

Күргәнегезчә, «закондагы бур»дан «сукага» җиңел генә күчүең ихтимал! Ә «закондагы бур» дәрәҗәсенә кире кайту өчен... ул чекистны, һич югында МВД офицерын үтерергә тиеш...

Бу белгәннәремне язаргамы, юкмы, дип мин озак уйландым. Нәрсә, ни теләдем мин?! Күп белүем белән мактанырга җыендыммы? Уйлый-уйлый мондый нәтиҗәгә килдем... Әйе, хәтер үткәннәрдән бик күп нәрсәләрне бикләп куя. Күргән-ишеткәннәрдән бик күбесе онытыла. Кайвакытта: «Нигә бу чүп-чарларны сызып ташлап, хәтеремне җиңеләйтмим соң?» — дип тә сукранасың... Ә хәтер күп очракта синнән дә акыллырак булып чыга. «Закондагы бур» лар системасының эшчәнлеге белән өстән-өстән генә таныштырган очракта да сез, зирәк укучыларым, аларның бөтен эшчәнлеге коммунистик дәүләт кануннарына нигезләнгән икәнен күргәнсездер? Шул ук аяусызлык, шул ук усаллык, бары тик югары кастаның кәефен саклап кына яшәү рәвеше, миллионлаган исемсез-хокуксыз коллар, «шушера»... Берчакта да кыл кыймылдатмаган «верхушка»ның рәхәт чигеп, кәеф-сафа корып яшәве... «Закондагы бур»лар коммунистлардан бер яклары белән генә аерыла, дип көлемсерәдем мин...

Әгәр яңа хуҗа килеп чыгып, большевикларча эшкә чакырып боерык бирсә, ата палач Сталин һәм аның яран-маймыллары вахтага утын түмәрләре күтәреп чыгарлар идеме икән?.. Һәм мин күз алдыма китереп елмаеп-куанып утырдым... Менә һәр күз сирпегән саен Сталинның канлы кубызына биегән кәҗә сакал Калинин... Аның янәшәсендә үк юаш булып күренергә тырышкан Ворошилов... Арты белән урындыктагы байтак помидорларны изсә дә юешлеген сиздермәс Анастас Микоян... Ах, «ирләкләрен» түмәргә кадаклап, адәм хуры итәсе иде дә... Вәт булыр иде җәза!..

Инде хыялны авызлыклап, кире борыйк та сәяхәтебезгә кайтыйк...

Безнең вагоннар Көнчыгышка ашыга, рельслар гүли, элек ишеткәннәр яңачарак эчтәлек белән байый, ә сүз-хәбәрләрнең өр-яңалары безне куып җитә. Каракларның Колымада чыгарган законнары бер тәүлек эчендә Көнбатыш төрмәләренә, Балтыйк буена да барып җитә, диләр, ышанырга туры килә. Төрмәара чыбыксыз телефоннар хәбәрләрне яшен тизлеге белән урынына китереп җиткерә. Гәҗит укымаган, журналлар күрмәгән, радио тыңламаган тоткыннар дөньяның тынын-сулышын белеп яшиләр диярлек. Майор Столяров легендар адәмчеккә әйләнеп бара, аның юрамаларын тоткыннар, яратып, бер-берсенә тапшыралар. Столяров һәркемгә өмет вәгъдә итә белә. Минем белемем сәгате-минуты белән тирәнәя, арта, хәзер без унар, унбишәр ел Магадан-Колыма тирәләрендә дуга бөккәннәр белән дә очрашкалыйбыз. Яңа сүз: илдәге барлык лагерьлардан сәясиләрне Казакъстан тирәсенә ташыйлар, бер тирәгә туплыйлар икән. Кызык! Кызык кынамы, кызык ярым! Черек күлдә тоткыннарны камерадан-камерага күчереп йөртәләр икән, моңа җавап табып та була. Ә болай, йөз меңләгән, миллионлаган сәяси тоткыннарның яңаларын да, искеләрне-стажлыларны да ниемә дип бер җиргә җыялар әле? Максатлары ни?.. Дөрес, коммунистлар режимыннан яхшылык көтү — иләк белән су ташу ул, ниятләре явызлыкта, бу юлы явызлыклары кая кадәр барып җитәр? Мин җавап көтеп стажлы, сакаллары төрмәләрдә

агарган агайларга карыйм. Алар миңа, иректән яңарак кергән яшь буын вәкиленә текәләләр. Ләкин әлегә җавап юк, без бер-беребезгә карашабыз да тынабыз. Көтеп карыйк, төрмә пәйгамбәре майор Столяровтан тагын нинди юраулар, фараз кылулар килеп җитәр...

Этапка чыгар алдыннан төрмә-вагонны шыплап-шыплап тутыралар да маневр паровозына тагалар. Паровоз тыкы-тыкы юлдан-юлга күчә, вагоннарны этә-төртә күчерә, арты белән вагоннарга шап итеп бәрелә, тоткыннар авып-түнеп китәләр, сәгатьләр буе йөри торгач, мингерәүләнеп хәлдән таялар. Бу юри шулай эшләнә, тоткыннар уңны-сулны онытсыннар, ориентирны югалтсыннар өчен, гомумән, адәм уларын кимсетү өчен үтәлә. Кинәт кузгалып, кинәт туктап, читлекләрдә тыгызланган тоткыннарның ачуын чыгаралар. Вагон конвойлары Черек күл сакчылары түгел инде! Үтә явыз, кансыз усал, дәһшәтле убырлар алар. Паровоз вагонны сөйри, чайкый, бәрә, шапылдата, аудара. Әллә шуңа күпләрнеең боендырыгы тотмый, кысталалар, бәдрәф сорала. Конвойга әйтеп кара син, авызың ачканга үкенерсең! Эт итәчәкләр! Хәтерләп калып бәдрәфкә аппарганда йозак белән калак сөягеңне сындырачаклар!... Күрше камерадагы берәүнең түзәр әмәле калмагандыр инде, тимер рәшәткә аша коридор идәненә чәптерде. А-а, моннан ары нинди гарасат купканын күрсәгез сез!..

Арлы-бирле үтеп йөргән, камерадагы хәлләрне күздән ычкындырмаган явыз конвоирлар бер мәлгә тындылар. Бу тынлык, сакчыларның күздән югалып торуы шул тиклем сәер иде ки, моңарчы шыпырт гөрләп юл кыскартырга тырышкан хәллеләр дә авызларына су капты. Коридор идәнендә теге бичараның «күлләвеге» күбекләнеп җәелеп ята. Шуннан ары ни булганын аңлашмый да калдык: коридорның ике башыннан, өстерелгән ау этләре сыман чабып, солдатлар чыкты да тимер-челтәр ишекны ачып ташлап, теге бәхетсезне сөйрәп чыгардылар. Бер солдат башыннан тотты, икенчесе аяктан, гәүдәсе белән коридордагы юеш өстеннән йөртеп ышкырга тотындылар, куркуыннан тын гына яткан кемсә бераздан тонык кына ыңгыраша башлады. Солдатлар алмашты, болары ятрәк кыландылар, бер күтәрәләр дә шап итеп идәнгә төшерәләр, әллә кыр-кырлардагы тимерләр чәнечкеле идеме, тегенең күлмәге аерылып, телгәләнеп бетте, ыңгырашу иңрәүгә әйләнде. Солдатлар алмаша тора, җәза дәвам итә, җилкә чиләнеп кан саркып чыкты.

Солдатлар тыелгысыз көлә, шаяра! Тән ярасын, сиптереп ага башлаган канны күргәч, мин янәшәмдәге юлдашларыма, күпне күргән, мең тапкыр сыналган сәфәрдәшләремә карадым. Исемдә ич, әлерәк кенә без үз язмышыбызны ачыклап, көчле бер йодырык булып йомарланган идек. Киләчәк хакында сөйләшкәндә бездән дә батыр, бездән дә кыю адәмнәр юк иде! Без үзебезне фикердәшләр, көрәштәшләр дип игълан иттек, горурландык! Әйе, әйе, горурландык! Без — Сталин режимының корбаннары! Без бу канлы режимга каршы көрәшкә чыккан ил егетләре! Тавышларыбыз көр иде безнең, бер-беребезне якларлык та, бер-беребезгә көчкуәт бирерлек тә, батыр идек без! Нигә хәзер, арабыздан беребезне таптап изгәндә, рәшәткәләргә ябышып, ачудан калтыранып шушы явызлыкны тамаша иткәндә нигә протест тавышлары ишетелми? Берәү башласын гына, дәррәү күтәрелеп чыгачакбыз! Сусыз калдырсыннар вагонны, тукмасыннар, ичмасам үзебезнең сарык көтүе түгеллегебезне, оешкан көчебез барлыгын белдереп, җәфа чигәрбез!.. Үзем шулай уйлыйм, ә үзем кысыла-кысыла чигенеп читлек стенасына кадәр барып җиткәнмен. Конвой гына күрмәсен, минем кысылган иреннәремне хәтерләп калмасын...

Дәшмәдек, канлы тамашаны сабыр гына, түзем генә карап тордык. Безгә курку, коллык кайтты. Тегендә, төрмә камерасында чакта чын идекме без, әллә безнең чынлыгыбыз хәзер ачыктан-ачык күренеме?.. Нигә качтым мин, ник постым? «Курыксаң, этнең күзенә карамаска тырыш!» — дип киңәш биргән иде берәү. Йөрәгем коридорга ташланып,

тегеләр белән сугыша башлардай булып тибә, беләк мускулларым кыймыл-кыймыл килә.

Канга манчылгач, һушыннан язгач, теге мескенне читлеккә кертеп ташладылар. Шул ук камерадан ике кеше чыкты, аларга сулы чиләк, чүпрәк бирделәр. Өлкән яшьтәге тоткын чиләккә капланып су эчәргә керешкән иде, артына лык иттереп китереп типтеләр. Алар карышусыз, сүзсез, тиз-тиз, ярарга тырышып, замат арасында коридорны юып, корытып чыгардылар...

## 2

*Подле меня будут люди, и быть человеком между людьми и оставаться им навсегда, в каких бы то ни было несчастьях не уныть и не пасть — вот в чем жизнь, в чем задача ее.*

Федор ДОСТОЕВСКИЙ

Безне Карабас дигән урынга, ниндидер яңа режим белән яшәячәк сәяси тоткыннарның «особый лагерена» алып баралар икән. Төрмәгә сер сыймый, ул каяндыр төртеп чыга дип әйткән идемме? Хак булып чыкты. Петропавел төрмәсенә безне таң яралганда, зәһәр суыкта китереп ташладылар. Вагоннардан төшерделәр, машиналар килеп җиткәнне көтеп, хәтсез таптанып тордык. Кыйналган теге бичараны иске-москы чүпрәкләргә төрештереп, алып төштеләр. Ике ягыннан ике кеше тотып тора, без аларны урап алып, җилдән саклагандай иттек.

Бу төрмәнең тәбәнәк, тар коридорына барып кергәч үк күңелләр сүрелде, монда безне көтелмәгән бәхетсезлекләр сагалый сыман тоелды. Юлда килгәндә шактый нык танышкан юлдашларымнан аерылдым, мине латышлар, литвалылар, молдованнар арасына китереп тыктылар. Белорус Василий Васильевич Терлецкий, молдован Леонтий Гаврилович Цурканнар белән шунда таныштык, моннан ары безнең язмышлар уртак булып китте.

Мин Петропавел күчеш төрмәсендә атнага якын булдым шикелле. Иң нык истә калганнардан шул булды: мин сары, каты кәгазь кулга төшереп, өйгә беренче хатымны юлладым. Лагерьдан килеп җитә алган хатларымны әни җыя барган, аларны кайсын кайда, мич арасында, лапас өрлегенә кыстырып куеп яшереп тоткан. Зур истәлекләр, мин аларны хәзер дә күз карасыдай саклыйм...

Икенче зур вакыйга, мин бу төрмәдә беренче японны күрдем. Квантун офицеры белән очраштым. Тәбәнәгрәк базык гәүдәле, японлыгы төсе-битенә чыккан бу елгыр кеше урысча әз-мәз пупаласа да, безнең беребез белән дә сөйләшми, эндәшми дә. Аның урысча аңлавын шуннан белдек, япон камерадашыбыз, чибәр чечен егете Мәһдигә бер-ике сүз әйткәли башлады. Беркөн кизү офицер иртәнге барлауга кергәч, төп-төз булып тегенең каршына чыгып басты да: «Когда переведете?» — дип сорады. Кизү офицер киерелеп кенә басып тора иде, японның таләпчән нык тавышын ишеткәч, кабалана башлады һәм: «Скоро, скоро!» — дип чыгып та китте.

Чечен Мәһди-Миша да сүзне сатып кына бирә, алай да минем мөселман, студент икәнемне белгәч, әз генә телен чишеп җибәрде. Шуннан белештем, японнар бу төрмәдә шактый икән әле! Аларны да этап белән Казагыстанга куалыйлар икән дә атна-ун көн элек бу төрмәгә китереп кертkәннәр. Эт-кош караклар утырган камерага тап килгәннәр болар. Караклар, гадәтләренчә, боларны «йолкырга», «чишендерергә»

тотынганнар. Сугыш күргән, урыска әсир төшеп кан-яшь йоткан, төрмә татыган японнар вак-төяк ыбыр-чыбырга баш биреп торамы соң?!.. Бик күп милләт улларын күрдем, кайбер халык вәкилләреннән читләшергә тырыштым, иллә мәгәр, япон кебек үзара дус, тату, ярдәмчел халыкны белмәдем. Бурлар моны искәрмәгәннәр, күрәсең. Рәсәйнең бүтән халыкларын ярты сүз белән җиргә чүктерә торган аждаһалар японнарның төз төбәлгән саллы йодрыкларыннан сәке астына тәгәрәгәннәр. Караклар тәҗрибәле, адәм сөяген сындырырга аларда йөз әмәл бар, пычак ялтыраган, тоташ стена булып японнарга ташланганнар. Надзирательләр җыелып, «хәзер японнарга күрсәтәчәкләр!» — дип, димәк, тамаша көтеп карап торалар икән... берзаман бурларның җимерек авызларыннан, ямьшәйгән танауларыннан кара кан ага башлаган... Японнарга ярдәмгә камерадагы өч-дүрт чечен егете дә чыккан. Алар берләшеп караклардан «җир күмере» ясаганнар. Җәнҗалның зураюыннан шүрләп, төрмә башлыклары японнарны төрле камераларга таратканнар. Бездәге япон һич кенә дә тынычлана алмый, иптәшләренең язмышы аны борчый, аларны берәм-берәм үтереп бетермәделәрме икән, дип шикләнә.

Мәһди-Миша. Уртадан калкурак буйлы, киек җәнлек кебек сак адымлы, иңбашларын чак кына алгарак чыгарып, үзен уртада яшереп йөри ала торган, җиңел хәрәкәтле, ап-ак йөзле искиткеч чибәр егет иде. Мәһдинең үз төрмәләре тикшерүчесен урындык белән бәреп имгәткәнен, соңра аны бер ай дәвамында тыела алмыйча дөмбәсләүләрен, карцерларда тотуларын, хәзер режимлы төрмәгә озатылуын безгә кадәр бу камерага урнашкан урыс сөйләде. Бу камерада гына түгел, Петропавел төрмәсенең бөтен почмакларында Мәһдинең кыюлыгын беләләр икән, «төрмә начальнигы да аннан сагая, батыр егет ул!» — дип сүзен бетерде урыс. Икенче көнне, чираттагы кизү офицер кергәч, Мәһди телгә килде, кайнарланып өч-дүрт җөмлә әйтте. Японны якташлары янына күчерүне таләп итте. Чыннан да, кичкырын японны бездән алып киттеләр. Мәһдигә: «Иптәшләре янына!» — дип аңлаттылар.

Ни әйтсәң дә монда тәртип мәрхәмәтлерәк — түбәнәк тынчу камералардан һавага алып чыгалар. Һава сулау мәйданы да шактый киң, иркен, мул яуган ап-ак карны мәйдан читенә нәни таучыклар итеп өйгәннәр. Бүтән камералардан да тоткыннарны чыгардылар, табышу-очрашу китте, мин дә арлы-бирле карана торгач, Авдеевны күреп алдым. Сөенешеп диярлек кул биреп күрештек. Авдеев тагын да арыкланган, киемнәре иске капчык кебек аннан да, моннан да бүселгән, сәләмәләнгән. Шанхайдан кайткан юаш лаборантка егерме биш елны такканнар. «Егерме биш ел!» — диде дә Авдеев күз яшьләрен кызганмыйча жылап җибәрде. «Оятлары юк... Күпме гомер калгандыр, иң авыры шунда — срокны кабердә тәмамларга туры киләчәк!» Түгәрәк ясап, мәйдан тирәли әйләнәбез. Ап-ак кояшлы кар күзләрне сукырайта. Борылышта, биек стена өстенә кош булып кунаклаган, ак толып кигән казакъ кызы — надзирательгә карап туктап калдым. Чибәр иде кыз, кус каратут йөз, сызылып яткан нечкә кара каш, борын почыклыгы да килешә тагын үзенә... Авдеев җилкәмә кулын салды һәм әтиләрчә йомшак тавыш белән: «Бозма күңелеңне!» — диде. Юатуы идеме бу аның, киңәш бирүе булдымы, аңламадым. Егерме өч яше тулып килгән егет чибәрлек алдында дулкынланмый нишләсен соң?

Команда тавышларына да күнегеп киләм, ишеткәч элеккечә йөрәк сикереп куймый. Теге килгәндә юлда кыйналган белорус (шул яктан булган икән!), иптәшләре йоклагач, чүпрәк-чапраклардан бау ясап асылынып үлгән икән. Мин бу хәбәрне ишеткәч, үтә нык борчылдым, аның үзәк өзгеч тавыш белән иңәлеп ыңгырашуы, конвой солдатларының кешнәүләре озак вакытларга кадәр колак төбемдә яңгырады.

Безнең вагонны тагын әрле-бирле кудылар, шуннан соң гына, безнең тәмам хәлдән тайганга инангач кына, бүтән вагоннарны тактылар. Без билгесезлек дингезенең ярларын эзләп тагын сәфәр чыгып киттек.

Бу юлы читлек-купеда без чамадан тыш ишле идек, ишек янында сыймыйчамы, кыймыйчамы торганнарның арык җилкәләрен тимер йозаклар белән кат-кат «үлчәделәр». Ничәү сыйдык икән, санамадым, санасам да оныткан булыр идем. Бара торгач, җилгәрү иләгендәге борчаклар сыман селкенә-селкенә ипләндек тагын. Этаплар турында күп язылган, алар бер-берсенә охшаганнар диярлек, шул ук сусызлык, ачлык, һава җитмәү, тын буылу, зар-моң, усаллану, үзара талашлар... «Юл газабы — гүр газабы»,— дигән татар. Бу дәһшәтле тапкыр сүзне һәркем, үз тәҗрибәсеннән чыгып кабул итә. Петропавел төрмәсе белән мине көткән билгесезлек арасы сәфәремнең иң кыен, иң авыр кишәрлеге булды. Бәхетемә, Казан төрмәсеннән биреп чыгарган селедкамны ашамаган идем әле, тамагым кибүдән бүтәннәр кебек үк интекмәдем, арабызда суга тилмереп, һуштан язучылар булды. Ни күрсәк тә без сүзсез, өнсез диярлек иде. Мескен белорус Казагыстан җирендә, тун каберда ятып калса да аның шәүләсе безне, шактый зур төркемне озата бара, куркырга кирәклеген секунд саен исебезгә төшереп тора иде. Тәүлек эчендә без уйсыз, нурсыз калган ярым хайваннар идек инде. Колбиләүчеләрнең Африкадан Америкага коллар күчерүе хакында әсәрләр язылган, аларда хак сүзләр күп. Безнең язмышны кара коллар язмышы белән янәшә куеп бастыргач кына тулаем аңларга була!

Вагоннан безне япан кырда куалап төшерделәр. Айлы, кырыс салкын төн. Тирләп, яныл-пешеп шушы шомлы төн кочагына керүгә суык патша безне куырып алды. Нигә, нигә суык патша һәрчак Рәсәй җәзачыларының союзнигы булды икән? Көч юк, хәл калмаган, өлкәннәр чак-чак аякларын сөйри, бер-беренә сеңеп килеп, әллә нинди рәвешләргә кереп каткан гәүдәләр язылмый, суык рөхсәтсез-нисез тамак төбен ялады, танаулар тыгылды, тоташ йөткерә, буыла башладык. Һәркем үз хәле белән онытылып, тирә-якка күз салырга көч-хәл калмаган икән, карасам, әнекәчем, безне тыгызлап солдатлар урап алган. Бишәрләп тезелергә команда булды, дәү якалы ак тун кигән карсак әче тавыш белән сүгә-сүгә безнең суык тешләгән сыек камырга әйләнгән төркемне сафларга тезде. Нидер көтәбез. Шулчак күзем күккә, безнең төркемнән дә тыгызрак тупланган йолдызларга төште. Нәкъ баш очымда, дәү сорау билгесе булып, Җидегән йолдыз яна иде. Инде ничә вакыт күккә карап, йолдызлар сафын инәнә чак-чак күтәреп торган карасу-күгелҗем офыкларны күзәткәнем юк иде. Йолдызлы күк тә тарайган, нәп-нәни төрмәдәй җир шары өстендәге бикле чатыр булып калган иде. Менә, менә, авыр, суык йолдызлар күккә ябышып тора алмыйча шыбырдап безнең өскә коелырлар кебек иде. Торабыз, дәшмибез, кемгә дәшәсең, конвой солдатлары киез итекле аякларын шап-шоп бәргәләгәндә безнең тишек-тошык ката-ботинка элгән аяклар әллә кайчан шыкранлап катты. Кузгалырга команда булды: «Шаг вправа, шаг влево, конвой стреляет без предупреждения!».

Шушы кыска гына иблис догасы моннан ары минем һәр адымымны, һәр хәрәкәтемне күзәтәчәк, мин бу явыз сүзләрне бик күп авызлардан ишетәчәкмен. Зур авызлардан, башмак иренле авызлардан, иренсез авызлардан, кечкенәләрдән, әмма һәр очракта да явыз авызлардан. Әле бу дөньяда иң күп яңгыраган вәхши җөмлә ирекка чыккач та төшләремә кереп йөдәтәчәк! Безгә сәер, ят тоелган боерык этләргә таныш, якын икән, алар бер-берсеннән узып өрә, сикергәли башладылар.

Димәк, бүген машиналар булмаячак, безне җәяүләп кенә куалап алып киттеләр. Барабыз, табан асларын тарткалап кар шыгырдый. Ютәллибез, абынабыз, сөртенәбез, егылмыйбыз гына. Әле бердәмлек, кардәшлек хисләре тәмам коелып бетмәгән, гәүдәләр егылам дигәндә бер-берсенә тотыналар. Арабызда яланкуллар шактый. Кар шыгырдавы көчәя, тоташ бер бимазалы тавышка әйләнә, күптән түгел явып киткән мамык карда безнең чуар-чуар эзләребез кала. Җидегән йолдыз! Безнең эз-иероглифларыннан син ни укыйсың?.. Без таптап бара торган ак мамык өстендә безнең күз яшьләребез кала. Керфекләрдә боз чуклары,

житү сакал-мыекларда боз сәйләннәре, бара-бара алар шыбырдап көелалар... Җилкәләрдә боз тараканнар! И күп алар, ишле алар! Алар балта сабы юанлыгы калган ботлар буйлап астан-өскә туктаусыз йөгерәләр. Кемнәрдер аһылдап артта кала башлады, уйсу җиргә төштек, ахрысы, кар тирәнәйде, урыны-урыны белән тезгә менеп житә, аяк киеме кунычларына тула, эри, кергән җиреннән чыкмый. Алдагылар адымнарын санап салырга тотынды, ләкин озак тын алырга ирек бирмәделәр, суык һаваны сискәндереп, тагын «дога» яңгырады. Кызык, конвой авызыннан усал сүз янгыры коя башлауга, этләр бердәм улап, өреп ана кушылалар. «Вперед, контрики! Вперед, недобитые фашисты!» Ул елларда бу команда да киң-киң Казагыстан җирендә, биек-биек Казагыстан күгенә менеп житәрлек итеп яңгырый иде.

Явыз конвой башлыклары — җирән, сипкелле, тәмәке төтененнән саргайган саргылт мыеклы, бүрәнә-бүрәнә ботлы, тырма куллы Рязань, Мәскәү урыслары гына түгел, үз чатырының төннегеннән бүтәнне күрмәгән төнтек, мокыт, тәбәнәк, кәрлә кыргыз, таҗик солдатлары да, дала түреннән, каяндыр адрессыз яклардан ишәккә атланып килеп чыккан күсә сакаллы, суырылган ач яңаклы, ярты чакрымнан әчегән тир исе аңкып торган казакъ әкәләре дә безнең турга килеп житкәч, арык ишәкләрен бер читкәрәк куып, муеннарын суза-суза: «Жубный фашист, жубный фашист!» — дип чәрелдиләр иде.

Бәрәкәтле дә, аяусыз да Казагыстан күкрәгенә кутыр булып яткан исәпсез-сансыз лагерьлар, ил кадерен белмәс читтән килеп тулган килмешәкләр, ярты дөнья күген каплаган биек-биек коймалар, җирне-күкне көчләп тоташтырып аркылы-торкылы яткан чәнечкеле тимер чыбыклар, еллар буе дәвам иткән ялган пропаганда үз эшен үтәгән иде инде: җирле халык номерлы тоткыннарга җирәнеп, нәфрәтләнеп карый. Очраганда бу нәфрәтне чыгармый каламы соң халык?! Бәлки бу чиксез лагерьлар аларның гадәт-йолаларын, яшәеш төсмерләрен, гомернең гади агышын бозганнардыр, өер-өер маллар рәхәтләнеп утлап йөргән далаларын тартып алганнардыр. Большевиклар булдыра алмаган эш юк, барысы да булгандыр... Шуңа ахрысы, лагерьлардан качып чыга алган бәхетсезләрнең юлы чикле, җирле халык эзләшә вә тотып бирә аларны, тотылган һәр тоткын өчен биш йөз тәңкә акча белән бер капчык он бирәләр. Әз мал түгел! Ә совет кешесенең кайчан вә кайда тук булганы бар?!

Боларын мин соңрак, совет җәза системасының «академиясен» тәмамлаганда белдем. Әле без башлангыч классларда акыл-гыйбрәт җыябыз. Юл, бигрәк тә төнге юлсыз юл, әчпошыргыч озын һәм җәфалы була... Ниһаять, катып-калҗаеп, биек-биек такта койма белән уралган ихата каршысына килеп сөрлектек. Койма баганалары башында тунган кошлар булып сүрән һәм моңсу лампалар яна. Күз бераз күнеккәч, аердым: каршыбызда биек-биек капка, ул бөтен иңенә-буена чәнечкеле чыбыклардан ясалган бизәкләр таккан иде. «Сөйләшмәскә!» — дигән команда этләрне сөендереп яңгырагач, телләр дә «төрмә»ләренә — теш артына кереп постылар. Өшеп, кәкрәеп беткәндә конвойның мыегын чуалтасы килми иде. Солдатларның карабин очлары юкка гына ялтырамыйдыр әле!..

Ике солдат ике яктан торып капканы киереп ачтылар, тәбәнәк бинадан чыгып, бер офицер сулга басты һәм кулындагы бер өем кәгазьләрне бияләе белән кагып тигезләде. Офицер бәрәм-берәм кәгазьне тартып чыгара да кычкырып укый. Латыш, литва фамилияләре колакка ят, офицерның белем чамалы, боза, боза да авызын тутырып безнең өскә бер лакан мат чәчә. Шуннан барысы да аңлашыла... Кытай, япон, немец һәм дөньяның бар милләтләре фамилияләрен урыс теленә күчерер өчен өч хәрефтән торган бер сүз житкәнен мин шунда аңладым! Фамилиям чыгуга алгарак авыштым да үз исемемне, атам исемен Казакъстан җирендә беренче мәртәбә урысча яңгыраттым. Әти, ишеттеңме икән?! Кергәч тә уң кулда караңгы, озын барак. Әчтәрәк ач тимсахлар булып

әз-мәз яктылык элгән шактый күп корылмалар шәйләнде. Утлар ач тимсахларның күзләре булып, безгә янап елтырыйлар иде. Бер җирдә тавыш ишетелми, хәрәкәт сизелми. Әллә кешесез, буш лагерьга килеп каптык инде? Баш очымда диярлек тавыш ишетеп, капылт күтәрелеп карадым, араларын кырык-илле метр калдырып сак вышкалары калкынган икән, иң якынында култыкса аша иелеп, пулеметын безгә төбәп ике солдат басып тора.

Һәрнәрсәнең азагы була, безнекеләр дә капка авызыннан кереп беттеләр, формулярлар бер офицердан икенчесенә, лагерь вәкиленә күчеп, безне Җирнең шушы шомлы ноктасына «пропискага керттe». Без Карабас лагереның яңа кунаклары булып чыктык. Бу юлы безне тезеп маташмадылар, тун эченә кереп чумган берәү җылы бияләйле кулын селкеде дә: «Вперед, контрики!»— дип үзе артыннан чакырды. Караңгы барак ишеге ачылды, карлы-бозлы аякларыбыз белән идән такталарын төя-төя, шапы-шопы килеп, эчкә үтеп кердек. Алданрак кергәннәр сукыр ут янган коридорга чыккан ишекләрне ачып карый башладылар, мәхшәр купты, кем кайда урын таба алса, шунда барып ауды. Без, әз-мәз күз ияләнгәннәр, бер ишеккә сыйдык. Җылыныйк дисәк, суыкны әллә үзебез иярте кердекме, әллә ул туймас тамак-ачәрвах безне көтеп торганмы, бүлмәләрнең бөтен почмакларыннан суык тешен ыржайтып карап тора иде. Сузылабыз — кар! Почмакларны кар сарган, түшәмдә дә ап-ак бәс!.. Безне бер чакта да ягылмаган баракка кертеп бикләгәннәр икән. Кычкырыр идек — тавышыбыз юк, ишек кагар идек — куллар күшеккән, шакшок килеп, йодрыкларны җиң эченнән күрсәтеп, тамак төбенә бәялгән сүгенүләребезне йотып җибәреп, как сәкегә тыгызланып яттык. Иртән уяна алмадык, яртыбыз суык тидереп чирләде...

Хак булды майор Столяров: Минск төрмәсеннән торып безнең Карабаска, соңыннан бөтен дөньяга яңгыраган күчеш төрмә-лагерена илтәчәкләрен дөп-дөрес юраган икән. Карабаста без шактый тоткарландык әле, лагерь «күчеш» дип аталса да, ни сәбәптәндер, безне ашыгыч таратмадылар, бригадаларга бүлделәр.

Карабас — минем өчен белем учагы, гыйбрәтләр дөньясы, караңгы көнелемне яктырткан якты кояш булды. Гомерем буе мине газаплаган сорауларга тулы җавапны мин шунда таптым. Минем алдагы тормышыма көч-гайрәт биргән җир улларын, Хәбир Зәйнуллин дәвамчыларын мин монда очраттым. Бөтен дөньядан җыелган фикер ияләрен, үз халыкларының уңай вә кире сыйфатларын туплаган милләт вәкилләрен кошлар очып кермәс биек коймалар артына бикләсәләр дә, тугры уй-фикергә бикләр бармыни?!

Алтынчы бригадага эләктем, бригадирым куна җилкәле, калын имән кискәседәй гәүдәле, кәр үгез муенлы, тәңкә-тәңкә куе кызыл сипкелле, бакыр чыбыклардан җыелган тыгыз чәчле, егерме биш-егерме җиде яшьләрдәге бандеровчы Николай Хохун иде. Яшьләй урысларга каршы көрәшкә катнашып китеп, әз-мәз дары исен дә иснәгән, кан төсе белән дә таныш бу авыл егете үз иленнән Казакълар дөньясына килеп җиткәнче байтак казаннарда кайнаган, Рәсәйнең мут каракларь, көяз бурларыннан аңа да килбәтсез гадәтләр йога башлаган, хәзерендә, тотрыклы сәясиләр арасына килеп кереп, үзен табарга, үзен аңларга тырышкан мәле иде. Бригадирларның күпчелеге бандеровчылар, яшьләр, чаялар, Бандера гаскәрләрендә булулары белән мактаналар, урыска баш бирергә бер дә исәпләре юк иде. Бригадаларның күпчелегендә западниклар — украин, белорус, поляклар, арага Рәсәй халыклары вәкилләрен дә, сыек шулпага тәм кертер өчен борыч сипкәндәй, сибеп таратканнар иде.

Өч-дүрт көн танышып, үксез баладай читтән-чоттан каранып йөргәч, мине вагонканың икенче катыннан бик сирәк кенә төшә торган карт грузин Александр Хуродзе чакырып алды. Үзем якынайдыммы, сизми калдым, мин аның янына «икенче этаж»га үрмәләдем, без күңелле генә сөйләшеп киттек.

Ашханәгә сирәк кенә барып кайта торган бу какча тоткын бүтәннәргә бер тамчы да охшамаган иде. Елмаюын беркемнән дә яшермәгән, үзалдына сүзсез утырганда да якты чыраеннан, тәсен жуя башлаган акыллы күзләреннән, аксыл-какча гәүдәсеннән тоташ нур агыла иде. Бу кешене ачулы-кырыс, моңсу-сагышлы итеп күз алдына да китереп булмый. Гәрчә Александр Хуродзе ун еллык беренче срогын Колыма, Магаданнарда «от звонка до звонка» тутырып куйган. Иртәгә чыгасы дигән көннең кичендә аны чакырып алалар да тагын ун елга хөкем ителүе хакында карар тапшыралар. Хуродзе ун ел дәвамында совет чынбарлыгын шулкадәр өйрәнгән була, «нигә?» дип тә сорамый... Ул үтәкүренмәле арык, теге ун елында бер тапкыр да кояш күрмәгәндәй тәне зәңгәрсу-көмеш төсенә кергән, дүрт почмакланган беләкләрен җиң генә җыеп тора төсле. Чәче, сакал-мыеклары ап-ак, дөнья гайбәтләрен ишеттермәс өчен колак тишекләренә кереп тулган эре-эре төкләр дә агарган. Бер күргәндә үк Хуродзены дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичкән гөнаһсыз фәрештә дип кабул итәсең. Картларның яшьләргә тартылуы, бар булган хәзинәләрен сонарганчы яшьләр белән уртаклашырга тырышуы табигый хәл, әмма мине Хуродзе аерата нык яратты дисәм дә, арттыру булмас. Мин аның үзе белән мең нужа күреп, кыегаеп-бөргәләнеп беткән кәтилүгенә тутырып, ашханәдән аш алып кайтам, соңыннан аны юам, әмма безнең якын арадашлыкның сере ул түгел иде. Хуродзе агай үз башыннан кичкәннәрне тәмләп сөйләргә ярата иде. Грузияне сагынып сөйлиме, Колыма-Магаданнарны каһәрләп искә аламы, бер башыннан кичкән мең гыйбрәтләрне тезеп китәме — аның тел төбе бер ноктага барып йомгаклана: совет власте мәңгелек түгел, ходa шаһит, ул чәнчелеп барып төшәчәк, дөнья иркен сулыш алачак, бары тик коммунистлар хакимияте генә халыклар иреген буып тора, аларның азатлыгын чикли.

Мондый фикерләрне Казаннан чыкканнан бирле ишеткәлим, без — Зәй ягы балалары Гурий Тавлин, Гәрәй Гәрәевләр дә — шундыйрак уйларга килә-китә яшәдек, ә монда сүзне аксакал, мең сынаулар аша үткән, бик күпләрнең иманын үзенә йоктырган, һәр сүзен айлар-еллар буе акылында әүкәләп йөрткән пәйгамбәрдәй адәм әйтә! Әйтәгенәме, сөйли башлаганда чак-чак ишетелгән зәгыйфь тавышы берзаман яңгырый башлый, секция почмакларына сарган тоткыннар әкрен-әкрен аның тирәсенә тартылалар, без гипнозланган төсле оеп-оныталып аның кискен дәлилләре, Совет властеның ни өчен чәнчелеп төшәргә тиешлеген исбатлаган кайнар җөмләләрен күңелләребезгә суырып алып тыңлыйбыз. Икәүдән-икәү калганда мин аңардан: «Чыннан да чәнчелеп төшәчәкме?» — дип сорыйм. Ул тирән ышаныч һәм ачыктан-ачык горурланып: «Ә ни өчен мин монда утырам? Без барыбыз да аны бәреп егуга өлеш керткән көрәшчеләр!» — дип кабатлый.

«Совет империясе таркалачак!» — диган, ул вакыт өчен гаять дәһшәтле, зур эчтәлекле сүзне беренче мәртәбә мин аның авызыннан ишеттем. Ул совет власте Грузиядә кылган явызлыкларны, Сталинның үчкә сусаган кансыз бәндә икәнлеген, үзе күргән яки ишеткән чын мисаллар белән ышандырырлык итеп сөйли иде. Мин аңа тәмам гашыйк булдым.

Төрмәдә көннәр озын, төннәр аңа караганда да озынрак. Ятасың да, түшәмгә карап, уйлардан чыгу-чыгәсең... Хуродзе агайны күрмәгәндә дә мин аның барлыгын тоеп, сүзсез генә сөйләшеп ятам. Этапта килгәндә кыйналган, соңыннан үз-үзенә кул салган белорус хакында уйлыйм. Үземне, Хуродзены, һәлак ителгән ул бичараны хәзерге аң үлчәвенә салып-салып карыйм. Нигә Хуродзе төрмәдә утыра, ә тере җанны изүче җәлладлар иректә?.. Хуродзе иманын яшереп сакламый, иманын һәркемгә ачып сала, уртаклаша. Совет власте шул үтәкүренмәле бәлтерәгән карттан курка!.. Курка икән, димәк ки, үзенең хак түгеллеген чамалый... Хак түгел икән, нигә бер чәнчелеп төшмәсен ди ул?..

Эх, ул сөйләгән гыйбрәтләрне язып-теркәп барган булсам... Тәүбә, тәүбә, кая ул, язып-теркәп барсам, гыйбрәтләре аның да, минем дә

башыма җиткән булырлар иде. Сталинны, совет режимын күрә алмаган, большевизмнан нәфрәтләнгән беренчеләрдән берсе булды ул изге грузин...

Яшьләр бер бандеровчылар гына түгел, арабызда урыс егетләре дә бар иде. Танышып киттек. Төрмәдә һәркем — гыйбрәтләр хәзинәсе, тере тарих ул!

Әйе, сугыш елларында колхозларга җитәкче булып йә ярым гариплар, аксак-туксак, бөкере-кәкереләр, йә булмаса үтә хәйләкәр, совет властен да алдый алган оятсызлар калды. Колхоз рәисе ул елларда чикләнмәгән власть иде! Сугыш елларындагы власть вәкилләре хакында әле татар әдәбиятында әсәрләр язылмаган. Миңлекамаллар, Айсылулар — миф алар, төпсез әкият. Авылның канын туйганчы эчте рәисләр, райком, райбашкарманың карарларына табынып крестьянның җанын ашады. Бигрәк тә чибәр хатын-кызлар, яшь киленнәр, киленчәкләр, толлар алар аркасында ничек җык күрде! Күпме кызларны бозып мирга чыгардылар шул сасы көзәннәр. Күпме сылуларның алсу күкрәкләрен изделәр?!.. Сугыш алдыннан кызлар әйләнеп тә карамаган маңка сарыклар, ханнар, патшалар булып калып, учларында унар хатынны сытып тоттылар...

Һәм мин шушы Карабас лагеренда моңарчы белмәгән олуг, тарихи вакыйгага тап булдым. Безнең бригадада колхоз рәисләрен үтереп, төрмәгә кергән өч егет бар иде. Митя Шорохов белән Василий Гостев икәүләшеп бер рәисне йомдырганнар. Миша Пермяков ялгызы бер рәиснең күкрәгенә ау мылтыгыннан атып чәнчелдергән. Нигәдер без тиз арада аралашып, якынаеп киттек. Митя озын буйлы, аксыл чырайлы, озын куллы, торна тезле, җеп иренле егет иде. Карыйсың, әле генә күренеп торган күз алмалары эреп югала да ул сиңа күз агы белән генә челәеп тора. Митяга туры карап та булмый, карашы авыр, куркыныч иде егетнең, әләй! Аның янындагы Вася, киресенчә, юкка да шаркылдап көлеп җибәрә торган, наянлыгы, бушлыгы өчен «Чума» кушаматы тагылган мокыт кына Себер баласы иде. Икесенә дә террор өчен егерме бишәр ел каты режимлы лагерь биргәннәр, әмма бу ике үтерүчене янәшә бастырсаң, рәиснең чүпрәк башына җиткән тимернең кем кулында булуын чамалау читен түгел! Вася-чума шул тирәдә юргалагандыр, мөгаен! Баракта бер-бер ыгы-зыгы туа башласа, Вася эһ дигәнче шунда барып җитә. Ыгы-зыгыларны алдан ук сизә торган, кысылырга яратучы борыннар була ич!

Миша Пермяковны да мин сәер бер ярату белән яраттым. Ул кабартма шешенке йөзле, симез, салынган күз кабаклы, күперенке сусыл иренле, авыр санлы, тотышы-кыяфәте белән арт аякларына баскан көчле аюны хәтерләтә иде.

Боларның өчесенең дә әнкәләрен колхоз рәисләре изгән икән. Хатыннар яшь, көчсез, ирләр сугышта вафат, тормыш авыр, рәискә каршы тора аласыңмыни?.. Өйгә килеп йөргәннәр сасы көзәннәр, төнлә-төнлә киләләр икән дә яшь хатыннарны анадан тума чишендереп, тезләндереп, исерек баштан аллы-артлы мукиләр икән. Малайлар исә аларның кәмитләрен, кыланышларын мич башыннан яки гөлбәчтән тамаша итеп торганнар. Тешләр кысылган, күз яшьләре көзге яңгыр булып аккан.. Рәисләр чыгып киткәч, тавыш күтәргәннәр малайлар, холыксызланганнар, мәктәптә укытучыларына әләкләп караганнар... Әниләре җылый-җылый юаткан, укытучылар бармакларын иреннәренә аркылы куеп: «Тс-с, балалар, тс-с!» — дип үгетләгәннәр, дәшмәскә өйрәткәннәр.

*Дәвамы бар*



# Рахмай Хисмәтулла

**Мин гомерем буена чорга сыеп бетә алмадым. Замана мине — болай да үсендерүчесе булмаган, кыюсыз, кире бер малайны — һәрвакыт тырнап, тарап, кыргычлап кына торды. Юлымны мин мең «ярамый»лар, аптыраулар, шикләнүләр, үз-үземә ышанмаулар карурманы аша ерып бардым.**

**Радиодан тапшырырга дип шигырьләр укысам, тавышым артык ярсулы, бунтарь булу сәбәпледер, аны һәрвакыт кечерәйтеп, кысып бирделәр.**

**Шигырь басарга тәкъдим итсәм, үземә иң ошаганнарын төшереп калдыралар, бик теләгән кереш сүземне яисә шигырьләрнең астына куелган датасын сызып ташлыйлар иде.**

**Төрле мөхәррирләрнең теләк-зәүкына, фасуны-карашына ярарга тырышып, инде мин күптән бер мәхлук хәлендә торып калырга тиеш идем.**

**Шөкер, замана теләгәнчә шомарып бетмәдем, ә җиде кат томан артындагы мәңге армас романтик сыман үзем булып калдым.**

**Сизәм, инде кулга иләштерелеп бетмәгән шәхесләр заманы килде бугай...**

## Су ялваруы

Минме сезгә хезмәт итмәдем, кешеләр?!
Мин су-лыш бирдем,
 су-сын бастым,
 су-сыл иттем,
Юдым сезне, тазарттым, иркәләдем,
Назладым сезне, хушландырдым,

---

Рахмай ХИСМӘТУЛЛА (1934) — *шагыйрь, прозаик, публицист; «Яшенле тау», «Ак догалар», «Сусау» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

Агымсуларымда
агуларыгызны агыздым.
Инде хәзер Су була торып,
үзем пычрандым, шакшыландым,
тәмам агуландым.
Ишетәсезме?
Мин су-кра-нып яшим,
су-лкыл-дап елыйм —
Су-са-дым чисталыкка,
ничек чистарыныйм?!
Мин — Су, тончыгам,
су-лы-шым кысыла,
Су-кыр булмасагыз, коткарыгыз!

*1990*

* * *

Елап калды гомер юлларымда
Сыйпап үтә алмаган гөлләрем...
Мине туя, сөя, күрә алмыйча
Минсез акты минем көннәрем.
Бик күп сулар тәнем татый алмады,
Зәңгәр күкләр — иреннәремне.
Әйтегезче,
Далаларда мине сагынып йөргән
Алсу таңнар күренмәдеме?
Әй гомернең зая үтүләре,
Эчелмәгән кояш рәхәте!
Читтә калдымыни ходай биргән
Бу дөньяның саф мәхәббәте?!
... Бөгәрләпләр куйды җаннарымны
Бавырларга төшкән кайгылар.
Шатлыкларым дөрләп яндылар да
Өсләремә көлләр яудылар.
Шул юата, ахры, беркайчан да,
Явыз иде, диеп әйтмәсләр:
Хәсрәтләрдән алда йөри җанда
Әйтелмичә калган рәхмәтләр.

*1990*

## Чишеп булмый торган төеннәр...

Каеннарга зирек пар түгел лә,
Тик каенга каен пар икән.
Йөз ел буе тартып интексәң дә
Очы чыкмас хәсрәт бар икән.

Зирек калыр үзенең сазлыгында,
Каен менәр йөгереп тауларга.
Менәлмәсәң син дә шул тауларга,
Кайгың әзер сине яуларга.

Шул кайгылар Хөкемендә калган
Мәҗнүннәргә хәер бирсеннәр.
Син юк дисең, җаным, бар икән шул
Чишеп булмый торган төеннәр.

*1992*

## Аерылган кеше зары

Киләсе кешеләр, килмәдегез!
Ни хата эшләвегезне белмәдегез.
Йа, Раббым, бу фәкыйрь бәндәгезнең
Эче тулы зар иде — күрмәдегез.
Миндәге тормышны теләмим сезгә,
Сарылар кунмасын йөзегезгә.
Бу нинди бәхетле икән дип карап,
Соклансыннар хәтта эзегезгә.
Тынычлык телим, гел шат яшәгез,
Коелмасын хәтта чәч бөртегегез дә.
Инде кар бөртеге булып яшьләнеп,
Эрүче мин булырмын керфегегездә.

*1982*

* * *

Зар белән тулды җаным, кемгә түгим?
Бурычка баттым тормышта, кемгә түлим?
Адаштым кереп уй карурманына,
Һич урын табалмыйм бер җаныма.
Кая элекке көлүләр, өметләр, кем алдады?
Күрче: элек кояшлы йөздә тамчы нур калмады...
Кул сузам ярдәм сорап: бирер кайсысы?
И юләр, сузма кулыңны — һәркемнең үз кайгысы!

*1982*

## Соңгы очрашу

Яңа күзен ачкан зәңгәр гөлем,
Сине сөеп, ахры, ялгышам.
Ә шулай да йөрер юлларыңа
Хисләремнән учак кабызам.
Минем гөлләр алтын көзгә бага,
Мин — кичке моң, ә син — язгы таң.
Изге кояш булып, юлларыма
Чыгар идең микән, чакырсам.
Зая үтте яшьлек минутлары,
Бу очрашу килде, килде соң.
Ишетәсеңме, ятып офыкларга,
Якты таңга үрелә кичке моң.

## Ник мин тал бөресе түгел...

Әверелдә арган йөрәгем
Кайгының карасына.
Таллыкларга кереп чумдым,
Таллыклар арасына.
Кунасы килде талларга,
Кунасым, тибрәнәсем,
Тыныч, сабыр таллар телен
Беләсем, өйрәнәсем.
Әверелсәгезче, талларым,
Җаным сердәшләренә,
Серләшериек бергәләп,
Чумып күз яшьләренә.
Яз тулы бал бөреләрс
Кага җәй ишегенә.
Ник мин тал бөресе түгел,
Ник бары кеше генә?..

*1984*

## Исемә төшсә...

*Фазулла абыема*

Кызыгы юк ла дөньяның — мәгънәсез:
Була бу күңелем буш һәм сай чак.
Читенсенәм үзем дә шулчак —
Исемә төшсә нурлы балачак.
Дөньяда юктыр кебек мәхәббәт,
Бар күңелләр дә каты таш кебек.
Яңадан оялам үземнән —
Төшсә исемә садә яшьлегем.
Юк кебек дөньяда изгелек,
Һәркем карый күк тик үз карынын.
Йомшарып китә иманым һәм җаным —
Исемә төшсә туган авылым.
И авыр бу дөнья, терәкләр юк,
Ялгызлык бәгырьне бик кисә.
Елавым, сыкравым чүп кенә,
Ятим әтием исемә төшсә.
Дөнья ком, кешеләр туң, гомер шом...
Ни мәгънә?! Бу гомер бик кыска.
Мәңгелек тоелам мин кинәт:
Газиз әнием исемә төшсә.

*1974*

## Күзгә рапсодия

Туры килдең нигә, бәгърем,
Гомер азакларына.
Салдың син чиксез-ахырсыз
Сөю газапларына.

Сине уйлап тугайларда,
Урманнарда югалдым.
Сүтә-сүтә йомгагыңны
Җепләреңә чуалдым.
Син җанның илаһи сере,
Күккә ашкан минуты,
Яшәүнең соңгы мәгънәсе,
Гомернең соңгы уты.
Сүндерерлек сулар да юк,
Су үзе янып чыгар.
Җиргә китсәм, бу утлардан
Җир янмый ничек чыдар?
Безнең йолдыз мәңгелектә
Күктә янып торса иде.
Җирдә калган тәнебезнең
Кабре бергә булса иде.
Мин бу җырны кешеләргә
Чыгармам дигән идем,
Әрнү-газапларыма да
Чыдармын дигән идем.
Ярсуларым, шашуларым
Сыймады йөрәгемә.
Җыр булып очып чыкты ул
Фани җир йөзләренә.
Бар икән кайнар яшьлеге
Гомер азакларының.
Юк икән чиге-ахыры
Сөю газапларының.

*1982*

* * *

Бәйләп куйды җанны, суырып торды
Мең борчуы шаулы каланың.
Юкса бит мин табигатьтә туган,
Табигатькә гашыйк баламын.

Таш капчыкта ятып үләннәрнең
Серләшүен күрми каламын.
Юкса бит мин үләннәрдән туган,
Үләннәрдә үскән баламын.

Тыңлый алмый калам яфракларның
Садә моңнар сыңрап үскәнен,
Көлеп яуган ләйсән яңгырларны
Туфракларның сусап эчкәнен.

Хәйран калып күзәтә алмый калам
Иделләрнең җәйрәп акканын.
Ишетмичә калам тып-тын таңда
Каеннарның бөре атканын.

Сагынылган дуслар янына да
Сугылалмый калам яратып.
Нишләргә дә белмим, яшәвемне
Язмыш җиле куйды таратып.

Анда барсам, монда эшем кала,
Монда калсам, анда — сагышым.
Җәсәдемне сибеп бар дөньяга —
Барысын да тигез тояр өчен —
Сер Иленә күчеп барышым...

*1991*

* * *

Кадим исемем аркасында
Мин күп еллар җәфа күрдем.
Мулла кушкан булса да аны —
Читенсенеп яшереп йөрдем.

Кызга ничек урыс сөймәс
Бу исемне әйтмәк кирәк?!
Әнә Роберт, Эльс, Гертлар
Гел пачутта йөрде күкрәп.

Сынды Иблис... Җиңде уң көч!
Түбән исемем кабат яна.
Җир шарында көне-төне
Намазларда кабатлана.

Нинди исем! Яңгырашыннан
Җанга-тәнгә рәхәт тула.
Сөенеп әйтәм кызларга да:
— Рәхмәтулла! Рәхмәтулла!!

*1992*



**Сафуан**

**Мулла Гали**



## Биздерсәләр туган җиреңнән

*(Шул исемдәге шигъри повестьтан өзек)*

...Зәңгәр күктә март кояшы көлә,
Дәрте ташып тора, күрәсең.
Ә якында ак-кызыл чәчәкләр
Күмеп киткән өйләр тирәсен...
Кашка айгыр кебек поезд чаба,
Тимер юлдан чаба кинәнеп.
Бер вагонда барган
Үзбәк дуслар белән
Сөйләшүләр китте көйләнеп:

— Татар халкы — гыйлем халык,—
ди бер агай,—
Мин үзем дә Казан басмасын
Укып, белем алдым мөгаллимнән,
Сөйләп торасы юк башкасын...
Хатыным да минем татар кызы,—
Анардагы пөхтә-чисталык!—
Кулларыннан асыл гөлләр тама,
Каян килгән андый осталык...
Үзе эшчән, яшен кебек җитез,
Йөзендә нур — тулган ай кебек.
Ачуым бик чыккан чак булса да,
Яшь кызлар күк бераз тартынып,
Бер елмайса — эреп төшәм менә,
Шул мизгелдә бетә ачуым.
Бәхетемне ходай
Өеп бирде миңа —
Хатын-кызның бирде асылын!

Күбесенең күзе
Җәүһәргә тәбәлгән —

---

Сафуан МУЛЛА ГАЛИ (1927) — *шагыйрь, берничә китап авторы. Казанда яши.*

Күзләренә чыккан соклану:
— Нинди сылу,
Фәрештә күк,— диләр,—
Әйтерсең лә гөлдән чыккан ул,

Җәүһәр апа, сизеп, читкә карый,
Мәк чәчәге кебек кызара...
Үзбәк егетләре, сагыз кебек,
Сыланалар чибәр кызларга.
... Сәмаркандны да
Үтеп китте поезд —
Такырлыклар, чүлләр башланды.
Котың очар күреп
Тимер юл өстендә
Асылынып торган ташларны...
... Актарылып ага Аму-дәрья,
Ярсып ага, ярны кимереп.
Күз ачкысыз ком бураны ясый
Судан искән көчле җил, өреп...
Күперне чыккач та
Чорджоу башлана,
Алай үзе бик зур түгел дә,
Тик мөлаем яктылыгы белән
Тиз урнашты кереп күңелгә...
Садыйклар да төште стансада:
«Карабекка... ничек барырга?»—
Диеп сораштылар,
Ашыгырга кирәк,
Өлгерергә — вакыт барында...
Карабекавыл ул
Район үзәге,
Чорджоуга бер сискән чакырым.
Садыйк юлдан бер йөк машинасын
Борып алып килде чакырып...
... Тирә ягы юлның ком диңгезе,
Юл тузанын ярып машина
Алга чаба,
Ә кальгалар гүя
Сөңге тотып калка каршыга.
Карабекавылда
Төште Җәүһәр, Садыйк,—
Әле тагын җәяү барасы —
Канал яры белән
Туры барганда да
Бер чакырым, диләр арасы.
Карабекавыл ул
Уртача бер авыл —
Балчык өйләр, озын бараклар.
Район үзәге дип
Уйламас та идең —
Бер баракта кызыл байрак бар...

* * *

...Күрештеләр — сөештеләр
Якын туганнар.

Хат алганнар — әзерләнеп,
Күтеп торганнар...
Үзәк каналның ярында
Икән өйләре —
Хәтерләтә диңгездәге
Ялгыз көймәне...
Канал буйлары камышлык —
Чүлнең урманы.
Эч пошыргыч күңелсезлек —
Күңел нурлары
Сүрелде — сүнде, яңадан
Дөрләп янарга,
Шигъри ялкында йөрәкне
Кирәк ягарга...

Локман җизни — гидротехник,
Суның башлыгы.
Сугара утыз колхозны —
Күпме басуны!

* * *

Укытучы кызлар җыелышып,
Садыйкларны килгән күрергә —
Берсеннән берсе
Чибәр бу яшь кызлар
Шатлык алып керде күңелгә.
Һәр ел саен, вуз бетергән сылу
Яшь кызларны Уфа-Казаннан
Урта Азиягә
Көчләп озатканнар —
Үз теләген Мәскәү казганган...
... Татарларны таркатырга Мәскәү
Эзли юлын — таба сәбәбен, —
Каршы әйтсәң,
Кыргый дуңгыз кебек,
Аларттыра башлый бәбәген...
Туган якны бик сагынган кызлар,
Җәүһәрләрнең үбеп йөзеннән:
«Саргаешып шунда
Без үләрбез...», диләр. —
Өметләре җебе өзелгән...
Көчләп китерелгән укытучылар, —
Гүя гадәт калган искедән, —
Берсе дә бит илгә кайталмаган —
Төрекмәнгә ул-кыз үстергән...
Күңелләре бераз тынычлангач,
Утырдылар кызлар табынга.
Туган як хәлләрен сорашулар
Менә кызып китте тагын да...
Садыйкны да алар димләделәр
Укытучы булып калырга.
Нишлисең бит, вакыт җитмәгәндер
Язмышлардан гыйбрәт алырга...
Локман җизни әйтте: кайнеш, китмә,
Китмә, кал син — эшлә шушында,

Ник өркергә, кер син укытырга,
Шушы кызлар белән кушыл да.
Риза буламы соң инде Садыйк,
Үзе килде ич ул укырга...
Мөнәвәрә апа башын иеп,
Күз яшьләрен сөртеп утыра:
— Ярар инде, Локман, үзсүзләнеп
Теңкәсенә тиеп утырма,
Килмәгән лә энем укытырга...
Дөнья күрсен, зур укысын әле...
— Ярар, «аягыңа бозау
Баскачтын»да, кайнеш,
Озак йөрмә — безгә кайт туры!
Укытырга теләмисең икән,
Шушы өйдә эшнең канторы...

* * *

Садыйкны анның
Җибәрәсе килми,
Үзләрендә килә тотасы —
Юк, җибәрмәс иде, үз кулында
Булса әгәр дөнья тоткасы...
Садыйкны афәт көткән кебек, анның
Билгесез шом борчый күңелен —
Курыкканга бәлки куш кынадыр,
Ул әүлия түгел түгелен...
Улы кебек күреп, Мөнәвәрә,
Садыйк белән ихлас кинәнеп,
Догаларын укып,
Гомер тели-тели,
«Китмә!», диеп сорый инәлеп...
Бик сагына шул ук Ык буйларын,
Күз йоммыйча төннәр үткәрә —
Күңеле белән кайта авылына,
Мөрәҗәгать итә күккә дә...
Күз алдына баса әрәмәләр —
Гөлҗимешләр җыйган чаклары.
Бергә уйнап үскән дускайларны
Уйламыйча калган чак бармы...
Их,
Үткәннәрдән чыңлый кыңгыраулар,
Күңелендә сайрый сандугач —
Җырлый да ул елый,
Җырлый да ул елый —
Ни хәл итсен илен сагынгач...

# Наис ГАМБӘР



**Нәрсә ул Яшәү?**

**Бу сорауга, әлбәттә, һәркем үзенчә җавап бирә алыр иде. Минемчә, Яшәү — ул минут-сәгатьләр, көн-еллар бозкрасыннан хасил булган өзелмәс, тоташ Хатирәләр чылбыры. Хатирәләр икән, димәк, анда уй-кичерешләр, борчу-шатлыклар, яну-көюләр дә булырга тиеш. Баксаң, бар бит алар, бар: Туудан алып Соңгы чиккә кадәр Кеше гомеренең һәр көне сокланып туялмаслык, сөйләп сүз бетмәслек тылсымлы әкияткә тиң ләбаса. Ләкин гомер чылбырына тезелгән көннәр — барыбер, бердәй түгелләр; була шундый вакытлар, була шундый минутлар — алар синең бөтен җаныңны актарып ташлыйлар, барлык вөҗдәнне биләп алалар, кайчак хәтта еллар агышын кирегә дә борып җибәрергә мөмкиннәр. Хикмәт шунда ки: бер көн — ул Мәңгелекнең бер кыйпылчыгы гына. Ләкин Мәңгелек дигәнең үзе үк бер көнгә сыеп бетәргә мөмкин.**

**Ярый, сүзебезне башлыйк. Хәерле сәгатьтә булсын!**

## МА — ТУ — У — У!!!

ЭССЭ

* * *

Казанга без таң алдыннан килеп төштек.

Машина бәллүендә йокымсырап барган җиремнән күзләремне ачсам, ни күрим: ул болын-кырлар, ул урман-үзәнлекләр — бар табигать алсу нурлар балкышына күмелгән иде; нәкъ Тукайдагыча

«Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң» атып килә иде. Әйе, язлар үтеп, җәйләр җиткәч, печән өсте кергәч кенә була торган, анда да йөз елга бер генә тапкыр кабатлана алырдай үтә дә сәгадәтле вә хиссиятле бер иртә иде ул: Кояш әле агач биеклеге дә күтәрелергә өлгермәгән, дөнья-хәят инде сихри нурлар белән тулган. Офыклар — алсу, алсу; кая күз текәмә — яшеллек, яшеллек: урманнар — яшел, кырлар — яшел... Күктә исә — җәяүле болытлар төркеме, кошлар өне, кошлар моңы...

«Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә». Кыскасы, җиһанда уяну шатлыгы, яшәү хөрлеге! Әнә, иртәнге таң нурларында балкып утырган Казан да күренде. Исәнме, иртә! Исәнме, Казан!

* * *

Шулай да Мөслим — Казан юлы безне шактый талчыктырган иде, «КамАЗ»ыбызны йөк алырга килгән склад каршына китереп туктаттык да, эш сәгате башланганчы бераз баш терәп алу зыян итмәс иде, дип, һәркайсыбыз үзенчә урын хәстәрләргә керештек. Шофер егет белән Рәйхан Хантимеров кабинада баш төртеп калдылар, ә мин, җаныма урын табалмыйча, машина әрҗәсенә үрмәләдем. Төнлә белән юлда безне узып киткән йөк машинасыннан төшеп калган берничә фанера кисәген алып салган идек һәм мин соңгы бер ел эчендә өстән төшмәгән фуфайкамны алдым да урман исе, туган як каены исе аңкытып торган ятагыма аудым. Ләкин кая ди ул йоклау! Уйлап кына кара син: әйткәнемчә, күз алдымда аллы-гөлле нурлар биешә, ә күңелдә — борчулар, борчулар...

Безнең ул чакта рәссам егет Рәйхан Хантимеров белән Мөслим районы үзәгендә туган якны өйрәнү музее оештыру нияте белән җенләнеп (мин башкача әйтә алмыйм) йөргән көннәребез иде. Казанга килүебез дә шул хаҗәттән иде: ясалма киез кирәк безгә һәм бик күп кирәк. Табып булырмы аны, без теләгәнчә бирерләрме, буш кул белән кайтып китмәбезме? Гавәм каршында көлкегә калмабызмы? Зурдан куптык ла, хәерсез; җитмәсә, бу дөньяда сине аңлаучыдан битәр, алдаучылар күбрәк ич. Мөслимдә дә, әнә, туган җиреңдә, күз күргән кешеләрең, моңа турыдан-туры «җаваплы иптәшләр» күпме тупсалар таптап йөреп тә музей ачу өчен яраклы бина табып бирә алмадылар. Һәм без череп беткән бер «тавык кетәге»нә кереп утырырга мәҗбүр булдык. Югыйсә, без уйлаганча, бу эшкә бөтен район җәмәгатьчелеге кубарылырга тиеш иде дә бит, юк шул, юк. Мөслимнең әле бу, әле теге почмагында шәхси «хан сарайлары» гөмбәдәй үсеп чыккан бер мәлдә, без — ике хәерче дивана! — үз дөньябызны онытып оешмадан-оешмага бусага таптап йөрдек: «Фәлән-Фәләнеч, ярдәм итегез инде, музей өчен бер-ике кило кадак» яки «бер-ике кубометр такта табып булмасмы», янәсе. Йә, хурлык түгел идемени бу? Әйтерсең лә музей дигәннәре безгә генә кирәк!..

Ярый, без бу хурлыкка түздек. Илшат та түзде (ул музейчылар командасының өченче әгъзасы иде). Безнең көндәлек сорауларга, әлбәттә, «тиешле иптәшләр» дә түзде. Чөнки, күп очракта, аларның колагы ишетми, күзләре күрми торган иде. Ә бит музей аларга да «кирәк» иде. Рухи хаҗәтләрен канәгатьләндерү, халык алдында, тарих алдында торган бурычларны үтәү өчен түгел, әлбәттә, югарыдан килгән рәсми кунаклар алдында: «Менә без дә тик ятмыйбыз, халык өчен яшибез»,— дип шапырыну өчен кирәк иде музей аларга. Шулай булмаса, алар без бушка эшләп йөргәндә, әйтик, булган экспонатларны саклап калу ниятеннән музейга магистраль үткәргечтән җылылык кертү өчен күкрәгебез белән диярлек асфальт юл астыннан тоннель тишеп чыкканда: «Первый»ның рөхсәте юк»,— дип әрекмән астына качмаслар иде дә, ахыр чиктә, «Первый» өйдә юк чакта без эшкә керешкәч: «Юлны бозсагыз, үзегез җавап бирерсез»,— дип бармак янамаслар иде. Хәер, андыйлардан ни сорый-

сың, куркаклыклары өстенә, түргә иске чабата элеп куйсаң, музей була, дип уйлый иде ич алар.

Ләкин монда бер яманаты чыккан партократияне генә гаепләү дөрес үк тә булып бетмәс иде. Әйтик, алар «по назначению» шулай сукырлык язмышына мәхрүм ителгән дә булсыннар ди, ә аларны сырып алган укымышлылар кайда иде? Аннары, бер уйласаң, аларны да гаепләп булмый кебек: халкыңның миеннән гасырлар буена тарихи аң суырып алынгач, ни хәл итәсең; икенчедән, илдә гомуми буталыш барган бер мәлдә нигә әле үзеңне кайгыртып, калганына күз йомып яшәмәскә — җайлы ич!

Тарихи аң дигәннән, шундый бер хәл булып алды. Кечерәк кенә бер оешмада баш инженер булып эшләүче бер иптәш — замана зыялысы! — үтеп барышлый музейга сугылып чыккан иде. Менә шул түшәмгә асылынып куелган мамонт сөяген күреп алды да: «Бәй, бездә дә тарих булганмыни?» — дип гаҗәпкә калды.

Менә шулай, җәмәгать!

Сүз дә юк, «илдә бер дус булмаса да, ил бөтен дошман түгел», дигәндәй, музей төзелешенә дә ихлас күңелдән ярдәм итүчеләр аз булмады. Исемнәрен аерып атамастан, шуны гына әйтә алам: кылган игелекләре күләменчә халык исеменнән рәхмәтләр яусын аларга!

Ләкин музей ачылу көнен иң зарыгып көтүчеләр — балалар иде. Хәтердә ич, музей төзелә икән, дигән хәбәр таралуга ук көн саен диярлек биш-алты укучы бала килә иде дә:

— Абыйлар, көне-төне шакылдыйсыз, сездә бик кызык, диләр, карап кына чыгыйк инде, — дип, күз яшьләре белән генә ялвармыйлар иде.

Аннары әбиләр, бабайлар килә иде. Алар исә, яшьлекләрен исләренә төшереп, барлы-юклы экспонатлар белән танышып йөргәннән соң:

— И оланнар, бик тә рәхмәтле эш башлагансыз икән, Аллаһе Тәгалә ярдәменнән ташламасын, — дип, берсеннән-берсе матур теләкләр теләп, үсендереп чыгып китәләр иде. Ходай түгел, нәкъ менә алар һәм энтузиастлар, авыл мәктәпләрендә музей почмаклары оештырган фидакярлар үзләренең ярдәменнән ташламады безне. Аларның тырышлыгы белән чүплек башларында аунап яткан, йә булмаса сандык төпләрендә, чормачоланнарда кадерләп сакланган халыкның күңел җәүһәрләре музей түрендә урын ала башлады. Шулай ул, шулай булырга да тиеш: музейны аны бер-ике кеше генә төземи, төзи дә алмый, аны халык үзе тудыра; көндәлек эше, яшәеше, көн итеше белән барлыкка китерә. Их, җәмәгать, төрледән-төрле музейлары булган халык нинди бәхетле халык ул! Беркөнне радиодан ишетеп калдым: Германиядә ел саен йөзләгән музей ачыла икән. Ә безнең... авылларда түгел, Казаныбызда — башкалабызда! — тарихыбызны өйрәнүче музей юк. Адәм көлкесе. Милли музеебыз юк!..

* * *

Менә шундый уйлар белән йокыга китә алмыйча күпме изаланып ятканмындыр, бервакыт лаштыр-лоштыр атлап килгән берәүнең нәкъ безнең машина янында туктап калуы сискәндереп җибәрде — таң ката нишләп йөри бу бәндә? Мин теләр-теләмәс кенә урынымнан күтәрелергә мәҗбүр булдым. Карасам, өстенә аксыл төстәге таушалганрак плащ, башына ямьшәйгән кәпәч кигән берәү кулларын маңгаена куйган да, янтая төшеп, Күк йөзенә текәлгән. Ә Күктә... Күктә — тантана: Кояш инде шактый күтәрелергә өлгергән; гөмбәзи җиһан — биек, тирән, ачык; Көн туып килгән офыкның бер читенә «туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене... аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме».

Теге Диванам әнә шул биниһая тирәнлеккә кереп чумган да уйга талган. Ул Күк йөзен күзәтә, мин — аны. Һәм шул мәлдә миемне бер

гасабилы уй көйдереп узып китте: «Йа, хода бәндәсе, тегеләйрәк түгелме соң син?»

Әйе, ул акылга җиңелрәк бер бәндә иде; көл төсле йончу йөзенә саран гына сирпелгән елмаюы да ничектер, гадәти кешеләргә хас булмаганча, үтә дә моңсу һәм газаплы иде шул аның.

«... Ни күрә икән ул тирән Күк чоңгылларында? Нинди уйлар бәргәләнә икән аның зәгыйфь аңында? Нинди көчләр сулкылдый икән аның йончыган, талчыккан, талкынган җанында?»

Чү! Тукта! Ни хакым бар соң әле минем аны шулай кимсетергә?! Каян беләсең, бәлки, рухы белән ул миннән мең мәртәбә сәламәтрәктер? Бәлки, бу дөньяның барышын миннән миллион тапкыр дөресрәк тә, тулырак та аңлый торгандыр? Бәлки ул көндезен дә Күк гөмбәзенә сибелгән йолдызларны күрә алу кодрәтенә ия булган бер җан ияседер?..

Менә аның сүрән, моңсу күз карашлары кинәт яктырып китте, кипшергән иреннәренә, бүлтәеп торган бит очларына (әллә офыктан сирпелгән нурлар уйнаклавы гына идеме ул?) алсулык йөгерде, янтык-какча гәүдәсе тураеп, күкрәге киерелеп киткәндәй булды. Кыскасы, аны күз алдымда алыштырып куйдылармыни: әле генә боегып басып торган җан иясе бу минутларда барлык җаны-тәне белән, барлык вөҗүде белән көлә-шатлана, тантана итә иде; газаплы авырудан соң кинәт савыгып киткән кеше кебегрәк бер ләззәтле халәттә булса кирәк иде ул.

Талгын җил исеп куйды. Ул, кәпәчен кулына алды да, башын горурanә тоткан хәлдә, сакаурак күкрәк тавышы белән Күккә текәлеп бер сүз, бары бер сүз әйтте:

— Ма — ту — у — у — !..

Миңа ничектер уңайсыз булып китте, үземне ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй хис иттем — Ул бит берүзе, тулы бер Җиһан белән күзгә-күз калып сөйләшә иде ләбаса! Дөресрәге, ул мине шәйләмәгәндер дә әле, шушы тузанга баткан машиналар, акшары коелып беткән шыксыз йортлар, вак-төяк мәшәкатьләр каршында дер калтырап торган кешеләр — берсе дә, берсе дә юк иде аның өчен бу минутта! Ул бар да, Җиһан бар...

Аннары ул, шулай сәер генә көлемсерәп бераз басып торды да, әкрен генә, җирне авырттыра күрмим, дигәндәй сак кына атлап, урыныннан кузгалды. Биш-алты адым киткәч, тагын Күк йөзенә күтәрелеп карады һәм тагын, үзе генә аңлаган телдә, әлеге сүзне кабатлады:

— Ма — ту — у — у!..

Ул китеп барды. Минем өчен гелгә, мәңгелеккә... Шул китүе белән мәңге чишелмәслек сорау да биреп калдырды: «Әй, кем идең син матурлыкны дөньядагы барлык адәми затлардан да ныграк тоя алган зәгыйфь акыллы изге җан иясе? Күктәге матурлыкка гына гашыйк-әсир идеңме син, әллә күңелеңдә изрәп яткан изге хисләрең кодрәти сүз булып оешып чыктымы?»

Мин тәмам гаҗиз идем. Бер атылуда машинадан сикереп төштем дә Рәйханны дер селкетә башладым.

— Син нәрсә, понимаешь, сәхәр вакытында төш күрә-күрә йокы симертәсең, җаны бар кешеләр, әнә, Җиһан белән сөйләшәләр...

Үзем шаяртмакчы булам, үземнең башта бөтенләй башка уйлар. Рәйхан да минем кебек юләррәк кеше: югыйсә, тора салып буш кул белән музей төзүгә алынып идемени, булып узган вакыйга хакында бер-ике сүз әйтү белән чикләвекнең юкәдә икәнлегенә тиз төшенеп алды — машина яныннан бер-ике адым читкәрәк китте дә, Күк йөзенә текәлеп:

— Нигә, ма — ту — у — у... ич! — дип куйды.

— Чынлап га, ма — ту — у — у ич!

Бу юлы инде әлеге Илаһи сүзне без икебез бер авыздан кабатладык.

* * *

Бу хәлләр әле кичә генә булып узган кебек иде, уйласаң, биш ел гомер узып та киткән икән. Гомер узгандыр, анысы, уза инде ул, ә шул вакыт эчендә бик күп вакыйга-күренешләр күңелгә кагылмыйча да узып киткәндер, бәлкем, ләкин әлеге хикмәтле Сүз колак төбемдә һәрдаим яңгырап торды дисәм, валлаһи, гөнаһ булмастыр. Үләргә җитеп йөргән, иң бәхетсез көннәремдә дә, түбәм белән болытларга орынып үткән мизгелләрдә дә шул бер Сүз гел күкрәгемдә сулкылдап килде:

— Ма — ту — у — у!..

Моңарчы мин аны, Хозыр Ильястай таңда пәйда булган теге гөнаһсыз зат кебек, Алла белән сөйләшкәндәй, бары үзалдыма гына пышылдый идем. Юк, алай гына да түгел, ул җаным буйлап үз уңаена, эчтән тын гына ага бирә иде. Ләкин күңелгә кайчак шом да килә: «Нигә соң әле бу дөньяның ма — тур — лы — гын күбрәк күрә алган, тормышны матурайту сәләтенә ия булган кешеләргә яшәве торган саен ныграк кыенлаша бара? Нигә ишетмиләр аларның кодрәтле сүзләрен? Әллә бөтен гавәм чукракланып беттеме соң, каһәр суккыры! Каты күңелле «Акыллы»лар күбәйгән саен, нечкә күңелле «Исәрләр» азая барамы соң әллә?»...

Шуңа да минем менә бүген Күкләрне яңгыратырлык, Җиһанны инрәтерлек итеп кычкырасым килә: җаны исәннәр — ишетерләр, теле барлар — кабатларлар, күзе барлар — күрерләр, иншалла!..

— Ма — ту — у — у — у!..

— Ма — ту — у — у — у!..

## БОЗ ӨСТЕНДӘ ЯЛГЫЗ МАЛАЙ

Безнең өй каршында ук буа бар. Дөресрәге, бар иде. Элегрәк, язын ташкыннар ташып үткәннән соң, урманнан төшкән кар сулары челтер-челтер йөгереп узгач, авыл халкы бердәй күтәрелеп, ат-арбалар белән кәс ташып, чытән-чыбык катнаштырып күпер алдына җыйнак кына бер буа буып куяр иде. Без үскән йортның капкасы терәлеп диярлек ачылгангадыр инде, тора-бара «Гыймран буасы» дип аталган бу сулык, күз кердисә, авылның каз-үрдәктән ишлерәк эреле-ваклы бала-чагасы өчен чын мәгънәсендә «халык шугалагына» әверелә иде. Бу элегрәк шулай иде.

Мин хәзер атам-анам йортында кунак кына. Менә бүген дә, газета эшләре белән тирә-юнь авылларда йөреп арыганнан соң, туган нигезгә сугылып чыгарга булган идем: хәл-әхвәлләр хакында сөйләшеп, чәйләр эчеп хушлашкач, өйдә берәрсе юлга чыгар алдыннан гына була торган тынлык урнашты.

— Ничек инде, куньп та китмисеңмени? — дип, бер яктан икенче якка әнкәй чыгып йөри. — Ниләр генә җибәрим соң күчтәнәчкә, бер ниләр дә юк, ичмасам. Бигрәк тизгә икән!

Һәм аннан тезеп китә: «Аягың бигрәк юка икән, юлга шулай чыгалармыни? Кая гына куйдым соң, сиңа дип атап бәйләп куйган чолкәм бар иде бит, югыйсә. Йон бияләй кирәк түгелме?»

— Юк, юк, әнкәй, — дим мин ничек тә аны тынычландырырга тырышып. — Берни кирәк түгел... Барысы да бар...

— Ал, ал, ни бирсәләр — шуны ал син, — дип сүзгә кушыла әткәй ишек алдына караган тәрәзә яктысына күтәргән «Авыл утлары»ннан аерылмыйча гына уенын-чынын бергә кушып. — Сандык ачылганда алып кал.

Үзем картларны тыңлыйм, үзем урам як тәрәзә аша буаны күзәтәм. Буа дисәң, хәтерең калыр — аның бер исеме генә инде. Аны быел буып та

тормаганнар. Ләм, сырганаклар басып бетергән төбендә, аның да урта бер төшендә аяк чылатырлык уентык су боз булып каткан. Шул боз уртасында бер малай басып тора. Безнең «күрше егете» Ильяс ул.

Егет булмыйни. Ильяс өченчеме, дүртенчеме класста укый ич инде: Индус белән Фәниянең икенче малайлары, зурысы хәрби хезмәттә. Менә ботинкалы конькие белән талпынып китә дә, колач киңлеге шугалагының икенче башына барып төртелә. Тагын икенче якка борылып талпынып китә. Бер-ике адым атлау белән аргы башка барып җиткәч, «беттедәмени әле» дигәндәй аптырап, күзлеген борыны өстенә күтәреп куя. Күтәреп куя да, бер кавым яр буендагы корып ауган өянкеләргә, ялан-кырлар ягына карап уйланып тора. Ни уйлый ул? Икеләнми әйтә алам: «менә шушы ярлар боз белән тулып торсын» иде дип күз алдына китерәдер бу минутларда Ильяс. Аның да телевизор-кинолардан күргән үз тиңнәре кебек очынып-очынып шуып китәсе, хоккей уйныйсы киләдер бу минутларда.

Мин түзмәдем, киртләч-киртләч катканаклы урамны бер-ике генә сикереп үттем дә, чалбар балакларына сырганаклар ябышмасын дибрәк, тар гына сукмак кебек җирдән күрше егете янына төшеп киттем.

— Нихәл, Ильяс, шуып буламы соң?— дим булдырган хәтле дустанә тавыш белән.

— Өйрәнеп кенә киләм әле. Күнекмәгәч, аяклар арый.

— Ничава, болай булса күнегер.

— Бозы бәләкәйрәк шул.

Бөтенләй үк «юк» дими Ильяс, күрәсең, ул моннан да зуррагын өмет тә итми.

— Иптәшләрең дә күренми нишләптер?

— ... абый килермен дигән иде дә, күренми шул әле.

Ильяс кем турында әйтергә теләгәндер, исемен ишетми калдым. Шулай да сорап куйдым:

— Зурмы соң әле ул?

— Сигезенчедә укый инде. Башка кеше юк ич.

Аннары Ильясның күзләре нурланып китте.


— Ну, килсә уйнар идек инде...— Соңгы сүзен ул сузып әйтте:— Кә-шә-кә-ле. Былтыр килгән иде, югыйсә.

Бу сүзләре белән ул мине тетрәндереп җибәрде. «Их, сабый күңеле,— дип уйлап куйдым мин шулчак үзалдыма.— Никадәрле беркатлы һәм ышанучан әле син. Синең өмет йолдызың нинди якты әле. Синең бик тә, бик тә бәхетле булуың өчен, конькида шуарлык уч төбе хәтле боз кисәге һәм бер иптәш тә җитә ләбаса. Сиңа шунысы да җитә, сиңа артыгы кирәк түгел. Әмма ялгызлык, тәгәрәшеп уйнарлык җан дустың булмау синең күңеләңә авыр таш булып ятмас микән? Ятмасын иде».

Һәм мин үзебезнең балачакны искә төшердем. Беләсеңме син, Ильяс, без менә шушы буа бозында егерме-утыз бала-чага гөж килеп, агач тамырыннан үзебез юнып эшләгән шарны үзебез урманнан алып кайткан кәшәкәләр белән куып уйный идек. Аягыбызда олтанлы киез итек иде, синеке кебек конькилар төшкә дә кермәле түгел иде. Әмма без синнән бәхетлерәк булганбыз икән. Чөнки без егерме-утыз идек, күп идек. Кызык иде безгә. Ә син юк бозында килмәгән (?) абыеңны көтеп йөрисең. Оят булса да синең белән кәшәкәле уйнар идем мин, бәләкәч күршем. Тик икебез сыярлык шугалак бозы да юк икән шул син яшәгән туган авылда.

Ильяс, олы кайгыңны дөньяга чәчүем өчен гафу ит, син аңларсың мине. Бу минем дә олы кайгым иде. Ышан, нәни дустым!

# ШИГЪРИЯТ



**Танылган шагыйрь, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Муса Галигә бу айда 70 яшь тула.**

**Сугышларда булып, авыр яралар алган, әмма илгә исән кайтып, илле елга якын гомерe инде шигъри ялкын-утларда янып үткән, әдәби хезмәтләре өчен орденнар белән бүләкләнгән хөрмәтле шагыйрь ул. Мөлаем йөзле, якты күңелле Муса агайның Казанда да элек-электән дуслары күп булды. Әле дә шулай.**

**Әйе, иллегә якын китабы дөнья күргән (арада башкортча ике томлык һәм урысча бер томлык калын сайланмалары да бар), Мәскәү әдәби журнал-газеталарында да даими басылып килгән шагыйрьне журналыбызның авторы буларак та яхшы беләләр. Ул үзе дә Казанга еш килә, Тукай көннәре — Шигърият бәйрәмнәрендә дә бик теләп катнаша. Без бу санда тәкъдим итә торган шигырьләрендә дә — әнә шул матур очрашулар, аралашулар, Казан белән чираттагы күрешүләр хатирәсе.**

**Рәдиф ГАТАШ**

## Муса Гали

### Сабый Тукай

*Тукай музеенда Х. Казаковның «Бәләкәй Тукай» картинасын карагач*

Зур күзләре аның шундый моңлы...
Гаҗәпләнү катыш сабырлык.
Дөньяның бар изгелеген җыеп,
Аның каршысына салырлык.
Күңелендә әле давыл түгел
Гөл селкенер җил дә исмәгән.

Кайда әле газап? Күзләренә
Болыт шәүләсе дә төшмәгән.
Барысы да алда,
ах, алда шул
Утлар йоткан илнең авазы.
Тау-тау хәсрәт. Чая талпынулар,
Болытлысы көннең, аязы.
Дөньяга ул ничек серле баккан,
Чак төшсә дә әле итәктән.
Сабый Тукай!
Аркасыннан сөеп,
Йөретәсем килде җитәкләп.
Йоклый әле еллар куенында
Ярсу акыл, шигъри чаялык.
Өнсез әле. Ләкин калкыр тиздән
Җанын суырып алыр яманлык.
Барысын да алдан тойгангамы,
Күзләреңдә шундый моң-сагыш.
Очканда да дөнья читлегеннән
Чүкмәс шагыйрь. Булыр мең алыш!
«Ах, сабый!» дип, җитәклисем килде...
Баксаң, дөнья ничек хикмәтле:
Ул үз рухы, үз иманы белән
Җитәкләгән бөтен милләтне.

## Шүрәле урманнары

Без җиләбез Тукай якларына...
Апрель бөреләре ямь-яшел.
Ташып бара җирнең гаярь көче,
Безне дә әле шул көч әйдәсен!
— Күз салыйкчы... Әнә теге якта
Шүрәлеләр йөргән урманнар!—
Диде Мәһди.
Шул хәбәре белән
Кинәт салды мине уйларга...
О, беләм мин, беләм,
сихри кылын
Чирткән монда шагыйрь җилләнеп.
Балачакка әкият иле булып
Сеңгән шуңа Кырлай җирләре.
Ә мин килдем монда
дөньябызны
Шүрәлеләр баскан заманда.
«Былтыр» күргән урман сарыгыннан
Хәзер алар ун кат яманнар.
О, бу якта ил җилеген суырган
Кара еллар инде санаусыз:
Шүрәлеләр булмый изге җанлы,
Шүрәлеләр була аяусыз.
Ят көчләрне, ләкин, ярып үтте—
Сукты тагын Тукай сәгате.
Мактап җырлый апрель бөреләре
Дөнья яңаруы сәләтен.

## Бер хатирә

Төнге Казан буйлап ялгыз узам,
Тартыла да күңелем кыллары.
Бер сөйләшсән икән Туфан белән,
Кыссаң икән Хуҗи кулларын.
Калган икән әле күпме серләр,
Күпме сүзләр яңа ярала;
Татар... башкорт... Гел янарса икән
Изге дуслык безнең арада.
Кайный бүген Казан.
                    Буш вәгъдәләр
Көймәс микән аның төбендә?
«Азатлыкмы?»— утлы сорау булып,
Җидегән яна аның күгендә.
Заман нервылары шундый кызган,
Таш чатнарлык кеше тыныннан!
Кемнәр әле, дисең, җинел алган
Үз язмышын үзенең кулына.
Кинәт, баксам, Сөембикә балкый:
Ай куйганнар... Менә күренеш!
Айга карап тик бер исерек улый:
«О, господи боже, бу ни эш?!»
Бу гадел эш, дим мин,
                    азат кеше
Булсын айлы, булсын кояшлы.
Яманлыкны җиңсен рух яктысы,
Басмасын, тик язмыш иңбашны.
Төнге Казан буйлап ялгыз узам...

## Кайт, Салават

«Ай-һай да гына...» дигән моңым сузып,
Йөреп чыктым җирем киңлекләрен.
Шиңгән анда япь-яшь хыялларым,
Сүнә бара тере өметләрем.
Җил шуышты дала күкрәгеннән,
Ялварып та микән, әллә елап;
Каршылады мине кошсыз урман
Елгаларым акты авыр сулап.
Ничек яткан ил-йорт күкрәгенә
Заманнарның яман бу юшкыны.
Күкрәгемне яра-яра чыкты
Җандагы бер тойгы, бер юксыну...
Кайт, Салават!
                    Якты киңлекләргә
Тарлык тулды. Ялган оялады;
Шыбыр-шыбыр килгән яңгыр түгел,
Ят вәгазьләр аңны томалады.
Җир селкеткән — бу зилзилә түгел,
Ата-баба корган җимерелә;
Җирең зары җырың булып кабынып
Курай тидерсән дә иренеңә.
Ярып чыгып Балтыйк дулкыннарын,

Күңелләргә сеңгән сының белән,
Кайт, Салават! Туңган хәтерләрне
Эретерлек утлы тының белән.
Кайт әле син!
Кылычың белән түгел,
Рухың белән кайт син үз җиреңә.
Кешеләргә янә өмет кайтар
Дуслык дигән хаклык җиңәренә.
Заман бүген бүтән,
Аң да башка,
Тик тетрәүләр кичеп мин тоямын:
Уралыңның алтын тамыры ул —
Синең иркең, синең ихтыярың.
Кайт, Салават!
Ил иманын зурлар
Изгелекле рух-теләгең белән.
Бар ыру-зат, бар телләрне бергә
Сыйдыра алган зур йөрәгең белән.
Кайт, Салават!
Кайт, Салават!

## Үтеп кенә китте

Ул бары тик үтеп кенә китте
Җитез болан сыман ялт итеп.
Үтте кызый, карашлары белән
«Мин — сафлык ул!» — диеп, ант итеп.
Бу караштан утлы мәхәббәткә
Әсир төшәр синме, минмедер...
Кемнедер ул яз гөледәй назлар,
Яшен булып сугар кемнедер.
Ул бары тик үтеп кенә китте,
Янып калды күпме карашлар.
Әллә нинди күз күрмәгән нурга
Тулып китте бөтен тарафлар.
Илаһи зат! Сиңа сихер бирде
Табигатьнең нинди көчләре?
Бер күз салсаң, уйный, җырлый башлый
Бу дөньяның бөтен төсләре.
Юкка сөйли кешеләр:
бәхетлегә
Күп капусы, имеш, ачыла.
Шау ябылып торсын шул күкләрең,
Син генә бас, җаным, каршыма.
Атлап үттең матурлыгың белән
Яман карашларны көйдереп.
Җан җылытыр изге хәбәр булып,
Сөендереп үттең, сөйдереп.
Сихри утлы, әй хатын-кыз заты,
Син үзеңдер чын бер яхшылык.
Карашыңнан нинди җир яшәрде,
Дөнья китте нинди яктырып...
Син үзең ул, үзең яхшылык!



# Халисә Мөдәррисова

## Былтыргы көз

Былтыргы көз, былтыргы көз
Алтын күперләр корды,
Күңелләр кыл, мәхәббәт — кул
Кылларда уйнап торды.

Аһ, ул алтын күперләрнең
Моңлы бер чыңлаулары...
Күзгә — күз, җанга — җан багып
Ул серне тыңлаулары...

Үткән көзнең ак моңнары
Ишелсә дә арага,
Быелгы көз салкынлыгы
Әйләндерә карага.

Әйләнәм дә тагын киләм
Җимерелгән күпергә,
Син бик якын, тик бик ерак,
Ничек күпер үтәргә?

Күпер генә үтәр идем,
Ятлар кичкән арадан,
Ватык күпер өсләрендә
Бәргәләнә минем җан.

* * *

Син йоклыйсың, ә мин китәм синнән,
Төшләреңдә мине күр, яме,
Һәм каршы ал минсез генә кичне,
Минсез генә моңсу иртәне.

Өзгәләмәм сине уңга-сулга,
Тыныч булыр, булмас «карышмак»,

---

Халисә МӨДӘРРИСОВА — *Башкортстанда яшәүче татар шагыйрәсе. Башкорт телендә басылган («Көмеш дага» һ. б.) берничә китап авторы. Журналыбызда даими басылып килә.*

Китә миндә синнән серле дөнья,
Ачылмаган яңа табышмак.

Булсын әйдә мең-мең мәшәкатең,
Ыгы-зыгың шунда исемсез,
Чәчел-түгел, күңел юаткан бул,
Тик бәхетле түгел син минсез.

## Казан дусларыма

Минем килү сезгә бәйрәм булсын,
Бу көндәлек соры чынбарлык
Энже кебек эчке якты белән
Бер балкысын, күңел чыңлатып.

Мин учыма салып тупаслыктан
Өшеп беткән ялгыз җанымны,
Сезгә киләм, дәва юллап киләм,
Юллап килгән кебек ярымны.

Мин — хыялый. Ничек бармын, шулай
Кабул иткән якын дусларым,
Сезгә киләм үз-үземне юллап,
Яз юллаган кебек кышларын.

Минем килү сезгә бәйрәм булсын,
Ул яктырак булсын таңнардан.
Чишмә кебек яңа җырлар типсен
Бәрәкәтле җырлы җаннардан.

Һәр очрашу безгә бәйрәм булсын,
Тансык булсын дуслар ишеге.
Ә китүем һәрчак сагыш булсын...
Мәңгелеккә китү шикелле.

* * *

Юк, кайтарып булмый үткәннәрне,
Ике какмый ярга бер дулкын,
Үткәннәрнең эзен эзләп килдем,
Үткәннәрнең эзе — сап-салкын.

Кадерләрен белер гомерләрдән
Үтеп киттек — ятлар җитәкләп,
Ә үткәндә ятим бала кебек
Үксеп калды безнең мәхәббәт.

Үткәннәрне эзләп йөрмә, диеп,
Җил йөгерә минем эземнән.
Үткәннәрне ташлап китеп була,
Ләкин булмый качып үзеңнән.

* * *

Көз инде, көз... Болыннарга
Салмак кына яфрак ява.
Ни хикмәт бу, сары келәм
Арасында җиләк — яңа...

Көннәр чуак, каен җиләк,
Су буенда — каз тавышы.
Җиләк пешә. Табигатьнең
Әллә инде бу — ялгышы?

Көз уртасы, тиздән ак кар
Каплап китәр бу болынны.
Очкын-җиләк, өзәм дисәм,
Тартып алам мин кулымны.

Көз инде, көз, су өстенә
Каз мамыгы, яфрак төшә.
Соңга калган сөю кебек,
Гүя качып, йә ут янып,
Елый-көлә җиләк пешә.

## Төш

Безнең мәхәббәт йолдызы
Атылган иде күктән.
Кулымда кулың җылысы
Суынган инде күптән.

Синең сәлам хатларыңны
Югалткан кебек идем.
Сине югалткан көнелне
Юаткан кебек идем.

Соңгы шат, салкын көлүең
Күңелдән чыккан иде,
Йөрәк сине, ак кәгазьдәй,
Хәтердән ерткан иде.

Бүген килеп кинәт кенә
Тынычлыгымны телдең:
Син көлеп түгел төшемә,
Сагышлы булып кердең.

## Кызыма

Урамда — март. Соңгы буран бурый,
Яз булмас та кебек быелга.
Ак касәдә гөл орлыгы йоклый...
Йоклый кыз күңеле, бар дөнья.

Быел шытып гөл буласы орлык,
Ниләр күрә синең төшләргә?
Җәйге кояш нуры, иркә җилләр,
Кырау үбеп үтәр көз мәллә?

Гөл орлыгы кебек яшь кызыма
Күп нәрсә сер, яңа, яшерен:
Уянасын белми, язлар көтми,
Һәм уйламый кырау төшерен.

Гомер язы якын, белми кызкай:
Ак касәдә чәчкә орлыгы.
Урамда март. Дөнья — төшләр күрә,
Җирдә әле кышлар тынлыгы,
Тик яз якын инде...



Рафаэль Хәким

# ИМПЕРИЯ КОЯШЫ БАТКАНДА

(МИЛЛӘТ һӘМ ДӘҮЛӘТ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР)

## Кеше хокуклары контекстында милли хокуклар

Иң изге идеяләр дә пычратылган Русиядә милли хокуклар бозылып кабул ителә, өркү һәм, хәтта, нәфрәт тә уята. Халыкларның тигез хокуклылыгына еш кына оятсыз тәкәбберлек дип, ә суверенитетка дәүләт җинаяте сыман итеп карыйлар. Башы чуалган Русия җитәкчелеге катлауланып киткән этник мәсьәләләрдән кеше хокукларын яклау лозунгысы артына качып, котылып калырга азаплана.

Кешедәге «кешелек»не миллилектән аерып карап булмый. Индивид тарихи традицияләр иясе, ул тел һәм гыйлем җыю аркасында шәхескә әйләнә. Шуңа күрә кеше хокукларына иң әлек туган телендә сөйләшү хокукы, үз мәдәниятеңне үстерү, яшәрлек мөмкинлекләрнең булуы һәм башка хокуклар керә. Шушы иң гади, иң табигый хокуклар булмаганда, башкаларының кирәге дә чамалы. Үз халыкларына балаларын камил милли мәктәпләрдә укытырга мөмкинлек тудырмый торган, халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү өчен җитәрлек матди мөмкинлекләр бүлеп бирми торган хөкүмәтләр теләсә нинди нәгърәләргә дә лаеклы.

Русиядә төп, тамыр халыклардан шүрләү кеше хокукларының, имештер, беренчел, ә халык хокукларының, янәсе, икенчел булуы турында әллә нинди ялган теорияләр уйлап чыгарырга мәҗбүрләр. Бу мәсьәләнең бөтен «нечкәлек»ләрен аңлау өчен «милләтче» белән «демократ» диалогын «тыңлап» карыйк әле.

«**Демократ**»: Кеше хокукларыннан өстен бер нәрсә дә булуы мөмкин түгел. Бу кешелек дөньясының иң зур казанышы, XX гасыр гуманизмының квинэссенциясе, кеше хокукларының беренчеллеген танымау — ул җәмгыять үсешенең цивилизацияле үсеш юлын кире кагу.

«**Милләтче**»: Мин кеше хокукларын танырга әзермен, ләкин халык хокуклары белән бергә.

«**Демократ**»: Кеше эшчәнлеген милләт белән бәйләп карау — ул әүвәлге кеше ихтыярын коллективка буйсындыруның тоталитар гамәлен дәвам итү дигән сүз. Кеше азатлыгы — беренчел. Калган барысы шуңа өстәлә генә.

«**Милләтче**»: Сорау бирергә рөхсәт итегезче: кеше хокуклары, аның азатлыгы теләсә кемгә дә кагыламы, әллә сайлап алынганнарга гынамы?

---

Ахыры. Башы 9 санда.

**«Демократ»:** Әлбәттә, бөтен халыклар да тигез хокуклы. Бу — безнең иманыбыз, кредобыз, ягъни һәр кеше дә, милләтенә, диненә, социаль чыгышына, җенесенә, тән төсенә карамастан, тигез хокукларга ия.

**«Милләтче»:** Тигез хокуклыкны туган телендә сөйләшергә, тиешле белем алырга, күмәк информация чараларына бертигез мөмкинлекләр булу дип анларга ярыймы?

**«Демократ»:** Һичшиксез!

**«Милләтче»:** Алайса минем мәнә телевизордан фильмнарны туган телемдә карыйсым килә, балаларымны бакчада көчли-көчли башка телдә сөйләштермәсеннәр иде. Мин кеше хокукларын шулайрак аңлыйм.

**«Демократ»:** Бу проблемалар турында минем дә ишеткәнем бар һәм монда бер яңалык та тапмыйм. Шунысын гына әйтәсем килә: бөек принципларны андый ваклыклар белән бутамыйсы иде. Иң әһәмиятлесе — кеше хокукларын чикли торган тоталитар дәүләтне җимерергә кирәк.

**«Милләтче»:** Әмма минем бөтен гомерем шул ваклыклар белән үтте. Милли белем алып булмаган, казна эше минем туган телдә бармый торган дәүләттән миңа ни файда? Бәлкем, минем таләпләремнең нигезе юктыр?

**«Демократ»:** Юк, нишләп булмасын, бик нигезле. Ләкин, Сез, милләтчеләр үзегезнең шул бәләкәй генә милли дөньягызга бикләнеп яшисез. Мәктәпләр өчен дә, башкасы өчен дә конкрет кешеләр җаваплы. Әнә шулардан таләп итәргә кирәк тә. Без кора торган демократик дәүләттә бөтен бу мәсьәләләр автомат рәвештә, үзеннән-үзе хәл кылыначак. Сабыр итәргә генә кирәк.

**«Милләтче»:** Соң, мин бит инде 1552 елдан бирле сабыр итәм. Әллә ул гомер генә җитмиме әле?

**«Демократ»:** 1552 елның ни катнашы бар монда? Монархы әле чын демократиянең булганы булмады. Менә, ниһаять, без хәзер цивилизацияле мөнәсәбәтләр дәверенә керәбез. Бүген иң әһәмиятлесе — уртак тырышлык белән демократиянең җиңүенә ирешәсе иде, ә калганы шуңа ялгана аның. Сез — милләтчеләр азатлыктан да кадерле нәрсә юклыгын аңларга тиешсез.

**«Милләтче»:** Минем өчен дә милли азатлыктан кадерлерәк бер нәрсә дә юк, демократия — ул шул милли азатлык бит инде. Башка тагын берәр төрле азатлык бармы әллә?

**«Демократ»:** Сез азатлыкны бик примитив аңлыйсыз. Миллилек — ул үзенә күрә тоталитаризм, ул шәхес азатлыгын чикли.

**«Милләтче»:** Минем халкымны коллар хәленә төшергән дәүләт — тоталитар дәүләт һәм, димәк, тоталитаризм да милли азатлык булгач кына бетәчәк.

**«Демократ»:** Тоталитаризмны бетергәч, һәркем өчен, азатлык булачак.

**«Милләтче»:** Ә демократик дәүләттә милли хокуклар саклануына нинди гарантия бар?

**«Демократ»:** Демократик дәүләттә кайсы милләттән булуның әһәмияте булмый.

Бу әңгәмәне тагын да дәвам итеп булыр иде. Ләкин теләсә кайсы очракта да проблема әнә шул халык хокукларының гарантына барып төртеләчәк. Халык хокуклары гарантияләнмәгәндә, кеше хокукларының бәясе — сукыр бер тиен. Андый гарантияне дәүләт бирә ала торгандыр. Ләкин менә нинди дәүләт бит ул? «Демократ»ларның җавабы әзер: демократик дәүләт. «Милләтче»ләр өчен демократия проблемасы төп мәсьәләне чишкәннән соң — үз дәүләтләрен булдырганнан соң гына килеп туа. Шуңа чаклы «демократик дәүләт», алар өчен иң яхшы дигәндә дә — ул мәгълүм сәяси йомшартулар булуны, начар дигәндә — изү субъектын алмаштыруны аңлата.

Русиянең урыс булмаган халыкларының хокукларын якламаячагы көн кебек ачык. Инде әгәр дә мәгәр Русия Бөекбритания кебегрәк демократик Дәүләт булып китә икән, анда да аның үз «Ирландия»се яки «Шотландия»се булмас дип ышанып әйтүе кыен. Ә инде Русия Америка юлын сайласа (ә ул хакта аның җитәкчеләре кабат-кабат белдерделәр), ул чакта андагы халыкларга Америка индеецларының хәле үзләренә җәннәт булып күренердәй мескеннәр язмышы әзер булачак.

Русия дәүләтен тамырдан үзгәртеп кормыйча, «милли мәсьәлә»не гадел хәл итеп булмаячак. Халыкларның хокукларын яклау һәм саклауны шушы мәнфәгатьләр сагында торырдай тиешле дәүләт челтәре булмаганда, бернинди демократия дә тәэмин итә алмаячак.

Мәсьәлә шунда ки: этник чыгышыңнан принципта беркая да качып котыла алмыйсың, «саф» кеше хокуклары дөньясында гына калып булмый. Халыкара документларда кеше хокукларының халык хокуклары белән бербөтен итеп кара-

луы юкка гына түгел ул. «Кеше хокуклары Хартиясе» өч документны берләштерә. Алар: **«Кеше хокукларының Бөтендөнья декларациясе», «Ватандарлар һәм сәяси хокуклар турында Пакт», «Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында Пакт».** Әгәр дә беренче документ шәхес хокукларын ачыкласа, калган икесе халык хокукларына карый. Әлеге «Пакт»ларның 1 маддәсендә болай дип язылган:

***«1. Бөтен халыклар да үзбилгеләнүгә хокуклы. Шул хокукка нигезләнеп, алар үзләренең сәяси статусларын үз ирекләре белән урнаштыралар һәм ирекле төстә икътисади, социаль һәм мәдәни үсешләрен тәэмин итәләр.***

***2. Бөтен халыклар да үз максатларына ирешү өчен халыкара икътисади хезмәттәшлектән, уртак файдага нигезләнгән һәм халыкара хокуктан килеп чыга торган нинди дә булса мәҗбүриятләргә зыян китермәслек итеп, табигый байлыкларыннан һәм ресурсларыннан, үзләре теләгәнчә файдалана ала. Бер генә халык та һичбер нинди очракта да үзенең яшәве өчен кирәкле һәм үзенеке булган мал-мөлкәтеннән көчләп баш тарттырыла алмый.***

***3. Ошбу Пактта катнашучы дәүләтләр, шул исәптән, үзидарәсе булмаган һәм аның карамагына кергән территорияләр өчен җаваплылык тота торганнары да, Берләшкән Милләтләр Оешмасы Уставы кагыйдәләре нигезендә үзбилгеләнү хокукын тормышка ашыруны хупларга һәм ул хокукны хөрмәт итәргә тиеш».***

Халыкларны яклау зарурлыгын истә тотып, БМО 1948 елны үзенең Уставында, ә аннары 1966 елны әлеге «Пакт»ларда халыкларның үзбилгеләнү хокукын кеше хокукларының иң төпкеләреннән берсе сыйфатында игълан итте. Бу принцип нигезендә теләсә кайсы халыкның үз җиренең һәм үз язмышының хуҗасы булырга, туган телен һәм мәдәниятен якларга һәм сакларга, үз милли дәүләтен булдырырга хокукы бар. Өстәвенә, андый хокукка иң элек төп-тамыр халык (санына да карамыйча) ия. Бары пычранып беткән иҗтимагый фикер генә үзенең тарихи ватанында үз дәүләтен булдыру өчен төп халык күпчелекне тәшкил итәргә тиеш дигән теориягә барып җитәргә мөмкин. Бер генә халыкара документта да халык язмышы турында сүз барганда демографик чикләүләр күрсәтелмәгән.

Халык хокуклары контекстыннан тыш кеше хокукларының мәгънәсе калмый, чөнки кеше хокукларын бозмауның гаранты төсендә дәүләт була. Әлбәттә, хыялда этник билгеләре булмаган барлык дәүләтләр өчен дә уртак булган хокук нормалары тупламасын күз алдына китерергә мөмкин. Теориядә бу операцияне эшләве кыен түгел, ә тормышта кеше үзенә бер аерым конкрет телдә сөйләшә, ул конкрет бер мәдәният иясе һәм моннан йөз чөерү мөмкин булмый. Асылда мәсьәлә кеше хокукларын тану яки танымауда түгел, мәсьәлә — бу хокукларны бозмауны, өстәвенә тулы күләмендә, бернинди киметүләрсез саклауны ничек тәэмин итүгә кайтып кала.

Кешеләргә үз гадәт-йолалары, мәдәниятләре кадерле һәм башкалар күзендә бу кыйммәтләр яхшымы, начармы — ияләре аларны дәүләтнең яклавын һәм саклавын тели. Аларны бернинди «демократик» кысаларга тыгызлап кертмичә, булганынча кабул итәргә кирәк. Мәдәни кыйммәтләрне яхшы-начарга, өстентүбәнгә, алдынгы-артта калганнарга аера башладың исә, колониализмга, империализмга һәм тоталитаризмга туп-туры юл ачылачагын көт тә тор.

Әйтеп үтелгәнчә, халык хокуклары контекстында карала торган кеше хокукларының гаранты булып милли дәүләт калка. Хәлбуки, тормышта этник һәм дәүләт чикләре бер-берсенә туры килеп бетми. Һәм шунлыктан мәсьәлә тагын да катлаулана төшә. Алай гына да түгел әле: полиэтник структуралы халык булганда нәкъ менә моноэтник дәүләт тигез хокуксызлык чыганагы булырга мөмкин. Русиянең төп проблемасы шунда: эчтәлеге белән полиэтник булуына да карамастан, хокукый яктан ул бары урыс дәүләте булып кына чыга. Олуг патшачыл (великодержавный), православный һәм бүленмәс Русия күптөрле халыкларның хокуклары гаранты була алмый. Ә Федератив Русия хәзергә ирешүе кыен булган максат кына булып кала.

Тышкы «богау»лардан арыну — ул әле азатлыкның беренче баскычы гына. Һәр милләтнең әле шәхес ирекен чикли торган эчке «богаулары» да була. Халык азатлыгының эчке ягын да күрмәү ялгышлык булыр иде. Милли дәүләт үзенең яшәве өчен генә яшәми, ул кеше азатлыгын үстерү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш, шул чакта мәдәниятнең бөтен потенциаль мөмкинлекләре ачылып, ул дөнья халыклары ярышында уңышлы катнаша алачак. Чын-чыннан ирекле җәмгыять «милли демократия» үсешеннән башка, ватандарларның азатлыгыннан, кеше хокукларын тәэмин итүдән башка мөмкин түгел.

Империянең мәҗбүри атрибутларыннан берсе булып курку-куркыту тора. Авызлыклау органнары тарафыннан ул хис аерым-аерым һәрбер кешедә генә түгел, тулы-тулы халыкларда да урнаштырыла. Асылда теләсә нинди дәүләт тә физик көчләүгә корыла, бу нәрсә аның, социаль институт буларак, төп билгесе булып тора. Хәлбуки, нормаль хәлендә чакта ил белән идарә итү өчен икътисади, сәяси, юридик, идеологик һәм башка чаралар да җитеп тора. Һәм бары тик кризислы әхвалдә генә, яки хокук тәртибен бозучы аерым ватандарларга карата гына дәүләт көчләү юлына баса. Империядә исә барысы да башкача: анда репрессия ысуллары гадәти гамәл сыйфатында файдаланыла.

Империя теләсә нинди ирекле фикерне, рәсмилектән теләсә нинди аерымлыкны эзәрлекли тора. Монда аның идеологиясендә «миллилек», «милләтчелек» белән тәңгәлләштерелә, ә «милләтчелек» дигәне кануннан тыш дип игълан ителә. Шулай итеп, ватандарлар һәм халыклар күңеленә курку һәм ышанлек кертелә. Шушы ике нәрсә халыкларны изүне тәэмин итә торган ике коралга әйләнә. Торгынлык елларында татар мәктәпләрен, газитләрен һ. б. ябуда гаепне үз өсләренә генә алып бетермәүләре белән урыслар бик хаклы. Чынлап та, «өстән» берниндн күрсәтмә килүнең дә кирәге калмаган иде. Татарның үз куллары белән мәктәпләр, газитләр, нәшриятлар ябылсын өчен Мәскәүгә әлеге курkуны дөрләтеп тору да җитә иде. Хәтта бүген дә әле Татарстанда күпләр үзләрен бик сак тота һәм суверенлык мөмкинлекләрен файдаланырга бик ашкынып тормый. Тиешле вәкарь белән: «Язмыш куласа, бер әйләнә, бер баса», дип куя. Дүрт гасырда җитмеш елга сузылган курку-куркыту режимы үз эшен эшләми калмаган шул.

Гадел булыйк, урыс халкы да куркудан хали түгел. Ул да шулай ук колларча баш иеп яшәде. Шуның өчен, күрәсең, урысларның империяне саклап калырга дигән әзерлеге какшаган булып чыкты.

Куркуның икенче ягында куркытып яшәткән өчен үч алу теләге ята. Тышкы зынҗырларыннан котылган социаль яки этник энергия — коммунистларны ул, демократларны, урысларны яки «милләтчеләрне»,— барыбер,— теләсә кемгә каршы юнәлергә мөмкин. Мондый хәяттә Русиянең үз традицияләре дә шактый гына дәрәҗәдә этәргеч булып тора ала.

Русиядә бер чиктән икенче чиккә тайпылу һаман-һаман кабатланып килә. Иҗтимагый аңда дөнья икегә генә бүленеп килә — яхшылык бар да, яманлык кына бар, имеш; оҗмах бар да, тәмуг кына бар. Большевиклар бу традицияләрдән файдаланып калды. Алар монда исемнәрне генә алыштырып куйдылар. Оҗмах урынына «коммунизм» дип куелды, тәмуг урынына — капитализм. «Классиклар» пәйгамбәр, буржуйлар иблис булып чыкты. «Киләчәк» дигән сүз белән бөтен аң томаланды. Күн күрү дигән нәрсәнең мәгънәсе дә югалды. Шуңа күрә кешеләр үзләрен дә, бүтәннәрне дә кызганып тормый башлады. Ике котыплы аң, «дошманнарга» карата нәфрәт кузгатып, шул нигездә «революцион борылыш» ясарга юл куйды.

Русиядәге бүген бара торган сәяси көрәш тә шундый аңнан ары китә алмый, киресенчә, һәр ике як (коммунистлары да, демократлары да) асылда, нәфрәт хисе белән сугарылган. Россия демократларының необольшевизмы шунда: алар котыпларны алыштырып куйдылар — капиталистлар урынына дошман итеп коммунистларны китереп чыгардылар, социализм урынына кенбатыш капитализмын куйдылар. Революция логикасы тагын җегәр җыеп килә. Телевидение белән матбугат иҗтимагый аңны мәкерле дошман әрәге белән интектерә, национал-социализм белән, «номенклатура» түнкәрешләре булуы бар һ. б. дип өркетә. Үтелгән 70 ел гомер «кара еллар» дип, ә революциягә чаклы еллар «бәхетле еллар» дип кенә сурәтләнә.

Большевиклар, социалистик бәхет вәгъдә итеп, хакимият башында утырып тора алдылар, демократлар, коммунистлар башына җитеп һәм капитализмга кире кайтып, бәхеткә килүне вәгъдә итәләр. «Тагы да бераз көч куеп,— диләр алар,— дошманны бәреп бетерәсе дә, аннары бөтенесе дә шәп булыр», янәсе.

Язмышның мыскыллап елмаюы шундадыр ки, демократия кешенең богауларын чишә дә, аны эчке курку хисеннән арындыра, социаль энергиягә үзен күрсәтергә ирек бирә, һәм нәтиҗәдә үзәкләштерелгән дәүләткә оппозиция килеп чыга. Монда, төп көч булып, гасырлар буе үз сәгате сукканны көтеп, халык йөрәгендә яшәгән этник энергия калка. Тарих күрсәткәнчә, хәтта бәләкәй генә этник төркемнәр дә, әгәр дә хакимият этносларның табигый әхвәлләре белән исәпләшми башлый икән, зур-зур дәүләтләрне тетрәтергә ихтимал. Русия демо-

кратлары да большевиклар алдына килеп баскан дилеммага тап булды: йә демократияне, ул бөтенләй буйсынмас була башлаганчы, бөтереп кире тыгып куярга һәм репрессия органнарын торгызырга, йә инде туп-туры Русияне таркатып ташлау юлына басарга. Тегесен дә, бусын да гафу итмәячәкләр. Ни гаҗәп: курку хисе демократларның да үз тотышларын билгели. Әгәр дә А. Собчак Татарстанның суверенитет игълан итүе уңае белән биргән интервьюсында: «Русиядән чыгарга большевиклар биргән хокукны бетерергә һәм Русия Федерациясен дезинтеграцияләргә маташулар кануни көч ярдәмендә туктатылырга тиеш», дип бәяли икән («Н. Г.», 7.08.92), бу инде, димәк, аның эчендә большевик утыра дигән сүз. Ул, куркуыннан шашып, «милли мәсьәлә»не хәл итүнең бердәнбер юлы шул дип, тизрәк ишек артына сөяп куйган күсәгенә ташланмакчы. Бу без алда әйтеп үткән «Россиядә милли мәсьәлә һәрчак хәрби мәсьәләнең бер өлеше булып килде», дигән тезисны тагын бер тапкыр раслый.

Тарих җәмгыятьнең революцион үсеше белән таныш. Ул «үсеш» нәфрәт белән үч алуга корылган була. Тарих шулай ук үзара сабырлык һәм консолидациягә корылган эволюция мантыйгын да белә. Моның беренчесе башкару өчен гадирәк, ул иҗтимагый аңның гади штампларын кулланып та гамәлгә ашырыла ала һәм нәтиҗәсен дә тиз бирә. Икенчесе исә — башкару өчен катлаулы, чөнки аң белән иҗтиһад итүне, төрле-төрле фикерләрне үзара килештерүне, төрле мәнфәгатьләрне һәм җәмәгать көчләрен ризалаштыруны таләп итә. Сәясәттә текәлек һәрвакыт примитив була һәм аның таянычы да хис кенә була. Уртачыл һәм эволюцион аң, сабырлык һәм түземлек сорый.

Большевиклар, халыкларның революцион энергиясен капитализмга каршы юнәлтеп, аны бик тә нәтиҗәле файдаланды. Бүген исә «антисоциалистик революция»не үткәрү күпкә кыенрак. Хәлләр тамырыннан үзгәрде. Таланган халыкка 1917 елда «буржуйлардан» тартып алыр нәрсә бар иде. Демократлар исә капитализмны халык исәбенә төземәкче: ә бу бер дә рухны күтәрми. Октябрьдә илдә сугыш бара һәм җимереклек хөкем сөрә иде, ә революция юл күрсәтте. Демократлар киресенчә иттеләр — болай имин генә яшәп яткан илне җимереклек һәм сугыш хәленә төшерделәр. Социализм җир йөзендә тигезлеккә һәм гаделлеккә өндәде һәм бу массаларның киң катламын җәлеп итми калмады. Демократлар социаль аерымлыклар тәкъдим итә һәм иң югары максат сыйфатында Көнбатышка табынуны, башкача әйткәндә, бөек дәүләтне Көнбатышның койрыгына әйләндерүне тәкъдим итә. Әле шуның белән бергә гап-гади теләнчелектән дә тартынып тормыйлар. Мондый сәясәт массаларны рухландыра алмый.

Сугыша-сугыша төзелгән социализм империалистик системаны какшатты, демократик лозунгларны күркәмләтте. Һәм ул, безнең илгә уңай нәтиҗәләр китермәсә дә, калган дөньяны тетрәнергә, эчке көчләрен җыярга һәм асылда «Буржуаз» корылышны үзгәртергә мәҗбүр итте. Диктаторлык режимнары алып ташланды, икътисад нәтиҗәле итеп көйләнде, колониаль сәясәттән баш тарттылар. Ә иң әһәмиятле — җәмгыятьтә сыйнфый нәфрәт һәм үзара кырылыштан котылдылар. Октябрь дөньяны гаделрәк итеп үзгәртергә тәэсир итте һәм бу аның тарихи казанышы булып тора.

Бүген инде 20—30 нчы еллардагы кебек, халык массаларының нәфрәтен һәм энтузиазмын кузгатуы кыен. Коммунистлардан һәм «милләтче»ләрдән «халык дошманы» ясавы авыр. Чөнки, беренчедән, тегеләре дә, болары да бик күп, икенчедән, демократлар үзләре дә шул ук «номенклатура» карынынннан килеп чыкканнар, өченчедән, төбәкләрдә җитәкче урыннарда шул ук коммунистлар утырып калды һәм аларның антикоммунистик сәясәт алып барасы килеп тормый. «Яңа революция» булмаячак.

КПСС белән союз мәркәзен таркаткач, демократларның көрәшер нәрсәсе калмады һәм бу хәл аларның үз сәясәтләрен үткәрү юлында җитди киртәгә әверелде. Шуңа күрә демократлар кабызып җибәрергә тырышкан нәфрәт аларның үз башларына гына төшәчәк.

Русия демократлары коммунистларга каршы «интернациональ» фронт тудыра алмады. Әйе, киресенчә, милли хәрәкәтләр йөзендә Русия демократлары үзләре дә сизмәстән хуплау түгел, ә оппозиция очратты. Милли аңның хосусиятен бөтенләй аңламауны Мәскәүнең Чәчәнстанга карата алып барган сәясәте ачык күрсәтә. Чәчән-Ингушстанда коммунистик режимны бәреп төшерүдә файдаланылган көчләр Русиягә мөнәсәбәттә коммунистларга караганда да битарафсызрак булып чыкты. Мәркәзнең һәр басымлы адымы саен җавап реакциясе көчлерәк була барды, бу Русиягә каршы тору теләген көчәйтте генә.

Русия халыкларында эчке аерымлану урысларда булганга караганда азрак һәм шунлыктан аларда сыйнфый көрәш ихтималы да кимрәк. Милли азатлык

булмас борын алар өчен тышкы каршылыклар эчкеләренә караганда әһәмиятле булып торачак. Шуңа күрә «милләтче»ләрнең хисләре дә башкарак юнәлештә. Бүгенге көндә күп кенә этник төбәкләрдә нәфрәт объекты булып коммунистлар түгел, ә урыслар тора. Начар тормыштан зарланганда «милләтче»ләр Мәскәү ягына күрсәтәләр. Аларның нәфрәте үзенә бер төрле, чөнки, гомумсоциаль мотивлардан тыш, анда этник мотивлар да — күп очракта гасырлар буе җыелып килгән үпкә һәм мыскыллар да килеп кушыла. Аяныч хәл, ләкин бу шулай. Нинди генә сурәткә керсә дә, нәфрәт булып кала инде ул. Революцион нәфрәтме ул, «демократик» нәфрәтме,— гаделме, гаделсезме — барыбер, аны матур гына итеп үз максатларына ирешергә теләгән төркемнәр файдалана ала. Тышкы «дошманнарга» булган мөнәсәбәтне җинел генә эчке процессларга да кайтарып калдырып була икәнен аңладылар да алар, шуның белән бөтен халыкның җанын җәфалый башладылар. Кызганыч хәл: нәфрәт психологиясе үз фәлсәфи нигезен дә таба. Чаллыдагы Татар иҗтимагый үзәге координаторы З. Әһлиуллин: «Без бүген туган телебез өчен көрәштә этләр белән бүреләр кебек булып калдык. Үз теле, үз дәүләте өчен көрәшкәннәрне бүреләр кебек, дибез,— көчле якта торган, сораган кулына хәер садакасы ала алган татар малаен, эткә саныйбыз. Бүреләр этләргә караганда азрак була. Әмма алар этләрдән рух өстенлеге белән аерылып торалар. Милли хәрәкәттә без, бүре рухы бетмәгән ирләрне берләштереп, этләрне ашарбыз һәм «тулысынча җиңүгә ирешмичә калмабыз» («Шәһри Казан», 21.08.92). Бу «хайванлык» психологиясе белән халык мәнфәгате арасында бернинди дә уртаклык юк, чөнки, андый психология мәдәни, зыялы халык нигезенә түгел, ә хайвани инстинктларга нигезләнгән була. Мондый «хайванлык» фәлсәфәсе «алдагы җиңүләр» белән рухландырып, кешеләргә нәфрәт сабагын укыта. Ягъни теләсә нинди сәяси көрәш рәвешләре һәм ысуллары хакимият башына басу юлында аклана дип әйтергә тырышалар.

Хаким буласы килү кеше холкының иң гаҗәп бер дәртедер. Ул адәм балаларын төрле-төрле эшләр эшләргә дучар итә һәм бер дә ярамаган юлларга да алып кереп китә. Хаким буласы килгән кеше, үз максатына ирешим дисә, бер нәрсәдән дә чирканып тормасын, янәсе, менә хәзер тиз генә тиешле нәтиҗә бирердәй теләсә нинди — антикоммунистикмы ул, коммунистикмы, олуг патшачылыкмы (великодержавный), әллә миллиме, динимe,— барыбер, шул идеологик пәрдәне күз алдына төшереп куя да үз эшен эшли башлый.

Хаким буласы килүнең, әгәр дә ул төп максатка әверелмәсә, әллә ни куркынычы да юк кебек үзе. Ләкин хаким булып алгач, әфәнделәрнең нәфесе кузгала башлаганы да мәгълүм. Хаким булып тәхеттә утыру хакына ул әлеге халык кальбендәге үч вә нәфрәтне файдалана башлый.

Нәфрәт хисе үз дошманын тапмый калмый. Эзләгәнен таба да ул — ул чакта инде син читтә карап кына тор! Өстен чыгу кирәк ул нәфрәт хисенә. Аста калырга яратмый ул. Гражданнар сугышы шушы нәфрәт идеологиясенең йомгагы булды. Бүген исә нәфрәт хисе кешеләрне яңа орышларга этәрә бугай.

Чын хөррият курку-куркытуны һәм нәфрәт хисен кичеп үтү ул. Демократия — сәяси һәм гомуми зыялыкка ирешү. Аны син җәмгыятькә көчләп тага алмыйсың. Файдасыз гамәл! Демократия, дип, көрәшеп азапланмыйлар, көрәшкәндә — тоталитаризм белән көрәшәләр. Ә демократияне су сибеп үстергән кебек үстермичә булмый — әгәр дә без һәрбер кешене гөл итеп күрә алсак иде, аның һәр яфрагыннан көн саен курку-өркү тузанын сөртеп торырга кирәк булыр иде, башка фикерләргә, телләргә, мәдәниятләргә зур ихтирам саклап, гөлләр кояшка борылган кебек, без дә башларыбызны алар тарафына борырга тиеш булыр идек.

## III. Русиянең күрәчәге: җавапсыз сораулар

### Русиянең баганаларын кем какшаткан соң?

Нәрсә соң әле ул Русия? Бу сорауны әле кичә генә беркем дә беркемгә дә куймый иде шикелле. Сәясәтчеләрне дә, халыкны да аерып тормастан әйтәм моны. Олуг урыс патшалыгы бетте, дөньядагы олы кешеләрнең фикерен гел дулкынландырып торган бөек мәдәният тәмам! Олы Русия үзенә

бернинди дә яңа фикер бирә алмаган яңа җитәкчеләре белән бер ялгызы аерым утырып калды.

Русиядә бара торган тормышны «шулай булырга тиеш иде инде ул» дип тә аңлатырга була. Империяләр бетәргә тиеш. Чынында да, бөтен империяләр дә таркалгач, Русиягә генә чират җитми торуы гаҗәп булыр иде. Мәсьәлә ачык шикелле. Хәлбуки, ничек итеп әле ул Русия, 1917 елгы һәлакәтләрдән арынып, аягына торып баса алган да, «совет» исеме белән үзен яңарта алган? Һәм бу хәлнең безнең көннәрдә дә яңадан булу ихтималы юкмы?

Русия патшалыгының фикри нигезләре Казан патшалыгын яулап алу һәм аннан соң мәскәүләрнең бүтән җирләрне басып алуына кайтып кала. Ул чакларда «Мәскәү өченче Рим» дигән, православие дине бөтендөнья әхваленә бик нык тәэсир итә, дигән, урыс җәмгыятенең әйләнәсендәгеләрне үз янына җыюы (җәмигъләгы) һ. б. турындагы әкиятләр урыс халкы аңына бик нык тукылып торыла. Ә дәүләт структуралары исә Алтын Урдадагы корылышны үзендә урнаштыра. Хаклыкка хилаф булмасын өчен әйтеп үтик, Явыз Иван (IV) заманында урнаштырылган «тәртипләр» яңа патшалыкка яңа вәхши хосусиятләр дә бирә. Ә аннан соңгы патшалар моңа үзләреннән «өлеш» кенә кертә килә. Беренче Петрдән соң Алтын Урданың йогынтысын Польша үрнәге, яки Көнбатыш Украина вариантындагы Көнбатыш сәясәте алыштыра. Русиянең сәясәте яңадан-яңа җирләр яулап алу, халыкларны буйсындырып, экономиканы шул җирләрдә җәеп үстерү, патша исеме һәм дә гаскәр көче белән, атлы казаклар һәм кәгазь түрәләре ярдәмендә бөтен кешеләрне бөкерәйтеп йөрергә юнәлдерелгән иде.

Демократия башлангычлары, Русиягә капиталистик мөнәсәбәтләргә ияреп кереп, 1905 елгы һәм 1917 елгы вакыйгаларга килеп тереләә. Инкыйлаб (революция) алдында булган дәверләр аңнарны гомумдемократик һәм социалистик фикерләр белән аклый, бик тә күркәм урыс мәдәниятен хасил итә. «Байлар оясы» дигән әүвәлге «багана»ларны капиталистлар да, язучылар да бик нык какшатты: алар «ризасызлыкның соң чигенә җиттек» дип тәкърарлады. Һәм империянең вәйраны өчен бер каты селтәнеп алу гына кирәк булган икән — беренче бөтендөнья сугышы кабынып та китә.

Урыс илендә социалистик идеяләр матур гына иңеп тә киткән булган иде шикелле. Чөнки ул идеяләр бергә-бергә эшләү-яшәү гадәтләрен алга сөрә иде, урында утыручыларга карышмаска кирәк, дия иде, тигезлек кирәклеге турында әйтә иде. Социализм Русия өчен бер дә чит нәрсә түгел иде. Киресенчә, Русия өчен чит нәрсә демократия булды.

Русиянең изелгән халыклары «революция» дигән сүзне үз якларына файдаланмакчы булганнар иде. Ләкин, Финляндия белән Польшадан башкалары, ничек булган, шул хәлдә империядә кала бирделәр. Моңа булышучы факторлар: халыкларның үз эчләрендәге сыйнфый аерылулар; большевикларның демократик лозунгларына ышанып, халыкта милли азатлыкка ирешү өмете уяну; «ак» армиянең һаман саен «бердәм һәм бүленмәс Русия» дип тәкърарлавы, Мәскәүнең «әйбәт» баш эшләтүе һәм Кызыл Гаскәрнең империя структураларын тиз генә үз урынына китереп утыртучы куәт булуы.

Кызыл Гаскәр куәте генә түгел, большевикларның идеяләре дә күркәм иде. Октябрь инкыйлабы империализмга, колониализмга каршы чыкты. Кырыс тормыш тәртипләрен шатырдатып ватты. Социализм гаделлек һәм тигезлек вәгъдә итте. Яңача иде бит болар, күркәм иде. Русиянең олуг патшалык фикере бөтенләй башка рәвеш алды — дөнья революциясе ясап, имештер, җир йөзендә тигезлек һәм гаделлек урнаштырачаклар!

Хаклык хакына, ул елларда башка милләтләр интеллигенциясендә урыс мәдәниятенә бик тирән ихтирам булганлыгын әйтми китеп булмастыр. Урыс язучылары, галимнәре, сәясәт әһелләре «милләтче»ләр өчен бик «зур абруй» иде — алардан күп нәрсәгә өйрәнделәр һәм аларга ышанып яшәделәр. Бик күпләр шушы бөек дәүләттә торулары, аның бөек әдәбиятына һәм мәдәниятенә ни дәрәҗәдәдер катнашлары булу белән горурлана иде. Нишләсеннәр соң? Коммунистик идеология кешеләрне рухландыргандыр, бергә туплагандыр инде...

Бүген инде бу факторлар юк. Урыс мәдәниятенең элекке абруе нык төште: беркемгә дә һәм бернәрсәгә дә охшатып эшлисе калмады. Урыс язучыларының съездлары ваклыклары һәм фантазия юклыгы белән шаккатыра. «Распутиннар»ның нотыклары, Куликово сугышы белән башланып, евангелие вәгазьләре белән тәмамлана. Урысның миллилеге тәре үбүләргә; җәзалап үтерелгән Русия монархы турында авыз суларын корыта-корыта сөйләүләргә һәм «мең еллык» патшалыкны саклап калырга өндәүләргә кайтып калды. Бу сүзләрне моннан йөз

еллар элек кенә интеллигенциясе ярты дөньяны үзенә каратып торган милләт вәкилләре сөйли. Ә бит ул чактагы интеллигенция андый абруйны патшаларга мәдхия укып түгел, ә хөррият идеяләрен яклап яулап алган иде. Толстойлар, Достоевскийлар, Чеховлар, публицистлар һәм XIX йөз ахыры — XX йөз башы фәйләсуфләре патша Русиясе гадәтләрен мактап сөйли ала идеме соң? Бүген исә урыс әдәбияты шундый дәрәҗәгә төште ки, ул Русия бик авыр кичерә торган фаҗигане дә янарыш дип исәпли.

Русиянең атом-төш потенциалыннан башка бер юньле бөек нәрсәсе калмаган, ахры, дигән тәэсир туа...

Революциядән соңгы Русиядән аермалы рәвештә, бүгенге Русиянең бер генә идеологиясе дә юк, ә демократия турындагы гомуми лозунглар һәм көне-төне коммунистларны хурлау белән генә этник һәм мәдәни яктан шундый чуар илне берләштерү мөмкин түгел. Антикоммунизм киң халык массалары өчен идеология булып тора алмый, ул бары тик үткәндәге идеологияләрне җимерергә генә ярый, хакимлеккә омтылучы кешеләргә бер корал гына ул. Хакимлек — күп кешегә насыйп бәхет түгел. Төп масса исә дөньяга ачык күз белән карый, аңа әхлакый кыйммәтләр, иман кирәк. Марксистик фәлсәфә юк икән, аның урынын башкасы алыр. Ләкин Рәсәй халкына бүген нәрсә тәкъдим итәләр соң? Антикоммунизм һәм православие! Беренчесенең кызыгы юк инде, ә икенчесенә бөтен кеше дә иман китерергә ашкынып тормый...

Урыс интеллигенциясе алдынгы идеяләр чыганагы булудан туктады, ул хәзер үзе бөтенесенең: валютасы йөри торган теләсә кайсы ил — АКШ, Төркия һ. б. авызына карап тора. Русия, милли горурлыгын югалтып, теләсә кайдан ярдәм сорый. Бөтен җир йөзе буйлап хәер сорашып йөргән ил башкалар өчен үрнәк булып тора аламы соң инде?! Русия гап-гади таркалуга дучар.

Коммунистларны туйганчы сүгәргә мөмкин, ләкин кимчелекләре җитәрлек булган булса да, алар бар халыкларны тыгыз кыршау белән «Советлар Берлегенә» берләштереп куйган кыйммәтләр барлыкка китерә алды. Революция алды концепцияләре җыелмасында социалистик концепция тарихи традицияләр белән иң нык бәйләнгәне иде. Ул Русиянең тирәндә яткан ихтыяҗларына җавап бирә иде. Бүгенге көндә идеологик бушлык барлыкка килде, ә бу безнең карашларыбызны борынгыдан килгән дөньяга юнәлтә. Әмма бит һәр халыкның үз тарихы була. Шуңа күрә кешеләр этник үткәннәрен искә төшерә башлады, «милли тормыш белән канәгать» булып, республика мәнфәгатьләре белән яшәргә тотынды.

Урыс идеясе бик аяусыз кризис кичерә. Урыс милләтенең төп рухи баганасы булган православие базар мөнәсәбәтләре һәм демократия белән начар килешә һәм шуңа күрә хәтта урысларны берләштерү вазифасын да үз өстенә ала алмый. Демократия урыс традицияләренең тамырына балта чаба, чөнки ул традицион тоталитар фикерләү белән хакимиятнең үзәкләштерелгән структурасына каршы төшә, коллективизм урынына индивидуализм һәм шәхес ирекен тәкъдим итә, башка илләр белән «хәрби узыш» урынына гади хезмәт белән шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Демократия Русия алдына катлаулы мәсьәлә китереп куйды.

Русия җитәкчелегенең гомуми концепциясен тикшерә башласаң, ә ул Русиянең бөтенлеген сакларга тели микән соң, дигән сорау алдында каласың. Һәм демократия ягында торган хәлдә «меңьеллык» Русияне саклап калуны яклап чыгу мөмкин эшме ул?

## Русиянең чик буйлары кайдан үтә?

Борылыш дәвере кешеләрне кайвакыт шулкадәр бутап бетерә ки, алар инде сәбәп белән нәтиҗәне дә аермый башлый. Менә Русиядән дә Татарстан адресына, имештер, ул мәңгелек корылмаларны җимерә, дип күпме нәгърәләр яудыралар. Котелмәгән афәттән аптырашта калган урыслар беркатлылык һәм еш кына ихластан: «Шундый әйбәт кенә яшәгәндә...» дип куялар. Аларның уфтануларын аңлап була: алар, күп кенә яктан үзләре дә үз олуг патшалыкларының корбанына әверелгән иде.

Империяләрнең, табигый оешкан полиэтник дәүләтләрдән аермлыгы шунда ки, алар да инде элегрәк оешкан халыкларны көчләп «берләштерә». Монархчы үз дәүләтләре булмаган этнослар мәгълүм бер дәрәҗәдә язмышлары белән әле килешеп тә яшәргә мөмкин, ләкин булган дәүләтләрен югалткан халыклар репрессив органнарның бераз йомшаруы белән империя нигезләрен күккә очыры-

рдай шартлаткыч матдәгә әверелә. Шуңа күрә империя үзенең бөтенлеген саклап калу өчен көч белән ассимиляция сәясәтен үткәрергә тотына. Ләкин бу сәясәт, мәгълүм нәтиҗәләр бирә алса да, мәсьәләне принципта хәл итә алмый.

Моннан беренче менә мондый йомгак килеп чыга: көчләп берләштерелгән халыклар табигый берлек хасил итә алмый. Тормыш күрсәткәнчә, монда дәүләтнең үзенең күпме яшәгән булуының әһәмияте юк икән. Мәсәлән, болгарлар Төркия протектораты астында 700 ел, эстоннар алманнар астында 500 ел, ә аннары әле урыс хакимлеге астында шактый торды, тик барыбер азатлыкка сусауларын онытмаган булып чыкты.

Урыс милләтенең үзенчәлеге шунда ки, аның тормышы гасырлар буе яңа яулап алуга җайланган иде. Биредә гади халыкның моннан файда күрү-күрмәвенең әһәмияте дә юк иде. Язмыш аңа нәкъ менә шундый миссия әзерләгән иде. Бер үк вакытта урыс милләте ике милләткә аерылган кебек булып чыкты: колонизация җимешләре белән туенып яшәүче «башкала» милләтенә һәм үз хәлләре дә буйсындырылган халыклар хәленнән әллә ни аерылып тормаган «провинциаль» милләткә. Санкт-Петербург милләтнең түгел, ә дәүләтнең ясалма башкаласы булды — аны чит ил кешеләре урыс сөякләре өстендә корды. Революциягә кадәр урыс мәдәниятен Мәскәү гәүдәләндерә иде, ләкин совет чорында ул тулысы белән милләтсезләнеп бетте... Моннан тагын бер йомгак ясап була. Өлкәләрдәге урысларның «тәртибе» Мәскәүдә утыручылар уйлаганча булмаска да мөмкин.

Планетаның 1/6 өлешен шундый тизлек белән яулап алу урыс милләтен үз тарихи ватанын онытуга китерде. Киев хәзер башка дәүләттә калды. Мәскәү исә иксез-чиксез үз проблемаларына кереп баткан сәер бер конгломератка әверелде. Кара туфраклы булмаган җирләргә беркемнең дә исе китми. Гасырлар буе барган колонизация дәверендә, Мәскәү кенәзлегеннән бик еракта чакта урыслар яңа этник шәкелләр дә үзләштерде. Ул гына да түгел, алар яңа җирләрдә яңа мәдәниятләр белән берегә башлады. Гомумән, урысларны «ачык» милләт дип әйтеп тә була. Алар башка халыклар белән бергә-бергә яши ала. Һәм шуңа күрә өченче йомгакны да чыгарып була: урыслар республикаларда андагы төп халыклар белән бергә үзбилгеләнергә әзер, алай гына да түгел, аларның Ерак Көнчыгышта, Себердә һ. б. җирләрдәме Мәскәүдән бәйсез булган мөстәкыйль дәүләтләр төзеп ташлаулары да бик ихтимал.

Югарыда әйтелгән факторлар Русиянең таркалу процессын аңларга һәм туачак дәүләтләрнең мөмкин булган чик буйларын фараз кылырга ярдәм итә.

1992 елга кадәр Русия юридик мәгънәдә СССР белән тәңгәл килә иде. Монда ике нәрсәне истә тотарга кирәк: беренчедән, урыслар халыкара аренада нәкъ менә СССР йөзендә китереп куела иде (дәүләт теле һәм мәдәнияте белән). Чит илләрдә сүз арасында да, матбугатта да СССРны Русия дип кенә, ә барлык совет кешеләрен — урыслар дип кенә йөртә башладылар, һәм бу дөреслеккә әллә ни хилафлык та түгел иде. Икенчедән, РСФСР ул чакларда шәхсән дәүләт түгел һәм аның суверенитеты юк иде. Хәер, аның мөстәкыйль компартиясе дә юк иде, бу үзе генә дә асылда СССР белән Русиянең тәңгәл килүен, һичшиксез, исбатлап тора иде.

РСФСРның суверенитет игълан итүе һәм аннан да битәр, СССРны юкка чыгару тарихи урнашкан Русиянең таркалуын башлап җибәрде. Бүгенге Русия Федерациясенең «тарихи Русия» ролен дәгъва кылырга нигезе юк. РСФСР, гомумән дә, Сталинның субъектив конституциясе, һәм үзенең бүленмәс булуына хаккы элеккеге СССРныкыннан бер тамчы да артык түгел. Һәрхәлдә, Украина, әйтик, Татарстанга яки Себергә караганда, Русия җирерәк. Юк дигәндә дә, Киев бит кайчандыр борынгы Русьның башкаласы булган, ә Казанны алай дип кем әйтә алыр икән?!

Русияне СССРны саклаганда гына саклап калып булыр иде: М. Горбачев бу юнәлештә тырышып та карады,— өлешчә, Союз төзеп һәм референдум үткәреп. Хәлбуки, аның хатасы реформаларының ярты-йортылы булуында, «милли мәсьәләне тулаем хәл итәсе урынга төрле» функцияләрне мәркәз белән союздаш республикалар арасында бүлешергә азаплануында иде. Ә референдумы бөтенләй дә файдасыз бер акт иде, чөнки этник проблемаларны урыслар күпчелеге фикерен ачыклау белән хәл итеп булмасы көн кебек ачык лабаса.

Ә шулай да Русия өчен иң фаҗигый хатаны М. Горбачев түгел, ә СССРны кулдан ычкындырып, Б. Ельцин ясады. Хакимлек өчен көрәш демократларның башын шулкадәр әйләндерде ки, алар вакыйгаларның кай якка таба китәсен дә фараз итә алмый башлады — аларга дәүләт түгел, ә хакимлекне алу һәм моңа бик тиз ирешү кирәк иде. Мәзәккә охшаш хәл килеп чыкты: демократлар Русиянең

суверенитеты өчен дәүләт атрибутлары да булмаган урыс милләтенең мескенлеге аләмен күтәреп көрәшә башлады. Алар хакимияткә иреште, әмма элекке Русияне югалтты, ә яңа Русияне төзүе искесен саклауга караганда катлаулырак шул ул.

Бүген Русиянең төгәл чикләрен сызып чыгу мөмкин түгел. Халыкларның үз ирекләре белән Русия дәүләтенә килеп кушылулары турындагы әкият реаль дөньядан хыял дөньясына чыгып яшәүче беркатлы һәм бик садә кешеләргә генә ярый. Төрле жирләрнең «үз ирекләре белән» төрле-төрле һәйкәлләр — коллык һәйкәлләре, һәм аларны әүвәлге «номенклатура» куйды, ә хәзергеләре тырышып саклый килә. Төп, тамыр халыкларның Русиягә исәп-хисап китереп тоттырыр заманнарына күп калмады инде, менә шунда урысның үз жире Бальзакның атаклы «җәйрән тиресе»сыман бөрешкәннән бөрешә барачак...

Урыс милләтенең этник сибелеп утыруы сәясәттә шактый зур роль уйнаса да, хәлиткеч фактор һәм бигрәк тә дәүләт чикләрен билгеләүче фактор булып тормый. Инде бүгенге көнгә үк 26 млн. урыс кешесе Русия Федерациясеннән тышта калды, һәм аларның, әйтик, Казагыстан өлкәләрендә тоташ-тоташ урнашкан булуларына карамастан, бу хәл Русия Федерациясе чикләрен билгеләүгә бер дә тәэсир итмәде. Ә ник соң әле бу Русия белән Татарстан мөнәсәбәтләренә йогынты ясарга тиеш, ди?!

Урыс милли идеясе кризис кына кичереп калмый, ул принципта демократия белән сыеша алмый һәм шуңа күрә башка идеология белән алыштырылмый калмастыр. Әлбәттә, үткәнне сагынучы национал-патриотлар әле халыкның бер өлешенең фикерен үз якларына шактый каратып торыр, әмма шуның белән бергә яңа идеология дә туып килә. Ул конкрет төбәкләргә: Ерак Көнчыгышка, Себергә, Донга һ. б.ларга нисбәтле. Урыс өлкәләре дә гомумән алганда Татарстан үткән юлны кабатлаячак: башта алар, безне Мәскәү эксплуатацияли һәм безнең Русия колониясе булып яшисебез килми, дияччәк. Аннары күпме бирен, күпме генә алганнарын исәпли башлаячаклар, нинди зур ресурслары булуын һәм сәяси мөстәкыйль булсалар, алардан файдалана беләчәкләрен искә төшерәчәкләр, бер каналлы бюджет, тышкы экономик мөнәсәбәтләргә хокук таләп итә башлаячаклар һәм, ниһаять, үзләрен мәркәз догъваларыннан аралый торган үз законнарын кабул итәргә тотыначаклар...

Бөтен дөньяда хакимиятне дезинтеграцияләү тенденциясе барганлыгын да әйтеп үтик. Хәтта федератив мөнәсәбәтләр шундый камиллеккә ирешкән Германия белән АКШ кебек илләрдә дә мәркәз һәм федераль хөкүмәт белән федерация субъектлары булган штатлар һәм төбәкләр арасында каршылыклар сизелепсизелеп ала. Аурупаның бөтен илләрендә дә диярлек провинцияләр ил эчендә генә түгел, халыкара мөнәсәбәтләрендә дә һаман күбрәк мөстәкыйльлек яулый баралар.

Төбәк мәнфәгатьләре һәм тулаем региональләштерү идеясе Русияне идеологик тупиктан тартып чыгарырга мөмкин.

Русия торган саен үзгынчылрак төшенчәгә әйләнә бара, ул төшенчә шактый ук аныk булмаган хисси лозунгларга кайтып кала. Русияне әүвәлге төсендә саклау мөмкинлегенә бер генә өмет тә юк. Аның якынча гына чикләрен билгели ала торган хокук нормалары юк. Әгәр дә Русия житәкчелеге реаль федеральләшү юлына басса, ул чакта ни буласын төгәлрәк фаразлап булыр иде. Әмма житәкчелек федератив мөнәсәбәтләргә омтылмый шикелле. Хәер, Русияне саклап калырга телиме соң ул?

## Федерацияме, конфедерацияме, әллә бәйсез дәүләтләрме?

Русия федерация яисә конфедерация дә була алыр иде, һәм бәйсез дәүләтләр булып таркала да ала. Теоретик яктан өчесенең дә булуы ихтимал. Аларның берәрсенең тормышка ашуы өчен конкрет объектив һәм субъектив шартларның туры килүе генә кирәк.

Соңгы елда матбугатта Русиянең милли-дәүләтчел корылышы хакында буа буарлык аналитик мәкаләләр чыкты. Аларның күбесе олуг патшалыкны сакларга иде, дигән ялкынлы өндәмәләргә кайтып кала. «Литературная Россия»дә (16.10.92) Ксения Мяло үзенең «Бүре чокыры» дигән мәкаләсен менә мондый сүзләр белән тәмамлый: «Ә шуның өчен, әгәр милли яшәвебез хакында ихтыярыбыз уяна икән, Русияне без, аны нинди генә вак кисәкләргә телгәләп бетерсәләр дә, кире җыеп алмый калмабыз. Чөнки жаныбыз — аларны, ә алар безнең жанны, ягъни үз жанын танып алыр». Матур әйтелгән әйтелүен. Ләкин мондый

мәкаләләрне укыгач, Русия аналитиклары һаман да шул борынгы «Ә бәлкем!», «Ә, бәлкем, барып чыгар әле» дигән сүзгә таяналар бугай дигән тәэсир кала. Ләкин бит Кара диңгездә төп портлары да югалды ич инде, Көньяк чик буйлары Әстерхан белән Ырынбурга таба чигенде, яңа Кавказ сугышы кызганнан-кыза бара. «Артыбызда Мәскәү ләбаса» дигән тарихи чакыру хәзер халыкка элеккеге тәэсирне ясамавы да бар.

Ташламаларга әзер күп кенә сәясәтчеләр һәм публицистлар, Русиянең славян һәм төрки халыкларын, ислам һәм христиан мәдәниятләрен кушып ниндидер бер симбиозга әйләндерүче Аурaзиячел дәүләт булуы турында тезис уйлап чыгарды. Аларның нәрсә әйтергә теләгәннәрен сизүе кыен түгел: имештер, йөз еллар бергә яшәү дәверендә татар һәм рус этнослары тәмам кушылып беткән һәм безнең янәсе, бүлешер нәрсәбез юк. Үзләре теләгән теләкне һаман кабатлап торып, алар кешеләрне генә түгел, вакыйгалар барышын да сихерләмәкче. Беравыктан үзләренең шул «сихер»ләренә җүләр кебек үзләре дә ышана башлыйлар. Ләкин чынбарлык бөтенләй андый түгел. Коми халкының бер генә милли мәктәбе дә юк. Кая инде монда «халыклар берлеге»нә урын?! Шушы бер генә факт та башкаларын карап та тормаска безгә нигез бирә. Русиядә халыклар хокукының ни дәрәҗәдә бозылып килүен фаразда гына күзалларга мөмкин. Бу мәсьәләнең әле көн тәртибенә калкып чыгасы күренеп тора, менә шунда инде күп халыклар Русиягә үз исәп-хисапларын китереп төртерләр.

Субъектив фактор тарихта гаять зур роль уйный. Фиркаләрнең, идеяләр һәм юлбашчыларның вакыйгалар барышына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын белер өчен Ататөрек белән Ленин принципларын чагыштырып карау да җитә. Ул ике империя дә бер үк вакыта диярлек туарыла башлый. Хәлбуки, төрекләрнең читтәге төбәкләрдән баш тартырга ирлеге җитте, һәм үз җирендә милли дәүләт корып куйды, большевиклар исә бар булган көчләрен әлеге җирләрне саклап калырга һәм империяне торгызуга юнәлтте. Тарих бүген Русия юлбашчылары алдына шул ук сорауны китереп куя. Йә, бу юлы алар нишләр икән?!.

СССРны кулдан ычкындыру, объектив рәвештә өлгергән булса да, империягә каршы хакыйкатьләр белән терәтелмәгән иде, һәм шуңа күрә дә Б. Ельцинның бу адымы Русия җитәкчелегенең йөзен күрсәтми. Сүз уңаенда әйтик, Союз килешүе проекты, республикаларны «сорт»ларга бүлү сакланып калган очракта да, милли-дәүләтчел корылышны федеральләштерүгә таба бер адым була иде.

Русиянең Федератив килешүе бу сәясәтнең аңлы дәвамы була алмады, киресенчә, ул суверенлашу процессларын бүлеп, шактый күп империя структуралары калдыруны — Союз һәм Русия министрлыкларының түзәлмәслек салымнарны, тышкы икътисади элементләрне бер мәркәз кулына туплауны һ. б. саклап калу максатын күздә тотты. Тарихи документ буларак, Федератив килешү бик тә гыйбрәтле һәм аны ныклап торып тикшерәсе, аннан сабак аласы иде.

Иң элек бер гади генә сорауга җавап биреп карыйк: Русия нинди гамәлгә кую документларына таянып тора соң? Монархия алыштырылды, тоталитаризмны кире кактылар, демократия курсы игълан ителде, ләкин гамәлгә кую мәҗлесе (Учредительное собрание) җыеп азапланмадылар. РСФСРны төзи башлау шулардан кузгалып киткән 1918 ел документларына да («Россия халыклары хокуклары декларациясе» һ. б.) әйләнеп кайтып булыр иде дә, ләкин аларда Федерация субъектлары буларак, өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләрнең катнашуы каралмаган. Шулай итеп, яки Федератив килешүдән субъектлар сыйфатында административ берәмлекләрне алып ташларга кирәк була,— ул чакта Русиянең хокукый нигезе барлыкка килә,— яисә Русияне өр-яңадан гамәлгә куярга, урынлаштырырга гына кала. Русия җитәкчелеге өченче һәм иң яман вариантны сайлап алды шикелле — бернәрсә дә урынлаштырып тормыйча гына, иске унитар бинага ялган демократик игъланнар эләләр.

Өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләр белән алай санлашып торуның нигә кирәге бар соң? Эш шунда ки, аларның үзләре чикләрендә яшәүче халыктан урынлаштыру вәкаләтләре алганнары юк. Алар бары тик административ берәмлекләр генә, аларның үз югары хакимиятләре, конституцияләре һәм үз кануннары юк. Шунлыктан җитәкчеләренең Федератив килешүгә кул куярга хаклары да юк. Менә шушында инде Руссиянең бөтенлегенә куркыныч яшеренеп ята. Шундый әһәмиятле мәсьәләдә аларга үз белдегенчә эш кылырга рөхсәт ителгән икән, башка мәсьәләләрдә дә алар хаксыз юлдан китеп бармаслар, дигән гарантия юк. Ул гына да түгел, Федератив килешү, республикаларны административ берәмлекләр белән тигезләп, соңгыларына «сепаратизм»га кануни сылтау да бирә. Хәзер өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләр, дәүләт суверенитеты турында декларацияләр кабул итеп тормыйча, референдумнар үткәреп турыдан-туры президентлар сай-

лап маташмыйча, Конституцияләр һәм башка законнар кабул итмичә дә, үзләренә суверен республика хокукларын таләп итә ала. Carte blanche аларга нәкъ менә федераль хөкүмәт тарафыннан, Русияне таркатуга китерә торган уйлап житкерелмәгән адымнар нәтижәсендә бирелде.

Әйтелгәннәрдән мондый нәтижә килеп чыга: Федератив килешүне Русияне гамәлгә куючы документ дип карап булмый, асылда ул үзәк хөкүмәтнең административ берәмлекләр белән хокукларны яңадан бүлешү турында килешү генә. Килешүе дә әле канәгатьләнерлек түгел, чөнки, аңа карагач, мәсәлән жир асты байлыкларының кем кулында — субъекттамы, мәркәздәме — икәнен дә ачыклавы кыен. Хокукый документлар катлаулы мәсьәләләргә ачык җавап бирергә тиеш. Шулай булмаганда, алар каршылыклар чыганагына әверелә.

Федератив килешү — олуг патшалыкның бүленмәслеге турында «автономияләр» имзалары белән беркетелергә тиешле документ, үзенә күрә «Русия ана-кай»га тугрылык турында ант иттерүче сәяси акт булып чыкты. Бер үк вакытта федераль хөкүмәт М. Горбачевка караганда бер адым арткарак атлады һәм 20 нче еллар гамәленә кире кайтты. Аерма шунда гына: әгәр большевиклар бу процедураны республикаларны декретлаштыру дип атап, автономияләргә Федератив килешүдән күбрәк вәкаләтләр биргән булсалар, Русия житәкчелеге Көнбатыш колагына ятышлы атамалар артына сыенырга мәжбүр булды. Ләкин мондый «сүз» зинасы Русиянең бөтенлеген дә жимерергә мөмкин.

Федератив килешү тагын да икенче бер гади генә сорауга җавап сорый: ул аерырга мөмкин булмаган килешүне, ягъни Федерациядән чыгу мөмкинлеген калдырмаган документны, килешү дип исәпләп буламы соң әле? Азатлык азатлык инде ул. Аны мәркәз ирке, аның хәрәкәтләре иркенә куелган азатлык дип карап кала алмыйсың. Әгәр дә милли сәясәттә халыкларның аерылып чыгуга кадәр үзбилгеләнү хокукы каралмаган булса, ул чакта Русия беркайчан да демократик та, федератив та була алмаячак. Алай гына да түгел, аерылып чыгу хокукын кире кагу үзеннән-үзе республикаларның җирләрен һәм гражданлыкны да кире кагу булып чыга. Федерация унитар дәүләттән шунысы белән аерыла да: ул «бүленә ала торган» була һәм суверен төбәкләрдән тора.

Федерация тасвирламасы буенча, яңа дәүләт — хасил итә торган дәүләтләр берлеге. Союзның шулай ук суверен дәүләтләрнең ихтыяри һәм тигез хокуклы берләшмәсе икәнлеген искә төшереп үтү дә зыянлы булмас. Барлык төшенчәләрне төрлечә конъюнктурага карап, аңлата торган безнең илдә генә искә төшереп торырга туры килә: теләсә нинди дәүләт, һичшиксез, суверенлыкка ия була, ә суверенлык исә бәйсезлек дигән сүз ул, ә килешүләр субъектлар тарафыннан «астан башлап» төзелә. Инде өстән төшерелгән «килешүләргә» килсәк, андый «килешүләр» гомумән дә була алмый, федерацияне өлкәләр кора алмый, чөнки аларның дәүләтнең административ берәмлекләре буларак, гамәлгә кую вәкаләтләре юк һ. б.

Федератив килешү — дәүләт корылышы турында бөтен нормаль күзаллауларны үзгәртеп, бозып бетергән юридик корама ул. Федерация субъектлары итеп Мәскәү һәм Санкт-Петербургны кертү үзе генә дә ни тора! Алайса, ни өчен соң Екатеринбургны яисә Түбән Новгородны да кертмәскә икән? Нәрсәсе белән алар Петербургтан начаррак? Элегрәк халык саны бер миллионга житкән шәһәрләрдә метро салу гадәте бар иде. Бу иске традицияне шәһәрләрнең субъектлыгын билгеләүдә дә кулланыгыз алайса: 1 миллионнан арттыңмы — РФка кер, 10 млн.нан артсаң — БМОга туп-туры!

Әйтелгәннәр өлкә яки шәһәр федерация субъекты була алмый, дигән сүз түгел. Әлбәттә, була алалар. Ләкин әгәр дә алар моңа дәгъва кыла икән, ул чакта алар үз халкыннан вәкаләт алырга тиеш, икенче төрле әйткәндә, барлык тиешле атрибутларга ия тулы бәяле дәүләт булсыннар!

Федератив килешүнең мәгънәсезлеген аның төп текстына капма-каршы килә торган Башкортстанның махсус беркетмәсе булу да ачык күрсәтеп тора. Теләсә нинди килешүнең мәгънәсе дә килешүче якларның мәнфәгатьләрен килештерүдән тора. Килешү принципта аның мәгънәсен үзгәртә торган ниндиләр кушымталар белән була алмый. Әгәр аның белән берәрсе риза булмаса, гади генә яңа килешү төзелә.

Ниһаять, үз-үзебезгә өченче, бөтенләй беркатлы сорау бирик: федерацияләрне ни өчен гамәлгә куялар да аларның мәгънәсе нидә? Дөнья тәжрибәсе шуны күрсәтә: федерацияләр аны оештыручыларның суверенлыгын тәэмин итү өчен төзелә. Нәкъ менә шул принцип йөз елларга Швейцария һәм АКШның стабильлеген тәэмин итте. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: АКШ Конституциясендә беренче үк төзәтмә — кеше хокуклары турында — билль-штатларда ватандарларның хокук-

ларын федераль хакимият кысуларыннан саклау өчен кабул ителде һәм бары соңгы 70 елда гына алар кеше хокукларын яклау һәм саклау дигән яңа аңлатма алды. Русиядә исә бөтенесе дә киресенчә эшләнде: федераль хөкүмәтнең «суверенитетын» гарантияли, аның хокукларын субъектлар дәгъвасыннан аралый торган документка кул куйдылар. Шуңа күрә үз суверенитетлары язмышын кайгырткан Татарстан, Башкортстан, Якутия һәм башка республикаларның «тәртибе» бик тә аклана. Мәгълүм ки, Татарстан Республикасын 1920 елдагы декретлардагы хокукларын кайтарган өчен сепаратизмда гаепләргә маташалар. Ләкин аннары 1937 ел килде һәм әлеге хокукларның эзе дә калмады. Федератив килешү яки Русиянең хакимият структуралары Татарстанга яңа диктатурадан гарантияләр бирә аламы соң? Әлбәттә инде, юк. Принципта андый гарантия булып, Татарстан белән Русия арасында ике яклы килешү белән беркетелгән «чыгу хокукы» гына һәм шулай ук Татарстанның халыкара танылуы гына тора ала.

Әгәр дә Русиянең бөтен һәм бүленмәс булуыннан чыгып карасаң, ул чакта Татарстан Республикасының БМОга алынуы аны җимерү кебек күренер иде. Ләкин әгәр үзара мөнәсәбәтләрнең күп төрле конфедератив-федератив рәвешләрен тану нигезендә Русияне реформаларга чын-чыннан омтылганда Татарстанның суверенитеты Русиянең яманаты чыккан «бөтенлеге» белән бик иркен сыеша ала. СССРны искә төшерик: анда Украина белән Белорусия БМО әгъзалары иде, һәм бер генә юрист та СССРның бөтенлегенә шик белдермәде.

Бүгенге көндә Русиянең «бөтенлеге һәм бүленмәслеге» тарихи традицияләр яисә инерция аркасында гына сакланып килә. Демократия принциплары Русиянең әүвәлге тарихи урнашкан карашлары һәм нигезләре — хакимиятне монарх яки генсек йөзендә үзәкләштерү белән капма-каршы килә. Б. Ельцинның халык тарафыннан турыдан-туры сайлануы мәгълүм дәрәҗәдә бөтен Русияне гәүдәләндерә һәм лигитимлык элементын хасил итә, ләкин президент монарх түгел бит әле һәм ул үзе турында «Дәүләт ул мин!» дип әйтә алмый. Шуңа күрә Русиянең хокукый нигезе бик тә какшаучан. Азмы-күпме җитди булган теләсә нинди сәяси вакыйганың илне котылгысыз таркатып ташлавы бар. Заманында кадет Милюков «бөтен һәм бүленмәс Россия» лозунгысы антибольшевистик блокны харап итте, дигән иде. Тарих бик гыйбрәтле дә бит, ләкин аның сабакларына колак салып бетермиләр шул.

Федератив килешү кабул итеп, Русия җитәкчелеге әүвәлге империяне нормаль федеральләштерү мөмкинлеген юкка чыгарды. Теләсә нинди Федератив килешүнең мәгънәсе шунда — ул күптөрле коллизияләрне истә тотып, дәүләт эчендәге мөнәсәбәтләр үссен өчен кысалар урнаштыра. Фередатив килешү кул куйганда ук Татарстан белән Чәчәнстанны читтә калдырды, ә Башкортстан өчен махсус кушымта әзерләнгән иде. «Кысалар» республикалар, өлкәләр, шәһәрләр башлыклары имзаларының карасы да кибеп бетмәстән шартлап сынды. Ләкин шуның белән федераль хөкүмәт үзенең сәләтсез икәнлегенә кул куйды. Төньяк Кавказдагы конфликтлар бу Килешүнең кирәген бөтенләй бетерде, чөнки аның нигезендә азмы-күпме җитдирәк проблемаларны җайга салу мөмкин түгеллеге бик ачык күренде. Федератив килешүнең бер генә яшәү мәгънәсе калды — ул республикалар һәм өлкәләр өчен мәрәгә әйләнде.

Русияне Федерация итеп үзгәртү өчен мәгълүм сәяси ихтыяр кирәк, ә ул Русия җитәкчелегендә юк, ахрысы, җитәкчелек хакимлеген саклап калу турында уйлый, ә дәүләтнең киләчәге турында кайгыртмый.

Килешү «кысалары» булмаган шартларда вакыйгалар республикалар һәм өлкәләрнең фактта суверенлашу юлыннан китәр, бер үк вакытта яңа сәяси үзәкләр хасил булып, алар тирәсендә яңа союзлар оеша башлар.

## IV. Халыкларның үзбилгеләнүе һәм халыкара хокук коллизияләре.

Халыкара җәмгыять дөньяны дәүләтләрдән тора, дип кычкыра, хәлбуки дөнья халыклардан тора. Бөек патшалыклар лидерлары, дөнья тәртибен һәм сәяси процессларны без урнаштырабыз, дип уйлый. Ләкин аларның бу тәкәббер уйлары халыкларның азатлыкка һәм үзбилгеләнүгә булган ихтыярына бәрелеп уала.

Татарстан үзенең яшәп килүе белән дөнья җәмгыяте алдына күп кенә унайсыз сораулар куя: Русия аның суверенлыгын танымагач, Татарстанны тануның кирәге бармы? Анклав территориядә принципта суверен дәүләт була аламы? Татарстанны халыкара җәмгыять таныса яки, киресенчә, танымаса, моның нәрсәгә китерүе мөмкин?

Көнбатышта сугыштан соңгы еллардагы пропаганда хөррият өчен көрәш тамгасы астында барды. Шул лозунгка тиң рәвештә бөтен абруйлы дөнья демократик һәм хөрриятсез илләргә аерылды.

АКШ конгрессы һәм БМО ел саен төрле илләрдәге режимнарның торышы турында нотыклар тыңлый. Куәтле радиостанцияләр һәм абруйлы гәзитләр демократия үлчәмнәренә сыешмый торган илләр исемлеген бөтен дөньяга тарата. Шулай итеп, җәмәгать фикере оеша, ә ул демократияне яклау өчен дигән булып, хәтта сугыш игълан итүгә һәм астан таркату эшчәнлегенә, башка дәүләтләрнең эчке эшләренә тыкшынуга, сепаратчы көчләргә ярдәм итүгә һ. б. һ. б. кадәр теләсә нинди хәрәкәтне акларга мөмкин. Җир йөзендә көнбатыш демократиясенең җиңү хакына эшләмәстәй бернәрсә дә юк, диярсең.

Татарстан бөтен демократик шартларны да үтәде. Игълан ителгән суверенитет гомумтанылган халыкара хокук нормаларына туры килеп кенә калмый, ул хәтта Русия кануннарына да каршы төшми: Татарстан Республикасы Президентын турыдан-туры һәм демократик сайлаулар булып узды. Бер үк вакытта Русия Президентын сайлаулар үткәрелмәде, референдум булып узды, анда халык үзе сайлаган юлга тугры икәнлеген раслады; ниһаять, Конституция кабул ителде, анда Республика демократик-суверен дәүләт — халыкара хокук субъекты дип игълан ителде. Барлык сәяси процедуралар да Республикада чит ил күзәтүчеләре контрольлегендә барды, һәм алар демократик нормаларның аз гына булса да бозылуын сизмәде. Татарстанда теләсә нинди фиркаләр эш итә һәм төрле гәзитләр чыга, парламентта национал-радикаллардан алып Русия өчен бөтенесен бирергә җан атып торучы депутат төркемнәренә кадәр төрледән-төрле фракцияләр бар. Соң, алайса ни өчен Татарстанны халыкара җәмгыять танып чыкмады? Бәлкем, Республика андый танылу өчен соңгы шартны үтәмәгәндер — сугыш ачып җибәрмәгәндер?! Күрәсең, БМО халыклар сугыш телендә, хәрби шантаж яки деколонизация категорияләре белән сөйләшә башлагач кына алар авазына колак саладыр һәм хәрәкәт итә башлыйдыр, ә «демократик» тел әле аның көндәлек эш теленә әйләнмәгәндер?

Гадәттә чит илләр экспертлары һәм сәясәтчеләре Татарстанга карата мондый сак булуны аны иң элек Россия таңырга тиешлеге белән аңлаталар. Моның мәгънәсен аңлавы кыен түгел. Россия бит заманында бу җирләрне басып алган, алар — аның табышы. Шуннан Россиягә карап тормастан тану — бу, имеш, чит табышка кул сузу кебегрәк була...

Халыкара хокукый аң сугыш хәлендә булуның «табигыйлегеннән» чыгып эш итә. Бу кешелекнең бөтен узганыннан килеп чыга. Бүгенге дәүләтләр дә яңа җирләр яулап алу юлы белән яисә кулга корал алып азатлык өчен көрәш юлы белән барлыкка килгән. Тегесендә дә, бу очракта да тупас көч уңышка ирешүнең соңгы һәм тугры чарасы булып килгән, ә сугышта җиңүче төп хаким булган. Шуның өчен Аурупа аңына, әйтик, Югославия халыкларының суверенитет өчен корал тотып көрәшүе дә, шулай ук сербларның үз дәүләтләре бөтенлеге өчен көрәше дә барып җитә. Ләкин Аурупага халыкларның тыныч юл белән үзбилгеләнүе, бигрәк тә халыкара оешмалар булышлыгы белән үзбилгеләнүе аңлашылмый. Әлегә хәтта, сәясәтчеләр тынычлык ягыннан торып көрәшкәндә дә хәрби фикерләү мантыйгы хакимлек итә.

Халыкара аренада демократия вакыт-вакыт гаҗәеп үзгәрешләргә дучар була һәм бик нык дәрәҗәдә конъюктура сәяси мәнфәгатьләргә бәйле. Көнбатыш өчен, мәсәлән, Б. Ельцин фигурасы тылсым көченә ия диярсең, аңа терәк булу өчен көнбатыш демократиясе күп нәрсәгә күз йомып калырга да риза. Әмма тагы да гаҗәбрәге Грузия белән бәйле. Аны тиз генә танып, БМОга да кабул иттеләр.

Ә бит Э. Шеварднадзе демократик юл белән сайланган, аннары көч белән бәреп төшерелгән Грузия Президенты урынына менеп утырды. Абхазиягә каршы сугыш ачты, абхазларны ачыктан-ачык кырып бетерергә чакырып торган парламентны җитәкли башлады. Сәер, ләкин факт — Э. Шеварднадзеның дуслык җепләре Көнбатыш илләре җитәкчеләренең демократик иманнарыннан көчлерәк булып чыкты. Алай гына да түгел, кеше хокукларын, хәтта аерым шәхесләрнең хокукларын бозу мәсьәләсендә бик үзсүзле гадел булган Берләшкән Милләтләр

Оешмасы, бүгенге көнгә кадәр Абхазиядәге сугышка карата фикерен белдергәне юк. Ә бит анда асылда тулы бер халыкның язмышы хәл ителә. Әхлак белән сәясәт бергә начар сыеша, демократия лозунгысын сәясәтчеләр еш кына үзләренең дөнья белән идарә итү теләкләрен тормышка ашыру өчен файдалана.

Дөньяның дәүләтләргә бүлгәләнгән икәнлеге мәгълүм, шуңа күрә ул дәүләтләрнең үз мәнфәгатьләрен планета мәнфәгатьләреннән өстенрәк күрүләрен аңлап була. Бөтендөнья сәясәтендә мәдәни һәм сәяси төрлелек бүгенге көндә яшәп килә торган дәүләт чикләрендә тормышка ашырыла. Дәүләт чикләре — төп тамга. Шуның белән халык турында фикер йөртәләр, аның статусын билгелиләр һәм дөньяда аның торган урынын аерып куялар. Чик буйларың бар икән — сине таныйлар, алар юк икән — син халык түгел, син бары тик этнологлар игътибарына гына лаеклысың.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы бик күркәм принциплар вә максатлар бәян итте. Алар арасында гаделлек, тигез хокуклылык һәм халыкларның үзбилгеләнүе дә бар, әмма гамәлдә аларның теркәлгән һәммәсе дә Аурупа хәвефсезлек, хезмәттәшлек киңәшмәсе (АХХК) документларында дәүләтләрнең теркәлгән бөтенлеген саклауга кайтып калды. Үзбилгеләнүгә омтылган халык өчен үз-үзен танытырга бер генә юл кала — дәүләте чикләрен теләсә нинди чара белән үзенә билгеләү. Үз капкаңны үзең яп (үз дәүләт чикләреңне үзең сыз) — хәзерге дөньядагы тәртип, халыкларга шушындый шарт китереп куя.

Татарстан хәле һәм аның азатлыкка омтылышы тагын шуның белән дә катлаулана: ул анклавта калды һәм аның башка дәүләтләр белән уртак чик сызыгы юк. Хәзерге карашлардан чыксаң, аның халыкара танылуына өмет итү мәгънәсез.

Анклав проблемасы юристларга да, сәясәтчеләргә дә бик кыен хәл ителә торган мәсьәләгә әйләнеп бара шикелле. Ләкин мондый фикер аны «хәрби» проблема белән бергә бәйләп караганда гына туа ала. Чынлып та, хәрби тактика күзлегеннән караганда, анклавта калган халык — бөтен яктан уратып алынган халык булып, аның, кулын күтәреп, дошманына бирелүдән башка юлы юк. Әмма ләкин шушы ук мәсьәләгә бөтенләй башка яктан да килеп карап булыр иде, ул — дөньяда иминлек саклау ягын күз уңында тоту. Алай иткәндә, максатның асылы яңа дәрәҗәгә менә һәм үзбилгеләнү процессына яңа фактор кушыла — анысы инде дөнья җәмгате мәнфәгате була. Ул чакта инде «уратып алынган» хәлдә, тарихи үзгәрешләр яки басып алыну анклавта калган халыкларның теләген танымаучы дәүләт белән очрашабыз.

Аек фикернең «анклав» дигән төшенчә белән килешәсе килми. Тыныч көннәрдә дәүләт чикләре ачык була ала, килешүләр вә шартнамәләр кешеләрнең ирекле йөрүен тәэмин итә. Димәк ки, «анклав» проблемасы, аны киңрәк итеп алганда — үзбилгеләнү мәсьәләсе — тыныч вакытта бернинди хәрби хәрәкәт белән бәйләнмәгән, тормыш итү өчен бик тә кирәкле булган яңача сәяси фикер йөртүгә кайтып кала.

Татарстан Республикасын тану-танымау Русиянең эчке проблемасы гына түгел, ул халыкара проблема. Татарстан мисалында без хәзер дөньядагы чишелеп бетмәгән мәсьәләләрнең бик киң балкышын күрәбез. Башка дәүләтләр тарафыннан Татарстанга мөнәсәбәт, бер яктан, мәйданый бөтенлек принциплары кысасында тыпырчынучы халыкара хокук коллизияләренең бөтен катлаулылыгын күрсәтсә, икенче яктан, ул халыкларның үзбилгеләнүгә хокукы барлыгын күрсәтә. Бик нык чияләнгән төен. Халыкара җәмгыять дөнья тоткасы дип халыкларны түгел, ә дәүләтләрне санаганда һәм дәүләтләр мәнфәгате дөнья мәнфәгатеннән өстенрәк дип исәпләнгәндә, ул чишелмәс төенгә әверелә. Бу төенне чишү юлы хокукый даирәдән битәр сәяси һәм, хәтта, фәлсәфи карашларга бәйле. Дөнья халкы сугыш фәлсәфәсеннән арынып, үзара тыныч яшәү фәлсәфәсен беренче урынга куярга мәҗбүр. Татарстанга карата башка дәүләтләр тарафыннан мөнәсәбәт хәрби белән тыныч фикерләү арасындагы аерманың, алар арасында бара торган эчке көрәшнең нинди авыр, катлаулы, хәтта фаҗигале икәнлеген бик ачык күрсәтеп тора.

## АХХКның «Җимерелмәс ун сүрәсе» һәм Аурупаның бүгенге көне

Берләшкән Милләтләр Оешмасы «халыкара тынычлык һәм хәвефсезлек тәэмин итү өчен оештырылган иде. АХХК Йомгаклау актында тынычлыкны саклау юллары ачык күрсәтелгән иде. Анда Арупа илләре, шулай ук АКШ һәм Канада «Үзара мөнәсәбәтләрдә монда катнашучы илләр эш итәчәк

принциплар Декларациясен» кабул иттеләр. Анда ун принцип бар: «дәүләт чикләренең кагылгысызлыгы», «дәүләтләрнең мәйданый бөтенлеге», «эчке эшләргә тыкшынмау», «көч кулланмау яисә көч куллану белән янамау» һ. б. Бу Декларация — «салкын сугыш» заманы, Аурупаның совет басып алуыннан коты чыгып торган заманның бер сулышы иде. Дәверенә күрә ул зур казаныш булды, чөнки сугыштан соң урнашкан чик буйларын канунлаштырып куйды, шуның белән Көнчыгыш агрессиясенең ихтималлыгыннан мәгълүм дәрәҗәдә иминлек тәэмин итте.

АХХКның ун сүрәсе, бушану чоры килеп житкәч, аеруча СССРда үзгәртеп кору көннәре башлангач, әүвәлге мәгънәсен югалтты.

Ул шулай хәрби гауғаларны, хәрби тыкшынуларны бетерү максатын үз алдына куйган булгач, АХХКның ваемнарын аңлавы кыен түгелдер. Ләкин АХХК принциплары Декларациясе нигезендәге ниятләр никадәр генә изге булмасын, барыбер аларның чикләнгәнлеген танымыйча булмый. Аерым алганда, үз дәүләтчелеге юк халык хокукларына нибары берничә юллык кына урын табылган: «Үз жирләрендә азчылык милләтләр булган дәүләтләр шундый азчылыкка караган кешеләрнең кануннар каршында тигезлеккә хаклары барлыгын ихтирам итәчәк, кеше хокукларыннан һәм төп азатлыклардан гамәлдә файдалануда тулы мөмкинлек бирәчәк, шул рәвешле бу өлкәдә аларның кануни мәнфәгатьләрен яклаячак». АХХК документларында БМО Уставы таныган халыкларның үзбилгеләнү хокукларына формаль гына булса да бер таяну юк. Соңгы еллардагы вакыйгалар бу мәсьәләгә теоретик якын килүләрнең житешсезлеген, халыкларның үзбилгеләнү хокукларын гамәлгә ашыруның барышын карап-тикшереп, моңа булышлык итәрлек ижтимагый институтларның юклыгын раслады.

Дәүләт чикләренең кагылгысызлыгы принцибы беренче карашка бик камил булып күренсә дә, аны абсолютлаштырганда тынычлык гаранты булудан этносара гауғалар һәм сугышлар чыганагына әверелеп китәргә дә мөмкин. Чөнки ул гаделлек, тигезлек принцибы һәм халыкларның үзбилгеләнү хокуклары белән еш кына каршылыкка керә. Бу тезисны Югославиядәге хәлләр дә раслады. Андагы вакыйгалар Аурупадагы тотрыклылыкның бик чамалы икәнлеген күрсәтте. Халыкара жәмгыять, АХХКның «изге сүрәләре»нә таянып эш итсә дә, Югославиядә сугышның көн саен киңәя баруын читтән генә борчылып күзәтеп торырга мәжбүр булды. Ә сугыш эчендә этник «чистарту»лар бара, меңнәрчә кешеләр үлә, кешеләрнең ачуы чиктән ашып, алар озак еллар буена килешмәс дошманга әйләнә. Нәфрәт һәм бер-берсенә ышанмау әүвәлге Югославия халыклары аңының аерылгысыз бер өлешенә әверелде, югыйсә алар бер-берсенә кирәк һәм бергәбергә яшәүнең кулай вариантын таба алган булыр иде. Моның өчен үз вакытында ук сербларның кызган башларына бераз салкын су кою да житәр иде. Югославиянең бүленеше ул очракта Чехословакия юлы белән китә алган булыр иде. БМОның бу гауғага катнашмый хәле юк иде, ләкин инде бу эш ызгыш бөтен Аурупага таралу куркынычы каршына килеп баскач, ә мәсьәлә үзе тәмам тупикка килеп кергәч кенә булды.

Югославия һәм СССРдагы этносара гауғалар гомумаурупа килешүләренә караганда бик күпкә куәтлерәк булып чыкты. Югославия Аурупаны яңа сугыш упкыны янына китереп бастырды. Шуның белән ул мәйданый бөтенлек принцибын гына алга сөрүнең әле яңа сугышлар килеп чыгудан һич тә коткармаганлыгын күрсәтеп кенә калмады, алай итүнең халыкара жәмгыятькә зур зыян китерә алуын да раслады.

Юристлар мәйданый бөтенлек принцибы белән халыкларның үзбилгеләнү хокуклары арасындагы бәйләнеш хакында фикерләшә. Ләкин эш юридик гыйбарәләр эзләп табуга караганда күпкә житдирәк тора. Абхазиядәге сугыш белән нишләргә? Анда бит бөтен бер халыкның жир йөзендә калу-калмавы хәл ителә. Хәзер нишләргә кала соң инде: «АХХКның «салкын сугыш» заманында ук эшләнгән принциплары хакына абхазларны кырып бетерергә ирек бирергәме?! Кайсы кадерлерәк: халыкның исән калуымы, әллә шул халыкны изеп тора торган дәүләтнең бөтенлегеме?!»

Югославия аерым бер мисал булса да, бик тә гыйбрәтле үрнәк. Шуңа охшашлы проблемалар Русиядә, Бельгиядә, Испаниядә, Бөекбританиядә бар. Гыйракта, Төркиядә, Кытайда вакыт-вакыт бик кискен этносара конфликтлар чыккалап тора. Этносара нигездә менә күп еллар инде Индонезиядә сугыш бара. Һиндстанда һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең башка кайбер илләрендә сугыш хәрәкәтләренең туктап торганы юк.

Жир йөзендә 5000 ләп этнос яшәп ята. Шуларның бары 180 е генә үз дәүләтләренә ия. Бу халыкларның күбесенең барлыгын да белүче юк, алар дөнья

цивилизациясе үсешенең олы юлы кырыенда торып калган. Ләкин аларның үсәргә-калкынырга омтылышларын туктата торган принципның булганы юк, аларның иреккә омтылышларын туктату мөмкин түгел. Ул табигый һәм изге омтылыш, ләкин ул бүгенге дөнья корылышының һәм тәртибенең ныклыгын әледән-әле сынап тора. Халыкларның үз азатлыклары өчен көрәше нәтиҗәсендә туа торган каршылыкларны чишү механизмы табылмый торып, дөньяның тыныч йокларга хакы юк.

Боларны дәүләтнең эчке проблемалары дип уйлау беркатлылык булыр иде. Бүгенге чикләрне ныклап урнаштыру һәм бер-береннең эчке эшләренә тыкшынмау буенча әллә нинди декларацияләр кабул итәргә мөмкин. Әмма эчке процессларны тышкы дөньядан аеру һич мөмкин түгел. Бер-бер урында купкан этносара конфликтлар, кагыйдә буларак, бу көрәшкә теге яки бу халыкларны, йә этник, йә экономик якынлык арасында яклый торган башка дәүләтләрне тартып кертә һәм бөтенлекнең бозылуына этәрә. Бәс, шулай икән, халыкларның үзбилгеләнүе буенча гомумтанылган ысуллар булдыру кулайрак булып чыкмыймы соң?!

Тайваньны яисә Төньяк Кипрны күрмәмешкә сабышырга мөмкиндер, ләкин алар бар бит, алар яши. Шул ук рәвешле Татарстанны да танымаска мөмкин, ләкин аның үсеп бара торган йогынтысы сәяси хәлләрдә чагылмый калмаячак. Төрле-төрле хокукый документларга таянып, азатлыкка сусаган йөзләрчә халыкларга күз йомып карарга мөмкиндер, ләкин табигый хокук башка теләсә нинди хокуктан өстенрәк тора һәм ул, иртәме-соңмы, хәтта иң аз санлы этнослар фикере белән санлашырга мәҗбүр итәчәк әле.

Халыкара җәмгыятьнең кайбер принциплары акылга сыймаслыгын кеше хокуклары белән халыклар хокукларын яклауның икесен чагыштырып караганда ачык күрәсең. Хокук сакчысын, диссидентны эзәрлекләү башланса, бөтен дөнья матбугаты чаң сугарга тотына. Төрле-төрле җәмгыятьләр булдырыла, БМОда, АКШ конгрессында, Аурупа оешмаларында кайнар сүзләр тулы нотыклар сөйләнә. Ә инде халыкларның хокуклары турында сүз кузгалса, җәмәгатьчелек ул халыкларның акрынлап үлә баруына гамьсез генә карап торуында була. Сахаров белән Буковскийларның исемнәрен ишетмәгән кеше калмагандыр, ә менә ингерманландлар яки комыклар, шапсуглар яки нугайлар турында дөньяның аерым белгечләре генә белә бугай. Русия житәкчелеге Идел буе алманнарының дәүләт статусын, Германия кебек куәтле дәүләт басымына да карамастан, кире кайтырырга уйлап та карамый. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән башка бер яклаучысы да булмаган бүтән халыкларга нишләргә кала соң инде?! Аларга, Кырым татарлары, йә чичәннәр кебек, үз хокукларын дәүләттән көрәшеп кире тартып алырга туры килә. Ләкин андый гамәлләр хәрби конфликтларга китерә. Кырым татарлары мәсьәләсе ничек хәл ителер? Үз орбитасына ул нинди илләрне суырып алыр? Осетиядә яки Абхазиядәге вакыйгалар ни белән бетәр? Төньяк Кавказда һәм Молдовада тынычлык урнашырмы? АХХКның «ун изге сүрәсе»нең какшамаслыгын тагын бер тапкыр раслау өчен күпме кешенең җаны кирәк булыр икән?

Дәүләтләр статус дионың саклануы хакына халыкларның хокуклары бозылуын да күрми калырга әзер. Һәркайсы үз мәйданы һәм чик буйлары турында гына уйлый. Инглизләр ирландлар белән шотландлардан сагая, канадалылар Квебек кешеләреннән, испаннар — басклардан һәм каталоннардан һ. б. Статус квога таянырга һәркайсының үз сылтавы бар. Ләкин планетабызның уртак язмышы белән бербөтен буларак бәйләнгән дөнья җәмәгатьчелеге мәнфәгатьләре дә бар ич әле. Аларны аерым дәүләтләр, йә булмаса, дәүләтләр төркеме мәнфәгатьләренә буйсындыру кыен. Халыкара хокукый аң, халыкларның санына һәм яшәү рәвешләренә карамастан, аларның хокуклары табигыйлегеннән чыгып фикер йөртергә тиеш. Дөньяның иминлеге инде сызылган чик буйларының ныклыгында түгел, ә бөтен халыкларга да үсешнең үзләре теләгән рәвешен сайлап алу мөмкинлеген булдыруга нигезләнгән.

## Яңа халыкара мөнәсәбәтләргә таба хәрәкәт

Арада иң демократиграк һәм ераккарак карап яши торган илләр милли азчылык һәм төп халыкларның хокукларын аныклый торган кануннар кабул итә. Аларның кайберләрен, мәсәлән, Дания белән Финляндиянең канунналәләрен үрнәк канунламә дип атарга була. Әмма ләкин хәтта барлык илләрдә дә шундый кануннар кабул ителгән очракта да халыкларның үзбилгеләнүе мәсьәләсе бетмәячәк, чөнки ул милли азчылыклар яки төп халыклар

хәленә генә кайтып калмый, ә күптән күп этносларга һәм мәйданый берлекләргә дә кагыла. Бу — дөнья җәмгыяте проблемасы, ул халыклар хокукларының бөтендөнья декларациясен кабул итүне һәм тиешле халыкара оешмалар булдыруны таләп итә.

Төрле илләрнең моңарчы тупланган уңай һәм тискәре тәҗрибәсенә таянып, БМОның кеше хокуклары буенча Комиссиясенең җәберсетүне булдырмау һәм азчылыкларны яклау буенча шөгъбәсе төп (тамыр) халыклар хокукларының Бөтендөнья декларациясе проектын әзерли. Анда күп кенә конкрет этник мәсьәләләр истә тотылган. Хәлбуки документ үзе бөтендөнья характерында булудан битәр «гамәл» рәвешендәрәк. Чөнки анда сүз аз санлы төп халыклар (Русиянең төньягындагы халыклар сыман) турында, кагыйдә буларак, үз традицион тормышы белән яшәүче һәм үз дәүләтләрен булдыруны дәгъва итмәүче халыклар турында бара. Бу проектта **халыкара** хокукның төп башваткыч — мәйданый бөтенлек белән халыкларның үзбилгеләнү хокукы арасындагы бәйләнеш игътибарсыз калдырыла. Ә бу мәсьәләне хәл итә торган документның кирәклеге турында әйтеп тә торасы юк.

Бу мәсьәләнең катлаулылыгы мәгълүм дәрәҗәдә хокук субъектының үзен билгеләү кыенлыгыннан килеп чыга. Кем үзбилгеләнүне дәгъва кыла ала да, кемне халык дип атарга? Бу уңайдан күп кенә сәясәтчеләр суверенлашу процессының чиге булмас дип сагая, чөнки принципта, әгәр дә аң белән фараз итсәң, теләсә нинди этник төркем, милли азчылык яисә мәйданый берлек үзен халык дип игълан итеп, үз дәүләтен кора башларга мөмкин. Бу вакытта ул табигый байлыкларын да, үз дәүләт чикләрен дә, постларын булдыруны да дәгъва итә ала. Суверенлашуның чикләре бармы аның?

Теоретик яктан, халыкларның үзбилгеләнүе юлына чикләр кую мөмкин түгел — каты критерийлар булсын өчен ни сан ягыннан, ни башка яктан характеристикалар юк. Ләкин реаль сәяси һәм икътисади практика бар. Кешеләрнең көнкүреше бик күп кысалар белән чикләнгән булуы ачык нәрсә: монда географик мәйдан, экологик даирә, табигый хәзинәләр, тел даирәсе, мәдәни берлек, үткәндәге тарих, үзаң һ. б. керә. Реаль практика җәмгыятьнең чиксез бүленеше юлына шактый нык киртәләр куя һәм процесс кешеләрне берләштерә торган күп сәбәпләр аркасында билгеле бер кысага керә. **Халык — ул үзбилгеләнүгә омтылышын ачык белдергән кешеләрнең социаль берлеге һәм аның мөстәкыйль берлек буларак шушы халыкның мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче иҗтимагый һәм дәүләт төзелеше була.**

Бу төшенчә этник билгеләр белән тулысынча тәңгәл килеп бетми, күп яктан ул төп (тамыр) халык төшенчәсенә турырак килә. Хәлбуки, тормышта бер халык сыйфатында бер генә түгел, берничә этнос, яисә төрле тарихи яки башка сәбәпләр аркасында зур этносның төп массивыннан аерылган бер өлеше чыгарга мөмкин. Тарихның мөстәкыйль субъекты буларак чыгарга сәләтле халыкларны исемләгәнче алдан ук билгеләү шактый катлаулы. Моның өчен этник сыйфатлардан тыш сәяси гамәлне исәпкә алу әһәмиятле. Ахыр чиктә теге яки бу берлекнең үзбилгеләнүгә дәгъваларының реаль дәрәҗәсен әнә шул билгели.

Нигә соң әле безгә БМОның халык хокукларын яклый торган махсус документы кирәк булды? Һәрбер кеше бөтен хокуклар һәм ирекләргә ия булырга тиеш дип игълан ителгән Кеше хокукларының Бөтендөнья декларациясе житмәгәнмени? Анда бит кешеләр расасына, тән төсенә, җенесенә, теленә, диненә, сәяси һәм башка иманнарына, милли яки социаль чыгышына карамастан, милкәте, катламы яисә башка хәле ягыннан бертигез дип карала. Чынлап та, этник тигез хокуклылык игълан ителгәч, тел һәм башка яклардан эзәрлекләү тыела, милләтләрне юк итүгә каршы БМОның махсус карарлары бар. Әмма алар бу таләпләрнең үтәлешен гарантияли торган тиешле институтлар белән ныгытылмаган.

Милли дәүләтләрнең этносларның аеруча, күпсанлы һәм үз-үзен тотышында бәйсез булган этносларның үсешен бик кайгыртып торасы килми. Алар андыйларда мәйданый бөтенлекләренә куркыныч күрә. Мисал өчен Русияне генә алыйк. Монда урыс булмаган халыклар асылда үз туган телләрен чит тел өйрәнгән кебек өйрәнә, мәдәниятләрен үстерергә акча аз бүленә, мөстәкыйль рәвештә табигый байлыкларыннан файдалана алмый — чынлыкта алар Мәскәүнең ярымколонияләре. Федераль хөкүмәт моңа риза, ә халыкара җәмгыятьнең моңа исе китми. Киресенчә, мондый мәсьәләләрне уртага салып тикшерү халыкара җәмгыять тарафыннан дәүләтләрнең эчке эшләренә оятсызларча тыкшыну дип кабул ителә. Шуның белән кеше хокукларын бозуларга ләббәйкә укыла. Алай гына да түгел, Русия Федерациясе республикаларының дәүләт суверенитеты турында деклараци-

яләр игълан итүләрен дөнья матбугаты коммунистик көчләрнең Б. Ельцин йөзендәге демократиягә каршы чыгышы дип тамгаларга базды. Экс-автономияләрнең хәрәкәт мотивларын аңлыйсы урында аларга төрле ярлыклар тактылар. Аның урынына дөнья җәмәгатьчелеге рәхәтләнеп Русия сәясәтчеләре ыргытканны кабып, Эстониядә, Латвиядә һәм Литвада «урысларның хокукларын бозу» турында чүбек чәйни. Ә монда бит урысларның туган телләрендә белем алырга, урыс гәзитләре укырга, Русия телетапшыруларын карарга бөтен мөмкинлекләре бар — алардан бары бу илләр кешеләре белән иркен аралашу өчен берничә йөз эстон, латыш, литва гыйбарәсен өйрәнү генә таләп ителә. Дөньяда бөтенесе дә олуг патшалыклар кулына кереп беткәч, алар, демократия лозунгларына сыенып, халыклар язмышын хәл итә.

Күрәсең, җирдә тынычлыкны саклау хакына халыкларны дискриминацияләүне туктатуның әһәмияте хакында тагын бер кат искә төшереп китүнең зыяны булмастыр. Аның әһәмияте кеше хокукларын бозуны туктатудан ким түгел. Сугышлар һәм революцияләр килеп чыгу сәбәпләрен тикшерә башласаң, этносара конфликтлар, мөгаен, беренче урынга чыгарлар иде әле. Һәрхәлдә, бу күңелсез статистикада аның өлеше, гауга сәбәбе буларак, кеше хокукларын бозуга карагында күпкә берәгәйлерәк.

Халыклар хокукларының бөтен дөнья декларациясе нигезенә шактый принциплар салынырга тиешле. Иң әүвәл кеше хокукларын халык хокукларыннан аерып карарга ярамый, чөнки һәр кешенең үз хасиятләре була: ул телдә, мәдәниятә күренә, кеше үз милләте йолаларына һәм гадәтләренә ия һ. б. Бу ихтыяҗларны канәгатьләндерүне кеше хокукларын тәэмин итүнең аерылгысыз өлеше итеп карау кирәк.

Кеше хокуклары халык хокукларына зыянга файдаланылырга тиеш түгел. Кануннар, хәтта кеше хокукларын яклау хакына дип кабул ителсә дә, әгәр дә халыкларның сәяси, икътисади, социаль һәм мәдәни үсешләре мәнфәгатенә каршы килә икән, андый кануннар гуманлы дип исәпләнә алмый. Кеше хокуклары белән халык хокукларының ярашуы принцибы Декларациянең нигезенә ятарга тиеш.

Демократик лозунглар еш кына үзбилгеләнү идеяләренең абруен төшерү һәм, хәтта, сәяси хәрәкәтләрне һәм фиркаләрне бастыру өчен дә файдаланыла. Демократияне еш кына шактый примитив аңлыйлар. Имештер, ул — монда торучыларның күпчелегенең генә фикерен ачыклау, этник азчылыкларның мәнфәгатьләрен исәпләп тормасаң да була, янәсе, һ. б. Ә бит демократиянең тәүге мәгънәсе — халык хакимлеге дигән сүз. «Монда торучылар» түгел, ә «халык» категориясе аның асыл характеристикасы булып тора. Демократия абсолют кыйммәт түгел, ул халык мәнфәгатьләре белән бергә бәйләнгәндә генә үз мәгънәсен ала, һәм шуңа күрә демократик чаралар этносларның хокукларын кысарга нигез була алмый һәм булырга тиеш тә түгел. Моннан түбәндәге нәтиҗә килеп чыга: этносларның үсешләрен тәэмин итмәүче, ә аларның хокукларын кысучы дәүләт бигрәк тә инде демократик дәүләт дип санала алмый.

Үзбилгеләнү хокукы үз дәүләтеңне булдыру мөмкинлеген күз алдында тота. Бу хокукны башкача аңлату аның мәгънәсен суырып ала, чөнки азатлыкның мәгънәсе дә шуннан тора бит инде: халык үз язмышын үзе хәл итәргә, сәяси һәм икътисади тормышын мөстәкыйль рәвештә үзе корырга тиеш. Халыкның үз дәүләтен булдыру хокукы бары тик шушы халыкның гына шик калдырмаслык итеп һәм демократик юл белән белдерелгән үз ихтыяры аша гына чикләнергә мөмкин. Шуңа күрә бернинди халыкара документ та халыкның үзбилгеләнү хокукларын чикли ала дип карала алмый. Бу уңайдан, чикләрнең кагылгысызлыгы һәм мәйданый бөтенлек принцибы үзбилгеләнүгә омтылучы халыкны көчләп тотып торуга аклану булып хезмәт итәргә тиеш түгел.

Төрле хәлләр аркасында халыклар үсешнең төрле баскычларында булып чыкты. Аларның үз дәүләтенә ия булганнары, «дәүләтсез» халыклар белән чагыштырганда, тагын да зуррак өстенлекләргә хуҗа була. Күп халыкларның артталыгы (ә моны рәсми хакимиятләр еш кына аларның үзбилгеләнү хокукларын чикләгәндә сәбәп итеп файдалана) күп яктан тарихи гаделсезлек, үткәндә басып алыну белән аңлатыла. Халыкларны ирексезләвен аларның артталыгы белән капларга тырышучы дәүләт үзе үк шушы артталыкның сәбәпчесе булып чыга. Шуңа күрә мондый халыкара принципны расларга кирәк: аның буенча теге яки бу халыкны изеп килгән дәүләт ул халыкның алдагы үсеше өчен матди һәм әхлакый җавап тотарга тиеш. Шулай итмәгәндә төрле халыкларның үсеш дәрәҗәләрендәге аерма һаман арта гына барачак, һәм неоколониализм, интеллектуаль, гыйльми, профессиональ һәм башка төр өстенлекләрдән файдаланып, яңа, тагы да астыртынрак рәвешләргә керәчәк.

Зур күләмдә милли сыйфатларын югалтуга һәм геноцидка (гомумән, һәлакәткә) дучар ителгән халыкларның хокукларын кире кайтару чаралары хакында аерым әйтеп үтәргә кирәк. Тормыш дәүләтләрнең ул хокукларны торгызырга ашкынып тормауларын күрсәтә.

БМОның да, АХХКның да, кызганыч ки, халыкларның үзбилгеләнүе ысулларын билгеләрлек һәм этносара гаугаларны булдырмау чаралары һәм тиешле институтлары юк. Халыкларның хокукларын билгели торган халыкара документлар кабул итү ул әле яңа типтагы халыкара мөнәсәбәтләрне формалаштыруда беренче адым гына. Халыкларга декларацияләр генә түгел, ә гомумтанылган нормаларны тормышка ашыру өчен дәүләтләр һәм халыкара җәмгыять тарафыннан бирелергә тиешле гарантияләр дә кирәк.

Бу юлда иң радикаль практик адым булып БМОның икенче палатасына вәкаләт бирү тора алыр иде. Ул палата дәүләт вәкилләреннән түгел, ә демократик юл белән сайланган төрле халык вәкилләреннән торыр иде. Халыклар турыдан-туры үз хәлләре һәм ниятләре турында чыгып дөресен сөйли алырлык андый палатаны булдыру күп кенә бозулар һәм этносара конфликтлардан котылып калырга мөмкинлек бирер иде. БМОны яңа принципларда үзгәртеп кору халыкара җәмгыятьне тупиктан чыгарыр һәм аңа яңа перспективалар ачар иде.

Җирдә тынычлыкны саклау өчен шулай ук Халыкара Хөкемгә халык хокукларын бозулар турындагы эшләрне карау һәм шулай ук тегеяки бу халыкның үзбилгеләнүе турындагы мәсьәләне куярга хакы бармы-юкмы икәнлеге турында карар чыгару хокукын бирү дә бик файдалы булыр иде. Үзбилгеләнү хәрәкәтен халыкара оешмаларның контроле астында алып бару этносара һәм мәйданый гаугаларны йомшартырга ярдәм итәр иде.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы үзенең Уставында гаять әһәмиятле принцип буларак халыкларның үзбилгеләнү хокукын раслап куйган иде. Үткән вакыт эчендә бу хокук сүз генә булып кала бирде, аны тормышка ашыра торган тиешле нормалар һәм халыкара механизмнар белән ул ныгытылып куелмады. БМО, асылда, дәүләтләр арасындагы чикләрне ныгыту белән шөгыльләнде. Вәгъдәләр өчен түләр вакыт та килеп җитте шикелле инде. Халыклар көтә.

## ЙОМГАК

**XX гасыр тәмамланып килә. Аның дәвамында ике бөтен дөнья сугышы булып узды, колониаль система таркалды, олуг империяләр җимерелде. Империяләрнең соңгысы Русия тирән кризис кичерә, үз эченнән яңа дәүләтләр бүлеп чыгарырга әзерләнә.**

**Кешелек тарихы башыннан алып бүгенге көнгә кадәр халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрдә сугыш фәлсәфәсе өстенлек алып килде. Дөньяның тоткасы булып көч тора, һәм ул бөек мәмләкәтләр тарафыннан идарә ителә. Хәлбуки, «кверенкелекне кимстү» кешеләрнең һәм сәяси юлбашчыларның аңын үзгәртә башлады. Халыкара мөнәсәбәтләрне зур үзгәрешләр чорнап алды. Тынычлык фәлсәфәсенә нигезләнгән яңа заман килә, һәм ул үзе белән тарих мәйданына моңарчы аз билгеле булган халыкларны да алып чыга.**

**Кешелек каршына җавап бирелергә тиешле сорау килеп басты: җир йөзендә тынычлыкны саклау өчен, планетаның чәчәк атуы һәм кешелекнең киләчәге өчен кайсысы әһәмиятлерәк: халыкара җәмгыятьнең болай да көчле һәм мәкерле булган дәүләтләргә терәк булуымы, әллә дөнья цивилизациясенә йөз тоткан халыкларны яклаумы? Бу сорау, әгәр дә сәяси мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләтлелеккә таянып килеимәгән булса, кышны сорау гына булып күренер иде.**

**Дәүләтләр гаять зур көчкә һәм чикләнмәгән диярлек хакимлеккә ия. Алар ихтыярына каршы торырлык көч юктыр да шикелле, бигрәк тә инде «дәүләтсез» халыкларның өмете юк кебек. Әмма ләкин планетар мәнфәгать бар бит әле: ул үз җанынны саклау хисеннән килеп туа һәм дәүләт мәнфәгатьләреннән өстенрәк тора. Үз заманында БМО колонияләрдәге халыкларны яклап чыккан һәм дәүләтләрне империализмнан арынырга мәҗбүр иткән иде. Бүген икенче «деколонизация» дәвере башланып килә. Планетабызның кумәк акылы халык хокукларын яклап һәм җир йөзендә уртак тынычлык хакына тәкәббер патшалык мәнфәгатьләреннән өскәрәк күтәрелми калмас. Моңа аның сәләте дә, көче дә җитәрлек...**

Урысчадан Эльс ГАДЕЛ тәрҗемә итте.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ТАТАР ЗЫЯЛЫСЫ... УЛ — КЕМ?

*Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар.*
*Сирәк ләкин, дөрест әйтсәм, кешелекле, хәялылар.*
*Әгәр күрсәң, кызарган йөз аларда, бер дә алданма;*
*«Оялгандыр!» димә яңлыш, «җибәргәндер» дисәң — әүля!*

Г. ТУКАЙ. *«Бәгъзе зыялыларымыз»*[1].

Беркем дә түгел. Бүген татар зыялысы юк. Язучысы, рәссамы, композиторы бар татар халкының, галим-голямасы бар, һәйкәлтәрашы (скульпторы), мигъмары (архитекторы) бар халкыбызның, әмма... гафу итегез, жиде-сигез миллионлы халыкның зыялысы — юк. Генерал-лейтенанты, «минем миллләтем — сәнгать» дип үлгән бөек таланты, АКШ белән эш итә торган академиклары бар, ләкин миллләтебезнең зыялысы юк. Юк һәм вәссәлам!

Моның сәбәпләре тарихта. Бу — безнең татар милләтенең генә фажигасе түгел, бу — Россия империясенә кергән бөтен милләтләрнең дә фажигасе. Россиянең иң югары органы, парламенты булган Учредительное Собраниене өч класс белемле матрос: «Каравыл арды»,— дип куып тараткан икән — бу инде кыргый илдә интеллигенциянең бәясе бер тиен дигән сүз. Учредительное Собраниенең депутатлары арасында империянең күпме-күпме укымышлысы, эшмәкәре булган!

1985 елда «Новый Мир» журналында мәшһүр бер галимнең әр-яңа рухтагы мәкаләсе чыкты. Ул анда без табынган Ленинның моңарчы бер томына да кертелмәгән бер өземтәсен китерә. Ильич бервакыт болай дигән икән: «Интеллигенция — говно». Андый сүзнең матбугатыбызда беренче тапкыр күренүенә бер гаҗәпләнсәм, Ильичның тәрбиясезлегенә икенче гаҗәпләндем. Октябрь борылышыннан соң Ленин, Дзержинскийларның һәм, гомумән, системаның бөтен эше интеллигенцияне кыру, юк итү булган бит...

Власть башына кем генә килмәсен, беренче чиратта ул үзен иң зур интеллигент итеп күрсәтергә тырышкан, һәм чын интеллигентны таптаган, бетергән. Ленин үзен анкеталарның берсендә «литератор» дип күрсәткән. Әдәбият буенча соңгы сүзне әйтергә яраткан. Николай Бухарин да үзен бөтен әдәбият буенча язучыларны өйрәтерлек дәрәҗәдәге кеше дип исәпләгән. Инде өч-дүрт класс белемле боевик Сталинга килсәк, ул үзен бөтен Совет империясендәге әдәбиятларга юл күрсәткән, чын интеллигенцияне аттырган, лагерьларда череткән. Ә үзе Горькийның «Кыз һәм үлем» шигырен укыгач, кырыена болай дип язып куйган: «Эта штука (! — М. М.) сильнее чем «Фауст» Гете. Любов побеждает смерть!» Беренчедән, дөньякүләм классик әсәрне Горькийның гади генә бер шигыреннән кимрәк итеп карау — чеп-чи наданлык, яки кылану. Икенчедән, башлангыч класс укучысына да мәгълүм ки, «любовь» сүзенең ахырына йомшаклык билгесе куела. Бу фразаның фотокопиясен бирер алдыннан күпме-күпме рәссам-графиклар иза чиккә: ничек итеп Сталин үзе дә сизмәслек дәрәҗәдә йомшаклык билгесен өстәргә? Менә сиңа даһи, менә сиңа бөек тел галиме, корифей, кормчий һ. б. һ. б.

Хөкемдарлар интеллигенция арасыннан беренче чиратта язучыларны, дин хезмәткәрләрен, философларны күралмаганнар. «Дин — халык өчен әфьюн»,— дип беренче мәртәбә әйткән, ләкин дин урынына «коммунизм» дип исемләнгән икенче әфьюн биргән кеше — интеллигент түгел. Чиркәүләрне талаган, попларны Колымага, Ак Диңгез-Балтик каналына сөрдергән Ленин, Сталин — интеллигент түгелләр. Большевизм идеология-житәкчелек эшенә беренче чиратта «кухарка улларын» куйды. Кухарка уллары (безнең телдә: әтрәк-әләм) исә, күн тужурка киеп, наган асып алгач, иң әүвәл укымышлы кешеләргә һөҗүм башладылар. Зыялы кеше бандит каршында һәрвакыт көчсез була. Моны Сталин бик яхшы аңлагандыр.

Моннан ике-өч еллар элек «Литературная газета»да бер автор (язып алмаганмын, гафу үтенәм) «интеллигентлык — рус төшенчәсе» дип язып чыккан

[1] Сүзлек: Бәгъзе — кайбер; хәялы — ояты, вөжданы булган кеше; «җибәргәндер» — эчкән мәгънәсендә; әүля — дөресрәк.

иде. Юк инде, нишләп алай булсын? Татарны канга батырып чукындырып йөргән православие миссионерлары интеллигент булганмы? Татар халкына каршы ачы агу белән тонәтелгән әсәрләр иҗат иткән рус укымышлылары интеллигент булганмы? Юк, интеллигент ул — кешене, аның динен, телен, гореф-гадәтләрен ихтирам итүче кеше. Мин, мәсәлән, катнаш аудиториядә чыгыш ясыйм, катнаш булганлыктан, рус телендә сөйләргә мәҗбүрмен. Залда — мәктәп укытучылары, вуз кешеләре, студентлар, кыскасы — интеллигенция. Бераздан миңа сораулар килә, язма рәвештә.

— Сез нишләп татарча сөйләмисез? Без сезне татарча тыңларга дип килдек. Әйтегез әле, сез бүгенге көндә нинди әсәр язасыз?

Мин шунда бу сорауга татарча җавап бирә башлыйм. Шунда нәрсә була дип уйлыйсыз? Рус милләтеннән булган кешеләр бер-бер артлы торып залдан чыгып китәләр. Казанда рус интеллигенциясе бар дип берәрегез миңа әйтеп карасын!

Минем бу күзәтүләрем бик күптәннән килә. 1960—1990 елларда мәшһүр Казан университетында эшләдем. Шуның егерме-егерме биш елында иҗтимагый эштә (ягъни, син бушлай эшлисең, ә шул эшне үз эшләре итеп исәпләп райком, горком, Обком партократлары рәхәттә яши) иза чиктем. Арадан берсе — һәр язны уздырыла торган фестиваль... Үзешчән сәнгать көчләренә смотр. Һәр факультет үзенчә уздыра. Иң яхшылары гомумуниверситет фестиваленә сайлап алына. Зур фестиваль исә университетның мәшһүр Актлар залында (Володя Ульяновның уку тәртипләренә каршы стачка оештыруы белән мәшһүр) уздырыла. Менә шуның программасын төзү, рәтләү буенча партком, профком кешеләренең башыннан пар чыга (райком дәрәҗәсендәге профкомның рәисе булып өч ел эшләдем). Кайсы җырдан соң нинди номер, кемне чыгаргач, кемне?

Тормыш исә бик гади: бер студент — чыгып «Вдоль по Питерской»ны җырлый: кул чабулардан түшәмдәге люстралар селкенә. Татар бүлегеннән берәү чыгып «Наласа»ны җырлый башлый: ярты зал кузгалып, дөбердәшеп чыгып китә. Менә сиңа «интеллигентлык — рус төшенчәсе».

Юк, интеллигент, татарда гына түгел, русның үзендә дә юк.

Рус интеллигентының язмышын руслар үзләре язар, әмма татар зыялысының тарихи фаҗигасен ачып бирер вакыт җитте. Тарихчы галимнәр Б. Солтанбәков, Р. Вәлиев, И. Таһиров, КГБ хезмәткәре Р. Кашаповлар бу эшкә тотындылар инде, ходай каләмнәренә мәдәт бирсен!

Ә татар зыялысының фаҗигасе бик гади һәм стандарт: большевизм үзенең антигуманистик хәрәкәтләре мәйданына татар зыялылары Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Йосыф Акчура, Габделбари Баттал, Садри Максудиларны сыйдыра алмый иде. Болар акыллырак булып чыктылар һәм, эшнең кая барганын сизеп, чит илгә киттеләр. Аларны, китмәсәләр, барыбер 1919, яки 1932, яки 1937 елда кыйнап, изеп, НКВД подвалларында таптап, авызларына пес итеп, үзләре карап торганда кызларын көчләп, һ. б. кабәхәтлекләр эшләп корбан иткән булырлар иде. Вакытында китмәгән зыялылар белән ни генә булмады соң? Иң асыл сөяк зыялы Газиз Гобәйдуллинның нинди камерада утырганын ишеткәнегез бармы? Фатих Кәрими... Европа халыкларының өч телен, рус, төрек, фарсы, гарәп телләрен камил белгән бу зыялының камерадагы соңгы көннәрен кем тасвир итәр безгә? Татарның асыл улларын — Һади Атласи, Гали Рәхим, Шәрәфләр, Җәмал Вәлиди, Гәрәй Хәсәни кебек зыялылар турында кайчан тулы-тулы монографияләр язарбыз?

Зыялылык-интеллигентлык ул бик тирән төшенчә. Ул — татар баеның, татар морзасының, татар мулласының нәселе, улы, оныгы булу дигән сүз түгел. Зыялылык ул ярым-йорты була алмый. Ул сыйфат кешедә йә бар, йә — юк. Тарихта моңа мисаллар байтак. Зур талант иясе, классик прозаик Галимҗан Ибраһимов, мәсәлән, Авыргазы ягында мәшһүр Гыйрфан хәзрәт гаиләсендә туган. Классик дини белем алган, «Галия»дә укыган, бераздан татар халкының якты горурлыгы булган «Аң» журналында эшләгән, аннан «Галия»дә укыткан. Татар халкының мактанычы бу!

Әмма, Г. Ибраһимов, минем карашымча, интеллигент түгел. Беренчедән, ул татар халкының үзаңына Тукай иң кирәк чакта, көрәш мәйданында аңа аягын чалган. Икенчедән, Октябрь фетнәсе булуга, ул үзенең элеккеге бик күп идеалларыннан баш тарткан: Фатих Кәрими фигурасын «Безнең көннәр» романының беренче вариантында лидер итеп күтәргән автор, фетнәдән соң моны сызып ташлый. Газиз Гобәйдуллин һәм аның бөтен нәселенә каршы мәкаләләр бастыра. Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Җ. Вәлидиләр белән матбугатта көрәш ача. Садри Җәләлне бетерешә. Интеллигент моңдый булмый. Ул китсен иде йә чит илгә, йә

инде Г. Рәхим, Ф. Кәрими, Ж. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Шәрәф кебек дәшмәсен иде... Тегеләрне төрмәгә озаткач, эшне бетергәч, НКВД бит инде «юеш эш»не оештыручыларны да юк итә. Шуңа мисаллар: ул үзе, Ф. С. Казанлы, Г. Толымбайский, Г. Гали, Л. Гыйльми һ. б. Бандитларның бик тә сыналган, хәтта искергән бер ысулы бит бу... Интеллигент (зыялы) кеше шуңа барыр идемени?

Тукай да иҗатының беренче чорында әле зыялы түгел. Яшь егет сатирик журналларда әледән-әле Йосыф Акчура, Фатих Кәрими, Габдерәшит Ибраһимов, Исмәгыйль Гаспринский кебек татар халкының бөек улларын тешләптешләп ала. Хәтта, Гаяз Исхакыйны да тешләп уза. Ләкин яшь егетнең бу мавыгуларын гафу итик. Без генә ул, хәзер, арткы акыл белән («задним умом») акыллы. Тукайда, еллар үткәч, прозрение була. Бик кызганыч, без шул «прозрение»не узмыйча, дөресрәге, узарга теләмичә, дөньядан, әле дә булса зыянлы иске мәкаләләр бастырып, искергән интервьюлар биреп китеп барабыз. Бездән чүп-чар гына кала, мактанмыйк, укучыны алдамыйк.

Тукай, күзе бик нык ачылгач, бөек шәхес Гаяз Исхакыйның кем икәнен аңлый һәм аны татар зыялыларының «чупан»ы (чабан, көтүче, житәкче мәгънәсендә) дип атый. «Мөхәрриргә» исемле бу шигыре аның «Мәктәп» журналының 1913 елгы март санында басылган, шагыйрь инде каты авыру. Бу — аның актык сүзләреннән берсе. Тукай, бөек Тукай, үләр алдыннан татар милләтенең лидеры, зыялысы кем икәненә тәмам инанган:

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилах,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берән чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

Алты ел торды чупансыз, айрылышты яшь көтү,
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар» дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

Тукайны без «Шүрәле», «Су анасы», «Китмибез» әсәрләре буенча беләбез. Чөнки аларны белү, кабул итү — жинел. «Мөхәрриргә» шигыре — катлаулырак. Анда — Тукайның дөньяга карашларында тулы бер үзгәреш. Нәтиҗә.

1966 елда Анкара шәһәрендә Габделбари Баттал-Таймасның «Казан төрекләре» исемле китабы (икенче басма) дөнья күрде. Бик кыйммәтле мәгълүмат тупланган бу китапта киң фикер йөртелә: китап бит Татарстан Обкомы аппараты, Главлит чиновниклары катнашмаган көе чыга. Китапта Йосыф Акчура, Садри Максуди, Һади Атласи, зур галим Зәки Вәлиди, Муса Ярулла-Биги, Габдулла Кариев рәсемнәре белән бер рәттән, драматург Кәрим Тинчурин рәсеме дә бирелә. Бу китапның тарихи әһәмиятен әйтеп бетерәсе юк. Идеология китабы түгел, фактлар чыганагы бу. Әмма талантлы драматург К. Тинчуринны татар зыялысы дип атый алмыйм мин. Аның таланты турында язган бер мәкаләм дә бар (юбилее уңаеннан). Нигә ул интеллигент түгел? Чөнки ул Совет власте елларында үз милләтеннән, үз халкыннан теш ыржайтып көлә. Рус хакимиятенә шул гына кирәк тә! Карагыз сез аның «Җилкәнсезләр»ен! Карагыз сез аның «Зәңгәр шәл»ен... Карагыз сез аның... Хәер, житәр. Карагыз сез башта М. Булгаковның «Бег» әсәрен. Эмиграция бара. Милләтнең, бөтен бер халыкның трагедиясе. Авыр язмыш. Рус, яһүд шул вакыйганы афәт буларак кабул итә. Ә бездә? Без — көләбез. «Җилкәнсезләр»дә дә көләбез, «Качаклар»да да көләбез. «Над кем смеетесь, господа?» Ул Зәки Вәлидиләр, Гаяз Исхакыйлар, Садри Максудилар тормыш яхшы булганнан («от хорошей жизни» дигән рус гыйбарәсеннән калька) чит илгә киткәннәрме? Без шул хәлдән, большевизм афәтеннән куркып ояларыннан купкан милләтебез вә зыялыларыннан көләбезме? Шуның, шул әсәрнең авторы булдымы интеллигент? Минем берничә мәртәбә чит шәһәр, чит милләт вәкилләре белән Г. Камал исемендәге театрда «Зәңгәр шәл»не караганым, үземчә тәрҗемә-фәлән итеп утырганым булды. Көләләр генә бит безнең милләттән! Дүрт абыстай талаша, ишан хәзрәт азына. Көләләр безнең татардан. Шуның авторы булдымы интеллигент?

Г. Камалның Октябрь борылышыннан соңгы иҗатын гына карагыз: элек татар милләтенә нинди зур хезмәт күрсәткән шәхес («Бәхетсез егет», «Беренче

театр», «Банкрот» һ. б.) яңа заманда пүчтәк бер автор була да кала. Гаяз Исхакыйга да кизәнеп ала. Белә: үзе монда паекка, карточкага ашы, кушканны яза, Гаяз исә, матди яктан алай ук иркен яшәмәсә дә, үзе уйлаганны яза. Ә бу — кизәнә. Совет властена ярарга тырыша. Мәҗит Гафури да интеллигент-зыялы түгел. Совет режимына яраклашып, ул татар зыялысы Дәрдмәндкә каршы әсәр яза — «Шагыйрьнең алтын приискасында». Имеш, ул, шәкерт, нинди хәлдә яшәгәндә, шагыйрь Дәрдмәнд ничек шәп йөргән...

1919—1920 елларда татар укымышлы-зыялыларыннан иң каймагы эмиграциягә китә. Алар арасында рус, төрек, француз, инглиз, фарсы, немец телләрен белгән татар егетләре була. Юриспруденцияне белгән ирләр була. Бу — рус телендә әйткәндә — «утечка мозгов». Утызынчы елларда Казан шәһәрендә яшәүче бик күп зыялы читкә китә: шапшак идеология аренасына әйләнгән Казаннан зыялы Газиз Гобәйдуллин чыгып китәргә мәҗбүр була. Китүенә сәбәп — аның тирәсендә оештырылган интрига, шантаж. Казан өчен зур югалту була бу. Казан Габдрахман Сәгъдине дә сыйдырмый: ана әдәби суд ясыйлар, «Колчак ягында булган»,— дип гаепләр. Имеш, Колчак гаскәре Бәгелмәгә кергәндә ул анда укытучы булып эшләгән. Чын зыялы Мәхмүт Галәүнең әсәрләрен Казан басмый. Шул ике романын бастырыр өчен ул Мәскәүгә китә һәм аларны русчага үзе тәрҗемә итә. Мисалларны тагы да китерергә булыр иде, ләкин мәсьәлә ачык: Казан утызынчы елларда тәмам большевиклашып бетә. Зыялылыкка урын калмый.

Менә шуннан соң инде 60—70 еллар буена татар милләте зыялы кеше эшләп чыгара алмый. Имеш, Уинстон Черчилль әйткән: интеллигент булу өчен өч шарт кирәк, дигән. Беренчесе — бабаң Оксфорд университетын тәмамлаган булу; икенчесе — атаң шул ук университетны тәмамлаган булу; өченчесе — үзең шуны тәмамлау. Әнә шул өченче буында гына зыялы ясала икән.

Чыннан да, зыялылык — ул ни? Нинди сыйфатлар кирәк соң кешегә зыялы булу өчен? Моның кагыйдәләре юк кебек һәм мин бу сорауга тулы җавап бирүне өстемә алсам, бик тә тыйнаксызлык күрсәткән булыр идем. Шулай да кайбер фикерләремне әйтим. Зыялылыкның тышкы атрибутларын белүчеләр күп: ишекне ачып хатын-кызны алдан уткәрү, трамвайдан төшкәндә үзең алдан чыгып аңа кул бирү, тарелкадагы итне уң кулдагы пычак белән кисеп, сул кулдагы чәнечке белән (гәрчә, бик тә уңайсыз булса да, мөселманча булмаса да) ашау, ашаганда кикермәү, авызыңны чапылдатмау һ. б. Совет дәүләтенең чит ил эшләре наркомы Чичерин дипломат Сергей Араловны Төркиягә илчелеккә озатканда болай дигән:

— Интеллигентлык ул өстәл янында ашап утырганда балыкны пычак белән кисәргә ярамаганын белү генә түгел. Тышкы күнекмәләрне кеше тиз, жинел үзләштерә. Интеллигентлык — кешелек җәмгыяте эшләп чыгарган әдәп-әхлак-акылны белү һәм шулардан кирәк вакытта файдалана алу дигән сүз.

Чыннан да, дин китапларында бу нормаларның барысы да әйтелгән бит. Дингә каршы көрәшү, димәк, зыялылыкка каршы көрәшү ул. Дин китапларында әйтелгән: кешегә зыян салма. Ә менә тарихчы Әгъдәс Борһанов белән Равил Фәхретдиневларга докторлык диссертацияләрен яклатмас өчен күпме көч куйды кайбер иптәшләр. Болар зыялымы? Әлбәттә, юк. «Совет интеллигенциясе» соңгы 60—70 ел эчендә нәрсәгә өйрәнде соң? Анонимка язарга, шантаж ясарга, бер-берсенә юл бирмәскә. Көнчелеккә. Дин китабы әйтә: әл-хәсүд мәхрүм. Ягъни, көнче кеше — бәхетсез, бәхеттән мәхрүм кеше. Язучыларга нинди генә анонимкалар килми? Сәхнә кешеләре арасында нинди генә интригалар юк?

Галим-голяма берсен-берсе батырыр өчен ни генә эшләми? Белемле кешеләргә юлны ябу өчен ниләр генә кылмыйлар?

Зыялылык белән безнең «интеллигенция» арасындагы аерма сәра (җир) белән Сөрәйя (җидегән йолдыз) аермасы кадәр (Риза Фәхретдинев сүзләреннән файдаландым).

Хәер, без моңа гаепле түгел. Язмышны сайлап алып булмый. Һөнәрне, дача урынын, хатынны, гаражны сайлап алып була, язмышны — юк.

Профессор Әгъдәс Борһанов бик тә кирәкле бер мәсьәлә күтәрә бу мәкаләсендә. Мәкаләдә сүз татар зыялылары турында бармаса да, автор кисәтә кебек: татар зыялылары һәм аларның тормыш юллары турында кайчан яза башлыйбыз? Әйе, сәләтле тарихчыларыбыз байтак. Ниһаять, аларның сәгате сукты. «Сыйнфый дошман» турында язып кандидат, доктор булулар — бетте. Чын тарихыбызны язар сәгать сукты. Форсаттан файдаланыйк...

Әле октябрь борылышына кадәр үк Г. Газиз (Газиз Гобәйдуллин) «Олугъ кешеләр...» дигән бер серия ачып татар милләтенең бөек уллары турында китаплар чыгаруга нигез салган иде. Безгә бүген шушы серияне торгызырга кирәк. Без

бу турыда тарихчы Алексей Литвин, Аяз Гыйләҗев һәм мин Татарстан китап нәшрияты җитәкчелегенә рәсми булмаган формада фикеребезне җиткердек. Бу турыда уйларга кирәк. Бу серия, бәлки, «Мәшһүр татарлар» дип аталыр. Әмма, без үз принципларыбызны да әйттек: каны татар булып та милләтебез өчен берни дә эшләмәгән кеше «мәшһүр татар» була алмас. Андый зур-зур исемле татарны бу сериягә кертканче, безнең өчен тау кадәрле хезмәт күрсәткән яһүд Семен Липкин, ярым-татар, ярым-рус Лев Гумилев бу сериядә мактаулырак урын алуы мөмкин.

Өметне җуймыйк: безнең буында булмады инде ул зыялылар. Ләкин милләтебез киләчәктә бу катлауны, бу структураны «эшләп чыгарырга» тиеш. Бу — дәүләткүләм әһәмиятле эш. Зыялылары булмаган көе Татарстан дәүләте яши алмаячак. Көнчыгышның акыл иясе Җәмалетдин Әфгани әйткән: гыйлем, мәгърифәт, зыялылык алдында тез чүгеп хезмәт итмәгән милләт яши алмас, аның ахыргы көне бик үкенечле булыр...

Үкенечле финалга бармасак иде. Профессор Ә. Борһанов мәкаләсе дә безне бу турыда уйланырга чакыра...

Шулай да, «интеллигент», «зыялы» — ул кем? Уйлавымча, болай, мондый кеше: үз мәнфәгатьләрен кайгыртмыйча милләте өчен, аның киләчәге өчен көрәшүче белемле, юридик әзерлекле, тормышында әхлаклы, динле, милли тарихны белгән ачык күзле, хөсетсез бер татар баласы.

Ул әле туар, үсәр, Татарстаныбызга хезмәт итәр...

Июнь, 1993 ел.

**Әгъдәс Борһанов,**

тарих фәннәре докторы, профессор.

# СЕЗ КЕМ БЕЛӘН, ЗЫЯЛЫЛАР?

Бармы бездә зыялылар? Сәеррәк тоелса да, бик җитди сорау бу. Аның тирәсендә инде байтактан шактый бәхәсләр дә бара. «Литературная газета»ның быелгы 6 нчы санында Ст. Рассадин зыялыларның тәмам беткәнлеген раслап маташа, алар «дворянлык беткән кебек үк бетте», чөнки моның социаль нигезе революциягә түгел, ә капитализмга юнәлеш тоткан Россиядә тайпылышсыз башланган эволюция тарафыннан какшады, ди. Анынча, әнә шундый Россиядә «идеализм үз-үзенә нык ышанган прагматизмга юл биргән».

Әмма шуны онытмыйк: тарихи тәҗрибәсе, үз традицияләре булып, Октябрь революциясенә кадәр яшәгән зыялылар, аеруча аның өске катлаулары Совет шартларында, әйтерсең лә, парга әйләнделәр, ягъни аларның бер өлеше юк ителде, кайберләре чит илгә чыгып китте яисә чит илгә куып чыгарылды. Интеллигенция үсешендәге дәвамчанлык бозылды. Большевиклар, әйтергә мөмкин, үз зыялыларын иңде интеллигенциянең нигезе беткән хәлдә хасил итәргә тотындылар (зыялыларның илдә калганы уртача яисә аннан да түбән дәрәҗәдә иде, алар большевикларга тәлинкә тотучы булып калды, шуңа күрә санга салмадылар да).

Күпмедер камилләшкән социаль төркемнәр (зыялылар) өч буын дәвамында оешып житә. Пролетар зыялыларның беренче буыны (1920—40 нчы еллардагы) — рабфак, коммунистик университетлар, кызыл профессура, уку-укыту җиңеләйтелгән югары уку йортлары шәкертләре. Менә шул баскычны үткән зыялылар инде берән-сәрән генә калды. Икенче буын зыялылар — бүгенге 40—50 яшьтәге кешеләр. Ә өченче буын — аларның балалары. Баштагы ике буында зыялылыгы, белеме җитмәгән яисә ярым-йорты хәлдәге өлкән кешеләрдән мирас рәвешендә күчкән «миң»нәр күп. Дөнья мәдәниятеннән аерылган, түбән сыйфатлы урта яисә югары белемгә генә ия булу, чит телләрне белмәү — әнә шул «миң»нәр. Бу

зыялыларының сыйфаты, кабатлап әйтәм, дөнья мәдәниятен белмәү белән билгеләнә дә инде, чит телләрне белмәү дә шуның бер сәбәбе. Рассадин билгеләгәнчә, «ярым-йорты гыйлемлекне яисә шәхес буларак бөтен була алмауны белеп торган хәлдә» зыялы дип йөртелүдән мин үзем дә баш тартыр идем. Фәкать өченче буын гына, нигездә, теге «мин»нәрдән күпмедер азат. Ул да үзенең тәпле, ныклы рәвешкә керүен соңгы елларда гына төгәлләп килә. Әлбәттә, дөнья мәдәниятенең көчле йогынтысы белән. Һәм иң мөһиме — демократия һәм урта сыйныф зыялыларының социаль нигезен булдыруга йөз тоткан вакытта. Россия интеллигенциясе ышыкта, аның егәр туплаган чагы гына әле.

М. Берг «Московские новости»нын 1993 елгы 8 нче санында зыялыларның социаль феномен буларак бетә баруын үзенчә аңлата: идарә итү формасы буларак, Көнбатыш либераль демократиясенә юнәлеш тотуның «яшәргә сәләтле бернинди альтернативасы юк», һәм ул зыялыларны «рухи-күреп фикерләү перспективасыннан» да мәхрүм итә, ди. «Рухи проекттан башка... урыс зыялысы берни майтара алмый» икән. Беренчедән, әгәр хәтта Көнбатыш либераль-демократик варианты бездә чын-чынлап кабул ителсә дә, аны Россиянең кыен һәм үзенә генә хас шартларында гамәлгә ашыру мөмкин булмас, дип уйлыйм мин. Икенчедән, тарих турыдан-туры кабатлануларны белми, алар үсешнең иң югары ноктасында гына булгалый. Базар шартларында гамәлгә ашыру өчен безгә Көнбатыш либерализмын кабул итү кулай, әмма аңа юл тоту гаять үзенчәлекле. Фараз итүемчә, башлангыч капиталны туплау, бер яктан, Көнбатыш илләрендәгечә булыр; икенче яктан, базар мөнәсәбәтләрен формалаштыру икътисадны дәүләттән аеру, алга таба акцияләштерү ниятеннән милекне хосусыйлаштырган нигездә барыр, һәм бу хәл шәхси милекчелекнең Көнбатыштагыча ук турыдан-туры үсеше рәвешендә булмаска да мөмкин. Монда, күренә ки, рухи эзләнүләргә мәйдан киң. Димәк, җәмгыять өчен зыялылар кирәк, бик кирәк әле. Алар капитализмның прагматиклыгы белән генә бетми.

Зыялылар халыкның мәдәнилеген үзләрендәге дәрәҗәгә җиткерергә тиешле. Россия интеллигенциясе исә мәдәни булуы белән генә чикләнеп калмаска тиеш. Ул һәрчак сәясәт эчендә кайный бит. Европа зыялыларыннан ул нәкъ шуның белән аерылып тора. Нәкъ менә шуңа да хакимият ияләре һәм, гомумән, реакционерлар аларны күралмады...

Иң яңа тарихның барлык күчеш чорларындагы кебек үк, зыялыларны хәзер дә консерваторлар һәм карагруһлар утка тота. Янәсе, бүгенге бәлаләргә зыялылар гаепле. Моны дәлилләү өчен гасыр башында чыккан «Вехи» һәм «Из глубины» дигән фәлсәфи-публицистик җыентыклар да файдаланыла: «Урыс интеллигенциясенең өстен агымы шушы көнгәчә үткән юл — хак юл түгел, ул һәлакәтле... Ул — егылу, тормыштагы уңай башлангычлардан тайчыну юлы, зыялылар аңлы урыс җәмәгатьчелегенең дөньяга карашына социалистик һәм анархик тәгълимат сеңдерүдә гаепле, зыялылар дәүләткә каршы көрәшне әйдәгән», янәсе. В. Распутинча, бу социаль төркемне мәдәни һәм зыялылык ягыннан бәяләү өчен Америка, Англия интеллигенциясе дәрәҗәсеннән фикер йөртергә кирәк, безнең интеллигенция исә «бүтән казанышлары белән ялтырап куйгалый» («Москва» журналы, 1991, 2 нче сан).

Россияне европалаштырырга омтылган Петр I вакытыннан бирле интеллигенция Көнбатыш фикерләрен алуда гаепле икән. Алайса, авторның «һәр милләт үзен яңартырга тиешле» дигәнен ничек аңларга? Дөньядан безне Сталинның тимер чаршавы аерып торганда, хәер, аннан соң да үз мәдәниятебезне үз өстәмәләребез белән генә «яңарттык» без. Нәтиҗәсе — һәр тармакта артта калу. Распутинча, безнең зыялылар сүрән урыс чынбарлыгын «үзенең тереклек итүдәге мәгънәсе белән фаш итте». Урыс чынбарлыгын пычрактан, явызлыктан, тәртипсезлектән арындырасы урынга, аны «таптый-изә башлады һәм урысның элек-тән килгән дәүләтчелеген яшәтүгә түгел, ә үлемгә китерә торган сугышны игълан итте».

Зыялыларны икенче, ягъни капма-каршы яктан Борис Ельцин һәм аның командасы да кыерсыта. Аеруча тырышлыкны «Независимая газета» авторлары күрсәтә. Әйтик, А. Кива шул газетаның былтыргы 12 декабрь санында Россиядә тирән структур реформаларның һаман өзелеп килгәнлегенә, эволюция үсешенең камалышта торганлыгына җавап эзли. Баксаң, бу безнең (зыялыларның — Ә. Б.) сабырсызлыкта һәм реализм җитешмәүгә бәйле икән. Дөрес, Кивага кадәр шуңдыйрак җавапны А. Севастьянов үзенчә ачыклаган иде. Ул зыялыларның гөнаһларын Радищевтан һәм дворян революционер-декабристлардан эзли башлый («Кайнар башларның авантюрасы өчен Россия Николай I нең утыз ел патшалык итүендәге авыр изүе, иҗтимагый-сәяси башбаштаклык, крестьян рефор-

маларын һәм капиталистик үсешнең һәлакәткә житкерү дәрәжәсендә тоткарлавы белән түләде»). Кива исәпләвенчә, хөкүмәтнең, аның халыкка каршы курсын тәнкыйтьләүче хәзерге зыялылар таркау, югалып калучан, хәлне аныклауга, аның сәбәбен һәм нигә китерәчәген җентекләүгә, киләчәккә юл табуга сәләтсез. Шуңа күрә автор эшлекле сәясәтчеләргә, «ак пирчәткә» белән гамәл кылучы «үткен егетләргә» үз гамәлен башкарырга комачауламаска тәкъдим итә. Халыкны исә җәнҗал чыгарырга гына сәләтле, дип саный. «Независимая газета»ның 1993 елгы 19 гыйнвар санындагы мәкаләсендә Кива интеллигенциянең хәтта сәяси сәхнәдән тизрәк китүен теләгән. Шул ук газетаның икенче авторы В. Шохина үзенең буталчык мәкаләсендә «эчтән каравы белән» демократияне тулаем интеллигенциягә тиңләштерә. (1993 ел, 20 февраль.)

Интеллигенцияне гаепләүләр, социаль феномен буларак, аның асылын аңлап җиткермәүгә бәйле. Күбесенчә шулай. Фикерләр буенча, зыялылар — аңлы, акыл хезмәте белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнүче һәм махсус белемгә ия кешеләр. Алар — табигый ки, халыкның бер өлеше. Интеллигенция дворяннарның, буржуазиянең хакимлек итүче катламнарыннан саркып чыккан. Ул чакта аны халыкның бер өлеше итеп карамыйча, ә бәлки халыктан өстенрәк итеп карауның нигезе дә булган. Әмма халыкны аның белән бер телдә сөйләшүче, бер үк милли үзенчәлекле һәм бер җирлектә яши торган төрле сыйныф һәм төрле төркем вәкилләре тәшкил итә бит.

Зыялылар — җәмгыятьтәге көч; әлбәттә, җимерүче дә, хасил итүче дә көч. Әмма шул ук вакытта ул — үзен яшәтүгә «комачаулаучы» көч тә. Бу сыйфаты тәнкыйтьчән булуында. Анысы — үзе өчен кыен да, кирәкле дә. Чөнки үз-үзенне белеп кенә мохитны белеп-бәяләп була. Интеллигенция торгынлыкка юл куя алмый, ул ваемсызлыкка һич тә битараф түгел, холкы шулай. Шуңа күрә аны «оппозиция фикерендә яши бирә» дип битәрләү эшче һәм крестьянны матди байлык җитештергәне өчен гаепләү белән бер.

Мәсьәләнең төбе — дәүләт белән зыялылар арасында үзара мөнәсәбәт булдыруда. Фикер иясе М. Гершензон әйтүенчә, интеллигенцияне халык белән мөнәсәбәт булдыруы өчен генә түгел, хакимиятне халык ярсуыннан яклаганы өчен дә якларга бик вакыт. Дәүләт — табигате белән консерватив та бит. Һәм ул, хакимият вәкилләре уйлавынча, илдә тәртип тоту өчен мәңгелеккә бирелгән чиксез мөмкинлекләр мәйданы. 1917 елгача зыялылар дәүләткә дошман дип билгеләнде. Янәсе, аларның эшчәнлеге иңкыйлабка хезмәт итә, чөнки самодержавиенең үзгәртеп корылуында башкача юлны сайлаулары мөмкин түгел. Һәм бүген дә үз халкын изеп яшәүне дәвам итә торган дәүләттән зыялыларга мөнәсәбәт үзгәртүне таләп итеп булмый. А. Московская «Независимая газета»ның 1993 елгы 23 февраль санында язганча, «хәзер интеллигенция... бәйдә булган көе иркен уйлаучы җан иясенә әверелде, ә асылда ул аппарат һәм бизнес кешеләреннән читкә тибәрелгән».

Интеллигенциянең фикерләве — халык күңелендәге вөҗданны, газапны чагылдыру ул. Аның иң яхшы, сәләтле, белемле вәкилләре алдан күрүчән, миллионлаган кеше йөрәгендәге «эчтән кайнаган шаукым»ны элегрәк сизүчән. Алар үзләре эзләп, тырмашып алган мәгълүмат белән бөтеннәрне аңлы итә, хаким затлар җиде йозак астына бикләгән хакыйкатьне өскә алып чыга. Шуңа да зыялылар — реакция корбаны: Советлар аларны җәлләп тормаган лабаса. Иң әйбәт дигән очракта да илдән куыла алар. Мәскәүдә «Ак йорт»ны саклаганда да зыялыларның (дөньяви, клерикаль, хәрби затлар) булуы очраклы түгел иде. Интеллигенция демократияне, димәк, Рәсәйнең киләчәген саклап калды. Һәм Рәсәй үз зыялылары турында кайгыртудан киләчәктә һич оттырмас иде.

«Литературная газета»да (1993, 7 нче сан) Л. Вахнина: зыялылар, халык белән бергә буласы урында, каушап калдылар, алар аны дәртләндерергә, якларга тиеш иде ләбаса, дип яза. Зурлап әйткәндә, әлбәттә, шулай тиеш иде. Әмма мәсьәлә шунда: кыргый базарның тегермән ташына килеп эләккән интеллигенциянең үзен кем яклар соң? Җәмгыятебез алган юнәлеш шундый бит: анда фән, әдәбият һәм сәнгать, гомумән, мәдәният тә дәүләт арбасыннан азлап-азлап төшә, коела бара. Икътисадны дәүләттән аеру мәсьәләсе сан-иш ягыннан күпмиллионлы милекчеләр булмый торып хәл ителмәгәндә, ул сәясәттән арына алмый. Ельцин хакимиятендәге фәлсәфәнең төп тезисы тоталитар монстрны җимерергә тырышам дип, хәтта халыкка каршы чаралардан да чирканмый.

Большевистик «социализм» фәкыйрьлекне, ГУЛАГларны, бәрелешләрне, экологик һәлакәтне гарантияли. Башкача түгел. Әмма хакимиятне тоташтан шәфкатьсез итеп тә күрсәтәсе килми, шуңа да большевистик социаль-икътисади тәрәлеш ноктасыннан корбаннарсыз, шәһитләрсез дә чыгылмастыр.

Социаль нигездә фәкыйрьләнүче халыкны тәшкил итеп торган большевизмны яңартуга зыялылар битараф була аламы? Юк. Шулай да кем гаепле? Халык каршылыгын гәүдәләндерүче интеллигенция үзе түгел. Моңа сәбәпче — власть үзе.

Шуны белү мөһим: кискен, борылышлы хәлдә гаделлек кенә җиңә. Хаклык эзләп маташучы демократик фикерле кешеләрнең күбесе никтер моны оныта. Әмма алар — большевистик яшәү рәвешеннән купшы һәм астыртын файдалану тарафдары. 1917 елгы тәҗрибәне искә алыйк. Ул исә элеккеге хакимият әфәнделәренең сәяси мәйданнан юк булуын, алар урынын яңаларның (радикалларның) биләвен күрсәтә. Сулдан большевиклар («гаделсезлеккә чик куярга» вәгъдә итүчеләр) килде. Аларның җиңүе үзләренең хаклы булганнары өчен түгел. П. Чаадаев фикерләгәнчә, дошманнарның аларны җиңәрлек үк хәлдә булмавы шунда ки, чөнки тоткан юллары дөрес түгел иде. Әлбәттә, революцион зыялылар халыкның иң алгы сафында булырга тиеш иде. Шулай булды да. Һәм бу — хата түгел. Хата — җәмгыять өчен гамәлгә яраксыз проект тәкъдим итүдә. Марксизмны бердәнбер дөрес тәгълимат итеп, халык башын бутауда ул хата.

Иоан Павел II нең 1991 елгы май аендагы бер вәгазендә әйтелгән кисәтүсе искәртәсем килә. Ул җәмгыятьнең алга баруында капиталистик алымнарны җиңел генә үткәреп кертергә маташучылардан сагаерга өнди. «Социализмның һәлакәте капитализм чатаклыкларын акламый», диелә вәгазьдә. Бу фикер капиталны башлангыч туплау вакытына карата аеруча хаклы яңгырый.

Кайбер икътисадчылар уйлавынча, без базарга керү шартларында экономик мәсьәләләрне хәл итеп кенә киеренкелектән чыга алабыз икән. Өстәвенә, алар фараз итүенчә, икътисади тәрәккыят социаль гаделлек белән ярашмый, күпчелекнең мәнфәгате өчен кемнәрдер интегергә тиеш икән. Бу — буталтыру, социаль гаделлеккә икътисадың нәтиҗәле булганда, җәмгыятьтә әхлак өстенлеге урнашканда гына ирешелә. Мәрхүм академик Андрей Сахаров 1989 елда, сентябрь аенда язган «Лион лекциясендә васыять рәвешендә: «Безнең ил нәтиҗәлелек һәм социаль гаделлек бер-беренә тәңгәлләшкән җәмгыять төзүнең тарихи җаваплылыгы алдында тора»,— дип әйткән иде бит. Әмма шундый хәлдә кайбер талантларның империя психологиясенә бирелүләре кызганыч. Ә хакимият урта агымдагы андый зыялылар белән рәхәтләнеп «уйный», үз кармагына ала, җәмгыятькә тагылган идеологиянең «классик»ларын зыялыларга ниндидер дәрәҗәләр, титуллар, исемнәр бирә-бирә хасил итә. Күпләр кабалага эләгә дә. Моннардан ничек котылырга? «Суга батучының һәләкәттән котылуы үзеннән тора»,— ди бит урыс әйтеме. Интеллигенция үзен-үзе яшәтерлек булыр өчен үзе үк кайгыртырга тиеш, үзенең профессиональ бергәлекләре, берләшмәләре, җәмгыятьләре аны хакимияткә матди яктан бәйле итмәслек булсын. Һәм моңа ирешергә мөмкин. Хикмәт — үзең булып калуда.

Дискуссия дәвам итә:

## БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

**Миргазиян Юныс**

# ЮЛЫБЫЗДАГЫ СИКӘЛТӘЛӘР, УПКЫННАР...

Татар әдәбияты. Бүген нинди ул? Аның киләчәге бармы? Бүгенге авырлыклар, чишелмәстәй тоелган төеннәр аша караганда ничегрәк күренә ул киләчәк? Мине менә шушы сораулар борчый. Бүгенге көндәге очраклы һәм уйлап оештырылган «ялгышулар» искә төшкәндә кәгазь өстеннән йөгергән каләм тукталып кала...

Совет чорында әдәбиятыбыз бик каты имгәнде. Ул тулысынча диярлек кыйбласын югалтты. Җитмеш елга сузылган большевиклар хакимиятенең иң зур уңышы — безне бик оста ялганларга, күз буярга өйрәтү булды. Ялган башта саркып кына, ә культ, торгынлык елларында исә язгы ташу гайрәте белән әдәбиятыбызга килеп керде. Ә әдәбият хакыйкать шартларында гына яши ала. Димәк, татар әдәбияты үлемгә хөкем ителгән дибезме? Аны үлемнән кем, нинди эшләр, нинди көчләр, нинди шартлар коткара алыр? Минем бәгыремне шушы сораулар сызлата.

Тарихка күз салып үтик. Фаҗиганең фаҗигасе, тоташ күз яшенә, канга баткан, өстен үлем каплаган уналтынчы гасырның уртасы — илебезгә коллык килгән еллар. Туган туфрагыбызны дошман чабатасы таптый. Үтереш, талау, чукындыру, ата-бабаларыбызның сөякләре күмелгән төбәкләрдән куылу... Ә әдәбият яши. Тез чүкми, чигенми, тәлинкә тотмый. Җәрәхәтле йөрәкне дәвалар-лык җырлар, риваятьләр, бәетләр туктаусыз туып тора.

Ул чакта татар булып туган бәндә икенең берсен сайларга тиеш: йә чукынып исән калу, яисә — үлем. Аяусыз альтернатива. Ике мөмкинлекнең кайсын сайлыйсың, муеныңа кылыч төшкәнче сайла! Искиткеч батырлык бу. Безгә изге үрнәк. Ерак бабаларыбыз үлемне сайлаганнар. Шул исән калдырган татарны. Һәм шундый шартларда әдәбият яши биргән. Укып карагыз, ул чор иҗатының үрнәге — «Ханәкә солтан бәете».

Дүрт гасыр коллык шартларында да ирек рухы белән сугарылган, хөр, әхлак кануннарын саклауга нигезләнгән иҗат татар әдәбиятын яшәтә килгән. Кандалыйлар, Утыз Имәниләр, Шиһабетдин Мәрҗаниләр... Шуларның иҗатларын укып карагыз. Бармы анда ялган? Бармы ул әсәрләрдә ялагайлык, ярашу, колонизаторларның канлы кулларын үбәр өчен тез чүгү? «Урыс булмасам да Рәсәй империясенә тугрылыклы мин» дип җырлаган шагыйрьне ул чорда җир йөтәр иде.

Ниһаять, 1905 еллар... Бозлар эри башлый. Хакыйкать офыгында таң беленә. Шиһабетдин Мәрҗани утыртып калдырган яңарыш орлыклары шытып үсенте бирә. Татар әдәбиятына Тукайлар килә. Әдәбият, сәнгать, театр, музыка — һәр өлкәнең, һәр тармакның әле артык зур булмаса да үз Колшәрифе барлыкка

килә. Һәм әнә шул чорның гайрәтле омтылышы муенына Сталинның канлы балтасы төшкәнче яши.

Явыз Иван чорын хәтерләткән канга баткан кара еллар бу. Кырыгынчы-илленче, алтмышынчы елларның беренче яртысында язылган әсәрләрне укып карагыз. Китап битләрендә дөреслек кан елый. Хакыйкать белән ялган арасында хәлиткеч көрәш бара. Искиткеч авыр шартларда хакыйкатькә омтылу, ата-баба васыятенә тугрылык татар әдәбиятында әле һаман яшәргә тырыша. Тырыша, ә дошман көчле...

Татар әдәбиятының фаҗигасен аңларга тырышкан кеше менә нәрсәгә әһәмият бирергә тиеш: Тукайлар чорында әдәбият китап укучылар аша турыдан-туры халыкка килеп тоташкан. Шәхес культы, торгынлык елларында исә әдәбият белән киң катлам масса арасына чөй кагу процессы башлана. Чөй кагу, тимер пәрдә кору, иҗатка богау салу. Әдәбиятны халыктан аерган имән чөй — әдәбият бюрократлары, тимер пәрдә — партия оештырган пропаганда, богау — коммунистик идеология. Киң катлам массалар һәм әдәбият арасына утыртыла килгән бюрократлар катламы елдан-ел үсә, күбәя, китап белән укучы арасы һаман ерагая, ниһаять, шушы стена калынлыгы аша әдәбият үзенең укучыларын күрми башлый. Тоталитар системаның әдәбият өлкәсендә тормышка ашырылган эше шуннан гыйбарәт. Юк, хакимият бу эш белән генә чикләнеп калмый, язучыларны тулысынча системага тоташтыру, яллау партиянең чираттагы вазифасы итеп куела. Һәм бу теләк, бу план эшкә ашырыла. Язучылар үзләренең иҗат итү эшләрен икенче планга күчереп, бюрократлар армиясенә кушылалар, системага хезмәт итә башлыйлар. Аларның бер өлеше бу эшне аңлы рәвештә, үз теләге белән эшли, икенчеләре, конформист буларак, башкаларга ияреп, күпчелеккә каршы чыгарга куркып башкара. Әкренләп иҗат сүнә, әдәбиятның тәэсире сүрелә, укучы әдипләрнең сүзенә ышанмый башлый һәм әкренләп китаптан бизә. Юк, вакуум беркайчан да буш тормый — чын әдәбият урынына әкренләп детектив, имитация юлы белән эшләнгән маскульт әсәрләр, порнография тула. Һәм шушы өлкәдә эшләүче кәсепчеләр барлыкка килә.

Җәмгыять пирамидасының төбәсендәге тәхет тирәсендә утыручылар арасында акыллы кешеләр булган, күрәсең. Алар әдәбият белән идарә итүне тулысынча үз кулларында тотмадылар, ә әдипләр арасыннан түрәлеккә әвәс аумакай бәндәләрне сайлап алып, шуларның куллары белән әдәби сәясәтне башкарып торганнар. Бу процесс икенче бөтендөнья сугышы вакытында яулап алган илләргә фашистлар хөкүмәте утырткан гауляйтерлыкны хәтерләтә. Чыннан да, Үзәк Комитет даими рәвештә һәр союздаш республикага аерым бер әдәбият гауляйтеры, автоном республикаларның берничәсе белән идарә итүче гауляйтерны тотты. Соңгы елларда Идел-Урал төбәгендәге автоном республикаларга күз-колак булып торучылар янәшәбездә яшәде. Гауляйтерлыкка омтылучы язучылар чиктән тыш күп иде. Шул урынга үрмәләү, конкуренция, ызгыш, итәк астыннан ут йөртүләр хакимият өчен гаҗәп тә файдалы нәрсә иде. Башка язучыларны ымсындырыр өчен партиянең Үзәк Комитеты гауляйтерларга бүләкләрне мул итеп өләшеп торды: миллионлаган тираж белән китап чыгару дисеңме, әсәре өчен гауляйтерның түшенә лауреат билгесе тагу дисеңме һәм даими депутатлык привилегияләре, ниһаять, илле яшьлек юбилей житкәч, Хезмәт герое итеп түшкә алтын йолдыз тагу ритуалы. Дөрес, соңгы вакытта кавалерларның күбесе түшләренә алтын йолдыз тагып кеше арасына чыгарга ояла башладылар. Чыннан да, өстәл янында утырып әсәр язу нинди геройлык булсын инде! Геройлыкны сугышта күрсәтеп була. Юк, Әфган сугышы шикелле бала-чаганы, карт-корыны, хатын-кызларны танкка таптатып, «дошман» яшеренгән кышлакны анда яшәүче барлык халкы белән бомбага тотып, җир белән тигезләп, миллионнан артык беркемгә бернинди зыян китермичә яшәүче тыныч кешеләрне кырып ташлау да геройлык түгел, вәхшилек. Чын геройлар Сөембикә һәм Колшәриф җитәкчелегендә Казанны варварлардан саклаучылар арасында булгандыр. Совет чорында исә андый геройлыкка тискәре бәя бирелеп килде.

Әдәбият дөньясына кайтыйк. Ялганга һәм аяусыз әшәке көчкә таянып эш иткән хакимият иртәме-соңмы җимерелә. Ә тоталитар хакимиятның җимелүе ниләр китерде соң әдәбият дөньясына? Урыс совет әдәбиятында, мәсәлән, әле кичә генә «халык дошманы», «империалистлар агенты» саналып йөргән Солженицынга иман китереп, аны бүгенге көннең пәйгамбәренә санап йөри башладылар. Татар әдәбиятында иң югары урынга Гаяз Исхакый менеп утырды һәм матур бер иртәдә Салих Баттал, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Батулла шикелле язучыларның «совет чынбарлыгын бозып, кәкре көзгедәгечә күрсәтергә тырышучылар» түгел, киресенчә, хакыйкатькә таянып иҗат итүчеләр икәнлеген аңладык.

Ләкин әдәбият белән киң катлам укучылар арасына оялаган бюрократлар әле һаман китәргә теләми. Син көчәнеп кычкырасың, башыңны ташка орасың — ә тавышың шул бюрократик катламга бәрелеп сүнә. Өнсезлек. Ишетми укучы безнең тавышыбызны! Ишеттерер юлын таптың да ди. Бу очракта да син морадыңа ирешә алмыйсың. Ышанмый ул син әйткән сүзләргә. Чөнки, без озак еллар буе аңа ялган сөйләдек, күз буядык, укучының, халыкның җилкәсенә атланып утырган, ул тапканны ашап, туздырып торган әрәмтамакларга ярдәм итеп тордык. Хөрмәтле укучының безгә ышанмаска хакы бар. Рәнҗемик аңа.

Мәктәп программасы нигезендә уздырылган әдәбият дәресләрен искә төшерергә тырышып карагыз әле. Әдәби әсәрләр гүяки сыйныфлар көрәшеннән генә тора иде. Матур әдәбиятның үзенә генә хас кануннарны, әдәби сурәтләрне, тел музыкасын, сүз тылсымын, әйтелмәгән сүзнең укучы күңеленә килеп житүен — боларны укучыга кем күрсәткән, кем аңлаткан? Юк, бары тик көрәш. Яшәү — көрәш, дөнья көтү — көрәш. Әдәбият — көрәш аренасы. Мәктәптә әдәбиятны өйрәнү — баланы әдәбияттан биздерү процессы иде дисәк, ялгыш булмас. Бу фикер гомумән әдәбият турында. Татар әдәбиятын мәктәпләрдә өйрәнү искә төшкәндә тәннәр чымырдап китә. Тарих дәреслекләрендә, урыс әдәбиятында, көндәлек матбугатта «татар-монгол золымы» дип аталган, җир йөзендәге иң тупас, иң пычрак уйдырма һәр адымда таш шикелле маңгаебызга килеп бәрелә торды. Шушы шартларда татар исеменә бәйләнешле әдәбиятны ничек өйрәнеп, ничек яратып булсын! Шушы шартларда ничек милли хисне, ата-баба, нәселебезнең, токымның ерактан калган өлгеләре белән ничек горурланып, аларны ничек саклап булсын? Без Бухенвальд, Дахау, Майданек концлагерьларында адәм балаларын юкка чыгару турында укыганда нәфрәт, косасы килү көче чәчләребезне үрә торгызганын тоябыз. Татарларны юкка чыгару эше совет чорында фашист концлагерьларындагыга караганда остарак һәм аяусызрак оештырылган иде. Концлагерьларда адәм баласын махсус мичтә яндыруга тоткыннар үзләре катнашмаган. Татарларны юкка чыгару эшендә исә татар түрәләре, куштаннар, тәлинкә ялаучы милләттәшләр, томаналар, хәтта карап торуга үз акылында булганнар да зур тырышлык белән коммунистлар партиясе куйган «интернациональләштерү» геноцидын эшкә ашырып килгәннәр. Сан ягыннан кимү, башка милләткә күчү, милләтара никахлар буенча (әйдә, горурланыйк!) без һәрвакыт беренче урынны тотканбыз. Исең, акылың китәрлек парадокс: без ничек милләт буларак йөз процентка юкка чыкмаганбыз икән? Социаль-психология өлкәсенә күз салганда бу феноменны аңлап һәм аңлатып була. Сыйфат кимү бәрабәренә, татарлыкны югалту юлы белән, «өлкән агайларга» ошый башлау аркасында без әзме-күпме исән кала алганбыз.

Татарлык белән бездәге нинди сыйфатлар югала барган соң? Сөембикәдәге ватанны, туган халкыңны сөю; Колшәрифтәге тугрылык; Мәрҗанидәге фикер кайрәте, акыл; Тукайдагы моң; Рудольф Нуриевтәге гайрәтле һәм нәфис талант егәре. Милли горурлык арсеналыннан югалган сыйфатларыбызны барлый башласак, аның очына-кырыена чыгып булмас иде. Кырыгынчы-илленче елларда шәрә килеш бозга катырганда да хәрби серне ачмыйча үлгән генерал Карбышевның батырлыгы турында сөйләгәндә: «Бу кешенең баш бирмәве, түземе, ватанга тугрылыклы булуы урыс характерын чагылдыра»— дип әйтмичә калмыйлар иде. Ә менә Әкрәм Шәриповның Карбышев турындагы китабында аның татар булуы ачыкланган. Герой генерал үзенең кайсы милләт вәкиле икәнлеген яшерәсе урынга, татарлыгы белән горурланып йөргән икән. Соңгы илле-алтмыш еллар эчендә милли горурлык татарлыкны яшерүгә алышынды. Җәмгыять пирамидасының очына үрмәләп югарыга күтәрелгәндә адым саен милли сыйфатның бер өлешен югалта идек без. Өскә калкып чыгып, пирамиданың сыртына атланып утырганда татар авылында татарга кияүгә чыккан татар хатыныннан туган бала кинәт кенә башкортка, яисә урыска әйләнеп куя иде. Ә бу мәсьәлә татар әдәбиятында чагылганмы соң? Алла сакласын! Кайсы язучының маңгаена утлы тимер белән басылган тамга аласы килә!?

Тукайлар, Гаяз Исхакыйлар чорында милли психологияне аңлауга, аны укучыга җиткерүгә зур әһәмият бирелгән. Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәшировлар, Әмирхан Еникиләр буынында бу эш әле дәвам итә. Татар әдәбиятын «бөек социалистик төзелешләргә, коммунистик хезмәт ударникларына» мәдхия җырлаучылар баскач, бу юнәлештә эш итү бөтенләйгә диярлек сүнде. Көчләп ассимиляцияләштерү «халыклар дуслыгы» дип атала иде. Хәзер Кавказда, Днестр елгасы буенда, Урта Азиядә коелган кан — шул «дуслык»ның дәвамы һәм нәтиҗәсе ул.

Революциягә кадәр иҗат иткән әдипләр мәдрәсә белеме алганнар. Аларның күпчелеге профессиональ руханилар — рухият өлкәсе белгечләре. Әле бүген дә әдәбиятта мулла балалары, рухани оныклары эшли. Китап укучы революциягә кадәр дин китабы белән әдәбият китабы арасындагы аерманы белмәгән диярлек. Мәчет мөнбәреннән вәгазь сөйләүне генә алыйк. Соңгы елларда әдәбиятның алгы сафына чыккан публицистикадан кайсы ягы белән аерыла бу эш?

Дини инану адәм баласының күңеленә тирәнрәк үтеп керә. Аның тәэсире, символлары, сурәтләү ысуллары әдәбиятныкына якын. Алланың барлыгына инану, аның гадел хөкеменә ышанып яшәү бу михнәтле дөньяда, бигрәк тә бәхетсезлеккә юлыккан чакларда, адәм баласына юаныч, күңеленә тынычлык һәм бәхеткә омтылу өчен көч биреп тора. Матур әдәбиятның тәэсире дә нәкъ шушы рәвештә. Диннең аермасы тик шунда: ул инанып яшәүчеләргә савап белән гөнаһ арасындагы чикне күрсәтеп, адәм баласын гөнаһ эшләүдән саклап торса, әдәбият исә укучыга хакыйкать белән ялган, яхшылык белән яман арасындагы чикне билгеләп тора. Ә инде хакыйкатьнең савапка, ялганның гөнаһка килеп тоташуын аңлатып торасы юктыр дип уйлыйм. Димәк, дин һәм әдәбият кешелек дөньясында бер үк вазифаны башкарып киләләр. Большевикларның дингә ыргыткан ташлары шул ук аяусызлык белән әдәбиятыбызга китереп тондырган. Кибет киштәләрендә муртаеп яткан татар китапларын күргәндә мин шушы турыда уйлыйм. Тик уйлау гына җитми. Ашыгыч чара кирәк.

Христиан диненә бары тик утызынчы елларда гына кул күтәрделәр. Мөселманлыкны үтерү эшен исә Явыз Иван белән архиепископ Макарий уналтынчы гасырның урталарында ук оештырып җибәргәннәр — татар әдәбиятын юкка чыгару менә кайсы заманнарда башланган булган. Хәйран калырлык хәл — ул ничек юкка чыкмаган?

Рухи байлыкның, гореф-гадәтләрнең дин мохитында гына саклана алуы турында күптән билгеле. Тоталитар империячел хакимият динсез корып таркала башлаган милли рухиятны «халыклар дуслыгы» дип аталган ассимиляцияләү процессында таптап килде. Шул гамәлләр белән янәшә «милли әдәбиятларны үстерү» лозунгысы астында колониаль шартларда яшәүче «ирекле» милләтләрне туган әдәбиятларыннан биздерү эше алып барылды. Бу эш ничек эшләнде соң? «Зур язучы» исеменәирешү өчен Мәскәүдә урыс телендә китап чыгару зарур иде. Бу хәл әдәбият бюрократлары телендә «бөтенсоюз аренасына чыгу» дип атала иде. Әдәбият дөньясының коньюнктурасын белмәгән кеше «бөтенсоюз аренасын» урыс телендә басылып чыккан татар китабын 240 миллионлы совет халкы дәррәү эләктереп алып шундук укый башлый дип күз алдына китергәндер, бәлки? Юк шул — тәрҗемәгә эләккән китапларның язмышы тагын да фаҗигалерәк иде. Урыс телле укучы авторның «нацмен» икәнлеген күрү белән китаптан шундук баш тартты. Тәрҗемәче халтурщиклар үзләре дә «нацменнар» теленнән «өлкән абый» теленә күчкән китаплар турында нинди генә мәсхәрәле фикерләр әйтмәделәр, «бөтенсоюз аренасы»на чыгу «бәхетенә» ирешкән авторларны ничек кенә кимсетмәделәр. Бу эш «вак» халыкларның әдәбиятларына искиткеч зур зыян китерде. Язучыларның күпчелеге үз халкы өчен түгел, Мәскәүдә басылып, «бөтенсоюз аренасы»на чыгу өчен язарга тотындылар. Әдәбият ялагайланды, ярашуга, ассимиляциягә дучар булды. Әдәбият халык тормышыннан, милли җирлектән аерылды. Тәрҗемәгә өметләнгән язучылар «өлкән абыйлар» әдәбиятына охшарга тырышып эшли башладылар. Татар әдәбиятын эпигонлык басып китте. Эпигонлык һәм вторичность.

Ә бит урыс әдәбиятының тәрҗемәчеләре арасында Борис Пастернак, Арсений Тарковский, Мария Петровых, Рита Райт-Ковалева шикелле корифейлар да эшли иде. Нишләп соң алар теләсә кайсы Аурупа халкын тетрәндерерлек «Әйтелмәгән васыять», «Әтил суы...», «Ташлар моңы» шикелле әсәрләрне тәрҗемә итмәгәннәр? Моңа, беренче чиратта, татар әдәбиятының тәхетендә ыштан төбе туздырган түрәләр һәм, икенчедән, безнең хәерчелек гаепле. Әнә грузиннар, әрмәннәр һәм Балтик буе халыклары экстра класслы тәрҗемәчене кулга төшерү өчен саранланып тормадылар. Ә татар авторларын кем тәрҗемә итте? Бу турыда сөйлисе дә килми...

Башка объектив сәбәпләргә татар язучыларының урыс телендә басылып чыккан китапларының түбән сыйфатлы булулары килеп кушылды. Татар китабыннан бизү тагын көчәйде. Юк, бу процессны китаптан биzү белән генә чикләп булмый. Көндәлек матбугатка, агитпроп китапларына тәязеп аккан ялган, күз буяу, икейөзлелек — болар барысы бергә кушылып, халыкны ташка басылган сүздән биздерү эшен бүгенге көн цинизмы, рухсызлыгы дәрәҗәсенә китереп җиткерделәр.

Тоталитар хакимият чорында иң кызганыч, иң нык тапталган, иң каты газап чиккән бәндә — эшен халтурага көйләмәгән иманлы язучы иде. Кулына каләм алу белән КГБның тимер рәшәткәле ярымподвал тәрәзәләре аның күз алдына килеп баса. Яза башлау белән Хәсән Туфан, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Ибраһимовларга салган богауларның шалтыраган тавышлары ишетелә башлый.

Менә ул яза башлады. Каршысына ялган килеп басты. Ялган әдипне хакимияткә мәдхия җырларга кыстый, мулллык, дан-шөһрәткә коенып яшәү вәгъдә итә. Әдип үз талантының тавышын ишетә. Ул белә, талант бит ул вөҗдан сизгерлеге, иман егәре. Талант хуҗасына болай дип пышылдый: «Әйе, әгәр син партиянең йомышчысына, хакимият куштанына әйләнеп ялган язсаң, майда йөзәсең. Сиңа зур, якты квартир бирәчәкләр, күтәреп кенә йөртәчәкләр, кесәң тулы акча булачак. Дөрес, зәвыклы укучы синнән бизәр. Зәвыклылар — алар аз бит. Күпчелек синең түшеңә тагылган орденнарга, лауреат билгеләренә карап ихтирам итәчәк. Ялган яза башласаң, югалту зур булмаячак. Югалту шул — мин сине ташлап китәчәкмен. Имансызга һәр тарафта юл ачык. Имансыз ни теләсә шуны эшли ала. Йә — мин, яисә дан-шөһрәт. Йә мин, яисә рәхәт тормыш-көнкүреш. Икенең берсен сайла».

Коммунистик идеологияне кабул итеп, системага хезмәт итә башлаган әдипнең эше бик тә җиңеләеп китә иде. Кемнәрне, нинди гамәлләрне мактарга, кемнәрне тәнкыйтьләргә кирәклекне партия турыдан-туры күрсәтеп торды. Ялгыш җибәрсәң, сине цензура төзәтте. Яза гына бир. Партия сүзен тыңлап, ул күрсәткән юлдан барсаң, китап бастыруны да, аны укучыга житкерүне дә өлкә комитетының пропаганда бүлеге үз өстенә алды. Хәтта бүләкләү, мактаулы исемнәр тагу да фирка җаваплылыгында иде.

Ә хәбәрдарлык килү әдәбият дөньясына тамыр җәйгән тәртипне юкка чыгарып ташлады. Кыйбла йөз сиксән градуска үзгәрде. Әгәр элек системага мәдхия җырлау уңышка ирештерсә, хәзер киресенчә, аны аяусыз тәнкыйтьләү лавр яфракларыннан үргән венок бүләк итә башлады. Плюс минуска, минус плюска әйләнде. Шушы хаоста, башбаштаклык баскан җәмгыятьтә язучы кемне мактарга, кемне тәнкыйтьләргә белмичә аптырап, җилкәсен кашып тора. Кемне мактарга? Демократнымы? Ауропаны сокландырган, Көнбатыштагы тормышны җайга салып, гаделлек урнаштырган демократия Рәсәйгә килеп керү белән халык телендәге «дерьмократия»гә әйләнде.

Бүгенге чынбарлыкны әдәбият күренешенә әверелдерү чиктән тыш авыр, чиктән тыш катлаулы. Көн тәртибендә — плюрализм, шаблонсызлык. Әдипләр каршына яшәешне һәр яктан, тирәнтен өйрәнү, анализлау, философия, социаль психология күзлеге аша үткәреп карау бурычлары килеп басты. Татар әдәбияты үзгәрешләр чорына әзерлексез килде. Милләтнең хәлен, аның киләчәген күрсәтергә тырышкан әсәрне халыктан яшереп тоттылар. Империя җимерелә башлагач, язгы ташу вакытындагыча, җәмгыятьтә ташу кузгалды. Ташу кузгалганда су өстенә чүп калка, җир эрегән чакта аяк асты баткаклана. Нәкъ шул күренеш бүгенге җәмгыятьтә. Дөньяны сәясәтчеләр чүбе, аларның әхлаксыз шапшак гамәлләре басты. Һәр нәрсәне сәясәткә әйләндереп торучы яәҗүҗ-мәәҗүҗ явы чорнап алды дөньяны. Иң зур кабахәтлек — милли омтылышларны сәясәткә батыру. Элек СССР дип аталган иксез-чиксез зур территориядәге хәлләрне аңлап та, бәяләп тә булырлык түгел иде. Бүген дә шулай. Мәскәү газеталары битеннән, телевидениедән, радиодан тоташ агым булып ялган тарата. Мин бераз вакыт Мәскәү татарларының милли хәрәкәтен якыннан күзәтә алдым. Кемнәр генә омтылмый милли лидерлыкка: кулларыннан эш килмәгән комсызлар, милләт мәнфәгатен сатып баерга, аның җилкәсенә атланып утырырга омтылучы әхлаксыз оятсызлар. Шулар арасында иң күбесе — Лубянка шымчылары. Кая карама, үзара бугазлашкан, ерткыч җанвар шикелле бер-берсен ашарга торган властька үрмәләүчеләр. Әдәбият безгә шушы чынбарлыкны сурәтләп күрсәтергә тиеш. Бармы икән татар язучылары арасында шушы эшкә көче житәрлек кеше?

Татар әдәбиятының үзгәрешләр чорына әзерлексез килүе нидән гыйбарәт соң? Без, татар әдипләре гомер буе мөстәкыйль фикер йөртүдән өркеп яшәдек. Фәлсәфи эзләнүләр тыелып килде, шәхси күзаллау гөнаһ саналды. Артта калган һәм алдынгы, ялкау һәм ударник, консерватор һәм прогрессив карашлы әдәбият геройлары белән мавыгып иҗат итү безне шәхеснең бөтен катлаулыкларын танудан, аңлый алудан мәхрүм итте.

Соңгы елларда үзара ярыша-ярыша романнар әмәлләү белән мавыктык. Укучының күңеленә тапталмаган яңа юллар эзләү, яңа жанрлар, сурәтләр табу өстендә бөтенләй эшләмәдек диярлек. Ә бит әдәбият кыры тирән үзгәрешләр, яңалык көтә.

**Әдәбиятыбызның яңаруы, аның офыклары, жанрларның кинәю хәрәкәте шактый зәгыйфь һәм әкрен бара. Әдәбият мәйданына килгән яшь буынның көчле сулышы, яңгыравыклы саф тавышы ишетелеп тормаганда китап сүзе әкеренләп көчен, тәэсирен югалта.**

Совет чоры безнең татар әдәбиятын берничә мәжбүри тема эченә куып кертеп йозаклап куйган иде. Егерменче еллар темасы — индустриализация. Авыл малае шәһәргә килә, заводка кереп эшли башлый, рабфакка кереп укый, сыйнфый дошман белән көрәшә. Утызынчы еллар темасы — колхозлашу. Кулакларга каршы сыйнфый көрәш. Кырыгынчы, илленче еллар — Бөек Ватан сугышындагы геройлык. Алтмышынчы еллар — нефть чыгаручыларның геройлыкларын сурәтләү. Җитмешенче еллар — КамАЗ төзүчеләрнең геройлыгы. Әдәбиятны «герой» дип аталган шаблон әрсезләр басты.

Китап язу өчен теманы язучы үзе сайлый иде дисәк, ялган булыр. Хөкүмәт бишьеллык план төзи. Партия съезд җыеп шул планны раслый һәм һәр тармакка, өлкәләргә, республикаларга йөкләмә тарата. Бишьеллык планга кергән эшләрнең героикасын халыкка сурәтләп күрсәтү — язучылар оешмасы өлкә комитеты каршында өстенә йөкләмә ала. Шул бишьеллык планга кертелгән төзелешләргә, авыл хуҗалыгын күтәрүгә, фәнни-техник прогресска багышланган романнар кирпеч-кирпеч булып китап киштәләренә килеп кунаклап тордылар.

Әдәбиятның чын вазифасы нидән гыйбарәт икән соң? Дөнья әдәбияты бу турыда нәрсә сөйли? Без шәрык халыкларының әдәби процессын начар беләбез. Ул әдәбиятларны бары тик шәрыкны өйрәнүче махсус уку йортын бетерүчеләр генә әз-мәз белә. Аурупа һәм Америка халыклары әдәбиятларына күз салып үтик. Болар — әдәбиятның иң югары уңышка ирешү төбәкләре.

Урта гасырларның азагы. Англия әдәбиятында — бум. Дөнья кинлегенә Уильям Шекспир иҗаты күтәрелеп чыга. Ренессанс чорының башланып киткән чагы. Италия әдәбияты бөтен дөньяга үрнәк. Данте Алигьеринын даны җир шарына тарала. Бөек географик ачышлар чорында Испания әдәбияты шаулап ала. Әдәбият тарихына Сервантесның исеме алтын хәрефләр белән языла. Әдәбиятның иң зур уңыш биреп торган җире шактый озак вакытка Франциягә күчә. Франсуа Вийон һәм Рабле чоры, Корнель һәм Расин чоры, Стендаль һәм Бальзак чорлары. Әле безнең чорга кадәр диярлек Париж дөнья күләмендә данлыклы әдәбият һәм культура үзәге, язучылыкка һәм сәнгатькә өйрәнү мәктәбе ролен уйнавын дәвам итә. Унтугызынчы гасыр азагында иң зур уңышларга ирешкән әдәбият — урыста. Лев Толстой һәм Федор Достоевский чоры. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Джойс чорында Англия әдәбияты зур уңышларга ирешә. Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач Америка әдәбиятында күзгә ташланып торган җанлану башлана — Хемингуэй, Фолкнер, Стейнбеклар чоры. Бүгенге көндә испан телендә язган Көньяк Америка язучылары алгы сафта — Габриэль Гарсиа Маркес, Кортасар, Борхес иҗатлары нәкъ шушы фикерне исбатлый.

Әдәбиятның үсүенә, аның кинәт күтәрелеп китүенә нинди көчләр тәэсир ясый икән? Шушы мәсьәләне ачыклыйсы килү дөнья әдәбияты тарихына мөрәҗәгать иттерә. Һәм без шуны күрәбез: әдәбият җәмгыятьтә зур үзгәрешләр, тарихи борылышлар башланыр алдыннан алгы сафка чыга. Димәк, бүгенге көндә безнең татар әдәбиятына зур өметләр багларга хакыбыз бар. Әдәбият зур уңышларга ирешсен өчен нинди шартлар булырга тиеш соң? Илдән илгә, халыктан халыкка күчеп йөргән әдәбият өлкәсендәге уңышлыклар шуны күрсәтә — иң беренче урында ирекле иҗат. Хакимияткә буйсынган, яисә кайсыдыр көчкә хезмәт иткән әдәбият уңышка ирешә алмый. Әгәр әдәбият тарихына кереп калган язучыларның иҗатларын өйрәнә башласак, без иң башта әдипнең кулына каләм алырга мәҗбүр иткән көчнең адәм баласының язмышын аңларга тырышу теләге икәнен күрәбез. Барлык әдәбиятларның төп герое — кеше язмышы, чорның кара көчләренә карата нәфрәт, кешенең җанын сыкраткан сорауларга җавап эзләү.

Шушы көнгә кадәр әдәбият туктаусыз түбәндәге сорауларга җавап эзли: бу дөньяга адәм баласы нинди максат белән килә, нинди теләк белән яши? Ул нигә бәхетсез? Ни сәбәпле кеше адым саен гаделсезлекләргә юлыгып тора? Кайсы юл бәхеткә алып бара?

«Нәрсә ул әдәбият?» дигән сорауга да шушы көнгә кадәр тулы җавап табылганы юк әле. Татар язучылары өчен бу сорау гаять актуаль һәм аны ачыклый алмасак без һаман өлкә комитетының йомышчы малае хәлендә булуыбыздан арына алмаячакбыз. Татар әдәбияты бүген дүрт ярым гасырга сузылган коллык тарихын яза. Нинди ялгышлыклар безне ирекне югалтуга дучар иткән?

Нинди шартларда, кайсы юллардан без тулы мөстәкыйльлеккә ирешеп, иркебезне кире яулап ала алырбыз? Ни сәбәпле яшәү белән үлем, ирек һәм коллыкның хәлиткеч мизгелендә татарларның зур бер өлеше теше-тырнагы белән коллыкта яшәүгә ябыша? Нишләп безнең арада сатлык җаннар күп? Нилектән без, күрә торып, милли хәрәкәтнең язмышын зур ваемсызлык, битарафлык белән дошманга сатып җибәрергә әзер торган имансыз кешеләргә тоттырабыз? Бүгенге көндә без күрәшкә, оешуга кирәкле көчебезне үзара ызгышка, бер-беребезгә комачаулык коруга тотып бетерәбез? Шушы таркаулык, бер-беребезне күрә алмау, милләт мәнфәгатен сатудан тартынмау, әхлаксызлык, рухсызлык безгә каян килеп кергән? Бу сыйфатлар дүрт гасыр ярымга сузылган коллык җимешләре түгелме икән? Бүгенге көндә татар әдәбияты алдында шушы сорауларга җавап эзләү, ирек яулау юлында очраган куркынычлы казалардан котылу юлын укучыга күрсәтү вазифасы тора. Бу чиктән тыш җаваплы вазифа. Әдәбиятның киләчәк юллары текә үрләр, төпсез упкыннар аша узачак. Әдипләрнең эше авыр, җаваплы, ялыктыргыч.

Азатлык көрәше адым саен икенең берсен сайлауны таләп итүче альтернативаларга килеп бәрелә. Әйтерсең нииндидер каһәрле көч безне туры юлдан яздыру өчен буталгыч юл чатлары әзерләп куйган. «Уңга барсаң, ирегеңне биреп муллыкка ирешә аласың. Сулга барсаң, малыңны югалтып ирекқә чыгарсың» дип язып куйганнар юл чатларына. Шушы икенең берсен сайлаган чакларда һәр очракта без чал тарихка мөрәҗәгать итәргә тиешбез. Бу турыда туктаусыз кабатлап торудан баш тартырга җыенмыйм мин. Ирекләрен туклыкка алыштыручыларның язмышлары фаҗигале. Тук яшәүгә ымсынып ирекләрен кулларыннан ычкындырган халыклар, этник берәмлекләр, аерым шәхесләрнең гомерләре һәр очракта ачлыкта, ялангачлыкта үтә. Ирекләрен соңгы сулышларын биреп саклый алучылар һәр очракта мул, иркен, бай тормышка ирешә торганнар.

Азатлык белән коллык альтернативасы көн тәртибенә килеп баскан чакларда тарих мәйданына Шаһгалиләр чыга. Иман сату, халыкның ирек яулавына хыянәт итү белән очрашкан саен исемә Хәсән Туфанның бер сүзе килеп төшә. «Бизнесмен» сүзен ул авызына ашамлыкка ияреп кырыгаяк элəккəндəге шикелле җирәнеп, укшып әйтә иде. Бөек шагыйрьдә күрәзәлек сәләте көчле булган, күрәсең. Ул «бизнесмен» сүзен матди файдага ирешү өчен иманын сатарга, халкына хыянәт итәргә әзер торучыны күздә тотып куллана иде. Мәшһүр шагыйрьнең юраганы юш килде. Карагруһларның алдынгы сафында, аларның байрак тотучылары арасында шактый гына татар кешеләре. «Вечерняя Казань» газетасының әхлакый шапшаклыгын, аның лайлалы хыянәтләрен гамәлгә ашырып торучылар арасында да татар хатыныннан туган җаннар да бар. Татарстан парламентында безнең мөстәкыйльлекне буарга кулларын сузып, тешләрен ыржайтып акыручылар арасында да хыянәтчел милләттәшләребез. Сатлык җаннарның мыжлап торган, КГБ шымчылары баскан җирләре — диаспора. Мин бу хәлне озак вакыт Мәскәүдәге «Туган тел» җәмгыятенең эшен күзәтү дәверендә күреп торам.

Татар әдәбиятының иң мөһим, иң актуаль бурычы укучыга шушы хыянәтләрнең чыганагын ачып, сәбәбен күрсәтү. Масса күләмендә үз-үзебезне сазлыкка батыру кайчан тукталыр? Бу сорауга бары тик әдәбият кына җавап таба алачак.

Богауларын өзеп ташлаган әдәбият кына!

Азадә-Гайшә Рүрлих

# ТАТАРЛАР:

# БЕР МИЛЛӘТМЕ, ӘЛЛӘ БЕРНИЧӘМЕ?

Бу мәкаләнең исеме үк үзенә күрә укымышлылыкның мина кырына чакыру булып яңгырый. Шул мина кыры аркылы хәвефсез берләнбер юл табу өчен түбәндәге төшенчәләрнең эчтәлеген төгәл ачыклау фарыздыр: «милләт», «милләтчелек» һәм «милли үзаң». Ләкин бу ачыклау һич тә мөмкин түгелдер, чөнки шул проблемага багышланган фәнни әдәбият, бер яктан, бик күләмле һәм күпсанлы булса, икенче яктан, галимнәрнең карашлары кайвакыт капма-каршы. Инде 200 еллар элек милләт теориясенең беренче пәйгамбәрләре Һердер, Бурке, Руссо, Джефферсон шуны Европа җирлегендә тикшереп карасалар да, бүгенге көнгә кадәр «милли бердәмлек нәрсә ул?» дигән кайнар бәхәсләр сүнмәгән. Хәзер дә, иң яхшы очракта, яна вариантлар тәкъдим ителә, алары да еш кына элекке яңарыш һәм үсеш модельләренең нигезендә һәм шуларга өстәмә булып кына яңгырый — мондыйлар күбрәк саф интеллектуаль һәм сәяси критерийларга таяна. Мәсәлән, Карлтон Хейес, Алфред Коббанс, Н. Һ. Кэррз, Һанс Кон элекке рухи тарихның традицияләре кысасында фикер йөртә. Дискуссияне Карл Дойч, Эли Кедури, Ойджен Вебер, Ч. Тилли, И. Гелльнер һәм Дадли Сирс хезмәтләре баетып җибәрде. Искә алынган авторлар милләт, милләтчелек, милли үзаң турындагы бәхәсләрендә, хәзерге социаль белем казанышларына таянып, төп игътибарларын социаль-икътисади үзгәрешләргә, яңарыш һәм үсеш теорияләренә юнәлтә.

Төгәл төшенчәләрнең юклыгын истә тотып Эрнст Хаас карашларына таянып, түбәндәге мәкаләдә без милләтне болай дип аңлыйбыз: башкалардан, читләрдән аерып тора торган ышанычлары, төрле сыйфатлары бердәй, үз дәүләтчелеген булдырырга яки сакларга омтылган социаль яктан оешкан шәхесләр берлеге. Шул шәхесләр үзләренең үзенчәлекләре һәм аерымлыклары аркасында аерым күмәк үзаңга ия булалар.

## Кырым һәм Идел буе татарлары: ике милләт?

«Социаль яктан оешкан шәхесләр берлеге» дип бу мәкаләдә татарлар күздә тотыла һәм 1979 елда аларның саны 6 317 468 иде.

«Татарлар» дигән төшенчә кыпчак төркиләренең варисларын аңлата, алар Монгол империясенең көнбатыш өлешендә, ягъни Җүчи Улусында яшәгән. Җүчи Улусы (Алтын Урда) җимерелгәннән соң бу халыклар төрле әтрафларга — Польша чикләреннән алып Кара диңгезгә, Урта Иделгә һәм Урал-

---

Азадә-Гайшә РҮРЛИХ (1942) — *АКШта (Лос-Анжелес) яшәүче татар галиме, төрле телләрдә басылган күп кенә тарихи хезмәтләр авторы. Бу мәкаләсе — авторның Алманиядә ясаган чыгышы «Die Muslime in der Sowjetunion und in Jugoslawien» (Кельн, 1989) җыентыгыннан алынды. Искәндәр Гыйләҗев тарафыннан алманчадан тәрҗемә ителде.*

га кадәр җәелгән. Бүген Идел буе, Кырым, Литва, Себер, Әстерхан һәм Касыйм татарлары Алтын Урда халкыннан килеп чыккан төп төркемнәрне тәшкил итә һәм алар өчен «татар» төшенчәсе «этнос» мәгънәсендә кулланыла. Этносны без монда үзенең җире, уртак традицияләре һәм тугандаш шивәләре барлыгы белән аңлатабыз. Этнос аңлы рәвештә башка халык төркемнәре белән элемтәләр урнаштырса, бу очракта аның милли үзаңы барлыгы турында сүз йөртергә мөмкин, ә аның үзен милләт дәрәҗәсендә карарга буладыр.

Бу төркемнәрдә милләт үзенчәлекләре барлыгы табигый рәвештә шундый сорау тудыра: аларның кайсыларын без милләт дип саный алабыз? Уйлавыбызча, без бары тик Кырым һәм Идел буе татарларын милләт дип санарга хаклыбыз, чөнки алар икесе дә, бер яктан, тарихи милләтләр сыйфатында элекке заманда үз дәүләтчелекләренә ия булды, икенче яктан, шул үткәннең мирасы 1917 ел революциясеннән соң тиз арада аларда мәдәни автономия, мәйданый автономия һәм, ниһаять, тулы бәйсезлек таләпләре һәм дәгъвалары тудырды.

Кырым һәм Идел буе татарларының ике милләт тәшкил итүе турындагы бәхәскә нигез тарихта күптәннән салынды. Беренче шундый омтылышлардан Кырым хакиме Таштимернең, Алтын Урдадан бәйсезлеген күрсәтергә теләп, үз акчасын суктыруын әйтергә кирәктер. Ләкин шулай да мөстәкыйль Кырым ханлыгының беренче хөкемдары итеп без Хаҗи Гәрәйне атарга тиешбез. Бәйсезлек чорыннан соң (1452—1588) ике йөз елга сузылган Госманлы солтанына бәйле (1588—1774) заманы һәм урыс прореκтораты еллары (1774—1783) булды. Ниһаять, әш 1783 елда урыс дәүләте тарафыннан яулап алу белән тәмамланды.

Нәселләр бәйләнеше Казан һәм Кырым ханлыклары арасында тыгыз мөнәсәбәтләр тууына җирлек бирә — 1445 елда Алтын Урда таркалуыннан соң, Казан ханлыгы да барлыкка килә. Бу мөнәсәбәтләр һәрвакыт тату булмаган — ике дәүләттә дә дөньяга бердәм ислам карашы хөкем сөрсә дә, барыбер аларда аермалык, хәтта бердәнберлек хисе үскән. Казан ханлыгы мөстәкыйль сәяси бердәмлек сыйфатында 107 ел яши: 1552 елның 15 октябрендә аны Явыз Иван яулап ала һәм шул вакыттан ханлык халкына карата рәхимсез сәясәт үткәрелә.

Урыс дәүләтенең яулап алынган илгә карата сәясәте бер максатка юнәлтелгән иде: татарларны халык буларак юк итү. Әлбәттә, бу сәясәтне тикшерү мәкаләбезнең төп нияте түгел, ләкин татар милли үзаңының формалашуында аның роле әдәбиятта әлегә тулы бәяләнмәвен искәртәсе килә. Мәдәният милләт орлыгы үсәр өчен уңдырышлы туфрак булган. Һәм милләт төшенчәсе җәдитчелек хәрәкәте нәтиҗәсендә көчәеп, шул шартларда җәелеп үсеп киткән.

## Татар милли үзаңының барлыкка килүе

Ш. Мәрҗани (1818—1889) — Урта Иделдә җәдитчелекнең атасы, татар милли үзаңының үсүенә гаять зур өлеш керткән шәхес. Беренчеләрдән булып ул үз халкы күз алдына тарихын бастырып куйды, беренчеләрдән булып «татар» этнонимын Идел буе мөселманнарын билгеләр өчен кулланды. Үз халкын татар дип атарга өндәде һәм: «татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай да түгелсең, кытай, урыс, француз һәм немец та түгелсең! Болай булгач, инде кем булырсың?» — диде.

## Тел үсешен кайгырту

Аның замандашы Каюм Насыйри (1825—1902) яңарыш хәрәкәтен баетып, киңәйтеп җибәрде, беренче булып туган теленең сафлыгын кайгырта башлады, аның халык үзаңын үстерүдәге нигез икәнен белеп, татар әдәби теленең Казан шивәсе нигезендә формалашуын яклады. Бу тел гарәп, фарсы һәм госманлы төрек сүзләреннән арынырга һәм халыкка якын булырга тиеш иде. Идел буе шивәсендә Насыйри тарафыннан календарьлар чыгарылды — 1871—1897 елларда алар татарларда вакытлы матбугат урынын алып торды.

Насыйриның татарлыгын бар кеше дә кабул итмәде. Аны иң көчле тәнкыйтьләгәннәрнең берсе Кырым җәдитчелеге атасы Исмәгыйль бәй Гаспралы иде. Ул барлык Русия мөселманнары өчен уртак төрки телне алга сөрде һәм шул телдә 1883—1914 елларда «Тәрҗеман» газетасын чыгарды. Исмәгыйль бәй мәдәни милләтчелекне яклап чыкты, чөнки, ул шуның үсеше генә урыс хөкүмәте һәм мөселманнар арасында булган сәяси каршылык сәбәпләрен юк итә һәм, ахыр

чиктә, хәтта иҗтимагый гармониягә китерә ала, дип уйлый иде. «Мөселманнарны әхлакый урыслашудан бары тик аларның интеллектуаль дәрәҗәсен һәм белемен үстереп кенә, ә моны үз нәүбәтендә татар телен мәктәптә һәм әдәбиятта кулланып кына саклап калырга мөмкин».

Габдерәшит Мәһди Кырым татарларының «милли, иҗтимагый һәм сәяси азатлыгы» өчен көрәшне башлап җибәрде. «Ватан хәдиме» (1906—1909) газетасы тирәсендә тупланган яшь татарлар «милләткә мәхәббәт — иманга мәхәббәт» дип игълан итте, ә «Ватан» җәмгыяте әгъзалары (1909—1917) Гаспралының «төркичелеге» урынына «татарлык»ны куярга омтылды.

Идел буе татарларында татарлык мәсьәләсе йогынтысы 1917 ел революцияләренә кадәрге милли хәрәкәткә дә, аннан соңгы еллардагы мәдәни бердәмлеккә һәм сәяси хезмәттәшлеккә дә җәелә. Совет чорында татарлыкны иң актив һәм күренекле яклаучы Г. Ибраһимов булды, үз фикерләрен ул 1927 елда басылган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барыр?» мәкаләсендә аңлатты. 1911 елда ук «Шура» журналында басылган фикерләрен кабатлап: «Без — татарлар, барлык кылганнарыбыз татарныкы, безнең киләчәктәге мәдәниятебез дә татар»,— диде.

## Мәгариф

Милли әдәби телне таләп итү җәдитчеләрнең мәдәни янарыш хәрәкәтендә иң зур урынны алып тора. Үз нәүбәтендә бу таләпкә ирешү өчен фидакарь рухи хезмәт, иҗади көч һәм гамәли сәләтлек фарыз иде. Сүзлекләр, мәктәп дәреслекләре, җәдитчелек әдәбияты һәм матбугаты милли традиция үсешендә төп чаралар иде. 1890 елларда, мәсәлән, Исмәгыйль бәк Гаспралы, А. Госманов, Миннулла Сабирҗан дәреслекләре генә билгеле булса, беренче бөтендөнья сугышы алдыннан аларның саны сизелерлек дәрәҗәдә артты — моны китап сатучыларның каталоглары һәм газеталарда басылган рецензияләр дә раслый.

Татар зыялылары милли рухта аралашу чараларын тулыландыру өчен җәдиди мәктәп дәреслекләреннән файдаланды. Монда без ике нигез күрәбез: 1. Русия хөкүмәте сәясәте татарларның иҗтимагый берләшүенә бер җай бирми иде; 2. XIX йөз ахырында Идел буе һәм Кырым татарларының белем дәрәҗәсен урысларныкы белән чагыштырсак, ул шактый югары булганлыктан, алар милли мәктәп челтәрен иҗтимагый берләшү чарасы итеп файдаланырга әзерлекләрәк булуы күренә. Кырымда, мәсәлән, 1867 елда татарларда 100 000 кешегә 154 мәктәп туры килә һәм аларда 5081 укучы белем ала иде (901 кыз һәм 4180 ир бала). Кырым татарларындагы һәм урыслардагы мәктәпләр һәм укучылар санын чагыштырып карыйк:

| **татарлар** | **урыслар** |
|---|---|
| 649,3 кешегә 1 мәктәп | 2747 кешегә 1 мәктәп |
| 27,9 кешегә 1 укучы | 66,1 кешегә 1 укучы |

Татарлар, барлык халыкның 17,85% тәшкил итсә дә, укучылар арасында 23% иделәр, урыслар исә Кырым халкыннан 62,5% тәшкил итсә, укучылар арасында бары тик 28,5% кына иде.

1867 һәм 1914 еллар арасында Кырым татарларының санына йогынты ясарлык демографик үзгәрешләр булмады, ләкин мәктәпләрнең саны җәдитчелек хәрәкәте нәтиҗәсендә сизелерлек артты. Идел буе татарларында бу вакытта (Казан губернасын гына алсак) 1088 мәктәп бар иде, шуларның 90% ысулы җәдит мәктәпләре иде.

## Автономия таләпләре

Тел, дин, милли мәдәният һәм сәяси тарих турында хәтирәләр — болар барысы да Идел буе татарлары өчен, шиксез, бик әһәмиятле төшенчәләр иде. XX йөз башында әлеге төшенчәләр Кырым татарларын да кузгатып җибәрде. Аларның милли узаннары 1905 елдан соң чын сәяси төсмер алды, «милләт» төшенчәсе алар өчен иң әүвәл сәяси үзбилгеләнеш иде, аннан соң инде мәдәни һәм мәйданый автономия һәм хәтта тулы бәйсезлекне дә аңлата башлады. 1905—1921 еллар арасында «милләтнең органик карашы» кызыклы бер метаморфоза кичерә һәм милләтнең сәяси концепциясе булып формалаша (моны

Дж. Илли үзаннын нәселдән килгән һәм тарихи характеры дип аңлата). Ул вакытта милли үзаң дәүләт гражданлыгы һәм халыкның суверенлыгы мәсьәләсе белән тыгыз бәйле була.

Русия мөселманнары арасында Идел буе татарларының өстенлеге һәм аларның мәсьәләләр куеп, чишелеш табарга сәләте, әзерлеге — алардан башка мөселманнарны бераз читләштерә һәм бу зур милләт эчендә сәяси мин-минлек («Эго») килеп чыгуына китерә. Монда, әлбәттә, аларның сәяси ихтыяҗлары да чагыла — 1917 елдагы мөселман корылтаендагы милли һәм мәйданый автономия турындагы бәхәс шул хакта сөйли.

1917 елның җәендә Кырым татарларының «Милли фирка»се оешуы милләтчелекнең сәяси үсеш күрсәтә. Аның җимешен, 1917 елның декабрендә Кырым татар дәүләте игълан ителүен үзенә күрә милли хыялның тормышка ашырылуы дип аңлап була. Ләкин бу Чәләби Җиһан житәкчелегендәге бер хөкүмәт, бер парламент, бер конституция белән аякка баскан Кырым татар дәүләте озын гомерле була алмады: 1917 ел кышында гражданннар сугышы нәтиҗәсендә юк ителде. Шул сугышның ахырында Ленин сәяси өлкәдә үзенең гаҗәеп зирәклеген һәм тактик осталыгын күрсәтте, ул милли үзбилгеләнү сәясәтен яклап чыкты, ләкин вәгъдәсен үтәүне хөкүмәте өчен куркынычсызрак заманга калдырды. Игълан ителгән сәясәтне тормышка ашыру Сталин тарафыннан бирелгән милләт төшенчәсенә: «тел, мәйдан, икътисад һәм милли мәдәниятнең үзенчәлекләре уртаклыгында күренә торган психик төзелешкә нигезләнгән, тарихи формалашкан ныклы гомумилек» билгеләмәсенә таяна иде.

1921 елның 18 октябрендә Халык Комиссарлары Советы әмере буенча, РСФСР составында Кырым Автономияле Совет Республикасы төзелүе игълан ителде. Сәяси бәйсезлек максатыннан баш тартып, әмер Кырым «милли дәүләте» оешуын канунлаштырды, юридик яктан Кырым татарларының сәяси барлыгын искәртеп үтте. Ләкин бу республиканың үзәкләштерелгән, федератив дип аталган Совет дәүләте эчендә гамәлгә куелуы күп мәртәбә авыррак бурыч иде. Вәли Ибраһимов җитәкчелегендәге җәдитчеләрнең бер буыны 20 елларда дәрт-дәрманнарын бәйсез милли берлек, мәдәни үсеш һәм чын сәяси автономия өчен көрәшкә сарыф иттеләр. Бу хәрәкәтне без «милли коммунизм» дип атыйбыз.

Идел буе татарлары да шуңа охшаш бер юл белән бардылар. 1917 елның 19 ноябрендә Үзәк Русиянең һәм Себернең Милләт мәҗлесе автономияле Идел-Урал дәүләтен игълан итте. Гражданнар сугышы аның оешуына мөмкинлек бирмәде. Кыска гына вакытка хыял янадан 1918 елның 23 мартында уянып китте: бу көнне большевикларның җитәкчеләре Көньяк Урал һәм Урта Идел җирләрен Татар-Башкорт Совет Республикасы составына кертергә вәгъдә бирде.

Ләкин хыял хыял булып калды. Зур Татар-Башкорт Республикасы (аның мәйданын элекке Казан ханлыгыныкына тиңләп була) большевиклар өчен игътибарга лаек сәяси альтернатива булмады. Моның урынына ике автономия: 1919 елның 23 мартында — Башкортстан, 1920 елның 27 маенда Татарстан республикалары оештырылды.

Бер караганда, чыннан да, Кырым һәм Идел буе татарларының, автономияле милләтләр булып формалашу юлларында ачык ярылып яткан уртаклык күзәтергә мөмкин. Ләкин мәсьәләне тәгәлрәк, эзлеклерәк өйрәнү аларның сәяси үзаңнары формалашуында сизелерлек аермаларны ача. Идел буе татарлары этник кысаны сәяси барлыкларында төп нигез итеп кабул итте һәм мәйдан мәсьәләсен аңа буйсындырды. Идел-Урал дәүләте мәйданы Идел буе татарларының милләт булып оешкан тарихи җирлеге булса да, төзеләчәк дәүләттә алар бердәнбәр милләт була алмас иде. Аңлашыладыр ки, Идел буе татарлары үзләрен Казан ханлыгы варислары итеп таный иде һәм шуңа күрә аларга милләт төшенчәсенең этник һәм мәйданый нигезләрен бер-берсенә тиң өлешләр итеп карау беренче авырлык китерми иде. Билгеле бер дәрәҗәдә мондый карашлар егерменче елларда да яшәвен дәвам итә — милли рухлы коммунистлар, беренчә дулкын булып, икътисади һәм мәдәни, иҗтимагый-сәяси өметләрен гамәлгә ашырырга күтәрелде. Уртак максатлары — татарлаштыру иде.

Татар милли рухлы коммунистларының тар этник максатларыннан аермалы рәвештә, М. Солтангалиевнең Туран республикасы проектын мин гомум төрки рухлы дип атар идем. Ләкин, күрәсең, монда да Солтангалиев туранчылыкны татарчылык файдасына корбан итәргә әзер, чөнки ул татарларда Көнчыгыштагы революция җитәкчеләрен күрә иде. «Татарларның эшче массалары һәм фәкыйрьләре революциядә катнашмадылар, шулай да Шәрыкъ илләрендә аны пропагандалауга бик зур өлеш керттеләр».

Егерменче елларда татарларның милли максатларына фәнни нигез биргән оешма Татарны гыйльми өйрәнү җәмгыяте була. Бу җәмгыятьнең 1925—1930 елларда чыккан журналы («Вестник ВНОТ») битләрендә Идел буе татарлары турында гына түгел, ә бәлки Кырым, Литва, Себер татарлары мәдәнияте турында да мәкаләләр басыла. Шундый активлык аркасында Идел буе татарлары янадан барлык татарларның матди һәм рухи мәдәниятен саклауда һәм коткарып калуда төп рольне уйный башлый.

## Кырым татарларын ватаннарыннан сөрү

1920—1928 елларда Кырым татарлары да, Идел буе татарлары шикелле үк, гаҗәеп зур фаҗига кичерде, бу вакытта автономияне алар һәм хөкүмәт тарафыннан аңлауда аерма ачык сизелде. Егерменче еллар ахыры — Кырым һәм Идел буе татар коммунистлары хыялларының рәхимсез җимерелү чоры, хәтта мәдәни автномия турындагы өметләр дә сүндерелә. Җитмәсә, егерменче еллар ахырында хыяллар гына түгел, шуларны тормышка ашырырга омтылучылар да кинәт кенә юкка чыгарыла. М. Солтангалиев, В. Ибраһимов кебекләр үз милли идеалларын һәм планнарын шул чаклы киңәйтеп җибәрәләр, аларның эшчәнлеге, әлбәттә, Мәскәүнең үзәкләштерү максатларына һич тә туры килә алмый. Шуңа күрә алар башта партиядән куылдылар, соңра физик юк ителделәр. Сәяси тапкырлыгы һәм кыюлыгы өчен ике республиканың зыялылары «чистартылды» һәм нәкъ икенче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан Идел буе һәм Кырым татарлары шул эзәрлекләүләр аркасында яңадан шок хәлендә кала.

Сугыш ике милләтнең параллель үсешен тамырдан үзгәртеп җибәрде. Ул Кырым татарларыннан Ватаннарын тартып алды һәм аларның милләт буларак танылуын юк итте. 300 меңлек халыктан бары тик 20—30 меңе немец ягыннан «саклану» отрядларында көрәшсә дә, татарларның барысын да «массакүләм хыянәттә» гаепләделәр. 1944 елның 18 май төнендә эчке эшләр министрының беренче урынбасары Иван Серов җитәкчелегендәге милиция отрядлары, яшен тизлегендә операция уздырып, татарларны Кырымнан кудылар. Шушы операцияне уздыруда Серовның гаҗәеп зур ролен танып, аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде һәм ул Ленин ордены белән бүләкләнде. Кырым татарлары барысы да сөрелде — балаларны да, картларны да җәлләмәделәр. Тиздән сөргендәгеләрне режимга тугры хезмәт иткән солдатлар да куып җитте (мәсәлән, бишенче партизаннар бригадасыннан комиссарлар Әхмәтов һәм Исаев). 1945 елның 30 июнендә исә Кырым республикасының бетерелүе турында указга кул куелды. Кырым РСФСРның гади бер өлкәсенә әверелде, ә 1954 елның 19 февралендә, СССР Югары Советы Президиумы карары буенча, ул Украина Союздаш Республикасына тапшырылды.

Халыкны ватаныннан сөрүдән соң хөкүмәтнең барлык тырышлыгы ярымутрауда татар мәдәнияте һәм тарихы эзләрен тулысынча бетерүгә юнәлтелгән иде. Архитектура һәйкәлләре җимерелде, Кырым татар телендә язылган яки басылган барлык китаплар (хәтта, марксистик әдәбият) яндырылды, авыл һәм шәһәр исемнәре үзгәртелде һәм славянлаштырылды.

Бүген Кырым татар милләте турында сүз йөртеп буламы? Хаас сүзләрен искә алсак, без кырым татарларын бүген дә икеләнмичә милләт дип санарга хаклыбыз. Ләкин галимнең аңлатмасы хәзер үзенә күрә мөһим генә бер үзгәртүгә мохтаҗдыр: бүген кырым татарлары бәйсез дәүләт төзү максатын куймый, бары тик тарихи ватаннарына кире кайту өчен генә көрәшә. Ватан өчен көрәш, милләт булып сакланып калу өчен көрәш алар хәрәкәтенең төп эчтәлеген тәшкил итә. Ул көрәш сәяси активлык һәм мәдәни үзаң байраклары астында алып барыла.

Сәяси активлык 1963 елда башланып китә: бу елда Кырым татарлары Мәскәүгә вәкилләр җибәреп, аклауны таләп итә. Активлык 1967 елның 9 сентябрь указыннан соң тагын да артып китә, чөнки бу фәрман татарларны өлешчә генә аклый. Шуннан соң кире кайту өчен петицияләр ташкыны җәелеп китә. Татар хәрәкәтенең яңа баскычы протест йөзеннән Муса Мамут һәм Иззәт Мәмәдалиев үз-үзләрен яндыргач, чын мәгънәсендә диссидентлык көрәшенә әверелә. Шул ук вакытта үҗәт Мостафа Җәмилевнең «татар милләтендәге ватандар, элекке Кырымда яшәүче» статусына (татарларга 1967 ел указы буенча бирелә) карышуы башлана. Җәмилев, кырым татары буларак, Кырымда яшәү хокукы өчен көрәшә. Кырым татарлары көрәшендәге бу сәхифәләр киң билгеле, тик алар тагын да тирәнтен өйрәнүгә мохтаҗ.

Сәяси активлыктан зәгыйфьрәк булса да, мәдәни үзаң кырым татарларында тирән тамыр җәйгән һәм ул аларны милләт буларак саклап калуда зур урын тота. Аның төп хезмәте — милли үзаңның иң мөһим чараларын — тел, әдәбият, музыка, милли мәдәният һәм традицияләрне үлемнән коткару һәм сөргендә туган яңа буыннарга тапшыру.

## Милли үзаңның көчәюе: татар әдәбияты һәм матбугаты

«Безнең хәзерге әдәби телебез — ул «Ленин байрагы» газетасының теле, әдәби әсәрләр теле, радиотапшырулар теле һәм, ниһаять, «Кайтарма» ансамбле теле. Шуңа без бүген «Йолдыз» журналының телен дә өстәп куя алабыз»,— дип язды 1986 елда кырым татар әдәби тәнкыйтьчесе һәм язучысы Алим Фәтисламов «Йолдыз» журналында.

Чыннан да, китерелгән цитата мәдәни аклануның аерым баскычларын күрсәтә, болар исә 70—80 еллар милли үзаңын мөмкин иттеләр. Өметнең беренче нурлары сөрүдән соң ун еллар үткәч кабынды. Ул чакта әле, 1954 ел карары буенча, һәрбер Кырым татары,— картмы ул, яшьме — 14 көн саен милициягә килеп билгеләнергә тиеш иде. 1956 елда Ташкент радиосы татар телендә тапшыруларын башлап җибәрде. 1957 елда ике зур вакыйганы атап була: Үзбәгестанда яшәүче кырым татарларына «Ленин байрагы» исемендәге газета бастырырга рөхсәт бирелде; шул ук елны «Кайтарма» ансамбле дә оештырылды. Озын гына өзеклектән соң, 1980 елда, «Йолдыз» әдәби журналының беренче саны чыкты.

## «Ленин байрагы» — кырым татар телен саклауда таяныч

«Ленин байрагы» гәзитендә атна саен диярлек «Лөгать» башы астында ике телдә, урысча-татарча сүзлек рәвешендә материаллар бирелә. «Лөгать» — сөргендә туган һәм үскән буынны «татарлаштыру» өчен иң мөһим чарадыр. 1985 елның февралендә редакция бу сүзлекне туктатырга ниятләгәндә, меңләгән хатларда укучылар аны дәвам иттерүне таләп итте.

Айга бер тапкыр «Лөгать» балалар өчен «Йолдызчык» исемле бер бит бастыра. Шушы бер бит балалар журналы вазифасын да үти. Төрле-төрле табышмаклар, кыска шигырьләр һәм хикәяләр кырым татар балаларын ана телендә укырга һәм язарга өйрәтә. «Йолдызчык» материалларының авторлары — күп очракларда төрле әдәби түгәрәкләргә йөрүче балалар үзләре.

Гәзит битләрендә Үзбәгестанда кырым татар телен укыту мәсьәләләре һәм, гомумән, тел белән кызыксыну мәсьәләсе җентекләп яктыртыла. Укытучыларның бар тырышлыгы мәктәп дәресләре белән генә чикләнмичә, укучыларның тел белемен камилләштерүгә юнәлгән. Шундый укытучылар арасында, мәсәлән, Алимә Батталова һәм Завидә Гафарова, икесе дә Низами исемендәге Ташкент педагогия институтының кырым татар филологиясе бүлеген тәмамлаган.

Гәзиттә фәнни мәкаләләр дә бастырыла, укучылар кырым татар телен өйрәнүгә караган мөһим бәхәсләр белән таныша. Аларда шушы юнәлештә булган казанышлар күрсәтелә: «Ана теле» дәреслеге 1968—1983 еллар арасында өч тапкыр басыла; 3—4 класслар өчен туган тел укыту планы төзелә; «Кайда берлек — шунда терелек» дип исемләнгән мәкальләр һәм әйтемнәр җыентыгы һ. б. басыла.

1986 елның сентябрендә «Ленин байрагы» Ташкентта уздырылган алтайчыларның фәнни конференциясе турында язды. Шуның материалларыннан XIV гасыр чыганагы «Кодекс куманикус»ны Кырым татар теленең беренче сүзлеге итеп тикшергән Б. Гафаровның чыгышы бигрәк тә зур кызыксыну уятты.

А. Фәтисламов урта гасыр Кырым документларыннан алып Җанмөхәммәднең «Дастан-и Тугайбәк»енә кадәр (XVII г.) Кырым татар язма теленең тарихын өйрәнде. Бу өлкәдә бигрәк тә зур казанышлар дип ул «Тәрҗеман» газетасы мәкаләләрен, А. Мәһди турындагы «Ватан хадиме» төркеме басмаларын таный, һәм әлеге материалларны Кырым татар әдәби теленең нигезе булып торырга тиешлеген күрсәтә.

Биредә шулай ук Кырым татар телен ачыктан-ачык пропагандалаган мәкаләләрне генә түгел, ә бәлки укучыларга татар тарихы турында объектив мәгълүматлар бирергә, Кырым татарларының милли билгеләрен аңлатырга һәм

шушы юл белән үткәнне акларга омтылган мәкаләләрне дә искә алырга кирәк. Шундыйлардан, мәсәлән, А. Мәһди һәм «Ватан хадиме» төркеменә кергән бүтән татар яшьләре «татарчылар» дип атала. Әйткәнебезчә, алар өчен изге төшенчәләр — «милләткә мәхәббәт — иманга мәхәббәт» аңлатыла.

А. Фәтисламовның фикерләрен башкалар да яклый: мәсәлән, А. Мәслих мәкаләсенең исеме «Телгә хөрмәт — илгә хөрмәт» «Ватан хадиме» төркеме чакыруын бик нык хәтерләтә.

Шулай итеп, 80 елларда элек үтерелгән милләтчеләрне, рәсми рәвештә рөхсәт булмаса да, кыю гына аклау бара дип әйтеп була.

Әдәби тәнкыйтьчеләрнең һәм әдәбият тарихчыларының хезмәтләрен дә искә алырга кирәктер. Хәзерге Кырым татар әдәбиятын анализлаган вакытта Б. Гафаров аны теләнең фәкыйрьлеге һәм примитивлыгы өчен тәнкыйтьләп, 1930 елга кадәр язылган мираска игътибар итәргә өнди. Ул, мәсәлән, «Милли фирка»ның элекке житәкчесе Осман Акчукраклы һәм милләтче А. Одабаш тарафыннан язылган әдәби әсәрләрне һәм мәкаләләрне искәртеп үтә, ләкин аларның сәяси эшчәнлекләрен телгә алмый. Мәкаләдә, димәк, 1936 елда Кырым татар АССРның педагогия институтында уздырылган чистартулардан соң тыелган исемнәр яңадан искә алынды.

Сөрелү һәм фажигале рәвештә тамырлардан өзелү, һичшиксез, кырым татар традицияләренең үсешен кинәт кенә туктатып куйды, шуңа күрә Гафаров һәм башкаларның тырышлыкларына без югары бәя бирергә тиешбез. Кырым татар язучылары бүгенге көндә милли үзаңны уятуда бурычларын һәм вазифаларын бик яхшы аңлый. Мәсәлән, Черкез Алинең «Али ага, ни өчен шигырьләр язмыйсың?» дип аталган шигыреннән юллар моны ачык күрсәтә:

Айлар кичте, еллар кичте, арыдым,
Укучылар булды дустым, сердәшем.
Зар булсам да, кабат эшкә керештем,
Онытмасын, дилем, халкым туфрагын.

«Ленин байрагы» һәм «Йолдыз» битләрендә әдәбият тоткан урынның әһәмиятын бары тик фольклорыбыз һәм борынгы традицияләребез, гореф-гадәтләребез әһәмияте белән генә чагыштырып буладыр. Ассимиляциянең билгесе, кырым татар үзаңына һәм мәдәниятенә зыян китерә алырлык һәр нәрсә каттый рәвештә тәнкыйтьләнә, укучыларга төрле шатлыклы тантаналар вакытында милли жырларыбызны жырларга тәкъдим ителә.

## Үзгәртеп кору заманында татар мәнфәгатьләре

«Ленин байрагы» да, «Йолдыз» да кырым татарларын Ватанына кайтаруны таләп иткән беренчеләр петицияләр яки ачык хатлар бастырмый. Ләкин бу максатка ирешер өчен хәрәкәт һичбер сәгатькә дә туктап тормый. Сөрелүнең гаделсезлеге күп санлы мәкаләләрдә, турыдан-туры булмаса да, һәрчак искә алына. Мондый мәкаләләр, мәсәлән, «Ленин байрагы»нда «Жизарәт» («Батырлык») рубрикасында басыла, алар барысы да Кырымны, Совет Ватанын яклаган геройларга багышлана. Ул геройлар истә, бигрәк тә, милләттәшләре хәтерендә — мәкаләләрдән шундый нәтижәгә килеп була.

Ләкин хәбәрдарлык һәм үзгәртеп кору дәвере дә Кырым татар тормышын кискен үзгәртеп жибәргән фажигале 1944 ел фәрманын гамәлдән чыгарырга тиз генә форсат бирми. КПССның милли мәсьәләләргә багышланган карарлары да, журнал-газетләрдә басылган мәкаләләр дә шул хакта сөйли. Мәсәлән, «Наука и религия» журналында басылган бер мәкаләдә кырымнан татарларның куылуы бары тик үч хисе белән генә искә алына. Ул Евпаториядә элекке мәчет бинасында урнашкан жирле музей эшчәнлегенә багышланган. Музей фондларында саклана торган борынгы грек, рим, башка культураларның калдыклары, дин һәм атеизм тарихына караган материаллар турында язылса да, кырым татарлары һәм аларның мәдәнияте бөтенләй төшеп калган. 1987—1988 елларда меңләгән Кырым татарларына ватанына кайтырга бирелгән рөхсәт милләткә тулаем кагылмады һәм Кырым автономиясен яңадан тергезүгә китермәде.

Шундый авыр хәлгә карамастан, кырым татарларының үз мирасы, ана теле белән бәйләнеше тулысынча өзелмәгән, болар барысы да аларның мәдәни үзаңнары үсешендә чагыла һәм кырым татарларын, Ватансыз булсалар да, милләт итеп исәпләргә мөмкинлек бирә.

Аларның Ватан өчен көрәшен демократик көчләр, шул исәптән, Идел буе татарлары һәм башкалар да яклый. Беренче тапкыр мондый яклау 1977 елның апрелендә Самиздат документларының берсендә: «Без Кырым татарларының көрәшләрен хуплыйбыз, шулай да безнең ахыргы максатыбыз — барлык төрки халыкларның берләшүе»,— рәвешендә гамәлгә ашты.

## Идел буе татарлары: миллəтнең тарихи узганы һәм хәзерге заманы

Идел буе татарларын да ана теленең хәле һәм үсеше борчый. Татар теле өчен көрәш Татарстанда гына түгел, күрше Башкорстанда да бара. Монда татарларның саны гомум халык санынннан 24,5% тәшкил итә (чынлыкта күбрәк — *редакция искәрмәсе*) һәм алар башкортлардан да күбрәк булып тора, ләкин театрлары да, Язучылар берлегендә татар бүлекчәсе дә юк. Бу мәсьәләләргә игътибар иткән Самиздат материалларына караганда, башкортларның зур өлеше ана теле дип татар телен таный, бу хәлне тагын да катлауландыра.

Самиздат документы буенча, Идел буе татарларының милли үзаңы миллəтнең шундый төшенчәсенә нигезләнә: аның мәйданы хәзерге Татарстан белән генә чикләнми, ә бәлки элекке Казан ханлыгы җирләренә туры килә. Соңгы ике унъеллыкта Идел буе татарларының барлык омтылышы яңадан тарихи Ватаннары чигендә аякка басуга юнәлтелгән иде. Шул ук вакытта алар мәдәниятләрен кабат җанландыруга да күп тырышлык куя.

«Казан утлары» журналы «Мәдәниятебез тарихы» башы астында басылган мәкаләләрдә әкренләп булса да борынгы мәдәни байлыгын барларга омтыла. Ул мәкаләләрне эчтәлекләре буенча ике төркемгә бүлеп була:

1. Татарларның төрле этник төркемнәренә яки диаспорасына багышланган материаллар.
2. Милләтчелектә гаепләнгән һәм 20—30 елларда юк ителгән зыялыларын аклау.

**Беренчесе.** «Казан утлары»нда Әстерхан һәм Себер татарлары турында мәкаләләр басылды, шулай ук XIX гасырдан казакълар арасында яшәүче татар төркеме турындагы мәкаләне искә алырга кирәк. Тел ягыннан изоляциядә булса да, бу төркем бабалары Бөгелмә һәм Бәләбәй якларыннан алып килгән матди һәм рухи мәдәниятен саклап калган.

«Казан утлары»ның татар диаспорасы белән кызыксынуын ике сәбәп белән аңлатып була: беренчедән, Идел буе татарлары, күрәсең, үз милләтләрен республика чикләрендә генә яшәүчеләр дип аңламый, Казан ханлыгында яшәгән халыкның варисы саный; икенчедән, республикада яшәүче татарлар барлык татар милләтен саклап калуда житәкче роль уйный, шуңа күрә дә алар диаспора татарларын этнография, тел һәм фольклор ягыннан активрак өйрәнергә тырышалар.

**Икенчесе.** Күренекле татар галимнәре Я. Абдуллин, М. Госманов һәм И. Таһиров тарафыннан тууына 110 ел тулуга багышлап язылган мәкаләдә 1938 елда репрессияләнгән зур татар зыялысы Һади Атласи фактик рәвештә аклана. Һади Атласи — Әлмәттә имам, либераль «Йолдыз» гәзитендә еш кына мәкаләләрен бастырган журналист. Икенче Дәүләт Думасы депутаты, танылган тарихчы — «Себер тарихы» (1912), «Сөембикә» (1912), «Казан ханлыгы» (1913) китаплары авторы. Революциядән соң ул Бөгелмәдә — тарих һәм немец теле, Казанда немец теле укыткан.

Мәкалә авторлары Атласи эшчәнлеге турында В. Бартольд тарафыннан әйткән сүзләрне хуплыйлар һәм шундый нәтиҗәгә киләләр: Бартольд Атласины «татар патриоты» дип атаса да, ул Мәскәү — Казан арасында XV—XVI йөзләрдә булган мөнәсәбәтләрне объектив тасвирлаган. Авторлар: «архив материаллары күрсәтүенчә («Казан утлары», 1986, № 11, 172—176 б.), Атласи чын мәгънәдә зыялы булган»,— дип яза.

Идел буе татарлары тарихында тагын бер бик әһәмиятле дәвер бар — ул Казан ханлыгы алды чоры, милли үзаңның формалашуында бик зур урын тоткан Болгар заманы. Бу дәвер татарларның бай мәдәниятен барлыкка китерүдә аерым бер урын алып тора, чөнки шуның белән аларның тарихта кабатланмас һәм игътибарга лаек роль уйнауларын исбатлап була. Шушы мирас тел, археология, тарих, фольклор, әдәбият мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрдә чагыла, тарихи романнар һәм драмаларда гәүдәләнә.

1985 елның маеннан «Казан утлары»нда «Татарстан — туган төбәгем» исеме астында мәкаләләр бирелә башлады. Кереш сүздә аларның максаты турында ачык әйтелгән: «Ватанга мәхәббәт — туган төбәккә мәхәббәттән башлана»... (№ 5, 9 б.)

Шушы баш астында басылган мәкаләләрнең авторлары — Компартиянең район комитетлары секретарьлары. Бу мәкаләләр асылда 1917 елдан соң төрле төбәкләр ирешкән уңышлар турында гына сөйләсә дә, аларның һәрберсендә төрле күләмдә тарихи кереш бар. Мәсәлән, Әлки районын яктырткан Н. Бакиров Болгар чоры турында мәгълүматлар бирә, башка мәкаләләрдә XIX йөз тарихы турында сүз барганда Буби мәдрәсәсе һәм Каюм Насыйри искә алына.

Узганнарны дөрес аңлау, аңа күбрәк игътибар бирү, узган гасырлар традицияләреннән кайберләрен бүгенге көндә файдалану — Идел буе һәм Кырым татарларының милләт буларак сакланып калуы өчен әһәмиятле.

Драматург Туфан Миңнуллин, 1986 елның язында Язучылар берлеге съездында чыгыш ясап, тарихи романнарны тәнкыйтьләүчеләргә җавап итеп, милли сыйфатлар һәм совет системасында алар уйнаган роль турында үзенең бик тә кыю аңлатмасын бирде — һәрбер милләт һәм аның милли характеры бердәнбер икәнлеген ул бик ачык искәртеп узды: «Гомумән кешеләр турында язу мөмкин түгелдер. Һәрбер кешенең, совет кешесенең туган төбәге һәм торган урыны бар. Шул урынны ул үзенең Ватаны дип атый. Ватан белән аның бәйләнешләре тарих, икътисад, экология, психология өлкәләрендә ята. Ватан кешедә бернинди хис тә уятмаса, ул очракта андый кеше дуңгызлыкка әверелә».

Кырым һәм Идел буе татарлары ватаннары һәм мәдәниятләре белән төрле бәйләнештә тора, шиксез ки, икесе ике аерым милләт тәшкил итә, бер үк вакытта алар икесе дә зур төрки дөньяның өлешләре булып кала.

# ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ БЕР ЧИРЕ

*Бүгенге көндә*
*элекке СССР халыклары кичерә торган*
*гомум кризисның ничек барлыкка килүе белән*
*бик күпләр кызыксына.*
*Ни булган?*
*Нинди сәбәпләр аркасында*
*бүген без шундый хәлгә төшкәнбез?*
*Алда безне ни көтә?*
*Мондый сорауларны*
*җәмгыятьне өйрәнүчеләрдән генә түгел,*
*бәлки кибеттәге чиратларда,*
*шәһәр транспортында һәм башка җирләрдә дә*
*еш ишетәбез.*

Яхшы хәл дип әйтик моны, чөнки андый сораулар туганда җәмгыять әкренләп сәламәтләнә-тазара, кешеләр, аңнары уянып, тоталитаризм идеологиясеннән арына, һәркем үзенең кемлеген, үзенә бер шәхес икәнлеген тоя-төшенә башлый.

Өстән боерык-карарлар килми башлаган яңа шартларда үткән тормышыбызны анализлаганда да фикер төрлелеге ныграк урнаша, кешелек тарихын яңача аңлау, чын дөресенчә төшенү процессы көчәя бара.

Мин: коммунистлар партиясе илгә хуҗа булган көннән башлап халык мәнфәгатьләренә каршы сәясәт үткәреп килде, дип саныйм. Бу сәясәтнең максаты — коммунистик номенклатураның сәяси хакимлеген һәм икътисади куәтен тәэмин итүче тоталитар режимны ныгыту иде. Коммунистлар ил башында торган заманның иң авыр, иң фаҗигале нәтиҗәсе шул булды — масса төсен алган маргинал кешеләр барлыкка килде, җәмгыять тулаем маргиналлаштырылды.

**«Маргиналлык» дигән социологик төшенчә кешенең берәр төрле социаль төркемнәр арасында калуын белгертә. Бусына да, тегесенә дә кушылмаган хәлдә ике арада калу кешенең хис-тойгы халәтенә тискәре йогынты ясый, үзен билгеле бер социаль төркемнең вәкиле итеп тою хисеннән мәхрүм итә, һәм нәтиҗәдә кеше үзенең социаль йөзен табу мөмкинлеген югалта.**

Элеккеге СССРда кешеләрне масса күләмендә маргиналлаштыруның төп сәбәбе коммунистлар партиясе тормышка үткәргән социаль сәясәткә барып тоташа. Бу сәясәтнең нигезендә җәмгыятьне социаль үзәкләштерү моделе, ягъни барлык кешеләрне дә бер төсле итү принцибы ята. Шушы модель-үрнәк буенча совет кешесе бер генә төстәге коммунистик җәмгыятьне төзүчегә кирәкле сыйфатларны туплаган бер кисәкчә-атом булырга тиеш. Тормышка керткән социальләштерү механизмы ярдәмендә, кешегә коммунистик системаның төп-төгәл бер шөребе булырга комачаулардай бөтен нәрсәне аңа якын җибәрмәскә тырыштылар.

Хәлбуки, кешенең социаль һәм шәхси яктан җитешүе өчен аның тәрбияләнүендә социальләшү һәм индивидуальләшү процессларының табигый ярашулары зарур. Безнең тоталитар дәүләттә индивидуальлек җәмгыятьнең үсешендә начар бер шаукым сыман итеп каралды. Кешенең шәхес буларак үзенә генә хас яхшы сыйфатларын күреп, шуларны үстерү кирәклеге тәрбия эшендә исәпкә алынмады.

**Шәхесне алга чыгара торган индивидуальлек мәсьәләсен инкяр итү нәтиҗәсендә аның теләк-ихтыяҗларына ярашлы, әмма каты тоталитар калыпларга сыешмый торган эш-фигыленә, баглануларына да юл куелмады. Актив социаль сәясәт дәрәҗәсенә җиткерелгән мондый мөнәсәбәт чынлыкта кешеләрнең тормыш-көнкүрешләрендә табигый рәвештә урнашкан социумнарны вату-җимерү дигән сүз иде. Җәмгыятьнең эчке кысасын әнә шулай таркалу нәтиҗәсендә анда тәртипсез-буталчык бер хәрәкәт башланды, кешеләр социаль җайсызлык, психологик тынычсызлык-кисезлек кичереп яши торган булдылар.**

**Шактый катлаулы бу таркату процессын мин җәмгыятьне маргиналлаштыру дип атыйм.** Тормышыбызда ул кинәт кенә пәйда булмады, бәлки әкренләп

барлыкка килде. Артык гадиләштереп күз алдына китерсәк, аны винегрет әзерләү белән чагыштырырга мөмкин булыр иде: ягъни башта кабыгын кыралар, ваклап турыйлар, аннары инде бергә кушып болгаталар. Әзер винегретта кайсы кисәге чөгендер, кайсысы бәрәңге икәнен дә аеруы кыен, чөнки соңгысына да чөгендер төсе ингән. Менә шушы гади генә чагыштыру мисалындагы кебек, җәмгыятьтәге маргиналлаштыру да ике чор уза.

Ил башында Сталин утырган беренче чорда миллионлаган кешене юк итү, имгәтү-гарипләтү эше башкарылды. Болар, башлыча, җәмгыятьне гадиләштерү процессына каршы булган яки каршы булырга тиеш дип саналган зыялыларның күренекле вәкилләрен җыеп төрмәгә тыгу, эшчән-тырыш крестьяннарны яшәгән җирләреннән читкә сөрү. Билгеле бер дәрәҗәдә шушы чорның нәтиҗәсе итеп Ватан сугышында һәлак булган исәпсез-хисапсыз корбаннарны да санарга мөмкин.

**Шулай итеп, беренче чорда ук инде җәмгыятебез, аның структурасы шактый дәрәҗәдә җимерелә.** Шулай да әле ул маргиналлаштырылган җәмгыять булмый. Әйтик, тоталитаризм машинасы тәрәне астына эләкмәгән крестьяннар җир кешесе булып калалар, крестьян психологиясенә хас булганча, намус белән иген игәләр, табигать белән сак эш итәләр. Яки, этник яктан килеп карасак, мәсәлән, татарлар үз телләрендә сөйләшеп, ата-бабаларының гореф-гадәтләрен саклап, татар булып кала бирәләр. Бу чорда мөселманлык тойгысы да көчле була.

**Җәмгыятебезне маргиналлаштыруның икенче чоры Сталин үлеп, аның явызлыкларын фаш итү, исән калган «халык дошманнары»н ирекккә чыгару һәм XX съездның демократик лозунгларыннан соң башланды.** Беренче карашка, моны гуманлашу чоры дип тә атарга мөмкин. Ләкин бу яңалыклар, кешеләргә билгеле бер уй-фикер иреге бирсәләр дә, зур социаль үзгәрешләрнең шәүләсе генә булып калдылар. Тоталитар дәүләт шәхесне авызлыклауның ысулларын гына үзгәртте, элеккеге каты чараларны сирәк куллана башлады. Чөнки беренче чорда җәмгыятебездә шәхесне бетерү эшендә тиешле эффектка ирешелгән иде инде, кешеләр масса күләмендә эчтән ирекне кысып-тыеп тора торган курку хисе кичереп яшиләр иде. Хәзер инде җәмгыятьнең бер чамага, бер төрлегә әйләндерелгән кисәкчәләрен үзара керештерү буенча күзгә артык бәрелми торган яшертенрәк эш башланды. Бу — шәхеснең үзенчәлекле сыйфатларын, йөз еллар дәвамында табигый рәвештә барлыкка килгән социаль хасиятләрне әкренләп бетерүнең стратегик юнәлеше иде, тик моны тормышка ашыруның тактикасы гына алмашынды.

Җәмгыятебезне маргиналлаштыру дигән катлаулы процессны төрле ноктадан: сыйнфый, этник, дини-әхлакый, хәтта женси яктан да килеп карарга мөмкин. Хатын-кызның табигатьтән бирелгән ана булу сыйфатын икенче планга чигерү, аның дәүләт эшендә эшләвен беренче урынга куюю кешенең женес буларак үзлеген инкарь итү дигән сүз бит ул. Ил өчен бу сәясәтнең социаль нәтиҗәләре яхшы булмады.

Сүзебез күп милләтле тоталитар дәүләтнең милли төбәкләре турында барганлыктан, бу мәсьәләне этник ноктадан карап ачыклау кулайрак булыр. Татарларны этнос буларак маргиналлаштыру 40—70 нче елларда, империячел-коммунистик амбиция күзлегеннән караганда, шактый уңышлы тормышка ашырылды. Шушы сәясәт нәтиҗәсендә татарларның үзләрен аерым милләт буларак хис итүе югала башлады. Милли аң-тойгыны бетерү эше төрле юнәлештә астыртын рәвештә башкарылды.

**Шундый чараларның ачык бер мисалы — планлы рәвештә чакырып икенче җиргә күчерү сәясәте.** Күченеп киткән татарлар икенче бер халык арасына барып урнаша һәм аларга татар булып яшәү мөмкинлеге бөтенләй булмый дип әйтерлек иде. Планлы рәвештә чит җирләргә күчерү сәясәте үзе бер зур тема, аның колачын, демографик нәтиҗәләрен күз алдына китерү өчен махсус өйрәнү-тикшерену кирәк.

Шулай да, фәнни әдәбиятта булган бик аз мәгълүматлардан чыгып та, республикабыз халкын башка төбәкләргә күчерү буенча Мәскәүнең шактый эш башкарганлыгын күрергә мөмкин. Мәсәлән, 1949 елның апрель аенда Татарстан өлкә комитеты бюросы татарларны үз ирекләре белән Карелфин ССРга күчерү эшенең торышын тикшерә (800 гаиләне күчерү күздә тотыла). 1952 елда ТАССР Министрлар Советы каршындагы күченү бүлеге Байкал аръягына һәм Архангельск өлкәсенә биш меңнән артык кешене озата[1].

Бер караганда, кешеләр яңа җиргә үз теләкләре белән китәләр кебек. Әмма мондый теләкнең сәбәбен төшенүе кыен түгел. Сугыштан соңгы бик авыр елларда Сталинның крестьянны талау сәясәте корбаны булган авыл халкы яңа җирдә яхшы тормыш вәгъдә итүләренә бик тиз алдана. Башлыча авылдан яшьләр китә.

Яңа җирдә, гадәттәгечә, татар егетләре авыр шахта хезмәтендә эшлиләр, тору өчен бернинди уңай шартлары булмаган кысан баракларда яшиләр. Һәм аларга милли рухларын саклау өчен бернинди мөмкинлек тә юк. Хикмәт башка бер этник мохиткә килеп эләккән татарларның милли тойгылары үз-үзеннән юкка чыгуында түгел, киресенчә, алар милли рухларын, гореф-гадәтләрен сакларга тырышалар. Яңа җирдә яңа тормыш башлаганда татарлар, кичләрен бергә җыелып, үзләренең җырларын җырлыйлар, уеннарын уйныйлар, милли ансамбльләрен, үзешчән театрларын оештыралар. Әмма аларның мондый үзешчәнлекләре әкренләп бетә, юкка чыга. Мәсәлән, илленче елларда Кемерово өлкәсенең Прокопьевск шәһәрендә татар җыр һәм бию ансамбле төзелә, ә Маяковский исемендәге культура сарае каршында «Агыйдел» дигән татар-башкорт ансамбле оешып, шуңа алтмыштан артык егет һәм кызлар катнаша. Алар әйбәт кенә репертуар төзиләр, концертлар куя башлыйлар[2]. Ләкин аларның бу иҗат үзешчәнлеге үсеп китә алмый, җирле хакимиятнең каршылыгына очрый. Шундагы бер мәдәният чиновнигы: «Милли җырларыгызны җырлыйсыгыз-тыңлыйсыгыз килсә, Казанга барыгыз»,— ди.

Билгеле инде, баштарак татарлар, бу хәлдән зарланып, югары оешмаларга хатлар язалар, милли рухларын саклау өчен ярдәм итүләрен сорыйлар. Ләкин аларның үтенечәнә бернинди җавап бирмиләр. Мондый хәлнең сәбәбен социализм төзү эшенә баштанаяк чумган түрәләрнең милли азчылыкларның үзенчәлекләрен саклау мәсьәләләренә игътибар итәргә вакытлары булмаган дип кенә аңлатырга мөмкинме? Әлбәттә, алай түгел. Бернинди дә җавап бирмәү, игътибар итмәү милли үзенчәлекләрне бетереп, аларны бертөсле бер бөтенгә әйләндерү сәясәтенең рәсми чагылышы ул.

Хакимиятнең милли бизәкләрнең ачылуын теләмәве әнә шул сәясәттән килә. Чит-ят җирдә яшәүче татарларга милли җан азыгы бирергә тырышып йөрүче аерым энтузиастларны эзәрлекләү дә әнә шуннан. Татарның мәдәниятен, телен саклау буенча кылган күп төрле үзешчәнлектән тыш, бу энтузиастлар, Татарстаннан читкә чыгып, татар газите һәм журналларын тараталар. Әмма татар патриотларын дәүләт учреждениеләрендә тикшереп, КГБ тарафыннан искәрттереп һәм куркытып, «үз урыннарына утырталар».

Шуңа күрә тырыш хезмәтләре белән илгә даннары чыккан татар шахтерларының әллә нигә бер радиодан татар җырлары ишеткәч, күңелләре тулып җылаулары бер дә очраклы хәл түгел. Аларның балаларының инде, татар моңын ишеткәч, күңелләре нечкәреп күзләренә яшь килми, чөнки алар урыс мәктәбендә укып тәрбияләнәләр. Шул рәвешчә әкренләп-әкренләп туган телнең, үз мәдәниятеңнең кирәклеге бетә бара, татарлык тойгысы, милләттәшлек хисе юкка чыга.

Татарларның милли үзлеген бетерү, аларны ким кешегә әйләндерү сәясәтенең тагын бер юлы бар. Бу юл үз халкының мәдәни байлыгын саклауга тырышкан милли интеллигенциянең эшчәнлегенә, йомшаграк итеп әйткәндә, уңайсыз шартлар тудыруда күренә. 1944 елның август аенда ВКП(б) Үзәк Комитетының «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карары, шулай ук 1949, 1950 елларда өстәмә рәвештә профилактик чара буларак кабул ителгән шундый ук карарлардан соң, партиянең Татарстан өлкә комитеты, шактый куркуга төшеп, «милләтчелек казынулары»на карата тагын да уяурак була башлады[3].

Моңа мисал итеп, 40 нчы елларның азагында, 50 нче елларның башында, идеологик гаепләр ягып, республиканың Язучылар берлегенә ябырылуны әйтеп китәргә мөмкин. 1947 елның август аенда «Правда» газетасында С. Бәхтияровның «Татарстан язучылары белән эшләүдә житди кимчелекләр» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Мәкаләдә Татарстан Язучылар берлеге партия бюросының йомшак эш итүе турында әйтелгән иде. Шул вакыттан соң инде Язучылар берлеген коммунистлар партиясенең идеологик ныгытмасына әйләндерү буенча актив эш башланды. ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты, Казан шәһәр комитеты һәм Бауман райкомы бюроларының бер-бер артлы махсус утырышлары булды. Шул елларда, янәсе, идея ягыннан зарарлы әсәрләр иҗат иткән өчен, Ф. Хөсни, Ш. Маннур, С. Баттал һәм Н. Исәнбәтләр партиянең каһәренә эләктеләр.

Театрлар репертуары да каты күзәтү астына алынды. Театр коллективларыннан, драматурглардан совет кешеләренең тормышын һәм көрәшен «дөрес» чагылдырган заманча спектакльләр таләп иттеләр.

Югары органнар бигрәк тә тарих фәнен каты күзәтү астында тоттылар. 1949 елда «Казан татарларының килеп чыгышы» исемле мәкаләләр җыентыгы каты тәнкыйть ителеп, туздырып ташланды. Китапның авторлары — танылган тарихчылар академик Б. Греков, А. Смирнов, Н. Калинин, Е. Чернышевларны житәр-

лек дәрәҗәдә марксистик-ленинчыл идеологиянең тарафдарлары булмауда, тарихны объективизм рухында яктыртуда, Шәрекътәге мөселман дөньясының йогынтысын арттырып күрсәтүдә, татарларның килеп чыгышында урыс иленең йогынтысын исә күрсәтеп җиткермәүдә гаепләделәр.

Илленче елларның ахырында КПСС өлкә комитеты берничә карар чыгарып, гарәп теленнән кергән кайбер терминнарны куллануга кайтарган өчен телчеләрне һәм матбугат хезмәткәрләрен тәнкыйть итте. Хрущев заманында бераз «боз эрү»не демократия килү дип уйлап, татар теленең язмышы өчен борчылучы лингвистлар телне ясалма рәвештә чуплауларга каршы көрәшергә керештеләр. Әмма аларның тырышлыгы бушка булды. Җитәкче органнар бер генә туры юл күрсәттеләр: ***«телнең үсеше милли үзенчәлекләрне кочәйтүдә түгел, бәлки телләрнең үзара үсә барган йогынты ясауларында»***, диделәр. Асылда, бу — татар теленә русизмнар тутыру дигән сүз иде.

Шул рәвешчә татар интеллигенциясенең чын милли мәдәниятне үстерүгә куйган тырышлыгы даими рәвештә тыела килде. Иҗат эшчеләрен икейөзлелек, конформизм (гамәлдәге системага җайлашу) шартларында эшләргә өйрәттеләр, аннары КПСС теләгән якка борыла торган идеология көнлекчеләренә әйләндерделәр. Уй-фикер эшчәнлегенең, рухи көчнең басылып-буйсынып яшәве нәтиҗәсендә, гомум милләт күләмендә милли горурлык тойгысы бетә башлады. Асылда, бу — татарлык хисенең югала баруы иде.

Шушы җирлектә халыкны маргиналлаштыруда икенче бер юнәлеш — җирле халыкны урыслаштырудагы тел сәясәте уңышлы рәвештә тормышка ашырылды. Төп хикмәт шунда: татар яшьләренең урыс телен белмәве яисә начар белүе югары белем яки урта махсус белем алу юлында зур киртә булып тора иде. Мәсәлән, 1947—48 елларда унынчы классларда имтиханнарны барлык укучыларның 70 проценты гына тапшыра. Күбесе урыс теленнән сынауны бирә алмый. 1947 елда урта мәктәпне тәмамлаучыларның 18 проценты, урыс телен начар белүләре сәбәпле, ВУЗга керә алмый.

Шунсы да ачык мәгълүм: бу заманда татарлар арасыннан бик аз гыйльми кадрлар чыгуның бер сәбәбе — урыс телен яхшы белмәү мәсьәләсе. Мәсәлән, 1947—49 елларда аспирантура тәмамлаган 95 кешенең егермесе генә татар, диссертация яклаган 45 кешенең исә җидесе генә татар[5].

Шуңа күрә, 1949 елда республикадагы мәктәпләрнең яртысыннан да кимрәге генә татар мәктәбе булуга һәм гомум белем алучыларның яртысыннан азрагы гына анда укуга карамастан, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Үзәк комитеттан РСФСР Мәгариф министрлыгын урыс теле һәм әдәбиятын укыту сәгатьләрен арттырырга мәҗбүр итүен сорый.

Биредә еш кына ишетелгәли торган бер фикергә тукталып китәсе килә: имеш, бүгенге көндә милли төбәкләрдә тел югалту мәсьәләсенең килеп тууына шундагы җитәкчеләр гаепле. Аларның урыслаштыру процессына катнашы барлыгын инкарь итмәстән, «ә башкача булуы мөмкин идеме?— дияse килә. Татарстанда гына түгел, бер генә союздаш республикада да туган телне укытуны яхшырту турында бер генә карар да кабул ителмәве очраклы хәлме? Шул ук вакытта барлык союздаш һәм автономияле республикаларда урыс телен укытуны яхшырту турында берничә карар кабул ителде.

Тоталитар дәүләтнең маргиналлар җәмгыяте төзүдә бик яхшы эшләгән тагын бер механизмы — илне индустрияләштерү белән мавыгу. 1940—70 елларда ул Татарстанда бигрәк тә кызу темп белән тормышка ашырылды. Шуның нәтиҗәсендә, башка начар яклары белән бергә, республиканың бөтен бер төбәкләрендә — көньяк-көнчыгыштагы нефть районнарында, Кама промышленность зонасында яшәүче халыкның традицион тормыш-көнкүреше җимерелде.

Биредә җәмгыятьне маргиналлаштыру иң югары дәрәҗәсенә җитте, чөнки ул элек-электән яшәп килгән тормыш структурасын бик тиз җимерә торган ике тенденция тәэсирендә: социаль-профессиональ үзгәрешләр һәм милләтләрне бергә болгатып кушу юлы белән гамәлгә ашырылды. Бер яктан, татар этносы илнең төрле төбәкләреннән бөтен союз төзелешенә килеп тулган төрле милләт кешеләре белән кушылып, сыегайды, үз төсен югалтты. Икенче яктан, гомер-гомергә иген игеп яшәгән җирле халык төркеме-төркеме белән берьюлы промышленность эшенә күчерелде. Мондый шартларда кичә генә авыл кешесе булган татарларның шәһәр тормышына күчүе, шәһәр культурасы элементларын тудыру һәм үзләштерүе шактый кыен мәсьәлә иде.

Төп байлыкны промышленность үсешенә тотып, кешеләрнең көнкүреш шартларын яхшыртуга бик аз өлеш чыгару хәлне тагын да авырлаштырды. Әнә шул шәһәрләрнең берничәшәр йөз фатирлы, яшәү өчен күңелсез-ягымсыз йортларын-

да маргиналлашкан яшьләр арасында җәмгыять өчен куркыныч төркемнәр барлыкка килүе очраклы күренеш түгел. Кешенең кеше булып тәрбияләнүендә зур әһәмияте булган, аңа милли намус төшенчәсе, әхлак-этика маяклары бирә торган милли аңның бетү-югалуы да монда шактый зур роль уйнады.

Җәмгыятьне этник яктан маргиналлаштыру хакында югарыда әйтелгәннәр, минемчә, халкыбызның яшәвенә рухи чыганак, олы әхлак таянычы булган милли аңны тергезү кирәклеген ышандыргыч итеп раслый.

Билгеле, яшьләр арасында агрессив төркемнәр барлыкка килүен җәмгыятебездә этносларны бетерү сәясәтенең нәтиҗәсе дип кенә карарга ярамый. Тормышыбызның табигый корылышын һәръяклап җимерүдән килеп туган хәл бу.

Сүземнең азагында тагын бер якка кагылып китәсем килә. Тоталитар режим, табигый рәвештә барлыкка килгән, үз алдына яши ала торган бай традицияле тормыш-көнкүреш формаларын бетереп, шуларны хакимият югарылыгыннан торып оештырылган төрле ясалма формалар: союз, клуб, комитет, җәмгыятьләр белән алмаштырырга маташты. Әмма күпчелеге дәүләт идарәләренә буйсынган бу ясалма оешмаларның эшчәнлеге гаҗәеп бертөрле иде, кешеләрнең теләк-омтылышларын канәгатьләндерерлек түгел иде.

**Тормыш исә коммунистик шәхес теориясенең үле идеологик схемаларына туры килми торган, үз гореф-гадәтләре, әхлак нормалары булган социальләшү формалары тудыра. Шәхеснең ирекле үсүен кысып-буып торган тоталитаризм шартларында еш кына көчләү-талаудан башканы белмәүче бандалар рәвешендә куркыныч социумнар да килеп чыга иде. Әлбәттә, җәмгыятьнең маргиналлашуын җинаять юлына баскан яшьләр барлыкка килүенә генә кайтарып калдыру мәсьәләне артык гадиләштерү булыр иде. Табигый корылышы җимерелгән, ясалма структуралы җәмгыятьтә маргиналлашу галәмәтләре тормыш-көнкүрештә үзүзенә урын таба алмауда ачык чагыла. Масса төсен алган бу хәл кешедә җавапсызлык, башкалар исәбенә яшәү, ярашырга тырышу, инфантильлек сыйфатлары тудыра. Минлек, «мин кем»лек тойгысын югалткан кешеләрдә барлыкка килә торган сыйфатлар бу. Гомум тигезлек, яңа кеше тәрбияләү дигән социаль утопияне тормышка ашырырга маташкан коммунистлар хакимияте, барлык чаралар белән кешенең кемлеген, милли тойгысын оныттырырга тырышып, бөтен бер халыкларны бетүгә таба йөз тоту, деградация хәленә җиткерде. Безгә яңадан төзәтү-тергезү өчен тоталитаризм хакимлеге калдырган иң авыр мирас бу.**

**Әлфия ГАЛЛӘМЕВА,**
тарих фәннәре кандидаты

**Искәрмәләр**

[1] Никифаров В. В. Халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерү чорында КПССның хезмәт ияләрен интернациональ рухта тәрбияләү буенча эшчәнлеге (1945—1952 еллар).— Тарих фәннәре кандидатлыгы диссертациясе. 66 б.

[2] «Советская Татария», 15.XI.1990.

[3] ЦИХНИТ, 15 фонд, 30 исемлек, 4 эш, 183—287 бб.

[4] Мусин М. «Халыклар туганлыгы, телләр дуслыгы». Казан, 1964. 34 б.

[5] ЦИХНИТ. 15 фонд, 30 исемлек, 6 эш, 227 б.

# БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

*— Халкыбызның сан ягыннан тарихи үсешен сез ничек күзаллыйсыз?*

— Идел-Урал татарларының демографиясе тарихы хакында шактый күп санда язмалар басылган, шул исәптән, аерым монографияләр дә бар.

Идел-Урал татарларының тарихи ватанында саны ничек үзгәрүен фәнни тикшерү нәтиҗәләре түбәндәге таблицада китерелә.

| Еллар | Саны (меңнәрдә) | Уртача еллык үсеш (процентларда) |
|---|---|---|
| XVI гасыр уртасы | 180—240 | — |
| XVI гасыр ахыры | 120—170 | — |
| XVII гасырның икенче яртысы | 190—200 | — |
| 1719 | 261,1 | — |
| 1744 | 327,1 | 0,1 |
| 1762 | 396,8 | 1,1 |
| 1782 | 509,3 | 0,62 |
| 1795 | 617,3 | 1,39 |
| 1833 | 1019,5 | 1,29 |
| 1857 | 1416,1 | 1,35 |
| 1897 | 2249,5 | 1,23 |
| 1912 | 2936,0 | 1,76 |
| 1920 | 2831,0 | —0,45 |
| 1926 | 2556,4 | —1,7 |

## I. XVI — XVII гасырлар

Татар тарихының бу чоры чыганаклар белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәгән. Шуңа күрә XVI — XVII йөзләрдә татарларның санын төгәл билгеләү гаять кыен эш, без аны якынча гына эшли алдык. Гомумән алганда, ул өч үрнәктә уздырылды. Төгәлрәк әйтсәк, бу очракта Казан ханлыгы гаскәренең саны, бу дәүләттә йомышлы һәм ясак түләүче халыкның нисбәте һәм XVIII гасыр башында татарларның саны хакында мәгълүматлар нигез итеп алынды. Шуның аркасында, килеп чыккан саннар йә артык зур, йә артык кечкенә булырга мөмкин. Күрәсең, монда (аерым алганда XVI гасыр өчен; XVI гасыр уртасына 210 мең кеше һәм ахырында 145 мең кеше) медиаль күрсәткечләр хакыйкатькә күбрәк якын тора булса кирәк. Югарыда без тапкан саннар нигезендә XVI — XVII гасырларда Идел-Урал татарларының саны хакында берничә нәтиҗә ясарга мөмкин:

1. Казан ханлыгында 0,5 тән 1 миллионга кадәр кеше яшәве хакында әдәбиятта китерелә торган мәгълүматлар чыганаклар белән ныгытылмаган һәм аларның шактый үстерелеп бирелүе күзгә күренеп тора.

2. Халкының саны бермә-бер артык булганга (ким дигәндә ун өлешкә) гына Урыс дәүләте Казан ханлыгын яулап алуга ирешә.

3. Урыс дәүләтенең Казан ханлыгын яулап алган чорларында соңгысы, ягъни татарлар, ил халкының өчтән бер өлешен югалта һәм бу чынлыкта демографик фаҗига була. Әүвәлге саннарына житү өчен Идел-Урал татарларына 150 ел вакыт кирәк була.

4. Халык тарихына моңа кадәр яшәп килгән исәпләрдән аермалы карарга мөмкинлек биргәнгә, демографиягә кагылышлы мәгълүматлар XVI—XVII гасырларда яшәгән татар халкы тарихын язганда, һичшиксез, игътибарга алынырга тиеш.

Ике йөз елдан артык дәвер эчендә (1719—1926 еллар) татарларның саны 9,8 тапкыр арта, ягъни 261,1 мең кешедән 2 миллион 556,4 мең кешегә җитә. Бу сан гомумрусия күрсәткечләренә якын тора. Идел-Урал татарлары санының уртача еллык үсеше шактый югары була һәм XVIII гасыр башы — XX гасыр арасында 0,79 процентны тәшкил итә. Ләкин, алда китерелгән таблицадан күренгәнчә, аерым чорларда бу саннар бер-берсеннән шактый аерыла. Инде XVIII гасырда ук татарлар санының ел саен мәгълүм күләмдә арта баруы күзәтелә. Мәсәлән, 1719—1762 еллар арасында ул 0,96 процент тәшкил итсә, 1762—1795 елларда бу сан 1,3 процентка җитә, ә гомумән алганда, XVIII гасырда үсеш 1 процентка тигез һәм ул гомумрусиянекеннән бераз зуррак. Шул ук вакытта 1762—1782 еллар арасында татарлар санының үсешендә зур югалтулар да булган. Безнеңчә, бу заманда барган крестьян күтәрелешләре (1773—1775 еллар) дә монда бик нык тәэсир ясаган булса кирәк. Идел-Урал төбәкләрендә бу югалтулар барлык халыкның 9,6 процентын тәшкил итәргә, ягъни 38—40 мең кешегә җиткән булырга мөмкин. Ләкин монда башка бер гаять мөһим мәсьәләгә игътибар итү зарур: XVIII гасыр уртасына һәм бигрәк тә ахырына Идел-Урал татарлары милләт булып калыплашуның беренче чоры өчен кирәк кадәр санга җиткән, дип уйларга тулы нигез бар.

XVIII гасыр ахырыннан алып XIX гасыр уртасынача татарлар санының уртача еллык үсеше 1,27 процентка җитә һәм реформалар чорында да югары кала, башка төбәкләргә күчеп киткәннәрне дә санап, 1,23 проценттан башлап 1,35 процентны тәшкил итә. Бу күрсәткеч XIX гасыр ахырына XX гасыр башына үзенең иң югары ноктасына җитә һәм 1,76 процентны тәшкил итә, ә күчеп китүчеләрне дә кертеп исәпләгәндә, ул тагын да югарырак була. Күрәсең, бу чорда татарлар санының шул рәвешле кызу үсүе реформа елларында халыкның тормыш дәрәҗәсе яхшыруына да бәйләнгәндер. Башка мәгълүматлар һәм, аерым алганда, шәһәрдә яшәүче татарларның гомерләре озаю да шул хакта сөйли.

Ләкин XX гасыр башы, төгәлрәге, аның икенче дистә еллыгы, демографик үзгәрешләрнең рәвеше буенча аңа кадәрге чорлардан бик нык аерыла. Революцияләр, сугышлар, җимереклек һәм ачлык татарларның санын сизелерлек киметә. 1912—1926 еллар арасындагы чорда төбәктә аларның саны 12,9 процентка, ягъни 380 мең кешегә кими. Бу — турыдан-туры югалтулар нәтиҗәсе генә түгел, ә татарларны Рәсәйнең башка төбәкләренә күчләп күчерүнең ачы җимеше дә. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында Идел-Урал төбәгендә 83,5 процент татарлар яшәгән булса, 1926 елга бу күрсәткеч 4,9 процентка кими (78,6 процентка кадәр). Бу хакта түбәндәге саннар да сөйли: Әйтик, Рәсәйдә татарларның гомуми саны 1912—1926 еллар арасындагы чорда 1,7 процентка, ягъни 57,3 мең кешегә кими. Бу сан Урта Идел һәм Урал буе төбәкләрендәгедән шактый ким.

XX йөз башында татар халкының сан ягыннан югалтуларын (турыдан-туры һәм шуның нәтиҗәсендә тумый калган кешеләрне дә исәпкә алып) бәяләп карарга мөмкин. Безнең исәпләүләр буенча, алар гаять зур булган. Бөтен Рәсәй буенча бу югалтулар 700 мең кешедән артык һәм шуларның 600 меңе — Идел-Урал татарлары. XX гасырда демографик хәлне күпмедер күләмдә кайбер күрше халыкларның (башлыча башкортларның) татарлар арасында эреп татарлашуы белән бераз унай якка үзгәртә. Исәпләвебезчә, XIX гасыр уртасында — XX гасыр башында барган этник процесслар нәтиҗәсендә, башка халыкларның кушылуы исәбенә Идел-Урал татарларының саны 6 процентка үсә.

Шулай итеп, татарлар турында алда каралган демографик мәгълүматлар халык тарихының аерылгысыз бик мөһим өлеше булып тора һәм аларга, бигрәк тә татар халкы тарихы буенча хезмәтләр язганда, җитди игътибар бирергә кирәк.

**Дамир ИСХАКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Фикрәт Төрекмән**

# ЮНЫС ӘМРӘНЕҢ КЕШЕГӘ МӘХӘББӘТЕ

Әдәбият тарихыбызда Юныс Әмрә XIII йөздә Анадулы киңлекләрендә барлыкка килгән төрек шигыренең иң әүвәлге остасы, иң элекке илчесе, хәтта аның нигез салучысы буларак билгеле. Аны болай күз алдына китереп тәкъдим итү дөрес, әмма бик үк тулы да түгел. Чөнки ул — төрекләрне һәм мөселманнарны гына түгел, ә бәлки барлык кешеләрне тыныч яшәргә чакырган нечкә, ягымлы һәм сөйкемле тавышлы бөек гуманист та.

Юныс Әмрә шигырьләренең нечкәлегендә тойгы һәм хиснең бәһаләп бетергесез булуы белән бергә, анда үзенчәлекле тәртип бәйләнешләре дә чагылыш таба.

Тирән кичерешле, сөю һәм ышанганлык тулы бер тойгы, жанлы һәм бизәкле халыкчан тел, тәңре һәм кеше мәхәббәтенә таянган гуманлылык — болар әнә шул өч төп элементның сөземтәсе инде. Безнеңчә, Юныснын башка шагыйрьләрдән аерымлыгы һәм җиде гасыр буена җанлы сүзләре яшәвенең иң бөек сере — бу өч элемент — гонсырның камилләшкән синтезы төзелешендә. Аның иҗатында борынгырак дәвер гуманистик фикерләр дә бар, алар да кеше дөньясын колачлау буларак кабул ителә. Көнбатыштагы бу төшенчә янында Көнчыгыштагы Конфуций һәм Будда карашлары да илаһи һәм кешелек төшенчәсе кыйммәтләре белән берләштерелә. Бу исә христианлык һәм ислам гуманизмының дини нигезләрен барлыкка китерә. Әмма һәрберсе үзләренең юнәлешләре эчендә килешәләр, тик диннәрдәге төрле мәзһәбләр идеологик күзәтүләре барышында бу гуманистик төшенчәне үзләренчә аңлаталар. Юныс Әмрә Көнчыгыш һәм Көнбатыш гуманизмы төшенчәләренең бер синтезын барлыкка китерде. Ул Көнбатышның ренессансында — янәрышта коллектив көчләр бер тырышлык белән иҗат иткән гуманизмны берүзе һәм каршылыклы бер социаль мохиттә тудыра алды.

Бу шундый социаль мохит иде, аны кайсы яктан гына алып карасаң да, андагы чуар шартлар тәртипсезлек һәм көчләүләр белән тулы иде. Бер яктан, XIII йөздәге Анадулы — социаль һәм сәяси тынгысызлык, икътисади авырлыклар, монгол яулары барлыкка китергән өметсезлек, кыскасы, таркалу һәм соңгы чиктәге бөлгенлек дөньясы иде. Икенче яктан, җайдак төрекләрнең күчмәчелек мәдәниятеннән утраклык һәм шәһәр мәдәниятенә күчә барулары матди һәм мәгънәви элементларны килештерү белән үзгәрешләр тудырган мәсьәләләр иде. Бу ике мәдәният арасындагы асыл аерма: күчмәчелек мәдәниятенең нигезе булган хайван асраучылыкны һәм игенчелекне, боларга бәйле иске гореф-гадәтләрне аңлау рәвешенә күрә, сугышчанлык фәлсәфәсен калдырып бару, яңа тормыш фәлсәфәсенең алга сөрелүе, кыскасы, юлбасар кеше тибы урынына бүтән кеше тибының урнашуын гәүдәләндерү була. Ачык киң әйләнә-тирәнең, ягъни дала дөньясының тар һәм чикләнгән мохите үткән иде инде.

Инде кайудан качмасаң,
Илгизәр кебек күчмәсән,
Үлем шәрабын эчмәсән,
Аһ, нишләтим, гомерем, сине!

---

Фикрәт ТӨРЕКМӘН — *төрек галиме, профессор. Төркиянең Измир шәһәрендә яши.*

Юныс Әмрә шигырьләрендә дөнья гуманизмы үсеше тарихындагы иң мөһим төшенчәләрнең барысы да урын алган. Аның гуманизмында тәнре идеясе шактый әһәмиятле урынны били. Төрек шигырендә тәңрене кешеләштергән, кешене тәңреләштергән беренче шагыйрьләрдән Юныс Әмрә булды. Тәңре кешенең үзендә, аның җанында ул.

Бу тылсымны бәйләгән,
Төрле телдә сөйләгән,
Җиргә, күккә сыймаган,—
Сыймас бу җан эчендә...

Күп эзләдем, тапмадым,
Таптым кеше җанында.

Ул тәсаууыф «Инәл-хәкъ» («Мин — Алла») дигән төшенчәсен гуманизмның нигез ташларыннан беренчесе дип аңлау хәленә җиткерә. Бу «Вәхдәттә — берлек» («Бер аллалыкта — берлек») дигән фикер кешене югары күтәрә һәм гыйшыкны алгы планга чыгара.

Кемдә бер бөртек гыйшык бар икән,
Алланың барлыгы андадыр.

Алла дөньясында йөз мең төрле гыйшык бар,
Үзеңә ал: һәр кайсы да лаек яр.

Юнысча, гыйшыклык кешедә аерым бер дулкынлану, сөенеч тойгылары уята. Гыйшык һәр нәрсәне сафландыра, кешене камилләштерә.

Гыйшык нәфсе иленә очты,
бар булганны ялкын алды,
Тәкәбберлек авын өзде,
анда сансыз орыш салды.
Ишетегез, дуслар, гыйшык ул бер кояшка охшар,
Гыйшкы булмаган күңелләр каткан бер ташка охшар.

Юныска тыйшык — кире кагылмаслык бер тойгы. Әгәр кеше тели икән, ул аннан аерылмас. Бу тойгы турында сөйләү дә мәгънәле.

Сөйләмәсәм сөйгәнемне,
Сөю дәрте буар мине.

Шагыйрь гыйшыкны, күңелләрендәге дин һәм мәзһәб аерымлыкларына карамастан, кешеләрне үлемсезлек дәрәҗәсенә күтәргән бөек, гүзәл бер кыйммәт итеп аңлый.

Дин вә милләтне сорасаң,
гашыйкларга дин нигә,
Гашыйк, мескен, белмәс, аңа
дин вә диндарлык нигә.

Юныста гыйшык дөньявига һәм ахирәтигә аерылмый. Шунлыктан аңа дөнья — гомер юлындагы бер баскыч кына. Яшәеш үзе — монда да һәм тегендә дә дәвам иткән бербөтен ул.

...Дуст, дин-иман кирәк икән,
Әйбәт көн ит бу дөньяда,
Иртәгә дә бетмәс эшең,
Бетмәгәнчә ул монда да.

. . .

Мин аемны җирдә күрдем,
Ни эшем бар күк йөзендә,
Миңа рәхмәт җирдән ява,
Кирәк җирдә үз йөзем дә.

Юныс тәңре һәм табигать белән күңел вә көч берлеге эчендәге кешене идеаль үрнәк итеп ала.

Ай булдым да кичен калыктым,
Болыт булып җиргә аудым,
Яңгыр булып шунда яудым,
Нур булдым да көнгә бактым.

Бердәм барлык хәленә килгән кешене ул тулы өлгереп җиткән, билгеле бер икеләнүләрдән арынган буларак итеп таный. Кешеләрне ниндидер кызганыч кол, ихтыярсыз бер бетерешкән дини мескеннәр итеп күрергә теләми. Җәннәткә ышандырган һәм җәһәннәм куркынычлары белән кешеләргә вәсвәсә салган хуҗаларны ул мәрхәмәтле булырга чакыра.

Хакның ихлас гашыйклары
Теләмәсләр җәннәтләрен,
Җәннәттән дә элегрәк
Үтәр алар хезмәтләрен.

Пәйгамбәр урынына кем калды,—
Халык башына ул бәлаләр салды,

Табарсың Алланы кальбеңдә-күңелдә,
Ул Кудес, Мәккәдә, Хаҗда түгел дә.

Дин белән дошманлыкның бергә сыеша алмаганлыгын, кешене рәнҗетүләрнең ярамаган бер эш икәнлеген ул үзенең гыйбадәтләрендә дә еш кабатлый.

Юныс Әмрә, күч куеп,
Киләкәсә мең хаҗ кылып,
Һәрвакытта хуш булып,
Күңелне биләү кирәк.

Күңел Алланы тапты,
Алла күңелгә бакты,
Кемнең күңеле сынык,
Үлгәчтән дә бәхте йук.

Бераз күңлең ятмаса,
Кылганың намаз булмас,
Җитмеш ике кеше дә
Кул биреп, юмый булмас.

Төре походлары һәм дини мәзһәпләрнең үзара гауга-тотышлары аркасында таркалу хәленә калган Анадулыда Юныс диннәрнең бер булуының ышанычын болай телгә китерә.

Күк йөзендә Гайсә белән,
Тур тавында Муса белән,
Кулда таяк — гаса белән
Чакырамын, Мәүлам, сине.

Ул кайчак мәчеткә керә, дога кыла; кайчан чиркәүгә бара, Инҗил укый, раһиб-монах була. Бу рухани кичерешләргә каршы булуга да карамастан, анда ул — үзгәрми торган бер максат. Бу максатка ирешкән кеше үлемсезлеккә ия була.

Үлә икән тән үлер,
Җаннар үләчәк түгел.

Юнысның динне аңлавы кеше белән башлана һәм кеше белән тәмамлана.

Мин үземдә минне күрдем,
Миндә генә мин булганны,
Бу хәлдәге җан газабын,
Ахи[1] белдем ни булганны.

Дәхи күрмә кемсәне дә,
            һич берәү дә буш түгел,
Кимчелекле яман караш
            үзиләргә хуш түгел,

---

[1] Ахи — тарихи: Госманлы империясендә һөнәрчеләрнең мөселман туганлы оешмасы әгъзасы.

— диеп, Юныс Әмрә һәр кешене нәкъ шулай лаеклы хөрмәт итә.

Үзеңә син ни теләсәң,
Үзгәгә шуны телә,
Дүрт китапның[1] мәгънәсе бу,
Бары да шуннан килә.

Юныста җитмеш ике милләт, ягъни төрле халыклар барысы да тигез санала. Барлык яратылганнарга бертөрле генә караш булмаса да, әгәр дә кемдер — халыкны өйрәтүче остаз икән, ул чынлыкта файдалы, ди шагыйрь.

Кешеләр арасында дошманлыкның, үч һәм явызлыкның булмаска тиешлеген ул еш-еш кабатлый. Тәңре белән кеше арасындагы гыйшык, Юныс Әмрәчә, бөек бер галәмәт ул.

Хакны чыннан сөйгәннәргә
Барлык галәм кардәш булыр.
. . . . . .
Күңелемнән кудым кинә — явызлыкны,
Кинә тотучыда бел син дине юкны.
. . . . . .
Шәһрәтебез зәгыйфь безнең,
Дошманыбыз кинә безнең,
Беркемгә дә үч юк безнең,
Барча галәм бердер безгә.

Шулай итеп, Юныс Әмрә кеше намусына хөрмәтне, мәгънәви яшәешенә инанычны һәм дини ышануларның чиксезлеген тәңрегә бәйлелеген һәр җирдә сөюгә таянган төшенчә һәм югары әхлак икәнлеген аңлатырга тели.

Юныс Әмрәнең кешене шулай кыйммәтләве бик чын. Дөньяның гүзәллеген ул һәм кешенең шул гаҗәеп дөньядагы нигъмәт-байлыклардан файдалану өчен яратылганлыгын сөйли.

Кызыл, яшел киенгән дөнья килен ишедер,
Йәш киленгә карап та туймаганы кешедер.
. . . . . .
Дин белән бу иманның тугрылыкта нигезе,
Ул тәмам булмаенча, дин нидән ныгыр үзе.

Чын гыйлемнең мәдрәсәләрдә өйрәтелмәгәнлеген үзе белгәнлектән, ул Хакны белү кирәклекне сөйли.

Гыйлем, гыйлем — белмәктер, үз-үзеңне белмәктер,
Син үзеңне белмәсәң, нинди гыйлем булмактыр?
Мин үземне шулай белдем,
дөрес аңла, хаклы булдым,
Эчтәге шик, шом-куркудан
азат булдым.

Ягъни яшәештә барлыкка ышануның һәр күренешенә түземлелек сакларга, тыйнаклыкка күнегергә, үзеңне күндәм күрергә өйрәнү — кыскасы, һәр яктан камилләшкән кешедә боларның мәңгелек икәнлеге ачыла.

Мин килмәдем дәгъва өчен,
Минем эшем гыйшык өчен,
Дустың өе — күңелләр, чын,
Күңел хуш итәргә килдем.

Юныс Әмрә боларны сөйләү белән игелекле кешеләргә төрлечә мөрәҗәгать итә. Шушы рәвештә халыкның кешелеклелек сыйфатына игътибар юнәлтә. Диннең кешелекчән һәм хакыйкать икәнлеген, бу юлда булганнарның Хак каршында очрашачаклары, дөньяви эгоистлыктан — үз-үзләрен сөюдән арыначаклары хакында сөйли.

Дөнья — минем ризыкым ул,
Халык — минем халыкым ул.
. . . . . .

---

[1] Дүрт китап — дини изге китаплардан Тәүрат, Инҗил, Зәбур, Коръән күз алдында тотыла.

Йә бер потка, йә хажга юлны тотам,
Ниндидер дин, нинди иманны тотам.

Юнысның гуманизмында күркәм әхлак һәм мәрхәмәтлелек — иң мөһим элементлардан. Аның «Рисалятен-нәсхийә» исемендәге мәснәвие әхлак төшенчәсен аңлаткан бер китап. Бигрәк тә Юныста идеаль сурәт буларак тасвирланганы дәрвиш тибында бирелә.

Дәрвиш бәгъре таштыр ул,
Күзе тулы яшьтер ул,
Куйдан да юаштыр ул,—
Син дәрвиш булалмассың.

Шөбагач кулсыз булыр,
Бусага телсез булыр,
Дәрвиш күңелсез булыр,—
Син дәрвиш булалмассың.

Юнысның әхлакны аңлавындагы мәхәббәт, нәзакатлек һәм чиксез киңлекне төшенеп житү зур сәнгать остасының әчкерсезлеген, ихласлыгын тагын да өскәрәк калкыта. Бу самимилек, саф күңеллелекнең асылы — Аллага ышанычның һәм аннан бәйле булуның, исламча фикерләүнең билгесе ул.

Шагыйрьнең мәрхәмәтлелегенә килгәндә, бу шулкадәр ачык ки, ул аны үзе болай аңлата:

Бар булганны хуш күрдем,
Аны яраткан өчен.

Юнысның йомшаклык күрсәтүчән булганлыгы хакында Шәйхелислам Әбуссогут әфәнде (1574 тә вафат) алдына куелган сорауны аның бу уңайдан чыгарылган фәтвасы бик яхшы ачыклый.

«Берәүнең мәчетендә төрле кешеләр һәм бала-үсмерләр көлешә-көлешә дога укыйлар икән, Тәүхид (бер аллалыкны тану) сүзләрен алмаштырып, әле «дили мән», әле «жаны мән» («Минем күңелем», «минем жаным»), дисәләр, тагы да йә «син бер олуг солтансың, жаннар эчендә жансың, чөнки ачык күрдем ки сине, син яшрен кемдер түгел», дип, яисә «жәннәт, жәннәт дигәннәре — бер өйдәге берничә хур кызы, теләгәнгә бир син аларны, миңа син кирәк, син», дип, күкрәкләренә суга-суга килбәтсез кылансалар, мәхәлләнең кайбер кешеләре гыйбадәтханәнең Шәйхе Зәедкә: «Бу төрле кыланышларга ничек риза булып торасың?» — дип сорагач, ул: «Моннан нәрсә килеп чыга? Тәңре: «Бөтен яратылган нәрсәләр — женнәр, кешеләр миңа табыналар», — дип әйтмәдемени?» — дигән.

Жавап: исеме телгә алынган хәлләр һәм эшләр, иң югары әхлаксызлык булу белән бергә, жәннәт хакында сөйләгәннәр дә жирәндергеч сүз һәм чынлыкта Алланы сүгү һәм көферлек.

Уйларыбызны Юныска юнәлдереп, аның

Без дөньядан китмәк булдык,
Калганнарга сәлам булсын,
Безнең өчен хәер-дога
Кылганнарга сәлам булсын.

Дәрвиш Юныс сөйләр сүзен,
Яшь тутырган ике күзен,
Безне белмәс — белмәс үзен,
Белгәннәргә сәлам бездән,

— дигән, яшәүнең мәңгелеген сөйләгән, кешегә бөек ихтирам хисләре белән сугарылган үлемсез шигъри юллары белән сүзне тәмамлыйсы килә.

Төрекчәдән **Шакир АБИЛОВ** тәржемәсе.

**Резеда Ганиева,**

филология фәннәре докторы.

# НӘҖИП ДУМАВИ: ШӘРЕКЪМЕ, ГАРЕПМЕ?

Кайсы мәдәниятка йөз тотарга, кайсысыннан үрнәк алырга? Көнбатыштанмы? Көнчыгыштанмы? Бу сораулар XIX йөзнең икенче яртысында — XX гасыр башында яшәгән бик күп татар язучылары, галимнәре, зыялыларының игътибарын җәлеп итә. Мәсәлән, мәгърифәтчеләр озак гасырлар дәвамында колониаль изелүдә, иҗтимагый һәм рухи торгынлыкта яшәргә мәҗбүр ителгән татарларны тәрәккыятькә илтү юлын европалашуда, урыс мәдәниятенә йөз тотуда күрделәр. Беркадәр соңрак әдәби-эстетик фикер мәйданына чыккан романтиклар, киресенчә, мәгърифәтчеләрнең акыл культын яклмады, буржуаз җәмгыятьтәге фәнни-техник тәрәккыятьне күккә чөюләре белән килешмәде. Алар фикеренчә, башка халыкларның әдәби һәм мәдәни казанышларын кыйбла итү татарның милли рухын, милли үзенчәлеген юкка чыгарачак, аны мөстәкыйльлектән мәхрүм итәчәк иде.

Борынгы дәверләрдән үк килгән милли башлангычны, татарлыкны, төркилекне, шәркыйлекне сакларга чакырулар яңа гасыр башында Нәҗип Думавиның әдәби-тәнкыйть эшчәнлегендә аеруча көчле яңгырый. Аның бу хактагы гыйбрәтле фикерләре безне бүген дә уйландыра, бер читтән икенче читкә ташланмыйча, Шәрекъ һәм Гареп мәдәниятенә үз мөнәсәбәтебезне булдырырга ярдәм итә.

* * *

XX гасырның унынчы елларында татар әдәбиятындагы романтизм киң колач белән үсеп китә, аның үз тәнкыйте һәм эстетикасы барлыкка килә. Дөнья әдәбиятының барлык романтиклары кебек, татар романтик язучылары да үзләренең әдәби-тәнкыйть эшчәнлекләрен мәгърифәтчеләрнең рационализмын һәм дидактизмын кире кагудан башладылар. Нәҗип Думавиның «Без мөляхәзә» («Йолдыз», 1915) һәм «Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән» («Аң», 1916) мәкаләләрендә дә шул ук күренеш: акыл культы кире кагыла, кеше күңелен, эчке дөньясын гәүдәләндерү үзәккә куела. Үз заманында бу мәкаләләр шактый бәхәсләр уятты, Җамал Вәлиди кебек танылган тәнкыйтьчене «Шәрекътән — Гарепкә» исемле мәкаләләр тезмәсе язуга этәрде. Совет чоры әдәбият белемендә Думави мәкаләләре бөтенләй диярлек өйрәнелмәде, телгә алынган очракта да аларга реакцион дигән кара мөһер сугылды. «Бер мөляхәзә», «Шәрекътән-Гарепкә мөнәсәбәте белән» мәкаләләренең тискәре бәяләнүенә сәбәп — аларда әдәбият һәм сәнгать фәлсәфәсен, аерым алганда, акыл һәм хис мәсьәләсен романтикларча миллилеккә, татар канына, татар дәһасенә (сәләтенә), үткән тарихына, җәгърәфи һәм климатик шартларга, шәркыйлектән килгән традицияләргә бәйләп аңлату.

Әйе, Думави «Бер мөляхәзә», «Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән» мәкаләләрендә «салкын гакылны», «тупас фәнне» хискә, хыялга, әдәби фантазиягә каршы куйды һәм бу хакта түбәндәге фикерләрне әйтте: «адәм фән белән түгел, хыял белән яши»; «зур адәмне үз зурлыгында яшәткән нәрсә — адәмнең иркен хыялы»; «иман, гыйшык, хыял — һич каюсы фәнгә сыймыйлар, фәннән качалар»; скульптура, музыка, сүз сәнгатен «фән, акыл куйган үлчәүләргә салып торырга бер дә хаҗәт юк... хәят хыялда, шулардан бер карауда анкып торган мәгънәдә», «фәнни, гаклый итеп красота аңлау хыялны, гыйшыкны, иманны үтерә» («Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән»).

Думави фикеренчә, әдәбият һәм сәнгатьне акыл һәм фән кысаларына гына сыйдырырга тырышу, икенче төрле әйткәндә, бары тик реализмны гына тану — мәгънәсезлек. Әдәбияттагы романтизм, символизм, футуризм кебек агымнарны да ул мәгърифәтчеләрнең салкын акылына һәм тупас фәннәренә җавап рәвешендә туды дип исәпли.

Думави фаразынча, һәр милләт тотрыклы психик сыйфатларга, ягъни архетипларга ия һәм ул, буыннан буынга күчеп, бүгенге әдәби процесска да тәэсир ясый, андагы сәнгатьчә фикерләү төрләрен, иҗат ысулларын, стиль үзенчәлекләрен дә билгели дип саный. Шуннан чыгып, ул халыкларны һәм әдәбиятларны икегә — акылга (фәнгә) һәм хыялга бай булганнарга бүлә. Аныңча, кайчандыр Шәрекъ бишегендә үскән татарларда һәм Көнчыгышка якын торган урысларда «хыялый көч» өстенлек итә. Хыялый көч исә әдәбиятта романтизмны ашландыручы һәм яшәтүче төп шарт. Шуңа күрә дә әдип «романтизм — хыяллар сыйдыра алмаган бер диңгез бит», ди. Реализмда исә хыял артык зур урын алып тормый, чөнки ул акыл богаулары белән чикләнгән.

Көнбатыш халыкларында, шул исәптән, алманнарда хыялый башлангыч юк, аларда бары тик фәнгә нигезләнгән акыл гына бар дип исәпли Думави. Бу исә аларның яшәешендә, психологиясендә, әхлакларында, дини ышануларында тискәре сыйфатлар гына тудырачак. Хәтта немец милитаризмы кебек социаль күренешне дә Думави буржуаз мәдәният һәм милли характер үзенчәлегеннән туган тискәре сыйфат итеп таный. Акыл һәм фән белән генә эш итү, аныңча, киләчәктә алманнарның сәнгатьчә фикерләүләрен дә көчсезләндерәчәк. «Хәзерге көндә фәннең иң тәрәккый иткән урыны — немецларны алыйк, — ди ул. — Фән бит боларны үтерә. Боларда шигырь, гыйшык, җылы иман бетәчәк. Болар шушы салкын тормышның салкын адәмнәре генә булып калачаклар» («Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән»).

Думавиның «Бер мөляхәзә» һәм «Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән» мәкаләләрендәге әдәби-эстетик фикерләр XIX — XX йөз башы европа һәм урыс әдәбият белемендә киң таралган мәдәният-тарих мәктәбе карашларын хәтерләтте. Француз язучысы Ипполит Тэн нигез салган бу мәктәп вәкилләре әдәбият һәм сәнгать фәлсәфәсен нигездә өч шартка — җәгърафи һәм климатик тирәлеккә, борынгыдан ук килгән, кан белән берекккән милли үзенчәлеккә, әдәби традиция һәм бәгланышларга бәйләп аңлатты.

Мәдәният-тарих мәктәбе тарафдарлары кебек, Думави да татарларның милли характер, милли мәдәниятләренең хосусиятләре билгеле бер мохиткә, урын һәм вакытка мөнәсәбәттә барлыкка килгән дип таный. Аныңча, бу тирәлек, бу урын — Көнчыгыш: «Без, татарлар, шөбһәсез, шәркыйбез, каныбыз — Шәрекъ каны. Бөтен тарихи күренешләребез, тарихи моң-зарларыбыз — һәммәсе дә шәркый» («Бер мөляхәзә»).

Думави күзаллаган вакыт төшенчәсе дә — борынгы Көнчыгышның бәдәвият җирлегендә, ягъни күчмә тормыш белән яшәгән заманда. «Татарлыкның бәдәвият җирлегендә (җирлегендә), — дип яза әдип, — бик зур мазыйсы (үткәне) бар иде. Табигый пакълегендә һәм шәркый мохитында бу мазыйга охшашлы бер мазый һичбер гареп милләтендә булмаган. Ничә гасырлар саф, алдаусыз, пакъ бәдәвият тормышында, иректә, киң мохиттә табигать асрап үстергән бу халыкның каны да, җаны да, хыялы да, әлбәттә, һичбер яктан башка тар мазыйлы халыкларга охшамый» («Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән»).

Думави татарларны табигать балалары дип атый. Шуңа күрә алар рухи яктан бөекләр һәм камилләр, әдәби зәвекъ һәм ихтыяҗлары да диңгездәй тирән һәм киң: «Татарлыкның бөтен мохиты — тигез сахра, иркенлек иде ки, — ди ул, — болар үзләре дә шигырь диңгезедер» («Бер мөляхәзә»).

Иҗат фәлсәфәсен җәгърафи тирәлеккә, климатка бәйләп аңлату Көнчыгыш халыкларында борынгыдан ук — гарәп шагыйре әл-Җаһиз (IX гасыр) һәм философ Ибне Хәлдүн (XIV гасыр) заманнарыннан ук килә. Европа һәм рус әдәбият белемендә мондый карашлар бары тик XIX һәм XX гасыр башларында мәдәни-

ят-тарих мәктәбе вәкилләре тарафыннан үзләштереләләр... Яңа гасыр башы татар әдәбият белемендә мәдәни һәм әдәби үсешне жәгърәфи һәм климатик шартларга бәйләп аңлатучы Нәҗип Думави булды. Марксизмга кадәрге әдәбият белемендә әдәбият һәм сәнгать фәлсәфәсен җәгърәфи шартларга бәйләп аңлатуның зур урын алып торуын «Пролетариат әдәбияты турында» хезмәтендә Галимҗан Ибраһимов та искәртеп үткән иде.

Җәгърәфи яшәеш, климат үзенчәлеге иҗатка һәм әхлакка турыдан туры йогынты ясый дигән карашларны Думави, татар жирлегенә җайлаштырып, романтикларча үзләштерде, аларның үзәгенә «кан», ягъни милләт төшенчәсен салды. Думавича, «бөтен бәшәрияттә аерым-аерым каннар бардыр, болар аерым-аерым милләт тәшкил итәләр» («Бер мөляхәзә»). Әдип милли канызбызны, ягъни татарлыгыбызны идеаллаштыра, аны башка каннардан өстен күрә. Моның сәбәбен изге ният белән — татарларның мәдәни тарихтагы урынын югарыда күрергә теләү белән аңлата. «Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән» мәкаләсендә ул болай дип яза: «Татарлык үзенең мәгърур, мөстәкыйль бөек рухы белән калкырга тырышырга тиеш, мәдәният зәминендә (жирлегендә) аяк басарга тиеш».

Иҗат эше канга бәйле, дигән карашлар Җамал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов хезмәтләрендә дә күзгә чагыла. Мәсәлән, «Татар шагыйрьләре» китабында Г. Ибраһимов Сәгыйть Рәмиевнең «Мин» шигыре турында болай дип яза: «Бунардан борынгы татар каны, татар куәте исе килә, ул куәт, ул йөрәкнең әле бездә бетмәгәнлеге күренә, тик икенче төскә, фәлсәфи, мәдәни рәвешкә кергән була» (**Әсәрләр.** *8 томда. 5 том. Казан, 1978. 91—92 бб.*).

Ә менә Дәрдемәнд «Гөрләгән сулар» исемле фәлсәфи шигырендә үзенең моң-сагышларын «мөкаддәс кан» һәм «изге сөт» сурәтләре ярдәмендә түбәндәгечә белдерә:

> Ни газизрәк, бу Ватанмы?
> Аһ, туган кавемем газиз;
> Ул мөкатдәс кан белән, ул
> Изге сөткә ни житәр.
> (**Сайланма әсәрләр.** *Казан, Тат. кит. нәшер, 1959. 62 б.*).

Кан-кавем-халык-милләт төшенчәсен үзәккә салган әсәрләр дөнья әдәбиятында һәм фәлсәфи-эстетик фикерендә еш күзгә ташлана (мәсәлән, Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, «Идегәй» дастаны, Эмиль Золя романнары, Ибне Халдун, Ипполит Тэн хезмәтләре һ. б.). Кызганыч ки, совет әдәбият белемендә «кан-милләт» мәсьәләсен яктырткан әсәрләр «прогрессив иҗат көчләрен тоткарлаучы реакцион күренеш» (Х. Госман) итеп тамгаландылар.

Думави һәр милләтнең канында аның үзенә хас куәте һәм иҗади эшкә сәләте — «дәһасе» бар дип раслый. Шушы уңай белән ул кешелек дөньясында югарыга, бөеклеккә, тойгынлыкка, илаһияткә омтылучы дәһаләр, тар даирәдән чыга алмаган дәһаләр, үсүдән туктап калган милләтләр дәһасе, еракка бара алмаган каннар, гареп дәһасе, татар дәһасе, реализмда декадент булып киткән дәһаләр, романтизмда хыялый булган дәһаләр турында фикер йөртә. «Аерым милләтләр үзләренең каннары, дәһаләре икътидарыннан, көченнән тыш эш эшли алмый» («Бер мөляхәзә»), дип нәтиҗә ясап, әдип «кан-дәһа» төшенчәсен универсаллаштыра һәм аны иҗат эшенең асылын билгеләүче хосусият итеп карый.

Әдәби традицияләр һәм тәэсирләр турында сөйләгәндә, Думави әдәби күчемлелекнең елга башын бәдәви Көнчыгыштан килгән «кан» һәм «дәһа» куәтендә, аның җайлы табигате, йомшак климаты тудырган һәм садәлек белән сугарылган милли психологиясендә күрә. «Шуңа күрә,— ди Думави — бездә, бүгенге татарларның балаларында, шәркый бабаларыбыздагы» рухани бөеклек калмаска мөмкин түгел» («Бер мөляхәзә»).

Думави әдәбиятта да, музыкада да, философиядә дә, дини ышануларда да шәркыйлекне яклады, борынгыдан килгән рухи камиллек, шигъри җанлылык, эстетик зәвыкълар яңа заманда да сакланырга һәм үстерелергә тиеш, дип санады. Шул сәбәпле ул чыгышлары белән Көнчыгыштан булган халыкларның музыкасында да — үзбәк (сарт) көйләрендә, башкорт моңнарында, казакъ (кыргыз) үләңнәрендә, иран гылкылдауларында татарларга «аш бирүче» хосусиятләр тапты, боларның кай төшендәдер татарларга якын үзлек сизде. Бу уңай белән Думави Шәһит Әхмәдиевнең җырчы Латыйф Фәттахов тарафыннан башкарылган үзбәк көйләренә карата әйткән тәнкыйть сүзләре белән дә, урыс көйләренә тәкълид рәвешендә язылган яңа татар көйләрен уңай бәяләве белән дә килешмәде; җырчы Камил Мотыйгинның атаклы урыс җырчысы Шаляпинга охшарга тырышуын да өнәп бетермәде, Европаның Штраус кебек танылган композиторы

иҗатыннан өйрәнүне дә кирәксенмәде. Чөнки аларда «тирән Шәрекъ тойгылары юк», аларның барысы да урыс һәм гареп дөньясындагы кебек, «фән кайчылары белән киселгән». Гомумән, музыка бары тик композиторның эчке сиземләүләре, ниндидер тойгынлык — интуиция җимеше, аның логик төшенчәләр белән алыш-биреше юк, дигән фикер XX гасыр башындагы татар романтик әдәбият белеме өчен генә түгел, шул замандагы Европа һәм Русиядә киң таралган позитивистик фәлсәфә һәм эстетика өчен дә бик хас сыйфат иде.

Музыкадагы кебек, әдәби традицияләр мәсьәләсендә Думави көнчыгыш каны күзлегеннән, татарлар өчен генә хас һәм кабатланмый торган милли дәһа — зирәклек, садәлек, хисси байлык ноктасыннан якын килде. Тукайның урта гасыр көнчыгыш романтик шигърияте үрнәгендә язылган мәхәббәт газәлләрендә ул «искиткеч шигъри гармония», хыялый мәгънәләр тапты, «фән үлчәвеннән куркулар юклыкка» игътибар итте, шагыйрьне «рамкасыз уйлаучы, үлчәүсез тасвир итүче» романтик итеп күрергә теләде. Ә инде аның житлеккән чор иҗатында Шәрекъ тәэсиреннән баш тартып, Европа һәм урыс әдәбиятлары тәэсирендә бирелүен, «Лермонтов, Пушкин аша Байрон школасына кереп китә язуын» Думави Тукай шигъриятен зәгыйфьләндерүче, хыялындагы хөрлекне азайтучы бер кимчелек итеп карады. Ул Фатих Әмирхан белән Галимҗан Ибраһимовның «Шәрекъ тойгыларын гареп дәһалары илә киендерүләрен», йә булмаса, аларның көчләнеп «гареп тойгыларына буялырга тырышуларын» да кабул итмәде. «Ни сәбәпле Гаязны бик ансат, Фатих Әмирханны авыррак, әмма Ибраһимовны бөтенләй мәшәкатьле аңлыйбыз?», дип сораучыларга Думави болай дип җавап бирә: «Гаяз әфәнде белән Фатих Әмирхан әфәнде икесе дә реалист язучыларыбыз булган хәлдә, Гаяз әфәндenең җөмләләрендә никадәр артык сүзләр булмасын, ләкин алар һәммәсе дә мәгънәне тотыралар гына, тасвирлап киңәйтәләр генә, һич булмаса, тасвирны бозмыйлар. Әмма Фатих әфәндедә,— дип дәвам итә ул фикерен,— бер генә сүз урынсыз төшсә дә, тасвирны аңлау чуала. Гареп романтикасы белән ашланучы Галимҗан әфәндегә килсәк, аның тасвирый җөмләләрен аңлау өчен кат-кат укырга кирәк ки, хәтта кайсы вакытларда мәгънәнең сөреше ягыннан тиз генә алынган бер тасвир икенче җөмләләр илә тәмам югала» («Бер мөляхәзә»).

Татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә мәсьәләсендә дә Думави Шәрекъ традицияләренә турылыклы булу-булмау ноктасыннан якын килә. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы ни өчен урысчага тәрҗемә ителми, дигән сораугa ул болай дип җавап бирә: «Чөнки бу әслүб (ысул), бу ифадә (аңлату), бу шигырь, бу тасвир, бу аң урысларга күптән таныш, алар туйган инде, аларда андый нәрсәләр тулып ята. Әмма Гаязныкы аларга бик яңа, бик кызык. Чөнки болар урыска ят рухта, шуның илә бергә кызык, дәртле рухта» («Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән»).

Думави әйтергә теләгән фикер шул: татар язучыларының иҗаты үзенең эчтәлеге белән дә, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге белән дә милли рухны гәүдәләндерергә тиеш. Шул очракта гына алар татар укучысы тарафыннан да, башка халыклар тарафыннан да яратып кабул ителәчәкләр. Шуңа күрә ул татарларның бары тик Көнбатыш һәм урыс әдәбиятларына гына йөз тотып, милли үзенчәлегебезне, иҗади дәһабезне, мәгънәви һәм хыялый көчебезне, шәркыйлыгыбызны югалту белән һич тә килешми. Чөнки «бөтен мөхәррирләребез гареп дәһаләреннән истиганә иткән (булышлык сораган) очракта әдәбиятыбыз татар әдәбияты булып түгел, бәлки Европа әдәбиятының, Европа дәһаләренең икенче бер телдәге куәте, шәүләсе генә булып туачак» («Бер мөляхәзә»).

«Бер мөляхәзә» һәм «Шәрекътән Гарепкә мөнәсәбәте белән» мәкаләләренең әһәмияте шунда ки, Думави унынчы елларда ук мәгърифәтчеләр мактаган европалашу һәм урыс мәдәниятенә генә йөз тотуның тискәре нәтиҗәләргә китерәчәген ярыйсы ук ачык сиземләде. Дөрестән дә, аның күрәзәчелеге күпмедер дәрәҗәдә тормышка да ашты. Октябрь инкыйлабыннан соң без рухи һәм гамәли тормышыбызда европалаштык, урыслаштык, Гаяз Исхакыйның Җан Баевичлары кыяфәтенә кердек. Ә менә инде XXI гасырга аяк басарга торганда акылга килеп, совет хөкүмәте тарафыннан өрәккә әверелдерелгән миллилекне, төркилекне, шәркыйлекне, кыерсытылган мөселман мәдәниятенең унай казанышларын кабат терелтү, торгызу, халыкка кайтару эшенә керештек.

* * *

Борынгы дәвердә дә, урта гасырларда да, яңа заманда да төркиләргә башка халыклар арасында эреп юкка чыгу куркынычы янамады түгел, янады. Мәсәлән,

Орхон-Енисей язмаларында төркиләр аксөякләренең кытайлылар йогынтысына бирелүеннән зарлана, гореф-гадәтләребезгә турылыклы булыйк, дип, ташка чокып васыятьләрен язып калдыра.

Ислам динен кабул иткән төркиләр мөселман мәдәниятенә кушыла, гарәп һәм фарсы дөньясының каршылыклы һәм купкырлы тәэсирен татый; гасырлар дәвамында үзләренең дини йолаларын гарәпчә башкара, фәнни хезмәтләрен гарәп телендә яза; әдәби-эстетик фикердә дә гарәп-фарсы традицияләрен дәвам итә. Иң мөһиме шунда: мөселман мәдәнияте аша төркиләр (татарлар, төрекләр, үзбәкләр, әзербәйҗаннар) Борынгы Греция, Рим, Византиянең мәдәни казанышларына барып тоташа, урта гасырлардагы төрки Яңарышның нигез ташларын сала.

XIX йөзнең икенче яртысыннан башланган европа-урыс мәдәни бәйләнешләреннән дә татарлар күп мәгънәви ризык ала. Шәрекъ һәм Гарәп традицияләренең синтезына ирешеп, XX гасыр башындагы Яңарыш хәрәкәтенең яңа сәхифәләрен ача. Әмма совет чоры татар әдәбиятында Шәрекъ һәм Гарәп традицияләре бердәмлеге, аларның тигез хокуклылыгы юкка чыгарыла; Европа-урыс дөньясына гына күз текәү аяныч нәтиҗәләргә китерә.

Гомумән алганда, алга киткән халыклардан өйрәнү, өлге алу — зарури күренеш. Бүген азатлыгын, мөстәкыйльлеген, дәүләтчелеген торгызу өчен көрәшүче татар халкының да XXI гасырда мәдәни кыйбласы үзгәрер сыман. Офыкта яңа маяклар — төрекләр һәм инглизлар шәйләнә; үз милли рухыбызны саклап, Шәрекъ һәм Гарәп тәҗрибәсен иҗади үзләштерү кабат көн тәртибенә килеп баса.

Monьŋ sonьnda Idege yzeneŋ juldaşlarьman rqamaqlarqa atlanьp, ber qatar bulьp tezelgeo, Bunbajlarqa qarap taqь da bolaj jьrladь:

Min mendermen, mindemen, Juqnь dmes irdermen,
Dustьm utьn syndermen Doşmanьm utьn jandьrman /I/
Yzem dimas namartke /2/ Appaq byz at mendermen,
Tuqsansьz jibe/3/suldьrman, Aslьn soramaj aş birmen.
Jaralьştan asavmьn /4/ Busalaq bulsa tuqtamam,
.............
Qaraqajdan biekmen, Davьl erse de qajьlman,
Qajnaşьp betken /5/botaqmьn Baltalasa da ajrьlman.
Tьltьŋnaqan /6/ kerence atlь, Qadьravnь jьqqanmьn/7 /
Jaqasь altьn kirevke Jaqalaşьp jьrtqanmьn.

---

1/ Şьrpь 1833 nce jьlda qьna cьqqan. Aŋaca utnь kybesence syndermice saqlaqannar. Ber qaile jaki ber devletneŋ saqlap utьn syndery ul qaile jaki devletneŋ xalьqьn ylerge meçbyr ity belen ber sanalqan, suqьş vaqtьnda doşman jaqnьŋ şeherendege utnь syndery ocen yzene mexsus qeskerler bulqan.
2/ Namart-keşeleksez adem/, na-merd/, 3/Jibe-suqьş qoralь.
4/ Asav- keşe qulьna ileşmegen, qьrьi, vexşi. 5/Qajnişьp betken-cьrьş 6/ Tьltьŋlaqanterle jaqqa borьla torqan
7/ Monda ajtelgen Qadьrav.


Бу фоторәсемдә сурәтләнгән кешеләрнең берсе татар укучыларына асруча таныш. Ул — Хөсәен Ямашев хәзрәтләре. Аның вафатыннан соңгы язмышы бәхетле булды: эшчәнлеге турында китапларда һәм башка төр тарихи хезмәтләрдә әледән-әле телгә алып үтелде, исеме урамнарга бирелде һ. б. Хәер, аның шәхесе шактый катлаулы һәм каршылыклы иде һәм ул яңа күзлектән торып карауны таләп итә. Ни генә булмасын, ул катып калган большевик түгел иде; ә кем белә, 17 нче елга кадәр яшәсә, мөгаен, «кыска курслар» кысасына да сыймас иде.

Ләкин бу очракта сүз аның хакында түгел. Рәсемдә һәрберсе аерым тукталып сөйләрлек хөрмәткә ия булган өч хатын-кыз бар. Апалы-сеңелле Мәдинә белән Әминә, танылган мөгаллим-педагог Ибраһим Терегуловның кызлары татар яшьләре иҗтимагый хәрәкәтендә башлап йөрүчеләр булып тарихка кереп калдылар. Әминә үз вакытында Сәгыйт Рәмиевнең кайнар мәхәббәтен яулап алган кыз, шагыйрь аңа шигырьләрен һәм пьесасын да багышлый. Ә сул яктан караганда, беренче булып Хәдичә Зариф кызы Бадамшина басып тора. Дөресен генә әйткәндә, бу рәсем аның рухына багышлап басыла да инде. XX гасырның беренче чирегендә татар иҗтимагый хәрәкәтенең иң күренекле эшлеклеләреннән саналган Хәдичә ханымга, кызганычка каршы, күп кайгы-хәсрәтләрне — һәм өстенә пычрак атулар, кулга алыну һәм сөргенгә озатылуларны — кичерергә туры килә. Ләкин ул бирешми, картлык көненә чаклы аек акыллы һәм киң күңелле шәхес булып кала. Алай гына да түгел, шайтан каһәрләгән Себер сөргенендә дә, үзенә никадәрле генә авыр булмасын, башкаларның хәлен җиңеләйтергә омтылып яши. Аның яшьлеге татар дөньясына бик күп күренекле кешеләр биргән Чистай якларында үтә. Аның абыйсы Бадамшин Дәүләт Думасының ике чакырылышына депутат булып сайлана. Язмыш аңа ике талантлы шәхес белән очрашу шатлыгын бүләк итә. Беренчесе — иртә үлеп киткән Хөсәен Ямашев. Икенчесе — танылган дәүләт эшлеклесе, Казакъстанның Мәскәүдәге беренче вәкиле, Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган казакъ егете Вәлидхан Таначев. Кулга алу һәм сөргеннәр аерып торган еллардан башка гомерләрен алар иңгә-иң торып, бик бәхетле итеп үткәрәләр. Хәдичә ханым «Урал» газетасен чыгаруда актив катнаша, 1917 елда Учредительное собраниегә кандидат була. Гомумән, Вәлидхан Таначев белән аның турында журналыбызның алдагы саннарының берсендә иркенләбрәк сөйләрбез.

Рәсемнәрдә (сулдан — уңга): **Хәдичә Зариф кызы Бадамшина, Әхмәтҗан хәлфә Мостафинның улы Г. Мостафин, Мәдинә Терегулова, Әминә Терегулова, Хөсәен Ямашев һәм әзербайҗанлы иптәш Меликов.**

Сәхифәне журнал өчен тарих фәннәре кандидаты

Булат **СОЛТАНБӘК** әзерләде.



# ТӨРКИЯ ИЛЧЕСЕ — «ЗАМАН»

**ZAMAN**
**(ЗАМАН)**
**ТАТАРСТАН**

"Телдә фикердә эштә берлек"
И.Гаспралы

Халыкара иҗтимагый-мәдәни гәзит

---

Татарстанның матбугат мәйданы торган саен киңәя бара — быел апрель аенда татарча гәзитләр сафына «Заман» да килеп кушылды.

«Заман»ның төп нөсхәсе Истанбул шәһәрендә зур форматта 16 бит күләмендә көн саен басыла. Ул Төркиянең меңнән артык исемдә чыга торган шундый басмалары арасында абруйлы урын алып тора — берьюлы ике йөз меңләп гаиләгә барып керә. Төркиядән тышта яшәүче төрекләр һәм башка төрки халыклар өчен «Заман» соңгы вакытта үзенең җирле басмаларын чыгарырга керешге — алар хәзер Алмания, Болгария, Әзербайҗанда — саф төрекчә; Казагыстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстанда яртылаш шул республика төп милләтләре телләрендә, Башкортстанда — башкортча, татарча, төрекчә басыла; бездә исә гәзитнең чиреге — төрекчә, калган битләре татарча дөнья күрә.

«Заман»ның максаты — укучыларыбызны Төркия иле белән таныштыру, аның тарихын, мәдәниятен, фәнен, динен, сәясәтен, икътисадын, халыкара бәйләнешләрен яктырту. Дөнья вакыйгаларына Төркия сәясәте күзлегеннән карап бәя бирү.

«Заман»ның тагын бер иң әһәмиятле бурычы — төрки җөмһүриятләрне, төрки халыкларны Төркиядә таныту, илләребез арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә өлеш кертү, кардәш халыклар арасына дуслык күпере салу. «Заман» төрки, мөселман халыклары казанышларын күрсәтүгә, алар бәйләнешын киңәйтүгә күп әһәмият бирә, әмма шул ук вакытта башка милләтләргә дә хөрмәт белән карауны һәм аңлашып тату яшәүне кайгырта.

Төрек халкы бөтен дөньяда танылган күп кенә әдәбият һәм сәнгать әсәрләре иҗат итте. «Заман»ның янә бер бурычы — шуларны татар укучысына туган телендә җиткерү. Ләкин ихсләнмәгез: гәзитебездә татар мәдәнияте үрнәкләренә дә урын бирәчәкбез. Аларның кайберләрен Истанбул басмабызда файдалану да күздә тотыла.

«Заман» Татарстанда быел зур форматта 4 бит күләмендә айга ике мәртәбә чыгарыла, ул Татарстан вакытлы матбугат каталогына 54155 индексы белән теркәлгән, аңа язылу өзлексез дәвам итә. Шул ук вакытта без аны 1994 елда атналык гәзит итеп чыгарырга әзерләнәбез, ул БДБ илләре вакытлы матбугат каталогы кушымтасына шул ук индекс белән кертелә. Киләсе елда аңа Татарстаннан читтә яшәүчеләр дә язылa алачак. 6 айлык бәясе Татарстанда — 1014 сум, аннан тышта — аз гына артыграк булыр.

Хөрмәтле укучыбыз! «Заман» гәзите сезнең өчен чыга, ул тагын да кызыклырак булсын өчен киңәшләрегезне һәм тәкъдимнәрегезне, хатларыгызны көтәбез. Хәбәрләшер өчен адресыбыз: ***420066, Казан шәһәре, абунә тартмасы — 69. Килер өчен адресыбыз — Казан, Декабристлар ур. 2. 4 кат. «Заман» гәзите.***

Киләчәктә «заман»дашлар булып яшик!

«Заман» редакторы
**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

Шушы айның ахырында күренекле драматург Риза Ишморатның тууына 90 ел тула.

Риза Ишморат (Риза Фәхретдин улы Ишморатов) 1903 елда, хәзерге Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында туа. 1913 елда аның әтисе, гаиләсен алып, Актаныш районының Уразай авылына кайта. Булачак драматург әнә шул авылда, алты яшеннән мәктәпкә йөреп, укырга-язарга өйрәнә. Аннары ул Янбарыс мәдрәсәсендә һәм Сараш авылындагы земство мәктәбендә урысча-татарча белем ала. 1916—1918 елларда укуын Минзәләдә һәм Уфаның «Госмания» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. 1920 елда Уфада педагогик курслар тәмамлый һәм эшли башлый.

1923 елда Риза Ишморат, Казанга килеп, театр техникумына укырга керә. 1926 елда, аны тәмамлагач, Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли башлый. Шушы елларда ул драматург буларак та таныла. «Йокы патшалыгында» һәм «Өтек философ» исемле драма әсәрләрен 1926 елда ул үзе сәхнәгә куя. Моннан тыш «Данлы чор», «Мәдинә», «Ил өчен», «Ватан» һ. б. әсәрләре дә сугыш алды елларында төрле театрлар сәхнәсендә куела.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Риза Ишморат фронтка китә һәм «Ватан намусы өчен» газетасы белән бергә Воронеждан Берлинга кадәр авыр юл үтә. Берлиндагы урам сугышлары вакытында авыр яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен күп орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Драматург сугыш елларында «Дошман лагеренда», «Ватан кызлары», «Кайту» кебек патриотик әсәрләр иҗат итә.

Сугыштан соң Риза Ишморат тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә. Ул күп санлы драмалар һәм комедияләр яза, татар халкының данлы уллары Муса Җәлил, Әсгать Җиһаншин кебек батырларның каһарманлыгын иҗатта гәүдәләндерә. Г. Тукай һәм аның замандашларына багышлап «И мөкатдәс моңлы сазым» исемле драма иҗат итә.

Риза Ишморат — кырыкка якын сәхнә әсәре авторы. Аның драма һәм комедияләре төрле елларда башка милләт театрлары сәхнәләрендә дә уйнала килде.

Язучы шулай ук әдәби тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнде, ул Вс. Иванов, М. Горький, Д. Фонвизин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Күренекле драматург Риза ага Ишморат үзенең 90 яшен тутырган көннәрдә дә актив иҗади тормыш белән яши. Матбугатта истәлекләр һәм кызыклы мәкаләләр бастыра. Ул каләмдәшләре белән тыгыз элемтәдә торып, заман сулышын тоеп яши.

**Аксакал әдибебезне барлык каләмдәшләре һәм «Казан утлары» журналын укучылар исеменнән олы юбилее белән кайнар котлыйбыз. Аңа яңа иҗат уңышлары һәм сәламәтлек, яхшы кәеф телибез!**

РЕДАКЦИЯ.

## ПРЕЗИДЕНТ САРАЕНДА ОЧРАШУ

Татарстан Җөмһүрияте Илбашы М. Шәймиев Казан Кремлендә АКШ һәм Россия Федерациясе галимнәре — Гарвард университеты профессоры Д. Горовиц, милләтара конфликтларны җайга салу буенча проект директоры Б. Аллин, Россия Фәннәр Академиясенең этнология һәм антропология институты директоры В. Тишков әфәнделәрне кабул итте.

Кунаклар АКШ гражданнарының Татарстан белән нык кызыксынулары турында әйттеләр, республикабызның милләтара проблемаларны цивилизацияле хәл итүдә ачык мисал булуын билгеләп үттеләр. Татарстан Конституциясендәге ике дәүләт теле һәм ике гражданлык турындагы маддәләрне югары бәяләделәр.

## ФЕДЕРАЛИЗМ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

6—8 сентябрь көннәрендә Казанда «Федерализм: глобаль үлчәмнәр һәм Россия үлчәмнәре» дигән халыкара гыйльми-гамәли конференция булып үтте. Федератив дәүләт төзелешенең тормышта ничек булырга тиешлеге турында фикер алышуларда АКШ, Германия, Һиндстан, Испания, Эстония, Бельгия, Италия, Иордания, Төркия, Франция кебек чит илләрдән һәм БДБ илләреннән килгән күпсанлы галимнәр катнашты.

Әлеге форум Татарстанның позициясен дөньяга танытуда, аны тагын да тотрыклырак итүдә зур роль уйнады.

## Ф. МӨХӘММӘТШИНГА — АКАДЕМИЯ ДИПЛОМЫ

Федерализм мәсьәләләре буенча Казанда үткәрелгән халыкара конференция вакытында Татарстан Югары Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшинга Халыкара информатизация Академиясенең әгъза-корреспонденты итеп сайлануы турында диплом бирелде. Дипломны Академиянең беренче вице-президенты, Ленин премиясе лауреаты Э. Евреинов тапшырды.

## ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

27 августта Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиев әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле казанышлары өчен язучы Р. Мөхәммәдиевка һәм рәссам Ә. Фәтхетдиновка җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен тапшырды һәм аларны кайнар котлады.

## ЭШЛЕКЛЕ ОЧРАШУ

27 августта Президент М. Шәймиев бер төркем язучыларны кабул итте, дустанә шартларда ике сәгатьтән артык әңгәмә үткәрде. Татар әдәбиятының киләчәге ничек булыр? Язучыларның яшәү мөмкинлекләре, иҗат шартлары нинди? Китап бастыру һәм каләм хакы түләү мәсьәләләре ни хәлдә? Чыннан да, иҗат интеллигенциясе вәкилләрен борчый торган мәсьәләләр бик күп хәзер. Иҗади кризистан, матди бөлгенлектән чыгу юллары турында байтак эшлекле фикерләр әйтелде. Дәүләт тарафыннан реаль ярдәм күрсәтү чаралары билгеләнде (гонорарларны арттыру, мохтаҗ ветеран әдипләрнең матди ягын кайгырту, культура өлкәсенә бюджеттан чыгымнарны арттыру һ. б.). Очрашуда шулай ук министрлар, нәшрият җитәкчеләре, Президент һәм Министрлар кабинетының җаваплы вәкилләре катнашты.

## ЧАЛЛЫДА — ЮНЕСКОның ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

14—18 сентябрь көннәрендә Чаллыда, «КамАЗ» мәдәният сараенда, ЮНЕСКОның «Яшь шәһәрләр мәдәнияте» дигән гыйльми-гамәли конференциясе булып үтте. Аның эшендә 16 дәүләттән 300 дән артык вәкил, галим катнашты.

Конференциядә катнашучыларга ЮНЕСКОның генераль директоры Фредерико Майорның һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең котлау сүзләре игълан ителде.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР АССАМБЛЕЯСЕ КОРЫЛТАЕ

Чувашстан башкаласы Чабаксарда Төрки халыклар ассамблеясенең III корылтае булып узды. Аңа 14 халыктан йөзгә якын делегат килгән иде. Котлау сүзләре белән Татарстаннан җөмһүриятебезнең Аксакаллар шурасы рәисе, Ш. Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыятенең почетлы президенты Р. Хәмидуллин, Татарстан халык депутаты, язучы Р. Вәлиев, Башкортстан халык депутаты Р. Таҗиев һ. б. чыкты.

Корылтайда ассамблеянең устав һәм программасына үзгәрешләр кертелде, оешманың байрагы кабул ителде. Корылтайда яңа җитәкчелек тә сайланды.

## ТАТАРСТАН НЕФТЕНӘ — ЯРТЫ ГАСЫР

Татарстанда «кара алтын» чыга башлавуга 50 ел тулу уңаеннан, Әлмәттә, нефть чыгаручыларның мәдәният һәм техника сараенда, зур тантана булды. Анда төрле буын нефтьчеләре, Рәсәйнең төрле төбәкләреннән һәм Америка, Төркия, Германия,

Франция, Италия, Венгрия кебек чит илләрдән килгән купсанлы кунаклар катнашты.

Татарстан нефтьчеләрен олы бәйрәм белән Татарстан Президенты М. Шәймиев котлады. Аннары Россия хөкүмәте башлыгы В. Черномырдинның котлавы бәян ителде. Нефтьчеләрне шулай ук Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Россия халык депутаты Р. Мөхәммәдиев иҗат оешмалары исеменнән котлады һәм «Татнефть» берләшмәсенә (генераль директоры — Р. Галиев) Россия Югары Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды.

## ХАЛЫКАРА СПОРТ ФЕСТИВАЛЕ

28 августта Татарстан Җөмһүриятенең мөстәкыйльлегенә 3 ел тулуга багышлап, Казанда Халыкара спорт фестивале үткәрелде. Татарстан физкультура һәм спорт комитеты, Мәдәният министрлыгы һәм «Ватаным Татарстан» газетасы тарафыннан оештырылган әлеге бәйрәмдә Англия, Төркия, Башкортстан, Марий-Эль, Екатеринбургтан һәм җөмһүриятебезнең төрле төбәкләреннән килгән спортчылар көч сынашты. Спортның күп кенә төрләре буенча ярышларда җиңүчеләргә Татарстан Президенты, Республикабыз Югары Советы һәм Министрлар Кабинетының мәртәбәле призлары бирелде. Командалар арасыннан беренче урынга Татарстанның Теләче районы (хакимият башлыгы — Рөстәм Кәлимуллин) лаек булды. Президент М. Шәймиев җиңүчеләргә 25 миллион сумлык акча чеклары тапшырды.

## «ВАТАН» ҖӘМГЫЯТЕНДӘ — КЫТАЙ ТАТАРЛАРЫ

Сентябрь аенда «Ватан» җәмгыятендә Җир шарының төрле кыйтгаларында яшәүче Кытай татарларының кызыклы очрашуы булып үтте. Түгәрәк өстәл артында барган дустанә-дулкынландыргыч сөйләшүләрдә АКШның Сан-Франциско шәһәреннән әниле-уллы Өметҗиһан ханым белән Җүнәйт Чапан оглы, Төркиянең Истанбул шәһәреннән Фәрит Бичури, Кытайның Синҗан (Синьзянь) автономияле округыннан Зариф Дулат һәм Казан университеты галиме Миркасыйм Усманов катнаштылар. Әңгәмә барышында сүз, нигездә, үзара аралашып-ярдәмләшеп яшәү, киләчәктә элемтәләрне тагын да ныгыту турында барды.

## «ШҮРӘЛЕ» ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ

Казанда беренче татар нәфис кинофильмының «бәби туе» булып үтте. Ул кинотасма мәшһүр шагыйребез Г. Тукайның «Шүрәле» әсәренә нигезләп эшләнгән иде. Кыска метражлы әлеге фильмда төп рольләрне танылган сәхнә осталарыннан Шәүкәт Биктимеров, Равил Шәрәфиев, яшь артистка Зәйнәп Фәхретдинова, әтиле-уллы Камил һәм Марат Бикмөхәммәтовлар башкара.

Фильмның режиссеры, сценарий авторы — Камил Бикмөхәммәтов. Татарча сөйләшүче «Шүрәле» тиздән экраннарда пәйда булачак.

## КЫРЫМ-ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕРЛӘШӘ

Соңгы өч елда кырым-татар язучыларының туган телендә Кырымда бер генә китабы да дөнья күрмәгән. Шуны истә тотып, кырым-татар язучылары үз оешмаларын булдырдылар. Ул Кырымда яшәүче 25 әдипне һәм читтәге 30 дан артык язучыны берләштерә. Язучылар оешмасы туган телдә китаплар чыгару белән шөгыльләнәчәк.

## «САНДУГАЧ» — АВСТРИЯДӘ ЯҢГЫРЫЙ

Танылган пианист, якташыбыз Рэм Урасин Австриядә үткән Шопен фестивалендә атаклы татар композиторы, Татарстанның Дәүләт гимны авторы Рөстәм Яхинның «Сандугач» көен уйнады. Тамашачылар аны алкышлап кабул иттеләр.

## ГАЛИ АКЫШ ИСЕМЕНДӘГЕ МӘКТӘП

Чаллыда татар мәктәпләре саны арта бара. Быел биредә шундый 12 мәктәп эшли. Бу — былтыргыдан 5 кә артык. Яңа салынган татар мәктәпләренең берсенә быел татар милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, Бөтендөнья Татар Лигасының Президенты, Татар халкы Милли Мәҗлесенең почетлы депутаты Гали Акыш исеме бирелде.

## КАШАПОВЛАР ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Чаллыда яшәүче кәсәбәче бертуган Кашаповлар ошбу ел башында «Шәһри Казан» газетасы битләрендә милләт мәнфәгатьләрен кайгырткан һәм туган Татарстаныбызның мөстәкыйльлеген ныгытуга юнәлдерелгән иң яхшы очеркларга, публицистик һәм башка кызыклы язмаларга ачык конкурс игълан иткәннәр иде. Үткән айлар эчендә әлеге абруйлы премиягә күренекле галимнәребездән — Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, профессор Индус Таһиров, тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов, техник фәннәр докторы Азат Зыятдинов, педагогия фәннәре кандидаты Мәхмүт Әхмәтҗанов, язучыларыбыздан — академик Әбрар Кәримуллин, Шамил Рәкыйпов, Таһир Нурмөхәммәтов, Дамир Гарифуллин, журналистлардан — «Сөембикә» журналының җаваплы сәркатибе Эльмира Әдиятуллина, «Шәһри Казан» газетасы каләм осталарыннан Әгъзәм Фәйзрахманов, Вакыйф Нуриев, Барис Айтуганов, Наил Ганиев лаек булдылар.

## БЕРЕНЧЕ ТАТАР МУЗЫКА МӘКТӘБЕ

Быел Казан шәһәренең Киров районында беренче татар музыка мәктәбе ачылды. Анда татар композиторлары иҗаты һәм музыка фольклоры җентекләп үзләштереләчәк. Фортепиано, скрипка классларында шөгыльләнүдән тыш, укучылар милли музыка коралларында — кубыз, курай һәм гармунда уйнарга да өйрәнәчәкләр.

# ҖИР ШАРЫНДА — «БИШЕК ҖЫРЫ»

Ошбу әсәрне иҗат иткән шәхес — Камил Вәлиәхмәт углы Муллашев — казакъ җирендә инде күптән танылган татар рәссамы. Гәрчә үзе 1944 елда Кытай җөмһүриятенең Синҗан (Синьзянь) провинциясенә караган Өремҗе шәһәрендә туса да, аның тормышы һәм иҗат юлы тугандаш Казагыстан белән үтә тыгыз бәйле. 1961 елда Өремҗедә сәнгать институтын тәмамлагач, Камил әфәнде Алма-Ата шәһәренә күчеп килә һәм шунда төпләнеп кала.

Рәссам К. Муллашев иҗади полотноларында рәсем сәнгатенең үзенә генә билгеле булган серле һәм гаҗәеп мөмкинлекләрен күңеле теләгәнчә тулырак, киңрәк ачарга омтыла. Аның һәр яңа әсәре — бүгенге көндә кешелек дөньясын борчый, уйландыра торган житди, актуаль күренешләр, хәлләр турында.

Реализм һәм авангард стильләренең үрелешеннән торган яңа стиль — Камил Муллашевның үз эш алымы. Аның «Җир һәм Су» триптихы, «Арал фаҗигасе», «Сүрия һәм Әфганстан» кебек композицияләре нәкъ шундый стильдә иҗат ителгәннәр. Синҗан провинциясендә яшәгәндә, балачагында һәм үсмерчагында хәтеренә сеңеп, күңеленә уелып калган онытылмас хатирәләр, Мәскәүдә Суриков исемендәге сәнгать институтында укыган чорында (1972—1978) рус һәм дөнья рәссамнары традицияләрен өйрәнү, Казагыстан туфрагында җирле халык һәм төрки халыклар мәдәният-сәнгате белән тирәнтен аралашу, аларның тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт, тел-төс үзенчәлекләре белән якыннан танышу Камил әфәндегә үз мохитен тудыруда, рәссам буларак тиешле югарылыкка күтәрелүдә зур булышлык күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, К. Муллашевның иҗаты ил һәм дөнья күләмендә танылу ала. 1981 елда ул Ленин комсомолы премиясенә лаек була, «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1984 елда исә Камил әфәнденең иҗади эшләре Париждагы атаклы Гранд-Пале Салонының көмеш медале белән бәһаләнә.

Казагыстанның әйдәп баручы рәссамнарыннан саналган татар егете К. Муллашевның тылсым көченә ия полотнолары Санкт-Петербургта оештырылган «ТАТАРТ» күргәзмәсендә дә күрсәтелеп, тамашачыларның күңелендә зур кызыксыну һәм кайнар рәхмәт хисләре уятты. (Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Камил әфәнде белән бергә ошбу мәртәбәле күргәзмәдә Казагыстанда яшәүче тагын бер талантлы рәссам — милләттәшебез Бәхтияр Табиев тә үзенең иҗади эшләре белән катнашып, татар дөньясын һәм үзләре яши торган кардәш җөмһүриятне данга күмде).

Инде К. Муллашевның «ТАТАРТ» күргәзмәсендә танылу алган «Бишек җыры»на киңрәк тукталыйк. Йокыга талыр алдыннан җаннарны иркәли торган назлы Ана җырын кемнәр генә хәтерләми икән?! Ул җыр, колакларда чыңлап, безне гомер буе озата бара... Рәссам, шул хакта ишарәләп, яшәешнең төп чыганагы булган Күк, Җир, Су һәм һәр өчесенең дә дусты саналган Кош образлары аша күңелләргә үз фәлсәфәсен салырга тели. Билгеле булганча, борынгы төрки халыклар фольклорында Кош образы кешенең тәненнән аерылып киткән җаны рәвешендә сурәтләнә. Полотнода гәүдәләндерелгән Кошлар, канатларын киң җәеп, иксез-чиксез киңлекләрдә очалар. Изге кошлар алар — борынгы Иран, Һинд, Урал һәм Кама буе халыкларының сынлы һәм гамәли сәнгатендә еш очрыйлар.

К. Муллашев картинасының үзәгендә — утрауда үзенә оя корган балалы Кош — хатын-кыз образы. Ул, нәниен иркәләп, бишек җыры башкара. Утрауның тирәягында шундый ук Кошлар: берәүләре — хатын-кыз рәвешендә, икенчеләре — ир-ат кыяфәтеннән... Кыскасы, биредә тынгысыз тормышның нәкъ үзе, яшәешебез турында, мәңгелек хакында уйланулар. Рәссам бу хакта полотнодагы бихисап төсләр гаммасы, төрки халыкларга хас сурәтләү алымнары аша әйтеп бирергә омтыла...

... Рәссам Камил Муллашевның иҗади эшләрен АКШ, Франция, Германия, Дания һәм башка күп кенә илләрнең күргәзмәләрендә, музейларында еш күрергә мөмкин. Киләчәктә Татарстан Җөмһүрияте һәм Казан тамашачылары да милләттәшебезнең иҗаты белән якыннанрак, үзебездә оештырылган шәхси күргәзмәсендә танышырлар, дигән изге өметтә каласы килә.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА.**

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосурәте

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте

# БАШЛАНДЫ!

Әйе, быелның 15 сентябреннән 1994 елның беренче яртыеллыгына газета-журналларга язылу башланды. Мәгълүм булганча, ул бик авыр шартларда бара. Кәгазь һәм ягулык бәяләре, элемтә хезмәте, типография чыгымнары арту сәбәпле, язылу хаклары да текә «күтәрелеш» кичерә...

Ләкин шулай да без ышанабыз: «Казан утлары»н даими укып килгән укучыларыбыз өр-яңа әдәби әсәрләр, кызыклы язмалар уку шатлыгыннан, журнал белән дуслыктан үзләрен мәхрүм итмәсләр. Менә шуна да «Казан утлары»н алдырырга теләүче дусларыбыз өчен әзер квитанция тәкъдим итәбез. Тулы адресыңны, исем-фамилияңне язып, аны тизрәк элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Әдәби-иҗтимагый җәһәттән татар халкының төп журналы саналган «Казан утлары» алга таба да рухи юлдашыгыз булсын!

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов:

на 1994 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на газету / журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на 1994 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, инициалы)

# БҮЛӘККӘ — «КАЗАН УТЛАРЫ»

«Тизрәк» дип әйтүебезнең хикмәте шунда ки, 1 ноябрьдән көндәлек матбугатка язылу бәяләренең тагын да артуы көтелә. Шунлыктан журналга сентябрь-октябрь айларында язылып калу хәерлерәк. Кемнәр иртәрәк язылса — шулар отачак!

Форсаттан файдаланып, без район хакимияте башлыклары, колхоз-совхоз, предприятие-учреждение җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәбез: күркәм эшләре өчен, хезмәт алдынгыларын «Казан утлары» журналы белән бүләкләү гадәткә кереп китсен иде. Чөнки журналның 6 саны — әр-яңа алты китап, өй китапханәгезгә саллы бер хәзинә дигән сүз.

Шунысын да искәртеп китик, күп кенә басмаларның бәясе 5—6 мең тирәсе булганда, безнең журналга язылу бәясе чагыштырмача арзанрак.

1994 елның беренче яртыеллыгына «Казан утлары»на язылу бәясе Татарстанда — 1980 сум. Индексыбыз — 73210.

Онытмагыз һәм оттырмагыз!

**ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!**

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).


- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

# ЯҢА КИТАПЛАР





**Әхсән Баянов. Сайланма әсәрләр. Ике томда, I том. Повестьлар. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1993.**

Укучыларның яраткан язучысы Әхсән Баяновның ике томлык Сайланма әсәрләре басылып чыкты. I томга әдипнең «Тау ягы повесте», «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог», «Аязучан болытлы һава» әсәрләре кергән. Аксакал әдибебез Әмирхан ага Еники китапта урнаштырылган мәкаләсендә язучы турында болай ди: «Миңа калса, Әхсән Баян табигате белән эзләнүчән шәхес, ягъни кайчандыр тапкан һәм таптап өйрәнелгән сукмактан йөрүче язучы түгел. Аның һәрбер яңа әйберсе эзләнүдән башланадыр кебек. Тема сайлаудан алып, формасын табуга кадәр...»

**Әхсән Баянов. Сайланма әсәрләр. Ике томда, II том. Повестьлар, лирик парчалар. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1993.**

Сайланма әсәрләрнең II томына түбәндәге проза әсәрләре кергән: «Төлке тоту кыен түгел», «Тавыш — табигать бүләге», «Аргы яр», «Мәңгелек бәхәс». Китапта шулай ук әдипнең кечерәк күләмле әсәрләре — лирик парчалар да урнаштырылган. Ахырда Әхсән Баяновның басылып чыккан китапларының исемлеге бирелгән.

*Ике томлыкның махсус редакторы Фәрваз Миңнуллин, рәссамы Ильяс Субаев.*




Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 30 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог